Татар әдәбияты 11

Татар әдәбияты
11

Ф. М. МУСИН, З. Н. ХӘБИБУЛЛИНА,
Ә. М. ЗАКИРҖАНОВ

Татар әдәбияты

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
11 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

(татар балалары өчен)

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән*

Яңадан эшләнгән өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 373.167.1:811.512.145*11
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
М78

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Мусин Ф. М.

М78 Татар әдәбияты : Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 11 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен) / Ф. М. Мусин, З. Н. Хәбибуллина, Ә. М. Закирҗанов.— Яңадан эшләнгән өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2006.— 462 б.
ISBN 5-7761-1635-X

ISBN 5-7761-1635-X

© «Мәгариф» нәшрияты, 2000
© «Мәгариф» нәшрияты, 2006, үзгәрешләр белән

Хөрмәтле укучылар!

Сез X сыйныфта татар әдәбиятын тарихи планда өйрәнә башладыгыз һәм VII гасырдан алып XX йөз башында булган Февраль, Октябрь революцияләренә кадәр яшәп иҗат иткән күренекле әдипләр, аларның иң яхшы әсәрләре белән таныштыгыз. Тарихи вакыйгаларга, халкыбыз тормышындагы фаҗигаләргә бәйле рәвештә әдәбият та каршылыклы үсә, югалтулар кичерә. Әмма ул, асыл максатына тугры калып, кешелеклелек, гаделлек, сабырлык, әхлаклылык һ.б. кыйммәтләрне яклау һәм саклауны төп темалар итеп ала.

Бу уку елында исә әдәби тарихыбызның шактый үзенчәлекле дәвере — 1917 елдан соңгы чоры белән танышачаксыз. Аның 80 нче еллар уртасына кадәрге өлеше «Татар совет әдәбияты» дигән исем белән атап йөртелде. Элекке СССРдагы башка халыклар әдәбиятындагы кебек, аның да төп үзенчәлекләреннән берсе — социализм тудырган һәм аңа хезмәт итүче яңа әдәбият итеп каралуында. Хакимият идеологиясе куйган таләпләргә җавап бирү белән бергә, ул үз халкының реаль тормышын, рухи дөньясын, милли хасиятләрен һәм уй-омтылышларын да чагылдыруны дәвам итте. Бу чор әдәбиятын хәзер яңача өйрәнү бурычы алга куела. Чөнки моңа кадәрге идеологик принциплар аны бөтен тулылыгында һәм объектив бәяләүгә мөмкинлек бирмәде. Шуңа күрә әдәбиятыбызның элек күрсәтелә алмаган яклары, үзенчәлекләре билгеләнә, шактый вакытлар «ак тап» булып килгән, ягъни онытылуга дучар ителгән әдәби әсәрләр, фактлар әдәбият тарихына кайтарыла.

Әдәби әсәрләрне өйрәнү, нигездә, ике максатка хезмәт итә. Берсе — иң яхшы сүз сәнгате үрнәкләрендә урын алган вакыйга-күренешләр аша халык тормышы белән танышу, безгә

кадәр яшәгән кешеләрнең шатлык-борчуларын күрү, аңлау, аларның хис-кичерешләрен үзебез аша үткәрү, матурлыкка шатлану, начарлыкка нәфрәтләнү. Икенчесе — мөстәкыйль рәвештә әдәби әсәрне анализларга, аны бәяләргә өйрәнү. Дәреслек-хрестоматиядә, әсәрләрнең төп үзенчәлеген билгеләргә ярдәм иткән сорау һәм биремнәр белән бергә, авторның төп идеясен аңлату юнәлешендә нәтиҗәләр дә ясалды. Монда бирелгән әсәрләр яки өзекләр сезгә матур әдәбиятны тирәнрәк аңларга, аны киңәшчегез, рухи ярдәмчегез итәргә мөмкинлек бирер дип ышанабыз.

Авторлар

20 нче ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре җиле җәмгыять тормышының барлык өлкәләренә, шулай ук әдәбиятка да кагылмый калмый. Аларның беренчесе һәм бик кыска гомерлесе, илдә демократик тәртипләр урнаштыруны күздә тотуы аркасында, татар әдәбиятының милли максатчан үсеше өчен киңрәк мөмкинлекләр ача. Шулардан файдаланып, әдипләр төрле юнәлешләрдә эзләнә башлыйлар. Әлеге революция белән рухланып, М. Гафури, мәсәлән, программа характерындагы «Татар байрагы» шигырен яза һәм анда татарның 400 ел колониаль хәлдә яшәгәннән соң, ниһаять, азатлыкка ирешүе идеясен романтик пафос белән чагылдыра. Бу шигырь белән бер вакыттарак язылган икенче бер әсәрдә — Ф. Әмирханның «Март каһарманы» хикәясендә исә — татар дөньясында революция йогынтысында хасил булган кайбер үзгәрешләргә тәнкыйтьчел караш өстенлек ала. Ачыграк әйтсәк, биредә әдип әлеге үзгәрешләр чорында татар мәгыйшәтендә бермә-бер күбәеп киткән милли каһарманнар арасында тыштан милләт хадиме булып күренеп, асылда үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан ялган «каһарманнар» да очравын сатира ярдәмендә ача. Бу ике әсәр, тулаем алганда, алга таба Совет чоры әдәбиятында мөһим урын алачак ике юнәлешкә нигез салалар. Аларның берсе — яңа җәмгыятьне романтик планда, ә икенчесе аны тәнкыйтьчел позициядән торып сурәтләү белән бәйләнгән иде.

Мондый милли-демократик характердагы эзләнүләргә бераздан октябрь вакыйгалары чик куя. Яңа большевистик идеология илдәге әдәбият-сәнгатьләрне үз максатларына хезмәт иттерә башлый. Табигый, туган илендә калган татар әдипләре дә шушы идеология кысаларында иҗат итүгә күчәләр. Аларның мөһаҗирлеккә киткәннәре генә үткәндәге әдәби традицияләр рухында язуларын дәвам итә. Шул нигездә яшәү офыгы

тагын да киңәйгән татар әдәбияты, гомумән алганда, төрле идеологик юнәлешләрдә эзләнүләр алып бара. Мөһаҗирлектәге әдәбиятның төп юнәлешен Г. Исхакый иҗаты аеруча тулы чагылдыра. Яңа тарихи шартларда татар милли әдәбияты вазифасын үз өстенә алып, ул милләт язмышына караган мөһим һәм борчу уята торган мәсьәләләрне яктыртуын дәвам итә. Әдипнең 20 нче елларда мөһаҗирлектә язган «Көз», «Җан Баевич», «Дулкын эчендә», «Өйгә таба», «Локман хәким» дигән әсәрләре шул хакта сөйли.

Совет илендәге әдипләр исә, инде әйтелгәнчә, яңа идеологиягә буйсынып, ул алга куйган бурычларны хәл итүгә керешәләр. Нәтиҗәдә әдәбият яңа тормышка йөз белән борыла. Революциянең беренче айларыннан диярлек әдипләр илдә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшне сурәтләүгә күчәләр. Бу көрәш, әдәбиятның төрле өлкәләрендә иҗат итүчеләрне — шагыйрьләрне, прозаикларны һәм драматургларны — бердәй кызыксындырып, башлыча романтик яки публицистик пафос белән яктыртыла. Моңа мисал итеп, М. Гафури, Ф. Бурнаш, Ш. Бабич, Г. Камал, С. Сүнчәләй, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил һәм башка шагыйрьләрнең күп санлы шигырь-поэмаларын, Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» һәм «Кызыл чәчәкләр», Ш. Камалның «Таң атканда», Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» кебек проза һәм драма әсәрләрен китерергә мөмкин.

20 нче еллар, илдәге гомум процесслардан тыш, татар дөньясы өчен ТАССР төзелү (1920), 1921 елгы ачлык, 1929 елда гарәп графикасын латин графикасына алыштыру кебек вакыйгалар белән дә характерлана, һәм болар әдәби процесска да билгеле бер эз сала. Ягъни Совет дәверен һәм революциягә кадәрге яшәешне шул чор рухында яктырту белән бергә, кайбер әсәрләрдә (мисал өчен, Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» һәм Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай» повестьларында, М. Гафуриның «Кеше ашаучылар» поэмасында яки Һ. Такташның «Югалган матурлык» пьесасында) илдә төзелә торган яңа җәмгыятькә теге яки бу планда тәнкыйтьчел караш та чагыла.

20 нче еллар әдәбиятын, аның аерым күренешләрен яки әсәрләрен хәзер үткәндәге мәгълүм идеологик кысалардан арынып һәм фәнни объектив рәвештә анализлау, бәяләү ихтыяҗы да туды. Монда бигрәк тә Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» һәм «Тирән тамырлар», Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе», «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар», «Күмелгән кораллар» һәм «Югалган матурлык» кебек

әсәрләре күздә тотыла. Шундый анализ әлеге әсәрләрнең реаль кыйммәтен һәм әдәбият тарихындагы урынын дөресрәк күзалларга мөмкинлек бирәчәк.

Гомумән алганда, 20 нче елларда татар әдәбияты, мөһаҗирлектә үзенең үткәндәге милли вазифасын дәвам итеп, ә Совет илендә яңа идеология кысаларына кертелеп, кайчак бу кысаларга сыешмыйча, революция тудырган системаны күпмедер тәнкыйть күзлегеннән дә карап яктырту юнәлешендә яши һәм үсә.

Хәзер исә шул елларда яшәп иҗат иткән олуг әдипләребез белән танышып үтәрбез.

Сораулар һәм биремнәр

1. 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре татар әдипләре иҗатына ничек тәэсир итә?

2. М. Гафуриның «Татар байрагы» шигыре белән Ф. Әмирханның «Март каһарманы» хикәясендә Совет чорындагы татар әдәбиятының нинди юнәлешләренә нигез салына?

3. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты татар әдәбиятында нинди урын тота?

4. Г. Ибраһимов һәм Һ. Такташ кебек әдипләр иҗатын яңача өйрәнү нигә кирәк?

5. 20 нче еллар әдәбиятының төп үсеш юнәлешләрен билгеләгән әсәрләрне атагыз һәм аларга анализ ясагыз.



Галимҗан Ибраһимов

(1887—1938)

Классик әдип, күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлын һәм «Яз башы»,«Алмачуар» хикәяләрен сез түбән сыйныфларда өйрәндегез. Бу уку елында язучының Октябрьдән соңгы иҗаты, аерым алганда, «Казакъ кызы» романы белән танышырсыз.

Галимҗан Ибраһимовның XX йөз башындагы иҗатын ике этапка бүлеп өйрәнәләр: 1907—1912 һәм 1913—1917 еллар. Башлангыч чор әсәрләрендә шәхес иреге, социаль тигезлек, милләт язмышы өчен борчыла. Әдип иске тәртипләргә, гаделсезлеккә каршы чыга. «Диңгездә», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» һ.б. әсәрләрендә реаль тормышка капма-каршы буларак романтик хыял дөньясы куела. Романтизм алымнарына нигезләнеп язылган «Яшь йөрәкләр» әсәре милли азатлык, рухи ирек мәсьәләләрен күтәрүе һәм сурәтләү чараларының байлыгы, психологизмның тирәнлеге белән аерылып тора. Алдагы елларда язылган әсәрләрендә реаль тормыш күренешләре өстенлек итә. Әдипнең иҗтимагый-сәяси карашлары үзгәрү аның иҗатында да чагылыш таба. «Карт ялчы», «Көтүчеләр»,«Безнең көннәр» һ.б. әсәрләрендә гади кешеләр язмышы, аларны бәхетле итү, социаль тигезлеккә, гаделлеккә ирешү юллары турында уйлану үзәктә тора. Шуңа да соңгысын бастырып чыгарырга рөхсәт бирелми.

Октябрь революциясен Г. Ибраһимов шатланып каршы ала. Бу вакытта ул крестьяннар мәнфәгатен кайгырткан сул эсерлар партиясендә була, бераздан большевиклар ягына чыга. 1917 елның ноябрендә Оештыру җыелышына (Учредительное собраниегә) делегат итеп сайлана. Ул таратылгач, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына эшкә күчә. 1919 елны

Г. Ибраһимов Казанга кайта һәм вакытлы матбугатны оештыру белән шөгыльләнә. «Эшче»,«Кызыл Армия»,«Безнең юл»,«Мәгариф» газета-журналларының беренче адымнары аның исеме белән бәйле.

1925 елны ул Мәгариф халык комиссариаты каршындагы гыйльми үзәк рәисе итеп билгеләнә һәм үзен оста оештыручы, зур галим итеп таныта.

Галимҗан Ибраһимов бөтен көчен илдә яңа җәмгыять төзүгә багышлады, ә үзе ахырдан инанып хезмәт иткән системаның корбанына әверелде. 1927 елдан каты авырып Кырымда яшәргә мәҗбүр булган Г. Ибраһимовны 1937 елда «халык дошманы» дигән нахак гаеп тагып кулга алалар һәм Казанга кайтаралар. Аның гомере 1938 елның 21 гыйнварында төрмә сырхауханәсендә өзелә.

* * *

Галимҗан Ибраһимов Октябрь революциясеннән соң да иҗат активлыгын киметми. Аның әсәрләре үткән мирас белән 20 нче еллар әдәбияты бәйләнешен тәэмин итте. «Яңа кешеләр» (1920) драмасында гражданнар сугышы чоры татар авылы кешеләре сурәтләнә. Тормыштагы, кешеләр аңындагы үзгәрешләр аша әдип киләчәккә ышанычын белдерә. Әмма ул, «канлы юл — изге юл» төшенчәсен кире кагып, гуманизм позициясендә кала. «Кызыл чәчәкләр» (1922) хикәясендә авылның төрле социаль катлавыннан чыккан биш егетнең язмышы сурәтләнә. Алар белән бәйле вакыйгалар аша автор үзара дуслык, милләт бердәмлеге мәсьәләсен күтәрә. «Алмачуар» (1922) хикәясендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтен ачуга бәйле җитди әхлакый проблемаларны билгели. Әдип гаделлек, чын ярату кебек сыйфатларның тирән эчтәлеген ачып сала. 1923 елда дөнья күргән һәм шул вакытта шактый кискен тәнкыйтькә очравы нәтиҗәсендә күп еллар онытылуга дучар булган «Адәмнәр» хикәясе, асылда, 20 нче еллар татар әдәбиятын идея-эстетик яктан баета. Совет системасын бары уңай яктан гына күрсәтеп һәм бәяләп килгән бер вакытта Г. Ибраһимов әлеге җәмгыятьтә җитди фаҗигаләргә дә урын булуын күрде. 1921 елгы ачлык бу әсәрдә яңа тормыштагы шундый фаҗигаләрнең берсе булып алга баса. «Тирән тамырлар» (1928) романында, бер яктан, үткәннең һәм бүгенгенең фаҗигале, каршылыклы күренешләре сыйнфый көрәш яссылыгында ачылса, икенче яктан, яңа хакимиятнең асыл сыйфатлары,

кешегә булган мөнәсәбәте Садыйк һәм аның якыннары белән булган хәлләргә бәйле күрсәтелә.

Әдипнең «Казакъ кызы» романы исә тугандаш казакъ халкы тормышын бөтен каршылыгында һәм киң колачлы итеп сурәтләве белән әһәмиятле.

Сорау һәм биремнәр

1. Г. Ибраһимовның Октябрь революциясеннән соңгы тормыш юлына һәм әсәрләргә нигезләнеп, хронологик таблица төзегез.

2. Әдипнең иҗтимагый-сәяси карашлары үзгәрүгә нәрсәләр йогынты ясый?

3. Язучының сезгә таныш барлык әсәрләрен жанр һәм тема ягыннан төркемләгез.

КАЗАКЪ КЫЗЫ

(Кыскартып алынды)

Киң дала, күрәсең гуй, ана җаткан,
Җебәктәй җәсел чүптә битен җапкан.
Аскар тау, балдай татлы сулары бар,
Ана шул анам иде мине тапкан...

Мәгъҗан Җомабаев

I

Казакъның уртача байлыклы, күп адәмле ике ыругсы бар иде. Берсен кара-айгыр дип, икенчесен сарман дип атыйлар иде. Болар меңләгән җылкылары, яхшы нәсел төяләре (дөяләре.— Ә.З.), исәпсез куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында, ак тирмәләр корып, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә үзләренең маллары артыннан рәхәт-рәхәт күчеп йөриләр иде. Бәхетләре ким түгел иде. Мәгәр «канымыз Чингиздән килә» дип мактанучы кайбер кабиләләр соңгы заманнарда, җир-суга тарлык кылып, үзләренең җәберләрен арттыра башладылар. Тик менә шул аларның күңелләрен борчый иде. Болай барса, ике арада яман гауга чыгу курынычын алга китерә иде.

Көннәрнең берендә, Тынычбай атаның елы тулганда, бата кыйлырга[1] дип, илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан зарланып әңгәмә ачылды. Сүз сүзне тартты, картларның берсе камчысын уйната биреп әйтә салды:

[1] Бата кыйлу — искә алу, еллыгын укыту.

— Ике йортның өлкәннәре кода булды дип ишеттек, мәгәр күз белән күрмәдек. Әгәр бу дөрес булса, җир берлеген кан белән беркетсәк, кайсы яман бу ике илгә җау чыгарыр?— диде.

Бу сүз, күңелдәге теләкне хәбәр рәвешендә сөйләп, димчелек кылу иде. Чалның[1] тапкырлы кинаясе мәҗлеснең хушына китте. Ил агасы өлкән аксакал Биремҗан әкә моны куәтләп алды:

— Найманнар белән дүрткаралар һәр ике йортның мазасын китәрәләр[2], кызларын урлыйлар, җәйләүләрен басып алалар, аяклы малларын куып китәләр; сарманнар белән караайгырларның кода булып кушылулары дошманның йөрәгенә ут салыр, башыннан акылын алыр, кодалык котлы булсын!— диде.

Башка сүзгә урын калмаган иде инде.

Хәбәр бөтен җәйләүгә таралды, куанычлар, казакъ әйтмешли, куенга сыймады. Шул көн сүз куештылар. Бер атна үтүгә, югары-түбән ат җибәреп, илне җыйдылар. Кымызның мул чагы, туктыларның[3] симез заманы, йөгерекләрнең дә, дер кайнап, йөрәк суккан вакытлары иде. Яше, карты, бүз баласы, сылу кызлары, җыелып, үләң[4], җыр әйтеп, думбра чиертеп, ат уйнатып, утыз көн уен, кырык көн туен кылып, ике ыруг кодалыкка кул бирештеләр.

Калым өчен күп сатулашу булып үтте. Озак талаштан соң йөз баш кара[5], дүрт йөз алтын, ике сандык асыл зат өстендә килештеләр.

Шул көннән Сарсымбайның яшь ярымлык кызы Карлыгач кара-айгырларның ай ярымлык ир баласы Калтайга әйттерелгән булды. Берсе — кияү, берсе калымлык саналып китте.

Айлар, еллар үтә. Яңадан-яңа җәйләүләргә күчәләр. Ике коданың катнашы күп, сыйлары уртак, уен-көлкеләре бергә бара. Тик әйттерелгән балалар гына үзләренең каената-каенаналарына күренмәскә, очраса — качарга, яшеренергә тиеш булалар.

Шул далада, шул шатлыклы күченүләр, шау-шулы маллар эчендә кайнап, ашлык сугып, сахрада ат уйнатып, туйларда бүз балалар, сылу кызлар, төрле җегет, төрле матурлар ара-

---

[1] Чал — карт.
[2] Мазасын китәрү — рәтен җибәрү.
[3] Тукты — тууына алты айдан артыграк вакыт узган куй бәрәне.
[4] Үләң — шигырь.
[5] Кара — терлек.

сында үләң, җыр әйтешкәндә катнашып, Калтай белән Карлыгач үсеп буйга җиттеләр. Мәгәр бер-беренә күңел якынлыгы юк иде әле. Кыз үзенең җегетен, очраганда, һичнәрсә аңламастан, хәйран булып карый иде. Яшүсмер Калтай бу сүзгә үткен, гәүдәгә үзеннән зур, чибәр кыз алдында ни әйтергә белмичә, бераз югалып, каушап кала иде.

Карлыгач сахраның матуры булып пешеп өлгерде. Тавышы өчен аны былбыл диләр. Җырлаганда казакъның акыннары аның зифа буен төз камышка охшаталар — билең нечкә, күзләрең тирән, керфекләрең уктай, үзең айдай дип мактыйлар иде. Ил эчендә дә коры исеме белән генә әйтмичә, Карлыгач-Сылу дип атыйлар иде.

Кыз гомеренең унсигезенче язына аяк басканда, һәр ике йорт, зур туй кылып, аны каенаталар йортына озату чараларын күрү уена төштеләр. Тиешле калым түләнеп беткән иде. Казакъның гадәте буенча, хәзер инде җегет, ата-аналарыннан, өлкәннәрдән яшеренрәк, киленчәкләр аркылы, кызның куенында булырга хак алган; һәм караңгы төннәрдә, җәйләүләр тынгач, аның күңеле, сабырсызланып, Карлыгач-Сылуның тирмәсенә тарта торган булды.

II

Җәйге кичләрнең берсендә Калтай Карлыгач-Сылу янына килә. Айбала килен аша кызга хәбәр җибәрә, әмма Карлыгач егетне кабул итмәячәген әйтә. Калтай, моңа хурланып, бик ачулы хәлдә кайтып китә.

III

Ил агасы Байтүрә морза үлем түшәгенә ятты. Мәгәр кабилә, партия талашлары эчендә кайнаган карт йөрәге, үткен мие сәламәт иде әле. Үзеннән соң найман, дүрткара балаларының язмышы ничек булуы турында күп уйланды. Дошманнарның баш күтәрүе аңа ачык иде. Үзенең бай тирмәсенең түрендә ятып, бу хакта күп баш ватканнан соң, чараларның берсе буларак, Биремҗан аксакалны чакыртып, аңардан бәхиллек алу фикеренә килде:

— Бу ялганда[1],— диде,— яхшылыгым күп булды, мәгәр яманлыгым да аз имәс. Дөньяныкы дөньяда бетсен: Азым әкәне җибәреп, үтенечемне әйтим, килсә, ту бия[2] суйдырып,

[1] Бу ялганда — бу вакытлы дөньяда.
[2] Ту бия — кысыр бия.

кымызны мул куеп, асыл елкыдан үзенә берничә кара бүләк биреп, ризалыгын сорыйм. Сүземне алса кирәк: үзе белән бергә үстек, бергә сабакка йөрдек, бергә ат уйнаттык. Ул тамырымның күңелен тапмый китсәм, җаным тыныч булмас. Найман балаларының миннән соңгы эшләрендә дә күп кыенлык чыгар,— диде.

Башына ак ефәк урамал сарган, кара күзле, ап-ак чәчле байбичә бу вакыт авыруның янында утыра иде. Байтүрәнең сүзләрен башына сыйдыра алмады, сабыр, мәгәр ачулы тавыш белән аны бүлде:

— Син,— диде,— акыл белән, баһадир ирлек белән гомер иттең. Инде ахыр көнеңдә бер тинтәклек кылыйм дип ятканыңмы бу?!

Авыру җавап бирергә өлгермәде, ишек ачылды. Аннан урта буйлы, калын муенлы, симез гәүдәле, агара башлаган сирәк сакаллы Якуп килеп кереп агасының кәефен сорады. Рөкыя бикә моңа гаҗәпсенгән тавыш, аптыраган йөз белән фаҗигане аңлатты:

— Ханнарның, солтаннарның баласы, аксөяк наймманнарның агасы, кырык ел ил тоткан абзаң бүген, мәлҗерәп беткән Бирем җан карт белән килешсәм, аны чакырып адәм җибәрсәм иде, дип ята, шуңа башым әйләнеп калды! Моннан егерме ел элек ул яман чалның Яңгырбайлар туенда миңа әйткән бер сүзе йортның хәтереннән чыкмаган булса кирәк... Ул адәмне мин ничек кабул кылырмын, ничек кунак итәрмен. Син бернәрсә әйт, бәлки телеңне алыр,— диде.

Якуп кирәгәгә асылынган иярләр арасыннан нидер эзли иде. Каеш аел белән көмешләнгән саплы камчыны тартып чыгарды да һичкемгә күтәрелеп карамастан әйтә куйды:

— Агам,— диде,— миңа моны кичә әйтеп иде. Ни дисәм дә, сүзем үтми калды... Биремҗан дигән ул исәр чал[1] — йортның барына да билгеле адәм гуй!

Ләкин үз гомерендә әйткәнен эшләми калырга өйрәнмәгән карт арыслан, авыру булса да, боларга колак салмады, өстендәге атлас юрганнарны бер яккарак ташлый биреп, ачуыннан башын күтәреп:

— Сәүләм[2] Рөкыя!— диде.— Аяллыгыңа[3] барма, күп гомер эчендә яманын да, яхшысын да күрми амал юк! Син егерме ел

---

[1] Исәр чал — җиңел акыллы карт.
[2] Сәүләм — нурлы йөзем, күз нурым.
[3] Аял — хатын-кыз.

элек аңардан бер каты сүз ишеткән булсаң, мин аның белән кырык ел талаш кылганмын; мәгәр акылыңны киң йөртергә кирәк: Сарсымбай дигән яман эт баласы безгә каршы гауга чыгарам дип ятыр; ил эчендә күп әңгәмә таралып китте. Уйлаганым — үзем өчен имәс, тәкъдир җитеп, ясаган иям җанымны үзенә кайтара торган булса, найманның, дүрткараның чамасын төзәтим дип яткан эшем гуй!— диде.

Сөйләүдән арып китте, хәлсезләнеп, кире ятты, ахыр фәрманын кыенлык белән әйтә алды:

— Мин ике сөйләргә гадәтләнмәгәнмен: Азымбай белән нугай молданы чакырыгыз. Кашка белән Дөлдөлне иярләгез, бу ике байгыш Коргак-Күл җәйләвенә барып кайтырлар!.. (...)

IV

Байтүрә Азым әкәне Биремҗан аксакал янына җибәрә.

V

Азым әкә үз гомерендә кабилә, партия талашларының борылмаларын күп кичерде. Ләкин бүгенге йомышы аның өчен тагы зуррак булып күренде: арадагы сүзләр ничек кенә әйтелгән булмасын, әмма аңа тапшырылган эш мәңге гаугалашып килгән ыругларның килешүе өчен бер чама тартып карау иде. Әгәр юл уңса, Байтүрәнең иң яман дошманнарыннан булган Биремҗан аксакал бу йортка килеп кымыз татыса, иттән авыз итсә, ул вакыт ике кабиләнең талаштан туктавында сукмак салынган булачак иде. Йөкләтелгән бурыч шундый зур булганга, карт үзен Якты-Күлдән кызылкортларга җибәрелгән илче итеп уйлады. Өс-башының да шуңа охшашлы бер рәвештә булуын кирәк тапты, авыру яныннан чыккач та, туры үзенең өенә таба бар кадәренчә киенеп килү өчен кайтып китте.

Бу җәйләүдә барлыгы унбиш тирмә бар. Боларның тугызы — авылның ярлы казакъларыныкы, уртадагы алтысы Байтүрәнеке иде. Картның өе бер читтәрәк иде.

Байдан чыгып, үз тирмәсенә атлау белән аның җаны әрнеп китте: ул алтмыш ел дөнья куды, Ходайга: «Мал да бирче, бак[1] та бирче!» — дип моңлык кылды. Шул Байтүрәләргә коллыктан котылуын, ил өстендә баш булуны өмет итте. Ләкин бәхет килмәде. Инде баеп җитәм дигәндә, каты буранлы, яман

[1] Бак — бәхет, уңыш.

бозлы бер көздә, аның күп хайванын җот[1] һәлак кылды. Карт тагы зәһәрләнеп, дөньяга, Аллага, байга үч итеп, сүгенеп йөри торган булды. Авыру арысланның фәрманын алып чыкканда, аның каршына ачылган күренешләр бу ачуын, бу әрнүен тагы арттырдылар. Тирмәдән далага күз ташлауга, аның алдына кайнап торган җәйләү килде: әйтерсең штаб тирәсен сырып алган миллионлы гаскәр! Шундый кара болыт булып, бөтен тирә-якны, даланы, кутанны, җәйләүне Байтүрәнең маллары каплап алып, шулай кайнашып торалар.

Әнә күлдән далага таба төяләр китеп баралар.

Гәүдәләре эре, өркәчләре ияр кебек ике аерылы, башлары кечкенә, муеннары түбәгә асылган; әйтерсең сафлап тезелгән кәрван: шулай акрын, салмак, сабыр гына тирбәлә-тирбәлә атлыйлар. (...)

VI

(...) Акылы, чәчәнлеге белән Сары-Аркада дан тоткан Биремҗан аксакал заманында уртача дәүләтле адәмнәрдән иде. Байтүрәләр эш башына менеп, бу аларга каршы гауга башлаганның икенче елында, караңгы төннәрнең берендә, бер көтү җылкысын куып алып киттеләр. Атбасар, Күкчәтау, Кызылъяр арасында йөргән зур кәрванын бастылар. Шул ике бәла аның билен сындырды, бәхетен кире җибәрде. Борынгы мактаулы Яшел-Сырт дигән җәйләүләр найман ыругларының интригасы белән урыс хәзинәсенең ат заводларына, хохолларга алып бирелеп, менә шул Коргак-Күл җәйләүләрендә күчеп йөри башлагач, малларга бу җирнең тозлы икълиме[2] ошамады, аксакал акрын-акрын бөлде. Үзе сукыраеп, бердәнбер угылы Җанбирде дә авырып киткәч, карт инде менә шул хәзерге хәленә төште.

Казакъның борынгы гадәте буенча, ул кунакка хөрмәт кылу тик кымыз һәм ит белән генә була дип карый, самавыр, чәй, бавырсак кебек начар бидгатьләрне[3] эшкә санамый иде. Килене чәй әзерләгәч, карт казакъ кунагыннан гафу үтенергә кирәк тапты:

— Ерак илнең мөсафиры безне гаеп кылмасын: байлыгымыз бетте... Өемез кымызсыз утыра! Үткән-барган кунакларны ит белән, кымыз белән сыйлап җибәрергә куәтемез җитмәүдән күңелем бозылып кала,— диде.

---

[1] Җот — азык житешмәгәнлектән терлекләрнең кырылуы.
[2] Икълим — климат.
[3] Бидгать — яңа кертелгән әйбер.

Дөньяны күп күргән, атаклы чәчәннәр белән сүз көрәштергән Азымбай бу аксакал алдында үзен югалтты. Картның һәрбер сүзе, гүя аның йөрәгенә ук булып кадала; гүя уйлап килгән йомышны алдан ук җимерелә бара кебек иде. Шулай да сүзне ул якка таба борырга батырлык кылды, озын әңгәмәләрдән соң, иплэп китереп, Байтүрәнең арзын[1] әйтә салды:

— Бу ялганда адәмнең яманлыгы да, яхшылыгы да булучан. Яшьлек тамырыбыз Байтүрә, каты наукасланып, тәкъдирем җитте дип, әҗәл көтеп ятыр... Мәгәр кордашым Биремҗанның күңелен алмый китсәм, кабердә җаным тыныч тапмас дип, мине сезгә җибәрде,— диярәк сүз башлады да соңгы утыз ел буенча найман белән сарман кабиләләре арасындагы талашны, моңа нигезләнгән партия, булыслык[2], билек сайлавы өчен булган талашларның тудырган фаҗигаләрен озак-озак итеп, бер-бер санап чыкты. Ахырында:

— Найман йорты ыруглары Урта йөзнең өлкән аксакалы Биремҗан әкәне үз илемездә кунакта күрсәк иде дигән өмет белән калдылар... Әгәр инде бу сүзләрдә хатам булса, олуг аганың ак күңеле мине кичерер, илченең аяк тайган җирләрен күрсәтер, төз юлга барырга акыл бирер, безнең теләгебез шул,— дип тәмамлады.

Казакъ сүзгә никадәр оста булса, башкалар сөйләгәнне дә шулкадәрле үк тыңлый белә. Кунакның ит пешәрлек вакыт сузылган сүзләрен Бирем әкә бик аз бүлдерүләр белән, тирән дикъкать эчендә, акылына салып утырды, аннан соң ашыкмый үзе сүз башлады:

— Безнең,— диде,— найман ыругсына ачуыбыз юк. Мәгәр ул партиянең башлыклары булган Байтүрәләр, Якуплар йортына барып кунак булуны, аларның кымызыннан, итеннән авыз итүне дуңгыз белән бер табактан тамак җыю дип күрәбез!— диде.

Сүз акты. Байтүрәләрнең утыз ел буенча, урыс түрә белән берләшеп, Сары-Арканы нинди хурлыкка, коллыкка төшерүләре, үзләре дәүләт-мал арттырып, илне, җирсез-сусыз калдырып, бөлгенлеккә салулары, алар сүзе белән җир аударылган, Өмбенең, Симинең, Яман-Каланың, Тургайның, Кызылъярның зинданнарында, даласын, итен, кымызын, анасын сагынып, тимер рәшәткә эчендә елап утырган казакъ балаларының

[1] Арзу — теләк.
[2] Булыс — волость.

газапланулары акрын, сабыр тел белән кунакның күз алдыннан үтте. Ахыр килеп:

— Илчегә үлем юк, мин сиңа шелтә кылмыйм, мәгәр,— диде,— син Байтүрәгә әйт: адәм баласы кулы белән эшләгәнне муены белән күтәрергә тиешле! Илгә таш чәчте, кан агызды, әгәр болар бугазына утырса, үз чәчкәннәрем үсте дип белсен!!! Тәкъдире җитеп, дөньядан кайтса, яшьлек тамырым булганлык өчен җиназасына барачакмын, мәгәр дәверенә, тәһлиленә кермәм, бүләген алмам, итеннән, кымызыннан авыз итмәм... Найман ыругларының яхшыларына миннән сәлам әйт!

Сүзнең болай бетүен кунак үзенә фатиха дип аңлады, әдәп йөзеннән тагы берничә моң-зарын әйтте, дөньядан шикаять кылды:

— Өметем зур иде, бу талашларның чиге күренми, күңелем бозылып калды, Бирем әкә,— дип, кулына камчысын алды.

VII — VIII

Аксакал белән саубуллашып чыгып киткән Азымбай җәйләүнең бер төркем кешесенә тап була. Дивана кимпер (карчык) илче өстенә таяк белән ташлана, аны ил-йортка афәт китерүче, халыкны ачлык-ялангачлыкка дучар итүче Байтүрәгә хезмәт итүдә гаепли. Мондый хурлыктан соң Азымбай найманнарга түгел, танабуга ыругысы Магҗан баласы Арысланбайга юл тота.

IX

Бу тирмәләр белән Кызыл-Уйсу арасындагы кутанда[1], бәйләүле колыннар янында, ак башлы хатыннар, чиләк, корык тотып, бия савып йөриләр иде. Карт, атны уңга тартып, өйләрнең арт ягына чыкты. Ике тирмә арасында җылгыр күзле, кайбер калку күкрәкле киленчәкләр белән, җефәктәй кара чәчләрен җилкәләрендә тулкынландырып, башларына кечкенә кызыл кәләпүшләр кигән сылу кызлар ачык һавада җырлый-җырлый киез басалар, бер кимпер аларга юлбашчылык кыла; бүз балалар, шулар тирәсендә бушны бушка бушатып, киленчәкләр белән, сылулар белән сүз көрәштереп, бүген кич яныңа барсам, кабул кылырсыңмы дигән мәгънәне читләп аңлатып, шаярып йөриләр.

Азымбай Арысланбай белән очраша һәм үзенең язмышын сөйли. Егет тә күргәннәре белән уртаклаша.

[1] Кутан — тирмәләрдән торган авыл уртасындагы мәйдан.

Азымбай әкә икенче көнне, итне ашап, кымыз белән әбдән мас булып алганнан соң[1], үзенең актык сүзен әйтте:

— Балам,— диде,— Алтын-Күл җәйләвенә бар. Сарманнарга миннән сәлам әйт. Ул йортның өлкәннәренә минем шушы сүземне ирештер: тауның ташы, ничаклы каты булса да, бер барып җимерелә икән! Диңгез булып җәйрап яткан күлләр дә бер корый икән! Байтүрә нәселе хәзер шуңа охшап калды!.. Әгәр сезнең танабугалар, кара-айгырлар, кызылкортлар, сарманнар яңа йорт салырга ният кылсалар, илнең ак күңел адәмнәре ярдәмгә әзер булырлар... Сарсымбай минем сүзләремә колак бирсен!

Илче кунакның бу кинаяләре җегеткә ачык аңлашылды. Аның күңелен шатлык белән тутырды. Үз ягыннан җавап итеп:

— Инде, Азым әкә, безнең җәйләүнең юлын күрдегез! Танабуга йорты һәрвакыт сезне үзенең кунагы кылмакка тели!— диде. Шул сүз белән далага чыктылар.

Атлар иярләнеп әзерләнгән иде. Карт, аягын өзәңгегә куя биреп, үзенең эчке зарын әйтте:

— Ясаган иям тел бирде, акыл бирде, мәгәр малың булмагач, бу дөньяда кадерең юк икән! Байтүрәнең эте булып, яман кимперләрдән кыйналуым күп ел гомеремне кыскартты. Инде калганын адәм сынлы үткәрсәм иде!

Озата чыккан җегетләр, моны аңламыйча, аптырашып, берберенә карандылар. Илче Азым әкә белән Арысланбай атларына менделәр. Берсе — Якты-Күлгә, берсе үзенең тамыры Карлыгач-Сылуның сагынып көтеп яткан җәйләвенә карап юлга төштеләр.

X

Сарсымбайның Алтын-Күл буена урнашкан җәйләвендәге көндәлек тормыш сурәтләнә.

XI

Карлыгач-Сылу, күптән уянган булса да, кичәге күңелсезлектән соң, анасына күренергә кыенсынып, күп уйларга гадәтләнмәгән башы белән үзенең авыр язмышы турында хафаланып, караңгы кайгы эчендә ята иде. Ялчы төнлекне ачты, югарыдан бөркелеп, сахраның саф һавасы тулды. Уң якның киезен күтәрделәр, якты кояш нурлары, кирәгәнең челтәрләре

---

[1] Әбдән мас булып алганнан соң — бөтенләй исергәннән соң.

арасыннан кереп, өйнең идәнендә, киез өстендә түшәлгән паласларда шакмак-шакмак булып уйный башладылар, сул якның ачыклыгыннан тыштагы яшел үләннәрдә кибеп барган чык тамчылары ялтырап күренде. Ләкин иркә Сылу һаман кузгалмады, түгәрәк тирмәнең уңъяк түренә, кирәгә буена куелган караватында чәчләрен туздырып, кечкенә, нәфис, алсуак аякларын кичке күлмәк эченә, үзеннән-үзе тулкынланып торган матур тәнен йомшак юрганнар астына яшерә-яшерә, һаман бер яктан икенче якка ауный бирде. Зиһенен нәрсәгә генә юнәлдерергә тырышса да, анасының кичәге сүзе аның колагыннан китми иде:

— Телемне алмасаң, сиңа биргән ак сөтемне бәхилләмәм!

Өченче көн кич җегете Калтай килде. Туй булмаганга, гадәт буенча, ата-анадан яшеренеп, киленчәк Айбала аркылы хәбәр итте. Карлыгач-Сылу, кискен сүз белән:

— Минем аңа кабулым юк,— дип җавап бирде.

Җегет хурланган, киленчәкнең, калымлык исеменнән ялганлап: каты наукасланып калдым, карагым үпкәләмәсен, дигән сүзенә ышанмаган.

— Яхшы анадан туган ул яман кыз белән безнең кара-айгыр йорты ни кылырга белер!— дип, каты ачу белән үзенең Байчобарын суга биреп, караңгы төндә кире кайтып киткән. Арадагы илче Айбала боларның барын да кызга шул көндә үк әйткән иде.

Ләкин байбичәгә бу хәбәрне ишеттергәнме яки ана йөрәге, үзе сизенеп, кодалык йорты белән ике арада зур талаш чыгачагын уйлаганмы — иркә Сылу моны белмәде. Мәгәр анасы Алтынчәч бикә кичә кызын чакырды да, башта сөеп, иркәләп, ай ярымнан туй булачагы турында ишарә кылды; кыз баланы күз агыңдай кылып үстерәсең дә чит йортка җибәрәсең, ана күңеле өчен күп хәсрәтле бер эш бу дигәндәй кинаяләр сөйләде.

Карлыгач-Сылу башта сүз кайтармады, ахырдан түзмичә, анасының күкрәгенә капланып:

— Чичәм[1], ике күзем, ул адәмгә бармыйм мин!— дип, туптуры әйтте дә елап җибәрде.

Ана гадәттән тыш хафалы тавыш белән кызын юатты:

— Өлкән нәселнең, яхшы атаның баласы булган бер җегет... Тәкъдирең шул... Яшь ярымнан әйтелгән, калым алынган!..— дип озак сөйләде.

---

[1] Чичә — әни.

Карлыгач, боларга карамастан, сүзендә нык торды, елавыннан туктап, ишек яңагына барып сөялде дә актык сүзен әйтте:

— Теләгәнеңне кыла бир, Калтайны яратмыйм, күңелем башкада... Әгәр көчләсәгез, гәүдәмне Алтын-Күлдән эзләп алырсыз!

Байбичәнең күңеле катты, шелтәле һәм үпкәле тавыш белән:

— Телемне алмасаң, без биргән җегетне ташлап, кодалар белән талаш чыгара торган булсаң, сиңа имезгән ак сөтемне бәхилләмәм!— диде. Шуның белән сүз киселде.

Үзен уятырга кергән яшь килен Айбалага Карлыгач эч серен чишә.

XII

Казакъ илендәге зур туйларның берендә бүз балалар белән яшь сылулар кара-каршы утырганнар. Думбрасы, зөрнәсе белән шау килеп, уен-көлке кылалар, үләң-җыр әйтешәләр. Карлыгач ундүрт яшендә генә, мәгәр буйга җитү, йөрәгендә дәрт уянган бер кыз иде. Аның каршысында асыл киенгән, укалы бүреге, алтынлы кәмәре белән ялтырап, кызылкортның бер җегете утыра. Мәгәр кызның күңеле моңа бармый. Җегетнең мактавына каршы каты чәнчеп, үләң белән җавап кайтара... Шулвакыт ишек ачыла, ялгыз бер җегет килеп керә. Бүз балалар, сылулар арасында кайнашып йөргән бер акын, тора биреп, кунак җегетне мактый башлый. Кыз аңа күз ташлый: озынча төз буй, яңа сызылып килгән куе кара мыек, маңгайга таба бераз киңәеп килгән акыллы йөз, билдә кәмәр, кулда камчы!

Яшь йөрәккә ут төшә, кан кайный, мәгәр танымады, кем дип сорарга кыймады, сүз әйтергә теле бармады...

Ахырдан түзмәде: «Кем иде ул?»— диде. Танабугаларның өлкәне Магҗан хаҗи дигәннең ялгыз баласы, диделәр. Мәгәр, диделәр, күңелеңне сузма. Найман иленең Азымбай дигән берәүнең, айдай йөзле, камыштай буйлы бер сылу кызы — ул җегетнең калымлыгыдыр, диделәр. Хәер, диде, киң далада кызның да, җегетнең дә сылулары аз имәс гуй, диде.

Мәгәр яшь күңел бу сүз белән тынычланырмы?! Адәмнең һичберенә әйтмәстән, аны эзли башлый.

Айлар үтә. Сарсымбай авылы Җылкы-Батканнан менә шул Алтын-Күл җәйләвенә зур кәрван булып күчеп барган заманда яңадан очрашалар. Картлар, өлкәннәр, хатыннар — һәммәсе арбаларга утырганнар, кайберләре төягә менгәннәр. Карлыгач-

Сылу, яулык ябынып, шул кимперләр белән утырып йөрсенме?! Ул кызлар, җегетләр белән ат өстендә уйнаклатып бара... Шул вакыт каршыдан асыл айгырларны иярләп менгән ике кыз, өч җегет килеп чыга. Арада теге Магҗанның баласы да бар.

— Юл булсын!

— Юл булсын!

— Сарсымбай әкәнең авылы Алтын-Күлгә күчеп бара ятыр.

— Танабугадан Яшел-Сыртка кунакка китеп барабыз.

Шул гади сүзләрдән соң арадан бер шаяны әйтә сала:

— Кызларның сылулары, җегетләрнең асыллары каракаршы килгән икән, бер уенсыз үтеп китәргә ярамас... Алышмы, бирешме?— ди.

Карлыгач, үз атын тарта биреп, алга килә:

— Безнең йорт алышка да, бирешкә дә әзер, үз чамагызны карагыз,— ди.

Тезгеннәр тартыла, камчылар уйный, өзәңгеләр селкенә башлый. Якты кояш астында ачык далада, чаң[1] кузгатып, айгырларны тирләтеп, ат өстеннән бер-берен тартып алу белән уйнап китәләр.

Сылу кызның бер яман уе бар иде, теге сызылган кара мыеклы җегетне, юртагыннан тартып төшереп, бер көлке кылсам дип ниятли иде.

Астындагы елдам атны суга биреп, җегетнең каршысына килә дә лачын коштай тизлек белән аның тезгенен тартып җибәрә, айгыры борылыйм дигәндә, култыгыннан тартып, бер якка өстери, җегетнең астындагы ак юртак бераз кайшала биреп куя, мәгәр егылмый; җегет тиз генә әйләнә дә кызның атына яман камчы бирә. Карлыгач тотып өлгерә алмый; җегет, аны куып җитеп, сүз әйтеп авыз йомылганчы, бөркет коштай кагына биреп, Сылуның биленнән ала да үзенә тарта; ат туктый, кызның аяклары өзәңгедән, үзе ияртән чыгам дигәндә асылып кала, егылырга рәт җитә...

Бүз балалар яңгырашып көләләр, җегет кычкыра:

— Җинүчегә ни бирәсез?— ди.

Карлыгач үзе дә көлеп җибәрә:

— Җегетлегең зур, теләгеңне ал!— ди.

Һәр икесе ат өстендә булган килеш, җегет, кызның гәүдәсен үзенәрәк тарта биреп, битеннән, тулы кызгылт иреннәреннән үбә дә кире иярגә утырта.

[1] Чаң — тузан.

Алар — кыйблага, Карлыгачлар төньякка карап китә бирәләр.

Менә бу җегет — кызның хәзерге тамыры Арысланбай иде. Шул көн аларның беренче якынаюлары булды.

Айбала бу хикәяне гаҗиб бер дәрт эчендә кайнап тыңлады.

XIII—XVIII

Далага чыккан Карлыгач киез басучы хатыннар белән сөйләшеп торганда, дивана кимпер килеп туктый һәм Байтүрә илчесе Азым әкәне кыйнавы турында сөйли.

Башка җәйләүгә үтеп баручы дүрт казакъ исәнлек-саулык сорашырга, кымыздан авыз итәргә Сарсымбайга туктый.

Дала тормышы, социаль тигезсезлек күренешләре тасвирлана.

Сарсымбай җәйләвенә Арысланбай килә. Аны шатланып каршы алалар. Икәү генә калгач, кыз белән егет мәхәббәттә аңлашалар. Сарсымбай соравы буенча Арысланбай сөргендә күргәннәре турында сөйли. Бай кызына яшь ат бүләк итүе турында әйтә. Айгырны алырга өчәүләп барырга булалар. Арысланбай үзенә Азым әкә килүе турындагы хәбәрне җиткерә.

XIX

Төш ауган, һава бераз талгынланган, көндезге кызу да кайткан, маллар һәммәсе далага, яшел үләнгә таралганнар, тик бүген бәрәнләп тә бүлтерекләре әле еракка китәрлек ныгып җитмәгән дүрт куй гына өй тирәсендә күренәләр. Бәйләүдәге колыннар, киң сахрада чабарга сабырсызланып, арканнарында тартылып, кич җиткәнне түземсезлек белән көтәләр. Тукал[1], урта өй каршысында зур казан тутырып, ит пешерә.

Сарсымбай күрше фәкыйрь тирмәдән бер җегетне кычкырып чакырды:

— Балам, син безгә атлар иярләп бир, менә Карлыгач-Сылу арыган атасын ерак җылкыга алып барырга көчләп тора,— дип, кызы белән Арысланбайга карап аз гына елмайды. Үзе, җиз комган тотып, сахрага юнәлде.

Бай әйләнеп кайтып, атлар иярләнеп өлгергәнче, җегет белән кыз өчен берничә минут аулак вакыт булды.

Карлыгач-Сылу хәлне сөйләп алды:

— Ачык әйтеп бетермиләр, шулай да ике айдан туемны ясап, мине Калтай йортына озатырга әзерләнүләре сизелә... Җегет өч көн элгәре килгән иде... Айбала җиңгәм артыннан хәбәр иттергән. Мәгәр мин, кабулым юк дип, кире кайтардым.

---

[1] Тукал — яшь хатын; ирнең икенче яисә өченче, дүртенче хатыны.

Ул киткәндә: яхшы атадан туган яман Сылу белән безнең ил ни кылырга үзе белер. Карлыгач өчен сарманнарга кара-айгыр ыругсы белән исәпләшергә туры килмәсен дип әйткән... Анам да сизенә булса кирәк: чакырып үгет кылды, мин җыладым, кочләсәгез, гәүдәмне Алтын-Күлдән эзләрсез дидем... Ул күз яше белән рәнҗеде; телемне алмасаң, ике йорт арасында талаш чыгара торган булсаң, сиңа имезгән ана сөтемне бәхилләмәм, дип каргады... Инде ни кылабыз?

Җегет моны көтмәгән иде. Ул калымлыгын түләгән тәкъдирдә, ата-ана риза булыр, кара-айгырлар да талаш кузгатмаслар дип өмет итә иде. Ләкин тукталырга исәпләмәде:

— Карагым, син хафа булма,— диде,— Биремҗан аксакалны алырга атлар китте. Ул килер, мин аның белән киңәш кылып багыйм. Сарсымбай белән байбичәне ризалатырга, бәлки өстенә алыр, булмаса, үз җаебызны карарбыз,— диде.

Кызның йөзе катты. Күзләренә ниндидер авыр уй чыкты:

— Бозылырга теләмәсәләр, ни кылырбыз?

Җегет бер сүздә кисте:

— Мин ярты юлда тукталырга өйрәнмәгәнмен, синең йөрәгең батырлыгына да ышанам; ат өстендә уйнап оча торган казакъ җегетләре далада бетте дисеңме? Караңгы төндә асыл аргамаклар белән Алтын-Күлдән Яман-Чүлгә китсәк, бу йортның кайсы адәме безне куып тотар да, кайсы җегетләре, танабуганың Магҗан баласы Арысланбай җәйләвеннән Карлыгач-Сылуны тартып алып кайтам дип, сугышка чыгар микән?!

Кыз мәхәббәт һәм кискенлек тулган матур кара күзләре белән җегеткә карады:

— Кара-айгырлар белән кан түгеш чыга калса?..

Атларны иярләтеп китерделәр. Бай да кайтып килә иде. Арысланбай, ачу катнаш усаллык белән:

— Хафа булма, колынчагым, бер җай табарбыз!— дип сүзен бетерде.

Атландылар да өчәүләп җылкыга киттеләр.

XX—XXVI

Җылкы көтүен эзләп табып, ошаган атны аерып алалар. Җылкычы егет атны кулга ияләштерә. Өстендә кеше йөртергә өйрәтә.

Җәйләүдә кичке ашны ашау күренеше бөтен нечкәлекләре белән тасвирлана. Атчабар Байтүрәнең вафат булуы турында хәбәр китерә.

Сарсымбайның икенче хатыны дивана кимпергә үзенең авыр язмышы турында сөйли.

XXVII

Бөтен дала тирән йокыда, тик Якты-Күл буендагы найманнарның уртадагы зур ике тирмәсендә генә ут яна. Байтүрәнең вафаты, иртәгә булачак җеназа һәм үлем хәсрәте бу йортның тынычлыгын алган, болар авыр кайгы эчендә иртәнге кумы мәшәкатьләре белән караңгы төнне уяу үткәрәләр. Якуп, Рөкыя, Яңгырбай, Азым әкәләр туктаусыз сөйләшәләр, нидер эшлиләр, нәрсәгәдер әзерләнәләр.

Якты-Күл җәйләве таң иртәдән шәрекънең базары, гаребнең карнавалы, гарәпнең мәхшәр дигәне кебек кайный башлады.

Көн яңгырлы, күктә кара-соры болытлар туктаусыз йөриләр, Якты-Күл ачулы тулкыннар белән өзлексез шаулый, юеш томанны бер яктан икенче якка куып, киң дала буенча каты җил сызгырып уйный иде.

Шуңа карамастан төш алдыннан Байтүрә авылының бөтен тирә-ягы җеназага җыелган халык белән тулган иде инде. Нечкә билле, ука күкрәкле бишмәтләр кигән, ак урамалар ябынган ак чәчле, җыерчык битле, кайгылы күзле кимперләр, елап күзе кызарган киленчәкләр һәм шау-шулы җирне ярата торган сылу кызлар, ак тирмәләрнең берсеннән чыгып, берсенә кереп, нигәдер йөреп торалар. Симез җилкәле, калын гәүдәле, һәрвакыт ат өстендә йөрүдән бераз кәкрерәк аяклы, киң маңгайлы, тар иякле, карасу йөзле, сирәк сакаллы, ике якка бәреп чыккан яңаклы казакълар, яңгырдан, җилдән колакчынны басып киеп, көпе өстеннән билгә кәмәр бәйләп, унарыегермешәре, өем-өем булып, килгән-киткәнгә, кергән-чыкканга ара-тирә күз салып, төрле җирдә нәрсә хакындадыр акрын, сабыр тавыш белән сөйләшәләр. Болар арасында чалма, җилән кигән татар муллалары, каракүл бүрекле, казаки, читек-кәвешле төрле татар сәүдәгәрләре, студент, семинарист киемендәге казакъ җегетләре, кысыкча кара күзләре, карасу киң йөзләре белән кай халыкның баласы икәнен күрсәтеп торган берничә офицер, бөтенләй европача киенгән, өлкән ак сакаллы карт казакъ адвокаты, күкрәккә медаль таккан калын биләр, бәдәл[1] эзләп йөргән, тар, нечкә чалмалы, сырган кызыл җөббәле гарәп хәерче хаҗилары, нәселе, киеме мәгълүм булмаган тагы әллә кемнәр — һәммәсе, һәммәсе шул мәхшәр кебек җәмәгать эчендә бер яктан икенче якка тулганалар.

---

[1] Бәдәл — үзе урынына кеше яллап хаҗга җибәрүче.

Бераз читтәрәк, бөтен басуны каплап, күбесенә пар ат җигелгән тарантас, арбалар, иярле атлар, алар тирәсендә чобалган ярлы казакъ ирләре күренә. Кутандагы киртәләрдә иллегә якын мал бәйләнеп тора. Арада берничә колынлы бия, ике симез айгыр, дүрт төя, биш корчаңгы тай, бер арты пычрак сыер, байтак куйлар күренәләр. Арбаларның, иярле атларның, өйләр арасындагы халыкның саны арткан саен, бу бәйләүле малларга да мәрхүмнең фидиясе өчен дуслары, кардәшләре тарафыннан китерелгән буталар, кысыр бияләр, яшь тайлар, чирле башмаклар, рәнҗү куйлар һаман кушыла бара, кушыла бара...

Бу хайваннар, үзара тыныша алмыйча, тешләшәләр, бияләр чыелдап тибенәләр.

Өйләрнең берсендә елау күтәрелә, ат кешнәве, төя акыруы, арба тавышы, адәм сөйләше белән гөж килгән мәйдан бик күп хатыннарның, берсен-берсе бүлә-бүлә, ачы, моңлы зар белән:

— Ай, түрәм, ау! Безне кемгә калдырдың, ау!..—дип, елап әйткән көчле, кызганычлы авазы белән дерелдәп китә, йөрәкләргә ниндидер авыр бер шом катнаш хәсрәт агуы төшә, кан тамырлары бу елаудан әрнеп өзеләләр.

Хатыннар тиз тукталмыйлар, мәрхүм Байтүрәнең яхшылыкларын сөйләп, аны сагынып, күз яшьле тавыш белән әйтәләр-әйтәләр дә, тагы йөрәк өзгеч бер ачы зар белән:

— Ай, җан түрәм, ау! Безне кемгә калдырдың, ау!..— дип, бөтен җәйләүдә, һәммә йөрәкләрдә шомлы бер кайгы уятып, күзгә яшь китерәләр.

Бу ачы, зарлы елауларның бераз тынып торган заманында, биленә думбра таккан бер адәм ат белән килеп төште дә мәет яткан тирмәгә таба китте. Казакъча киемле, ябык йөзле, дивана йөрешле, хыялый күзле бу кеше тирә-якның мәшһүр акыннарыннан Тылсымҗан иде.

Мәйданда төрле яктан:

— Акын килде, акын килде!— дигән тавыш ишетелде.

Кичәдән бирле туктаусыз ат өстендә чабып, җәяү йөгереп, байбичә Рөкыя һәм мәрхүмнең энесе Якуп белән бергә дәфенҗеназа артыннан йөргән Азымбай карт бу шагыйрьне күрүгә кулыннан алды:

— Күзеңдә яшь, йөзеңдә кайгы күренә. Сүзең беттеме? Ник бернәрсә әйтмисең дә?— диде.

Акын хыялый күзләре белән Азым әкәгә карады да шунда ук казакъ арасында мәгълүм, авыр, акрын бер көйгә салып җавап кайтарды:

— Акылым китсә дә, сүзем бетсә дә, гаҗәп имәс. Сары-Арканың өлкән ил агасын югалттык түгелме?!— диде.

Акынның тирәсенә бер-берсен таптап халык өелде. Ул үзенә әйткән һәрбер сүзгә, аз гына да туктамыйча, көйләп җаваплар бирүдә дәвам итте.

Шагыйрь тирәсендә тупланган халык эчендә Карлыгач-Сылуның кияве Калтай да бар иде. Акылы, фикере ким булса да, башкалардан калышырга теләми торган бу җегет ямьсез борын тавышы белән Тылсымҗанга бәйләнде:

— Күзеңнән су ага, йөзең кара көйгән, юеш кабердән чыгып килдеңме, юкса?— диде.

Акын һич уйламастан, көйгә салып, шул мәгънәне әйтте:

— Кайгы белмәс, дөнья җимерелгәндә дә хәсрәт чикмәс үлек йөрәкләр барлыгын ишетәбез. Мәгәр бүген казакъ баласының күзендәге яшькә, йөзендәге ваем һәм хафасына һичберәүнең исе китмәсен! Адәм түгел, җир-күкнең үзе бүген авыр уйга калды, якты кояшны каплаган куе кара болытлар, өстебезгә явып торган яңгырлар — Байтүрә морзаның вафаты сәбәбеннән күк йөзенең кара кайгы пәрдәсе һәм хәсрәтле күңеленең күз яше имәсме?— диде.

Калтай тынды, башкалары, акынны мактап:

— Ай, ярыктык, ясаган ияң үзеңә чәчәнлекне кызганмый биргән гуй!— диештеләр.

Акын туктамады, һаман төрле көйгә салып җырлый бирде:

— Бүгенге хәсрәтне әйтү өчен, чәчәнлек кирәк имәс. Күңелең ак булса, йөрәгеңдә илгә мәхәббәт кипмәсә, син телсез булсаң да, бүген кайгы җырын көйләрсең!.. Ай, Байтүрәм, син бер идең! Каның Чингиздән килә! Ата-бабаларың ханнар, солтаннар иде! Яшьлегеңдә азамат[1] булдың! Ир чагында ил өчен кан койдың. Картлыгың килгәч, көн димәдең, төн димәдең, йортның, аләүмәтнең[2] кайгысы синең кайгың булды!.. Син киттең, исемең далада мәңге яшәр, мәгәр безне кемгә калдырдың, ау!— дигән мәгънәдә, байның зур нәселен, исәпсез байлыгын, илдә өстенлеген җырлады.

Мәрхүмнең дуслары моны әләктереп алдылар, акынның эзе буенча үзләре арттырып, бөтен җыелган халыкка сүз күбәйттеләр.

---

[1] Азамат — булдыклы, батыр егет.
[2] Аләүмәт — җәмәгать, халык.

Татар муллаларыннан берсе ниндидер зур нугай ишанның сүзен очырды, гүя ул әйткән була:

— Әгәр Байтүрә булмаса иде, далада диннең, исламның хәле мөшкел булачак иде,— дип.

Бу җеназага җыелган халык эчендә үзенең күп алыш-биреш эшләрен утәү исәбе белән килгән, заманында казакъ даласында җон-ябаганы чирек хакка алып, әйберне биш мәртәбә кыйммәт сатып, үлчәүдә һәр ике тәкъдирдә алдашып баеп киткән якын шәһәрнең татар сәүдәгәре моңа каршы тагын арттырды:

— Өяз начальнигын, губернаторны гына әйтмим, ярыктык Байтүрә ак патшаның үзенә дә мәгълүм адәм иде гуй. Бу хәзерге Николай Второй дигән патша тәхеткә утырганда, областан карнаваниягә барган ике ил агасының берсе — Байтүрә имәсме?— диде.

Байтүрә партиясенең олыларыннан Яңгырбай дигән бай, үткен казакъ, боларга хатимә бирде[1].

— Байтүрәбез бар иде. Чингизләрдән килгән бер аксөяк ил агасы иде. Аның урынын кем ала белер — Кодай үзе юл күрсәтсен!— диде.

Дуслар, шулай аклап, күккә күтәрделәр, дошманнар, гәрчә җеназага килсәләр дә:

— Казакъ йортының өстендәге бер яман адәм чәнчелде, инде ил үз хәлен үзе белер, казакъ йорты найман балаларына яңадан кол булмас,— дип, үлгән Байтүрә урынына энесе Якупның утыру ихтималына каршы, үз кешеләре арасында җыелып-җыелып, утлы сүз йөртүдә дәвам кылдылар.

XXVIII

Җәмәгать шулай үзара шау килеп торганда, теге акын тирәсендә үләң тыңлаучыларның берсе, бу җәйләүгә таба килгән арбаны күрсәтеп:

— Атлары Сарсымбайныкына охшый... Түрдә утырганы Биремҗан аксакал имәсме?— дип сүз ташлады. (...)

Аксакалны җитәкләп алып килеп, зур ак өйнең каршысына, үләнгә киез палас җәеп утырттылар. Аның тирәсенә илнең өлкәннәре җыелды.

Яңгырбайның кузгатуы буенча, сүз кукалга, урыс түрәгә, ак патшага күчте. Бирем бераз тыңлады да бу сүзләрне кырт кисте, Яңгырбайга карап шелтә ясады:

---

[1] Хатимә бирү — нәтиҗә ясау.

— Син үзең, мәрхүм агаң Байтүрә һәм сезнең бабаларыгыз белән бер нәселдән килгән, бергә эшләгән Кече йөзнең Әбелхәер ханнары, бөтен Өч йөзгә хан булыр өчен урыс патшага Сары-Арканы саттыгыз! Бабаларыгыз ханлык өчен, аталарыгыз солтанлык өчен, сез үзегез, түрәлек, билектә булыслык өчен яхшы җәйләүләрне кулыгызда калдырып, мал, дәүләт саклау өчен, Сары-Арканы урыс патшага кол кылдыгыз! Инде хәзер килеп, кара чикмән, кукал баскан даланың бер почмагын миңа кире алып бирмәк буласызмы?! Мин карт инде, ясаган иямнән әҗәл көтәм, миңа ике адымнан артык тупрак кирәкмәс,— диде.

Бу сүзләр бер-берен таптап тыңлаган җәмәгатькә яшен кебек тәэсир итте. Мәрхүмнең һәм барлык найманнарның дошманнары:«Ай, ярыктык аксакал, һәр сүзе мең алтын гуй»,— дип, эчләреннән бәйрәм иттеләр. Дуслары:«Бу акылдан язган чал исәрне китерү кирәкмәс иде!»— дип кара көйделәр. Адвокат, берничә семинарист, студент казакълар, хәйран булып, якында стражник юкмы дигәндәй як-якка карандылар. Арадан бер карт казакъ, торып, рәнҗүле, шелтәле тавыш белән, карт кунакка сүз ачты:

— Аксакал, сиңа хөрмәтебез зур, мәгәр күңелебездә шөбһә бар: син Әбелхәерне, нугайның Тәфкилев генералын гомер буена сүгәсең, нәселләре Чингизгә барган аксөяк найман балаларын мал, дәүләт, түрәлек өчен Сары-Арканы кол итәләр дип хурлыйсың, мәгәр Яшел-Сыртны кукал килеп басканда, без бөтен йорт, алач кычкырып, казакъның өлкәнен-яшен сугышка чакырдык. Шулвакыт каршы әйтүче безнең өлкән атабыз Биремҗан әкә түгел идеме?

Карт шул секундта ук җавап бирде:

— Әйе, мин идем! Кукалның малын каулап, йортын яндыруга мин каршы булдым. Сәбәбен беләсең килсә, сукыр чалның сүзен тыңла. Үзең белмәсәң, башкалардан сора, Биремҗан бөтен гомере буенча малыннан, йортыннан язып, казагым, карагым дип, талаш кылып йөргән адәм имәсме?

Җыелган җәмәгать:

— Өлкән атаның сүзе рас гуй...— дип, төрле яктан кычкырдылар.

Аксакал дәвам итте:

— Бу сүз рас булса, мин сезгә тагын бер рас сүз сөйләп бирим: берзаман хан куеп, аннан соң, боларны бетереп, урыннарына солтаннар сайлатып күп азапланганнан соң, урыс патша Сары-Арканың йөрәгенә керергә уйлады. Барлык казакъ

җире — урыс йортының уртак малы, дип әйтә салды. Үзенә хезмәт кылган адәмнәрдән мал белән, ялган ант белән алдап биләр, булыслар сайлата башлады. Аңарчы без белмәгән, ишетмәгән адәмнәр — кукаллар, урыс түрәләр безнең җәйләүләрне, зур күлләрне, елгаларны алып, кара чикмәнгә бирә, безне яман корыган чүлләргә куа торган булды. Ул заманнарда Сары-Арканың күп җирендә булдым, мәгәр һәркайда аксакалым буенча күз яше түктем. Ясаган иямә шулвакыт ант бирдем: кайда мөмкин — шунда кукалны, кара чикмәнне үтерү, канын кою, малын урлап китү — миңа бурыч булсын, дидем... Кулымнан күп җан кичердем: урысның күп малын далага качырдым; көннәрнең көнендә атлары югалган өчен бер казакъ йортына килеп, талаш кылып яткан биш кукалны күрдем. Янымда гайрәтле җегетләр бар иде, сәбәбен сорамадым: җавабын үзем бирермен, түбәләгез, каннарын түгегез дошманнарның дидем!.. Арада сугыш китте, сүз әйтеп авыз йомганчы, кара чикмәннәр быт-чыт булып җиргә сузылып ятты. Арадан берсе, качып, өйдә яшеренгән икән. Җегетләрем аны тоттылар да, кыйнап, анасын югалткан бута кебек акыртып, каршыма китерделәр. Бу бичара начар киемле, чабаталы, ак сакаллы бер кукал иде. Күрүгә аягыма егылды, аз-маз казакъча бытылдый икән: «Өемдә биш балам... авырып яткан кимперем бар. Мине кызган!»— диде. «Әй, атаңа нәләт булгыры! Казакъны талыйсың, җәйләвен аласың, инде үз башыңа төшкәч, кызгану кирәк булдымы?»—дидем. Кукал карт сабый балаларча җылады: «Ут агасы,— диде,— сүземне тыңла, миңа тидертмә»,— диде. «Әйтәчәгең ни? Сөйлә!»— дидем. Бичараның ак сакалы буенча мөлдер-мөлдер күз яше акты:«Без ни кылыйк,— диде,— туган илебездә кояш җылы, туфрак яхшы, анда алма, йөзем үсә; мәгәр,— диде,— көн итәргә җиремез булмаганнан, тынычсызлык чыгаргач, безне бу якка куалар. Сезгә килсәк, җәйләвемезне аласыз дип, сез безне каһәрлисез, инде без кая барыйк?»— диде. Яман каты акырып җылый бирде. Күземә яшь килде, янымдагы бүз балаларга:«Картны куя бирегез, китсен, күңелем бозылды»,— дидем. Берәүсе телемне алмады, яңадан түбәли башлады. Карт аягыма егылды, шундый бер яман җылады, йөрәгем парчаланды. Җегеткә: «Тукта!»— дидем. Ачуланып миңа карады, кукалның йөзенә каты бер камчы сызды да, атын тартып, янымнан кача бирде. Шул көннән антымны боздым, кукалның, кара чикмәннең канын коюдан, малын куудан күңелем суынды. Яшел-Сырт өчен, алач кычкырып, сугыш ачуга каршы әйтүем

менә шуннан соң иде... Акылың булса, башыңа сал: берәү сине кыйнаса, аның камчысы гаепмеме, кулымы?

Аксакалның сүзе шау-шу тудырды. Аңлаучы аз булды, арадан берәү чыгып, каты әйтә башлады. Кайберәүләр: «Моның картлыгы җиткән, акылы китеп калган»,— диделәр. Башкалар: «Илнең өлкән агасына мондый сүзне әйтә алган телең корысын!»— диделәр.

XXIX — XXXVIII

Вафат булган Байтүрәне күмү йолалары үтәлә. Җеназа намазы укыла. Садака һәм бүләкләр өләшенә. Байтүрәне ләхеткә төшереп күмәләр. Зираттан кайткан халык тирмәләргә җыела. Коръән укыла. Тапкыр сүз көрәшенә нигезләнгән мәҗлес башлана. Ул ыруг-кабиләләрнең үзара көрәшүче ике төркемгә аерылып таралуы белән тәмамлана. Сарсымбай, Арысланбай, Биремҗан аксакал бергәләшеп Алтын-Күлгә кайталар. Икенче көнне таң беленгәндә, Сарсымбай җәйләве яңа урынга күчеп китә. Юлда Карлыгач яшьлек дусты Чулпан килен булып төшкән җәйләүдә була, аның авыр тормышын белә. Яңа урында — Кызыл-Комда җәйләү торгызу эшләре башлана. Саубуллашканда, Арысланбай Карлыгачка бер-ике көннән урлап китәчәген әйтә, әзер булып торырга куша.

XXXIX

Канлы, кызгылт ут эчендә туган иртәнге кояш даланың туфрагын партия талашлары эчендә каршы алды.

Якуп белән Янгырбай җеназага җыелган җәмәгатьнең юк өчен сүз чыгарып, кычкырышып таралуларын яхшы аңладылар. Үзләре белән барачак ыругның, партиянең юлбашчыларын шул көндә үк җыйдылар, киңәш кылып, эшкә тотындылар. Кемгә мал бирергә, билек, авылнайлык вәгъдә кылырга, дошман арасына ничек коткы салырга — һәммәсен уйлаштылар.

Азымбай карт теге вакыттагы гөнаһлы уеннан кайтты, аттан төшмичә, кирәк адәмнәрне күреп, көн-төн чапты. Бер тәүлек эчендә йөз чакрымны урап кайтып, асыл аргамакларны яндырган вакытлары да булды. Сайлау көнендә артык шар алу өчен түгеләчәк алтынның, өләшенәчәк аяклы малның, бирeләчәк чапанның, тунның хисабына чик куелмады. Берничә йөз кара, егерме-утызар мең алтын чыга икән, моның алдында, әлбәттә, тукталмаячаклар.

Рөкыя байбичә бу талашның үзәгендә иде. Ул кайчандыр Сарсымбай бикәсе Алтынчәчкә әйткән сүзен яңадан хәтерләде:

«Кирәксә — мал бирәбез, кирәксә — кыз бирәбез, кирәксә — җир аударабыз, мәгәр үз дигәнебезне кылабыз!»

Арада бик куркыныч бер хәл бар иде. Яңгырбайның кызы Гөлфаныс, җиде яшендә чагында ук әйттерелгән адәмен яратмыйча, башка берәү белән тамырлык кылып йөри иде. Бу соңгы бүз бала үзенең сөйгәнен, караңгы төндә дүрт җегет белән килеп, ат өстендә урлап качкан иде. Бу сәбәптән Яңгырбай ыругсы белән кияү йорты арасында зур талаш чыгарга тора, әгәр бу вакыйга була калса, найманнар белән кара-айгырлар партиясеннән җәберләнгән кодалар ыругсы, болардан китеп барып, Сарсымбайга кушылачак, йә үзләре бер партия булачак, яисә читтә катнашмый калачак — һәр тәкъдирдә зур зыян киләчәк иде. Бу кодалык Рөкыянең үз диме, үз осталыгы белән ясалганга, ул, ант итеп, көрәшкә катнашты. Азым әкә аркылы кырык җегетне җыйдырды, итнең симезен астырды, кымызны мул куйды, һәммәсенә бүләкләр вәгъдә кылды. Бүз балаларның берничәсе, сыйланып, өйләренә китсәләр дә, башкалары, байның йөгерекләрен менеп, урлаган җегетнең авылына бардылар. Яман сүгенеп, илне мыскыл кылып, кызны кире алып кайттылар. Гөлфанысны урлаган ил байлыкта урта булганга, Рөкыянең артында урыс түрә торганын яхшы белгәнгә, яңадан сугыш башларга батырчылык кылмадылар.

Бу вакыйга тирә-якка зур хәйранлык бирде, ярылып китәргә әзер торган кияү кабиләсен тагы ныграк боларга баглады: найманнар белән шаярырга ярамавын күрсәтте.

Сарсымбайлар өчен бу зур бер күңелсезлек булды. Ләкин моңа карамастан, алар талашны көчәйтә бирделәр.

Болар Яңгырбай, Якуп кебек аксөяк түгелләр, алар чаклы алтын, мал да тарата алмаслар, кирәк вакытта ярдәм итәргә артта урыс түрә дә юк, шулай булса да, Биремҗан аксакал җиңүгә нык ышана иде. Найманнарны халык ак патшаның йомышын үтәүче дип карый, тыштан хөрмәт күрсәтсә дә, эчтән дошманлык саклый, яхшы җәйләүләрнең китүенә, казакъ йорты, тар кабер кебек, һаман кысыла баруына баш сәбәп — шул Байтүрә нәселе дип уйлый, гөнаһсыз җир аударылган, богауланып, каланың абактыларында яткан казакъларның язмышы өчен шул Байтүрәләрне шелтәли иде. Илнең, йортның күпчелеге шулай карагач, инде акыллы-усал Байтүрә морзаның калдыкларына казакъ баласы тавыш бирмәс дип иман китерә иде.

Сарсымбайда үткәргән төндә сүзнең күбе шул турыда булды.

Туктаусыз симез найманнарның яман кара тарихларын, үзе алар белән ничек көрәшкәнен озак-озак хикәя кылды.

Карт, чыннан да, бу фаҗигаләрнең җанлы тарихы иде.

Аның бабалары Кече йөздә Әбелхәер кул астында яшәделәр. Үзенең дәрәҗәсенә канәгатьләнмичә, өч йортның уртак өлкән ханы булу исәбендә йөргән Әбелхәер, калмыклар белән сугышны бәһанә[1] итеп, ак патшага койрык болгый башлагач, Бирем әкәнең ерак бабасы Торсынбай өлкән ханга әйтте: «Лачыннан котылдырам дип, бөркет авызына ташларга телисең, исемең Әбелхәер булса да, эшләгәнең хәер имәс»,— диде. Кабиләсе көчле булганга, хан аңа ашыгып җәза бирә алмады. Ләкин үз юлыннан тукталмады. Тәфкилев килеп, Петербург ягын каера башлагач, Торсын тагын түзмәде. Әбелхәернең кардәше Бүребай белән татар генералының йөзенә бер камчы орды да тулпары белән далага качты, шуннан Кече йөзне бөтенләй ташлап, Урта йөзгә күчте. Кәрван башы Мостафа дигәнгә ялланып, Кызылъяр, Күкчәтау, Сими, Ташкент, Троицк араларында кәрван йөртте. Картая башлагач, шул якларда мал асрап, бер илгә кушылып, җәйләү тотып яшәп калды. Торсынның балалары зур бай да булмадылар, тынычлык та тапмадылар.

Биремҗан балалык, яшьлек чакларын шул әкиятләр эчендә үткәрде.

Җегет булгач, азаматлык белән дан чыгарды. Ир уртасы чагында ул үз ыругсы кызылкортлар арасында гына түгел, башка кабиләләр эчендә дә аләүмәт эшендә ил агасы булып торган иде инде. Сары-Арканың ханнары бетерелде. Алар артыннан диванлык[2] төзелеп, ага солтаннар мәйданга чыгарылды. Бара торгач, болар да югалды: дала авылнайлар, биләр, булыслар кулына калды.

Болар, элекке вакыттагы кебек, аләүмәт эшендә зур хезмәтләр кылганлыгы, җәмәгать файдасына яшәгәнлеге өчен ыругның, кабиләнең ышануы буенча дәрәҗәгә менгән аксакаллар түгел, мәгълүм туфракта утырган халыкның сайлавы буенча гына куелалар иде.

Бу сайлауларда илгә хезмәт иткәнлек түгел, байлык, мал түгүлек беренче рольдә булып китте.

Элеккечә, кан-ыруглык нигезе җимерелеп, мәгълүм туфракның сайлавы мәйдан алгач, бу урыннарга урыс түрәнең

[1] Бәһанә — сәбәп, сылтау.
[2] Диван — дәүләтнең югары киңәшү оешмасы.

яратканнары, аның теләгәннәре үтә башлады. Биремҗан аксакалны берничә мәртәбә булыслык, билек урыннарына сайларга теләделәр, ләкин ул якын бармады, казакъ түрәләренең күкрәгендәге дәрәҗә медальләреннән җирәнеп сөйләнде: «Боларны эт муенына таксыннар, үз муенымны алар белән пычратмам»,— дип, мыскыл итеп көлде.

Бирем әкә шулай йөргәндә, борынгы ханнарның, ага солтаннарның балалары заманның барышын сизделәр, көчнең кайдалыгын күреп, бөтенләй икенче юл тоттылар.

Найманнарның берәве бу туфракта, үзе тырышып, мал түгеп, булыс булды. Якыннарын авылнай, би кылды, илнең-йортның эше боларга күчте. Ак патшаның адәмнәре боларны үз итеп кабул итте.

Биремҗан аксакал тагы яңа дошман алдында калды.

Моңарчы тик кайһәрләп йөрсә дә, Байтүрә үлгәч, ул инде, үзенең картлыгына, сукырлыгына карамастан, ак сакалын күтәреп, талаш мәйданына чыкты.

Үзе дәрәҗә эзләми, аләүмәтнең файдасын күзәтер дип, Сарсымбайны Байтүрә урынына булыс ясап үткәрергә тели; бусы барып чыкса, яман авылнайларны, ришвәт буенча эш йөрткән биләрне аннан соң берәм-берәм төшерергә, урыннарына юньле, ак күңел адәмнәр куярга уйлый иде. Арысланбайның Карлыгачка кул сузуы кара-айгырлар белән дошманлык тудырачагын яхшы белгәнгә, җегетне шелтәләве шул яктан иде. Сарсымбай өчен бу бик зур терәк иде.

Арысланбайдан соң төн буена сөйләшеп кундылар. Карт теләсә дә, иртә белән Сарсымбай аны тагы җибәрмәде:

— Кодаларым да килә, сезнең белән бергә киңәш итмәсәк, хәлебез яман,— диде.

Ләкин кунаклар да кунаклык өчен килмиләр иде. Алар янына танабугадан илнең бае Ирҗан, кызылкорттан Әхмәт чакырылды.

Болар найманнан җәберләнгән, яхшы җәйләүләре алынган, юк-бар сәбәп белән зарар күргән, моның өстенә кодалык, һич булмаса, билкодалык кебек җепләр белән сарманнарга бәйләнгән кабиләләрнең башлыклары — байлары иде.

Сарсымбай булыс булса, башкалары би булып, авылнай булып үтәргә тиешле иде.

Туктының симезләре суелды, кымыз мул куелды, байбичә, кунакларның кадерен белеп, бик сирәк ашлардан булган куырдак, көйгән бөйрәк кебек сыйлар хәзерләтте.

Яңа җәйләүнең саф һавасында майлы ит белән карынны тутырып, кымызны әбдән мас булганчы эчеп, илнең өлкәннәре көн буенча киңәштә үткәрделәр.

XL — XLIII

Күпчелек ыруг-кабиләләрнең кемне яклаячагы ачыклана. Биремҗан аксакал, Сарсымбай уртадагыларны үз якларына аудару турында фикер алышалар. Сарсымбай, серләрен найманнарга җиткерүдә гаепләп, ялчысы Җолкынбайны кыйный. Егет Юныс картка үзенең кайгысын, бәхетсезлеген сөйли. Арысланбай үзенең өч егете белән Карлыгач-Сылуны урлап кайтырга дип юлга чыга.

XLIV

Кызга алдан хәбәр җибәрелгән иде. Айбала киленчәк күлнең төньягына карый торырга, әгәр камышка атлар тукталса, барып белешергә дә Карлыгач-Сылуга әйтергә тиешле иде. Ләкин бүген кичкә каршы бер-бер артлы мәшәкатьләр чыга торды. (...)

Хатын чарасыз иде. Алтынчәчкә булышып, әйбер хәзерләп йөрде. Тик тукал казаннан ит бушатып, йортның өлкәннәре кул юып, табынга утыргач кына, Айбала киленчәк башка мәшәкатьләрдән котыла алды. Авылның иң читендәге фәкыйрь тирмәсенә кайтып, аз гына утырган иде, аның үткен колагы төн ягыннан берничә атның дөп-дөп басып килгәнен ишетте. Җиргә ята биреп тыңлады, тавыш тукталды.

Хатын серне аңлады, күл буенча камышка таба тизләп йөгерде: анда бераз яшеренә төшеп, колакларын кайчы кебек торгызган иярле атлар янында берничә колакчын торганы күренә иде.

Арысланбай кулындагы камчысын уйнатып каршы килде:

— Алтынчәч байбичә белән Бирем әкәнең яман шелтәсен ишеттек, мәгәр башкача амалымыз юк, без көтәбез,— диде.

Киленчәк, кутан ашасыннан ашыгып килеп, ак өйгә керде.

Ни күрсен, ана белән кыз, акрын гына сөйләшеп, сай табактан майлы итне, казылыкны ашап утыралар. Тыш яктан иң тыныч бер мәҗлес. Сүз белән әйтә алмады, мәгәр кызга бер караш ташлады, шуның белән бөтен эшне аңлатты.

Байбичә, гадәт буенча, киленчәкне ашарга утырырга чакырды. Ләкин Айбаланың йөзендә, каушаган тавышында ни дә булса барлыгы мәгълүм иде. Карлыгач-Сылу, сизенеп, яшерергә теләде, киленчәккә:

— Карагым, әнә торган сөлгене алып бирсәңче!— диде.

Хатын бераз тынычланды, кызга сөлге биреп, үзе табак янына утырды. Кыз яңадан бер-ике капты да, кулын сөртеп, гадәтне бозу булса да, башкаларның беткәнен көтмичә, комганын алды, башына, өстенә киде дә, ак тирмәгә бәхилләшкәндәй бер күз йөртеп, далага чыкты.

Аның шул чыгуы унсигез ел яшәгән гаиләсеннән бөтенләйгә китүе, күңеле сөймәгән Калтайдан да, ул адәмгә бирү өчен, тиздән туй ясап озатырга хәзерләнгән кадерле әкә-чичәсеннән дә качуы — котылуы иде.

XLV

. . . .

Яман-Чүл җәйләве бүген яңа хәбәр белән уянды:

— Арысланбай җегет Сарсымбайның кызы Карлыгач-Сылуны бу төндә урлап алып кайткан!

Моны башта ялчы хатын белде. Ул, куркып, хәйран калып, куйчыга сөйләде, аңардан көтүчегә, ялчыга, аннан берничә минут эчендә бөтен авылга таралды. Карлыгач-Сылу, иң гади киленнәр кебек, башына урамал бәйләп, кулына чиләк тотып, Арысланбайның апасы белән кутанга бия саварга чыккач, бу инде бөтенләй бер бәйрәм төсен алды. Кимперләр, өлкән хатыннар, килеп, аркасыннан сөйделәр.

— Яхшы аягың, ак бәхетең белән кил!— дип сәламләделәр.

Җегетләр, читләр күз салдылар:

— Арысланбай кызның асылын таба белгән,— дип мактадылар.

Куйлар, сыерлар куылып, колыннар бәйләнгәч, җәйләүнең төрле ягыннан картлар килделәр. Боларның телендә сәлам, котлау булса да, йөзләрендә, күзләрендә курку күренә иде. Кыз урлауны күп күргән, күп ишеткән бу өлкән адәмнәр шулай ук моның ахырын да беләләр иде. Яңгырбай кызын урлаучы җегетнең ыругсына, йортына килгән кебек хәлләр боларны бераз хафалый иде.

Ләкин күп белдермәделәр, киленне яраттылар, инде ни күрсәк тә, Сарсымбай ничаклы адәм җибәрсә дә, каршы торып, якларга тиешлеген эчләреннән беркетеп таралдылар.

Бүген бия суелды, кымыз күп эчелде. Карлыгач-Сылуның килен булып төшүен уен-көлке белән, ат чаптыру белән шаушу кылып үткәрделәр.

Ләкин чын туй алда иде әле.

Яңа кушылган ике яшь, алдагы куркыныч катнаш бәхетле минутлар эчендә, сарманнар белән кара-айгырлардан нинди хәбәр килүен көтеп яши башладылар. Карлыгач үзен богаудан котылган адәм кебек сизенде, нинди генә талашлар, сугышлар, рәнҗешләр булса да, яңадан Калтайга бармаска ант итә-итә, бу яңа җәйләүдә яшь киленчәк булып калды.

XLVI

Кызның урлану хәбәре ил кыдырып, кымыз эчеп, кызык эзләп, кыз күзләп йөргән бүз балалар, сайлау алды талашы белән җәйләүдән җәйләүгә туктамый чапкан агалар аркылы бөтен далага шул көн эчендә таралып өлгерде.

Дошманнар шатландылар. Яңгырбай белән Якуп, моны ишетү белән, кара-айгырларга адәм җибәрделәр. Кияү җегетенең мондый хурлыкка төшүен күтәреп калу ярамый гуй, дип коткы салдылар. Сарсымбай белән танабуга һәм сарман йортларын талаштырырга ут кузгаттылар. Һәм моңа нык ышаналар иде.

Дуслар тирән хафага төштеләр. Сарсымбай белән байбичә, башларын уып, ачудан кара көйделәр.

Алтынчәч:

— Өлкән атаның баласы дип кунак кылдым, килсә, түремә утырттым, ашымны ашап, йортыма... китте,— дип, яман тиргәнде.

Калымлыгы урланган Калтай:

— Мин ул атаңа нәләт балага күрсәтим, кара-айгырлар белән алай шаяру буш үтмәс!— дип сүгенеп, кызны Яман-Чүл җәйләвеннән сугыш белән кире алу өчен, үз тирәсендәге җегетләрне оештырырга, кымыз белән, ит белән сыйларга, кан кыздырырга, кабилә намусын уятырга тотынды.

Арада иң каты хафаланган адәм Биремҗан әкә булды.

Хәбәр килгәндә ул үз авылының бае — Әхмәтнең өлкән тирмәсендә кунаклар белән кымыз эчеп, борынгы әңгәмәләрне сөйләп утыра иде. Ишетүгә, кинәт аягүрә басты. Таягын алды, сабырын югалтты:

— Яхшы атадан туган ул яманга мин әйттем гуй: бала булма, акылыңа утырыр чагың җиткән, дидем... Сүземне алмаган икән, атаңа нәләт!— дип, шундый әрләде, күп еллардан бирле карттан мондый сүзләр чыкканы юк иде.

Аксакалны куркыткан нәрсә ике кабилә арасында талаш башлануы иде. Чөнки моңардан дошманнар файдаланачак, симез найманнар тагы җиңәчәк иде.

Әхмәткә әйтте:

— Атларыңны җиктер, мин хәзер кара-айгырларга китәм,— диде.

Яше сиксәнгә җитеп, күзе сукырайган карттан мондый кискенлекне күреп, һәм гаҗәпсенделәр, һәм сокландылар.

Бер сәгать вакыт үтмәде, тарантаска җиккән ак ат кара-айгырлар ыругсының башлыгы Сарыбайның җәйләвенә, өлкән ак тирмәнең артына килеп туктады.

Монда таяк тыгылган кырмыска түндәге кебек кайнашалар, талашалар иде. Һәммә сүз кара-айгырларның уналты ел буенча калым түләп килгән кызларын урлаган танабугалардан һәм урлаткан сарманнардан ничек намус кайтару турында иде.

Сарыбай хафалы йөз белән каршы алды. Аптыраган, каушаган рәвештә кунакны сәламләде, өйгә кертеп утыртты да:

— Өлкән ата, безгә ни кылырга киңәш бирәсең? Кара-айгырларның намусларын таптадылар гуй!— диде.

Аксакал юл буенча бөтен әйтәчәген уйлап, тәсбих кебек тезеп, санап килгән иде.

— Балалар,— диде,— ашыкмагыз, минем килүем дә шуның өчен: кара-айгыр йорты гомер буенча симез найманнар белән талаш кылды, дошманнарыгыз күп, инде тагы яңа бер дошман арттырудан сак булыгыз,— диде.

Халык тирмәгә тулган, ире-хатыны, яше-карты бары да мондалар иде. Арадан бер карт, торып:

— Кыз җегетнеке имәс, бөтен илнеке... Борынгылар: «Ирдән китсә дә, илдән китмәс»,— дигәннәр. Безнең кара-айгыр йорты, алач кычкырып, сугыш кылып, үз киленебезне үз йортыбызга кайтарырга әзерләндек,— диде.

Башка картлар да моңа шаулап кушылдылар. Җәберләнгән кияү кечкенә буе, ямьсез карлыккан тавышы белән ниндидер тәртипсез сүзләр сөйләп китте:

— Малым бетсен, йортым таралсын, мәгәр мин ул Карлыгачны кара-айгырга кайтармый туктамам,— диде.

Ләкин бу сүзләр тиешле нәтиҗәне бирмәделәр. Калтайны начар менәзе[1] өчен дә, казакъ йортында булмый торган ят бозыклыклары өчен дә үз иле яратмый иде. Аның атасы Иржан,

---

[1] Менәз — характер.

түрәлек хыялы белән җенләнүчеләрнең берсе булганга, улын, түрәлеккә хәзерләү өчен дип, аз-маз хәзерләтеп, семинариягә биргән иде. Бер елдан соң аннан ниндидер усаллык өчен кудылар. Бер кимпер аны: «Урыс булмады, казакълыгын да югалтты!» — диде, халык та шулайрак карый иде. Кызның урлануына каршы баш күтәрү — җегет өчен түгел, ыругның намусы өчен иде.

Аксакал сүзләрен тыңлады да, кабиләнең үз эчендә дә ике төрле уй барлыгын күргәч, ачык кискен сүзләрдә озак вәгазьләде:

— Ул яман җегет үз кылганының обалын[1] табар, мәгәр илнең өлкәннәре акылга салсыннар, озын чәчле бер аял өчен талаш кузгатып, кан түксәк, дусларыбыз җылар, мәңгелек дошманнарыбыз — ак, симез найманнар бәйрәм итәрләр, безгә рәхмәт әйтерләр, ашыкмагыз, уйлап эшләгез,— диде.

Әгәр Калтай урынында илнең үз итеп, йөрәгендә асраган сөекле җегете булса иде, аксакал, бәлки, күп эш чыгара алмаган булыр иде. Әгәр явыз дошман найманнар күз алдында көлеп, теш ыржайтып, талашыгыз, берәм-берәм барыгызны йотарбыз, дип тормасалар, җегет нинди генә кадерсез адәм булмасын, аксакалның сүзе үтмәс, кара-айгырлар, бер мәртәбә кузгалып, киленне бу йортка кайтару өчен, бер күтәрелеп караган булырлар иде. Ләкин шул югарыгы сәбәпләр үзләрен күрсәттеләр. Бирем әкә сүзеннән соң кара-айгырның өлкәннәре уйга калдылар.

Күп талаштан соң, җегетнең даулавына карамастан, Биремҗан аксакал илнең канын басты, талашны туктата алды:

— Сарман белән танабугаларның өлкәннәре килеп, караайгырга арыз күрсәтәләр, бирелгән калымны барлык туган балалары белән кире кайтаралар, шуңа риза булмасалар, бу йорт үз намусын ат өстендә алач кычкырып, яу кылып алачак!

Шуңа килештеләр. Аксакал Кызыл-Комга китте. Үзе белән кара-айгыр кабиләсенең өлкәннәреннән дүрт казакъны ияртте. Болар ике йортның арасында булган талашны төзәтер өчен илчеләр иде. Барысы бергә Сарсымбайга килделәр. Анда бөтен авыл курку эчендә, хафа, кайгы эчендә иде.

XLVII

Ләкин кызылкорт белән кара-айгыр өлкәннәренең бергә килүен күргәч, Сарсымбай эшнең кая барганын тиз аңлады. Байбичә, йөрәге белән әрнесә дә, фаҗиганең кансыз, талашсыз

[1] Обал — гөнаһ.

бетәчәген сизенде. Бу җәйләүнең өлкән өендә тагын ыругның, илнең өлкәннәре җыелды. Күп каты сүзләр, үпкәләр әйтештеләр. Менә хәзер талашачаклар да сикереп атка менәчәкләр, һәр ике як үз юлына гауга өчен китәчәк дигән куркыныч минутлар булды.

Ләкин Сарсымбайның сабырлыгы җиңде. Күп талашлардан соң кара-айгырлар җәйләвендә, Сарыбайның өлкән өендә булган килешүне монда да кабул кылдылар. Тик Сарсымбайның каты торуы буенча андагыга кечкенә бер кушымта арттырдылар:

— Сарсымбай үзенең кызы Карлыгач-Сылу өчен алган калымнарын бөтен көенчә кире кайтарачак. Мәгәр бу малның, акчаның яртысын Арысланбай кызның атасына түләргә тиеш.

Бу соңгысы бераз гаҗәбрәк булып чыкты. Кайбер картлар моңардан мыскыл итеп көлделәр:

— Юк белән әвәрә кыласыз, безнең атларны җилгә бәйлисез. Кызыңны урлап киткәннән калым сорамак — казакъ йортында булмый торган бер эш... Әгәр танабугалар моңа риза булмасалар, кыйлачагыңыз ни нәрсә?— дип көлделәр.

Тагы талаш, каты ачы сүзләр белән үпкәләш китте. Бирем әкә, җыелганнарның һәммәсенә яман ачуланып, тавышны туктатты:

— Башларына тай типмәгән булса,— диде,— танабугалар моңа күнәрләр! Яхшы сүз колакларына үтмәсә, үзләре белән бергә дүрт ыругның каты камчысына ничек түзәрләр?!

Бу каты сүз иде. Моның астында «әгәр ике йортның киңәшенә буйсынмасалар, аларга каршы дүрт кабиләнең сөңгесе тора» дигән мәгънә бар иде.

Кымыз күп эчелде. Туктының яхшысы асылган, куырдак ясалган иде. Илне канга батырачак бер эштән болай котылуларына шатланып, әңгәмәне суктылар да, дәүләтең мул булсынны әйтеп, илче кунаклар Сарыбай җәйләвенә килешү булганлыкны хәбәр итәргә юнәлделәр. Биремҗан аксакал үз иленә кайтып китте.

Ләкин аның эше бетмәгән иде әле. Авылның бае Әхмәтне, өлкән яшьтәгеләрне җыеп сөйләде дә Яман-Чүлдән Арысланбайны чакырырга кушты.

Бүген бу җәйләү куркыныч астында иде. Ике якның берсе, яу булып килеп, авылны басар, кызны яңадан алып китәргә гауга чыгарыр дип көтәләр иде. Һәр хәлгә каршы ирләр, беркая китмичә, бай йортында ит ашап, кымыз эчеп гомер уздыралар,

байтак атларны иярдә тоталар иде. Коргак-Күлдән атчабар күренгәч, бераз тынычландылар. Бай җегет белән берничә картның чакырылу хәбәре бу тынычлыкны тагы арттырды. Эшнең килешү белән бетәчәгенә өметне зурайтты. Кичә кыз урлап кайткан атларны яңадан иярләттеләр дә ыругның ике өлкәне белән Арысланбай җегет Бирем әкәнең җәйләвенә юл тоттылар.

Аксакал кунакларны яман шелтә белән каршы алды:

— Байлыгыңыз зур түгел, ыругыңыз кечкенә... Үз чамагызны онытып, ахмак арысландай айга сикерәсез... Кара-айгырларга, сарманнарга каршы гауга чыгарып, бу далада кем белән яшәргә уйладыгыз?— дип озак тиргәде.

Җегетнең кире чигенергә исәбе күренми, мәгәр сүзендә, йөзендә, гадәт буенча, бераз үзен гаепле күргәнлек төсе бар иде:

— Безне чакыртуыгыз ни өчен иде, өлкән ата?— диде.

Карт бераз кыза төште:

— Сине — камчылар өчен, картларны киңәш кылу өчен чакырдым!— диде.

Танабуганың арада өлкәне бер сүз әйтте:

— Казакъның менәзен, йоласын Бирем әкә бездән яхшы белә дип ышанабыз, җегет үзенә тиң кызны урласа, ул кире кайтарылмый торган иде!

Кызган каннарга бу бераз ут өстәде, аксакал тагы яман сүкте.

Ләкин кунаклар телләрен тешләделәр, алар, үзләренең шәрәфен саклау белән бергә, гауга чыгармыйча бетерү ягындалар иде.

Карт сөйләп бирде. Килешүнең юлларын аңлатты. Урлаган кызга калым сорауны казакъ йортында беренче ишетәбез дип, болар да бераз гаҗәпләнделәр. Беремҗан чал тагы баягы сүзен әйтте:

— Калым түләмәсәгез, кара-айгыр белән сарманның камчысын ашарсыз!

Тагын бераз кызыш-талаш китүе мөмкин иде. Арысланбай эшне җиңел өзде.

— Безгә карындаш булган ике ыругның өлкәннәре биргән киңәшне бозарга амалыбыз юк, мин Сарсымбай йортыннан кара-айгырга кире кайтачак барлык калымның яртысын кызның атасына түләргә ризамын,— диде.

Шуның белән килешү булды. Танабуганың өлкәннәре:

— Безне зур талаштан коткардыгыз,— дип, аксакалга рәхмәт әйттеләр.

Китәр алдыннан җегет Бирем әкә ыругсының һәммәсен үз җәйләвенә кунакка — туйга чакырды.

— Бу өлкән шатлыкны бәйрәм кылып, туй ясап үткәрергә телибез, берсекөнгә безгә рәхим итәсезләр,— диде.

Шул ук көндә танабугаларның өлкәннәреннән ике адәм, яхшы атларны иярләп, яңа көпеләр, яңа колакчыннар киеп, бай белән байбичәгә, тукалга, илнең өлкәннәренә асыл бүләкләр, алтын акчалар алып, Кызыл-Ком җәйләвенә кодалык белән киттеләр.

Шуның белән Карлыгач-Сылу өчен күтәрелгән гауга бер дәрәҗәдә басылырга исәпләде. Тик кияү җегет Калтай гына моңа буйсынмады, агасы Сарыбайга каты бәйләнде:

— Кызны, сугышып, яңадан үз йортыма китерәм. Булмаса, үз намусын үзе саклый белмәгән бу илне ташлап китәм!— дип, тавыш кузгатудан, нәрсәгәдер әзерләнүдән тукталмады.

Моның белән ул үз ыругсы каршында кадерен тагын бетерде, аксакалларның, өлкәннәрнең киңәшен тотмаганга, аны үз адәмнәре дә шелтәли башладылар. Моңа каршы ул симез найманнар белән дүрткаралар арасында үзен яклаучылар тапты. Яңгырбай астан ут йөртте: «Уналты еллык калымлыгын тартып алганда да, үз баласын яклый белмәгән ыругның намусы кайда икән?»— дип, коткыны туктатмады. Азымбай карт бу эш өчен, җәйләүдән җәйләүгә чабып, күп ат тирләтте. Мәгәр йөри торгач, ул үзе дә, кара-айгырларның осталыгы аркасында, Сарсымбай партиясенең тозагына килеп эләкте.

XLIX

Кояш күренмәде. Иртәдән үк авыр, карасу болытлар даланың өстен каплап алдылар. Җил кузгалды, өзек-өзек каты яңгыр үтте. Дөнья ямьсез, һава юеш, салкын, сахра күңелсез иде.

Бүген сайлау була.

Һаваның начарлыгына карамастан, елгасыз, күлсез тигез яланның уртасында утырган ак кирпеч өйнең бөтен тирә-ягы мәхшәр кебек халык белән тулган иде.

Илнең өлкәннәре, авылнайлары, байлары, биләре, аксакаллары әнә шул тәбәнәк, киң, акбурлы, өч кенә тәрәзәле өйнең эченә тыгызланып кереп утырганнар, тышта һәр ике якның адәмнәре шулчаклы кан кайнаткан бу талашның ахырын күрергә җыелганнар. Иярле атларның исәбе юк. Ике ат җигүле тарантаслар, дугасыз дышлолар, ике тәгәрмәчле арбалар,

бәйләүле төяләр, болар тирәсендә шаулап йөргән көпеле, колакчынлы казакълар, яшьләр, картлар, урамаллы хатыннар, нидер көтеп, сабырсызлык белән шаулашалар иде. Бер читтә, үзенең ак дөлбәр төясенә менгән хәлдә, Сарсымбайның бичәсе Алтынчәч күренә. Икенче якта кыйммәтле экипажга кырын ята төшеп утырган данабикә Рөкыя кем беләндер сөйләшеп тора... Яшел тасмалы, сары төймәле кара шинелен киеп, яшел читле фуражкасын бер якка салып, кылычтан, револьвердан, зур мыеклы, кырган сакаллы стражник хохол Крапченко бик зур вәкарь белән тәртип саклап йөри...

Җәмәгатьнең шау-шуы арасында кем җиңәр, кайсы як күп алыр дигән сүз еш ишетелә, ара-тирә талашып та алалар. Ләкин эшнең чамасы Якты-Күл җәйләве файдасына бармаса кирәк. Найманнар белән дүрткараларның йөзләрендә, сүзләрендә ниндидер бер шөбһә сизелгән кебек. Әмма кызылкорт, караайгыр, сарман, танабугалар исә күкрәкләрен киереп, тавышны күтәреп сөйлиләр. Арада Җылкычы ата Юныс карт та күренә. Ул туктаусыз сөйли, өем-өем торган җәмәгатьнең әле берсенә, әле икенчесенә бара. Бер җирдә, Сарсымбайны мактап, Якупны чәнчә, дошманнарны уен сүз белән шаярта:

— Күрмәгәнегезне күрерсез, симез найманнар,— ди.— Ханнар, агай солтаннар баласының яхшы нәсел тулпарын казакъның җай юртагы Байчобар бүген узып киләчәк,— ди.

Аның бу сүзе тиз тарала, кара болыттай капланып, тулкын кебек шаулап торган киң мәйданда авыздан авызга йөри башлый. Каршы як тавышлана, каннар кыза...

Шулвакыт кирпеч өйнең ишеге ачыла, аннан өстенә көпе кигән, башы ялангач, җиту чәчле казакъ җегете йөгереп чыга да, шунда торган атка сикереп менеп, ияргә аягүрә баса, кулын авызына куеп, бөтен мәйданга каты, ачык санаулы тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Казакъ йорты өчен зур сөенеч булды! Илнең теләгәне табылды: Сарсымбай ундүрт шар артык алды!.. Якуп җиңелде!!!

Мәйдан гөж килә. Коточкыч шау-шу күтәрелә. Җәяүлеләр, атлылар, бер-берен таптап, управлениенең тәрәзәсенә, ишегенә тыгызланып капланалар, стражник Крапченко:«Бунт чыгарасыз, безобразие!»— дип, халыкны куарга, тәртип урнаштырырга азаплана; арттан килгән тулкын белән аны егып, аяк астына изеп үтәләр. Арбалар, төяләр, тарантаслар урыннарыннан кузгалалар, эләгешәләр, кучерлар үзара кычкырышып, камчылашып алалар.

Берничә минут үтә, эчтән чал сакаллы, ялтыр погонлы, кылычлы, рәсми киемдә начальник килеп чыга. Аның йөзендә ачу төсе бар, иреннәре дерелдиләр. Янгырбай белән Якуп аңа нидер әйтәләр, болар да кара көйгәннәр.

Ул арада калын, симез гәүдәле, тоташ муенлы, тар иякле, киң маңгайлы шат, көләч йөзе белән Сарсымбай ишектә күренә. Җылкычы ата белән чәчле җегет шауларга тотыналар, җәмәгатьтән күбе моңа кушыла: кычкырып, көлеп, тавышланып, аның тирәсенә җыелалар. Бөтен мәйдан кузгала, тулкыннар бер-берен аударалар.

Шул шау-шу эчендә иярле атлар, тарантаслар, төяләр далага чәчеләләр, җәйләүләргә таралалар.

L

Кыш уртасы җитте. Киң дала тирән кар астында калды. Симез җылкылар уйнаклап йөргән җәйләүләрдә хәзер инде күз ачкысыз ачы буран белән яман җил ажгыра; ач бүреләр, көннең зәһәр суыгына түзә алмыйча, кич малга баруны исәпләп, шул карлы давыл эчендә караңгы төннәрне көтеп, тешләрен шакырдатып йөриләр. (...)

Даланың кар баскан юлларыннан җәяүләп, зур буйлы, начар киемле бер казакъ җегете Сарсымбай кышлавындагы бер йортның капкасына тукталды, җавап булмады. Тәрәзә шыкылдатты, һаман тавыш чыкмады. Юлчы: «Адәме йоклаган булса, этләре өрергә кирәк иде»,— дип, балчык койма ашасыннан ишегалдына сикерде.

Монда адәм аягы басмаган, сукмак салынмаган тирән кардан башка нәрсә юк иде. Төньягында киң, тәбәнәк түбә, кыексыз балчык азбарлар кар эченнән ауган капкалары белән чак кына күренеп утыралар.

Җегет бераз аптырап калды.

Ул байның җир аударылганын белә, аның җәй көне үк киткәнен дә ишеткән иде. Ләкин бит байбичә Алтынчәч белән тукалны сөрмәделәр, малны алмадылар. Болар кайда булыр?

Юлчы яңадан тыш якка төште дә, кышлау буйлап, як-ягына карана-карана китте. Арада зур тәрәзәле, түбәсе кыеклы, үзе агачтан салынган өй — тик шул Сарсымбайныкы иде. Монда башка өйләрнең барысы да балчыктан эшләнгән яки бөтенләй җирне казып ясалган, бик кечкенә бер-ике карындык тәрәзәле, түбәләре тигез, үзләре кардан чак кына башлары күренеп торган кызганыч землянкалар, җимерек алачыклар иде.

Малга иркенлек өчен, җәй көне бүленеп, сигезәр, унар гаилә бер авыл булып йөрсәләр дә, җәй көне аерым йөргән йортларның байтагының кышлаулары бергә иде. Монда барлыгы утызлап өй бар иде.

Юлчы авыл өстеннән бер мәртәбә күз йөртте дә тәрәзәсеннән кечкенә генә ут яктысы күренгән бер йортка барды. Зур, усал эт аны һаулап каршы алды. Берсе балчык өйгә терәп, берсе аерым салынган тәбәнәк, киң балчык азбарларда атларның ашавы, сыерларның акрын гына күшәве ишетелде. Болар җегеткә җан бирделәр, малның беразы йортта асралганын күрсәттеләр. Аңа, һәрнәрсәдән бигрәк, атларның өйдәлеге кирәк иде. Тыштан кар баса башлаган кечкенә ишекне шакылдатты.

Эчтән тавыш килде.

Җегет, тышкы ишекне ачып, алдагы бүлмәгә керү белән сәлам бирде.

Түрдә, сәке өстендә, инде ятарга әзерләнгән, сирәк сакаллы, чуар көпеле, аягында читекле, өлкән карт утыра иде. Сәламен алды, кунакка шат булганлык тавышы белән:

— Юл булсын, балам, түрдән уз!— диде.

Мөсафир барып күреште, ни кылып йөргәнен әйтте.

Мич янында, салкын өйне йокы алдыннан азрак җылытыйм дип, ягып, өреп азапланган киленчәк бар иде, җегет аңа:

— Аманмысыз?— диде.

Килен башын күтәрмәде, акрын тавыш белән җавап кайтарды:

— Шөкер!

Бу йорт аксакалныкы, түрдә утырган карт — Биремҗан әкә иде.

Җегет, биш айдан бирле качып йөреп, менеп китәргә ат сорау өчен килгән иде. Ләкин моны, әлбәттә, керә-керүгә үк әйтә салырга теләмәде.

Каты суыкта туңып килгән мөсафирны шул көенчә йоклатырга мөмкинме? Вакыт соң булса да, килен, коедан су китереп, самавыр куйды, шүрлектән каймак, бавырсак алды, чынаяклар чыгарды.

Тышта, ахрысы, җил-буран көчәядер, бер генә катлы тәрәзәдән, морҗадан аның адаштырган җен баласы кебек елап-елап ыжылдавы өйгә дә ишетелә иде... Шуңа колак салып, чәйне акрынлап эчеп, кунак белән хуҗа озын-озын әңгәмәгә киттеләр.

Җегетнең беренче сүзе Сарсымбай турында иде.

Карт тирән бер сулады:

— Партия талашы дигән ул пычракка аягымны гомеремдә бер баскан идем, җиңеп тә чыккан идем, мәгәр ахыры яман булып калды,— диде.

Биш ай буенча адәмнән, полициядән яшеренеп, дөньяның хәлен белми йөргән мөсафир җегеткә вакыйгаларны бер-бер санап бирде. Җегет болардан шаша калды.

Хәлләр, чыннан да, көтелмәгәнчәрәк иде.

Кара-айгырлар, сарман, танабуга, кызылкортлар, берләшеп, сайлауда дошманны җиңделәр. Мәгәр моның белән эш бетмәгән иде. Булыслык бие булып сайланган Сарсымбайны урыс түрә начальникның билгеләве кирәк иде. Ак патшага каршы адәмнәр белән күп катнашы бар, шундый сүзләре ишетелә дип, монда тоткарлык чыкты. Ул арада Карлыгач-Сылуның элекке кияве Калтай үзенең иле белән, агасы белән зур талаш куптарды, ахырдан:

— Үз баласының намусын яклый белмәгән кара-айгыр йортында мин гомер итә алмыйм!— дип, малны хөкем белән бүлдереп, үз башына аерылды да авылны ташлады. Яңгырбай моңа килеп катнашты, җегеткә үз нәселеннән бер кыз тапты, туй ясап:

— Кара-айгырлар кадерен белмәгән асыл җегетләр дүрткарада хөрмәт табалар!— дип, дөнья шаулатып, Калтайны үз авылына алды.

Менә шул җегет Сарсымбай белән Арысланбай өстенә зур фетнә кузгатты. Яңгырбай аркылы яхшы бер адвокатны табып, кәгазь бирдерде. Башлыча гаеп шул иде: «Сарсымбай бездә кода заманында зур мәҗлестә әйтте: мин булыслык бие булыр өчен, түрә булыр өчен кызыкканым юк, мәгәр ак патша казакъ даласын талый, җәйләүне кукалга бирә, безне, кипкән комга куып, ач үтермәк була, мин менә шуңа каршы тормак өчен сайланам, диде»,— дип, әләк сөйләде, түрәгә шымчылык кылды. Моңа: «Без Сарсымбайның ул сүзен ишеттек!»— дип, кырык казакъ ант итте.

Боларга каршы: «Бу антлар барысы да ялган... Ул антчылар Сарсымбай белән фәлән мәҗлестә юклар иде, фәләне базарда, фәләне авыру, фәләне туйда иде»,— дип, бик күп казакълар Сарсымбай ягыннан ант бирделәр.

Бу соңгы антчыларның антлары ялган, алар сарманнан мал алды дип, өченче, дүртенче антлар кушылып, шундый зур шаушу, гауга кузгалды ки, элекке талашлар бары да кечкенә булып калды.

Мәгәр, ахырында, Калтай аркылы Якуп-Яңгырбай партиясе җиңде. Сарсымбайны булыслык бие кылып начальник беркетмәде, ак патшага каршы далада тынычсызлык тудыралар дип, илнең өлкәннәреннән дүрт адәмне җир аудардылар. Болар эченә Сарсымбай белән Арысланбай да керде. Бердәнбер кандидат Якуп иде, ул мәрхүм абзасы Байтүрә урынына ил агасы — булыслык бие булып эшне кулга алды да дошманнарын изә башлады.

Карлыгач-Сылу әле иренә яңа кушылган иде. Арысланбай сөргенгә җибәрелгәч, яшь киленнең ялгызы бу илдә торырга йөрәге җитмәде, мин синнән калмыйм, диде. Хәлләрне ерактан аңлый торган Алтынчәч байбичә дә, монда ирсез калганда, симез найманнар көн бирмәячәген күрде. Җылкычы ата белән үзе, базар йөреп, малның һәммәсен сатты да тукалны, Гөлчәчәкне алып, Карлыгач-Сылу белән бергә, ире, кияве артыннан китте.

Бу ике фамилия электән үк далада зур сәүдә йөрткәләгән адәмнәр иде.

Борынгылар: «Кеше илендә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул»,— дисәләр дә, «Ни эшлик, анамыз Сары-Арканың киң даласы безне үги кылды!» — дип, бөтенләй калага күчтеләр һәм шунда яшәп калдылар.

Сарсымбайның сөрелүеннән берничә көн үткәч, Яңгырбайның яңа дусы Калтайны үтереп, гәүдәсен күлгә ташладылар. Танабуганың бер җегете белән Җолкынбай бу эштә шөбһәгә алындылар. Дүрт казакъ Коръән тотып ант итте:

— Җолкынбай безне бу эшкә катнашырга чакырган иде, риза булмадык,— диделәр.

Танабуга җегете шул көндә кулга алынды, богауланып, калага зинданга озатылды. Җолкынбай исә алты стражник белән приставның үзен тотар өчен килүен сизенде дә, берәүнең атына менеп, далага чапты, үзен танымаган чит бер җиргә китеп, кукалга яки заводка ялланмакчы иде.

Башкаларның да язмышлары буталып беткән. Азымбай картның сере ачылган. Дошманга сатылуы беленгән. Моңа ачудан Якуп, аны кыйнатып, малларын читкә кудырган. Хәзер ул акылдан шашкан, ди. Кулына думбра тотып, өйдән өйгә көйләп йөри икән, җырлаганы һаман: «Мал бир дидем, бак бир дидем... бер бирдең — җот алды, тагы бирдең — Якуп алды... Инде мине кая куясың, ясаган иям!» — дигән кебек, мал-бәхет турында гына була, ди.

Симез найманнарга каршы якта хәзер кара-айгырларның башлыгы Сарыбай бик каты талаш алып бара. Якуп-Яңгырбайның барлык дошманнары шуның янына оешалар икән.

Бу вакыйгаларны сөйләп беткәч, карт бөтен сахрада ялгыз калган адәм тавышы белән кайгырып куйды:

— Дөньясыннан күңелем суынды... Тыштан бер аяк тавышы ишетелсә, әҗәлем киләдер, ярыктык, дигән өмет белән көтәм... Мәгәр аннан синең кебек кайгылы бер адәм килеп керә!— диде.

Бердәнбер улының күптән түгел вафаты картны тагы ныграк ватканга охшый:

— Күкнең эшендә ялгышлыклар булса кирәк, минем кебекләрне калдырып, тулы канлы яшь җаннарны алалар,— ди.

Тышта җил туктады, тәрәзәдән күкнең кечкенә бер кисәге күренде — анда болытлар таралган, йолдызлар ялтырыйлар иде. Тимерказыкның урыны таңның якынаюын күрсәтә иде.

Мөсафирда ашыгырга теләгәнлек сизелде, аңа, кышлаулар уянып, юлда халык йөри башлаганчы бераз җир китеп калу тиешле иде. Картка моны әйтеп, үзенең йомышын аңлатты:

— Киң далада үзенә бер урын тапмый каңгырып йөргән бәхетсез бер ятакчы адәм булып калдым... Мәгәр бу дөньяның бер җае әйләнмәсме, миңа да кояш карамасмы дигән өметем юк имәс... Гомер булса, бер яхшылык белән кайтарырмын, син, Бирем әкә, чамаңнан килсә, миңа менеп качарга бер ат бирсәң иде! Башка берәүгә күренергә күңелем ятмый тора,— диде.

Карт хәлне тиз аңлап алды, берсүзсез бирергә булды. Җегеткә җавап кайтару урынына, шунда бер якка сөялә биреп, ярым йоклап утырган киленчәккә эндәште:

— Колынчагым, сары күнле ияр белән кыска камчыны, бер каеш йөгәнне алып бирсәңче!— диде.

Үзе урыныннан кузгалды, капшанып, киемнәрен тапты, өстенә тире эчле көпесен, ике якка салынган колакчынын киде, аягына киез эчле, озын кунычлы зур итекне тартты да:

— Йөр, балам, юлчының юлда булуы яхшы!— дип, җегеткә җитәкләнә биреп, йортка чыкты.

Буран бөтенләй тукталган, ерак күк йөзендә йолдызлар яналар. Киң даланың ялтыр ак кар диңгезенә каршы салкын белән елмаялар. Аяз һава үтә суык, аяк астында кар шыгырдап тора.

Хуҗа кулындагы йөгәнне кунакка бирде, якындагы абзарга күрсәтте:

— Шунда дүрт ат булыр, кара яллы колынны тотып ал,— диде.

Кунак күрсәтелгән җиргә кереп китте.

Абзардан җылкыларның куркып бер якка таба кузгалу тавышы ишетелде. Берсе каты пошкырды,ниндидер баганага бәрелде, бераздан җегет белән бер ат килеп чыкты.

Бу — кышкы тибендә бераз ябыгып, җоннары салына төшкән, озынча йомры буйлы, калын ботлы, нечкә гәүдәле, зур кара яллы, кара сыртлы, яра кашкалы, кола төсле бер айгыр иде.

Чит адәмнең җиде төн уртасында кереп тотуы аны бераз борчыган, шөбһәгә калдырган иде, ләкин хуҗасын күргәч тынычланды. Аркасына ияр салып, аел тартуга да гаҗәпсенмәде: «Тибендә кунган җылкы көтүендә берәр хәл бардыр яисә кышлауга бүре килгәндер дә шуны куарга чыгалардыр»,— дип уйлады. Ят кешенең ашыгыч, мәгәр булдыклы кылануы аның бу уйларын тагы көчәйтте.

Күк йөзе болытлардан бөтенләй сафланган иде инде, еракта таң сызыла башлады, ул, аксыл нур булып, тирә-якка җәелде, аның артыннан кызгылт ут төсенә кереп бара иде.

Җегет үзенең уңган, бу эшкә өйрәнгән куллары белән тиз әзерләнеп бетте. Хуҗа картка ихлас күңелдән рәхмәт әйтте, ике куллап күреште дә атка сикереп менде.

Бирем әкә мөсафирга ак юл теләп калды.

Кола айгыр, төнге кунакны алып, кызыл уттай яна башлаган ерак таңга таба кар ярып юнәлде.

Бу юлчы җегет — сарманнарның ил агасы Сарсымбайда ялчы булып торган Җолкынбай иде.

Биремнәр

1. Романдагы вакыйгаларны берләштерегез һәм, шуларга нигезләнеп, сюжет сызыкларын билгеләгез.

2. Һәрбер сюжет сызыгының эчтәлеген ачыгыз, аларның бәйләнешен аңлатыгыз.

3. Карлыгач-Сылу һәм Арысланбайның охшаш һәм аермалы якларын табыгыз, эчке каршылыкларын күрсәтегез.

4. Биремҗан аксакалны характерлагыз.

5. Партияләр көрәшенең сәбәпләрен һәм нәтиҗәсен ачыклагыз.

6. Соңгы бүлектә Җолкынбайның эш-гамәленә салынган мәгънәне билгеләгез.

7. Үзегезгә аңлашылмаган сүзләрне дәфтәрегезгә языгыз һәм, бергәләп, мәгънәләрен төшенегез.

8. Төрле урыннарда бирелгән пейзажның вазифасын ачыклагыз.

«Казакъ кызы» романы

Галимҗан Ибраһимовның бөтен әсәрләре үзәгендә кеше бәхете, мәхәббәт, дуслык, бердәмлек мәсьәләләре тора. «Казакъ кызы» романында да әдип моңа турылыклы кала. Әсәр 1911 елда тәмамланган булса да, төрле сәбәпләр аркасында, бары тик 1924 елда гына басылып чыга. «Казакъ кызы» — XIX йөз ахыры — XX йөз башы казакъ халкы тормышының сәяси, иҗтимагый, әхлакый каршылыкларын үз эченә алган, үзенчәлекле образ-характерларга бай әсәр. Романда вакыйгалар ике сюжет сызыгы буенча бара. Берсе Карлыгач — Арысланбай мәхәббәтенә бәйле, икенчесе ыруглар арасындагы власть өчен көрәшне чагылдыра. Сюжет сызыклары, бөтен әсәр буенча янәшә барып, бер үк вакытта диярлек тәмамлана.

Яшьләр мәхәббәтенә бәйле вакыйгалар әсәрнең лиризмын арттыра, хис-кичерешләр байлыгын, геройларның күңел дөньясын ачып бирүе белән җәлеп итә, кызыксыну уята. Карлыгач-Сылу да, Арысланбай да — башкалардан шактый аерылып торучы, шәхес иреген, үз мәхәббәтләрен якларга һәм сакларга әзер яшьләр. Аларның исемнәре дә төп идеяне ачуга хезмәт итә. Бу — милләт азатлыгына ирешү. Моның өчен ирекне яратучы «кошлар», кыю йөрәкле, батыр «җанварлар» кирәк. Карлыгач белән Арысланбайның кушылуы киләчәк көрәш өчен нигез әзерли.

Ыруглар арасындагы көрәшне тасвирлауга Г. Ибраһимов зур урын бирә. Ике төркем каршылыгын төрле яссылыкта ача, сәбәпләрен кабат-кабат билгели һәм укучыны шундый нәтиҗәгә китерә: бу — ак патша алып барган сәясәт нәтиҗәсе. Царизм «бүлгәлә һәм хакимлек ит» принцибыннан чыгып эш итә. Ыруглар арасындагы каршылык аңа халыкны буйсындырып тоту, милли азатлык көрәшеннән читләштерү өчен кирәк. Романда моны аңлаучыларның берсе — Биремҗан аксакал. Шуңа да ул кайда гына булмасын, кем белән генә аралашмасын, колонизаторлык сәясәтенең асылын аңлату белән бергә, үзара татулыкны, килешеп яшәүне яклый һәм моның өчен бөтен көчен куя. Хәзергә явызлык көчле, ул гаделлеккә юл бирми. Сайлауларда Сарсымбай җиңеп чыкса да, төрле интригалар аша хакимияткә найманнар башлыгы Якуп килә. Моның артында ак патша кешеләре торуын аңлау кыен түгел, чөнки алар үз позицияләре йомшарудан һәм Биремҗан идеяләренең киңрәк таралуыннан куркалар. Бу уңайдан әсәрнең

ничек тәмамлануы игътибарга лаек. Җолкынбай олыгайган, көчсезләнгән Биремҗан аксакалдан хәер-фатиха ала. Арысланбай, Карлыгач кебекләр зинданга ябылса да, азатлык өчен көрәшүчеләр бетмәгән. Җолкынбай аксакалның милләтне берләштерүгә бәйле эшчәнлеген дәвам иттерә.

Күргәнебезчә, ике сюжет сызыгы, берләшеп, милли азатлыкка ирешү юлларын билгеләргә ярдәм итә. Автор бу турыда ачыктан-ачык язмый. Әсәрнең 1911 елда язылуын искә алсак, аңлашыла да. Әмма көрәшүче төркемнәрнең байлык турында гына кайгыртуларын күрсәтеп, ә каршы торучы көчләрнең җимерелгән язмышларын, кан-яшь түгүләрен тасвирлап, укучыны нәтиҗә ясарга этәрә. Үзара татулык булмаганда, ил-йортта тынычлык бетә, афәт килә. Соңгы бүлек, гомумән, тирән символик мәгънәгә ия. Сайлаулардан соң илдә урнашкан хәл буранлы кыш белән тәңгәлләштерелә. Авылда бары бер генә өйдә ут яктысы күренеп, яшәүгә өмет уята, ул да булса — Биремҗан йорты.

Әсәрдә милләт язмышына бәйле башка җитди мәсьәләләр дә күтәрелә. Берсе — хатын-кыз азатлыгы. Әдип аны, бер яктан, Карлыгач-Сылу эш-хәрәкәтләренә, икенче яктан, тукал, Чулпан язмышларына бәйләп ача. Соңгыларының язмышка буйсынуы, бәхетсезлеге фонында Карлыгачның мәхәббәте өчен көрәшен сурәтли. Г. Ибраһимов социаль тигезсезлек, иҗтимагый каршылык мәсьәләсен дә читләтеп үтми. Ыруглардагы аерым гореф-гадәтләр, алар арасындагы талашлар гади халыкка бәхетсезлек кенә алып килә.

«Казакъ кызы» романы сурәтләү чараларына бик бай. Дала тормышы, яңа урынга күченеп китү, җәйләү кору, сайлау күренеше, кичке аш, этнографик бизәкләр — һәрберсе хәтердә калырлык итеп тасвирлана. Әдип табигать күренешләреннән оста файдалана. Алар, гадәттә, вакыйга-күренешләргә, геройларның эчке кичерешләрен ачуга хезмәт итә яисә символик мәгънә белдерә.

Шулай итеп, роман 20 нче еллар татар әдәбиятының гүзәл үрнәкләреннән берсе булып тора. Әсәр Галимҗан Ибраһимовның талантын, язучы буларак осталыгын ача һәм прозаның киләчәктә үсеш юнәлешен билгеләргә ярдәм итә.

Кәрим Тинчурин
(1887—1938)

XX йөз башында татар драматургиясенең һәм профессиональ театрының ныклап аякка басуына һәм үсеш-үзгәрешенә пьесалары белән генә түгел, талантлы артист, оста оештыручы һәм режиссер, театр сәнгате белгече булуы белән дә җитди өлеш керткән Кәрим Тинчурин гыйбрәтле дә, фаҗигале дә тормыш юлы үтә.

Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә Пенза өлкәсе Беднодемьянск районы Белоозерка (Аккүл) авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Әтисе җир эшкәртү, мал асрау белән шөгыльләнгән. Әнисе Мәхмүдә апа йомшак күңелле, укый-яза белгән хатын булган. Ул балаларына еш кына халык батырлары, пәйгамбәрләр турында кызыклы вакыйгалар сөйләгән. Кәримне күрше авыл мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ләкин белем алырга көчле омтылышы булган, хыялый табигатьле малай да, аның әти-әнисе дә моның белән генә канәгатьләнмиләр.

1900 елның җәендә 13 яшьлек Кәримне, бер танышларына ияртеп, Казанга «бәхет эзләргә» җибәрәләр. Казанда ул бер чәйханәгә савыт-саба юучы булып урнаша. Эшләп бераз акча туплагач, шул елның көзендә Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Җәйләрен Идел буе шәһәрләрендә йөреп, төрле эшкә ялланып акча җыя һәм кышка тагын мәдрәсәгә әйләнеп кайта.

1905 елгы революция тәэсире мәдрәсә стеналары аша үтеп керә. Шәкертләр торган саен күбрәк демократик матбугат белән, социал-демократик идеяләр белән танышалар. 1906 елның февралендә, мәдрәсә тәртипләренә каршы чыккан өчен, 87 шәкертне (алар арасында Кәрим Тинчурин да була) «Мөхәм-

мәдия» мәдрәсәсеннән куалар. Ул башта Тамбов якларына китеп урман каравылчысы булып эшли, аннары Түбән Новгород, Саратов якларындагы авылларда балалар укыта.

Кәрим Тинчуринның Октябрьгә кадәрге иҗаты эзләнү, үз йөзен, язу стилен билгеләү чоры булып тора. Күпчелек әсәрләрендә К. Тинчурин тормышның реаль картиналарын татар зыялыларының тормышта үз урыннарын эзләүләре, халыкка хезмәт итүгә карашлары яктылыгында бирә. Аның пьесаларында реалистик күренешләр мелодрама һәм романтизм элементлары белән кушылып китә.

20 нче еллар башында татар профессиональ театры җитди кыенлыклар кичерә. «Сәйяр» труппасының таркалуы, аның җитәкчесе Г. Кариевның вафат булуы, күренекле артистларның китүе яки төрле шәһәрләрдәге труппаларда таралып эшләве һ. б. сәбәпләр халыкның рухи тормышында зур роль уйнаган театр сәнгатенә җитди игътибар бирүне сорый. Шундый шартларда К. Тинчурин 1922 елны Казанга чакырып кайтарыла һәм аңа Татар дәүләт театр труппасы оештыру бурычы куела. Ул яңа театрга төрле шәһәрләрдәге күренекле артистларны һәм яшь композитор Салих Сәйдәшевне чакыра. Аларга хәзерге Н. Островский урамында урнашкан Яшь тамашачылар театры бинасы бирелә. Татар дәүләт академия театрына әнә шулай нигез салына.

Кәрим Тинчурин, күпкырлы әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлек алып барса да, әдәбият тарихына беренче чиратта 20 нче еллар татар драматургиясенең иң күренекле вәкиле булып кереп калды. Революциядән соң «Йосыф белән Зөләйха», «Тутый кош», «Сакла, шартламасын» комедияләрен язган драматург. Шул елларда бер-бер артлы «Казан сөлгесе», «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл», «Хикмәтле доклад», «Ил» һәм 30 нчы еллар башында «Кандыр буе», «Алар өчәү иде» пьесаларын иҗат итә.

Драматург үзен беренче чиратта комедия остасы итеп таныта. Г. Камал, Г. Исхакый традицияләрен дәвам итеп, әлеге жанрны яңа идея-эстетик биеклеккә күтәрә. Көнкүреш материалын сәяси фикерләр белән кушу, сатирик пафосны фаҗигале пафос белән аралаштыру, көлкене арттыручы алым-чаралардан, тел байлыгыннан оста файдалану, әсәрләрнең композицион төзеклеге аша характерларның психологик ачылышы — болар барысы да К. Тинчурин комедияләренә хас үзенчәлекләр булып тора.

Кәрим Тинчурин, театрның баш режиссеры булып эшләү дәверендә, беренче остазы Г. Кариев тәҗрибәсен үстереп кенә калмый, үзе дә бик күпләр өчен укытучы була. Драматурглар Т. Гыйззәт, Р. Ишморат, артистлар Г. Кайбицкая, С. Айдаров һ. б. истәлекләрендә К. Тинчурин мәктәбен хөрмәт белән искә алалар.

30 нчы елларның катлаулы, каршылыклы сәяси-иҗтимагый мохите К. Тинчуринга да килеп җитә. 50 яше тулган көннәрдә — 1937 елның 17 сентябрендә ул «халык дошманы» дип нахакка гаепләнеп кулга алына һәм 1938 елның 14 ноябрендә атып үтерелә. Башка бик күп репрессияләнгән авторлар белән бергә, аның әсәрләре дә кулланылыштан алына. Бары 1955 елны гына әдип тулысынча аклана. Аның бай иҗаты халыкка кире кайтарыла.

Күренекле драматург, режиссер, артист, педагогның исемен мәңгеләштереп, 1989 елны Татар драма һәм комедия театрына Кәрим Тинчурин исеме бирелде. Әдипнең әсәрләре бүген дә сәхнәләрдән төшми, заманча актуаль булулары белән яңадан-яңа тамашачыларның мәхәббәтен яулап ала.

Биремнәр

1. К. Тинчуринның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләгез.

2. Драматургның тормыш һәм иҗат юлына нигезләнеп, дәфтәрегезгә хронологик таблица төзегез.

3. К. Тинчурин белән С. Сәйдәшевнең иҗади хезмәттәшлеге турында сөйләгез.

4. Әдипнең театр сәхнәсендә үзегез караган берәр спектакленә рецензия языгыз.

СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР

(Драмадан өзек)

КАТНАШУЧЫЛАР:

Сәрвәр — ятим кыз.
Исмәгыйль — аның сөйгәне, хәзрәттә ялчы. Ятим егет.
Надир мәхдүм — бөкре, гаять ямьсез, утыз яшьләрендә.
Гөлнур — Сәрвәрнең әбисе.
Фәрхи — им-том итүче карчык.
Фатыйма — Сәрвәрнең дус кызы.
Сираҗи — көтүче карт.
Шәйбәк — көтүче малай.

Сафый — кабер казучы.
Беренче егет.
Икенче егет.
Өченче егет.
Беренче кыз.
Саттар — староста.
Писарь.
Мулла.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Икенче күренеш

Уртача тормышлы авыл өе. Исмәгыйль, Сәрвәр.

Исмәгыйль. Сәрвәр җаным, сиңа сөенеч, үземә көенеч хәбәр китердем.

Сәрвәр. Нәрсә?.. Нинди хәбәр?

Исмәгыйль *(хат биреп).* Менә мәхдүмнән хат!.. (...) Үземнең баемнан үз сөйгәнемә хат тапшырырга мин тиеш, күрәсең... Миңа ни кушсалар, мин шуны эшләргә тиеш. Мин ялгыштым, мин ялгыштым. Сәрвәр, сине сөеп мин ялгыштым. Миңа башканы, үз тиңемне сөяргә кирәк иде. (...)

Сәрвәр. Юк, юк, Исмәгыйль, син ялгышмадың... Мин сине генә сөям. Мин мәхдүмне сөймим, сөя алмыйм. Аны кызгансам да сөя алмыйм. (...) Син миңа ышанасыңмы, юкмы?

Исмәгыйль. Ышанам, Сәрвәр, бик ышанам, шулай да без кавыша алмабыз. (...) Сәрвәр җаным, гомере ятим булдым, гомере кеше кулында үстем, кеше эшләрен эшләп гомерем уза. Гомеремдә миңа синнән башка якты чырай күрсәткән, татлы сүзләр әйткән кеше булмады. Син минем атам-анам да, син минем байлыгым да, син минем барысы, барысы... (...) Мин сине... юк бит, аңлатырга сүз юк! Менә хәзер тотып үтер, мин риза, мин күңелемнән синең кулыңнан үләргә дә риза.

Сәрвәр. Исмәгыйль җаным! Күңелеңне тыныч тот... Мин дә шулай ук. Синнән аерылуны уйлаганда, минем дә шулай ук йөрәгем үлә. Безнең йөрәкләребез моннан соң үлмәсләр. (...) Мәхдүмгә мин ассалар да чыкмыйм. Дөрес, мин аны бик кызганам. Зәгыйфь кеше, бичара.

Исмәгыйль. Ул да бәхетсез шул. Мин ятим, кеше кулында гомергә ялчы булуым белән бәхетсез. Ә ул үзенең зәгыйфьлеге белән бәхетсез.

Сәрвәр. Менә миңа өйләнгәч, бәхетле булырсың. Менә күр дә тор. Мин сине бәхетле итәргә тырышырмын... (...)

Исмәгыйль. Юк, Сәрвәр, безгә кавышу насыйп булмас. (...) Безне аерырлар. Мин төшемдә шулай күрдем. Өч тапкыр шул бер үк төшне күрдем. (...) Күзге караңгы төн, имеш. Күктәге йолдызлар шундый яктылар, имеш. (...) Бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә һәркайсы үзенә берәр йолдыз алганнар икән. Син дә шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде. Тагын бик күп, бик күп егетләрнең йолдызлары сүнеп, күк йөзе корымлы кара таба төсле караңгыланып, каралып калды. (...)

Сәрвәр *(елап)*. Җитәр, җитәр, җитәр... Юк, юк, бу — ялган төш, бу дөрес түгел. (...)

Исмәгыйль чыга, әби керә.

Гөлнур. Сәрвәр бәбкәм, кызыл канатның оясын таптым. Келәт астына оялаган икән. Унбер йомырка. (...)

Сәрвәр. Әби, төштә йолдызлар сүнсә ни була?

Гөлнур. Төшне һәрвакыт яхшыга юрарга кирәк. Төштә кан күрү — күз яше, кайгы, бәла-каза галәмәте. (...)

Әүвәлгеләр һәм Фәрхи.

Фәрхи. Юлым уң булыр. Өйдә икәнсез. Саумы, Гөлнур, саумы, Сәрвәр бәбкәм. Йә, бер дога кылыйк! (...) Сүзне боргалап-сыргалауда файда юк. Йомышым менә шул. *(Тәрәзәдән күренгән Надирга кулы белән изи.)* Сәрвәр бәбкәм, якынрак кил әле, менә нәрсә: хәзрәтебез Надир мәхдүменә Сәрвәргә яучы итеп җибәрде.

Сәрвәр *(сискәнеп)*. Нәрсә?!

Фәрхи. Бик бәхетле сәгатьтә тугансың икән, бәбкәм. Остабикә булырга тәкъдиреңдә язылган, күрәсең... Менә шул, бөтен туй чыгымын хәзрәт үз өстенә ала. Бер тун, ике йон күлмәк, мамык шәл, читек-кәвеш, шәһәр юрганы, камзул, бер мамыклы, бер мамыксыз бишмәт, бирнәлекләр алырга дүрт йөз сум акча... (...) Йә, Гөлнур, туйны кайчан билгелисез?

Гөлнур. Сәрвәр бәбкәм үзе ни әйтер бит.

Сәрвәр. Әби, мин мәхдүмгә чыкмыйм. Мин аны сөймим. (...) Әбкәем җаным, мине мәхдүмгә бирмә. Минем сөйгән кешем бар. (...)

Гөлнур. Мин Сәрвәр теләгенә каршы баралмыйм. Мәрхүм ата-анасының васыятьләре шулай. (...) *(Чыга.)* (...)

Әүвәлгеләр һәм Мәхдүм керә.

Надир. Исәнмесез, Сәрвәр туташ!.. (...) Фәрхи абыстай, минем Сәрвәр туташка бер-ике сүзем бар иде, мөмкин булса...

Фәрхи. Ярый, ярый, мәхдүм, мин дә чыгам. *(Чыга.)*

Сәрвәр. Фәрхи түти, чыкма. Юкса мин дә чыгам. *(Чыкмакчы була.)*

Надир *(каршы төшеп)*. Сәрвәр туташ! (...) Мине яратмавыгызны хатларыма җавап бирмәвегездән үк аңладым. Ләкин сез мине аңламыйсыз әле. Минем тышкы күренешем шайтанга охшаса да, миндә дә җан, йөрәк бар. Бәлки, минем шул җанымны, йөрәгемне аңларсыз.

Сәрвәр. Мин сезне, Надир мәхдүм, кызганам.

Надир *(кызып)*. Юк, мин үземне сездән кызгандырырга килмәдем. Мине кызганган кеше — минем дошманым. Мине Алла кызганмаган бит. Адәмнәр дә мине кызганмасыннар. (...) Менә мин,— Сәрвәр туташ, Алла тарафыннан җәберләнгән, Сәлах хәзрәт баласы, зәгыйфь, шайтан кыяфәтле, гурбун мәхдүм. Сезнең мәхәббәтегезне сорарга килдем. (...) Сез мине бервакытта да янып, өзелеп сөя алмассыз. Анысы мөмкин дә түгел. (...) Мин аны беләм. Сез миннән җирәнмәсәгез, шул җитә. Ә мин сезнең гомергә аяк астыгызда туфрак булыр идем. (...)

Сәрвәр. Мин сезне кызганам.

Надир. (...) Мин сездән үтенәм, мине кызганмагыз. (...) Мин ялгыз идем. Аңлыйсызмы, егерме биш яшькә кадәр ялгыз идем, сез ул ялгызлыкның авырлыгын белсәгез иде. (...) Менә ике елдан бирле мин шул авыр газаплы ялгызлыктан котылып тора башладым. Сез коткардыгыз, Сәрвәр туташ. (...) Мин ике елдан бирле су буйларына, зиратларга, урманнарга барып җырлыйм. Егерме биш яшемә кадәр мин җырның нәрсә икәнен дә белмәгән идем. Сез миңа җан керттегез. (...) Дөрес, мин мөнәҗәтләрдән башка көй белмим... Менә шул мөнәҗәт көйләрендә үземнең хисләремне күрсәтә алам. Менә хәзер дә җырлыйсым килә. (...)

Сораулар һәм бирем

1. Исмәгыйль ни өчен үзен бәхетсез саный? Надир турында ул ниләр уйлый?

2. Исмәгыйль нинди төш күрә? Аны ничек юрыйлар?

3. Ни өчен Надир үзен кызгануларын теләми?

4. Ячы карчык Фәрхи сездә нинди фикер тудырды?

5. Надир мәхдүмнең Сәрвәргә булган мәхәббәте турында фикер алышыгыз.

6. Тексттан үзегез аңламаган сүзләрне табып, сүзлекләр ярдәмендә аларның мәгънәләрен төшенегез.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй. Фәрхи белән Гөлнур сөйләшеп керәләр.

Фәрхи. Алла, Гөлнур, нәрсә ашатып ул казларыңны болай симерттең? (...) Нигә болай иртә йолыктырасың? Салкыннар да башланмаган бит әле.

Гөлнур. Калага җибәртеп сатарга уйладым. Көзне көтсәң, үткән елгы кебек, коры калуың да бар. (...) Тавык күз Зарифына ни булган? Нишләп сине тиргиләр?

Фәрхи. Җен шомлыгын миннән күрәләр. Шул Зарифлары, Фәрхи әби, зинһар, мине солдаттан калдыр дип ялынгач, барлыгы утыз пот арышка ишан хәзрәт даруын колагына гына салдым. (...) Тәһарәте булмаган икән, шул җен сугып, авызлары кыйшаеп, телләрен зәхмәт сугып, хәзер үләргә ята. Менә шуны миннән күрәләр. (...) Кем, Гөлнур, сүз озая сүз чыгып, онытып китмим, дим. Мине хәзрәт тагы шул Сәрвәр турында сөйләшергә дип җибәрде бит. Нишлисең инде, нигә болай кире кагып торасыз? (...) Әнә хәзердән үк халык Сәрвәр турында әллә нәрсәләр чыгара башладылар.

Гөлнур. Нәрсә, нәрсә тагы? Ятим баланы кайсы тагын рәнҗетмәкче була?

Фәрхи. (...) Бик сөйлиләр. Янәсе, Сәрвәр хәзрәтнең хезмәтчесе Исмәгыйль белән... (...)

Гөлнур. (...) Әйтсәм әйтим инде, ләкин, зинһар, бер кешегә дә чыгара күрмә. Бер-ике атнадан туй ясап, Исмәгыйльне йортка кертәбез... (...) Менә шуңа күрә казларны йолкырга ашыктык. (...)

Гөлнур, Сәрвәр, Фатыйма.

Фатыйма. Гөлнур әби, ата-бабадан калган йоланы эшләмичә ярамый, диләр. Кичкә егетләр кертмичә моннан чыгу юк, диләр. Егетләр дә кертмәгәч, каз өмәсе буламыни?..

Сәрвәр. Әби, кертик инде. Кертмәсәк, кызлар үпкәләрләр. (...)

Гөлнур. Ата-баба йоласы инде, кертерсез.

Фатыйма. Менә рәхмәт, Гөлнур әби, бик рәхмәт. Әйдә, кызлардан сөенчесен алыйк. (...)

Сәрвәр, Фатыйма, Исмәгыйль, Надир, кызлар һәм егетләр.

Фатыйма. Кызлар, егетләрдән бусага ялы түләтәбезме?

Кызлар. Түләтәбез, түләтәбез!

Фатыйма. Алай булса, канатлар алып керегез!.. (...)

Ыгы-зыгы башлана. Еракта «Каз канаты» җыры ишетелә.

(Егетләр ишек янында «Каз канаты» көенә җырлыйлар.)

Каз канаты кат-кат була, ир канаты ат була.
Җаның сөйгән яр янында җанга рәхәтлек була.

Кызлар. Каз канаты кат-кат була, кыз канаты ак була.
Бусага ялын түләгән хөрмәтле кунак була. (...)

Фатыйма. Сиңа, егет, ни кирәк?

Исмәгыйль. Кара кашлы кыз кирәк.

Фатыйма. Ни эшкә соң ул кирәк?

Исмәгыйль. Әнигә килен кирәк.

Беренче егет. Анаң юк ич синең.

Гомуми көлү.

Фатыйма. Сиңа, егет, ни кирәк?

Исмәгыйль. Миңа нечкә бил кирәк.

Фатыйма. Ни эшкә соң ул кирәк?

Исмәгыйль. Ансыз яна яшь йөрәк.

Сәрвәр. Егет, сиңа ни кирәк?

Исмәгыйль. Каз мамык ястык кирәк.

Сәрвәр. Казларыбыз мамыксыз, кызлар йоклый ястыксыз.

Фатыйма. Шуны да син белмәгәч, йөрмә монда вакытсыз. *(Кыйныйлар, гомуми көлү.)*

Сәрвәр. Сиңа, егет, ни кирәк?

Исмәгыйль. Ак каз канаты кирәк.

Сәрвәр. Ни эшкә соң ул кирәк?

Исмәгыйль. Очарга.

Сәрвәр. Ни эшләргә?

Исмәгыйль. Матур кызлар кочарга. *(Сәрвәрне кочакламакчы була. Фатыйма арасына керә.)*

Фатыйма. И-и өтек карга. Буш кул салма кызларга! Акчаң кайда?

Исмәгыйль. Акча сезгә кирәксә, менә ул тулы кесә.

Кызлар. Канат сатам, канат сатам, канат сатам!..

Исмәгыйль. Кая ул, мин алам. *(Сәрвәр каршысына баса.)* (...)

Сәрвәр. Акчаң җитәрме соң? Үзең чибәрме соң?

Исмәгыйль. Акчам җитәр, үзем чибәр. *(Кочакламакчы була.)*

Сәрвәр. Кагылма миңа, исәр!.. Кая ялың?

Исмәгыйль *(акча тешләп)*. Мә, ал!

Сәрвәр. Нәрсә ул?

Исмәгыйль. Ял.

Сәрвәр. Ярый, кал.

Исмәгыйль. Юк, элек ал! *(Үбешәләр, гомуми көлешү, шаушу.)* (...)

Беренче егет *(читтә боегып торган Надирга)*. Мәхдүм, син ничек болай монда киләсе булдың? Ясин укыргамы әллә?

Гомуми көлү.

Надир. Юк, син наданны күрергә килдем.

Икенче егет. Мулла халкында теш тә булмаса, ул нигә ярый. Бөтен авылның казларын ашап бетерер өчен кирәк бит ул аларга.

Гомуми көлү.

Надир. Ә син, егет, телеңә салынма. Бездә дә ул бар, менә ул. *(Үртәп, телен чыгара.)*

Гомуми көлү. Сәрвәр уңайсызланып аптырап тора.

Беренче егет. Коръән укый-укый шулай үскәнме әллә бәлеш ашапмы?..

Көләләр.

Надир. Син нәрсә дисең тагы? Нигә сез мине рәнҗетәсез? Нигә рәнҗетәсез?!

Икенче егет. Сез муллаларны рәнҗетерсең.

Надир. Мин мулла түгел. Менә мин сезнең шикелле булыр өчен монда килдем. Минем сезнең шикелле үк буласым килә. Аңлыйсыңмы, сезнең шикелле үк.

Икенче егет. Безнең шикелле булыр өчен, бөкреңне юнасың бар әле.

Егетләр көләләр.

Н а д и р. Көлмәгез миннән, көлмәгез. Юкса мин сезне... *(Пәкесен чыгара. Кизәнә.)*

Е г е т л ә р. Ярамый, ярамый, мәхдүм!..

Кызлар чинашалар.

С ә р в ә р *(барып кулыннан тотып).* Мәхдүм, сансызланмагыз. Мәҗлеснең ямен җибәрмәгез. Егетләр, мәхдүм — минем кунагым... Аны рәнҗетерлек бер генә сүз әйтсәгез дә, бәхил түгел.

Н а д и р. Рәхмәт, рәхмәт, Сәрвәр туташ. Мин куям. Мин куям... Рәхмәт, сез мине аңладыгыз... Егетләр, туташлар, сез мине үз арагыздан бүген кумагыз. Менә шунда почмакта гына утырырмын. Әйе, почмакта гына. Сез уйнагыз, көлегез, миңа карамагыз... Мин сезгә уңайсызламам. Сәрвәр туташ, менә шул почмакта гына утырырга рөхсәт итегез. Гайфулла, Шакирҗан, килегез, килешик. Миңа рәнҗемәгез. Минем ачуым чыкты. Сез әйтмәсәгез дә, бөкрелегемне дә, шайтанга охшаган кыяфәтемне дә беләм бит. Менә, кызлар, сезгә бүләк. Менә бусага ялы... Миңа каз канаты кирәк түгел... Миңа аны сатучы булмавын белеп килдем. Уйнагыз, егетләр. Җырлагыз, биегез! Мин сезгә уңайсызламам. *(Почмакка утыра.)*

К ы з л а р. Мәхдүм, бүләкне бик күп алгансың... Рәхмәт.

С ә р в ә р. Мәхдүм, сез инде безнең шаяруларны гаепләмәгез!..

Н а д и р. Юк, юк, һич. Уйнагыз, мине бөтенләй юк дип уйлагыз. Әйе, бөтенләй юк. Менә шулай. *(Утыра.)*

Б е р е н ч е е г е т. Мәхдүм, без бит инде — надан кеше, тупас телле булабыз. Мин бит болай уйнап кына, кызык өчен генә синнән көлдем. Рәнҗемә... Әйдә, безнең белән бергә уйна... (...)

Бию башлана, иң элек Исмәгыйль белән Сәрвәр бииләр. Башкалар да бии. Иң ахырдан мәхдүм бии. (...) Ул биегәндә, с т а р о с т а, п и с а р ь һәм п ү н ә т ә й килеп керәләр. Кызлар йөзләрен яшерәләр. Аптырашып калалар. (...)

С т а р о с т а. Бу ни эш, мәхдүм?.. Килешми, килешми. (...) Егетләр, туктагыз! Йомыш бар. Писарь, кәгазьгә карап кычкыра башла!

П и с а р ь. Гайфулла Шәмсетдинов... (...)

С т а р о с т а. Гайфулла энем. (...) Бас шунда. Егетләр, исемнәрегез чыкканнар менә шунда килеп басыгыз!

Писарь. Сирай Нәҗметдинов, Исхак Курамшин, Касыйм Галиев, Мифтах Алмаев, Исмәгыйль Әхмәдуллин, Мөбарәкша Салихов...

Староста. Башкалар монда күренми. Егетләр, хәзер каравыл өенә әйдәгез. Иртәгә калага барабыз. (...) Патшадан урәдниккә хәбәр килгән. Киләсе елга караласыларны хәзер үк наборга чакыралар, ди. Ярман патшасы безнең патшага каршы сугыш ачкан.

Барысы бергә. Сугыш!!!

Катып калалар, Исмәгыйль Сәрвәргә ташлана. (...)

Исмәгыйль. Менә ул сүнгән йолдызлар каян килеп чыкты...

Сәрвәр катып кала.

Староста. Йә, әйдәгез, егетләр!!!

Кызлар елашалар, егетләр чыгып китәләр.

Надир *(шатланып)*. Сугыш, әһә, сугыш!.. Мин сугышка бармыйм, мин калам. Мин зәгыйфь, мин бөкре. Мин гурбун... *(Сикерә, шатлана.)*

Сәрвәр урынында катып кала. Урамда егетләр җырлап китәләр.

Каз канаты мамыксыз,
Ир канаты бәхетсез.
Илдә ризык калган булса,
Исәнлектә кайтырбыз!.. (...)

Пәрдә төшә.

Сораулар һәм бирем

1. «Аулак өй» күренешенә нигезләнеп, шул чор яшьләре турында фикер алышыгыз.

2. Авыл яшьләре белән Надир арасындагы каршылыкның сәбәбе нәрсәдә?

3. Кичке уенда Сәрвәрнең нинди сыйфатлары ачыла?

4. Сугыш башлануын ишеткәч, Надирның үз-үзен тотышын ничек аңлатыр идегез?

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче картина

Беренче күренеш

Исмәгыйль һәм Сәрвәр.

Сәрвәр. Юк, юк, җаным, сине җибәрмим. Син кайтмассың. Син үләрсең, сине үтерерләр. Мин синсез нишләрмен? Барма, барма, кач идән астына, ындырга, кибән астына кач!

Исмәгыйль. Ярамый, ярамый, җаным. Без күрәсен барыбер башка күрмәс. Шулай язган, күрәсең. Әҗәл җитмәгән булса, бәлки, кайтырмын да.

Сәрвәр. Юк, кайтмассың, кайтмассың... Безнең генә бәхетсезлегебезгә каршы явыз ярман сугыш ачкан икән. Аптырадым, башым катты. Йөрәкләрем кысыла. Фәрхи әби дә килми бит, ичмасам.

Исмәгыйль. Фәрхи әби ни эшкә?..

Сәрвәр. Дару китермәкче иде. Бәлки, шифасы булып каладан кире кайтыр идең.

Исмәгыйль. Кая инде безгә дарулану... Аны алырга акча кирәк бит.

Сәрвәр. Анысыннан эш тормас иде әле. Бөтен күлмәкләремне, сөлгеләремне — барысын бирер идем. Тик китерсен генә иде. (...)

Өченче күренеш

Сәрвәр һәм Фәрхи әби.

Сәрвәр. Фәрхи әби, анам бул. Үтенечемне кире какма. Ни сорасаң, шуны бирәм. Даруыңны бир. Бәлки, шифасы булыр. (...)

Фәрхи. Менә, кызым, картларны тыңларга кирәк. Мәхдүмгә чыккан булсаң, җаның тыныч, күңелең шат булыр иде. Ярман безнең авылга килгәндә дә, аны сугышка алмаячаклар. Хәзерге заманда шундый ир үзе бәхет. Үзе хәзинә.

Сәрвәр. Үткәннәрне оныт, Фәрхи әби... Мин Исмәгыйльдән башка барыбер тора алмас идем. Үткәннәрне онытып, бүген изгелегеңнән калдырма безне...

Фәрхи. Кара әле, Сәрвәр, бирсәм бирермен дә — бик кыйммәт бит. Синнән файда итүем түгел.

Сәрвәр. Күпме теләсәң, шулкадәр ал. Шифасы гына булсын.

Фәрхи. Шифасы була инде... Үткән елны дүрт авылдан унбиш егетне калдырдым. Менә хәзер дә унлап егет күтәп тора. Кеше ризыгына кереп булса да бирәм. Бәясе кырык пот арыш булыр.

Сәрвәр. Безнең арышыбыз юк. Менә туйга дигән күлмәкләрем. *(Сандыкны ачып.)* Мә, ал, менә сөлгеләрем, теләгәнчә ал!.. Шифасы гына булсын. *(Фәрхи, күлмәкләр, сөлгеләрне сайлап алып, ашъяулыгына төрә.)*

Фәрхи. Ярый инде. Сүзеңне кире какмыйм. Ике күлмәк, унбиш баш сөлге. Бер ашъяулык алдым.

Сәрвәр. Ал, ал, теләсәң, тагын ал.

Фәрхи. Ярый, тагын алыйм берәр сөлге, алайса, күбрәк бирермен. *(Сөлгеләр ала.)* Тәрәзә пәрдәңне төшер... *(Кесәсеннән бер шешә чыгарып.)* Үземнең даруларга вакытым юк. Унлап егет анда көтеп тора. Үзеңә генә өйрәтеп калдырам. Исмәгыйльне менә шунда ян белән яткыр. Уң колагы аста булсын. Каз канаты белән сул колагын арчып ал, шуннан соң менә шушы даруны колагына сал да менә монысын аның өстенә сал... Башын селкетмичә торсын. Башта авыртыр, чыдасын... Шуннан соң колагы тишелеп ага башлар. Яисә авызы, күзе кыйшаеп калыр... Бисмилла әйтеп эшлә. Төшендеңме? Кешегә әйтәсе булма!

Сәрвәр. Алла сакласын. Әйтәмме соң... (...)

Фәрхи. Кая, шифасы булсын, утыр, дога кылыйк... Аллаһе әкбәр. Бу — даруның садакасы гына, шифасы булып, Исмәгыйль кире кайтса, тагын түләрсез.

Сәрвәр. Анысыннан эш калмас. Бик рәхмәт инде, Фәрхи әби. Даруларга үзеңнең вакытың юкмыни?

Фәрхи. Әйтәм лә бит. Урак өсте... Сау бул... Шифасы булсын! *(Чыга.)*

Алтынчы күренеш

Исмәгыйль һәм Сәрвәр.

Сәрвәр. Әйдә, әйдә, ишекне яп! *(Сандыктан даруларны чыгарып.)* Менә шуны хәзер колагыңа салырга кирәк. Менә күр дә тор, каладан кире кайтарырлар үзеңне. (...)

Исмәгыйль. Әллә нишләп күңелем бер дә тартмый бит.

Сәрвәр. Соң, шулай итеп, мине гомергә елатырга уйлыйсыңмыни? Мин бит синнән башка беркөн дә тора алмам... (...)

Исмәгыйль. Ярый, тапшырдык... Алай-болай була калсам, бәхил бул.

С ә р в ә р. Бернәрсә булмас. Бөтен ил шулай эшли бит.

И с м ә г ы й л ь. Булса да, үкенеч юк. Анда барып та барыбер. *(Ята.)* (...)

С ә р в ә р *(канат белән колагын арчып)*. Шифасы гына булсын инде. Бисмиллаһ иррахман иррахим. *(Дару сала.)* Селкенмә, селкенмә, тик ят!..

И с м ә г ы й л ь. Аһ, аһ!.. Үтерә, яндыра!.. (...)

С ә р в ә р *(елап)*. Чыда, бәгърем, чыда!..

И с м ә г ы й л ь *(сикереп торып)*. Юк, юк! Чыдар хәлем юк! Үләм... (...) *(Идән буйлап тәгәри.)* Аһ... Аһ! Бәхил бул!.. Безгә кавышу насыйп... булмаган икән... (...) Сәрвәр, Сәрвәр, кил, кал... Бәхил бул... Бәхил бул... Үләм... Үләм... (...)

С ә р в ә р *(кинәт елавыннан туктап, Исмәгыйльне капшап)*. Аһ!.. Аһ!.. Үлде... Исмәгыйль... Исмәгыйль! Бәгырем! Бер генә... Бер генә сүз эндәш!.. Аһ!.. Үлде... Мин үтердем... Мин, мин... (...) Ярдәм, ярдәм итегез! *(Ишеккә таба йөгерә.)* (...)

Бик каты елап, һушыннан тая язып сулкылдый, ыңгыраша башлый. Шулвакыт урамда егетләр җырлаган тавыш ишетелә. (...)

П ә р д ә төшә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Икенче картина

Беренче күренеш

Г ө л н у р *(елап утыра)*. Суфидан тәлинкәләр дә яздырдым. (...) Иман хәзрәттән дә өшкерттем. Шифасы булмады. Бигрәк каты яратышкан булганнар икән. Ике чын сөйгән кавыша алмый, диләр иде. Чындыр, ахрысы. *(Елый.)*

Ф ә р х и. Кара әле (...) идән астына ябып ашатмыйча, эчертмичә җиде көн, җиде төн тотарга кирәк. Җен зәхмәте уразадан курка, ди. (...)

Г ө л н у р. Аның инде күргән газаплары да җитәрлек.

Ф ә р х и. Җенен качырырга кирәк. Кыйнаганыгыз бармы соң?

Г ө л н у р. Син ни сөйлисең? Кыйнарга ничек кул күтәрелсен. (...)

Әүвәлгеләр һәм Ф а т ы й м а .

Ф а т ы й м а . Саумы, Гөлнур әби? Сәрвәр кая?

Гөлнур. Бәбкәләрне ашатырга чыккан идем. Шул арада әллә кая чыгып киткән. Коега-фәләнгә төшеп үлмәсә ярар иде.

Фатыйма. Нигә яхшылап сакламыйсың? Хәле яхшырак түгелме?

Гөлнур. Һаман шул бер көе.

Фәрхи. Кара, кем, Гөлнур, ат селәгәе эчерергә кирәк. Ат исеннән җен кача, ди.

Фатыйма. Тагы ни калмаган, берсенең башына җиттең инде, монысын да үтермәкче буласыңмы? Убырлы карчык! (...)

Әүвәлгеләр һәм Надир.

Надир. Сәрвәр йоклыймы әллә?

Гөлнур. Юк, мәхдүм, качып чыгып киткән.

Фәрхи. Мәхдүм, Сәрвәргә тәрьяк ашатырга кирәк. Тәрьяк исеннән җеннәр кача, ди.

Надир. Чык моннан, шайтан карчык!.. Инде Сәрвәр башын ашарга йөрисеңме? Чык дим, юкса... (...) *(Җилкәсеннән тотып чыгарып җибәрә.)* (...)

Фәрхи *(чыгып барганда)*. Тәүбә, тәүбә, чынлап та, саташкан, ахры. Җибәр, җибәр дим, гурбун шайтан! Җибәр, бөкре шайтан!

Надир. Ә шулаймы? Гурбун шайтанмы?.. (...) Менә сиңа!.. *(Җиргә егып буа башлый, Фәрхи гырылдый.)*

Фатыйма. Чү, мәхдүм, нишлисең? Үтерәсең бит. *(Фатыйма һәм Гөлнур аларны аералар.)*

Фәрхи. Менә кешегә ит яхшылык. Менә бөкре шайтанга Сәрвәрне димләп... *(Надир җилкәсеннән тотып, ишектән этеп чыгара.)* Каравыл, каравыл! Үтерәләр, үтерәләр! (...)

Фатыйма *(мәхдүмне утыртып)*. Тынычланыгыз, тынычланыгыз! Гөлнур әби, салкын су китер!.. *(Гөлнур чыга.)* Шул хәшәрәтнең сүзләренә карамагыз. Котырган ул!..

Гөлнур *(керә)*. Менә, мәхдүм, су эч! Бисмиллаһ иррахман иррахим...

Надир *(су эчә)*. Рәхмәт, Гөлнур әби. *(Бүлмә буйлап йөри.)* Әби, Сәрвәрнең хәле һаман бер көе дисеңме?

Гөлнур. Һаман шулай... Алга бармый. Үләр инде, ахры, мескенем. Бигрәк бәхетсез бала икән. Ата-ана мәхәббәтен күрә алмый үсте. Сөйгәненнән вакытсыз аерылды. Тәкъдире кара булган, күрәсең, бәбкәмнең... *(Елый.)*

Надир. Елама, әби... Менә мин дә еламыйм әле... Минем кадәре аны сөюче, минем кадәре аны ихтирам итүче дөньяда

түгел, җәһәннәмдә дә булмас. Шулай да еламыйм, хәер, минем гомеремдә дә елаганым юк... Нигә еларга... барыбер мине аяучы булмас, мине Алла үзе дә аямаган бит.

Гөлнур. Тәүбә диген, бәбкәм. Тәүбә диген. Аллага тел озайтма! (...)

Надир. Ярый, әби, мин артык сүгенмәм инде. Барыбер файдасы юк. Шулай бит, Фатыйма туташ. Син дә Сәрвәрнең хәлен белергә килдеңме?

Фатыйма. Бик кызганыч бичара.

Гөлнур, сәкегә намазлык җәеп, тәсбих тартып утыра.

Надир. Кызганыч шул... Ә мин көннәр буе янында утырам... Әнә шул шашкан Сәрвәр янында рәхәт табам. Ул минем белән сөйләшә. Җырлый, мин дә аңар кушылып җырлыйм. Читтән караган кеше мине дә, шөбһәсез, шашкан дип уйлар, ләкин мин гомеремдә дә шаша алмам, мин рәхәтләнеп шашар идем, ләкин булдыра алмыйм, булмый. Шашар өчен Сәрвәр төсле җаннар, Сәрвәр төсле кеше кыяфәтендәге фәрештәләр булырга кирәк. Ә мин — гурбун шайтан... Сәрвәр белән без Исмәгыйльнең каберенә барабыз. Ул җырлый, мин Коръән укыйм. (...) Ә беләсезме нәрсә, Сәрвәр хәзерге хәлендә миңа акыллы чагыннан да сөйкемлерәк. Ул минем белән сөйләшә. Минем күзләремә туры карый. Кулларымнан тота. Миннән чирканмый. Ә бит терелсә, икенче төрле булуы мөмкин. Әйе, ул миңа хәзер элеккедән дә сөйкемлерәк... Хәзер Сәрвәр минеке... Аны миннән бер кеше дә аерып ала алмас. Их, Фатыйма, әгәр сез минем йөрәгемне ярып карасагыз, һушыгыздан таяр идегез. Җәһәннәм анда, чын җәһәннәм. Әгәр дә Алла әләксә, үзе дә янар иде анда, ихлас янар иде, һи-һи-һи...

Фатыйма. Һаман Аллага тел озайтасыз, алай ярамый.

Надир. Ярамый шул, тәүбә, тәүбә... Әйттем исә кайттым.(...) Ә Сәрвәр туташны эзләргә кирәк. Коега батып куюы да бар бит... Ул чагында дөньяда торырлык калмый... Иң соңгы өмет тә югала. Дөньяда өметсез торып булмый. Барып эзләргә кирәк. *(Тора.)* (...) *(Ерактa «Каз канаты» көенә Сәрвәрнең җырлаганы ишетелә.)* Чү, чү... бу аның тавышы... Ул кайта. (...)

Каз канатлары, чәчәкләр, үләннәр, башаклы саламнар кочаклап, Сәрвәр керә. Күлмәге сәләмә, чәчләре тузган, яланаяк, чәчләренә үләннәр ябышкан, җырлый.

С ә р в ә р. Каз канаты йомшак һәм ак,
Каз канаты сөттәй ак.
Кыйгак, кыйгак, кыйгак, кыйгак,
Без барыбыз бүген шат. (...)

(Канатларын идән буйлап тарата. Шуларны рәтләп тезеп, каранып, аларга карап җырлый.) (...) Канат сатам, канат сатам, канат сатам!.. Кая ул? Мин алам... (...) Акчаң җитәрме соң? Үзең чибәрме соң? (...) Нәрсә ул?.. Ал... Ярый, кал!.. (...) *(Торып, күзләрен зур итеп ачып, як-ягына карана.)* Чү, чү, йолдызлар сүнәләр... *(Надирга.)* Йолдызлар, йолдызлар сүнә!.. Син кем, син кем?.. Әйе, әйе, син теге аждаһа ялчысы кем әле! Сәлам әйт аңа... Каз өмәсенә килсен... Килсен... Мин аны кызганам... Мәхдүм, пычагыңны ташла, мәҗлесне сансызлау килешми... Исмәгыйль, Исмәгыйль. Хәзер китерәм. Хәзер колагыңа салырбыз!.. Хәзер, хәзер. (...)

Гөлнур, Фатыйма елыйлар. Надир агарып катып Сәрвәргә карап тора. Сәрвәр, тезләнеп, канатларын кочаклап елый. Акрын гына п ә р д ә төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сугыш фаҗигасеннән им-томчы Фәрхи карчык ничек һәм нинди максатта файдалана?

2. Ни өчен Сәрвәр, үлем куркынычы була торып, Исмәгыйльнең колагына дару салуга бара?

3. Фәрхи карчыкка кайбер геройларның мөнәсәбәтен күрсәтегез.

4. Надирның «Шашкан Сәрвәр янында рәхәт табам» дигән сүзләрен аңлатыгыз.

5. Исмәгыйльнең үлеменә, Сәрвәрнең акылдан язуына кем гаепле? Фикер алышыгыз.

6. Сүзлек өстендә эшләүне дәвам итегез.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зиратлык. Агачлар, каберләр, кабер ташлары.

Беренче күренеш

С и р а җ и һәм Ш ә й б ә к.
Көтүче Сираҗи, ялгызы чыбыркы очы ишеп, бер таш өстендә утыра. Шәйбәк зур паузадан соң чыбыркысын шартлатып керә.

Ш ә й б ә к. Бабай, көтүне урман авызына сөрикме? Анда үлән шәп булыр.

С и р а җ и. Нигә, монда әллә азык начармы?

Ш ә й б ә к. Монда да яхшы әле. Теге яңгырдан соң кырлар болын төсле булып китте. (...) Бабай, бу инде ярман патшасы белән безнең патша сугыша, ди. Шул инде ике патша үзләре алда торып сугышалармы?

С и р а җ и. Патшалар үзләре сугышмый, аларның халыклары сугыша. (...)

Ш ә й б ә к. Бабай, бу сугыш ни өчен чыга?

С и р а җ и. Патшалар ачуланышалар да, әйдә халыкны куып сугыштыра башлыйлар. (...) Җиңгәне җир ала, плен ала, шәһәр ала.

Ш ә й б ә к. Ул алынган җирләр, шәһәрләр кемгә була?

С и р а җ и. Кемгә булсын, патшага, байларга, купецларга, янаралларга була. (...)

Ш ә й б ә к. Ә теге җиңелгән патша үз җирләрен, акчаларын җиңгән патшага бирәме?

С и р а җ и. Ни өчен үзенекен бирсен, халыктан җыеп бирә. Менә безнең авылдан җыелган иманалар шундый җирләргә китәләр. (...)

Ш ә й б ә к. Бабай, бу каберне таныйсыңмы?

С и р а җ и *(борылып)*. Кайсын?

Ш ә й б ә к. Менә монысын. Менә, менә!..

С и р а җ и. Юк, кемнеке соң?

Ш ә й б ә к. Исмәгыйль абыйныкы.

С и р а җ и. Кайсы Исмәгыйль?

Ш ә й б ә к. Хәзрәттә хезмәтче булып тора иде бит. Сугышка бармас өчен, колагына дару салып үлгән.

С и р а җ и. Аның кабере шулмы? *(Торып, чыбыркысын шартлата.)* Чыбыркысы да чыбыркысы... Елан төсле, һүп! *(Шартлата.)* (...)

Ш ә й б ә к. Бабай, һавада карлыгачлар уйный. Төнгә тагын яңгыр булыр.

С и р а җ и *(кулын маңгаена куеп, күккә карый)*.Бирсен Ходай, карлыгачлар уйный шул. Болай булса, төнгә дә калмас.

Ш ә й б ә к. Бабай, әнә урман артында болытмы ул, нәрсә ул?

С и р а җ и. Кая? Ә-ә, болытмы әллә янгынмы? Төтенгә дә охшый.

Ш ә й б ә к. Бая аз гына иде, хәзер әнә ничек. (...)

С и р а җ и *(кулын куеп карый)*. Боз булмаса ярар иде. Бик гайрәт белән күкрәп килә. Әйдә, улым, көтүне авылга якынрак сөрик.

Чыгалар, еракган күк күкри башлый.

Алтынчы күренеш

Көн караңгылана башлый. Сәрвәр, чәчәкләр, каз канатлары, саламнар кочаклап, җырлап, Исмәгыйль каберенә килә. (...) Күк күкри.

Сәрвәр. Каз канатын кызлар сата,
Ир канатын кем сата?
Ир канатын патша сата,
Туган илне елата.
(Елап.)
Нурлар чәчеп күк йөзендә,
Алсуланып таң атар.
Ярсыз калган кыз баланы
Кемнәр генә юатыр?

Чү, чү, йолдызлар сүнә, йолдызлар сүнә, сүнәләр, сүнәләр. Йолдызлар сүнәләр... *(Каты күк күкрәп, яшен яшьни.)* Аһ, аһ, аһ!!!

Бик каты кычкырып егылып үлә. Күк күкри. Яшен яшьни, яңгыр ява башлый. Күк күкрәве еракланганнан-еraклана. Күк йөзе ачыла башлый.

Унберенче күренеш

Мәхдүм ялгыз.
Мәхдүм, торып, Исмәгыйль каберенә таба килә.

Надир. Бу ни бу?.. Сәрвәр мескен йокыга киткән. Йокла, нарасый, йокла. (...) Чәчәкләр китердеңме? Яхшы, бик яхшы, чын сөешү шулай була ул, шулай!.. (...) Ә миңа аларны китерүче булмас. Һич, һичкем китермәс. Минем бит беркемем дә юк. Мин ялгыз... Дөньяда да ялгыз, каберемдә дә ялгыз... (...) Мәңге, мәңге... ялгыз... *(«Уел» көенә җырлый.)*

Ник яраткан Ходай дөньясына
Ярсыз, дуссыз сынганлай ят күңел?
Икеләй генә телгәй, һай, бер былбыл,
Нигә үлгән тилгәндәй мин түгел?..

Мескен, чыланып беткән... *(Җиләнен салып каплый.)* Туңма, җаным, туңма. Сиңа җылы булсын... Менә шулай... Чү!.. Салкын... Сәрвәр, Сәрвәр!.. Өне юк... Күгәргән!.. Ул, ул үлгән... Сәрвәр үлгән!.. Ахыры, иң соңгы өметем дә сүнде. Тагын ялгыз!.. Сәрвәр күгәрченем, урманнарга кем белән чыгармын,

кем белән менә шул кабер янында утырырмын?.. Моннан соң «Каз канаты»н кем җырлар?! *(Елый.)* Юк-юк, елап булмый. Яшь каткан. (...) *(Ерактан күк күкри.)* Хуш, хуш, күгәрченем, хуш, дөньядагы бердәнбер куанычым... Ходай, синең җаныңны алып, актык йолдызымны сүндерде... Сукырның актык таягын сындырды. *(Кинәт торып, чалмасын бөтереп.)* Хәзер мин үземә ни эшләргә кирәген беләм... Моның өчен һичбер кешенең мине шелтәләргә дә, көләргә дә хакы юк... *(Чалмасын агачка бәйли.)* Мин үземә үзем хуҗа!!! Ташлар, агачлар, каберләр, менә күрегез, шаһит булыгыз!.. Мин үземә үзем хуҗа!..

Асылынып үлә, бик каты күк күкри, яшен яшьни, яңгыр ява. (...)

П ә р д ә төшә.

Сораулар һәм бирем

1. Сираҗи Шәйбәккә сугышны ничек аңлата?

2. Сәрвәрнең үлеменнән соң Надирның «Иң соңгы өметем дә сүнде» дигән сүзләре турында фикер алышыгыз.

3. Геройларның үлеме вакытында автор табигатьнең ярсуын күрсәтә. Ул моның белән нәрсә әйтергә тели?

4. Надирның үз-үзен үтерүен сез ничек аңлатасыз?

«Сүнгән йолдызлар» драмасы

«Сүнгән йолдызлар» — фаҗигале драма, анда катлаулы, тормышчан вакыйгаларда шәхес һәм җәмгыять каршылыгы сурәтләнә. Төп конфликт исә аерым кешеләр, кеше белән төркем, кешенең эчке каршылыкларында ачыла. Әлеге конфликт гаять кискен булып, фаҗига белән тәмамланса да, трагедиягә хас булганча, хәл ителмәслек түгел. Геройлар үлеме төп конфликтны хәл итүнең бердәнбер чарасы булып тормый.

Драма 1923 елны языла һәм анда сугыш афәтенең халык тормышына, аерым шәхесләр язмышына тәэсире сурәтләнә. Әсәрдәге вакыйгалар «мәхәббәт өчпочмагы» (ике егет һәм бер кыз) сюжетына нигезләнеп алып барыла.Ләкин драматург үзенә кадәрге авторларны кабатламый, ниндидер мәхәббәт маҗаралары сөйләми. Трагизм һәм мелодрама элементлары үзара кушылып киткән әсәрнең үзәгендә кеше шәхесе, аның язмышы, бәхеткә хокукы мәсьәләсе тора.

Пьеса бер-берсен яратучы Исмәгыйль һәм Сәрвәрнең очрашуы белән башлана. Исмәгыйль икенче бер егеттән — мәхдүм

Надирдан — Сәрвәргә мәхәббәт хаты алып килгән. Мөлаемлыклары, сүзләренең, хисләренең сафлыгы белән аларны яратып өлгергән укучы (тамашачы) алда булачак фаҗигане сизгәндәй сискәнеп китә: кыз белән егет арасына икенче егет керә. Шуның өстенә Исмәгыйль ямьсез төш күргән: «Бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә һәркайсы үзенә берәр йолдыз алганнар икән. Син дә (Сәрвәр дә) шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде. (...) Бик зур, әллә тагын кырык башлы бер аждаһа килеп чыкты да, ди, безне берәм-берәм ашый башлады, ди». Сәрвәрнең әбисе әлеге төшне начарга юрый: «Кара аждаһа — кабер, дигән. Кемне ашый, шул үлә».

Ятимлектә үскән, кешегә ялланып көн күрүче Исмәгыйль әлеге төш тәэсирендә яши башлый. Сәрвәр исә бәхете өчен көрәшүен дәвам итә. Алдагы күренешләрдә без мәхдүм Надир белән очрашабыз.

Надир мәхдүмнең дөньяга, кешеләргә булган ачуы һәм Сәрвәрне үзенеке итү, һәрвакыт күрә алу теләге бөтен акылын, җанын каплап алган. Сугыш башлану хәбәрен ишеткәч, аның «Сугыш, әһә, сугыш!.. Мин сугышка бармыйм, мин калам»,— дип шатланып кычкыруын шулай гына аңлатып була.

Сугыш башлангач, Исмәгыйль үзенең юрауларының дөреслегенә тагын бер кат ышана. Ул, тагы да көчсезләнеп, алсалар — китәм, калдырсалар — калам дип йөри башлый, нәтиҗәдә колагын «дару»лаган сөйгәне Сәрвәр кулында җан бирә. Бу фаҗигане Сәрвәрнең көчле йөрәге дә күтәрә алмый — ул акылдан яза. Соңыннан Исмәгыйль кабере өстенә ятып җан бирә. Сәрвәрнең үлеме мәхдүм Надирның да соңгы өметен бетерә. Ул: «Хуш, хуш, күгәрченем, хуш, дөньядагы бердәнбер куанычым... Ходай, синең җаныңны алып, актык йолдызымны сүндерде»,— дип, үзен үзе үтерә.

Якты, матур хыяллар белән яшәүче, бәхеткә тулы хокуклары булган геройларның үлеме бөтен кара көчләргә беренче чиратта сугышка һәм аны башлаучыларга нәфрәт, ләгънәт булып яңгырый.

К. Тинчурин кеше бәхете мәсьәләсенә бәйле җитди проблемаларны укучы-тамашачы алдына куя. Драматург кешегә хас булган мәхәббәтне гаять матур, серле хис-кичереш итеп сурәтли. Нәкъ менә мәхәббәт хисе Сәрвәрне кыю, кискен адымнарга

этәрә, бәхете өчен көрәшергә өнди. Надирга исә көч, ышаныч, яшәү матурлыгын күрү мөмкинлеге бирә. Кешенең бәхеткә, мәхәббәткә хокукы яклану, боларга киртә булып торган сугыш афәтенә нәфрәт булып калка.

К. Тинчурин үзенчәлекле, үзләренә генә хас сыйфатлары белән аерылып торган геройлар иҗат итә. Әбисе тәрбиясендә үскән Сәрвәр үзенең горур табигате, ярдәмчел, кешелекле, әдәпле булуы белән җәлеп итә. Ул киләчәк бәхетенә ышанычы белән башкалардан аерылып тора. Аның өчен үтеп чыкмастай киртәләр юк. Сәрвәр бай, тук тормышта, ләкин яратмаган кешесе белән яшәүгә караганда, авыр шартларда, шулай да үзе сайлаган кеше белән булуны өстен күрә. «Мин Исмәгыйльдән башка барыбер тора алмас идем»,— ди ул.

Тышкы күркәмлеге генә түгел, ә күңел байлыгы белән дә аерылып торган Исмәгыйль Сәрвәргә олы мәхәббәт саклаcа да, үзен кызга тиң түгел дип саный. Автор аның ихтыярсыз, хәтта мескен булуын күрсәтә. Бу аның ятимлеге, аннан да бигрәк хокуксызлыгы, кешедә ялчы булып хезмәт итүе белән бәйле. «Язмыштан узмыш юк» дигән гыйбарәгә ияреп, ул үз бәхете өчен көрәшүдән дә баш тарта.

Надир мәхдүм — Кәрим Тинчурин иҗатындагы иң уңышлы образларның берсе. Татар әдәбиятында табигать тарафыннан кимсетелгән кеше образының бу кадәр тирән фәлсәфи эчтәлек белән, үзенчәлекле олы характер итеп сурәтләнгәне юк иде әле. «Менә мин, Сәрвәр туташ, Алла тарафыннан җәберләнгән, Сәлах хәзрәт баласы, зәгыйфь, шайтан кыяфәтле, гурбун мәхдүм. Сезнең алдыгызда сезнең мәхәббәтегезне сорарга килдем. (...) Сез мине бервакытта да янып, өзелеп сөя алмассыз. (...) Сез миннән җирәнмәсәгез, шул җитә. Ә мин сезнең гомергә аяк астыгызда туфрак булыр идем»,— ди җавапсыз мәхәббәт утында янучы Надир. Башкаларда бары тик кызгану хисе генә уятучы һәм шуңа күрә бөтен дөньяга ачулы мәхдүмнең олы, гөнаһсыз йөрәге бар. Ул да кеше, ул да, өзелеп, җанытәне белән ярата. «Мин сездән утенәм, мине кызганмагыз,— ди ул Сәрвәргә. — Мин ялгыз идем. Аңлыйсызмы, егерме биш яшькә кадәр ялгыз идем, сез ул ялгызлыкның авырлыгын белсәгез иде... (...) Менә ике елдан бирле мин шул авыр газаплы ялгызлыктан котылып тора башладым. Сез коткардыгыз, Сәрвәр туташ. (...) Мин ике елдан бирле су буйларына, зиратларга, урманнарга барып җырлыйм. Егерме биш яшемә кадәр мин җырның нәрсә икәнен дә белмәгән идем. Сез миңа җан керттегез».

Тышкы кыяфәте һәм социаль хәленә бәйле рәвештә Надир авыл яшьләреннән читләшкән. Аның беренче тапкыр кызлар-егетләр белән аралашырга омтылуы кискен каршылыкка очрый, һәм бары тик Сәрвәрнең акыллы эш-хәрәкәте аркасында гына фаҗига булмый кала. Авыл егетләре белән мәхдүм арасындагы каршылыкның сәбәбе нәрсәдә соң? Надирның кемгә зыяны тигән? Болай да мескен егеттән ни өчен шулай усал көләләр? Моны аңлату өчен тарихи чорны күзалларга кирәк. 20 нче еллар — дингә, дин әһелләренә каршы көрәш дәүләт сәясәтенә әйләнә барган вакыт. Шунлыктан К. Тинчурин теләпме-теләмичәме гади егетләрнең руханилар вәкиленә каршылыгын күрсәтергә тиеш булган.

Надир бик горур, үзен кызганучыларны дошман күрә, чөнки башкалар белән тигез буласы килә. Сәрвәрне яратуы аңа яшәү көче бирә, мәхәббәте тормыш мәгънәсенә әйләнә. Ул Исмәгыйльнең хисләрен хөрмәт итә, шуңа да икесе арасында каршылык юк. Надир хыялында туган бәхетен акылдан язган Сәрвәр белән аралашуда таба. Кызны югалткач, яшәү мәгънәсен югалта һәм, үзенә үзе кул салып, бу дөньядан китә.

«Сүнгән йолдызлар» музыкаль жанрда язылган. Исмәгыйль белән Сәрвәрнең кара-каршы җырлары, егетләр хоры, «Каз канаты» җыры, бер яктан, әсәрнең лиризмын, икенче яктан, трагизмын арттыралар, шуның белән аның тамашачыга тәэсир итү көче тагы да көчәя.

Драмада сурәтләнгән аулак өйдә кич утыру күренеше, имтом итүче карчык Фәрхигә, көтүче карт белән көтүче малайга бәйле вакыйгалар әсәрнең реалистик нигезле булуын, тормышчанлыгын күрсәтәләр.

«Сүнгән йолдызлар» бүген дә, заманча актуальлеген югалтмаган гуманистик характердагы әсәр буларак, театр сәхнәләрендә уңыш белән бара.

Биремнәр

1. Дәреслектән һәм «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән файдаланып, әсәрнең жанрын билгеләгез.

2. Драманың төп темасын һәм шуңа бәйле рәвештә төп каршылыгын күрсәтегез.

3. Исмәгыйль һәм Сәрвәр образларына характеристика бирегез, каршылыкларын ачыгыз.

4. Надирның характер сыйфатларына нигезләнеп, аның үлеме алдыннан әйткән «Мин үземә үзем хуҗа!» дигән фикерен аңлатыгыз.

5. «Сүнгән йолдызлар»дагы яшьләр мәхәббәтен М. Фәйзинең «Галиябану» драмасындагы мәхәббәт белән чагыштырыгыз.

6. Түбәндәге темаларның берсенә инша языгыз:

1) «Татар драматургиясен үстерүдә К. Тинчуринның роле»;

2) «Сүнгән йолдызлар»дагы Надирга минем мөнәсәбәтем».

7. Әсәрнең исеме белән сурәтләнгән вакыйгалар арасындагы бәйләнешне аңлатыгыз.

8. «Яраткан язучым» дигән темага сыйныфта әңгәмә оештырыгыз.

Драма жанры турында

Әдәбиятның драма төре берничә гасыр буе трагедия һәм комедия жанрлары буларак кына яшәп килә. XVIII гасырда реаль тормыш вакыйгаларын үзләренә хас драматик конфликт һәм хәрәкәт белән сурәтләү зарурлыгы туа. Әнә шулай Мәгърифәт чорында ул вакытта «мещан драмасы» дип аталган драма жанры барлыкка килә. Бу жанр рус әдәбиятында бары XIX гасырда гына теоретик яктан нигезләнә, һәм аның классик формаларын без Н. А. Островский, А. П. Чехов һ. б. драматурглар иҗатында күрәбез.

Татар әдәбиятында жанрлары ачык билгеле булмаган драма әсәрләре XIX йөзнең икенче яртысында барлыкка килсәләр дә, драма жанрының беренче үрнәкләрен XX йөз башында Г. Исхакый, Г. Камал иҗатларында очратабыз. Драма жанры катлаулы тормышчан вакыйгаларны (шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм башка кешеләр, шәхес һәм коллектив арасындагы) сурәтли. Трагедиядән аермалы буларак, драмада конфликт хәл ителмәслек кискен булмый. Билгеле, геройлары һәлак булган драмалар да бар, ләкин аларның үлеме төп каршылык нәтиҗәсе яки хәл итүнең бердәнбер чарасы булып тормый. Комедиядән аермалы буларак, драма тормыштагы һәм кешеләр характерындагы кимчелекләрдән ачы итеп көлүне дә максат итеп куймый. Бу һич тә драманың аерымланып яшәве дигән сүз түгел, киресенчә, һәр әдәби әсәр кебек, әлеге жанрда да без трагедия һәм комедия элементларын күпләп очратабыз.

Драманың үзенә генә хас үзенчәлеге булып геройларның көчле борчылуларына, капма-каршы якларның хисләргә бай җитди көрәшенә нигезләнгән драматизм тора. Драматизм кара-каршы көрәшүче көчләр арасындагы үз теләк-омтылышларына ирешү өчен, карашларының, идеалларының дөреслеген раслау өчен булган тормышчан, шул ук вакытта кискен драматик конфликтта чагылыш таба.

Һади Такташ

(1901—1931)

Һади Такташның иҗаты бай һәм күпкырлы. Ул — театр һәм драматургия үсеше тарихында тирән эз калдырган драма һәм трагедияләр авторы да, чор таләбен тирән тойган үткен фикерле публицист, тәнкыйтьче һәм журналист, прозаик та. Әмма, барыннан да элек, ул — шагыйрь. Сирәк очрый торган талантка ия булган шагыйрь.

Һади кечкенәдән җырлар, такмаклар чыгаруга һәвәс булган. Җиде яшендә чакта ук ул авылдашы — дусты Мокамайның йомырка урлап тотылуы уңаеннан такмак чыгара.

Әдәби эш белән чиксез кызыксыну һәм белемен арттырырга теләве Такташны 1919 елның көзендә Оренбургка китәргә мәҗбүр итә. Ул анда «Юксыллар сүзе» газетасында җаваплы секретарь булып эшкә урнаша, Афзал Таһиров кебек күренекле әдипләр белән таныша, шәһәрнең мәдәният тормышында актив катнаша, сәяси курсларда укый. «Юксыллар сүзе»ндә шигырьләре, хәбәрләре басыла. 1921 елның язында Ташкентка күчеп, анда университетта әдәбият укыта. «Белем йорты» журналында җаваплы секретарь булып эшли. Шунда ул «Таң кызы», «Урман кызы» шигырьләрен, «Җир уллары трагедияс»н яза. 1922 елны Такташ берничә ай Мәскәүдә яшәгәннән соң, шул елның көзендә Казанга килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда төпләнеп кала.

Казанга килгәч, Такташ берникадәр вакыт татар театрында суфлер булып эшли, аннары «Чаян», «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре» журналларында һәм 1926 елның октябреннән 1929 елның мартына кадәр «Азат хатын» журналы редакциясендә җаваплы секретарь вазифаларын башкара. 1929 елда ул яңадан «Чаян» журналы редакциясенә кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда эшли.

1923 ел ахырларыннан башлап Һ. Такташ иҗатында һәм язу стилендә тормыш чынбарлыгын сурәтләү көчәйгәннән-көчәя барып, шагыйрьне яңа ачышларга китерә. Аның лирик-публицистик шигырьләре һәм, ниһаять, яшьлеккә, мәхәббәткә, тормыш матурлыгына багышланган «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу» кебек лирик поэмалар Такташны 20 нче еллар татар поэзиясенең алдынгы сафына чыгара. Әдип халыкның уй-хисләрен, хыял-омтылышларын илһамланып җырлаучы трибун-шагыйрь булып танылa.

Һади Такташның бай мирасында башка жанр әсәрләре дә зур урын били. Ул — «Күмелгән кораллар», «Югалган матурлык» һәм «Камил» исемле драма әсәрләре авторы. Үз вакытында бу драмалар татар сәхнәсендә куелып уңыш казаналар.

Газета-журнал редакцияләрендә озак эшләү әдипнең журналистик талантын да ачып җибәрә. Ул заманның күп төрле актуаль темаларына багышланган дистәләрчә публицистик мәкалә, очерк һәм фельетоннар бастыра. Һ. Такташ төрле жанрдагы әсәрләре белән татар әдәбиятының классик язучысы булып танылды. Шагыйрь иҗатына Муса Җәлил мондый бәя бирә: «Һ. Такташ поэзиясе үлемсез. Аның югары художестволы формада бирелгән, тирән идея эчтәлеге белән сугарылган шигырьләре хәзерге көндә дә актуальлекләрен югалтмыйлар...»

Һади Такташ поэзиясе бигрәк тә төрки халыклар арасында киң танылган.

Башкортстанның күренекле шагыйре Баязит Бикбайның, Һади Такташка югары бәя биреп, тирән ихтирам белән язган мәкаләсендә мондый юллар бар: «Һади Такташ...— татар поэзиясендә бөтен бер дәвер ачкан кеше. Чын татар поэзиясен бөек Тукай тудырган булса, аның Совет чорындагы югары күтәрелешен... Такташтан башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Гүзәл Такташның мактаулы йогынтысы бер үз әдәбияты белән генә чикләнеп калмый, тугандаш көнчыгыш республикалар поэзиясенә дә шифалы зур йогынты ясады».

Такташның шигырь һәм поэмалары башка телләргә дә тәрҗемә ителделәр. Шагыйрьнең мәңге сүнмәс иҗаты халыкта яши. Иң тирән мәгънәдә ул — халык шагыйре, татар халкының батыр йөрәкле, ялкынлы җырчысы. Ул хәзер дә халык белән бер сафта атлый, үлемсез поэзиясе белән киләчәккә бара, әсәрләре төрле телләрдә яңгырый.

Биремнәр

1. Һ. Такташның «Иптәшләр», «Мокамай» шигырьләрен исегезгә төшерегез, аларның уртак темасын билгеләгез.

2. Шагыйрьнең тормыш юлы турында хронологик таблица төзегез.

МӘХӘББӘТ ТӘҮБӘСЕ

(Поэмадан өзекләр)

Яшьлек,
Гом(е)рең кыска синең,
Шундый кыска булып тоела,
Кичен чәчәк аткан була,
Ә таңында инде коела...
Мәхәббәт,
Ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта,
Тиле яшьлек ярты гом(е)рен бирә
Аның хисе белән янарга...
Янган яшьлек,
Үткән мәхәббәтләр,
Алар мәңге миндә терелмәс,
Күзләрем дә хәзер беркемгә дә
Гыйшык уты эзләп текәлмәс.
Инде...
Тәүбә иттем ул эшләрдән,
Азгын күңел күпкә басылды,
Ирке чикләнмәгән йөрәгемә
Башлык итеп куйдым гакылны.
Гакыл башлык булган көннән алып,
Көн-төн елый мескен йөрәгем,
Һәр көн ызгыш, һәр көн йөрәгемә
Гакыл-башлык бирә кирәген...
Их, син, яшьлек,
Их, син, тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен чәчәк аткан булдың,
Ә таңында...
Ә таңында инде коелдың...
Язгы сандугачлы яшьлек таңым
Үтте инде...

Он(ы)тылдылар бик күп исемнәр,
Инде яшьләр хәзер яратсыннар,
Инде яшьләр хәзер сөйсеннәр...
Ә мин...
Ә мин үзем бөтенләйгә
Тәүбә иттем андый эшләрдән,
Читтән генә хәзер көлеп йөрим:
— Гыйшык!—
Диеп йөргән кешеләрдән...
Шулай да әле, кызлар,
Алла хакы өчен,
Миннән бераз читтә йөрегез,
Я тәүбәне шунда боздырырсыз,
«Гыйшык» итеп куеп берегез!..
Юк шул,
Гыйшкым хәзер иясенә
Кире алынмаска бирелгән,
«Аның» рәс(е)мен беркем, бервакытта
Ала алмас минем күңелдән...
Шуның өчен тыныч күңел белән,
Туктап менә шушы урында,
Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка
Булган көчле гыйшкы турында...

Зөбәйдәнең рәс(е)ме

Кайчак шулай бер-бер иптәшеңдә
Ут(ы)рып сөйләшергә сүз тапмыйсың,
Өстәленнән альбом кебеген алып,
Рәсемнәрен мактый башлыйсың...
Шулай ялкау гына сөйләнгәндә,
Күзләр бер рәсемгә туктала,
Кара болыт кебек тузган чәчләр
Хыялыңа кереп чорнала...
— Бу кем?— дисең,
Ә ул, көлеп кенә:
— Бу, — ди, — хәзер бала анасы,
Матур иде, яшьли иргә чыкты,
Хәзер инде алты баласы...—
Ди ул,
Ә син алданганың

Белдермәскә теләп тынасың.
Ә бераздан:
— Алай икән...
Дигән булып,
Альбом битен ябып куясың.
Матурлык ул шулай,
Кызда булса,
Җыерчыклы йөзгә әйләнә,
Ирдә булса,
Аның матурлыгы
Сакал, мыек белән бәйләнә...
Мәхәббәт тә—
Нәфис матур чәчәк,
Ләкин
Үзе гаҗәп гомерсез,
Кайчак загс белән соңы бетә,
Ә кайчакта...
Яхшук күңелсез...
Зөбәйдәнең рәс(е)ме —
Альбомымның
Күзгә бәрелеп торган ур(ы)нында,
Альбомымны карап чыккан кешеләр
Һаман сорый аның турында:
— Бу кем?— диләр,
Ә мин җавап бирәм:
— Матур кыз, — дим,—
Булган комсомолка,
Бөтен кешене үзенә карата,
Ә син, егет,
Бераз кичектең шул —
Ул бер наборщикны ярата...

Зөбәйдәнең гыйшкы

Сандугачлы таңнар,
Зур урманнар
Аның гыйшкын бизи алмады,
Язгы зәңгәр күкнең йолдызлары
Матурланып күктә янмады...
Аның гыйшкы көзен чәчәк атты
Эштә,

Собраниедә,
Урамда,
Күңел язы шаулап үтте аның
Тәңкә карлар яуган буранда...

Әй, җырлыйсы килә шушы җырны,
Шундый якын бу җыр күңелгә,
Җырланган җыр кебек яшьлек таңым
Шаулап үтте...
Шаулап үтте инде гомергә...

Их!
— Зөбәйдә, бар бүген собраниегә,
Анда аның бүген докладды;
Ул елмаер сиңа тагын да,
Затып[1] килеп кайткан чагында...
— Зөбәйдә, бар бүген театрга,
Бәлки, анда аны күрерсең,
Аның белән залда йөрерсең...
— Зөбәйдә, син барма театрга,
Йөрмә, бәгърем, аның артыннан...
Саклана күр егет халкыннан...

Ашкынулы көннәр шулай үткән,
Минутлардан эзләр калмаган;
Яшьлек үзенең җылы кочагында
Зөбәйдәне һаман алдаган...
Ә беркөнне...
Аны наборщигы
Кунак итеп үзенә китергән,
Алар бергә утырганнар...
Соңыннан
Бүлмә уты сүнгән,
Алар икәү
Төнге караңгыда калганнар...
Төн караңгы булган...
Төн буенча
Аппак[2] карлар җиргә яуганнар...
....

---

[1] Затып — озатып.
[2] Аппак — ап-ак.

Ул көнне ай күктә, эш тапмыйча,
Эче пошып сүгенеп йөргән,
Ул төнне Әүхәди, юлга чыгып,
Кире кайткан куркып бүредән...
Шушы төнне Гыймади, эт өрсә дә,
Тәмле йокысыннан тормаган.
Шәкүр карак аның абзарыннан
Күк айгырын кереп урлаган...
Ләкин
Шушы төнне Зөбәйдәнең
Кайдалыгын беркем белмәгән,
Карт анасы ярты төнгә кадәр,
Ни өчендер, аны эзләгән...
Тик
Мәхмүт торган йортта
Бер студент
Ябылмыйча калган ишектән
Зөбәйдәнең:
— Мәхмүт, бәгърем, җибәр! — дигән
Ярты елау тавышын ишеткән...

Айлар үткән...
Тәңкә карлар ява,
Аппак карлар;
Ә Зөбәйдә эшкә бармады,
Керфекләре җиргә карый аның,
Наборщигы аны алдады...

Зөбәйдә һәм ай

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә...
Ул тын гына
Айга карап килеп утырды,
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен
Канлы яшьләр белән тутырды...
— Их, син, яшьлек!
Их, син, тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен чәчәк аткан булдың,

Ә таңында...
Ә таңында инде коелдың...

Зөбәйдә,
Ул тиздән ана булыр,
Доктор шулай дигән аңарга...
— Йөрәк,
Ян син, ян син, йөрәк,—
Кан бирелгән сиңа янарга!..
Ә син кайда, ата булыр кеше?
Шулмы булды синең сөюең,
Шулмы инде синең:
Ирекле сөю,
Яңа тормыш диеп йөрүең?..
Кичтә янган утлар таңда сүнсә,
Кичен тагын алар кабына,
Зөбәйдәбез бүген бала көтә,
Үзе наборщигын сагына...
Менә баласына күлмәк тегә,
Чәнчеп-чәнчеп ала инәсен...
Зөбәйдә!
Әйт, кемне болай,
Кемне болай сагынып көтәсең?

Ачулы җил

Урам буйлап җил бер ис(е)рек белән
Гулять итеп кайтып килә иде...
Ә Ибәй карт,
Юньсез,
Көрәк тотып,
Йорт алдында карлар өя иде.
— Бу ни хәл бу?— диде җил күрде дә,—
Нәрсә дисең инде кешеләргә,
Ачу килә,
Шундый эшне күреп,
Кулым күтәрелми эшләргә!—
Мин тау өеп китәм,
Ә кешеләр
Чыгалар да шуны көриләр,

Мин матурлыйм,
Алар чыгып таптап йөриләр...
Тфү!—
Диде,
Үзе зур урамнан
Эре-эре кырга атлады,
Ачу итеп кырдан карлар ташып,
Бөтен урамнарны каплады...
Таң булуга, урам көрәүчеләр
Җилнең бабаларын сүктеләр,
Ә шул төнне безнең Зөбәйдәне
Больницага алып киттеләр...
....
Кайда син, әй, ата булыр кеше,
Шулмы инде синең сөюең?
Шулмы инде синең Зөбәйдәгә:
— Комсомолкам, бәгърем!— диюең?

Мәхәббәтнең соңы

Кан эчендә яткан Зөбәйдәне
Ак мендәргә китереп салганнар,
Күз төпләре күм-күк,
Иреннәре —
Кара күмер булып янганнар...
Ул селкенми ята,
Аны әллә нәрсә
Басып торган кебек сизелә...
— Тукта, елау тавышы килә,
Бала елый...
Кемнең баласы?
Ник ул елый?.. Ә ник мендәреннән
Башын күтәралмый[1] анасы?..
Тукта...
Нигә авыр болай?
Әллә нәрсә...
Күз аллары шундый караңгы...
Ул кузгалды,

[1] Күтәралмый —күтәрә алмый.

Кинәт авыр гына:
— Күрсәтегез,— диде,— баламны!
....
Ана —
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга;
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке — ана булуда!..
Бала елый,
Матур йорт эчендә
Яшь бер бала елый,—
Кемнең баласы?
Ник ул елый?
Ә ник күрер өчен
Килми аның сөйгән атасы?..
Тышта соңгы карлар ява,
Алар инде
Кышкы карлар кебек туңмыйлар.
Тышта язгы җилләр исә,
Алар инде салкын булмыйлар...
Карлар эрер,
Җылы тиргә батып,
Кар астыннан чыгар май ае;
Ә урамда, язның килерен белми,
Елап утыра песи малае...
— Елама юкка,
Дөнья матур нәрсә,
Әйдә, миндә кунак булырсың,
Дуслыгымны аңлап алдашмасаң,
Урлашмасаң, миндә торырсың...
Анаң, тәүфыйксызны, ташлап киткән,
Атаң, явыз, сине белми дә.
Кардәшләрең дә юк,
Шәһәр шул бу,
Белмисеңдер монда кемне дә?
Шулай, дустым!
Сезнең песи халкы
Балаларын ташлап китәләр;
Песи халкы гына түгел,
Этләр, аюлар да,
Кешеләр дә шулай итәләр...

Ярый әле сезнең песи малайлары
Ни булса да тере туалар,
Ә кешеләрнең күбесе,
Бала табудан куркып,
Корсакта чакта ук буалар.
Әйдә, киттек!
Минем яшь чагымда
Песиләрдән дуслар күп иде,
Син дә шулай кунак булырсың,
Язга кадәр миндә торырсың.
....
— Атасы аның, бәлки, мәңге килмәс,
Улын, бәлки, мәңге күралмас[1]..
Улы үсәр, җитез, матур булып,
А, юк!
Ата күң(е)ле күрми түзалмас[2]!
Тукта!
Ишек ач(ы)лып, берәү әкрен генә
Зөбәйдәгә таба атлады;
Күз яшьләре җиңде аны,
Кинәт борылды да
Йөзен кулы белән каплады:
— Зөбәйдә, син кичер мине!— диде,
Үзе Зөбәйдәнең күкрәгенә килеп ташланды...

Алар килештеләр...
Ә биш көннән
Загс белән тормыш башланды...

Ә ай күктә һаман сүгенеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк, улы да юк,
Төн үткәрсен соң ул кем белән?..
Җил, хәерсез, ятып йокламаса,
Җирдә алай-болай иткәли,
Төнлә йөргән кайбер кешеләрнең
Бүрекләрен урлап киткәли.
Ә ай көлә,

---

[1]Күралмас — күрә алмас.
[2]Түзалмас — түзә алмас.

Айга кызык була,
Ай ялгыз ул картлык көнендә;
Өйләнәлми калган, шуның өчен
Кайгы нуры күренә йөзендә...

Сораулар һәм биремнәр

1. Вакыйгаларны өлешләргә бүлегез, һәрберсенең эчтәлеген сөйләгез.

2. Поэманың төп темасын һәм күтәрелгән мәсьәләләрне ачыклагыз.

3. Зөбәйдә образы, аның эчке каршылыгы турында фикер алышыгыз.

4. Мәхмүткә сез нинди бәя бирер идегез?

5. Әсәрдәге кабатлауларны табыгыз, аларның роле нидән гыйбарәт?

6. Поэмадагы төп вакыйгага метафора булып килгән күренешләрне табыгыз. Әсәр идеясен ачуга алар ничек хезмәт итә?

7. Лирик геройның вакыйгаларга мөнәсәбәтен ачыклагыз.

8. Астөшермәдә (сноскада) бирелгән сүзләргә игътибар итегез. Такташ ни өчен аларны шулай «хаталы» итеп язды икән?

«Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы

Һади Такташ үзенең иҗатында яшьләр, гаилә һәм мәхәббәт мәсьәләләренә зур урын бирде. «Мәхәббәт тәүбәсе» — шагыйрьнең әхлак мәсьәләсен кыю куйган әсәрләреннән берсе. Поэманың сюжеты катлаулы түгел. Комсомолка Зөбәйдә наборщик Мәхмүтне чын күңелдән ярата. Яшь егет Мәхмүт тә башта кызны сөюен белдерә, ләкин гаилә төзү мәсьәләсе килеп баскач, ул гафу итмәслек җиңел акыллылык күрсәтә: Зөбәйдәне авырлы хәлендә ташлап китә. Ул үз мәхәббәте, үз баласы каршында җаваплы булуын оныта. Такташ менә шуңа каршы чыга һәм мәхәббәтнең сафлыгын, гаиләнең нык булырга тиешлеген яклый. Яшь эшче, комсомолец Мәхмүттә ахырда кешелек сыйфаты, вөҗдан кушуы өстенлек ала. Поэма яшьләрнең берберсен аңлаулары, гаилә төзүләре белән тәмамлана. Мәхмүтнең хатын-кызларга җиңел карашын, мораль җаваплылыгын аңламавын тасвирлау аркылы, шагыйрь кайбер яшьләр арасында күренгән эгоистлыкның начарлыгын, тормыш төзү өчен чит нәрсә икәнлеген аңлата. Шул ук вакытта ул Зөбәйдәнең мәхәббәте, аның хисләрен аеруча бер җылылык белән тасвирлый.

Зөбәйдә башта сабыйларча саф күңелле кыз һәм соңыннан нечкә хисле яшь ана образы булып күз алдына килеп баса. Шагыйрь Ана исемен бөек исем итеп саный, гаиләнең нык-лыгын, бала тәрбияләүнең җаваплылыгын, аналарга хөрмәт белән карарга кирәклеген искәртә.

«Мәхәббәт тәүбәсе»ндә тормышның күңелсез бер вакыйгасы күрсәтелсә дә, поэма күтәренке рухта, яшьләрне яхшыга өндәүче җылы лирика белән язылган. Поэма күңелдә тирән эз калдыра. Реалистик образлар яшьлек һәм мәхәббәт турындагы күтәренке романтик юллар белән үрелеп бирeлэләр.

Такташ, образларны сурәтләү, гомуми кичерешләрне, яшәү шартларын бирү өчен, табигать күренешләреннән, пейзаждан еш файдалана. «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә алар күбрәк контраст, параллель, чагыштырма итеп, янәшә кую төсендә алыналар.

Такташ яшь совет хатын-кызларының җанлы образларын бирде. Зөбәйдәдән соң ул шат күңелле, эшлекле кыз Алсу образын зур мәхәббәт белән тасвирлады. Яшьләр арасында «Алсу» поэмасы иң яратып укылган әсәрләрнең берсе булып китте. Андагы көчле оптимизм, яшьлек хисенең бөркеп торуы һәркемнең күңелендә матур эз калдыра. Монда шагыйрьнең осталыгы да, яшьлек дәрте белән рухлануы да күренә.

Такташ яшьләргә сокланып карады, аларның бүгенгесен һәм матур киләчәген киңрәк күрергә, тирәнрәк хис итәргә тырышты һәм көрәш пафосы, патриотик хис белән яктыртылган күтәренке яшьлек романтикасын җырлады. Шагыйрьнең яшьләр арасында зур уңыш белән еш кына чыгыш ясаулары да аның яшьләргә якын торуыннан килә.

Шагыйрь үзенең әсәрләрендә яшьләрне шәхси тормышта да, эштә дә нык булырга өндәде.

30 нчы ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Мәгълүм булганча, бу еллар иҗтимагый-сәяси планда илдә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшнең фронтлардан тыныч тормышка күчерелүе белән характерлана. Хәзер яңа тормыш дошманнарын халык арасыннан эзләүгә күчәләр. Илдә социализмны сыйнфый көрәш көчәя бару шартларында төзү идеясен уйлап чыгарып һәм шуңа ияреп, яңа идеология әдипләрне дә совет чынбарлыгын шул көрәш яссылыгында сурәтләүгә этәрә.

Сыйнфый дошманнарны язучылар арасыннан да эзләү китә. Һәм Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ш. Усманов, М. Галәү, Г. Нигъмәти кебек әдәбиятыбызның күренекле вәкилләре 30 нчы еллардагы мәгълүм репрессияләр корбанына әвереләләр, ягъни «халык дошманнары» дип гаепләнеп кулга алыналар һәм җәзалап үтереләләр. Бераздан Х. Туфан, И. Салахов, Ф. Кәрим, С. Рәфыйков шикелле әдипләр дә «халык дошманы» мөһере сугылып кулга алыналар һәм байтак еллар төрмә-лагерьларда газап чигәләр.

Илдәге әдәбият-сәнгатьне тулысынча үз кулына алып, большевиклар партиясе, алар белән җитәкчелек итүне нигезләү һәм ныгыту максатында илдәге күп санлы әдәби оешмаларны таратып, алар урынына бер оешманы — СССР Язучылар берлеген төзи. Бу мәсьәлә хәл ителгән совет язучыларының Беренче бөтенсоюз съездында, шулай ук югарыдан күрсәтмә буенча, совет әдәбиятының бердәнбер иҗат методы дип социалистик реализм раслана һәм шул нигездә әдәбият белән партия җитәкчелеге мәсьәләсе теоретик яктан да хәл ителә.

Шушы метод принципларына һәм таләпләренә нигезләнеп, татар әдипләре төрле жанрларда, әмма башлыча уртак бер рухта заман чынбарлыгын һәм үткәндәге яшәешне яктырту белән шөгыльләнәләр. Мондый тасвирның характерлы мисаллары булып прозада Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», Ш. Камалның «Матур туганда», Ф. Сәйфи-Казанлының «Өч нарат», М. Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары, А. Шамовның «Бер мәхәббәт тарихы», М. Әмирнең

«Агыйдел», Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Г. Бәшировның «Сиваш» повестьлары, поэзиядә Ә. Фәйзинең «Флейталар», Ф. Кәримнең «Җиденче мич», М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмалары, драматургиядә К. Тинчуринның «Кандыр буе», Ф. Бурнашның «Ялгыз Ярулла», Ш. Камалның «Габбас Галин», Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар», Ш. Усмановның «Кичеккән фәрман» пьесалары тора. Хаким идеологиягә бераз гына туры килеп бетмәгән әсәрләр исә (мәсәлән, Х. Туфанның «Ант» поэмасы яки Ф. Бурнашның «Таһир — Зөһрә» трагедиясе) сәяси яктан кире бәяләнәләр. Дөрес, кайбер әдипләр кайвакыт рәсми идеология кысаларыннан чыккан әсәрләр дә тудыралар. Мәсәлән, Х. Туфан Кавказ һәм Урта Азия республикаларына сәяхәте тәэсирендә язылган шигырьләрендә («Узып барышлый», «Күмелгән эзләр истәлеге», «Ташкент багларында» һ. б.) дөньяга һәм шәхескә киңрәк фәлсәфи позициядән торып карый.

Әдәбиятта гомумән совет җәмгыятенә, аның яңа кешесенә дан җырлау бурычы куелган бер вакытта поэзиядә халык җыры мотивларына ияреп язылган моңсу җырлар тудырыла (Х. Туфанның «Ак каен»ы, Ә. Фәйзинең «Умырзая»сы, М. Җәлилнең «Сагыну»ы, С. Хәкимнең «Юксыну»ы) һәм алар шигърияткә халыкчан рух өреп җибәрәләр. Халык иҗатын өйрәнү нәтиҗәсендә М. Җәлил үзенең «Алтынчәч» драматик поэмасында күпгасырлык тарихында бик зур сынауларга һәм югалтуларга дучар булган туган халкының үлемсезлеге идеясен борынгы дастан һәм әкият мотивларына нигезләнеп яктырта.

Кыскасы, 30 нчы елларда «халык дошманнары»н фаш итү кампаниясе һәм яңа идеологиянең басымы бермә-бер көчәйгән шартларда татар әдәбияты, тормыш һәм шәхес турында шул чор рухында фикер йөртү белән бергә, кайвакыт үз сүзен дә әйтә һәм үзенең милли мөстәкыйльлеген саклап кала алды.

Сораулар һәм бирем

1. 30 нчы елларда татар әдәбияты яшәешенә нинди иҗтимагый-сәяси факторлар тәэсир итә?

2. СССР Язучылар берлеге ни өчен төзелә, һәм социалистик реализм методы нинди максатка хезмәт итә?

3. Татар әдәбиятының 30 нчы еллардагы югалтулары нидән гыйбарәт?

4. Бу чорда татар әдипләренең рәсми идеологиягә яки пропагандага туры килеп бетмәгән эзләнүләрен конкрет мисалларга нигезләнеп анализлагыз.

Гадел Кутуй
(1903—1945)

20—30 нчы еллар татар әдәбиятында үзенең актив иҗади эзләнүләре белән аерылып торган Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) 1903 елның 28 ноябрендә хәзерге Пенза өлкәсендәге Татар Кынадысы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1912 елда аларның гаиләсе Самара губернасындагы Алексеевск авылына күчеп килә. Гаделша шушы авылдагы рус мәктәбендә укуын дәвам иттерә.

Югары белем алу нияте белән, Гаделша 1920 елда Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетына укырга керә. Әмма ике курстан соң, техник фәннәргә күңеле ятмыйча, институттан китә һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбендә әдәбият укыта башлый. Бер үк вакытта ул иҗат эшчәнлеген активлаштырып җибәрә. Татар поэзиясенә Г. Кутуй футурист шагыйрь буларак килеп керә. 1923 елда «Безнең юл» журналында аның «Яшь футурист шагыйрь» исеме астында бер цикл шигырьләре басыла, ә 1924 елда «Көннәр йөгергәндә» дигән беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә. Үзләрен футуризм тарафдарлары дип игълан иткән рус шагыйрьләре, бигрәк тә В. Маяковскийның форма өлкәсендәге эзләнүләренә ияреп язылган бу шигырьләр, ул вакыттагы татар әдәби җәмәгатьчелегенең игътибарын җәлеп итәләр һәм бәхәс тә уяталар. Чөнки шигъри формада яңалыкка дәгъва иткән әлеге шигырьләр матбугатта традицион поэзияне инкарь итү дип бәяләнделәр. Форма өлкәсендәге эзләнүләрнең ахыр чиктә әдәбиятта фикер төрлелегенә китерү ихтималын күздә тотып, ахры, ул вакыттагы рәсми тәнкыйть мондый эзләнүләрне чикләү, әдәбиятны бары бер, реалистик планда гына үстерү турында кайгыртты. Әмма биредә «реализм» төшенчәсе үзе дә тарайтып һәм гадиләштеребрәк аңлатылды.

Заманның идеологик таләпләренә җавап бирергә теләп, Г. Кутуй, тиз арада футуристлык эзләнүләрен калдырып, шул чор рухында язарга керешә. Үз каләмен ул төрле-төрле жанрларда сыный, ягъни шигырьләр, хикәяләр, пьесалар, фельетон, очерк, мәкаләләр, спектакльләргә рецензияләр яза. Театр дөньясы белән мавыгып китеп, Г. Кутуй 20 нче елларда драматургия өлкәсендә актив эшли. Аның «Балдызкай», «Директор Җәмилов», «Күк күгәрчен», «Җавап», «Казан» дигән пьесалары театр сәхнәсенә дә менәләр. 30 нчы елларда исә Г. Кутуй күбрәк проза өлкәсендә иҗат итә. Нәкъ шушы вакытта, дөресрәге 1935 елда, әдипнең иң күренекле әсәре — «Тапшырылмаган хатлар» повесте дөнья күрә. Совет чорында тәрбияләнгән татар хатын-кызының шәхси пландагы шактый катлаулы язмышын каршылыклы һәм нечкә хисләр аша чагылдыруы белән бу әсәр заманында укучылар арасында зур популярлык казанды, башка күп кенә телләргә дә тәрҗемә ителде.

Бөек Ватан сугышы башлану Г. Кутуй иҗатында да борылыш тудыра. Сугышның беренче көннәреннән ул ил азатлыгы өчен көрәшкә чакырган патриотик шигырьләр, публицистик мәкаләләр, хикәяләр яза. Ә инде 1942 елның июнендә фронтка киткәч, Г. Кутуй сугыш турында үзе күргән-кичергәннәргә нигезләнеп яза башлый. Фронт газеталарында аның шушы рәвешле язылган күп кенә мәкаләләре, репортажлары, башка төрле публицистик язмалары дөнья күрә. Г. Кутуйның сугыш елларындагы әдәби эшчәнлегенең күркәмрәк нәтиҗәләре хыял һәм лирик хис белән сугарылган иҗатка карый. 1944 елда, Казанга ялга кайткан вакытында, ул «Рөстәм маҗаралары» исемле «хыялый роман»ын яза. Бу әсәр яшь укучыларның иң яратып укыган китапларыннан берсенә әверелә. Мондый уңышның сере, барыннан да элек, әсәрнең бала күңелен һәм хыялын яхшы белеп язылуында иде. Кеше күңеленә игътибарын арттырып, Г. Кутуй сугыш елларында татар әдәбиятының да иң лирик формаларыннан булган нәсергә мөрәҗәгать итә һәм «Без — сталинградчылар», «Сагыну» кебек киң яңгыраш алган нәсерләрен тудыра. Бу әсәрләрдә сугыштагы кешенең патриотлык, туган илгә бирелгәнлек, еракта калган туган якны сагыну шикелле сыйфатлары һәм хисләре үтә бер нечкәлек белән чагылдырылды.

Г. Кутуй, инде сугыш беткәч, 1945 елның 15 июнендә Польшадагы Згеж шәһәрендә госпитальдә вафат була.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Кутуйның әдәбият белән кызыксына башлавына нәрсәләр йогынты ясый?

2. «Рөстәм маҗаралары»н исегезгә төшерегез. Әсәрнең яратып укылу сәбәбе нидә?

3. «Сагыну» нәсерен бергәләп укыгыз һәм лирик геройның хискичерешләре сәбәбен билгеләгез.

ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

(Кыскартып алынды)

Беренче хат

Искәндәр!

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны каткат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан 8 ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис»,— дип килеп танышкан Искәндәр иде.

Нинди матур истәлек. Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тискәре яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр — шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.

Исеңдәме беренче танышуыбыз?

1923 ел иде. Аяусыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң, мин Казанга килеп чыктым. Казан университеты рабфагына укырга кердем.

Тормышка юл табуыма мин шат идем. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә, бөтен бәхетләр бергә минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә, мин шат һәм күләч идем. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.

Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым. Һәрбер сөю һәм сөелүнең: «Эх, яратасы иде, сөясе иде»,— дип хисләр ташкан чагы була. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый. Шомырт та чәчәк ата. Сандугачлар да сайраша. Чияләр дә вакыты җиткәч кызаралар, тулылыктан матураялар. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән:

— Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт,— дип, тын беткәнче кочышасым килде.

Озак та үтмәде — студентлар арасында зур кичәгә хәзерлек репетицияләре башланды. Без бер бүлмәдә биш кыз тордык. Кичә була дигәч тә, без бөтен бүлмәбез белән анда катнашырга язылдык. Беренче репетиция ТКУ студентлары тулай торагында билгеләнде. Без барып кергәндә, син анда идең инде. Сине күрү белән үк, без синең турыда яшерен сер итеп сөйләшә башладык. «Бу кем?»— дип соравыбызга, шундагы бер студент:

— Артист Искәндәр,— дип җавап бирде. Яшермим, син безнең күбебезгә ошадың.

Әйе, син матур идең. Безнең бүлмә кызлары исә синең бу матурлыгыңны хыял буяулары белән тагын да бизәргә, бизәп баетырга тырыштылар. Афишада синең фамилияңне күргән саен, без, актык тиеннәребезне җыеп, театрга чаба торган идек.

Сөю кешегә шатлык һәм көч бирә. Чөнки кичәгә хәзерләнеп йөргән көннәрдә, мин рәтләп йоклаган чагымны да хәтерләмим. Бу зур кичә өчен мин «Тормыш турында җыр» әзерләдем. Бу җыр минем башымда бик күптәннән бирле йөрсә дә, көен таба алмыйча җырламый тора идем. Ләкин синең йомшак мөгамәләң, зәңгәр күзләреңне тутырып елмаеп каравың миңа көч бирделәр, уйланган җырымны көйгә салдылар. Бу җырда мин азатлык һәм матурлык, табигать һәм сөю турында күп кенә нәрсә әйтергә теләдем. Мин җырымның һәрбер сүзенә ачык буяу һәм тавыш яктылыгы бирергә тырыштым. Кырга чыгып, буш биналарга кереп репетиция ясадым. Җырланасы җырымны мин иртәнге һава җилләрендә назладым, кояш нурларында җылыттым. Хезмәтем бушка китмәде. Зал мине тиз аңлады. Мине кат-кат сәхнәгә чакырдылар. Ә мин, нишләргә белмичә, сәхнә артына чыгып, үзем тудырган җыр тәэсиреннән исереп, декорацияләр арасына кереп качтым. Шул вакыт берәү:

— Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис, җылы,— диде.

Бу «берәү» — син идең. Мин, синең шулай якын булуың шатлыгыннан бернәрсә дә әйтә алмыйча, синең зәңгәр күзләреңә карадым. Йотыла-йотыла матур итеп карарга тырышканымны хәзер дә хәтерлим. Шул ук вакытта бу зур бәхеттән әллә кая качасы, чыгып китәсе килгән иде. Ләкин баскан урынымнан кузгала алмыйча тордым. Чөнки сул аяктагы оегымның сүтеге ботинкама тыгып куелган иде. Менә шул чыккан төсле тоелды. Мин аны, сиңа күрсәтмәс өчен, уң аягым белән капларга тырыштым.

Концерттан соң танецлар булды. Син вальска чакырдың. Танец вакытында син:

— Галия, сезгә артистка булырга кирәк... Сез үзегездә булган талантның кадерен белмисез... Мин сезне шефка алырга телим... Сез атаклы җырчы булырсыз... Мин сезнең кара күзләрегезне яратам... Алар әллә ничек ягымлылар... Сезнең күзләрдә мин үземне күрәм. Рөхсәт итсәгез мин сезне озата барыр идем,— дидең. Мин шатлана-шатлана риза булдым.

Без чыгып киткәндә, безгә таба бик күп күзләр текәлделәр. Безне озаткан күзләр арасыннан аермачык күренгәне студент Вәли Сафиуллинның кара күзләре булды. Сафиуллин мине ярата иде. Дөрес, ул үзе бу турыда миңа бервакытта да әйткәне юк. Киресенчә, ул һәрвакыт миннән качарга, миңа күренмәскә тырыша иде. Ә мин Сафиуллиннан көлеп йөрдем. Мин бу акыллы студентта, бөтен фәннәрдән иң алда барган укучыда, хатын-кызларның байтагын сокландырган кыюлык, батырлык сыйфатларын күрмәдем. Ул күп вакытта йокымсырап йөри иде. Минем карашымда мондый йокымсыраган салмак кеше озак яши алмас, хәрәкәт яраткан заманыбыз андый кешеләрне онытыр дигән фикер туган иде. Безне озатып калган чагында да, Вәли Сафиуллинның күзләрендә әнә шул бетү, сүнү эзләре күренде.

Искәндәр!

Бу кичне син гаҗәп игътибарлы идең. Сүзләрең җылы, тавышың йомшак иде. Төн буе сине тыңлыйсы килде. Мин бу кичне, сине култыклап барганда:

— Нинди бәхет! Мин үземнең киләчәк тормышымны күрәм. Акыллым Искәндәр, мин сине үлгәнче яратырмын, мин сиңа яхшы иптәш булырмын,— дип уйладым.

Син мине тулай торакка хәтле озаттың. Парадный төбенә җиткәч, син йөрәккә ятышлы гаҗәеп бер елмаю белән минем иреннәремә карадың. Ә мин оялып читкә борылдым. Син:

«Галия... син нинди акыллы... бу онытылмаслык кичәнең дәвам итүен телим»,— дип, мине кочагыңа алдың. Шушындый рәхәт кочактан соң баскыч буйлап ничек менгәнемне, бүлмәгә ничек кайтып кергәнемне дә хәтерли алмыйм.

Мәхәббәт кешене матур итә. Бүлмәгә керү белән үк мин көзгегә карадым. Гомеремдә беренче тапкыр мин үземнең йөзем-кыяфәтем белән канәгатьләндем.

Төнге сәгать икедә бүлмәдәшләрем кайттылар. Алар, өстәлгә күз төшерү белән үк:

— Оһо, эш зурга киткән икән. Хәер зарар юк, егете чибәр,— диделәр.

Мин уйланып утыра-утыра өстәлгә җәелгән кәгазь өстен «Искәндәр», «Искәндәрем» шикелле бөдрә сүзләр белән язып тутырганмын.

Беренче мәхәббәт яраткан кешеңне матур итеп күрсәтә. Чөнки бу төнне мин, синең турыңда уйлаганда, синдә бер генә дә кер, начар як күрмәдем. Тик Фатыйма гына:

— Яхшы кара, Галия, ул синең җырыңа гына гашыйк түгелме?— диде.

Мин иртүк беркемгә бернәрсә әйтмичә урамга чыктым. Кабан күле буе урамына киттем. Ник? Белмим. Бу көнне дөнья якты, көн җылы иде. Миңа карап күп кенә халык үтте. Яныннан ирле-хатынлы бер пар үтеп китте. Эх, кешеләр дә соң... боруларына гына кара: берсе — алдан, икенчесе — арттан, эт белән мәче шикелле. Кем белә? Бәлки, алар да, бер-берсен тизрәк күрер өчен, озын төннәрен сәгатькә карап утырганнардыр.

Искәндәр!

Бу уйлар мине хәзер дә ташламыйлар. Әйе, матур семьялар да бар. Ләкин аларны күп итәсе килә. Юкса начар семья аркасында тормышлар ватыла, кешеләр биртелә, гарип тойгылар җәмәгать эшенә начар тәэсир итә.

Үзем хат язам, үзем Кабан күле күперенә басып торгандагыдай уйланам. Яңадан күз алдыма шул чагымны китерәм. Әнә бер пар бара. Бу ике кеше бер-берсенә кысылып, чит кешеләр ишетмәсен дигәндәй, нәрсә турындадыр сер итеп сөйләшеп баралар. Тукта... Әллә күзләрем саташамы? Булмас, ялгышамдыр...

Әйе, күпме генә аһ-ваһ итсәм дә, бу кешенең берсе син идең. Сине тану минем иң матур уйларымны пычратты. Күпме катып торганмын, ачык хәтерләмим, ләкин шул минутта күз алдымнан нинди картиналар узганы исемдә. Әле мине үпкән

эзләрең бетәргә дә өлгермәгән... инде аны, янында бара торган кызны үбәсең, кочасың төсле тоелды.

Шуннан соң без гаҗәп озак тоелган ике атна буенча очрашмый тордык.

Мин тормышта, Искәндәр, сөйләп бетергесез кыенлыклар күрдем. Сигез яшемдә ата-анасыз калдым. Тугыз яшемдә туганнарым тәрбиясенә күчеп, бала чагымны, сабый көннәремне бишек тирбәтеп үткәрдем. Мин үксез балалар белән бергә урамда йөрдем. Хаксызга кыйналганым, гаепсезгә иң әшәке сүзләр белән сүгелгәнем бар. Ләкин болар бар да синең ялганыңны белүдән җиңелрәк иделәр.

Синең ялганыңны сизгәннән соң, мин ябыктым, суырылдым.

Икенче очрашуыбызда мин синнән кем белән булуыңны сорадым. Син: «Күрше йортта торучы танышым»,— дидең. Аннары, сораганны көтмичә үк: «Аның белән минем арада шикләнерлек бернәрсә дә юк»,— дип, шикләндерерлек әйберләр сөйләдең. Яшермим, мин сиңа ышанмадым. Чөнки кешеләрнең бозык өлешендә булган әхлаксызлык аларны ялганга өйрәтә. Ялганлау сине кызартмый да. Сез, ирләрнең бозык өлеше, бер үк «сөям» сүзен ике-өч көн эчендә өч-дүрт кешегә әйтә аласыз.

Казан университетында укыган чакта, мин җәмәгать эше буенча Елга аръягы эшчеләре арасында йөрдем. Анда миңа Галиәкбәр дигән бер эшчене өенә йөреп укытырга туры килде. Гаҗәп бәхетле семья иде бу. Квартирасына керсәң — чыгасың килми: коры һавалы, яп-якты өч бүлмә, ванна, кухня. Зур улы — Кызыл Армиядә командир, икенче улы — инженер-төзүче, бер кызы — инженер-химик. Кече кызы музыкага өйрәнә.

Беренче баруымда Галиәкбәр абзый, бер миңа, бер карчыгына карап:

— Балаларым командир да инженер булгач, надан калу ничектер килешми. Нехорошо. Хәреф танып булмасмы дим,— дип, дәрес арасында үзенең тормышын сөйләп китте.

Ул өч ай эчендә укырга-язарга өйрәнде. Менә шушы карт белән карчыкның, Советлар илендә яңадан яшәргән, яшьлек белән чәчәк аткан ике кешенең шатлыгын күрсәң — шаккатыр идең. Мин аларга бик тиз ияләштем.

Икенче хат

Искәндәр!

Беренче хатымны сиңа җибәрмәдем. Хатымны җибәрерменме, юкмы — анысын да белмим. Менә хәзер дә синең өчен түгел, үзем өчен язам, үземнең тормышым белән сөйләшкәндәй утырам.

Икенче очрашуыбызда син:

— Галия, мин сине генә яратам. Минем матур тормыш төзисем килә. Ышанмыйм, мин бик күп хатын-кызны күрдем. Ләкин андый тормыштан туйдым. Хәзер бер генә кешене яратасым килә. Ул бер кеше — син, әйдә, бергә тора башлыйк,— дидең.

Мин сине, Искәндәр, артык якын күрдем. Үзең дә үзгәргән, бунтарьлыгың басыла төшкән кебек тоелдың. Без еш очраша башладык. Һәрбер очрашуыбыз матур төш шикелле үтә иде.

Шушындый кадерле минутлар белән матур кыш үтеп тә китте. Яз... чәчәкле яз... Мәхәббәтле яз җитте. Сирень агачлары чәчәк атты. Сандугачлар сайравы ишетелде. Яшь йөрәкләр, йолдызларга карап, төрле телләрдә, төрле тавышта «сөям», «яратам» сүзләрен әйтә башладылар.

Бу язда мин рабфакны бетердем. Бу язны без бергә кушылдык.

Очрашу кичәләре гадәткә кереп киткәнгә, син мине зур самавырыңны куеп, тәмле күчтәнәчләреңне хәзерләп көтә идең. Тора-бара оялуым да бетте. Квартира хуҗаларына да ияләштем. Бу кичәләрдә байтак матур китаплар укылды, күп кенә рольләр өйрәнелде. Спектакльләр булганда, мин, синең бүлмәңдә ялгыз калып, китаплардагы каһарманнар белән сөйләшә-сөйләшә синең кайтканыңны көтә идем. Мин үземнең белемемне арттырырга өйрәндем. Әдәбият, фән, техника китапларын, тарих-политика журналларын һәрвакыт күздән кичереп бардым.

Ышанмыйм, мин алдынгы совет хатыны гына түгел, гүзәл хатын булырга да теләдем. Менә шуның өчен дә мин сине театрдан кайтканда белемемне арттырып кына түгел, матурлыгымны сакларга тырышып та каршы ала идем. Син дә мине буш итмәдең. Бик еш, гримыңны да сөртмичә, миңа, минем яныма, кочагыма ашыга идең.

— Нигә болай?— диюемә, син, мине үбә-үбә:

— Галиям, мин бу рольне син күрсәткән төзәтмәләр белән, сине сөеп, синең турыңда уйлап, син биргән шатлык эчендә

уйнадым. Залда яңгыраган алкыш бер миңа гына түгел, сиңа да иде,— дип җавап бирдең.

Кайбер көннәрне мин дә спектакльләргә бара идем. Синең белән бергә шатлана һәм кайгыра торган идем. Ләкин син, Искәндәр, сәхнәдә генә түгел, тормышта да артист булгансың.

Көз көне мин Казан университетының медицина факультетына укырга кердем. Бу көзгә хәтле безнең тормыш яхшы барды. Ә көз көне иртә чәчәк аткан мәхәббәтебезнең хуш исле яфраклары арасында сары яфраклар күренә башладылар.

Иң элек син минем укырга керүемә каршы тордың.

— Артистка булырга теләмисең икән, миңа яхшы иптәш бул... Белемең болай да җитәрлек... Күгәрченнәр күк гөрләшеп торыйк, укыма,— дидең.

Бу беренче бәрелешүдә синең сүзләреңдә ата-бабаларыбызның тавышлары ишетелгәндәй булды. Ләкин мин үземнең иркемне, теләгемне, киләчәгемне корбан итәрлек дәрәҗәдә түгел идем. Чөнки мин, синең әмерләреңә карамастан, университетка укырга кердем.

Шуннан соң без бер бүлмәдә торсак та, сирәк, бары тик төнлә белән генә очраша торган идек. Иртә белән, мин дәрескә киткәндә, син йоклап кала идең, ә кичләрен сине театрдан көтәкөтә мин йокыга китә идем. Чөнки син уникедә кайтасы урынга, бик еш икедә, өчтә кайтырга өйрәндең. Җимерелә башлаган семьяны ныгыту өчен, «Гаилә дәфтәре» уйлап чыгардым. Минем уемча, без бу дәфтәргә гаилә эчендә булган барлык кимчелекләрне яза барырга, шуны укып төзәлергә тырышырга тиеш идек. Син бу дәфтәргә әйләнеп тә карамадың. Ә мин сиңа болай дип җавап биргән идем:

«Минем характерымны өйрәнеп бет, сорауларыма игътибар ит, ярдәм күрсәт»,— дигән сүзләреңне ничек аңларга? Нигә мин сине өйрәнергә тиеш тә, син мине түгел? Синең бу сүзләрең: «Миңа буйсын, миңа кол бул»,— дию белән бер бит. Бу — бик иске караш. Шулай ук мин синең турыда ялгыштыммыни?»

Әйе, ялгышканмын шул. Чөнки без икебез дә ул чакны мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңлап җитә алмаганбыз. Без бер-беребезгә сокландык. Шуның исереклегендә икенче сайланышны, идея сайланышын, аның кирәклеген сизми калдык. Идея сайланышына тормышка, җәмгыятькә, эшкә карашның бер булуы, сәяси караш бердәмлеге кирәк. Безнең арада идея сайланышы юк иде. Киресенчә, синдә, Искәндәр, бергә тора баш-

лагач та, тышкы матурлык астына яшеренгән иске карашлар чәчәк атарга тотындылар.

Озакламый мин балага уздым. Бу хәл икенче бәрелешүгә сәбәп булды. Башта ике-өч көн эндәшмичә йөрдең. Ә соңыннан:

— Без әле яшь. Синең укыйсың да бар. Мин — артист, мин — иҗат кешесе. Бала икебез өчен дә тере богау булачак,— сүзләреннән,— мине яратсаң, минем белән торырга теләсәң, бала китермә!— дип куркытуга күчтең.

Әйе, мин риза булмадым. Мин кыз таптым.

Бала да булгач, кыз да тугач, син әллә нишләдең. Синең һәрбер кыланышыңнан «менә көтмәгән бәла» дигән фикерне укып була иде.

Син көн саен диярлек:

— Бүген дә рольне өйрәнеп булмады. Бу шау-шуда иҗат итеп буламыни?!— дия башладың.

Әйе, гаиләдә бала тавышы яңгырагач, син мине татар кызы булуым өчен дә тирги башладың. «Татар кызы матур итеп сөя белми. Болай да аз матурлыкны балага биреп, үзе буш кала» шикелле сүзләр синең төп сүзлегең булып киттеләр. Шул рәттән үк минем җәмәгать эшенә катнашып йөрүемне дә тәнкыйть итә башладың:

— Җил куып йөрисең шунда. Шайтан кушамыни сиңа әллә кемнәрне укытып йөрергә? Җыелышларга чабарга берәү дә кушмый, үзең чабасың. Дәрестән башка җиргә йөрергә мин сиңа запрещаю,— дип бармак янадың.

Җәмәгать эшен ташлау, заман агышыннан аерылып калу, синең «запрещаю»ларыңа буйсыну минем өчен үлем белән бер булыр иде. Җәмгыять хисе, җәмгыять өчен яшәү фикере синең «запрещаю»ларыңа буйсынудан өстен булырга тиеш икәнлеген мин сизгән идем инде. Минем гаилә, мәхәббәт турында булган карашларым да әнә шул хисне — җәмгыять өчен файдалы булу тойгысын үстерергә теләүдән туган нәрсәләр. Идея сайланышы булмау аркасында безнең гаиләбезнең җимерелүенә төп сәбәп — җәмгыятькә карата мөнәсәбәтне төрлечә аңлау булды. Мин үзем моны бик соң аңладым. Һәм шуны яхшы итеп аңлагач кына, гаилә фаҗигасе нәтиҗәсендә туган яраларым тиз һәм җиңел төзәлделәр.

Балама мин Кадрия дип исем бирдем. Бу да сиңа ошамады.

Дөрес, сиңа җиңел булмады. Ләкин син бер генә тапкыр да гаиләнең кытыршы яклары турында күзгә-күз карап сөйләшергә, аңлашырга теләмәдең. Тик расходның күплеге турын-

да гына зарлана идең. Авырга алма, Искәндәр, бергә торган чагында мин сине чыгышың, тәрбияң белән шелтәләмәдем. Инде хәзер, ул елларны син бик еш атаң мәзингә охшап китә идең, дип әйтә алам. Син бит балага сөт алырга биргән акчаны да, садака акчасын караган шикелле, әйләндереп-әйләндереп, мең кат карый идең.

Мин бик еш: «Искәндәрнең яхшы яклары да күп, ул үзгәрер әле»,— дип уйлый идем. Һәм, кулымнан килгәнчә, сине үзгәртергә тырыштым. Мин, сиңа төшкән расходны җиңеләйтү өчен, аз сәгатьләр белән генә чикләнгән ялымны төрле учреждениеләргә плакатлар, лозунглар язып үткәрдем.

Кышкы салкында, әче буранда, иртәнге сигездә бер кулыма китаплар кыстырып, икенче кулыма бала күтәреп, яслегә ашыга идем. Син татлы йокыда кала идең. Миңа булышу түгел, «Болай торуның ахыры булырмы, юкмы? Ашарга хәзерләмичә киткәнсең»,— дип, тиргәү сүзләрен генә әйтә идең.

Мин баламның көндәлек дәфтәрен язудан, язылганын укудан рәхәтлек таба идем. Ләкин син, Искәндәр, бу дәфтәргә бер генә тапкыр да күз төшермәдең. Безнең арабыз ерак хәзер. Ләкин Кадрия синең дә балаң бит. «Көндәлек»нең кайбер өземтәләрен уку файда китерергә мөмкин. Менә алар:

3 ай, 10 көн.

Кадриям мине таный. Нинди шатлык. Димәк, кызымның башы эшли. Тик Искәндәргә иярләшмәве генә мине борчый.

4 ай, 24 көн.

Бүген ял көне. Балам белән сөйләшеп утырдым. Кич белән Галиәкбәр абзыйларга барып кайттым. Бүген Кадриягә бер букет чәчәкләр алдым. Кадрия ачык, якты, ялтыравыклы әйберләр ярата.

6 ай, 20 көн.

Мин биегән чагында, Кадриям кычкырып көлә. Ясле дә дә үзен бик яраталар.

7 ай, 18 көн.

Кадрия «әннәннә» дип әйтә башлады. Бүген (ял көне) көн буе янымда шаярып утырды. Мин стена газетасына килгән мәкалә-хәбәрләрне төзәттем.

Бер яшь.

Тазалыгына сокланмаган кеше юк. Бүген мин аңа яңа күлмәк кигездем. Иптәшләр дә котларга килделәр. Тик Искән-

дәр генә Кадриянең туган көнен оныткан. Ул бүген төнге икедә генә кайтты. Бүген еладым.

Бер яшь, 2 ай.

Кадрия йөри башлады. Китап сорап йөдәтә.

Бер яшь, 4 ай.

Кадриям кызамык белән авырый. Больницага салдым. Һәр көн янына барып йөрим. Өйдә шундый күңелсез...

Бер яшь, 9 ай.

Кичә Кадрияне демонстрациягә алып чыктым. Өйгә кайткач, бик озак «шулай, шулай» дип урамдагыча маршлап йөрде.

Искәндәр!

Хатыңда балаларның көндәлек тормышлары турында язуымны сорыйсың. «Миндә дә аталык хисе кузгалды», — дисең. Эч пошканнан гына әйтелгән сүз түгелме бу?

Балаларым яхшы үсә. Атасыз үсүләреннән башка зарланырлык нәрсәләре юк. Кадриям МТС янындагы балалар бакчасына йөри. Бик күп җырлар белә.

Кичләрен без аның белән икәүләп җырлыйбыз. Безгә карап Рафаэль дә җырлаган булып кылана.

Искәндәр!

Син Рафаэль тугач, нинди тамаша ясаганыңны хәтерлисеңме? Аны онытуы кыен. Син бит больницага мине каршы алырга да бармадың.

Мин больницадан кайтып хәл җыярга өлгермәдем, син:

— Син, Галия, артист хатыны булырга түгел, яслегә бала караучы булып керергә иде, хәер, мин сине гаепләмим, үзем гаепле, уйламыйча өйләнүем өчен гаепле, сәхнә кешесе һәрвакыт иреклe булырга тиеш... Ә мин семья белән, балалар белән богауландым... Мин синең белән артык тора алмыйм... Үсмәгән балалар өчен үземне корбан итә алмыйм... Хуш... Мине эзләмә,— дидең дә чыгып киттең.

Дөрес, йөрәгемнең әллә кай почмагында сиңа карата җылы хисем бар иде әле. Шулай да мин сине туктатмадым. Син, ихтимал: «Бу елар, муеныма асылыныр, миннән башка тора алмас, чакыртыр, ялварыр», — дип уйлагансың.

Мин ялварырга да, тезләнергә дә теләмәдем. Башта миңа бик кыен булды. Син чыгып киткәндә, минем бөтен байлыгым — ике балам иде.

Мин синнән бер тиен дә сорамадым, үзең аңлап бирмәдең. Хәер, сине хәзер театрда эшләми, киткән дип тә сөйләделәр.

Мине бәладән коткаручы кешеләр университет директоры Даутов иптәш белән партком секретаре Николаев булдылар. Галиәкбәр абзый белән студентлар коллективы да күп ярдәм иттеләр. Аларның миңа күрсәткән туганлыклары сыйнфый туганлык иде.

Бу соңгы бер ел эчендә без бөтенләй күрешми тордык. Ахырысында институт тәмам булды. Бер айдан соң, ике баламны күтәреп, Әдрәс районына врач булып эшләргә киттем.

Өченче хат

Искәндәр!

Син үзеңнең хатыңда: «Тормышың ничек уза? Балалар мине сагынамы? Авылда күңелсез түгелме? Берсен дә калдырмыйча яз»,— дисең. Кызыксынуың өчен чын күңелдән рәхмәт.

Мин район үзәге булган Әдрәс авылына килеп төштем.

Бу авыл миңа бик ошады. Монда иске авыл эзләрен күрсәтеп торган мәчет тә, фәлән дә юк. Авыл уртасыннан боргаланып-сыргаланып агымсу үтә. Су буена алмагачлар, чия һәм шомырт агачлары тезелгән. Яз көннәрендә авыл ап-ак чәчәкләргә күмелә. Авылдан бер километрда урман эчендә ял йорты урнашкан. Авыл уртасыннан поездлар уза. Кырларда тракторлар җыры яңгырый. Таш юлдан грузовик һәм җиңел машиналар йөри.

Ләкин авылда тора башлау белән миңа бик күп кыенлыкларга очрарга туры килде. Амбулатория — врач пункты — ташландык хәлдә иде. Бинасы җимерек, салкын. Миңа хәтле пункт белән бер фельдшер мөдирлек иткән. Ул пунктка килгән спиртны эчү һәм ялган справкалар язып өләшүдән башка бернәрсә белән дә кызыксынмаган. Башка медицина эшчеләре дә эшкә салкын карарга гадәтләнгәннәр.

Райздрав урындыгына вакытлыча утырган тәҗрибәсез 20 яшьлек кыз үзеннән чыгып бернәрсә дә эшли алмый.

— Монда мин ничек эшләрмен икән,— дип котым очты. Аптеканың ярлылыгы эчне пошырды. Беренче тапкыр: «Әллә ташлап качып китимме?»— дип тә уйладым. Ләкин китмәскә, киртәләрне җимерергә булдым.

МТС эшчеләренең ярдәме белән тиз арада гына амбулатория бинасын чистарттым, түшәмен, стеналарын агарттым. Аптека мөдиренә кискен рәвештә иң кирәкле даруларны булдырырга куштым. Авыруны тыңлап карау, градусник кулла-

ну, авыруга карточка тутыру шикелле нәрсәләрне керттем. Авылларга чыгып йөрергә план төзедем.

Ашлык җыю вакыты җитте. Авылда берүзем калып, эшчеләремне участокларга беркетеп, төрле авылларга чыгарып җибәрдем.

Шулвакыт эчендә районыбызда медицина эшен югары дәрәҗәгә күтәргән өч вакыйга булып алды.

Беренче вакыйга — 6—7 яшьлек бер кыз баланың Әдрәс суына бату вакыйгасы. Бу кызны мин элегрәк тә белә идем. Аның исеме — Нәфисә. Ул бик еш минем Кадриям белән уйный иде. Нәфисә, йөзә белмичә су кереп, тирән чокырга очрап баткан. Балалар шау-шуына җыелган халык аны берничә минуттан соң гына судан үлек килеш чыгарган.

Хәзер дә күз алдымда. Әнә ул өстәлдә ята. Тәне күгелҗем төскә керә башлаган. Баласының юеш чәчләрен үбә-үбә ана елый. Аяк очында нәрсә эшләргә дә белмәгән ата:

— Доктор, берәү генә бит... Шулай ук үлдемени?— ди.

Халыкны чыгарырга, ананы алып китеп тынычландырырга куштым. Баланың авызын ачып, сулыш өрү эшләргә тотындым. Пульс бөтенләй юк. Тәрәзәне ачтырып, һаваны алмаштырдым. Кулларым талганчы сулыш ясадым. Күзләремнән яшьләр тамарга тора. Йомшаклыгыма ачуланам. Докторга болай изрәргә ярамый дип, үземә батырлык кертергә тырышам. Ә үзем сулыш ясый-ясый авыз эченнән генә: «Терел, терел, бәгырем, яңадан уйнарсың, Кадрия белән йөрерсең... терел...»,— дим. Баланың атасы нәрсәдер сөйли: «Ардыгыз инде, доктор, булмый, күрәсең»,— ди бугай. Ләкин мин ишетмим. Күрше бүлмәдә баланың анасы — Зәйтүнә апа акыра: «Баламны җәфалыйсыз гына...» Монысын да ачык ишетмим. Һаман сулыш ясыйм, һаман авыз эчен арчыйм.

Һәм... шатлыгымнан күз яшем тамды. Йөрәк тибеше кузгалды.

Бөтен өмет өзелгәч, бичара ана елый-елый тавышсыз калгач, бала үзенең тере икәнен белгертте, сулыш алган кебек булды, авызыннан су акты. Күз кабакларын селкетте. Әйе, баланың йөрәге тибә башлады. Шуннан соң миндә көч арткандай булды. Мин бөтен көчемне баланы саклап калырга, тибә башлаган йөрәкне туктатмаска тырыштым. Бала исән калды.

Икенче вакыйга күрше авылда булды. Беркөнне үземне Чымты авылына авыруны карарга алып киттеләр.

Сәкедә, толыплар белән томаланып, бармаклары белән мендәргә ябышып, 18—20 яшьлек бер кыз ята. Температурасын карадым — 39°. Пульсын санарга дип кулына сузылсам — кан. Карчык:

— Кузгатмагыз, узар... Зыяндашлы бала ул... Һәр ел шулай була торган иде,— ди.

Кулларымны юып, авыруга ярдәм бирергә тотындым. Ул бала тапкан. Ләкин соңгылыгын алмыйча калдырганнар. Мин тиешле ярдәмне күрсәттем дә карчыкка:

— Авыруга тынычлык кирәк, беркемне дә кертмә,— дип, авыл Советына киттем.

Авыру бер атнадан аякка басты.

Өченче вакыйга — төрле җирдә дәваланып та сәламәтләнә алмаган бер картның Әдрәскә килүе булды. Аны: «Синдә рак»,— дип куркытканнар. Карт миңа килгәндә бөтенләй ябык иде; яңаклары ябышкан, күзләре эчкә баткан, үзе көчкә йөри.

— Ашый торган ашымны йота алмыйм,— ди. Шул уңай белән ике-өч көн эчендә үземдә булган бөтен әдәбиятны яңадан карап чыктым. Һәм шуннан соң гына картка:

— Куркырлык бернәрсә дә юк. Синдә рак түгел,— дидем. Кулымнан килгәнчә үзен дәваларга тотындым. Шушындый чаралардан соң авыруым аз гына булса да ашый башлады, баш чатнавы бетте, тыныч йоклый торган булды.

Бу өч вакыйга минем рухымны күтәрде, кыюлыгымны арттырды.

Ахырысында квартирага да күчтем. Мең бәла белән аннан такта, моннан кадак, тегеннән бур җыеп, ремонтны очлап чыктым. Аптеканы икенче бинага күчердек. Ләкин бу эшләрнең ахырына чыгар өчен күп көч түгәргә, йокы калдырырга туры килде. Болар һәммәсе дә беренче айларымда ук минем өстемә төшкән иде. Авылларга да чыгарга туры килә иде. Аннан арып, тузанга батып кайтасың. Өйгә килеп керү белән ике яктан ике балам сарыла. Алар белән рәхәтләнеп, уйнап-көлеп йокларга ятасың.

Үткән ел балаларым өчен радио куйдырдым. Еш булмаса да, балаларым белән бергә су керергә барам, урманга чыгам. Пианино алырга җыенуымны яздым шикелле. Ләкин балалар өчен болар гына җитми. Аларга тере кеше дә, ата да кирәк.

Синең белән аерылуга өч еллап вакыт узгач, Кадрия бик еш:

— Әнкәй, нигә безнең әтиебез юк? Минем әтием кемгә охшаган? Ник ул хат язмый?— дип сораштыра башлады.

«Без аерылдык, сез ятим калдыгыз»,— дип, иске заман сүзләре белән кәефләрен бозасым килми. Ата турында сүз чыккан саен мин аларга:

— Ул Мәскәүдә укый. Укып бетергәч кайтыр. Сезгә бүләкләр китерер,— дип сөйлим.

Балаларга шулай сөйләгәч, гаилә тормышым белән кызыксынган кешеләргә дә «ирем читтә» дип ялганнарга өйрәндем. Кем белә, бәлки гайбәттән саклану өчен генә дә мин «ирем бар» дияр идем. Чөнки авылда тол хатынга — ире булмыйча балалар асраган кешегә — начар күз белән карау бетмәгән әле.

Искәндәр!

Бу хатны мин, өзеп-өзеп, ялгыз калган минутларымда язам. Кайчагында шундый хатлар язуыма кәефем дә китә. «Ни өчен язам?»— дип, үз-үземә сораулар бирәм. Йөрәккә тулган шул. Бушанасым килә.

Мин сиңа балаларыма «әткәй» табуым турында язарга уйлаган идем. Бу гаҗәп эш болай булды:

Кичләрнең берсендә, студентка чагымнан калган дәфтәрләрне актарганда, корзина төбеннән бер рәсем килеп чыкты. Бу рәсем минем белән бергә укыган, миңа яшерен мәхәббәт тотып йөргән рабфак студенты Вәли Сафиуллин рәсеме иде. Рабфакта чакта мин стена газетасында эшли идем. Шуннан эләгеп калган рәсем, ахры. Рәсем караган кичне, Искәндәр, мин сине уйламаска тырыштым. Ирекле-ирексез гел Вәли Сафиуллин тирәсендә әйләндем. Һәм кинәт яңа дөнья ачкан шикелле: «Вәлинең фамилиясе дә минем фамилиям белән бер, мин дә Сафиуллина бит. Кадрия: «Әткәй кайда? Ул кемгә охшаган?»— дип сорый. «Менә синең әткәең. Менә минем ирем»,— дип, Вәлине үземә хыялый ир» иттем. Бу кичне мин Сафиуллин рәсемен, рамга куеп, стенага элдем. Ә иртәгесен Кадрия белән Рафаэльгә:

— Карагыз, әткәегез нинди чибәр. Ул тиздән кайтыр,— дип, аларны «хыялый ата»лары белән таныштыра башладым.

Рәсем төшерергә яратуымны син яхшы беләсең. Тора-бара Вәли рәсемен үз рәсемем белән янәшә куеп төшердем — икәү бергә төшкәндәй чыкты.

Бервакыт, үтенеп сорагач, син минем белән рәсемгә төшәргә барган идең. Шунда син Кадрияне итәгеңә алып төшкән идең. Бу рәсем миндә әле дә саклана. Алар икәү. Шуның берсеннән синең башыңны кисеп алып, Сафиуллин башын куеп төшердем.

Бу рәсемнәрнең барысы да стенага эленделәр. Аларга үзем дә, балалар да, күршеләр дә ияләштек.

Яшермим, бик еш Вәлине күрәсе килгән көннәрем була. Хәтта кайтып кергәч, аның рәсеменә карап: «Вәли, син хәзер кайда? Галия исемле «хатының» барлыкны үзең беләсеңме? Галия — синеке!» — дип хыялланам.

Балаларга ата табылды. Ләкин «хыялый ата»ны чын ата итеп саклап баруы бик кыен булды. Кадриянең: «Әткәй ник хат язмый?» — дип соравына каршы, үз-үземә хатлар язарга туры килде. Соңра һәр ун көн саен мин, башымнан уйлап чыгарып, Вәлидән дип, үземә һәм балаларга сәлам хатлары китерергә өйрәндем. Хат алгач, җавап та язарга кирәк була. Айга берике тапкыр минем белән бергә Кадрия дә «ата»сына хат яза.

Бу эшнең ахыры куркыта. Балалар үскәнче бу «сер» ачылмасын гына иде. Ә үскәч, мин аларга үземнең юләрлегемне әкият итеп сөйләрмен.

Ләкин үткән ел әлеге суга баткан Нәфисәнең анасы Зәйтүнә апа, газета китереп, бик каты куркытты:

— Кара әле, Галия, монда синең иреңне язганнар, рәсемен дә төшергәннәр,— диде.

Вәли Сафиуллин, Казан рабфагын бетергәннән соң, Мәскәүгә киткән. Университетның физматында укыган һәм төннәр буена математика өстендә утырган. МГУны бетергәч, Мәскәү урта мәктәпләренең берсенә математика укытучысы булып кергән. Анда вузларда сокланырлык рәвештә математика кабинеты оештырган. Укыту эшенә үзенең модельләрен керткән, профессорның әйтүенә караганда, Сафиуллин математиканы иң күңелле, иң җиңел дәрес иткән. Аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләгәннәр. Мәкаләдә әнә шулар языла.

Күпме уйланып утырганмын — ачык хәтерләмим. Тик, болай булгачтын, Вәлинең «хыялый ата» булуы ачылыр, миннән көләрләр, дип курка башлавым гына исемдә. Аннары «Вәлине Әдрәстә кем күрсен соң?»— дип, үз-үземне юатып та куйдым.

Ярый. Тыныч йокы яки хәерле иртә, Искәндәр. Вәли турында уйлап, өченче хатымны шуның белән тәмам итәм.

Дүртенче хат

Искәндәр!

Тормышыма зур үзгәреш керткән бер вакыйгага булу аркасында бу хат нәкъ 20 көн өзелеп торды. Шунлыктан Мәфтуха апай турында да язалмый калдым. Мин сиңа байтак нәрсә турында язарга уйлаган идем. Ләкин көтмәгән бер вакыйга

килеп чыкты, хатымны чуалтты. Шуның аркасында башта язылган өч хатымны да җибәрми калдым.

Бу көн амбулаториядә авыруларны карап бетереп китәргә җыенганда гына, ял йорты докторы, кереп:

— Ирең безгә ял итәргә килде. Синең турында сөйләгәч, бик шатланды. Бүген янына килә,— диде.

Кулымда градусник иде — төшеп ватылды. Бер-ике минутка телсез калдым. Нинди ирем? Кем? Искәндәрме? Вәлиме? Нәрсә уйларга да, кемне күрергә дә белмәдем. Ял йорты докторы — гаҗәп культуралы кеше. Ул канлы ярага тоз салырга яратмый — минем нинди хәлдә калуымны аңлады, күрәсең:

— Шатлыгыңнан шаккаттың бит, Галия. Ярый, мин киттем. Иреңне каршы алырга комачауламыйм. Аннары ашыгыч эшләрем дә бар. Икәүләп безнең янга, мороженое ашарга барыгыз,— дип чыгып китте.

Ял йорты докторы чыгып киткәч, ярты сәгать чамасы кабинетымда бикләнеп утырдым. «Искәндәр булмас, аның белән бөтен нәрсә өзелгән, беткән. Ул булса — күрешермен, сөйләшермен дә бетәр. Вәли булса нишләрмен? Романтикага бирелеп тудырылган «хыялый ирем» юкка чыккач, халыкка, балаларга нәрсә әйтермен?» — дип уйландым. Өйгә кайтырга җыенып, амбулатория ишеген ачтым. Ишек төбендә Вәли Сафиуллин иде.

— Мөмкинме? — диде.

— Рәхим итегез...

Без кабинетка кердек. Ул бик нык үзгәргән. Йокымсыравы беткән. Олылык төсе кергән. Тик аның күзләрендә генә элекке Сафиуллин билгеләре калган. Йөзендә — шатлык.

— Әдрәстә очрашырбыз дип, кем уйлаган?!

— Әйе.

— Я, ничек торасыз? Сез мине оныткансыз да инде. Хәер, белмим. Ә мин рабфакны, рабфак белән бергә сезне дә бик еш искә төшерәм,— дип сөйләп китеп, мине уңайсызлыктан чыгарырга тырышты.

Бер ярты сәгать сөйләшкәннән соң:

— Буш булсагыз, мине чәй белән сыйлар идегез. Ял йортында чәйне көнгә бер тапкыр гына бирәләр, ә мин — яратып чәй эчәргә өйрәнгән кеше. Гаиләгез белән дә таныштырырсыз,— диде дә урыныннан кузгалды.

Башта мин аны өемә чакырырга да, чакырмаска да белмәдем, чөнки балаларым әткәй дип Вәлинең муенына асылынулары мөмкин. Рәсемнәрне күреп мине дә, үзен дә уңайсыз

хәлдә калдырыр. Мин шулай уйладым. Ләкин шулхәтле озак күрешми торганнан соң «вакытым юк» дип Вәлине дә кайтарып җибәрергә теләмәдем. Тик амбулаториядән чыккач кына, башыма килгән фикерне әйтә алдым:

— Әнә теге як йортны күрәсезме? Мин шунда торам инде. Приемнан соң өс-башны алыштырасы бар. Ун-унбиш минуттан соң шунда килергә булсагыз, мин сезне вареньелап чәй белән сыйлармын,— дидем.

Ул риза булды.

Мин, өйгә кайтып, балаларны урманга җиләккә җибәрдем. Самовар куеп, өстемне алыштырдым. Һәм түземсезлек белән Вәлине көтә башладым. Стеналарга эленеп куелган рәсемнәрне кузгатмаска булдым. Сер ачылгачтын ахырына кадәр ачылсын, дидем.

Самовар өстәлгә менү белән Вәли килеп керде.

— Сезнең квартирыгыз шәһәр квартирларыннан бер дә ким түгел,— дип, керүенә бүлмәләрне мактый-мактый, күзен стеналарга, рәсемнәргә төшерде. Рәсемнәрдә үзен күрүгә гаҗәпсенде. Ләкин эндәшмәде.

Тик чәй алдында гына, бер-беребезгә ияләшә төшкәч кенә, түбәндәгечә сөйләшүләр китте:

— Карагыз әле, Галия,— диде ул,— мин ял йортына килеп төшкәннең икенче көнендә үк миңа: «Сезнең хатыныгыз биредә доктор булып эшли»,— диделәр. Юлда йөргәндә, ял йортларында ятканда кеше белән нинди кызык нәрсәләр булмый! Тиз танышасың. Шунда моңарчы берәүгә дә сөйләмәгән серләрне сөйлисең. Моннан соң мәңге очрамаслык кешеләр белән дуслашасың. Бу юлы да: «Мине берәр кеше белән бутыйлар, күрәсең, әйдә кызык булсын»,— дип уйладым да, «Хатының монда»,— дип әйтүчеләргә: «Әйе шул, минем хатыным монда эшли»,— дия башладым. Ләкин ял йорты докторы да шул ук сүзне әйткәч, «Сезнең хатыныгыз Галия Сафиуллина»,— дигәнне дә ишеткәч, борчылырга тотындым һәм сезне күрәсем килде: «Фамилияләр бер булганга шулай әйтә торганнардыр»,— дип уйласам да «юк» дип җавап бирергә телем бармады. Чөнки рабфакта чакта мин хыял итеп йөргән Галиямнең хәзер кешеләр тарафыннан «Синең хатының Галия» дип йөртелүе минем өчен рәхәт иде. Инде үзегезне күрдем. Менә монда, сезнең өегездә утырам. Стенада үземнең рәсемнәремне күрәм. Ләкин бит мин сезнең белән бервакытта да рәсемгә төшкәнем юк. Миңа охшаган кеше кем ул? Ялгышмасам, сез

артист Искәндәргә чыккан идегез. Аерылдыгызмы әллә? Искәндәрдән соң әнә шушы рәсемдәге кешегә чыктыгызмы? Нинди кәмит бу? Зинһар, аңлата күрегез.

— Искәндәр белән мин күптән аерылдым. Шуннан соң берәүгә дә чыкмадым, дияр идем, хата булыр. Чөнки рәсемдәге кеше «ирем» булып хисаплана. Балаларым аңа «әткәй» диләр.

— Кем соң ул?

— Ул — сез. Мин ул рәсемне рабфактан калган дәфтәрләрем арасыннан таптым.

— Димәк, сезне минем хатыным дип йөрүләре дөрес?

— Әйе, дөрес.

— Ләкин мин бернәрсә дә аңлый алмыйм. Бу эшкә сәбәп нәрсә?

— Әгәр дә бу эш сезне борчыса, мин хәзер үк рәсемнәрне алып яшерә алам һәм телисез икән, ял йортына барып, «Бу Сафиуллин минем ирем түгел»,— дия алам. Ләкин сез монда күп булса тагын бер ай торасыз. Авырсынмасагыз, мин сездән бу «кәмит»нең — «фаҗигале кәмит»нең дәвам итүен сорар идем.

— Ягъни?

— Ягъни гаиләгез турында сүз чыкканда...

— Мин өйләнмәгән, минем гаиләм юк...

— Минем турыда сүз чыкканда дим мин...

— Әйе...

— Галия минем хатыным, иптәшем, дип әйтегез.

— Ни өчен? Нигә? Һич аңламыйм.

— Вәли, сез миңа бик авыр сораулар бирәсез. Курыкмагыз, мин сезгә ике баламны тагарга, сезгә кияүгә чыгарга уйламыйм. Бу бары сезне һәм үземне кешеләр алдында да кыен хәлдән чыгару өчен генә. Юкса я сез, я мин, икебезнең берсе хәзер үк моннан китәргә тиеш.

— Беребез дә китми. Мин риза. Тик үзем белмичә мин ничек итеп сезнең ирегез булганмын? Шуны беләсе килә.

— Анысын хәзергә сорамагыз. Мин аны сезгә... Димәк, риза?

— Риза.

— Рәхмәт,— дидем дә кулымны суздым һәм аны балаларның яшьләре, исемнәре белән таныштырдым. Үз өенә килгән кебек миңа кереп йөрүен сорадым. Балалар белән әткәйләре шикелле сөйләшүен үтендем.

Шуннан соң ул көн саен безгә килеп йөри башлады. Балалар аңа бик тиз иялә штеләр. «Әткәй», «әткәем» дип, артын-

нан калмыйча йөриләр. Бергә урманга, чиягә йөрдек. Шул вакытларны райздрав:

— Ирең дә кайткан, ашлык җыю вакыты да җитә. Син бер 15 көнгә отпускага чыгар идең. Аннары кызу эш булыр,— дип, үземә отпуск бирде.

Без көн саен очраша торган булдык. Бергә төрле китаплар укылды. Студент чаклар искә төшерелде. Мин үземнән курыктым. Чөнки Вәлине чын-чынлап ярата башлаганымны сиздем. Аның белән ничек саубуллашырмын, бергә кушылмас борын ничек аерылырмын, дип йөрәгем сызлады.

Менә хәзер дә, шушы хатны язып утырганда да борчылам. Вәли көн саен миннән үземне аның хатыны дип халыкка белдерүемнең сәбәбен сорый. Мин «иртәгә», «иртәгә» дип сузып килдем. Соңгы соравына «китәр көнеңдә әйтермен» дидем. Иртәгә ул китә. Ничек аңлатырга! Кайчагында миңа, ул мине, элеккечә үк ярата төсле тоела. Хәтта шаярып утырганда:

— Галия, чынлап та, мин синең чын ирең — иптәшең булсам, ягъни без бергә кушылсак, ни әйтер идең?— дип сораулар да бирә.

Ләкин мин мондый сораулар бирелгәндә, я эндәшми калам, я шаярып әйтелгән сүзгә борам. Чөнки мин аның мәхәббәтенә җавап бирә алмам төсле. Ике балалы булуым, рабфакта аңардан көлеп йөрүем — синең белән торуым аның исенә төшәр, ул борчылыр, борчылса да әйтмәс. Әйтми калуы аңа газап булыр. Ә мин аның газап күрүен теләмим.

Иртәгә Вәлинең китү көне. Мин бүген эшкә чыктым. Башым һич эшләми. Гел аның турында уйланам. Аның белән аерылу Казаннан киткән минутларыма караганда да авыррак буласын беләм. Бу хатны шунда өзеп: «Вәли, мин сине яратам бит, ләкин без синең белән хыялда гына ир һәм хатын булып калырбыз»,— дип, хатны аңа борасы килә.

Берәү ишек шакый.

Вәли: «Иртәгә соңгы кич, озак утырырга килермен»,— дигән иде.

— Ярыймы? — ди ул.

Искәндәр!

Күрше бүлмәдә Вәли утыра. Яза алмыйм, кулларым калтырый.

Вәли:

— Иртәгә китәм, Галия. Ләкин китәсе килми. Ияләштем. Шулай да китәм, Галия. «Хыялый ирең» булуымның сәбәбен

беләсем килә. Тагы да ярты айга калырга мөмкин иде. Калсам, бөтенләй китә алмам, дип куркам. Серне ачыгыз,— ди.

Мин, «хәзер» дип, икенче бүлмәгә керәм һәм шушы сүзләрне язам. Болай гына сөйләп мин аңа барыбер аңлата алмам. Чөнки үземне бик начар хис итәм. Шуңа күрә дә сиңа язылган хатларны Вәлигә бирергә булдым. Укысын да теләсә ничек аңласын. Хәзер янына чыгам да:

— Мә, дустым, шуларны укып чык. Бу — минем тормышым. Шуннан барысын да аңларсың,— дим.

Хуш, Искәндәр! Сау бул! Хуш, Вәли! Синең белән саубуллашуы миңа бик тә авыр булыр.

Галия

Автордан

Кадерле укучым!

Быел яз көне миңа бер гаиләдә кунакта булырга туры килде. Бу гаилә үзенең шатлыгы, бәхетлелеге белән мине бик кызыктырды. Шулхәтле тату торган семьялар әле бездә хәзер генә күбәеп чәчәк атып баралар. Мин аларга һәр кич саен кереп йөри башладым. Һәм соңгы баруларымның берсендә:

— Сез бик яхшы торасыз. Беренче танышуыгыз ничек булды? Сөйләргә ярыймы?— дип сорадым.

Яңа дусларым миңа сез укып чыккан әлеге хатларны чыгарып бирделәр һәм:

— Сез язучы бит, файдаланырга мөмкин,— диделәр.

Мин, хатларны укып чыгу белән, фамилияләрне һәм район, авыл исемнәрен алмаштырып, аларны, дусларымның рөхсәте белән, матбугатка чыгарырга уйладым.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Тапшырылмаган хатлар»ның жанр үзенчәлеген билгеләгез. Аның әһәмияте нәрсәдә? Г. Кутуй әсәргә ни өчен шундый исем биргән?

2. Хатлар эчтәлегенә бәйле төп вакыйгаларны ачыклагыз.

3. Галия һәм Искәндәр образларын характерлагыз, охшаш һәм аермалы якларын күрсәтегез.

4. Галия хатларны ни өчен яза башлаган дип уйлыйсыз?

5. Әсәрдә нинди мәсьәләләр күтәрелә? Аларның бәйләнеше аша төп теманы ачыклагыз.

6. Повестьта нинди иҗади алымнар кулланылган?

7. Алдагы дәресләрдә башлаган сүзлек төзү эшен дәвам итегез.

«Тапшырылмаган хатлар» повесте

Әсәр хатлар формасында язылган. Повесть дүрт хатны үз эченә ала. Сюжет үткәннәрне искә төшерү һәм үз чоры вакыйгаларын хикәяләү, төп образның тормышка мөнәсәбәтен белдерү юлы белән үстерелә. Хат язу дәвамында Галия шәхес буларак ачыла бара.

Әсәрдә Галия образы психологик яктан шактый тирән ачыла. Ул беренче хатта Искәндәргә карата йөрәк түрендә бөреләнгән беренче мәхәббәтнең никадәр чиста, ни дәрәҗәдә саф булганлыгын горурланып яза. Галия Искәндәрнең матурлыгына соклана. Ә инде Искәндәр, килеп: «Сезнең чәчләрегез нинди йомшак, нәфис, җылы»,— дип, Галиягә карата мактау сүзләре әйткәч, аның күңелендә көйрәп яткан хисләр ялкынланып кабына. Чынлап та, яшьләр һәр икесе чибәр, матур. Бу яктан алар пар килгәннәр. Беренче тапкыр студентлар кичәсеннән Искәндәр белән бергәләп чыгып киткәндә, Галия үзен бик бәхетле итеп сизә.

Галия һәм Искәндәр образларының уй-фикерләре, хәрәкәтгамәлләре аша Г. Кутуй кеше психологиясенең никадәр катлаулы, каршылыклы булуын күрсәтә. Шул ук вакытта мәхәббәт, гаилә, балалар язмышы мәсьәләләрендә кешеләрнең (ир белән хатынның) никадәр җаваплы икәнлеген образлы итеп ачып бирә. Гаилә төзүнең кеше гомерендә олы һәм хәлиткеч адым булганлыгын күрсәтә.

Икенче хатта вакыйгалар үстерелә. Әдәби геройларның эшхәрәкәтен сурәтләү барышында аларның характеры, тормышка мөнәсәбәте тагын да ачыграк күренә.

Искәндәр белән Галия гаилә тормышы корып җибәрәләр. Мәхәббәт хисләре белән исереп, башта тату, күңелле яшиләр. Ләкин матур итеп яшәү озак дәвам итми, гаилә күген караңгылык сөреме каплый. Галиянең, рабфакны тәмамлап, университетның медицина факультетына укырга керергә теләве Искәндәргә ошамый. Беренче аңлаша алмау шуннан башланып китә.

Озак та үтми, Искәндәр Галия каршында икенче яктан ачыла башлый. Алар, бер-берсенең тышкы матурлыкларына сокланып, ашыгыбрак тормыш башлаган булып чыгалар. Искәндәрнең Галиягә карата игътибарлылыгы, гашыйк булуы вакытлыча гына булган. Алар арасындагы каршылык — ир белән хатын арасындагы гади бозылышу гына түгел, бәлки тормышка булган ике карашның бәрелешүе.

Өстәвенә гаиләдә бала туа. Каршылыклар тагын да тирәнәя. Икенче бала туганнан соң, Искәндәр гаиләсен ташлап чыгып ук китә. Ләкин Галия авырлыкларга бирешми. Укуын дәвам итә, балаларын карый. Шулай ук Галия ялгыз да түгел, аңа эшче Галиәкбәр абзыйлар гаиләсе, университет җитәкчелеге, студентлар коллективы тормышта үз урынын табарга булышалар.

Икенче хатта Галия гаиләнең таркалу сәбәбен болай аңлата: «Идея сайланышы булмау аркасында безнең семьябызның җимерелүенә дә төп сәбәп җәмгыятькә карата мөнәсәбәтне төрлечә аңлау булды. Мин үзем моны бик соң аңладым. Һәм шуны яхшы итеп аңлагач кына, семья фаҗигасе нәтиҗәсендә туган яраларым тиз һәм җиңел төзәлделәр».

Өченче хатта Галиянең ике бала белән Әдрәс авылына эшкә баруы — врач булып эшли башлавы турында сүз бара.

Яшь булса да, күп кичерешләрне, борчуларны башыннан уздырган Галияне биредә яңа каршылыклар көтә. Ике бала белән яшәү урыны булмау, аптекада кирәкле дарулар җитешмәү, амбулаториянең ташландык хәлдә булуы, өстәвенә Галиуллин шикелле җитәкчеләрнең медпункт эшенә игътибар итмәве Галияне кыен хәлгә куя. Ләкин ул авырлыклар алдында баш ими, китмәскә, «киртәләрне җимерергә була». Иң беренче амбулатория бинасын тәртипкә китерә, аптеканы рәтләү ягын кайгырта. Табигый таланты, сизгерлеге өстенә югары уку йортында алган белеме, эш сөюе һәм кешелек сыйфатлары Галияне халык алдында тиз таныта. Ул һәрвакыт халык арасында булырга тырыша, авыруларга игътибарлы һәм ярдәмчел. Кешеләр дә Галиянең хезмәтен бәяли, үз итә, аңа ышанып карый.

Әсәрдә авыл тормышы, авыл кешеләренең уй-фикерләре, эш-хәрәкәтләре уңышлы тасвирлана. Бу исә төп образны тулырак ачарга ярдәм итә. Галиянең тирән белеме, үз эшенә җаваплылык сизеп, намус белән каравы, халыкка турылыклы булуы конкрет вакыйгаларны сурәтләү һәм кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләр дәвамында ачыклана бара. Яшь күңелнең сыкрануы, вакытлар узу белән балаларның этиләре турында сораштырулары сюжетны катлауландыруга китерә. Болар, барысы бергә кушылып, беренче хатта күренеп кенә калган Вәли Сафиуллин образын алгы планга куя. Вәли белән очраклы рәвештә фамилияләре бер үк булу Галиягә бу ирне балаларына «хыялый эти» итеп уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Ул үзенең фантазиясе, күңел җылысы белән балаларын юатырга,

аларның этиләре барлыгына ышандырырга тырыша. Галия — гадел һәм саф күңелле хатын, ул Вәлигә өмет тотмый.

Дүртенче хатта Гадел Кутуй тормышта үз урынын табып, халыкка хезмәт итү эше белән ялкынланып яшәгән хатын-кызлар образларын сурәтли. Галия — табибә, ә Мәфтуха апа исә — колхоз рәисе. Бу ике кешенең дөньяга карашлары, уй-фикерләре уртак. Галиягә тормышта үзенең җәмгыять өчен кирәклеген тоеп яшәү көч бирә. Шулай да шәхси борчулар, гаилә тормышында булып узган күңелсезлекләр җанны сыкрата. Менә шундый көннәрнең берсендә, Галиягә таныш булган кеше — Вәли Сафиуллин килеп керә. Ул Әдрәс авылы янына урнашкан санаторийга ялга кайткан. Вәли белән Галия очрашалар. Вәли нык үзгәргән, кыюлана төшкән, хезмәте белән хөрмәт казанган орденлы укытучы ул хәзер. Вәли олы җанлы, кеше хисләренә сак һәм игътибарлы.

Әсәр ахырында «Автордан» дигән исем астында бирелгән кушымтада Галия белән Вәли Сафиуллиннарның бәхетле гаилә тормышы башлап җибәргәнлекләрен беләбез.

«Тапшырылмаган хатлар» повестенда язучы төрле иҗади алымнардан файдалана. Иң беренчесе — хатлар язу формасы. Г. Кутуй, прозада хатлар алымын кулланып, героиняның психологик кичерешләрен, күңел дөньясын тирәнрәк сурәтләүгә ирешә. Шул ук вакытта автор, публицистик чигенешләр ясап, дөнья хәлләре, төп геройны чолгап алган вакыйгалар турында да сәнгатьчә сөйләп бирә. Гаилә төзү, бала тәрбияләү, хатын-кызларның тормыштагы роле, кешенең гражданлык хисе, вөҗданы, намусы, яшәү мәгънәсе, тормышның кадере турында үзенә генә хас поэтик стиль белән иҗат итә.

Антитеза да сәнгатьлелеккә ирешүдә әсәрдә уңышлы кулланыла. Мәсәлән, Галиянең яшәү рәвеше белән аның әтисенең тормышы арасында зур аерма бар. «Минем атам үз телен дә кирәгенчә белмәгән. Ә мин — аның кызы — татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм. Минем атам... бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин — чулак Фәхри кызы — хәзер үзем доктор». Мондый алым, повестьның идеясен ачыклауга турыдан-туры өлеш кертү белән бергә, әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен, эстетик тәэсир итү көчен дә арттыра.

Кешенең эчке кичерешләрен сәнгатьчә тирән итеп сурәтләгән «Тапшырылмаган хатлар» повесте хәзер дә һәркемне дулкынландыра һәм яратып укыла.

40 — 50 нче ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Бу елларда татар әдәбияты шул чор белән бәйле рәвештә шактый катлаулы һәм авыр юл үтә. Аның яшәешенә сугыш чоры таләпләре һәм сынаулары, сугыштан соңгы рәсми пропаганда һәм илдә башланган үзгәрешләр эз сала.

Сугыш елларында әдип сүзе ил азатлыгы өчен көрәштә мөһим идеологик корал итеп каралды һәм әдәбият алдына фронтта да, тылда да алып барылган шушы көрәшне, анда күрсәтелгән халык батырлыгын калку итеп чагылдыру бурычы куелды. Татар әдипләре үзләренең гражданлык бурычын намус белән үтәделәр. Алай гына түгел, ил азатлыгы өчен көрәштә алар турыдан-туры кулларына каләм һәм корал тотып катнаштылар. Сугыш башлангач, 100 гә якын татар язучысы, ягъни Татарстан язучылар оешмасы тулы составында диярлек фронтларда булды. Аларның беришесе фронт газеталарында хезмәт итте, икенчеләре алгы сызыкта көрәште. Шул сәбәпле әлеге чордагы татар әдәбияты ил күләмендә солдат әдәбияты булып танылды. Шул ук вакытта ул елларда безнең әдәбият зур югалтулар да кичерде. М. Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Н. Баян, Х. Мөҗәй кебек инде сугышка кадәр киң танылган әдипләр белән берррәттән, бу чорда татар әдәбияты үзенең киләчәге булган һәм сәләтләре әле ачыла гына башлаган күп кенә яшь каләмнәрен дә югалтты. Шундый югалтуларга карамастан, татар әдәбияты әлеге дәһшәтле һәм фаҗигале заман турында рәсми идеологиягә сыеша алмыйча, күпмедер үз сүзен дә әйтә алды. Бу хәл бигрәк тә немец яки совет концлагерьларына яисә төрмәләренә эләккән әдипләргә хас иде. Шундыйлардан Х. Туфан, М. Җәлил һәм Ф. Кәрим үз язмышларында һәм иҗатларында татар халкының шул дәвердәге гомум халәтен, каршылыклы язмышын төрле яклап чагылдырдылар. Ачыграк әйтсәк, әлеге шәхесләр халкыбызның сугыш дәверендәге зур

югалтуларын да һәм тиңдәшсез батырлыгын да гәүдәләндергән затларга әверелделәр.

Сугыш чорының характерлы бер үзенчәлеге безнең халыкта тарихи хәтерне көчәйтеп җибәрүе белән бәйләнгән. Шул сәбәпле әдәбиятта да купмедер тарихка игътибар арту күзәтелә. Бу хәлнең иң күркәм үрнәге булып Г. Исхакыйның мөһаҗирлектә язган «Олуг Мөхәммәд» дигән тарихи драмасы тора. Конкрет тарихи вакыйгаларга нигезләнгән бу әсәрендә милләтпәрвәр әдип Россия һәм СССРда гасырлар дәвамында гел кире планда бәяләнеп килгән Казан ханлыгы һәм аның рус кенәзлекләре белән мөнәсәбәтләре турында дөреслекне ачып бирүгә ирешә.

Сугыштан соңгы чорда совет чынбарлыгын рәсми пропаганда рухында чагылдыру тенденциясе тагын да көчәя кебек. Татар әдәбиятында ул бигрәк тә 40 нчы еллар ахыры 50 нче еллар башы авылын сурәтләүдә ныграк сизелә. Традиция буенча авылны әдәбиятыбыз өчен милли яктан мөһим дип санап эш итсәләр дә, күп кенә авторлар аның ул чордагы яшәешен өстән-өстән һәм җиңеләйтебрәк чагылдырдылар.

Ә 50 нче еллар уртасыннан шәхес культын фаш итү нәтиҗәсендә илнең иҗтимагый-рухи яшәешендә башланган җанлану йогынтысында татар әдәбиятында да эзләнүләр активлаша, кичәге һәм бүгенге яшәеш хакында объективрак фикер йөртүгә омтылыш көчәя. Һәм бу яңарыш иң элек авыл темасын яктыртуда чагыла. Монда бигрәк тә авылның колхозлашу, сугыш һәм аннан соңгы еллардагы яшәешенә игътибар арта. Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», А. Расихның «Язгы авазлар» романнары, Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» повесте кебек элеге чорлар авылы тормышын дөресрәк яктыртырга алынган әсәрләр белән башланган әлеге яңарыш хәрәкәте тора-бара татар әдәбиятында «авыл прозасы» дигән мәгълүм күренешне тудыра. Бу күренешнең асылын халкыбыз өчен милли-тәкъдири әһәмиятле дөнья булган авылны чын булганынча, реаль каршылыклары, кыенлыклары һәм югалтулары белән сурәтләргә алыну тәшкил итә. Проза өлкәсендә башланган бу яңарыш алга таба әдәбиятыбызның башка тармакларында да күзәтелә.

Сораулар һәм бирем

1. 40—50 нче елларда татар әдәбияты үсешенә иҗтимагый-идеологик характердагы нинди факторлар тәэсир итә?

2. Ни өчен сугыш елларындагы әдәбиятыбызны «солдат әдәбияты» дип атадылар?

3. Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәрим кебек шагыйрьләр белән халкыбызның сугыш чорындагы язмышлары арасында нинди уртаклыклар бар?

4. 50 нче еллар уртасыннан формалаша башлаган «авыл прозасы»ның асылы һәм гомумәдәби хәрәкәттә тоткан урыны нидән гыйбарәт?

5. «Авыл прозасы»ның идея-эстетик үзенчәлекләрен конкрет әсәрләргә анализ ясап ачыгыз.

Муса Җәлил
(1906—1944)

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып,—

дип язган патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин бүләге лауреаты Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлы татар әдәбиятында иң югары биеклекләрнең берсе, халкыбыз горурлыгы булып тора.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, М. Җәлил фронтка җибәрүләрен сорап гариза бирә. Тиздән аны хәрби-сәяси курсларга укырга җибәрәләр. Минзәләдә урнашкан әлеге курсларны тәмамлагач, ул өлкән политрук дәрәҗәсендә Волхов фронтына җибәрелә. «Отвага» газетасының журналисты буларак, М. Җәлил фронтның алгы сызыгында еш була. 1942 елның июнендә ул хезмәт иткән 2 нче удар армия немец гаскәрләре чолганышында кала. Зур булмаган төркемнәргә бүленеп, канлы сугышлар белән үзебезнекеләр ягына чыкканда, Җәлил авыр яралана һәм әсирлеккә эләгә. Лагерьдан лагерьга куылып йөртелү, ачлы-туклы яшәү, кыйналу, рухи кимсетелү шартларында да шагыйрь рухын сындырмый саклап кала, тоткыннарда кешелек сыйфатларын, яшәүгә, җиңүгә, азатлыкка ышаныч тойгыларын югалтмаска булыша.

Немец командованиесе Совет Армиясенә каршы сугышу өчен әсирләрдән милләтләре буенча легионнар җыя башлый. Шундый беренче батальон татар-башкорт әсирләреннән дә төзелә. Ышанычлы иптәшләреннән яшерен оешма туплаган М. Җәлил, бер лагерьдан икенчесенә иркенләп йөрергә, әсирләр белән сөйләшергә мөмкинлек алу өчен, әлеге легионга языла. Патриотлар махсус «артистлар» труппасы оештыралар, кон-

цертлар белән Германия һәм Польшадагы лагерьларда булалар. Яшерен рәвештә листовкалар тараталар, җыр, шигырь белән әсирләрнең патриотик хисләрен уяталар, күңелләрендә иреккә омтылыш чаткылары кабызалар, яшерен көрәшкә өндиләр, фашизмга каршы нәфрәт тойгыларын көчәйтәләр. Җәлилчеләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә фронтка җибәрелгән бер батальон, немец офицерларын юк итеп, Белоруссия партизаннарына кушыла. Бу вакыйга яшерен оешма әгъзаларын чиксез шатландырса, фашистларны, саклык җаннарны активлаштыра. Польша партизаннары белән берлектә хәзерләнгән кораллы восстаниегә берничә көн калгач, гестапо җәлилчеләрнең эзенә төшә, һәм аларның күбесен, кулга алып, төрмәгә ябалар. 1944 елның февралендә Дрезден шәһәре суды яшерен оешманың иң актив әгъзаларын үлемгә хөкем итә. Ул шул елның 25 августында тормышка ашырыла.

Биремнәр

1. Алдагы сыйныфларда алган белемегезгә таянып, М. Җәлилнең тормыш юлын сөйләгез.

2. Бөек Ватан сугышы елларында М. Җәлилнең тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы турында әңгәмә үткәрегез.

ХУШ, АКЫЛЛЫМ

(*Әминәгә истәлек*)

Хуш, акыллым, соңгы сәламемне
Юллыйм сиңа җилләр аркылы,
Барсын сиңа, кайнар сәлам булып,
Йөрәгемнең сүнмәс ялкыны.

Киткән чакта Казан Кремле
Магнит төсле тартты уемны.
Син балконнан мине, яулык болгап,
Озатасың төсле тоелды.

Син торасың төсле миңа карап,
Аерылганга бераз көенеп;
Хыялымда сине соңгы кабат,
Суырып үптем, яшькә төелеп.

Киттем, дускай, кайнар өмит белән,
Дошман явын җиңеп кайтырга.

Батырларча каты сугышырга,
Тап төшерми изге антыма.

Бик күңелле булыр җиңеп кайтып,
Бил кысышып җылы күрешү;
Өмит, җаным, болай шәп шәбен дә,
Ләкин... сугыш уен түгел шул!..

Хуш, акыллым, әгәр кайталмасам,
Яраланып юлда егылсам,
Йөрәгемдә саклап ялкыныңны,
Акрын-акрын тәнем суынса,
Хуш, акыллым!
Соңгы минутта да
Мин уйлармын синең турында;
Уйлар минем туңган күкрәгемне
Җылытырлар синең куеныңда.

Соңгы кабат назлап үбүеңне
Мин тоярмын салкын иренемдә,
Син татлы су миңа эчергән күк
Авыр сулап яткан җиремдә.

Йолдызларга карап, мин сагнырмын
Күзләреңнең җылы карашын.
Җилләр сыйпар, синең кулың булып,
Күкрәгемнең тирән ярасын.

Ахыр чиктә синең саф сөюең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын.

Киттем, дускай, якты бәхетебезне
Бирмәс өчен ерткыч кулына.
Егылганда алга егылырмын
Киртә булып дошман юлына.

Татлы булыр йокы...
Тормышымны
Батырларча бирсәм ил өчен,
Тормыш дустым, синең йөрәгеңдә
Дәвам итсә йөрәк тибешем.

Хуш, акыллым! Соңгы сәламемне
Юллыйм сиңа җилләр аркылы.
Барсын сиңа, кайнар сәлам булып,
Йөрәгемнең сүнмәс ялкыны.

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу әсәрдә лирик герой нинди хисләр кичерә? Сәбәбен аңлатыгыз.

2. Лирик герой нәрсә дип юана?

3. Кабатлауларны табыгыз, алар нәрсәгә хезмәт итә?

4. Шигырьнең төп идеясен ачыклагыз.

КОШЧЫК

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз.
Көне буе шунда казынабыз,
Әйтерсең лә тирес корты без.

Кояш чыга койма аръягында,
Күрше кырлар нурга коена.
Тик нигәдер аның нуры безгә
Тими үткән төсле тоела.

Ерак түгел урман, кыр...
Кемнеңдер
Ишетелә чалгы кайравы.
Кичә шуннан бер кош очып килеп,
Шул коймага кунып сайрады.

Чакырсам да, кошчык,
Син бу йортка
Үзең теләп очып кермәссең.
Керә күрмә, безнең кан-яшь йотып
Интеккәнне үзең күргәнсең.

Сайра безгә шушы нәләт төшкән
Койма аша гына булса да,
Шунсы да бит безгә зур юаныч,
Җырларыңнан күңел тулса да.

Син очарсың, бәлки, минем илгә,
Син иректе, җитез канатлы.
Тик әйт, кошчык,
Синең минем янга
Бу килүең соңгы кабатмы?

Соңгы кабат булса, тыңла,
кошчык,
Соң теләген мәгърур җанымның;
Оч син илгә нәфрәт һәм мәхәббәт
Җыры булып тоткын шагыйрьнең.

Ук шикелле үткен канатыңнан,
Таң шикелле якты җырыңнан
Танып сине халкым:
«Бу, дип, аның
Соңгы җыры көрәш кырыннан.

Чәнечкеле чыбык бәйләсә дә,
Дип, шагыйрьнең аяк-кулларын,
Бер көч тә юк җирдә богауларлык
Аның кайнар йөрәк моңнарын».

Оч син, кошчык,
көчле җырым булып,
Шушы сиңа соңгы теләгем.
Тәнем калсын монда,
(Нәрсә ул тән?)
Барсын илгә минем йөрәгем.

Сораулар һәм бирем

1. Лирик герой халәте нәрсәләр белән чагыштырыла? Тирес корты һәм кошчык образлары нәрсәгә хезмәт итә?

2. Аның соңгы теләге нинди? Тән һәм йөрәк каршылыгына нинди мәгънә салынган?

БҮРЕЛӘР

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып, якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.

Күпме кан, күпме яшь ат ите!
Ялтырый бүренең күзләре.
Бит моны төн буе атышып,
Тураган кешеләр үзләре.

Бүреләр башлыгы — карт бүре,
Исереп кешеләр канына
Йөргәндә, сискәнеп туктады
Бер авыр яралы янына.

Яралы ыңгыраша, саташа,
Каенга терәгән башкаен.
Кызганып егетне, җил белән
Тибрәнеп сыкрана ак каен.

Кызганып егетне, елыйлар
Миләүшә һәм лалә чәчәге.
Тәгәри үләнгә чык түгел,
Гөлләрнең гөнаһсыз яшьләре.

Карт бүре егетне иснәде,
Аптырап күзенә карады.
Һәм кинәт нидәндер сискәнеп,
Бер читкә тайпылды яралы.

Яралының зәгыйфь сулышы
Бәрелде бүренең борнына.
Юк, бүре тимәде,
сак кына
Борылып юнәлде юлына.

Таң белән килделәр кешеләр,
Күрделәр яралы егетне.
Яртылаш ул тайган исеннән,
Шулай да яшәве өметле.

Кешеләр егетнең тәненә
Кыздырып шомполлар бастылар.
Туйганчы җәфалап,
соңыннан
Ялгыз ак каенга астылар.

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып, якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.
Бүреләр,
        аһ... ләкин бүреләр
Бу кадәр үк ерткыч түгелләр.

Сорау һәм биремнәр

1. Шигырьдәге кабатлауларны табыгыз, аларга салынган фикерне ачыклагыз.

2. Әсәрдә сурәтләнгән ике күренешкә бәя бирегез.

3. Шагыйрь ни өчен сынландыру алымы кулланган?

«Тупчы анты» җыентыгы

М. Җәлилнең Бөек Ватан сугышы чоры иҗаты икегә бүлеп өйрәнелә. Берсе — сугыш башланганнан алып 1942 елның июненә кадәр, ягъни дошманга әсир төшкәнче язган шигырьләре, икенчесе — фашизм тоткынлыгында иҗат ителгән атаклы «Моабит дәфтәрләре». Әдипнең фронт лирикасы тупланган шигырьләре 1943 елны Казанда «Тупчы анты» исеме белән басылып чыга. Әлеге җыентыкка кергән шигырьләр публицистик, көрәшкә өндәү рухында язылулары, халык нәфрәтен чагылдырулары белән үзенчәлекле. Шагыйрь бөтен көчне җиңү өчен тупларга өнди. «Әйдә, җырым» шигырендә дошманга каршы изге сугышка күтәрелгән шагыйрь образы алга килеп баса. Әдип җырның рухи көченә тирән ышаныч белән «Фашистларга каршы пуля һәм җыр бил каешымда бергә саклана»,— ди. Шигырь фашизмга тирән нәфрәтне, лирик геройның хаклык өчен үлемгә дә әзер икәнен, ялкынлы дәртен күрсәтү белән тәмамлана. «Хуш, акыллым» шигырендә шагыйрь үзенең интим хисләрен чагылдыра. Шул ук вакытта сөйгәненә булган мәхәббәт хисе туган илен ярату тойгысына үсеп әверелә, кеше өчен иң газиз булган бу ике төшенчәнең бергәлегенә ирешелә.

М. Җәлилнең бу чорда язган «Тупчы анты», «Чулпанга», «Күпер», «Каска» һ. б. шигырьләрен үзәк тема, үзәк мотив берләштерә: лирик геройның Ватанын сакларга анты, фашизмга каршы көрәшкә чакыру, җиңүгә тирән ышаныч, сугышка ачу-нәфрәт хисе.

«Моабит дәфтәрләре» җыентыгы

М. Җәлилнең фашист тоткынлыгындагы иҗат иткән шигырьләре әдәбият тарихына «Моабит дәфтәрләре» исеме белән кереп калды. Бу исемне Муса Җәлил үзе куймаган. Байтак шигырьләренең Моабит төрмәсендә иҗат ителүеннән, шунда ук дәфтәрләргә теркәлүләреннән һәм әлеге төрмәдән туган илгә юл алуларыннан чыгып, җыентык шул исем белән атап йөртелә.

Җыентыкка тупланган шигырьләр шагыйрьнең олы йөрәген, рухи ныклыгын, туган иленә, халкына бирелгәнлеген, шигырьләрен чын мәгънәсендә үлемсез корал итеп күтәргәнен раслаучы маяклар булып торалар. Яшәү белән үлем арасында булу, кайгы-хәсрәт, кан һәм яшь белән тулы вакыйга-күренешләр шагыйрьнең соң чиккәчә киерелгән кичерешләре аша сәнгать әсәре булып әверелә. «Моабит дәфтәрләре»ндә әдипнең уй-хисләре, тормыш турындагы фәлсәфәсе тематик киңлектә, жанр төрлелегендә ачылалар. Арада хис-тойгылар белән тулы лирик шигырьләр дә, сюжетлы поэмалар да, балладалар да, тормышчан күренешләр сурәтләнгән юмористик һәм сатирик әсәрләр дә бар.

Шигырьләрдән калкып чыккан шагыйрь образы гаҗәеп зур гомумиләштерү көченә ия. «Кичер, илем», «Ирек» кебек шигырьләрдә туган илгә мәхәббәт, ирекнең кадере коллыкның авыр газаплары белән чагыштырыла. Шагыйрьнең рухи ныклыгы фашизмга нәфрәт, үч тойгысына үсеп әверелә.

«Кошчык» шигырендә дошман «тирес корты»на әверелдерергә теләп кол иткән, тимерчыбыкка ураган шагыйрь образы алга килеп баса. Тоткынлыктагы лирик геройга кояшның җылы нурлары да сизелми. Чалгы тавышы яңгыраган урманнан кошчыкның очып килүе аны сискәндереп җибәрә. Герой табигатьтәге башка бер генә җан иясенең дә ул күргән михнәтләрне күрүен теләми. Аның сагыш белән, сагыну белән тулы йөрәгенә ирек кошының җырлары да «зур юаныч». Әсәрдә кошчык лирик геройның якын дусты, кайгысын уртаклашучы, аның соңгы васыятен туган халкына тапшыручы булып кала.

Шигырьдә автор кулланган шигъри алымнар — ирек белән коллыкны каршы кую, кошчыкка ирек символы буларак эндәшү, дүрт һәм биш тезмәле строфаларның эзлекле бирелеше — зур идеяне ачарга, үзенчәлекле яңгырашка, тәэсир итү көчен арттырырга булыша.

Фашистларның ерткычлыгын сурәтләгән вакыйгаларда Җәлилнең тирән нәфрәте, үч алырга чакыруы чагыла («Вәхшәт», «Бүреләр» һ. б.). Шагыйрь газаплы төрмә шартларында да яшәү белән үлем, тормышның фәлсәфи мәгънәсе турында уйлана. «Сандугач һәм Чишмә», «Җырларым», «Үлемгә» кебек әсәрләрендә туган ил, ирек, бәхет, матурлык өчен үлгәннәр алдында баш ия, аларга дан җырлый.

«Дуска» шигыре Җәлилнең дусты, көрәштәше, каләмдәше А. Алишка багышланган. Шуңа да әсәр Ватан азатлыгы өчен гомерләрен биргән ике зур шәхеснең киләчәк буыннарга васыяте булып яңгырый. Әйе, һәркемнең гомере бер генә, һәм ул аны үзенчә үтә. Ләкин ничек? Дөрес, матур яшәүне ничек билгеләргә? Шагыйрь әлеге сорауларга сорау белән җавап бирә:

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне,
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Халкы белән бер теләктә булу аңа көч бирә. Шуңа да иленә хыянәт итеп алган «исәнлекне» ул кабул итә алмый. Шагыйрь ил гомеренең, аның азатлыгының «батырлык һәм илгә тугрылык»тан бәйле булуын тирән аңлый:

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер —
Ил гомренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бара аның яктысы.

Әнә шул рәвешле, әдип батырлык фәлсәфәсен ил азатлыгына бәйләп аңлата. М. Җәлилнең «Сөеклемә», «Сөю», «Күлмәк», «Төрмәдә төш» шигырьләрендә үзенең иң кадерле кешеләре — хатыны Әминәгә һәм кызы Чулпанга булган ярату хисенең изгелеге, көче, аның шагыйрьгә илһам һәм ныклык бирүе сәнгать чаралары белән сурәтләнә. Сөйгәненә мәхәббәт әдип йөрәгендә Ватанына, халкына мәхәббәт белән бергә кушылып яши.

М. Җәлилнең шигырьләре утызга якын телгә тәрҗемә ителде. Ул татар әдәбиятының зурлыгын дөньякүләм танытты. Шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» циклы тынычлык, азатлык сөюче меңнәрчә кешеләр тарафыннан шатланып һәм сокланып каршы алынды. Әдипнең шигырьләре, сәнгать әсәре буларак, зур тәэсир итү, тәрбияви көчкә ия. Алар, Җәлил һәм

җәлилчеләрнең көрәш юлын, каһарманлыкларын ачу белән бергә, туган илне ярату, көрәш һәм җиңү символы булып та торалар. Шагыйрьнең йөрәк каны белән язылган әсәрләре батырлыкка һәм матурлыкка, яшәүгә һәм мәхәббәткә, иреккә һәм яктылыкка мәдхия булып яңгырыйлар. М. Җәлил шигърияте татар поэзиясен яңа баскычка күтәрде, халкыбызның рухи байлыгына әверелде.

Сораулар һәм биремнәр

1. М. Җәлилнең Бөек Ватан сугышы чоры әсәрләрен ни өчен икегә бүлеп карыйбыз?

2. М. Җәлилнең тоткынлыкта иҗат ителгән шигырьләре ни өчен «Моабит дәфтәрләре» исеме белән атап йөртелә?

3. «Моабит дәфтәрләре»нең тематикасын һәм жанр төрлелеген күрсәтегез.

4. М. Җәлил үзенең шигырьләрендә яшәү мәгънәсен нәрсәдә күрә? Шуны билгеләгән юлларын укып күрсәтегез.

5. «Моабит дәфтәрләре» циклының әһәмияте нәрсәдә?

Фатих Кәрим
(1909—1945)

Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Үз авылларында башлангыч белем алганнан соң, 1922 елда абыйсы Габдулла Кәримов (әдәбиятта ул Ярлы Кәрим буларак билгеле), Бәләбәй шәһәренә алып килеп, андагы педагогия техникумының хәзерлек курсларына урнаштыра. Бу курсларны 1924 елда тәмамлагач, әлеге абыйсы аны Казанга алып китә. Биредә 1925—1929 елларда Фатих техникумда укый. Шушы уку елларында ул әдәби иҗат белән кызыксынып китә. Һәм 1926 елдан матбугат битләрендә аның яшьләр тормышына кагылышлы мәкаләләре, балалар өчен язылган шигырьләре һәм хикәяләре күренә башлый.

1928 елда балалар өчен «Яшь ленинчы» исемле газета чыгарыла башлагач, студент Ф. Кәримне әлеге газетаның җаваплы сәркатибе итеп билгелиләр. 1931—1933 елларда хәрби хезмәттә булганда Идел буе хәрби округының Казанда татар телендә чыга торган «Кызылармияче» газетасы редакциясендә эшли. Армиядән кайткач, дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторын җитәкли һәм анда 1937 елга кадәр, ягъни репрессиягә эләккәнче эшли.

Нәшриятта эшләү еллары Фатих Кәримнең әдип буларак формалашу һәм чыныгу чорына әверелә. Ул яңа чынбарлыкның төрле күренешләрен һәм мәсьәләләрен лирик-публицистик рухтарак яктырткан күп санлы шигырьләрен, «Яшен яктысы», «Тавышлы таң», «Аучылар», «Аникин» кебек поэмаларын тудыра. Аларда шагыйрь үзе яңа системаның актив көрәшчесе сыйфатында алга баса. 30 нчы еллар ахырында, репрессиягә эләгеп, «халык дошманы» язмышын кичерүе дә Ф. Кәримнең

социализмга ышанычын һәм бирелгәнлеген йомшарта алмый. Ирекка чыгу белән ул 1941 елның декабрь аенда үзенең Ватанын фашист илбасарларыннан саклау өчен фронтка китеп бара. Сугыш елларында үзенең патриотлыгын ул солдат буларак та, шагыйрь буларак да ачык раслый. Чөнки Ф. Кәрим гомерен дә һәм иҗатын да тулысынча ил азатлыгы өчен көрәшкә багышлый. Аның гомере дә Бөек Ватан сугышында өзелә.

Ф. Кәримнең сугыш елларындагы иҗаты да тулысынча патриотизм рухы белән сугарылган, ил азатлыгы өчен көрәшкә багышланган иде. Шушы рух һәм көрәшне тулырак чагылдыру өчен, әдип әдәбиятның төрле формаларына мөрәҗәгать итә. Поэзиядә күп санлы лирик шигырьләрдән тыш, ул «Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Тирән күл», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы» поэмаларын, прозада «Разведчик язмалары», «Язгы төндә» повестьларын, драматургиядә «Шакир Шигаев» драмасын һ. б. иҗат итә. Заман таләпләренә ияреп язылсалар да, Ф. Кәрим бу әсәрләрендә сугыш чорын, шул вакытта кешеләрнең уй-кичерешләрен шактый дәрәҗәдә төрле яклап чагылдыруга ирешә. Гомумән, интернациональлекне миллилектән өстен куйган социалистик идеология хакимлек иткән заманда яшәгән Ф. Кәрим, үз иҗатында гомум совет идеалларын һәм идеяләрен яктырту белән бергә, татар әдибе дә булып кала алды. Дөрестән дә, аның әсәрләрендә татар рухы, татар кешесенең уй-фикерләре дә чагылыш тапты. Ф. Кәримнең нахакка гаепләнеп төрмә сынавын үткән үз язмышы да — ахыр чиктә авырлыклар алдында баш имәс, ил азатлыгы өчен көрәштә куркуны белмәс татар рухы һәм характерының ачык чагылышы ул.

Бирем

«Кеше язмышы — ил язмышы» гыйбарәсен Ф. Кәрим тормышы мисалында аңлатыгыз.

СИБӘЛИ ДӘ СИБӘЛИ

Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми.
Уема да кертмәдем мин
Аның бу төн үләсен,
Разведкадан кайткан чакта
Тиде немец пулясы.
Өс-башы юеш. Көрәкләргә
Үзле балчык сылаша;

Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.
Кайгыдан каралып торган
 Япь-яшь нарат төбенә
Япь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.
Япь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми;
Көзге төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьдә нинди вакыйга турында сүз бара? Аны ике өлешкә бүләргә туры килсә, ничек бүләр идегез?

2. Шигырьдә *төн, җил, яңгыр* ничек сурәтләнә? Табигать күренеше һәм лирик геройның кәефе арасында бәйләнеш бармы?

3. Кайсы юллар сезгә аеруча тәэсир итә, шуларны укып күрсәтегез.

4. Шигырьне яттан өйрәнегез.

РАЗВЕДЧИК ЯЗМАЛАРЫ

(Повестьтан өзек)

Без — икәү. Минем иптәшем — Акморат исемле төрекмән егете. Акморат — урта буйлы, җиңелчә юка гәүдәле егет. Какча кара-кучкыл битендә сирәк кенә шадралары бар. Ефәкләнеп торган йомшак кара чәчләренең бөртекләре пилоткасы читенә сарылганнар. Акморат, үзе егерме алты яшьтә генә булса да, бик шәп итеп мыек җибәргән. Кабарынкы кара мыек. Болай да ак тешләре кара мыек астыннан аеруча ак булып күзгә бәреләләр. Акморат — аз сүзле кеше. Аның биргән сорауларга да башын селкеп, я бер як чигәсен җыерчыкландырып, я булмаса сыңар күзен кысып кына җавап бирүе кайчакларны үзенә булган күңел җылылыгын суындырырлык дәрәҗәдә эчне пошыра. Бу хәл бигрәк тә икәү генә булганда, кичергән вакыйгалы хәлләрне уртаклашасы килгән чакларда була. Ул бервакытта да сиңа текәлеп карап тормый. Бернинди чырай ачыклыгы күрсәтмичә, яшен тизлеге белән күз генә төшереп ала. Аннан, өске иренен ак тешләре арасына кысып, мыегын селкетә-селкетә, кара күзләрен еракка юнәлтә. Күзләре аның, төнге күкне айкаган прожектор кебек, туктаусыз хәрәкәтләнеп торалар. Нәрсә турындадыр туктаусыз уйлый кебек ул.

Ләкин сугыш кырында, үлем үкчәңә басып йөргәндә, Акморат — иптәш инде. Кул-аяклары өзелсә дә, тешләре белән сине бәладән коткарырга әзер торган иптәш. Үз канын түкми торып, иптәшенең канын агыздырырга ирек бирми торган егет.

Тамаклар чатнап сусаган чакларда Акморат бер кружка су тапса, башта аңа үз иренен тигезмәс. Кара мыегының бер очын гына селкетеп:

— Мә, эчең, эчең, әкә,— дияр.

Ләкин ул биргән суны эчкәндә, аның синнән дә кайнаррак канлы икәнен, сиңа караганда ике тапкыр артыграк сусаганын онытмау синең вөҗдан эшең инде.

Менә бүген безнең Акморат белән көн буе бер тамчы да су эчкәнебез юк. Эчәсе килә, тик кайдан алып эчәргә? Көн дә караңгыланып килә бит. Ә без, иртәнге яктылык күтәрелгәннән бирле, беркая да чыкмыйча, бомба ярылып чокылган бер чокырда, чытырлар арасында ятабыз. Тирә-як тигез ачык ялан. Каршыда, без барырга тиеш якта, каен катыш имән урманы. Урман итәгендә, без яткан чокырдан бер ярты километр биредә, кечкенә авыл. Без көн буе шул авыл тирәсендәге хәрәкәтне күзәтеп яттык. Икебезгә бер бинокль. Бүгенге күзәтүдә аның артык кирәге булмады. Авыл картада күрсәтелгән. Без барырга тиеш авыл. Моңа нык ышандык. Компас безгә, без компаска хыянәт итмәгәнбез, туры барганбыз.

Әйе, көн буе авылны һәм авыл артындагы урманны күзәтеп яттык. Авыл артында урман. Өч-дүрт метрлар чамасы урман эчендә зур гына юл булса кирәк. Көн озынында бу юлдан йөк автомобильләре төрле күләмдәге ящиклар төяп урман эченә үттеләр. Буш машиналар кире кайттылар. Безгә әнә шул ящикларның кайда бушатылуларын белергә һәм ул урынны оста итеп картага төшерергә кирәк. Безнең инде көн буе бомба чокырында, чытырлар арасында ятып төшергән картабыз да бар. Тик ул картада ак нокталар күп әле. Төн караңгысы җир өстен каплагач, без дә бу төндә үз картабыздагы ак нокталарны каралтырга тиешбез.

Безнең игътибарны бигрәк тә урман эчендәге юл тартты. Авылны да күзәттек. Тик анда разведчикларны кызыксындырырлык бер хәрәкәт тә күзгә чалынмады. Авыл боек. Ара-тирә күренгәләгән кешеләрнең хәрәкәтләрендә ниндидер сөремле сүлпәнлек бар. Авыл тавышсыз. Без көн буе әтәч кычкырганны, сыер мөгрәгәнне, эт өргәнне ишетмәдек. Бертөрле дә балалар тавышы чыкмауга мин аеруча игътибар иттем.

Күз бәйләнеп килә инде. Урман артына баеган кояшның куе озын нурлары, күккә күтәрелгән саен кыскара барып, бөтенләй сүнделәр. Кояш баеган урында офыкның башка җирләреннән аерылып торган сүрән яктылык кына калды.

— Я, Акморат, кузгалабызмы?— дидем мин һәм, тирән сулап, Акморатка карадым. Терсәгенә таянып кырын яткан Акморат, чытырлар аша еракка текәлгән күзләрен йомып, өске иренен ак тешләре арасына кысып, бераз тын торды, аннан:

— Көтә төшсәк, яхшы булмасмы?— диде.

Мин кабатлап бер сүз дә әйтмәдем. Янымда яткан автоматымны алдым да шинель итәгем белән аның кожухын, дискын сөртергә тотындым. Анда тузан бармы-юкмылыгын күреп булмый иде. Тик мин ни эшләргә белмәүдән генә бу эшкә керештем. Акморат та таянган җиреннән торып утырды. Автоматын кулына алып әйләндергәләде. Ни өчендер Ф-1 гранатасын бер кесәсеннән алып икенчесенә салып куйды. Аннан хәнҗәрен кынысыннан тартып чыгарды, чәч пәкесе үткерләгән кеше кебек, бармак битләре белән хәнҗәренең үткерлеген тикшерергә кереште. Бераздан Акморат, утырган җиреннән очып китәргә әзерләнгән кебек бөтен гәүдәсе белән селкенә-селкенә, ике кулындагы ике хәнҗәрне күз алдында яшен тизлеге белән бөтерелдерде-бөтерелдерде дә күз иярмәс тизлек белән ике хәнҗәрне ике ягына кадап та куйды. Үзе, бер кул белән шалт итеп, минем җилкәмә сукты:

— Һа, әкә, башларымыз гына исән булсын, туып-үскән җирләргә кайтырмыз, биермез, кушырдай кызлар кочармыз, аларның ак кулларыннан алып, татлы шәраблар эчәрмез. Сез шуңар ризамы?— дип, балаларча, куана-куана кулымны тотты.

Акморат минем кулымны җибәрмәде әле:

— Сезнең татар кызлары кушырайлармы, әй, безнең бигрәк тә колхозлардагы төрекмән кызлары...

Ул сүзен бетермәде, артына борылып, чытырларны сак кына күтәрде, тирә-якка күз төшерде:

— Вакыт, юлымызда булыйк. Бу кара төндә юлымыз ак булсын. Моратларымызга ирешик,— диде ул.

Җиргә кадалган хәнҗәрләребезне алып кыныларына тыктык. Автоматларыбызны алдык. Үрмәләп чокырдан чыктык. Тынып тирә-якны күзәттек. Шикле бернәрсә дә күзгә чалынмады. Мин алдан, Акморат минем арттан, ярты чүгәләгән килеш, сак һәм салмак озын адымнар белән авылга таба атладык.

Бу авылда көндезге күзәтүләребез вакытында безнең билгеләнгән бер өебез бар. Авылның безгә якын читендәге калай түбәле кызыл кирпеч өй. Өйнең ихатасы, ишегалдында каралтылар юк. Ташландык өйгә охшый. Ләкин көн озынына бер хатын ул өйгә кереп-чыгып йөрде. Кичкә табарак ишегалдына

чыгып утын кисте. Бераздан морҗасыннан сыек кына зәңгәр төтен дә күтәрелде. Шул хатыннан башка ул өйгә кереп-чыгып йөрүче булмады.

Бер атлап, бер туктап, тирә-якка карана-карана, без шушы өй янына барып җиттек тә арт як стенасына ышыкландык. Мин автоматымны җилкәмә кидем дә кулыма хәнҗәр алдым. Шәүлә кебек тавыш-тынсыз гына беренче тәрәзәгә бардым. Бөтен өлгеләре такта-мазар белән капланган, бер әйбер дә күренми. Кул белән капшап карасам, өстәге бер өлгенең пыяласы исән икән. Ләкин үрелеп карарга буй җитми. Икенче тәрәзәгә барсам, анысы бөтенләй кирпеч белән томалап, сыланып ук куелган.

Сугыш вакытында бомба, снаряд шартлаудан пыяласы уалып коелган бу тәрәзәләр Гитлер китергән караңгылыкның беренче символы булып торалар. Элек үтәдән-үтә кояш нурлары йөргән зур тәрәзәле якты өйләр томаланганнар. Тәрәзәләре кирпеч, такта белән капланган. Өйләргә пыяла ватыкларыннан оештырган берничә өлгедән генә саран яктылык төшә. Бу өйләрнең эчләре подвалда ясалган төрмә камераларын хәтерләтәләр.

Акморат янына кире барып, бер сүз дә эндәшми генә аның җиңеннән тоттым. Ул ияреп минем арттан килде. Беренче тәрәзә янында ымлап кына аңа дүрт аякланып торырга куштым һәм, аның калак сөякләренә басып, югарыгы өлгегә капландым.

Өй эче караңгы. Мичтә талгын гына ут яна. Мич каршына бер хатын утырган. Ул мич алдындагы урта кул чүлмәктән кашык белән бәрәңге ала, әрчеп икенче савытка сала. Ара-тирә капкалап та куя.

Төштем.

— Бер хатын утыра, башка кеше күренми. Шул көндезге хатын булса кирәк.

— Сез кереңез. Мин биредә саклыйм,— диде Акморат. Аяк очларыма басып кына ишеккә бардым. Эткәләп карадым — бикле. Кул аркам белән генә шакыдым. Бераздан өй ишеге ачылган тавыш ишетелде. Кыштырдаган аяклар чолан ишегенә якынайдылар. Ярты пышылдаган тавыш белән русча:

— Кем бар, ни кирәк?— диде чыгучы.

Шик юк, карчыклар тавышы. Мин дә яшертен тавыш белән генә эндәштем:

— Мөмкин булса, ачыгыз әле.

Карчык ишекне ачты:

— Кем син, нәрсә кирәк сиңа?

Мондый шартларда йөрәгендә яра булган кешене йөрәк тавышы белән җиңел буйсындырып була. Мин аеруча серле, яшертен тавыш белән авызымны карчыкның колагы янына ук китереп пышылдадым:

— Әби, нәрсә кирәген кергәч сөйләшербез. Мине ишек төбендә тотма; мөмкин булса, өеңә керт. Мин — юл кешесе, кеше күзенә артык чалынасым килми,— дидем. Үзем, ул-бу булудан шикләнгәнемне карчыкка мөмкин кадәр ныграк сиздерергә тырышып, тәвәккәллеккә бардым: — Әби, мине үз улың итеп каршы ал, хәзер кемлегемне аңлагансыңдыр инде,— дип өстәдем.

— Кер,— диде карчык. Ишек артына чигенеп юл бирде. Мин чоланга кердем. Әби, карчыкларга хас саклык белән генә, ишекне ябып бикләде... Һәм чолан караңгылыгында: — Улым, син Володяның берәр иптәшеме әллә?— дип сорады.

Володя әбинең улы булса кирәк. Ләкин кем ул Володя? Иптәшемме минем яки дошманыммы?.. Ярый, мин хәзергә аның иптәше булыйм.

— Шулайрак, әби, якын дусты дисәң дә ярый. Өеңдә үзеңнән башка тагын кемнәр бар?

Карчык өй ишеген ачты:

— Кер, бәбкәм, кер, тыныч бул. Үзем генә. Өем караңгы, ул-бу кыштырдаса шикләнмә, бер тынгысыз мәчем бар, шул булыр,— диде карчык. Үзе мине, кулы белән капшаштыргалап, өйгә кертте.

Ишектән кергәч, сул якта зур мич. Мин уң яккарак берике адым атладым да туктадым. Карчык, җиңел генә адымнар белән мич алдына барып, чыра кабызды. Янган чырасын күзләре өстендә тотып каршыма килде. Гаҗәпсенеп, иреннәрен калтыратып, бертын миңа карап торды.

— Йа Аллам, кызылармеец бу!— диде, читкә карап. — Син чын кызылармеецмы? Каян килеп чыктың?— диде карчык. Үзе, минем җавабымны көтмичә, шунда ук борылып югары почмака барды: урындыкка басып, иконалар каршында эленеп торган лампаданы кабызды. Янган чырасын тагын күзләре өстендә тотып, каршыма килеп басты.

Кечкенә буйлы карчык. Тормыш аның арка сөякләрен яхшы ук бөкрәйткән. Өстендә тапланып беткән телогрейка. Яланбаш, ап-ак чәчен, җыйнак итеп тарап, ике толымга үргән һәм, шул нечкә толымнары белән башын әйләндереп, очларын маңгай өстенә китереп бәйләгән. Маңгаенда нечкә җыерчыклар. Ләкин

кашларына әле чал аз кергән. Юка, калку борыны; алгы тешләре исән булсалар кирәк, бөрешкән иреннәре авызын җыйнак саклыйлар; сул күзенең кабаклары шешенгән, күз төбе кара янган, шуннан башланган яра эзе, ике кашы арасыннан, маңгаеннан үтеп, юка ак чәчләре арасына кереп сузылган. Яра күптәнге булмаска тиеш, чыра яктысында да аның кызыллыгы, кубып бетмәгән кутыр калдыклары күренеп торалар.

Карчык бертын текәлеп карап торды да, янган чырасын бер түбән төшереп, бер югары күтәреп, минем өс-башымны җентекләп чыкты. Аннан тиресе сөякләренә ябышкан как бармаклары белән чыраның күмерен төшерде. Салкын гына тавыш белән:

— Урманнан киләсеңме, тегермәннәнме?— диде.

Бу сорау мине аяктан екты. Безнең телләр аерылды булса кирәк.

— Володяны каян беләсең соң син?— дип тә өстәде карчык.

Сизәм: карчыкны шиккә төшердем. Хәзер тойгыга таянам. Немецлар вакытлыча хуҗалык иткән җирдә, карчыкның үзен тотышына караганда, ул безнең Володяның әнкәсе булырга тиеш. Мин Володяны белмим, Володя мине белмидер. Без аның белән шушы караңгы өйдә очрашып аңлашсак, бәлки кочаклашып үбешер дә идек. Безнең дуслыкны күрү шатлыгыннан күзләре яшьләнгән карчык, икебезнең дә анасы булып, башларыбызны сыйпар иде.

— Әби, мин Володяны белүен белмим...— дип, елмаюлы күзләрем белән карчыкка текәлдем. Бу сүзләрем карчыкка ошады булса кирәк. Ул, кул аркасы белән күзләрен сөртеп:

— Белгәнгә ошамыйсың шул,— диде. Йөзендә серле ягымлылык яңадан балкыды:— Көн бик җилле булды, салкын алгандыр, мич алдына утырып җылын.

Карчык кулындагы чырасын мичкә илтеп ташлады.

Бөтен өй эчен тынгысыз шәүләләр белән тутырып, почмактагы лампада гына җемелди иде.

Артыма яшереп тотып торган хәнҗәремне сиздерми генә кынына тыктым да, өстәл янындагы артсыз агач урындыкны алып, мич каршынарак барып утырдым. Карчык яңадан, кабаланып, бәрәңге әрчергә кереште.

Минем эч поша. Ничектер карчык белән бирелеп сөйләшергә сүз таба алмыйм кебек. Үземдә мәгълүм бер дәрәҗәдә каушау сизәм. Кулларымны мичтәге ялкынга каршы куеп җылыткан булам.

— Авылыгызда хәлләр ничек соң, әби, немецлар бик борчыйлармы?

— Инде борчыр җирне дә калдырмадылар. Менә шушы бәрәңге пешерә торган чүлмәкне дә тартып алып чыксалар, дөнья төгәлләнә,— диде карчык, үзе: — Йа Алла, йа Алла! — дип, тирән сулап куйды.

Тынлык. Карчык башын түбән игән дә онытылып тирән уйга талган.

Шулвакыт еракта, авылның икенче ягында, эт улаган тавыш ишетелде. Карчык сискәнеп китте. Күзләре яңадан сер яшереп елмайдылар. Карчык тавыш ишетелгән якка башын борып сулышсыз тыңларга керешге. Бераздан эт улаган тавыш яңадан ишетелде. Ләкин бу юлы ул якын иде. Тавышка карап этнең урам буенча улап бирегә табан килгәнен белергә була иде.

Карчык кинәт, бөтенләй яшенә, кыяфәтенә хас булмаган хәрәкәт белән сүткән төргәкләрен тиз генә җыйнап икона артына кыстырды да урынына элеп куйды.

— Улым, кач, киләләр. Кулларына эләгеп харап була күрмә. Икебезнең дә тере килеш тиреләребезне тунарлар,— диде карчык. Җилфердәп, аны-моны җыештырып, өй эчендә йөрергә керешге. Тегендә сугылды, монда сугылды. Мин дә аякка бастым. Тәрәзәгә каты итеп кемдер бер генә чиертте. Акморат булса кирәк. Карчык сиздеме, сизмәдеме, тәрәзә тавышына игътибар итмәде. Шулвакыт гөрелдәгән автомобиль тавышы ишетелде. Карчык тиз генә идән тактасын ачты да миңа базга төшәргә ымлады. Автомобильнең безнең өй янына килеп тукташанын сиздем. Башка юл калмады, тәвәккәлләп базга төштем. Төшүем белән артымнан идән тактасы ябылды. Җилкәмә әллә нинди чүпләр коелды. Борыныма тынчу дымлы һава, чи бәрәңге исе килеп бәрелде. Капшанып, бер почмаккарак бардым. Анда эченә бәрәңге тутырган бер ящик булса кирәк. Шинель итәкләремне җыеп, шул ящик өстенә утырдым. Тыңлыйм, йөрәгем лып-лып тибә. Югарыда, минем баш өстемдә, карчык ни эшли торгандыр, аның кыштырдаганы ишетелми. Ул да тынып тыңлый булса кирәк.

Нәрсә булыр? Күңелгә әллә нинди шикле уйлар төшә. «Юк, бу андый карчык булмас»,— дип, үземне тынычландырырга тырышам. Бу минутта Акморат ни эшли, нинди чаралар күрә икән? Көтмәгән төрле хәлләр килеп чыгып, бер-беребездән аерылмыйк тагы. Тапшырылган эшне үтәмичә, борын төшереп кайтып керү яки суга төшкән кебек югалып калу бу безнең

өчен, ут сызыгы артында безгә ышанып калган окоптагы иптәшләребез өчен күтәрә алмаслык хурлык булыр.

Кинәт, җимерердәй итеп, чолан ишеген кактылар. Карчык өй ишеген ачып сорады:

— Кем бар анда?

— Бабка, их, их, элта я, — дигән җавап ишетелде. Карчык берсүзсез барып чолан ишеген ачты.

Менә өйгә керделәр. Тупас тавышлары, дагалы итекләре белән минем баш өстемдәге идән такталарын деңгелдәтеп таптап йөри башладылар. Бу кешеләр кыска-кыска гына бер-берсенә сүз ташлаштылар. Билгеле, немецлар икәү булсалар кирәк.

Утырам. Тешләремне кысып сулыш алам. Хәнҗәремнең сабын шулчаклы кысып тотканмын, кулым авырта. Бервакыт тамак төбем кычытып йөткерәсем килде. Минем бу бәладән котылу өчен күргән чараларымны белсәгез, көләр дә, елар да идегез. Актык чиктә мин аңардан менә ничек котылдым: бугазымны тышкы яктан ике бармагым белән бик каты кысып тоттым да, авызыма төкерек җыеп, аны йотарга тотындым. Йоткан вакытта бугаз хәрәкәткә килә, ике бармак арасыннан шуышып югарыга күтәрелә. Шулай ышкылудан кычытуга охшашлы йөткерү чакыра торган борчу басыла. Моны язып та тормас идем. Ләкин ул минем язмышымны саклап калган бер чара булды.

Кыскасы, мин бер сәгатькә якын немецлар табаны астында — базда яттым. Бу вакыт эчендә алар, карчыктан самовар куйдыртып, чәй эчтеләр. Самовар кайнаганчы, өстәл янына утырып, нәрсәдер эшләделәр: консерв ачып ашадылармы, парабеллумнарын тазарттылармы — әйтә алмыйм. Ара-тирә урыннарыннан кузгалып йөрештерделәр. Озын-озын җөмләләргә эштән чыгарып җимергән бер-ике рус сүзе кыстырып, карчык белән сөйләшергә маташып карадылар. Ат кебек кешнәп көлделәр, сүгенгәләп тә алдылар. Кызып-кызып сөйләштеләр — нәрсә турында? Аңламадым, кызганыч.

Мин немецча бераз сукалыйм. Ләкин немецлар үзара сөйләшкәндә тыңлап торып аңларлык, сүзгә кушылырлык түгел.

Вакытында немец телен яхшылап өйрәнмәвем өчен, базда немецлар табаны астында утырганда, үземне бик каты тиргәдем, булдыксыз кешегә санадым. Немец телен яхшы белсәм, базда утырган минутта гына да разведка өчен, бәлки, бик кыйммәтле әйберләр эләктерер идем.

«Дошманның телен яхшы белергә кирәк!»

Караңгы базда утырганда, үз күңелемә шундый лозунг яздым мин.

Югарыда әйткәнемчә, мин бер сәгатькә якын базда, каһәрле немецларның халык иркен таптый торган дагалы итек табаннары астында яттым. Бер сәгать! Бу бер сәгать вакыт эчендә мин немецлар коллыгы астында яшәүнең, Гитлер вурдалаклары табаны астында тапталуның ни дәрәҗәдә авыр, кичерә алмаслык хурлыклы, кимсетүле тормыш икәнен үз җилкәмдә татыдым. Әгәр дә немецлар тырнагы астында калсам, минем үземнең, хатынымның, күз нурыма тиң балаларымның, гомумән, халкымның тормышы, үткәрәчәк көннәре, киләчәге — менә шушы баз. Йөрәкне дерелдәтә, йөзне саргайта торган авыр, тынчу һавалы, караңгы тирән баз. Өстемдә, көнен кояш нурлары белән бизәлгән, ә төнен җемелдәп торган алтын йолдызлар сибелгән чиксез зәңгәр күк урынына, үрмәкүч пәрәвезе белән капланган идән такталары. Ул идән өстендә пычрак итекләренең бөтен чүпләрен синең җилкәңә коеп, баскан саен синең йөрәгеңә басып, шак-шок атлап немец йөри. Синнән, синең намусыңнан ат шикелле кешнәп, күгәргән тешләрен ыржайтып көлә.

Шушы уйлардан соң тәнем эсселе-суыклы булып китте.

Менә немецлар кузгалдылар һәм китәргә җыендылар булса кирәк. Карчыкка бер авыз да сүз әйтмәделәр. Шак-шок басып чыгып киттеләр. Аларның һәр адымы минем башыма күсәк белән суккан кебек булып калды. Тынып калган өйдә бераздан карчыкның борын эченнән генә мыгырдаганы ишетелде:

— Кул бармакларын, сандалга салып, чүкеч белән төясе нәрсәләр! Өй ишегеңне ябып чыгып китәрлек вөжданнары да юк бит аларның.

Барып каты итеп ишекне япты. Шуның белән аз гына булса да ачуын басарга тырышты, күрәсең.

Мин, тонык кына булса да, тагын эт улаган тавыш ишеттем. Автомобиль гөрелдәп кузгалып китте. Инде миңа да кабаланырга кирәк. Карчыкның кайгылы сүзләре белән артыграк мавыгып уңайсыз хәлдә калдым. Акморат мине аркылыторкылы салып тиргәгәндер.

Карчык ыңгырашып сайгакны ачты. Чыктым. Өй эче тәмәке төтене белән тулган. Өстәлдә самовар, яньчелеп беткән консерв банкасы, коньяк шешәсе һәм бөтен өй эчендә әллә нинди, күңелгә авыр, ят бер ис.

— Көчкә чыгып киттеләр, аяклары коргырлары,— диде карчык. Ярый әле, күрәсең, Алланың шәфкатедер инде. Авылы-

бызда исән калган бердәнбер эт бар. Күп бәлаләрдән шул эт коткара. Бөтен авылыбыз белән ул этне иң кадерле җан итеп саклыйбыз.

Мин карчыкның сүзләрен аңлап бетмәдем.

— Нинди эт, ничек, нәрсәдән коткара ул? — дип сорадым.

— Ишетмәдеңмени, немецлар килер алдыннан бөтен авыл буйлап бер эт улап үтте. Шул этне әйтәм. Ул — безнең авылда исән калган бердәнбер эт. Башкаларын тиреләрен тунап алу өчен немецлар атып үтереп бетерделәр. Ә бу эттә, күрәсең, адәм акылы бар. Аны һич тота алмыйлар. Көндез кеше күзенә күренми ул. Төнен сакка чыга. Авылга ят кешеләр килсә, шушы әллә каян, ерактан сизеп, бөтен авыл буенча улап үтә — хәбәр итә. Авыл халкы, аның улавын ишетү белән, таралган итәген тиз генә җыеп ала. Ай, ул эт! Син аны белмисең генә, безне бик күп бәлаләрдән коткарды ул,— диде карчык. Мин беренче тапкыр аның йөзендә елмаю күрдем.

Эт вакыйгасы миңа бик сәер тоелды. Ул этне күрәсем, шулай улап хәбәр итеп йөрүен үз күзем белән күзәтәсем килде.

— Әби, нигә ул этегез менә без сезнең авылга килеп кергәндә уламады?

Шулай дип соравым булды — телемне тешләдем: «Без килгәндә», имеш, ә карчык каршында «мине» генә белә. Ярый әле, минем бу саксызлыгыма карчык игътибар итмәде.

Карчык, горурланып, тавышсыз гына көлде:

— Сез бит — үз кешеләребез. Ул үз кешеләребезне кайдан гына килсәләр дә сизә, уламый. Немецлар килсә генә улый,— диде.

Без карчык белән яңадан әкрен генә сөйләшергә керештек.

— Болар нинди немецлар тагын?— дип сорадым мин.

— Фашист офицерлары. Берсе яз көне айга якын минем өемдә торган иде. Шуннан бирле үткән-сүткәндә һәрвакыт кереп йөри. Ашап-эчеп чыга, кайвакытларны кунып та китә. Әрсез, тупас бернәрсә шунда. Шул куркак җан аркасында өй әйләнәмдәге бөтен каралтымнан мәхрүм калдым.

— Ничек аның аркасында мәхрүм калдың?

— Аның аркасында шул. Үз күләгәләреннән үзләре куркалар бит алар. Шул яз көне миндә торганда, аны көн-төн өй әйләнәсендәге часовойлар саклады. Часовойларга гына ышанмады. «Өй тирәсендәге бу каралтылар миңа һөҗүм итәргә килүчеләр өчен яшеренергә бик уңай урыннар булып торалар»,— дип, бөтенесен җимерттереп ташлатты. Җимергән абзар, келәт бүрәнәләремне, түбә, түшәм такталарын солдат кухнясына

утын итеп ягып бетерделәр. Ишегалды уртасында өем генә шыр ялгыз утырып калды.

«Безнең партизаннар офицер әфәнделәрнең өннәрен алганнар икән»,— дидем мин үз-үземә һәм, тешләремне кысып, астыртын гына елмайдым. Аннан сораулы күз карашларымны карчыкка текәдем:

— Әле нәрсә эшләделәр соң алар, чәй генә эчтеләрме?

— Юк, башта кесә фонарьларын рәтләделәр. Аннан язулы кәгазьләр актарып утырдылар. Миндә торганы нәрсәдер язып, конвертка салып сургучлады да миңа таныш булмаганына бирде.

Мин карчыкка сиздерми генә иренемне тешләдем. «Эх, ул конвертны кулга төшерергә!»— дигән уй башымда чаткыланды.

Җай белән генә сүзне төп мәсьәләгә бордым. Урман, аның эчендәге хәлләр, көн буе ниндидер ящиклар ташыган автомобильләр турында җентекләп сораштым. Карчык бөтен нәрсәне энәсеннән җебенә чаклы каш астыннан гына күзәтеп йөри торган, күп белә торган карчык булып чыкты. Ул миңа бик кыйммәтле материаллар бирде.

Анам белән исәнләшкән кебек, кипкән кулларын кысып исәнләшеп өйдән чыктым. Карчык, миңа хәерле юл теләп, чолан ишеге төбеннән озатып калды. Аяк тавышы ишетелмәслек ераклыкка киткәч, туктап колак салдым. Карчыкның чолан ишеген ябып бикләвен, өй ишеген ябуын ишеттем. Аннан яңадан, борылып, карчыкның өе янына килдем дә Акморат белән очраштым. Ул минем карчык янында озак торуым турында бер шелтә дә ясамады. Немецлар килүе турында да сүз кузгатмады:

— Файдалы сүзләргә ирештеңезме?— генә диде.

Без, аяк очларыбыз белән генә басып, карчык мине озатып калган якка бөтенләй капма-каршы булган юл белән урман арасына кереп югалдык.

Сораулар

1. Фашистларның авылга керүен нәрсә хәбәр итә? Эт нинди бәлаләрдән коткара? Аларның кешеләргә ярдәме турында тагын нинди мисаллар беләсез?

2. Разведчикларга нинди эш йөкләнгән була? Алар максатларына ирешәләрме?

3. Разведчиклар турында тагын нинди әсәрләр укыганыгыз, фильмнар, спектакльләр караганыгыз бар?

1960—2000 ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

XX гасырның икенче яртысына караган бу елларны тарихи-иҗтимагый вакыйгаларга, халыкның рухи тормышындагы үзгәрешләргә, милли үзаң үсешенә һ. б. га нисбәтле ике чорга бүлү кабул ителгән: 1) 1960—1980 еллар уртасы; 2) 1980 елларның икенче яртысы — 2000 еллар.

Беренче чор тарихка «торгынлык еллары» исеме белән кереп калса да, әдәбиятта ул җитди сыйфат үзгәрешләре башлану белән характерлана. Бу елларда татар сүз сәнгатендә *ике идея-эстетик юнәлеш* барлыкка килә. *Беренчесе,* рәсми төстә булып, хакимият идеологиясенә нигезләнә. Әлеге әсәрләрдә җитәкчеләргә, партиягә мәдхия уку, интернационализм идеяләрен хуплыйбыз дип, милләтләрнең ассимиляцияләнүен яклау һ. б. үзәктә тора. Бу тенденция тарафдарлары, совет системасын гел үсештә карауны дәвам итеп, аның хәзерге этабын нык үскән социализм дип бәяләп, Татарстанның һәм татар халкының 50 нче еллардан соңгы яшәешен әлеге рәсми позициядән чыгып яктырту белән шөгыльләнделәр. Моның өчен алар республикадагы икътисади үзгәрешләргә игътибарларын арттырдылар. Мәгълүм ки, 50 нче еллардан алып Татарстан ССРның нефть һәм химия промышленносте, энергетика һәм машина төзелеше буенча иң эре үзәкләреннән берсенә әверелә. Шундый үзгәрешләр белән бәйле рәвештә республика тормышында шәһәрләшү процессының тагын да көчәюе татар халкы яшәешенә дә йогынты ясый. Рәсми идеологиягә ияреп һәм туган халкыбызның тормышын матуррак итеп күрергә теләп, әдипләр күпчелек очракта әлеге йогынтыны уңай яктан гына чагылдырырга алындылар. Ачыграк әйтсәк, әдәбиятта республика икътисадындагы үзгәрешләр татарларның профессиональ-техник һәм рухи яктан үсүенә булышты дигән фикерне үткәрүгә басым ясалды.

Болар барысы 60 нчы еллардан соңгы татар әдәбиятында күбрәк эшчеләр дөньясын сурәтләү аша чагылдырылды. Сугыштан соңгы чорда республикабыз икътисадындагы һәм тормышындагы үзгәрешләр иң әүвәл нефть промышленносте барлыкка килүе һәм үсүенә бәйле була. Әдипләр дә 50 нче еллардан ук шушы өлкәгә игътибарларын көчәйтәләр һәм төрле жанр вәкилләре аны үзләренчә яктыртырга алыналар. Бу темага беренчеләрдән булып мөрәҗәгать иткән шагыйрьләрне, мәсәлән, ул башлыча тормыштагы яңару процессын чагылдыру ягыннан кызыксындыра. Мисал өчен, Ә. Маликовның «Ташчы» һәм «Дуслык юлы», С. Хәкимнең «Үрләр аша» поэмаларында, Х. Камалов шигырьләрендә нефть промышленносте йогынтысында республика икътисадында һәм тормышында аерым кешеләр язмышында хасил булган уңай үзгәрешләр романтик күтәренкелек белән сурәтләнә.

Прозада да, аерым алганда, И. Газиның «Гади кешеләр», Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар», Ш. Бикчуринның «Каты токым» романнарында нефть белән бәйле уңай үзгәрешләр аерым герой язмышлары һәм образлары аша шулай ук калку итеп чагылдырыла.

Прозаикларның, шагыйрьләрнең һәм драматургларның 70 нче елларда игътибарын бердәй җәлеп иткән тагын бер икътисади күренеш булып КамАЗ төзелеше торды. Бу тема, конкретрак әйткәндә, Б. Камаловның «Урамнар киңәя», М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да» повестьларында, М. Хәсәновның «Кама таңнары», Ә. Баяновның «Ут һәм су» һәм «Таш китап» романнарында, Р. Мингалимовның «Күз карасы», Х. Камаловның «Язмыш елмаюы», С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмаларында, Д. Вәлиевнең «Дәвам» һәм «Диалоглар» пьесаларында күпмедер романтик гомумиләштереп, ягъни уңай яктан бәяләп яктыртылды. *Икенче юнәлеш* исә, милләт язмышы белән тыгыз бәйләнештә булып, күпгасырлык традицияләргә таяна, гомумкешелек кыйммәтләрен яклый, кеше яшәешен туган җиренә, халкына, гореф-гадәтләренә, рухи-мәдәни мираска мөнәсәбәтле тасвирлый. Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ә. Еники, С. Баттал, Ф. Хөсни, Н. Фәттах, И. Юзеев, Х. Туфан, С. Хәким, Х. Вахит, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин һ. б. ның әсәрләрен без бүген дә кыйммәтле ядкарь буларак кабул итәбез.

Коммунистик идеология белән бәйле рәвештә бу елларда төп иҗат методы буларак социалистик реализм санала. Әмма яшә-

ештәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә аның әдәби-эстетик эчтәлеге киңәя. Тормышны бөтен тулылыгында, катлаулылыгында чагылдыру максатында ул традицион реализм элементлары белән байый. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Туган туфрак», А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» һ. б. әсәрләрдә, яшәешнең, милләтебезнең мөһим сорауларына мөрәҗәгать ителеп, халыкның гасырлар дәвамында тупланып килгән әхлакый кыйммәтләре яклана. Иҗтимагый һәм сәяси тормыштагы җитди каршылыкларга карамастан, татар әдәбияты үсешүзгәрешен туктатмый. Иң яхшы әсәрләр рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителә. А. Гыйләҗев, Ә. Баянов һ. б. талантлы каләм ияләре әсәрләрендә моңа кадәр күпертелеп, идеаллаштырылып сурәтләнгән социалистик җәмгыятьнең тискәре яклары ачыла, эзоп теле белән тәнкыйть ителә.

1980 елларның икенче яртысы — 2000 еллар әдәбияты үсеше илдә башланып киткән демократик үзгәрешләр белән тыгыз бәйле. Сүз, матбугат иреге, хәбәрдарлык яулап алыну халыкларның милли үзаңы үсешенә китерә. Ил яңа икътисади юнәлешкә борыла — кызу темплар белән капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлый. СССР дип аталган империя таркала, элекке союздаш республикалар мөстәкыйль дәүләтләр булып аерылып чыга. Автономияле республика булган Татарстанда да җитди иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр башлана. Дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация (1990), республиканың Россия дәүләтендәге урынын билгеләү буенча үткәрелгән референдум (1992), Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү (1992), Россия белән Татарстан арасында шартнамә төзелү (1994) — татар халкының соңгы еллардагы милли-азатлык хәрәкәтенең төп вакыйгалары әнә шулар.

Татар халкының милләт буларак сакланып калу мәсьәләсе алгы планга чыгып, рухи-мәдәни өлкәдәге үзгәрешләрнең төп юнәлешен билгели. Кискен мәсьәлә буларак татар халкының туган телен әкренләп югалту куркынычы аеруча калку итеп куела. Ул исә үткән тарихыбызның фаҗигале һәм данлы сәхифәләрен объектив чагылдыру, танылган шәхесләребезнең эшчәнлегенә тарихи дөрес бәя бирү, рус тарихчылары тарафыннан күрмәмешкә салынган факт-күренешләрнең халкыбыз һәм Россия тарихындагы урынын билгеләү һ. б. җитди сорауларны алга куюга, эзләнү-тикшеренүләр башлауга китерә.

Ил язмышын, җәмгыятебезнең киләчәген билгеләгән проблемалар татар әдәбиятында да үзенең чагылышын таба. Әкренләп әдәбият тарихындагы «ак таплар» бетерелә башлый. Китап укучыларга Г. Ибраһимовның «Адәмнәр», Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай», Г. Рәхимнең «Идел», Г. Толымбай әсәрләре һәм, аеруча киң яңгыраш алып, Г. Исхакый исеме, бай мирасы кайтарыла. Бу чор әдәбиятының мөһим бер үзенчәлеге буларак, татар халкыныңерактагы һәм якындагы тарихын чагылдырган, шулай ук танылган шәхесләрнең әдәби образларына мөрәҗәгать иткән күп санлы әсәрләр языла. Р. Батулланың «Сөембикә», М. Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере», Җ. Рәхимовның «Батырша» романнары, Ә. Рәшитовның «Колшәриф», «Мөхәммәдьяр» поэмалары, Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә», Ю. Сафиуллинның «Идегәй» пьесалары тарих һәм заман бәйләнешен әдәби-эстетик тирәнлектә чагылдыруның уңышлы үрнәге булып тора.

Әдәбиятның эчтәлеге, тема-проблемалары үзгәрү әдәби юнәлеш, агым, иҗат методы, сурәт чараларына да зур йогынты ясый. Сүз сәнгате социалистик реализм иҗат методыннан баш тарта. Татар әдәбияты төп иҗат юнәлеше итеп традицион реализмны ала. Әмма моны бертөрлелеккә омтылу дип аңларга ярамый. Ерактан килүче традицияләргә тугры калып, әдипләр романтик сурәтләргә, натурализм элементлары белән баетылган тасвирлауларга иркен мөрәҗәгать итәләр.

Соңгы елларда реализм һәм романтизм кысаларына кермәгән, әдәбият белемендә модернизм һәм постмодернизм дип аталган төшенчәләр белән билгеләнә торган алым-чараларга игътибар арту күзәтелә. Аның асылын тормыш-чынбарлык күренешләрен яңача, үзенчәлекле форма, эчтәлек һәм сурәтләү чаралары аша чагылдыру билгели. Н. Гыйматдинованың «Ак торна каргышы», Г. Гыйльмановның «Албастылар», М. Гыйләҗевнең «Бичура», «Баскетболист» һ. б. әсәрләрдә яңа форма эзләү, төрлелеккә омтылу, мифология һәм фольклор белән бәйле образларга, күренешләргә мөрәҗәгать итү, гротеск, пародия алымнарын, төп вакыйгага метафора булып килгән күренешләрне файдалану белән очрашабыз.

Совет чорында, нигездә, рус һәм Көнбатыш әдәби-фәлсәфи фикеренә йөз тоткан татар әдәбияты соңгы елларда Көнчыгыш мәдәниятен дә үз итә башлады. Бу, бер яктан, урта гасырларда гарәп-фарсы һәм төрек әдәбиятлары йогынтысында җирләш-

кән тема-мотивларга, жанрларга мөрәҗәгать итүдә (Р. Гаташ робагыйлары) чагылса, икенче яктан, мөселманлыкка тартылуда, ислам дине яклаган рухи кыйммәтләрне ачу-аңлату, әдәби чаралар ярдәмендә тасвирлау белән аңлатыла. Шул рәвешле озак вакытлар онытылып торган рухани әдәбият формалашу юлына керә. Аның уңышлы үрнәкләре белән Ф. Бәйрәмова иҗатында («Соңгы намаз» әсәре) очрашабыз.

Бөтен әдәбият өчен уртак дип каралган гомум мәсьәләләрне яктырту белән бергә, 1960—2000 елларда проза, поэзия, драматургия һәм балалар әдәбияты күбрәк үзләренә хас эзләнүләр дә алып бардылар. Бу чор әдәби процессы анда әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәненең роле үсү белән характерлана. Агымдагы әдәби хәрәкәтне җентекләбрәк анализлау һәм бәяләү белән бергә, әдәбиятыбызның күпгасырлык тарихын бербөтен итеп торгызу буенча да нәтиҗәле эш алып барыла. Боларның барысы хакында әдәбиятыбызның әлеге төрләренә багышланган бүлекчәләрдә җентеклерәк итеп сөйләнер.

Сораулар һәм биремнәр

1. 1960—2000 еллар әдәбияты ни сәбәпле ике чорга бүлеп өйрәнелә?

2. XX гасырның 60—80 нче еллары әдәбиятында күзәтелгән ике юнәлешне билгеләгез, аларга хас сыйфатларны күрсәтегез.

3. 1980 елларның икенче яртысы — 2000 елларда Татарстанда булган иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның әдәбиятка йогынтысы нәрсәдә чагыла?

4. Әдәбиятның эчтәлеге үзгәрүне сез ничек аңлыйсыз? Мисаллар китерегез.

5. Соңгы елларда рухани әдәбиятның яңаруы нәрсә белән аңлатыла?

1960—2000 ЕЛЛАР ПОЭЗИЯСЕ

Әлеге чор шигъриятен икегә бүлеп күзәтү ясыйк.

1960—1980 еллар шигъриятенең үсеш-үзгәрешенә иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни вакыйгалар зур йогынты ясый. Илдәге демократик үзгәрешләр тәэсирендә әдәбиятның, аеруча шигъриятнең җәмгыятьтәге роле үсә. Башка әдәби төрләргә караганда алданрак заман үзгәрешләренә йөз тоткан поэзия 60 нчы елларда сәхнәләргә менә, стадионнарда яңгырый. «Тыелган» әдипләрнең, шул исәптән Х. Туфан, Ш. Бабич, Дәрдемәнд, Н. Думави һ. б. иҗатының әйләнеп кайтуы, өзелгән традицияләрнең торгызылуы да сан һәм сыйфат үзгәрешләренә уңай йогынты ясый.

Әлеге елларда шигъриятнең төп көчләрен өлкән буын шагыйрьләр Ә. Ерикәй, Ә. Давыдов, Н. Арсланов, С. Хәким, Х. Туфан, С. Баттал, Ш. Маннур, 50 нче елларда әдәбиятка килгән Г. Афзал, Ш. Галиев, И. Юзеев, Х. Камалов, Ә. Баянов кебек урта буын һәм 60 нчы елларда кыю адымнар атлаган Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Мингалим, бераз соңрак иҗатка килгән А. Хәлим, Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановлар, Ф. Яруллин, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллин, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, Х. Әюпов һ. б. тәшкил итә.

Шигырь-поэмаларында хисләр дөньясын, акыл һәм хис көрәшен күп төрле төсмерләрдә, бизәкләрдә чагылдырган шагыйрәләр С. Сөләйманова, Г. Зәйнашева, К. Булатова, М. Фәйзуллина, Р. Вәлиева, Н. Сафина, Ф. Зыятдинова, Б. Рәхимова һ. б. шигъриятнең үзенчәлекле бер катламын тәшкил итә.

Бу чор поэзиясе бертөрле генә бәяләнми. Бер яктан, партия, хөкүмәт карарларына, Ленинга мәдхия уку, шәһәрләшүне мактау, татар теленең кулланылыш мәйданы тараюны күрмәмешкә салыну һ. б. дәвам итсә, икенче яктан, чын халыкчан шигърият гади кеше мәнфәгатен яклап чыга, татар язмышы өчен борчылып аваз сала.

Поэзиядә кешенең рухи дөньясын, шатлык-борчуларын, теләк-омтылышларын үзәккә алган Н. Арслановның «Ир гайрәте», М. Әгъләмовның «Еракка китеп кара», Р. Харисның «Кеше» кебек әсәрләрендә җәмгыять, гаилә, шәхеснең үзара мөнәсәбәтенең чагылышын күрәбез.

Татар шигърияте туган ил, туган җир, ата-ана туфрагы кебек изге төшенчәләргә һәрдаим мөрәҗәгать итеп килә. Г. Афзал («Туган җиреңнән китмә»), Ә. Рәшит («Авылны сагынганда»), К. Сибгатуллин («Эзләмәгез әллә кайлардан»), Ш. Галиев («Туган тел»), Р. Фәйзуллин («Менә без дә үсеп җиттек, әни») һ. б. иҗатында сагыну, юксыну хисе тагы да тирәнәя, фәлсәфи мәгънә ала.

Шигърияттә зур бер катламны бөек шәхесләрнең әдәби образлары тасвирланган әсәрләр алып тора (Х. Туфан. «Могикан», С. Хәким. «Кырыгынчы бүлмә», Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш», М. Әгъләмов. «Тукайдан хатлар», «Акмулла арбасы»).

Лирик поэзиядә интим хисләрне чагылдыру табигыйлеккә омтылу рәвешен ала. 60—70 нче елларда язылган лирик шигырьләр көйгә салынып, киң яңгыраш алган җырлар булып китә. С. Хәкимнең «Башка берни дә кирәкми», Ш. Галиевнең «Раушаниям, бәгърем», И. Юзеевнең «Яшь наратлар», «Мәтрүшкәләр», Г. Зәйнашеваның «Китмә, сандугач», Р. Фәйзуллинның «Аккошлар», Р. Вәлиевнең «Зинһар өчен, кермә төшләремә» кебек җырлары төрле буын кешеләре өчен якын һәм истәлекле.

Сатирик эчтәлекле шигърият яңа баскычка күтәрелә. Г. Афзалның («Мыек борам», «Тәвәккәл әби», «Тотып җибәр, апаем») һәм Ш. Галиевнең («Шәвәли маҗаралары», «Юаттылар», «Камырша») тормыштагы, кешеләр характерындагы кимчелекләргә каршы юнәлтелгән кинаяле юморы киң яңгыраш ала.

Бу чордагы табышларның җитди бер өлеше лиро-эпик жанр үсеше белән бәйле. И. Юзеевнең «Мәхәббәт китабы», Р. Харисның «Ант суы», Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан», Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн», «Сәйдәш», М. Әгъләмовның «Онытма, Европа» кебек әсәрләре татар шигъриятенең казанышы буларак бәяләнә.

1960 еллар поэзиясенең тагын бер үзенчәлеге форма өлкәсендәге эзләнүләр белән бәйле. Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим кебек шагыйрьләр ирекле шигырьне тагы да үстереп, баетып җибәрә, киң яңгырашына ирешә.

1980—2000 еллар шигърияте җәмгыятьтәге үзгәрешләргә гаять сизгер булып, үзенең мөнәсәбәтен даими белдереп бара. Бу елларда да ул әйдәп баручы позициясен саклый. Шигърият мәйданын Г. Афзал, Ә. Баянов, И. Юзеев, Рәшит Әхмәтҗанов, Ә. Рәшитов, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Ф. Яруллин, Р. Харис, Р. Гаташ, Г. Марат, Х. Әюпов, К. Сибгатуллин, З. Мансуров, Р. Зәйдулла һ. б. тота. Алар янәшәсендә кешенең рухи матурлыгына, мөлаем хис-кичерешләренә, нечкә тойгыларына йөз тотып Л. Шагыйрьҗан, Э. Мөэминова, Н. Сафина, Р. Вәлиева, К. Булатова, Б. Рәхимова, Ф. Зыятдинова, Ф. Тарханова, Э. Шәрифуллина, А. Минһаҗева, И. Иксанова һ. б. шагыйрәләрнең ихласлык бөркелеп торган иҗаты балкый.

Татар поэзиясе традицияләргә тугрылыгын саклый. Берәүләр, заман чынбарлыгына йөз белән борылып, вакыйга-күренешләрне реалистик сурәтләрдә чагылдырса (Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Л. Шагыйрьҗан, З. Мансуров, А. Хәлим һ. б.), икенчеләргә хыял дөньясын, күңел кичерешләрен, интим хисләрне, бәхетле яшәешкә омтылышны романтик тасвир чаралары, сурәтләр муллыгы ярдәмендә бирү хас (И. Юзеев, Р. Гаташ, Роберт Әхмәтҗанов һ. б.).

Шигърият тематик төрлелеге, жанр байлыгы, сурәт чаралары муллыгы белән аерылып тора. Соңгы елларда халыкның үткән тарихына игътибар арту күзәтелә, шуңа да шигырьләрдә туган илгә, туган җиргә тугрылык хисләре киң урын ала (Г. Афзал. «Ачы язмышлар», Зөлфәт. «Туфрак тарта»).

Ф. Яруллинның «Керәшче», Зөлфәтнең «Җаннарга тия шул», «Имансызлар», И. Юзеевнең «Указлы шагыйрь булганчы» һ. б. әсәрләр татар теленең, диннең, гореф-гадәтләрнең сакланышы мәсьәләләрен кыю куюлары белән игътибарга лаек. Гомумән, милли эчтәлек бу чор шигъриятен иңләп үтә. Милли идеяне эстетик идеал итеп күтәргән (М. Әгъләмов. «Иман тәрәз шакый», К. Сибгатуллин. «Иман»), олы шәхесләрнең якты образларын чагылдырган (Р. Харис. «Нәҗип Җиһанов», «Сәйдәш яры», Зөлфәт. «Күрешә калсак», И. Юзеев. «Син бит тыңлый белә идең») шигырь-поэмаларның күпләп язылуы шул хакта сөйли.

Соңгы елларда әдипләр игътибар иткән табигатьне саклау (З. Мансуров. «Ятим Су анасы», «Балык кычкыруы»), ата-анага тирән хөрмәт, алар каршында җаваплылык (Р. Миңнуллин. «Әнкәмнең догалары», Ш. Маннапов. «Картлар кайта җомгадан») кебек мәсьәләләр дә заман таләбе буларак алга чыкты.

Шулай итеп, хәзерге татар шигърияте XX гасыр традицияләрен яңа шартларда үстергән хәлдә, тормыш-чынбарлыкның катлаулы, четерекле күренешләрен чагылдыруның яңадан-яңа юлларын, сурәт чараларын эзли һәм халыкның рухи ихтыяҗларына җавап биреп килә.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX гасырның 60 нчы еллары поэзиясенә йогынты ясаган шартларны күрсәтегез.

2. Бу чор шигъриятенә хас үзенчәлекләрне билгеләгез.

3. 1960—1980 еллар лирикасын әйдәп баручы авторлар дип кемнәрне атар идегез?

4. 1980—2000 еллар поэзиясенә караган шагыйрәләр иҗатына хас сыйфат-билгеләрне атагыз.

5. Хәзерге шигърияттәге тематик төрлелек нәрсә белән аңлатыла?



Гамил Афзал
(1921—2003)

Гамил Гыймазетдин улы Афзалов (Гамил Афзал) 1921 елның 23 маенда Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Колхозлашу чорындагы каршылыклар, мәҗбүр итүләр аркасында Гыймазетдин абзый гаиләсе белән Магнитогорск шәһәренә күчеп китә. Авылда беренче сыйныфны тәмамлаган Гамил монда җиделлык мәктәпне бетерә. Укыганда ук шигырьләр язу белән мавыга, һәм 1937 елны матбугатта беренче шигыре басылып чыга. Шул елны ул Троицк шәһәрендәге педагогия техникумына укырга керә. Беренче курсны тәмамлагач, каты авырып китә һәм укуын ташларга мәҗбүр була. Тиздән аның аяклары атламас була. Больницага кереп дәвалану да ярдәм итми. Шундый авыр хәлдә Г. Афзал 1954 елны апасы янына, Башкортстанның Калтасы районы Шәрип авылына күчеп китә.

Авылның матур табигате, кош-кортлары, балыклы елгакүлләре, саф һавасы, шифалы сөте, барыннан да бигрәк якты йөзле, ярдәмчел, тапкыр сүзле, эшкә батыр халкы Г. Афзалның аякларына гына түгел, бөтен тәненә, борчулы җанына дәва була. Бу турыда ул «Юл башы» исемле автобиографик әсәрендә болай дип яза: «Шәрип авылы миңа күп нәрсә бирде: тормышка мәхәббәт бирде, чыкылдап торган, уен-көлкеле, тупасрак юморлы халык телен бирде, бик күп сюжетлар, темалар бирде, салмак сабырлык бирде, илһам бирде».

1955 елны «Совет әдәбияты» журналында Г. Афзалның берьюлы 9 шигыре басыла. «Мин иркен сулап куйдым,— дип яза ул югарыда күрсәтелгән әсәрендә,— чыгып барган җан кире кереп, дөньяга ун тырнагым белән ябыштым. Мин терелә башладым, йөри башладым. Инде иркенләп, елый-елый, көлә-көлә

язарга тотындым, көн-төн». Эзләнүләренең, тормыш, табигать, яшәеш турындагы уйлануларының нәтиҗәсе буларак, 1957 елны шагыйрьнең «Кар сулары» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Г. Афзалның үткен сатира һәм юмор, тормышчан лиризм белән язылган шигырьләре тиз арада киң катлау укучыларда популярлык казана. Аның әсәрләре сәхнәләрдән яңгырый, җыентыклары рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителә.

Әдәбият-сәнгать яңалыкларына якынрак булу теләге һәм кайнап торган зур төзелешләр, шәһәр-калалар әдипне үзенә тарта. 1964 елны ул Әлмәт шәһәренә күчеп килә һәм шунда яшәп кала.

Г. Афзалның иҗат юлына күз салсаң, 50—60 нчы елларда язылган әсәрләрендә юмор-сатира жанры, ә аннан соңгы чорларында туган җир, туган тел, тынычлык, хезмәт, поэзия, яшәү мәгънәсе, бөек шәхесләр һ. б. турындагы лирик шигырьләре өстенлек алуы күренә. Тукай һәм Бабичлардан килгән тирән мәгънәле, үткен сатира чорыбызның, җәмгыятьнең ямьсез якларын бөтен тулылыгында һәм оста чагыштырулар, сынландырулар, гипербола аша әдәби сурәтләве белән заманча яңгырый.

Әдип лирикасында халыкның уй-фикерләре, шатлык-көенечләре лирик герой кичерешләре аша бирелә. Шагыйрь туган ил, туган җир төшенчәләренең изгелеген җырга салып әйтә:

Дулкынланып тибрәлә җыр:
«...Сандугач кунмас инде,
Ямьле булса да торган җир,
Туган ил булмас инде».

Г. Афзал тел үзенчәлекләренә халыкның гаҗәеп матур, җор сөйләменнән, ә язу осталыгына үзенә кадәр яшәп иҗат иткән шәхесләрдән өйрәнә. Шунлыктан үзенчәлекле бай мирас калдырган атаклы кешеләргә багышлап язган шигырьләре тулы бер цикл тәшкил итә. Алар арасында, Гомер, Г. Тукай, Кол Гали, М. Фәйзи, Ш. Бабич, С. Хәким, Н. Некрасов һ.б. белән бергә, сәнгатьнең башка өлкәләрендә зур уңышка ирешкән С. Садыйкова, Б. Урманче, И. Шакиров һ. б. га багышлап язганнары бар. Әдип бөтен иҗаты буенча Г. Тукайның мәһабәт образын тудыра, аңа сокланып, үрнәк алып яши һәм үзенең иң олы остазы дип саный. Халыкның иҗтимагый һәм рухи тормышындагы урынын бәяләп, болай дип яза:

Илдә туган ил улы син, илдә яндың
нур булып,
Ил күгендә яз идең син, илдә калдың
җыр булып.

Туган җир белән бәйләнештә табигать образы Г. Афзал иҗатында эзлекле үстерелә. Ул әдипкә яшәү көче, иҗат дәрте бирә. Табигать матурлыгы еш кына лирик геройның интим хисләре, уй-хыяллары белән бәйләнештә бирелә. Аның «Урман сукмагы», «Өянкеләр моңы», «Көз», «Карт имән», «Сандугачлы яшел урман», «Зирек җырлый» һ. б. шигырьләре әнә шундыйлар. Шагыйрь табигатьне нечкә тоемлап тасвирлый:

Сары дулкын булып арыш җитә,
Болыннарда зәңгәр моң йөри...

Г. Афзалның байтак шигырьләренә көй язылган. Аның «Татарстан таңнары», «Очрашу», «Өф-өф итеп» һ. б. җырлары, халкыбыз күңелендә үз урынын алып, бүген дә яратып җырланалар.

1977 елны «Айлы кичләр» җыентыгы һәм «Борылам да карыйм...» циклына кергән шигырьләре өчен Г. Афзалга Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә. Әдипнең күпкырлы бай иҗаты бүген дә заманча яңгырашы белән киң катлау укучыларда теләктәшлек таба.

Сорау һәм биремнәр

1. Г. Афзалның тормыш юлын сөйләгез. Бу турыда аның «Юл башы» исемле автобиографик әсәрен укыгыз.

2. Әдипнең чын мәгънәсендә шагыйрь булып китүенә, тормышта үз урынын табуына нәрсәләр этәргеч ясый?

3. Ул: «Дөньяга ун тырнагым белән ябыштым»,— дигән сүзләре белән ни әйтергә теләде икән?

ӨФ-ӨФ ИТЕП

Малай туды безнең. Нинди шатлык!
Икебезгә уртак бәхет таптык.
Сокланабыз аңа исебез китеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Егет үстерәбез туган илгә,
Мондый асыл малай бездә генә.

Тирбәтәбез йоклаганын көтеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Затлы кием, ефәк аңа гына,
Тәмле-татлы нәрсә тамагына.
Тәпи йөри башлый яңа гына,
Тып-тып итеп, тып-тып итеп.

Малай үсә. Буе, яше арта,
Бәби чагы инде калды артта.
Көн диванга ятып, «Казбек» тарта,
Пыф-пыф итеп, пыф-пыф итеп.

«Әни, давай, миңа шиблет кидер,
Даваегыз заграничный нидер,
Әти, давай, папироска йөгер,
Лап-лап итеп, лап-лап итеп!»

Йөгерәсең, кала тузан тузып,
Автомобильләрне юлда узып.
Магазинга, магазинга тизрәк,
«Казбек» кирәк, «Казбек» кирәк!

Яңа мода костюм тапты уйлап,
Газиз парәң булгач, бостон юллап,
Йөгерәбез икәү урам буйлап,
Анда лап-лоп, монда лап-лоп.

Укырга җибәрдек, бармый анда,
Безнең сүзне алмый искә-санга.
Коньяк эчә хәзер ресторанда,
Голт-голт итеп, голт-голт итеп.

Матур кызлар белән прәннек ашый,
Акча сорап, безгә допрос ясый,
Бирми торсаң, хәзер кыйнап ташлый,
Дөп-дөп итеп, дөп-дөп итеп.

Сорау һәм биремнәр

1. Шигырьне каршы якларга аерыгыз.
2. Ике өлешнең дә уртак һәм аермалы якларын әйтегез.
3. Кабатлаулар нәрсәгә хезмәт итә?

«КЫЗЫЛ БАЛЧЫК» ПРОМАРТЕЛЕНДӘ

Бригадиры тәртип-фәлән карап тора,
Бер бухгалтер хезмәт хакын санап тора.
Бер технолог сызым сыза, башын кашый,
Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый.

Тәэминатчы бияләй белән тәэмин итә,
Кладовойчы чүлмәкләрне кабул итә.
Секретарь кыз боерык яза, боерык ташый,
Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый.

Замначальник тәрәзәдән карап тора,
Ялкаулар, дип әрләп тора, янап тора.
Ә начальник доклад яза ярсый-ярсый,
Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый.

Артель эшли, артель гөрли, контор яза...
Бәйрәм җитә, тантаналы утырыш бара.
Начальниклар, елмаешып, бүләк ала,
Ике малай доклад тыңлый һәм кул чаба.

Сорау

Автор бу шигыре аша нинди фикер җиткерергә теләгән дип уйлыйсыз?

МЫЕК БОРАМ

Тәрәзәдән карап торам,
Гайрәт белән мыек борам.
Төрле хәвеф-хәтәр белән
Тулып яши безнең урам.
Мөмкин түгел күрми узу,
Адым саен тәртип бозу.
Иртә-кичен һәр урамда
Эчеп йөргән хулиганга
Бирер идем каты җәза,
Килеп чыгар бәла-каза;
Тешне кысып карап торам,
Гайрәт белән мыек борам.

Үгез күзле аю егет,
Трамвайда бушка килеп,
Мәсхәрәли кондукторны,
Ул ишәктә намус зурмы?!
Ничек түзим тынып калып,
Якасыннан борып алып
Бирер идем каты җәза,
Килеп чыгар бәла-каза.
Таш атканга ат, диләр, аш,
Ике түгел минем дә баш.
Курмәмешкә салынып торам,
Гайрәт чәчеп мыек борам.

Ни әйтсәң дә, бушка инде,
Минем күршем — чучка инде,
Кайчан кермә, күзең салма —
Өе тулы тавыш-гауга.
Эшләмичә өйдә ятыр,
Табак-савыт кырыр-ватыр,
Көне-төне хатыны белән
Сугышалар дөбер-шатыр.
Биреп булмый каты җәза,
Чыгып куяр бәла-каза.
Дәшми генә тыңлап торам,
Гайрәт белән мыек борам.

Түзеп торып булмый алай,
Өй түрендә малай-шалай,
Иртә димә, кичен димә,
Чыр-чу килеп футбол тибә.
Ачу эчтә тынмый һич тә,
Күрше малай бөтен көчкә
Капкага дип бер тибә дә
Чалтырата тәрәзәмә...
Бирер идем каты җәза,
Килеп чыгар бәла-каза,
Форточкадан карап торам,
Гайрәт чәчеп мыек борам[1].

Минем көннәр шулай үтә,
Минем мыек һаман үсә.
Кыш та җитте, ачы буран,
Мин урамда басып торам.
Ике егет килеп чыкты —
Мине карга сугып екты.
— Каравыл! — дим,—
эшләр харап,
Ник үтәсез читкә карап?!
Пүскәй артны
тукмасыннар,
Башка гына сукмасыннар,—
Башны карга тыгып торам,
Гайрәт белән мыек борам.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне вакыйгаларга бүлегез.
2. Соңгы вакыйга нәрсә белән үзенчәлекле?
3. Әдип көлүнең нинди алымын кулланган? Нәтиҗә ясагыз.

---

[1] Шигырьнең моннан соңгы өлешен шагыйрь Салих Баттал язды. *(Автор искәрмәсе.)*

Зөлфәт

(1947 елда туган)

Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов) Татарстанның Мөслим районы Яңа Сәет авылында игенче гаиләсендә туган. Ул, Уразмәт урта мәктәбен тәмамлагач, 1965—1969 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укый. Зөлфәт үзенең һөнәре итеп журналистиканы сайлый. Аның беренче шигъри тәҗрибәләре матбугатта мәктәп елларында ук күренә башлый.

Халыкның күркәм сыйфатларын калку итеп чагылдырган «Чакырылмаган кунак», тарих һәм кешеләр язмышы турында уйланулар тулы «Сугышта үлми былбыллар», язучы һәм сәнгать, тормыш һәм иҗат турындагы фәлсәфи шигырьләре «Хемингуэй үлеменә», «Айлы соната», «Сине Блок уйлап тапкан бары», лирик эндәшләрдән торган парчалар, җырлар һәм башка халыкчан сурәтләргә бай шигырьләр Зөлфәт иҗаты өчен хас.

Шигъриятгә Зөлфәтнең үз тавышы, үз аһәңе бар. Анда кискен ноталар да, киеренкелек тә яки чишмә агышыдай ритмнар да һәм иң нечкә көйләрне дә табарга була. Шагыйрь чынбарлык күренешләрен, лирик геройның рухи дөньясын халык язмышы, үткәндәге зур тарихи вакыйгалар яки бүгенге көннең мөһим проблемалары белән фәлсәфи бәйләнештә ачарга омтыла.

Зөлфәт шулай ук «Җен кызы», «Ат өреккән бер төн», «Гасырдан озын бер көн» исемле пьесалар авторы буларак та мәгълүм. Бу әсәрләр курчак театры сәхнәсендә куелды. «Мәкерле песи» дигән беренче татар балалар операсының либреттосын да ул язды. Моның өчен шагыйрь Муса Җәлил исемендәге премиягә лаек булды. Татар әдәбиятын үстерүгә куйган хезмәтен олы бәяләп, аңа Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Сорау

Зөлфәтнең иҗат үзенчәлеге нидән гыйбарәт?

ТЫЛСЫМ[1]

Изсәләр дә, кылыч чапсалар да,
Юлыкса да юлда мең үткел[2],
Шигырьле тел — фанилыкка[3] бәйсез
Үлемгә баш бирми андый тел.

Гамәлендә азат адәми зат —
Амин тотсын яки чукынсын —
Әмма сүздә шигъри куәт[4] булса,
Ул сүз,— димәк, үзе бер тылсым!

Шигъри сүзем минем — саф тылсымым
Авыр чакта сезгә кагылсын —
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен безне бу тылсым!

Кардәшләрем! Сезнең җанда туган
Шигырьләрне әйтер сүз көчен
Ни өчендер Ходай миңа биргән —
Өлешемә тигән көмешем...

Дөньялыкта яман сүзләр булмый,
Яман әйтүчеләр булмаса —
Булсын сүзем сүзләр чишмәсендә
Сүзләр чылтыратыр
Колаша[5].
Китсен сүзем фани бу дөньяга,
Йөрер юлы аның ак булсын —
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен безне бу тылсым...

---

[1] Тылсым — берәр эшне башкаруда сихерле, серле алым.

[2] Үткел — тау сыртлары арасындагы тарлавык (перевал).

[3] Фани — бетә торган, үзгәрә торган, вакытлы.

[4] Шигъри куәт — әдәби сүз көче.

[5] Колаша — орлык киптерү һ. б. өчен эшләнгән җайланма; монда күчерелмә мәгънәдә кулланылган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сүздәге шигъри куәтне ничек аңлыйсыз? Һәркемнең сүзендә шигъри куәт буламы?

2. Шагыйрь нәрсәне тылсымга тиңли?

3. Шигъри сүзнең савыктыру көче бармы? Өченче строфаны үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

4. Шигырьнең соңгы строфасын ничек аңлыйсыз?

5. Шигырьнең сезгә аеруча тәэсир иткән юлларын укып күрсәтегез.

6. *Куәт, савыктырсын* сүзләренә синонимнар табыгыз.

7. Сез шигырьләр укырга яратасызмы? Кайсы шагыйрьнең нинди шигырьләре сезгә тәэсир итә? Ни өчен дип уйлыйсыз?

8. «Әдәби сүзнең тәэсире» темасына сөйләшү үткәрегез.

ДҮРТ ҖЫР

Аргы ярда әле көмеш җырлар,
Елларның да аргы ярында,
Чыдар микән йөрәк ахыргача
Җырлаганчы шуның барсын да?

Беренче җыр — илем турында ул,
Олы юлга дәшкән җырдыр ул,
Йөрәк кадәр чәчәк бөреләре
Тирбәлешеп торган кырдыр ул...

Икенче җыр... Әни турында ул,
Ун мең еллык тере көйдер ул;
Бу җиһанда җанны җылытучы
Бердәнбер өй, изге өйдер ул.

Өченче җыр... Сөю турындадыр —
Мең яңарган иске моңдыр ул;
Яшәү өчен, чиксез дәвам өчен
Һавадыр ул, сихри тындыр ул.

Дүртенче җыр... Бусы җырланадыр
Елларның иң аргы ярында.
Анысын каен җырлар... Каберемдә...
Калганнарын — үзем! Барын да!..

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь үзе өчен мөһим булган нинди дүрт җырны билгели?

2. Шагыйрьнең һәр җырын ничек аңлыйсыз? Үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

3. Шагыйрьнең икенче җырындагы «Ун мең еллык тере көйдер ул» дигән юлын аңлатып бирегез.

4. Аңлашылмаган сүзләрне табып, аларның мәгънәләрен ачыклагыз һәм сүзлегегезгә язып куегыз.



Ренат Харис
(1941 елда туган)

Ренат Харис (Харисов Ренат Мәгъсүм улы) 1941 елның 6 маенда Ульяновск (элекке Сембер) өлкәсенең Богдашкино районы Зирекле Күл (Кәшә) авылында туган. Р. Харисның балачак һәм мәктәп еллары Татарстанның Буа төбәгендәге авылларда уза. 1958 елны Буа шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп, бер ел чамасы слесарь-сантехник булып эшли. 1959—1963 елларда Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. Институтны тәмамлаганнан соң, Татарстанның Арча педагогия училищесында рус теле һәм әдәбияты укытучысы (1963—1964), аннан Казанда комсомолның Татарстан өлкә комитетында пропаганда буенча инструктор (1964—1965), 1965—1971 еллар арасында «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталары редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип һәм 1971—1973 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе вазифаларын башкара. 1973—1982 елларда ул — Татарстанның мәдәният министры урынбасары, 1982 елдан 1989 елга кадәр «Казан утлары» журналының һәм 1991—1995 елларда «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире булып эшли. 1990 елдан Р. Харис — Татарстан Югары Советы һәм 1995 елдан Татарстан Дәүләт Советы депутаты, 1995—2000 елларда Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы һәм Дәүләт Советы Рәисе урынбасары.

Р. Харис — әдәбият мәйданына 60 нчы еллар башында килгән һәм шигърияттә үз тасвири алымын, үзенчә язу стилен булдырырга омтылган шагыйрьләрнең берсе. Республика көндәлек матбугатында аның исеме 1962—1963 елларда күренә башлый, 1968 елда «Беренче карлыгачлар» сериясендә тәүге

җыентыгы («Җир һәм Кеше»), ә тагын бер елдан олы шагыйрь Сибгат Хәким кереш сүзе-фатихасы белән «Кайтаваз» исемле китабы басылып чыга. Хәзер ул — Казан, Мәскәү нәшриятларында татар телендә һәм русча тәрҗемәдә дөнья күргән өч дистәдән артык исемдәге шигъри тупланмалар авторы. Аларның һәммәсе диярлек — үз вакытында әдәби тәнкыйтьтә уңай бәя алган җыентыклар.

Татар халкының тарихи үткәне, бүгенгесе һәм өметле киләчәге, Кеше һәм Табигать, аларның үзара бердәмлеге — шагыйрьнең иҗат эшчәнлегенең төп-үзәк темаларыннан берсе әнә шул. Революция чоры каһарманнарыннан Мулланур Вахитов, Камил Якуб кебек тарихи шәхесләрнең тормыш һәм көрәш фаҗигаләрен яктырткан «Мулланур», «Камил Якуб», сәнгать кешеләренең иҗат шатлыкларын һәм газапларын шигъри осталык белән ачып биргән «Рәссам», Ватан сугышы вакыйгаларына бәйле «Җәлилчеләр» һәм «Ат иярләү», «1972 ел икмәге», тарихи «Ант суы», чечен халкы фаҗигасен чагылдырган «Бүре күзе», бүгенге болгавыр заманны сарказм белән тасвирлаган «Һарут белән Марут» поэмалары, Ф. Кәрим, Дәрдемәнд, Табигать, Вакыт, Җир, Мәхәббәт турындагы шигъри цикллар, «Кеше» ораториясе шагыйрьнең шушы олы темаларны яктырту юнәлешендәге җитди уңышлары булып тора. «Кеше» ораториясе өчен шагыйрь Р. Хариска һәм композитор М. Яруллинга 1972 елда Татарстан яшьләр оешмасының М. Җәлил исемендәге бүләге бирелде.

Соңгы елларда Р. Харис иҗатында мәхәббәт лирикасының көчәюе һәм шигъри теленең яңа тасвири сыйфатлар белән баеп баруы күзәтелә. Моны бигрәк тә «Кәзге мәхәббәт» (1991) җыентыгына кергән лирик шигырьләрендә һәм «Зөләйха», «Өч үбешү», «Гармунчы», «Хыянәт» кебек поэмалар мисалында ачык күрергә мөмкин.

1997 елда Ренат Харис лирик шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Хисемнең исеме» (1996) китабы өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә, «Йосыф кыйссасы» балет либреттосы өчен Россия Дәүләт бүләгенә лаек булды (2006).

Р. Харис үз иҗатында кече яшьтәге балаларны да онытмый. Балаларга багышлап, ул «Матур өй» (1988), «Лап-лап» (1996), «Әбәк» (2001) исемле шигъри җыентыклар бастырды, 80 нче елларда исә Казан курчак театры сәхнәсендә аның «Тылсымлы алан» дигән пьесасы уңыш белән барды.

Р. Харис — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1972), Каракалпак АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1980), Халыкара мәгълүмат академиясенең мөхбир әгъзасы (1993).

Сораулар

1. Р. Харисның халык тарихын өйрәнү, аның киләчәге турында борчылуын ничек аңлыйсыз?

2. Шагыйрь иҗатының кайсы юнәлешләре сездә кызыксыну уятты?

КЕШЕ КАЙЧАН МАТУР?

1

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта —
башкаларны чакырганда
үзе яккан учакка;
ятлар белән танышканда
күзләре җылынганда;
шул җылылыкның рәхәтен
җаның белән тойганда.

2

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта —
ерак дусын очраткачтын,
елаганда кочаклап;
җырлаган чакта җырының
моңында эрегәндә;
бәхеткә таба чапканда,
күршеңә юл биргәндә.

3

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә —
шигырь тыңлаган чагында
уйга чума белгәндә;
мәхәббәтен сүзсез генә
аңлаткан мизгелендә;
бәхет белән сөйләшкәндә
бәхетнең үз телендә.

4

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә —
иң авыр минутында да
тормышка гашыйк хәлдә;
сөйгән ярын югалтса да,
сөюен саклаганда;
иң «гөнаһлы» гыйшыкның да
сафлыгын аклаганда.

5

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт —
иле өчен, халкы өчен
яшәгәндә җан атып;
замананың авырлыгын
җилкәсенә алганда;
олы данга ирешеп тә,
кече булып калганда.

Сорау һәм бирем

1. Шагыйрь бу шигырендә кеше матурлыгының төрле мизгелләрен сурәтләгән. Сезгә аларның кайсысы иң якын?

2. «Кеше һәрьяктан гүзәл булырга тиеш» дигән темага сөйләшү оештырыгыз.

ХӘЛ-ӘХВӘЛ

Хәл-әхвәлләр сорашудан
Башлана һәр күрешү...
Канга сеңгән гадәтләрнең
бу — иң матур өлеше!

Җанга рәхәт булып китә
Хәл-әхвәл сорашудан —
барыбыз да тумыштан ук
күнегеп беткән шуңа.

Әйбәт дибез, яхшы дибез...
Бик сирәк зарланабыз,
Җелекне киптерә диеп,
Хәл-әхвәл дигән явыз.

Сер бирмәскә тырышабыз —
Аллага шөкер! — дибез:
тән — җан белән,
жан — аң белән,
аң — заман белән игез...

Сораулар һәм бирем

1. Күрешкәч, хәл-әхвәл сорашуны автор яхшы гадәт дип саный. Сезнең фикерегез ничек? Хәл-әхвәл сорашуга нәрсәләр кирә?

2. Безнең халыкта сәлам бирүнең үз кагыйдәләре бармы? Алар ниндиләр?

3. Соңгы строфаны ничек аңлыйсыз?

4. Сез танышларыгыз белән аралаша беләсезме?



Хәсән Туфан
(1900—1981)

Чорыбызның күренекле шагыйре Х. Туфан турында каләмдәше, якын дусты, шагыйрь Сибгат Хәким болай дип яза: «Туфан — авыр, катлаулы юл үткән, татар поэзиясенең зурлыгын гел сиздереп торган, Такташлар чорын бүгенге белән нык тоташтырган бердәнбер олы фигура. Татар поэзиясендә Туфан бер генә, башка Туфан юк!» Әлеге юллар Х. Туфанның шәхесен, фаҗигале язмышын, гаҗәеп бай иҗатын һәм аның кыйммәтен күзалларга мөмкинлек бирәләр.

Хәсән Фәхри улы Туфан 1900 елның 9 декабрендә Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Рус миссионерлары тарафыннан көчләп чукындырылып та кире үз диненә кайткан бу авыл кешеләре җәбер-золымны күп күрәләр. Рухи кимсетү, мыскыллау өчен, яңа туган балаларны әниләре исеменнән ясалган фамилия белән язганнар.

Булачак әдипкә дөньяның зурлыгын, матурлыгын, серлелеген беренче булып әнисе күрсәтә. Бу турыда үзенең истәлекләрендә Х. Туфан болай дип искә ала: «Әни минем, гәрчә язу яза белмәсә дә, халыкның бер баласы буларак, ифрат шигъри җанлы кеше иде. Дөньяның, табигатьнең матурлыкларын күрергә иң әүвәл әнием өйрәтте мине.

...Әни миндә: «Бар нәрсәнең дә җаны бар икән, чишмәләр генә түгел, җилләр дә, яфраклар да, йолдызлар да сөйләшә икән»,— дигән иман тудырды».

Х. Туфан, табигать моңнары белән беррәттән, халыкның җыр-бәетләрен, такмак-мәзәкләрен, гадәт-йолаларын күреп, ишетеп үсә, аларны яшь күңеленә сеңдерә бара. Бала вакытта ук, үзе әйткәнчә, җырның йодрыктан көчлерәк икәненә тө-

шенә. Авыл мәдрәсәсендә китап дигән серле дөньяга керә. Белем алырга, укуга теләге, омтылышы зур икәнен күрсәтә.

Октябрьдән соң Х. Туфан казакъ далаларына китеп укытучылык итә. Гражданнар сугышы чорында, Колчак армиясенә мобилизацияләнүдән качып, Омск якларына китә, шунда берничә ел яши.

Дөньяның ачысын-төчесен байтак татыган, күңелендә шигъри хисләре ташып торган егетнең күңеле татар әдәбияты һәм сәнгате үзәге булган Казанга тартыла, һәм ул шунда күчеп килә.

Ил өстенә килгән авыр еллар ачысы Туфанны да читләтеп үтми, ул уналты ел буена Сталин лагерьларында газап чигә. Шагыйрьнең төрмә-лагерьлардагы михнәт-газапларын уртаклашучы кеше — хатыны була. Ирен «халык дошманы» дип кулга алгач, Луизаны эшеннән чыгаралар, фатирын алалар. Ул судка мөрәҗәгать иткәч кенә урынына кайтаралар. Ләкин тиздән яңадан куалар. Кышкы салкында фатирдан фатирга, бүлмәдән бүлмәгә йөрү эзсез калмый. Суык тиеп, улы үлә. Олы йөрәкле бу хатын бер-бер артлы килгән кайгы-хәсрәттән бөгелеп төшми. Азык-төлек белән бик авырлашкач, ул донор булărак, канын бирә һәм аның өчен алган ризыкны төрмәдәге иренә җибәрә.

Төрмә-лагерь шартларында да Хәсән Туфан кешелек сыйфатларын җуймый. Кулыннан килгән кадәр тоткыннарның хәлен җиңеләйтергә тырыша: кайсының хәлен белешә, күңелендә ышаныч тойгылары уята, кайсына кием-салым белән булышу юлларын эзли. Аны «изге җан» дип йөрткәннәр. Бу кушамат үзенә һәм әйберләренә беркемнең дә кагылырга хакы юк дигәнне аңлаткан. Әлеге язылмаган кагыйдәне карак-бандитлар да төгәл үтәгән.

Әдип өчен иң авыры,— билгеле, иҗат белән шөгыльләнергә мөмкинлек булмау. Шулай да ул әсәрләрен күңел дәфтәренә салып барган һәм мөмкинлек булу белән кәгазьгә төшергән. Х. Туфан үзенең шигырьләрен, иптәшләреннән алып берничә кат күзлек киеп, бик очлы карандаш белән папирос кәгазенә язып барган. Бик нечкә итеп төреп, аларны ипи эченә яшергән һәм утта сохари итеп киптергән. Шулай итеп, ул байтак шигырьләрен саклап кала алган. Ә бик күпләре, яшерелгән урыннарда калып, мәңгегә юкка чыкканнар.

Сталинның «шәхес культы» фаш ителгәч, 1956 елның мартында Х. Туфанны азат итәләр. Шул елның 26 сентябрендә ул

Казанга кайта. 1957 елның 27 августында Татарстан Югары суды, Х. Туфанның гаепсезлеген танып, аны тулысынча реабилитацияли.

Әдип җаны-тәне белән шигърияткә чума. Ул, Тукай, Бабич, Такташлар традициясен дәвам итеп, халыкчан рухтагы әсәрләрен яза. Аның шигырьләре чын мәгънәсендә халыкка рухи азык, илһам чишмәсе булып әвереләләр.

1966 елны Х. Туфанга Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Аның «Әйткән идең...», «Сиңа», «Ромашкалар», «Агыла да болыт агыла», «Киек казлар» һ. б. җырлары бүген дә еш яңгырыйлар. Әдип үзенең бәхетен иҗатта, халкына хезмәт итүдә тапты. «Иҗат — бәхет ул,— дип язды ул истәлегендә,— иң матур, иң көчле бәхет ул! Иң бәхетле чагым — иҗади накалда яшәгән чак. Җанның, күңелнең, йөрәкнең, бәгырьнең дөрләгән, кайнаган чагы, уй һәм хиснең аера алмаслык булып кушылып, ташып торган чагы».

«Үзе бер чор» (С. Хәким) булып яшәгән, иҗат иткән олы шәхес Хәсән Туфан 1981 елның 13 июнендә Казанда вафат булды.

Аккош күлендә сагыш, моң,
Юксынып сорый урман:
Гасырның үзе кебек чал
Кайда дип синең Туфан?

(С. Хәким)

Сорау һәм биремнәр

1. Х. Туфанның балалык еллары һәм аның шагыйрь булып китүенә әнисенең тәэсире турында сөйләгез.

2. 20—30 нчы елларда әдип тормышында нинди үзгәрешләр була?

3. Х. Туфанны туган җиреннән, халкыннан, әдәбияттан аерып торган фаҗигале еллар турында сөйләгез.

4. «Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син
Каның белән ялгагансың ич!» темасына, Луиза Салиаскарова турында материал туплап, реферат языгыз.

Ә ҮТКӘНГӘ ХАТЛАР БАРМЫЙЛАР

Күтәренке шундый
Безнең күңел,
Шундый тирән безнең куаныч:
Бер-беребезне гүя өч көн түгел,

Ә утыз ел күрми торганбыз!
Сөйләшүләр безнең, киңәшүләр
Шундый матур гөрләп куйгалый:
Утыра монда өстәл тирәсендә
Ике Хәсән гүя, дүрт Һади...
Беребезнең сүзе бетәр-бетмәс
Икенчебез баса,
Сүз башлап,
Гөрләп тора бүлмә, әйтерсең лә
Тугыз Туфан анда, ун Такташ!..
Юксынырмын,
Әгәр еллар миңа
Агач йөрәк биреп китмәсә;
Юксынырмын,
Әгәр кешегә хас
Сыйфатларым корып бетмәсә!
Юк, бетмиләр сагыну-саргаюлар,
Алар бездә арта баралар.
Чагылышы булып шуның менә
Йөрәгемнән яшьләр тамалар.

Сораулар

1. Шигырьдә лирик геройның нинди хисе чагыла?
2. Лирик геройның хисләре кузгалу кем белән, нәрсә белән бәйле?
3. Автор кулланган сурәт чаралары нинди функция үти?

КАЙСЫ АТТА СИҢА КАЙТЫП БУЛА?

(«Кармәт истәлекләре» циклыннан)

Яшь гомерем зәңгәр чәчәк —
Үтәр димәгән идем...

Халык җыры

Таныйм сине, таныйм, үсмер чагым:
Син һаман шул — уйчан, әдәпле.
Өстеңдәге киндер зәңгәр күлмәгең дә
Таныш миңа — зәңгәр сәдәпле.

Киндер күлмәк, яңа, яшь чабата.
Ак эшләпә — кара тасмалы.
Йөгереп кенә кайтыр идем шунда,
Үтә алсам алтмыш басманы...

Дәшсәләр дә
Еллар, юллар мине
Әкияттән дә ерак-еракка,
Кармәт офыклары киңлеге дә
Җитә иде миңа ул чакта.

Тик бер генә кочак бәхеткә дә
Риза улың идем мин синең!
(Исеңдәме, Ниса, исеңдәме? —
Ул «бер кочак бәхет» син идең...)

«Мәгълүм булсын әле дөньяга,— дип,
Безнең дә бит «егет» икәнлек!» —
Уң кулның без урта бармагына
Бакыр балдак киеп җибәрдек...

Сүнде ләкин,
Шиңде безнең бу дәрт:
Бакыр балдак тутыга икән;
Елтыр тешле, керсез теләкләрнең
Ихлас теле тотлыга икән;
Дөнья безнең
Якты елмаюның
Яңагына «утырта» икән...

...Җитен күлмәк,
Көяз, шәп чабата.
Ак эшләпә — кара тасмалы...
Кайсы юлдан сиңа, кайсы атта
Кайтып була, гасыр башлары?!

Сораулар

1. Лирик геройның нинди хисе чагыла һәм аның чыганагы нәрсә?

2. Герой үзенә нинди бәя бирә?

3. Икенче һәм җиденче строфалар кабатлануына нинди мәгънә салынган?

АГЫЛА ДА БОЛЫТ АГЫЛА

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Нәрсә әйтсен: берни белми ул,
Хәбәре юк минем йөрәктән.
Мине бары чылатып үтте
Кукурузлар белән беррәттән...
Нәрсә әйтсен: берни белми ул.

Роман кебек күңелле син, юл!
Азмы синдә гомер уздырдым,
Ничә кием чабата синдә,
Ничә кием итек туздырдым!
Роман кебек күңелле син, юл!

Ә син, яңгыр, искә төшермә
Итегемнең ничек икәнен...
Яланаяк килдем дөньяга,
Шулай гына, бәлки, китәрмен.
Ә син, яңгыр, искә төшермә!

Зират бит ул Сабантуй түгел,
Нигә анда киенеп китәргә?
Бу дөньяның бер пар итеген
Нигә юкка әрәм итәргә?
Зират бит ул Сабантуй түгел.

Агыла да болыт агыла
Таулар аша Казан ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Бирем һәм сораулар

1. Кабатланган урыннарны табыгыз, мәгънәсен ачыклагыз.

2. Шигырь исеме лирик герой хисенең сәбәбен ничек белдерә? Лирик герой ни өчен болытка, юлга, зиратка мөрәҗәгать итә?

3. Юл образы нинди символны аңлата?

Х. Туфан иҗаты турында

Тормыш юлы бик тә гыйбрәтле булган Х. Туфанның иҗаты да гаять үзенчәлекле. XX гасырның 20 нче елларында әдәби иҗатка килеп, ул бай мирас калдыра. Аның шигырь-поэмалары татар шигъриятенең казанышы булып таныла. Х. Туфан-

ның иҗат юлын өч этапка бүлеп өйрәнү кабул ителгән: 1) 20—30 нчы еллар; 2) 40—50 нче еллар, ягъни тоткынлык чоры иҗаты; 3) 60—70 нче еллар.

1920 еллар башында, Казанга килеп яши башлагач та, Х. Туфан яңа тормышның ашкын героен, андагы рухи һәм психологик үзгәрешләрне сурәтләгән шигырьләре белән танылa. Бу елларда язылган «Зәңгәр бүре», «Башлана башлады», «Бибиевләр», «Ике чор арасында» кебек поэмаларына әдәбиятта яңалык буларак бәя бирелә. 1930 елны әдипнең беренче җыентыгы басылып чыга. Бу елларда әдип сәнгатьчә эзләнүләрен дәвам итә. Әсәрләре лиризм, халыкчанлык белән байый. Шагыйрь символ, метафора кебек сурәт чараларыннан уңышлы файдалана. Гражданнар сугышы фаҗигаләрен чагылдырган «Ак каен», заман үзгәрешләрен аңларга омтылу рухында язылган «Ант», «Очрашырбыз әле» кебек лирик-фәлсәфи әсәрләре басылып чыга.

40—50 нче елларда, туган җиреннән, гаиләсеннән, якыннарыннан аерылып, газаплы тоткынлыкта яшәгәндә дә, Х. Туфан тормыш һәм язмыш, мәхәббәт һәм сагыш, матурлык һәм нәфрәт турында тирән лиризм, олы фәлсәфә белән сугарылган әсәрләрен иҗат итә. Аның иҗаты, яңа яклары белән ачылып, иң югары ноктасына җитә. Сәнгатьчә эшләнешләре һәм уйфикерләренең тирәнлеге белән гаҗәеп камиллеккә ирешкән «Каеннар сары иде», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Агыла да болыт агыла», «Кайсыгызның кулы җылы?» һ. б. шигырьләре поэзиябезнең алтын фондына кереп калды.

Үзе еракта яшәсә дә, Х. Туфан фашизм алып килгән сугышның ачы фаҗигасен бөтен күңеле белән тоя. Сугышка һәм аны башлаучыларга тирән нәфрәтен белдерә. Шагыйрь тол хатыннарның, сабый балаларның хәсрәтен уртаклаша.

Сугыш темасына әдип соңрак та әйләнеп кайта. «Җирдә ике ак канат ята» (1953) әсәрендә төлке тарафыннан ботарланган аккошның канатлары аны фашизм концлагерьлары, аларда юк ителгән гөнаһсыз балалар, хатын-кызлар, картлар турындагы уйларга этәрә. Бу елларда Х. Туфан, үз язмышының драматизмын тирән аңлап, сагыш, моң белән тулы шигырьләрен яза. Әдипнең ирекккә омтылышы, туган җирен сагыну, сөйгәнен юксыну теләге белән кушылып, аның йөрәк авазы, җан сыкравы булып яңгырый:

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Шагыйрь — табигать баласы. Шуңа да ул аның алдында сокланып баш ия:

Гөлләр сорый миннән: «Нишләп, Туфан,
Уйга калдың әле син шулай?»
— Белмим, гөлләр, уйга калып шулай
Гүзәлеккә сокланам бугай.

(*Гүзәл*)

«Аралагыз мине», «Киек казлар», «Ромашкалар» һ. б. әсәрләрендә сурәтләнгән җанлы һәм тере булмаган табигать образлары лирик геройның хис-тойгыларын, теләк-омтылышларын чагылдыруга хезмәт итәләр. Алар артында ярату һәм сагыну хисендә янучы шагыйрьнең олы йөрәге күренә:

Киек казлар каңгылдаша
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит, дип
Елашалар микәнни?

(*Киек казлар*)

Х. Туфанның бөтен иҗаты буенча сузылып килгән, 40—50 нче еллар иҗатында аеруча нечкә лиризм һәм нәфислек белән сурәтләнгән темаларның берсе — мәхәббәт. Шагыйрь өчен ярату хисе — иң олы, иң изге, табигатькә җан өрүче, яшәүгә ямь бирүче хисләрнең берсе. Әдипнең «Сиңа», «Ромашкалар», «Әйткән идең...» һ. б. шигырьләрендә сагыну тойгылары гадәтилеге, тормышчанлыгы белән үзенчәлекле.

Ромашкалар үскән далада
Искә төште бергә чакларым;
Көтә микән, сагына микән, дип,
Канатларын йолкам аларның.

(*Ромашкалар*)

Х. Туфан шигърияткә үзенчәлекле шигырь формасы белән килде. Аның 40—50 нче елларда бу өлкәдәге эзләнүләре яңа уңышка китерә. Шагыйрь беренче һәм соңгы юллары кабат-

ланып килгән биш юллы строфа кулланып яза башлый. Борынгы Шәрык поэзиясенең күренекле вәкилләре Хәйям, Фирдәуси, Нәвоилардан килгән, рус әдәбиятында С. Есенин уңышлы кулланган бу форма Х. Туфан уй-фикерләренең мәгънәсен тирәнәйтергә, эмоциональ тәэсир итү көчен арттыруга булыша.

Гөлләр инде яфрак яралар,
Хәбәр итеп язлар җитәсен.
Язлар җиткәч, сугыш бетәсен
Көтеп утыра сабый балалар.
Гөлләр инде яфрак яралар.

(*Гөлләр инде яфрак яралар*)

Шагыйрьнең бөтен иҗаты кешене зурлау, аның рухи көченә соклану белән сугарылган. Әдип бигрәк тә фәлсәфи эчтәлекле «Сөйли торган материя», «Сүз кушасы килә талларга», «Һиндстанны эзлим», «Кая шулай ашыгасың йөрәк?» һ. б. әсәрләрендә кешенең табигать, җәмгыять белән бәйләнешләре, аның тормышы, бәхете турында уйлана.

Хәсән Туфан 60—70 нче елларда да иҗат активлыгын киметми. Аның лирик герое, заман мәсьәләләре белән якыннан кызыксынып, шатлыкларга куанып, әхлаксызлык күренешләренә борчылып яши. Әдип еш кына үткәнгә әйләнеп кайта, анда бүгенгегә аваздаш күренеш һәм вакыйгалар эзли. Аның «Гомер эзләрен буйлап», «Кармәт истәлекләре» циклларында, «Еракларга алып киттеләр» лирик поэмасында үткән белән безнең заманның бәйләнеше дә, киләчәккә ышанычы да үзенә хас алым һәм чаралар белән сурәтләнә. Шагыйрьнең халкыбыз тарихында, рухи тормышында тирән эз калдырган олы шәхесләргә багышлап язган әсәрләре дә тулы бер цикл тәшкил итәләр.

Әдип шигъриятнең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылып яшәде, аның үсеш юлына маяклар какты. Яшь авторларга бик игътибарлы булып, күбесенә үзенең фатихасын бирде. Хәзерге поэзиянең үзәген тәшкил иткән Ш. Галиев, И. Юзеев, М. Әгъләмов, Зөлфәт һ. б. шагыйрьләр үзләрен Х. Туфан мәктәбе шәкертләре дип атыйлар. Олы әдипнең тормышы, иҗаты туган җиренә, халкына бирелгәнлек үрнәге булып тора. Ул шуның белән безгә якын һәм кадерле.



Сибгат Хәким
(1911—1986)

Сибгат Хәким... Туган телне һәм әдәбиятны сөючеләргә бу исем яхшы таныш. Бөек Ватан сугышына кадәр үк әдәбият мәйданына килеп, хис-тойгыларга бай, музыкаль яңгырашлы, сурәтләү алым-чараларын мул кулланып, лирик шигырь поэмалар иҗат иткән әдип сугыштан соңгы татар поэзиясенең халыкчан юнәлештә үсеп китүенә җитди өлеш кертә. Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлилләрдән килгән матур традицияләрне, чордашы Х. Туфан белән бергә, үзенчәлекле үстереп, эстафетаны бүгенге көн шагыйрьләренә тапшырган С. Хәкимнең шигърият дингезендә лаеклы урыны бар. Сибгат Хәким 1911 елның 4 декабрендә Татарстанның Арча районы Күлле Киме авылында туа. Ул кечкенәдән атаклы шәхесләр турында истәлекләр тыңлап, шигырь-әкиятләр ишетеп үсә. Хезмәт сөючән, бай телле, тапкыр халыкның җыр-моңнарын, матур сыйфатларын, гадәтйолаларын яшь күңеленә сеңдерә. Мәктәптә укыган елларда шигырьләр яза башлый, кайберләрен стена газетасына да урнаштыра.

1931 елны С. Хәким пединститут каршындагы рабфакка укырга керә. Тиздән аны әлеге институтның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчерәләр. 1937 елны институтны тәмамлый. Бу елларда С. Хәким актив иҗат итә башлый, танылган шагыйрь-язучылар белән якыннан аралаша. Алар тәэсирендә поэтик осталыгын арттыра бара.

1938 елны С. Хәкимнең «Беренче җырлар» дип исемләнгән беренче җыентыгы дөнья күрә. Тиздән «Пар ат» поэмасы да басылып чыга. Аның беренче әсәрләрен Г. Тукайдан килгән классик поэзиянең традицияләрен үзенчәлекле дәвам итүче буларак бәялиләр. Шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына

кешенең табигый хисләрен, кичерешләрен тормышчан вакыйгаларга нигезләп ачарга тырышу хас. Тирән лиризм белән сугарылган хис-тойгыларны ул гади итеп әйтергә тырыша.

Әдип беренче поэмаларында ук бөек Тукайның якты образына мөрәҗәгать итә. «Пар ат» поэмасының һәр юлында олы шагыйрьнең бу дөньядан вакытсыз китүе өчен әрну дә, аның халык күңелендә мәңгегә калуы белән шатлану да, бөеклеге алдында баш ию дә сизелеп тора. «Шагыйрьнең балачагы» әсәрендә С. Хәким яшь вакытта Г.Тукайның апасы Сажидәдән ишеткәннәрен, фактик тормыш материаллары буларак, әдәби сурәтли, шуңа да поэма тормышчанлыгы, реаль нигезе белән уңышлы.

1948 елны, Кавказ якларына дәваланырга барганда, С. Хәким үзе сугышып йөргән җирләр аша үтә. Таныш авыл-калалар, шагыйрьнең күңелен дулкынландырып, үткәндәге дәһшәтле елларны, сугышчан иптәшләрен хәтергә төшерәләр. «Бөтен үткәнем кабат терелде,— дип искә ала әдип. — Вагон тәрәзәсеннән кергән таныш җил күңелемнең әллә кайсы төшенә кагылды, күңел тулды, сыкранды, ташыды; карадым, аерыла алмый бөтен нәрсәгә йотылып карадым. Менә кайда минем шул кешеләр турында исән калган иптәшләремә сөйлисем килде, әрнеп-әрнеп язасым килде». Шуның нәтиҗәсе буларак «Курск дугасы» поэмасы языла. Шагыйрь үзенең хатирәләрен яңарта, дусларын сагынып искә ала, һәлак булганнарның истәлеге мәңгелек булуын сөйли.

Аның әсәрләрендә туган як темасы бөтен иҗатын иңләп үтә. Туган җир матурлыгын сурәтләп язган әсәрләре, шигъриятенең иң югары ноктасын билгеләп кенә калмыйча, татар поэзиясенең иң уңышлы әсәрләре арасында урын алдылар. Аның «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә», «Фазыл чишмәсе», «Ага чишмәм», «Бер тауда ун чишмә» кебек шигырьләре, көйгә салынып, халкыбызның рухи чишмәсенә әверелделәр.

С. Хәким поэзиясенең бер үзенчәлеге шунда: ул бүгенге вакыйга-күренешләргә мөнәсәбәтен үткәннәр аша күрсәтә. Шуңа да әдип әледән-әле яшьлек елларына, данлы сугыш кырларына, ил тарихындагы зур вакыйгаларга әйләнеп кайта. Үткәнгә бәйле әсәрләре арасында күренекле шәхесләргә багышланганнары тулы бер цикл алып тора. Ул Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, Ф. Кәрим һ. б. мәһабәт шигъри образларын тудырды. Алар арасында

аерылып торганы — Тукай... Күп санлы шигырьләрдә, бигрәк тә «Кырыгынчы булмә» поэмасында, бөек шагыйрьнең халыкның рухи дөньясында тоткан урыны яңа яклары белән ачылып китә. Әдип, Тукайның авыр язмышына бер сыкранса, аның иҗаты белән мең горурлана.

С. Хәким һәрвакыт әдәбиятыбызның бүгенгесе һәм киләчәге белән кызыксынып яшәде. Үзенең мәкаләләрендә күп авторларның иҗатына тулы анализ ясап, җитди киңәшләр бирде, татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләрен билгеләде.

Үзенең бай иҗаты белән халык күңелендә лаеклы урын алган халык шагыйре С. Хәкимгә 1960 елны Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде, ә 1970 елны әдип Россиянең М. Горький исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. С.Хәкимнең шәхес буларак формалашуына нәрсәләр тәэсир иткән?

2. Әдипнең башлангыч чор иҗаты нәрсә белән характерлана?

3. Әдип поэзиясенең тематик, жанр төрлелеген билгеләгез.

4. Шагыйрьнең шәхесе белән әсәрләре арасында нинди бәйләнеш бар? Фикер алышыгыз.

5. «С.Хәким — фронтта» дигән темага реферат әзерләгез.

ГЕЛ КОЯШКА КАРЫЙ ТӘРӘЗӘЛӘРЕҢ

Атым минем үргә менгән саен,
Шатлыгым да артканнан-артты.
Ватанымның якты бер почмагы син,
Казан арты, әй Казан арты.

Кыр җилләре иркәләде килеп,
Тукай моңы ерактан тартты;
Әкиятләрең белән ачылды телем,
Казан арты, әй Казан арты.

Менә авыл, таныш кешеләрем,
Хыялларым ник болай татлы?
Гел кояшка карый тәрәзәләрең,
Казан арты, әй Казан арты.

Сорау һәм бирем

1. «Татлы хыял» эпитеты нәрсәгә хезмәт итә?

2. Шигырь исеменә бәйле строфаларның уртак мәгънәсен табыгыз.

БАШКА БЕРНИ ДӘ КИРӘКМИ

Туып-үскән шушы җирнең ямен
Алыштырмый икән һичнәрсәң.
Башка берни дә кирәкми,
Үзем чапкан печәннәрне
Бер туйганчы иснәсәм.

Миңа гына шулай тоела микән
Бөтен рәхәтләре соң аның?
Башка берни дә кирәкми,
Үзем тапкан чишмәләрнең
Ятып эчсәм суларын.

Урләре дә зәңгәр дулкын-дулкын,
Ул үрләрнең чиге кайда соң?
Башка берни дә кирәкми,
Дусларның мин гомерем буе
Тойсам җылы карашын.

Биремнәр

1. Шигырьне өлешләргә бүлегез, һәрберсенең эчтәлеген табыгыз.

2. Лирик геройның теләкләрен билгеләгез һәм аларның уртак мәгънәсен табыгыз.

3. Шигырь исеме кабатланып килә, аның каршылыгын билгеләгез. Шуннан чыккан төп идеяне күрсәтегез.

Туган як җырчысы

Сибгат Хәкимнең шигъри мирасы тема һәм жанр ягыннан бай, яшәешнең төрле якларын иңләп алуы белән аерылып тора. Җәмгыятьне, халыкны борчыган җитди мәсьәләләр, аерым цикллар тәшкил итеп, аның иҗат биеклекләрен дә билгели. Алар түбәндәгеләр: бөек шәхесләрнең төрле өлкәдәге эшчәнлеге алдында баш ию, аларның үз чорында һәм киләчәк буыннар өчен әһәмиятен күрсәтү; Бөек Ватан сугышының фаҗигале күренешләре, гади сугышчыларның батырлык үрнәге ниге-

зендә җиңүнең әһәмиятен, тынычлыкның кадерен фәлсәфи планда ачу; җәмгыятьтә урын алган әхлаксызлык, җинаятьчелек күренешләренең сәбәпләре турында борчылып уйлану, моңа капма-каршы буларак, активлыкка, намуслы, гадел яшәешкә чакыру; туган як һәм аның кешеләренә, халкыбызның матур сыйфатларына, гореф-гадәтләренә, традицияләренә, бәйрәмнәренә соклану, шулар аша милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгырту һ. б. Соңгысы С. Хәким шигъриятен тулысынча иңләп үтә, әсәрләрен бер үзәккә бәйли. Туган як матурлыгы, халкыбызның җыр-бәйрәмнәре әдипне иҗат дөньясына әтәргән. Үзенең истәлекләрендә ул шигъриятькә китерүче ике сәбәпне күрсәтеп, берсенең җәмгыятьтәге үзгәрешләргә, пионер, комсомол оешмаларына, Казанга килүенә, пединститутта укуына бәйле булуын әйтә һәм болай дәвам итә: «Бу юл белән янәшә мине поэзия дөньясына алып кергән тагын икенче юл да бар. Минем хисләр шул юл белән күбрәк бәйләнгән, күңел һәрвакыт аны эзли...

Безнең авыл Мари Республикасы чигендә. Бер үрдә — татар авыллары, икенче үрдә — мари авыллары. Үрләрдәге җил тегермәннәре, зират һәм кирәмәтләре белән бу якның сере тагын да тирәнәя төште. Юлларда аркаларына пилаларын асып, тузан тузгытып, мари ягына — урманлы якка баручы такта яручылар, аларга каршы каяндыр кайтып килүче балта осталары белән мари кызларының авыл читендә киндер тукмаклаганда җырлаган җырлары белән күңелгә керде...

Ә татар халкының үз җырлары... Ниндидер үз характерына туры килгән авыр, сабыр моң. Әйтерсең ул аның язмышыннан сыгып алынган. Күңелгә бер керсә, тиз генә чыкмый, төпкә утыра, төпкә ята. Кечкенә вакытта мин кайсы авылда бәйрәм — шунда чаптым. Ашарга тәмле нәрсә күп эләкмәде, әмма җырны туйганчы тыңладым. Бу яшьлек чиредер, бәлки? Юк. Мин әле хәзер дә шул чир белән авырыйм. Минем хәзер дә бер генә Сабан туен да калдырганым юк. Һаман да шул халык моңы тарта...»

«Гел кояшка карый тәрәзәләрең» шигырендә лирик геройга Казан арты бик тә якын, чөнки монда аның теле ачылган, монда ул бөек Тукай моңын ишетеп, йомшак җилләрендә иркәләнеп үскән. Тормыш авырлыкларын җиңеп алга бару, үрләр арты үрләр яулау аңа шатлык китерә. Лирик геройның «хыяллары татлы», чөнки ул туган ягының, аның кешеләренең киләчәгенә ышаныч белән карый. «Гел кояшка карый тәрәзә-

ләрең» дигәндә, «кояш» сүзе бәхет, өмет, шатлык алып килүче алдагы көн символы булып килә.

«Башка берни дә кирәкми» — С. Хәким иҗатындагы табышларның берсе. Лирик герой өчен туган җир яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Туган җире аның өчен генә кадерле, аңа гына җан рәхәте, күңел тынычлыгы бирә кебек тоелса да, алдагы строфада инде әлеге төшенчәнең киң булуы, кеше яшәеше белән тыгыз бәйлелеге турында уйлана. Лирик геройның «үзе чапкан печәнне иснәү», «үзе тапкан чишмә суын эчү», «дусларының җылы карашын тою» кебек теләкләре туган җирнең кеше яшәеше мәгънәсен билгеләүче төшенчә булуын ачыклый. «Башка берни дә кирәкми» лирик геройның соңгы теләге булып яңгыраса да, ул кабатлана һәм шуның белән каршылыкка керә. Югарыдагы фикерләргә таянып, мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: гаять киң төшенчә булган туган җирдән башка берни дә кирәкми.

«Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигырендә лирик геройның туган ягын сагыну, аңа ашкыну хисләре кузгалган, чөнки монда аның балалык эзләре калган, яшьлек мәхәббәте, хисләре, хыяллары кабынган, монда аның үзенә генә таныш «җыры» — хатирәләре бар. «Кайтам, кайтам туган якларыма» кабатланып килә һәм сагыну хисенең тирәнлеген, дәрәҗәсен белдерә. Соңгы строфадагы кабатлану лирик геройның юануы булып килә. «Юл» образы тормышны, ачылган мөмкинлекләрне, ышанычны белдерә.

«Сусау»да лирик геройның туган ягын сагынуы шундый көчле ки, ул кыр өстеннән искән җилләргә табына, чишмәләренә тезләнә. «Сусау» сүзе, күчерелмә мәгънәдә килеп, туган якка омтылу, аңа ихтыяҗ көчле булуны, бик теләүне аңлата. Ул кабатланып килә һәм әлеге сагынуның, омтылуның дәрәҗәсен билгели. Лирик герой бәхетен туган ягы, аның кешеләре, ягъни туган халкы белән бәйләп карый. «Сусаудан янган күңелгә Су салып торсаң икән» дип, лирик герой туган ягы, халкы белән бергә аралашып яшәргә омтыла, һәм ул аңа ышана да. Шуңа әлеге юллар юану да булып тора.

Шулай итеп, әлеге шигырьләрне түбәндәгеләр берләштерә: лирик геройның туган ягын сагынып яшәве үзәктә тора. Балалык, яшүсмер еллары үткән, табигате белән җанга якын җир һәркемгә кадерле. Ул безгә көч, ышаныч бирә. Лирик герой бәхетен халыкның тормышы, киләчәге белән бәйләп карый. Алдагы көннәргә ышанычы аңарда өмет уята.



Равил Фәйзуллин
(1943 елда туган)

Равил Габдрахман улы Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Татарстанның Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студент елларында ук үзенчәлекле, өметле шагыйрь буларак танылa.

Равил Фәйзуллин — 60 нчы елларда әдәбият мәйданына килеп, үзенчәлекле шигырь формасы, яңгыравыклы һәм фәлсәфи эчтәлек белән поэзиягә яңа сулыш өргән, Х. Туфан, С. Хәкимнәр буынын эстафета буларак дәвам иткән шагыйрьләрнең берсе.

Р.Фәйзуллин башлангыч чор иҗатында ук сөйләм интонациясенә нигезләнгән шигырьләре белән традицион форманы тагы да үстереп, баетып җибәрде. Шуның белән әдип Һ.Такташ, Х.Туфаннардан килгән иркле шигырь төшенчәсенең яңа мөмкинлекләрен ачты. Шагыйрь тынгысыз җанлы. Аны олы тормыш үзәгендә булган кеше шәхесе һәрвакыт борчып тора. Күңелендәге хис-кичерешләрне табигать күренешләре аша үзенчәлекле чагылдыра. «Күкне бизәкли карлыгач», «Йолдызлар» һ. б. кебек шигырьләрендә табигатькә соклану да, аннан көч алу да, матурлыкны күрергә өйрәнү дә ачык сиземләнә. Р.Фәйзуллин — фәлсәфәче шагыйрь. Әсәрләренә фикер тирәнлеге, акыл белән хис көрәше, үзенчәлекле нәтиҗәләр ясау хас. Аның «Көрәшчеләр», «Гадиләргә гимн» поэмаларында яшәү максаты һәм мәгънәсе, бәхет төшенчәләре турында бәхәс алып барыла. Әдип намуслы хезмәте белән материаль байлык тудыручы гади кешеләр алдында баш ия.

Шагыйрь лирикасында мәхәббәткә багышланган шигырьләр үзенчәлекле урын алып тора. Яшәешкә җан өргән, тормыш-

ка ямь биргән сөю хисен Р. Фәйзуллин үзе аңлаган фәлсәфи югарылыкта сурәтли. Аның «Мәхәббәт күзсез була, ди...», «Аккошлар», «Яшьлегеңне, гомереңне...», «Сөйдем аны. Шаштым!» һ. б. шигырьләрендә шашкын мәхәббәт утында янучы лирик геройның интим хисләре тормышчанлык белән үрелеп бара. Әдип мәхәббәтнең икенче ягын — сагыш, ачу, фаҗигане дә онытмый. «Яшь хатын», «Кем шакымас топлар ишеген», «Нарат» һ. б. әсәрләре әнә шундый кичерешләрне чагылдыра.

Р. Фәйзуллин иҗатында туган иле, туган халкы турында уйланулары тулы бер цикл алып тора. Бу теманы әдип халыкның фаҗигале тарихы, бөек шәхесләре, бүгенгесе һәм киләчәге, туган тел, табигатьне саклау мәсьәләләре белән бәйләп үстерә.

Яз — тереклек башлангычы. Ул табигатькә җан өреп кенә калмый, киләчәккә ышаныч-өметләр дә уята. Әдип бөек Тукайның халкыбыз тормышында тоткан урынын әнә шундый язга тиңли. Олы шагыйрьнең күңелендәге ышанычка, «кара елларда да язын җуймавына» соклана, аның бүгенге һәм киләчәк буыннарга васыятен билгеләп, «...булалган бит Илгә игелеклелек кылу үрнәге!» дип яза.

Равил Фәйзуллин бүген дә актив иҗат итә. Аның заман, ил, халык тормышына бәйле вакыйга-күренешләргә мөнәсәбәтен белдергән тирән эчтәлекле әсәрләре әледән-әле шигърият сөючеләрне шатландыра.

Ул Татарстан яшьләр оешмасының М. Җәлил исемендәге бүләгенә (1970), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә (1978) лаек булды, аңа Татарстан Республикасының халык шагыйре дигән хөрмәтле исем бирелде (1999 ел).

Сорау һәм бирем

1. Р. Фәйзуллин 60 нчы еллар поэзиясенә нинди яңалык алып килгән?
2. Шагыйрь иҗатының тематик киңлеген күрсәтегез.

ЯЗДАН АЕРЫП БУЛМЫЙ ТУКАЙНЫ!

Яздан аерып булмый Тукайны!
Язда килгән, язда ул янган.
Язы, киләчәге барлар ничек китсен,
ничек югалалсын дөньядан.

Язны җуймый кара елларда да
халыкның ул гүзәл гамьнәрен,
хыялларын чорлар аша безгә —
бүгенгегә китереп бәйләде.

Тел яшергән Тарих кына белә
бар кылганын аның, күргәнен.
Ә шулай да булалган бит Илгә
игелеклелек кылу үрнәге!

Бу тарихта мәшһүрләрне куйсаң
ул яшәгән хәлгә, урынга,
байтагының шаулы даны түгел,
чыкмас иде, бәлки, тыны да!

Яшерен һәм мәңге үлмәслеген
дәлилләргә мохтаҗмы халык?
Шикләнүче булса, кара, тикшер,
бер бәгърен — Тукаен алып!

Апрель.
Кемнәр көтми ышанулар, гөлләр,
Яшәрүләр биргән бу айны?
Яздан, гаделлектән, киләчәктән
мөмкин түгел аеру Тукайны!

Сораулар һәм бирем

1. Шагыйрь Тукайның олылыгын ничек билгели?

2. Әсәрдә Тукай бүгенге «мәшһүр»ләр белән ничек чагыштырыла?

3. «Яздан, гаделлектән, киләчәктән мөмкин түгел аеру Тукайны!» юлларын ничек аңлыйсыз?

4. Әсәрдә халыкның үлемсезлеге Тукайга тәңгәлләштерелә. Ни өчен?

5. Шигырьне ятлагыз.

ЯКТЫ МОҢ

Күчә җилдә ак комнар.
Ярга кага дулкыннар.
Акчарлаклар Иделдә.
Туган илем күңелдә.
Чык ялтырый гөлләрдә
Аяз таңлы көннәрдә.

Алтын Кояш күгемдә.
Газиз әнкәм күңелдә.
Җилкәннәрдә җил бәрә.
Ярда рәшә тирбәлә.
Рәхәт Туган җиремдә!
Сөйгән ярым күңелдә.

Сораулар һәм бирем

1. Туган ил төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз?

2. Шагыйрь туган ил төшенчәсен нинди образлар аша чагылдыра?

3. Шигырьдәге идея-фикерләрне файдаланып, «Туган җирем» темасына сөйләшү үткәрегез.

Рәдиф Гаташ

(1941 елда туган)

Рәдиф Кәшфулла улы Гатауллин (Гаташ) 1941 елның 30 мартында Башкортстанның Кушнаренко районы Марс авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Башкортстан дәүләт университетына укырга керә. Ике елдан соң Казан дәүләт университетына күчә. Аны 1964 елда тәмамлап, Мөслим районы Уразмәт урта мәктәбендә укытучы булып эшли.

Аның беренче шигырьләре Уфада «Кызыл таң» газетасында күренә башлый. Ул шигърияткә үзенең ярсулыгы, романтик хисләре һәм үзенчәлекле лирик герое белән килеп керде. Аның иҗатында мәхәббәт темасы өстенлек итә.

Авторның «Гөлләр су сорый», «Бу — сиңа кылган догам», «Кояшлы утраулар», «Диңгез эзлим», «Мәхәббәткә мәрхәмәт», «Кар астында гөлләр», «Кальбеңә хис юлласам», «Гамь шәрабы», «Мәңгелек сусау», «Шигърият, синең хакка» (мәкаләләр җыентыгы) һәм башка китаплары бер-бер артлы дөнья күрә торалар һәм халык тарафыннан хуплап каршы алыналар.

Рәдиф Гаташ соңгы елларда шәркый шигъри алымнарга, үлчәмнәргә, образлар системасына мөрәҗәгать итә. Ул, аларны туган телендә бик урынлы кулланып, татар шигъриятен өр-яңа төсмерләр белән баета.

Аның «Друзья моих друзей», «Сороковая весна» кебек тәрҗемә китаплары басылып чыкты. Шулай ук шигырьләре поляк, украин, казакъ, азәрбайҗан, башкорт, каракалпак, осетин, литва, латыш телләрендә төрле газета-журналларда, җыентыкларда дөнья күрде.

Рәдиф Гаташ «Казан утлары» журналында шигърият бүлеген җитәкли. Ул — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре һәм сәнгать эшлеклесе, әдәбият өлкәсендә Һ. Такташ һәм Ф. Кәрим исемендәге бүләкләр лауреаты.

Сораулар

Рәдиф Гаташ иҗатында үзенчәлекле яклар бармы? Алар нәрсәдә чагыла?

ИРЛӘР БУЛЫЙК!

Ирләр булыйк һәрвакыт һәм һәр адымда,
малай чакта —
уйнаганда,
күккә карап төрле уйлар уйлаганда.
Кыйналганда.
Ирләр булыйк — үсмер чакта,
беренче кат яратканда:
яшьтәш кызыңа оялып беркөн аңлатканда.
Үпкәләшеп йөрешкәндә.
Килешкәндә.
Ирләр булыйк —
якыннардан аерылганда
һәм аларны сагынганда.
Егет булгач юллар үтеп
арган чакта,
ерып булмас карурманда
калган чакта.
Куркынычның күзенә карап
барган чакта,—
тормыш таләп иткән һәр урында,
утта, суда.
Ирләр булыйк —
мәхәббәттә җиңелгәндә,
чигенгәндә,
кайгы һәм шатлык килгәндә,
мәҗлесләрдә, бәхәсләрдә...
Акыл һәм дәрт көрәшкәндә.
Вәгъдәләрдә.
Ирләр булыйк — ир булгач та,
картайгач та.
Ирләр булыйк!
Һич югында
күк гөмбәзен иңебездә
бары бер көн тотып торыйк.
Ирләр булыйк!

Сораулар һәм биремнәр

1. Автор шигырен ни өчен «Ирләр булыйк!» дип атаган? Ул кайсы очракларда ирләр булуны шарт итеп куя? Шигырь юллары белән дәлилләгез. Сез ул фикерләр белән килешәсезме?

2. Бу шигырь сездә нинди хисләр уятты?

3. Үзегезгә аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен бергәләп ачыклагыз, сүзлеккә язып куегыз.

УКЫТУЧЫ

Уч төбенә куеп Җирне гүя,
бүгенгесен аның, үткәнен
күрсәтте ул безгә... урап кайтып
күрелмәгән илләр үтәли.

Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
көрәшергә безне өндәде:
— Яратыгыз Җирне! — диде һаман,
Ләкин:
— Мине яратыгыз! — димәде.

Аңа бүген еллар аша карыйм:
көлеп басып тора күңелдә...
Ах, хәйләкәр абый!
Җирне, кешеләрне яраттырып,
яраттырган икән үзен дә.

Сораулар

1. Сезнең дә шушы шигырьдә сурәтләнгән кебек укытучыларыгыз бармы? Аларны ни өчен хөрмәт итәсез?

2. «...күрсәтте ул безгә... урап кайтып күрелмәгән илләр үтәли» юлларын сез ничек аңлыйсыз?

1960—2000 ЕЛЛАР ПРОЗАСЫ

60 нчы елларда прозаиклар үткәндә әдәбиятта инде шактый актив, әмма заман идеологиясе белән бәйле рәвештә берьяклырак яктыртылган темаларны яңарак шартларда тулырак һәм объективрак чагылдыра башлыйлар. Иң әүвәл миллитәкъдири әһәмиятле булып торган авылның тарихи борылыш чорларындагы яшәешен тулырак сурәтләүгә игътибар арта. Шул нигездә хасил булган «авыл прозасы» Г. Бәширов, И. Гази, Ф. Хөсни, А. Расих, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Баянов, М. Мәһдиев, М. Хәсәнов кебек әдипләрнең алдарак искә алынган әсәрләрен үз эченә ала. Татар әдәбиятының революциягә кадәрге милли вазифасы кабаттан торгызыла башлап, әлеге әсәрләрдә авыл язмышын милләт язмышы белән бәйләп карауга игътибар арта.

Татар прозаикларының бу чорда «иске» теманы «яңача» яктыртырга омтылулары тагын сталинизм дәверенә багышланган әсәрләрдә шактый сизелә. Мәсәлән, Э. Касыймовның «Гомер ике килми», Г. Ахуновның «Идел кызы», М. Хәсәновның «Язгы аҗаган», И. Салаховның «Колыма хикәяләре», Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романнарында, Ф. Бәйрәмованың «Кыңгырау» повестенда тоталитаризм тәртипләренең безнең халыкка китергән зыяны геройларның драматик яки фаҗигале язмышлары аша чагылдырыла.

Совет чоры әдәбиятының иң мөһим темаларыннан булган Бөек Ватан сугышын сурәтләүдә дә 60 нчы еллардан соңгы прозада кызыклы гына үзгәрешләр күзәтелә. Бердән, сугыштагы бөтенхалык батырлыгының яңадан-яңа мисалларын эзләп, Ш. Рәкыйпов, С. Шакир һәм З. Әхмәтҗанов кебек авторлар үзләре тапкан геройлар турында күп санлы очерклар һәм документаль повестьлар яздылар. Икенчедән, сугыш чорын төрле яклап, аның моңа кадәр күләгәдә калдырылган күренешләренә дә дикъкать итеп һәм солдатны төрле уй-хисләргә ия

булган шәхес итеп сурәтләүгә басым ясап яктыртуга игътибар арта. Шул нигездә совет әсирләренең дошман оясындагы тиңдәшсез көрәшен һәм катлаулы язмышларын чагылдырган әсәрләр (Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» һәм «Җимерелгән бастион», Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», Ш. Маннурның «Муса», М. Хәсәновның «Язгы аҗаган», Ә. Галиевнең «Йолдызлар шаһит» дигән роман-повестьлары) белән бергә М. Рафыйковның «Илһам авазы», Г. Әпсәләмовның «Миңа унтугыз яшь иде», Ә. Еникинең «Без дә солдатлар идек», Ә. Маликовның «Яшьлек утравым», Х. Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» һәм «Безне өйдә көтәләр» кебек сугыштагы кешене төрле яктан һәм төрле алым-чаралар ярдәмендә сурәтләгән роман-повестьлар дөнья күрә. Һәм алар укучыларга сугышны тулырак күзалларга булышалар.

Татар прозаикларының тормыш турында объективрак фикер йөртергә омтылулары тагын аларның тарихи үткәнгә, дөресрәге халкыбызның күпгасырлык тарихына игътибарлары артуга китерде. Бу үткәнне күбрәк аерым тарихи шәхесләр яшәешен һәм эшчәнлеген сурәтләү аша яктыртырга алынып, алар татар тарихын аның хәзергерәк чорларыннан борынгырак дәверләренә күчә бару юнәлешендә сәнгатьчә гәүдәләндерү белән шөгыльләнәләр. Хәзерге әдәбиятыбыз һәм гомумән халкыбыз өчен бик кирәкле бу процесс, конкрет алганда, А. Расихның «Ямашев», Г. Әпсәләмовның «Күк күкрәр», Г. Шәрипованың «Гафур гаиләсе», Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе», Җ. Рәхимовның «Батырша», В. Имамовның «Сәет батыр», Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар», М. Хәбибуллинның «Кубрат хан», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» һәм «Атилла», Батулланың «Сөембикә кыйссасы» кебек роман-повестьларында ачыграк чагыла. Соңгы вакытларда прозада үткәнне сурәтләүнең милли офыгын киңәйтү омтылышлары да күзәтелә. Татарларның бөтен дөньяга таралып яшәүләрен искә алганда бик мөһим булган мондый омтылышның характерлы үрнәкләрен И. Салаховның «Иманнар тамыр җәйгәндә» һәм Я. Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романнары тәшкил итә. Аларда Казакъстанда һәм Себердә яшәүче милләттәшләребезнең тарихы һәм гыйбрәтле язмышлары чагылыш таба.

Халкыбызның күпгасырлык үткәне белән бергә, 60 нчы еллардан соңгы прозада аның хәзерге яшәеше дә төрле яклабрак сурәтләнә. Бу яшәешне милли яссылыкта карауга игъти-

барны арттырып, әдипләр, революциягә кадәрге әдәби традицияләрне дәвам иткәндәй, күбрәк татар дөньясының борчу уята торган мәсьәләләре белән кызыксыналар. Болар исәбенә авылның хәзерге рухи-әхлакый халәте, халыкның рухи мирасына һәм табигатькә мөнәсәбәт, татар интеллигенциясенең хәл-әхвәле һ. б. керә. Гомумәдәби хәрәкәткә конкрет мисаллар китереп күзәтү ясалган бүлекчәдән күренгәнчә, мондый мәсьәләләрне прозаиклар да татар милләтенең хәзерге яшәеше һәм язмышы турында тирәнрәк уйланып яктырталар. Шул нигездә татар прозасы үзенең милли вазифасын ачыграк күзаллап эзләнә һәм үсә.

Сораулар

1. Проза жанрына нинди төр әсәрләр кертеп карала?

2. Хәзерге көндә иҗат итүче кайсы прозаикларны беләсез? Алар нинди темаларга ныграк игътибар итә?

Фатих Хөсни
(1908—1996)

Совет чоры татар әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов) 1908 елның 3 февралендә хәзерге Татарстан Республикасының Саба районы Олы Мәтәскә авылында туа. Кечкенәдән үк әдәбиятны яраткан Фатих, 1924 елда Казанга килеп М. Вахитов исемендәге мәктәптә укый башлагач, үзе дә каләмгә алына. Аның «Дөнья матур миңа» дигән беренче шигыре «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының 1927 елгы 4—5 санында дөнья күрә.

Иҗади эзләнүләрен шигърият өлкәсендә башлаган Ф. Хөсни бераздан прозага күчә һәм алга таба бөтен иҗат гомерен шушы өлкәгә багышлый. 30 нчы елларда ул күп кенә хикәяләр, авылда колхозлар төзүгә багышланган «Җир тыңлый» романын (1931) һәм танылган музыкант Фәйзулла Туишев турындагы «Гармунчы» повестен (1939) яза.

Бөек Ватан сугышы башлану бөтен әдәбияттагы кебек Ф. Хөсни иҗатында да мөһим борылыш тудыра. Ягъни ул да сугыш темасына йөз белән борыла. Биредә язучының дәвамлы командировкада булып сугышны үз күзләре белән күрүе дә зур гына роль уйный. Бу елларда ул күп кенә очерклар һәм хикәяләр белән бергә «Йөзек кашы» (1942) дигән мәгълүм повестен яза.

Сугыш җиңү белән тәмамланганнан соң, Ф. Хөсни дә иҗатында тыныч тормышка әйләнеп кайта һәм заман темасын, ягъни сугыштан соңгы авылны «Җәй башы» (1950) һәм «Авыл өстендә йолдызлар» (1953) повестьларында шул еллар рухында — күбрәк лирик-романтик пафос белән сурәтли. Авыл тормышында җитди каршылыклар яки каршылыклар тапмыйча, автор төп игътибарын геройларның шәхси яшәеш

мәсьәләләренә юнәлтә һәм аларны әле лирик, әле драматик планда хәл итә.

Ф. Хөснинең 50 нче еллар иҗатындагы иң зур уңышы булып «Җәяүле кеше сукмагы» (1957) романы тора.

Үткәндәге татар авылы, аның кешеләре хакында Совет чоры идеологиясе рухында фикер йөртсә дә, әлеге роман, гомумән алганда, авылның гореф-гадәтләрен, телен, башка рухи-әхлакый кыйммәтләрен яхшы белеп һәм хөрмәт итеп язылуы аркасында, әдәбиятта үзенә күркәм урын яулады.

Алга таба, бигрәк тә 60 нчы еллардан Ф. Хөсни татар әдәбиятында башланган яңарыш хәрәкәтендә актив катнаша. Бу хәрәкәт башлап татар халкы һәм аның әдәбияты өчен тәкъдири әһәмиятле булган авыл яшәешен һәм язмышын тирәнрәк аңлау, объективрак яктырту белән бәйләнгән иде. 50 нче еллар урталарыннан шәхес культын фаш итү нәтиҗәсендә илдә сүз ирегенә юл ачылу белән бәйле рәвештә барлыкка килгән әлеге яңарышка беренчеләрдән булып килеп кушылып, Ф. Хөсни, колхозлашу чоры авылы турында объективрак сүз әйтергә теләп, югарыда искә алынган «Җир тыңлый» романына кабаттан әйләнеп кайта һәм аны яңа заман рухында шактый үзгәртеп, «Утызынчы ел» исеме астында 1963 елда бастырып чыгара. Дөрестән дә, яңа басмада язучының күмәкләштерү чоры авылына карашы зур гына үзгәрешләр кичергәне, бигрәк тә әлеге процесска килеп эләккән кешеләрнең каршылыклы уй-хисләренең, кайчак фаҗигале дә төс алган язмышларының тулырак һәм тирәнрәк чагылдырылуы күренә. Әсәрнең уңышында Ф. Хөснинең үтә халыкчан теле дә зур гына роль уйный.

Әдипнең бу романнан соң язылган «Минем тәрәзәләрем» (1965), «Гыйльмениса» (1968), «Мәйдан» (1970), «Язмыш» (1973—1975), «Картая белмәс картлык» (1977) кебек повестьларында да реаль тормышка тагын да якынаю, шәхси күргән-кичергәннәргә ныграк таяну сизелә. Бу әсәрләр арасында Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Гыйльмениса» повесте аеруча кызыклы. Авыр сугыш елында авылдашлары хөрмәтләп үткәргән бер карчык юбилеенда журналист буларак катнашудан туган бу повестенда Ф. Хөсни, гади авыл хатынының ана вазифасына үтә җаваплы каравын тормышчан детальләрдә сурәтләп, татар хатын-кызының борынгыдан килә торган гүзәл сыйфатларын үзендә чагылдырган Гыйльменисаны хәзерге яшьләргә үрнәк итеп куя.

Сорау һәм бирем

1. Ф. Хөсни иҗатында авыл темасы нинди урын алып тора һәм ни өчен дип уйлыйсыз?

2. Ф. Хөснинең 60 нчы еллардан татар әдәбиятында башланган яңарыш хәрәкәтендә катнашуы нидән гыйбарәт?

УТЫЗЫНЧЫ ЕЛ

(Романнан өзек)

Дөнья булгач, бу салкын февраль төнендә, бәлки, бернинди гамьсез йоклап ятучылар да булгандыр, әмма Әтәчле авылында, асты өскә килгән Әтәчле авылында, белмим, кемгә карата гына моны әйтеп булыр иде икән? Монда һәр кешенең үзенчә гамемоңы бар: берәүләре гомер иткән ояларыннан сөрелергә торалар. Икенчеләре, ияләшкән-сыналган көнкүрештән аерылып, бөтенләй бүтән, әле тузаны өскә кунмаган һәм ничек булачагын әйтеп булмый торган яңа көнкүрешкә күчеп азаплана. Күчәләр, әмма башлары мең төрле шик-шөбһә белән тулы. Яңа көнкүреш, үзенең нәкъ әнә шул яңалыгы аркасында, күңелләрне чак кына өркетеп, бер үк вакытта алгысытып та, шикләндереп тә тора — бик җәннәт итеп күрсәтәләр инде күрсәтүен дә, ул җәннәтнең соң идән-сәкесе, сәкегә җәеп ятарлык мамык түшәк-ястыгы булырмы икән? Әллә югыйсә идәнгә салам түшәк җәеп кенә яткырырлармы икән? Өченчеләрен, кулларында идарә дилбегәсе булган башлыграк кешеләрне, алардан өстәрәк торучы өлкәнрәк башлыклар: «Колхозны тиешенчә җәннәт итеп күрсәтә белмисез. Өндәү-димләү эшләрегез начар бара. Колхозлашу процентыгыз бик түбән»,— дип өсте-өстенә әрләп торалар, кыскасы, кемдә генә гамь-борчу юк икән?!

Ә Нажиядә менә, үзенекеләрдән инде әллә кайчан күңеле суынган, яңа тормыш тарафыннан кабул ителмәгән Нажиядә, канат-каурыйлары ныгып җитмәс борын тормыш давылы оясыннан бәреп төшергән ул бала кошта, табигатьнең нинди середер, бүтән кешеләрнекенә охшаган баш әйләндергеч гамь сөреме юк дип әйтерлек. Инде ул барысын да белә, инде барысына да әзер, күңеле таш булып каткан, җилкенерлек бернәрсә дә күрми, шулай ук бернигә дә исе китми. Яшь ояга кушыльрга омтылып карамады түгел, кушмадылар, кушарга кирәк тапмадылар.

Үзенекеләрнең һәм, шул карт оя белән берлектә үзенең дә, Әтәчле авылыннан сөреләчәкләрен ишеткәч, аңарга хәтта бераз җиңелрәк тә булып китте кебек, әйдә, сөрә бирсеннәр. Ичмасам, берөзлексез күңелне алгысытып торучы кешедән ераграк булыр, узганда-барганда күләгәсе күзгә чалынмас, күзгә чалынмагач, күңел дә алай иләсләнмәс. Ә кем белгән, бәлки анда дөньяның бүтән кызыклары табылыр, бер Әтәчле авылында гына түгел ич дөнья...

Шулайрак уйлый иде Нәҗия. Әмма ничек кенә уйласа да, күңеле урынына утырмый, тынгы юк, өйдә буталасы килми, чыгып барыр урын тапмый, ятып күзенә йокы керер төсле түгел. Ә аяк өстендә чуалганда, өйдәгеләрнең ыгы-зыгысына кушылырга, алар белән бергәләп елашырга, әйберләр җыярга, ятларга калдырмас өчен өскә катлы-катлы күлмәкләр өяргә, киеп һәм алып бетерергә мөмкин булмаганнарын, кеше-кара күзенә бик чалынмыйча гына, кемнәргәдер илтеп томырырга кирәк булачак. Ә Нәҗия боларның берсенә дә катнашырга теләми, ник янмый шунда әйберләре...

Шул рәвешчә, ничек итеп бу соңгы төнне үткәреп бетерергә, ничек итеп таңны, иртәне җиткерергә белмичә, җанына урын тапмагандай, бер өйдән икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә күчә, ышыграк почмакта тукталып, озак-озак катып тора. Уйланып түгел, болай, бер уйсыз таш сын кебек катып тора. Шул рәвешчә, үги анасының, эш рәте белмәүче, тик кушканны гына башкарып йөрүче Шәмҗамалның, кайгы уртаклашу сылтавы белән кергән, ләкин чынлыкта исә «күңелләре һәм байлыклары купшыган чакта ничек тә булса берәр иске-москы әйберләре артмасмы?» дип хәерчеләнеп көтүче күрше-күләннең күзенә бик чалынмаска тырышып йөргәндә, Нәҗия «Яшь йөрәкләр» дигән бер пьеса китабы күреп алды. Кайчандыр каты тышлы булып та, кулда күп йөргәнлектән, тышлыгы каерылып беткән бу иске китапны Нәҗия үзе, моннан берничә атна элек, Вафин абыйсының кулында күреп, балаларча үрсәләнеп, ялынып алган иде. Әнә бит нинди кызык вакытлары да бар иде бу дөньяның! Нәҗия Сәрвәр апасы өенә качып, ян тәрәзә төбенә таяна биреп, сәгатьләр буе китап укып утыра торган иде. Кулына нинди китап эләксә шуны укый, берсен дә талымлап тормый, бөтенесеннән тәм таба, бигрәк тә сәхнә өчен язылган китапларны яратып укый иде ул. Укый иде, укый иде, ул да түгел, үги әнкәсе, кереп: «Эштән качып нишләп монда утырасың?» — дип тирги башласа, каршы бер сүз әйтмичә чыгып чаба иде.

Әмма озак түгел, җайлы форсатны туры китереп, тагын тегеләрнең күзләреннән ычкына, тагын Сәрвәр апасы өенә кереп бикләнә, мендәр астына яшереп куйган китабын тагын кулына ала, тагын ян тәрәзә төбенә янтая һәм тагын җаны-тәне белән китапта сурәтләнгән дөньяга чума иде. Әнә бит булган икән кызык чаклар, тиздән менә аларны сагынып сөйләргә генә калыр инде.

Тышлыгы каерылып беткән «Яшь йөрәкләр» пьесасы кызның күңелендәге истәлекләрне яңадан һәм бу юлы инде алда торган аерылышу моңы белән җылытып, яңартып җибәрде, димәк, хәзергә әле ташка ук әйләнеп бетмәгән икән бу йөрәк. «Котдус абый китабы. Илтеп бирергә кирәк үзенә» дигән уй килде кызга. Шундук тагын «Бәлки, үзен дә туры китерермен» дигән мавыктыргыч уй да килде, һәм шуннан соң ул кинәт канатланып киткәндәй булды. Әтисе өйдә юктан файдаланып, ул озак тормады, өстенә кыска жакеткасын элеп, башына ябасы шәлен кулына тотып, икенче култыгына әлеге «Яшь йөрәкләр»не кыстырып, арт капкадан гына тыкрыкка, ә тыкрыктан урамга чыгып чапты. Теге өйдәгеләр, үз мәшәкатьләре белән мәш килеп, кызның чыгып киткәнен шәйләми калдылар, хәер, шәйләсәләр дә берни дә кыра алмаслар иде, соңгы мәртәбә күрешеп калу нияте белән алгысыган яшь кызны тыеп калу мөмкинме соң!

Ләкин кызның җилкенүләре юкка гына булды, күрешү нияте барып чыкмады, Вафин өенә кайтмаган иде әле. Шәмсия карчык болай вакытсыз килеп кергән кызны бераз сәерсенебрәк, ләкин ачык йөз белән каршы алды. Шундук җиделе лампаның кысылган утын күтәреп куйды, өстендә кич киеп ята торган иске күлмәк кенә икәнлеген күреп алгач, карчыкларча каударланып, тиз генә өстен дә алыштырып өлгерде. Хәтта самавыр да куеп җибәрмәкче булган иде дә, Нәҗия каршы килгәч, кулына чырагачын тоткан килеш аптырабрак калды. Үзенең «Алла биргән өйдәш егете» белән бу чибәр кыз арасында ягымлы бер якынлык булганлыгын соңгы вакытларда ул сизенгәндәй йөри иде, Галләм хаҗи хәтле Галләм хаҗиның кызы тикмәгә генәме соң аңарга — авылның икенче очындагы Шәмсия карчыкка килгәләп, шул очтагы Таш-чишмәдән су китергән чакларында суын дигәндәй кереткәләп йөрер иде икән? Инде менә болай вакытсыз, бикле ишекне ачтырып, коры кул белән диярлек килеп кергәч, карчык яхшы ук ньк аптырый калды. «Әллә, Ходаем, ябышып чыгуы шушымы икән? Алай

дисәң, Котдус үзе дә бергә булыр ие. Аннары тагын кулында төенчеге-әхрәте дә күренми» дигән уйлар үтте аның башыннан.

Дөнья хәлләреннән әллә ни хәбәре булмаган, иртәгә иртә белән ике семьяның авылдан озатылачагы турында әле ишетеп тә өлгермәгән һәм, гомумән, колакка бераз саграк Шәмсия карчык өчен бу төнге сәгатьләрдә кызның егеткә ябышып чыгу ихтималыннан бүтән ихтималның дөньяда булуы һич мөмкин түгел иде, күрәсең. Әгәр инде ул уйлаганча булып, кызның, чынлап та, ябышып чыгуы шушы икән, ул аны үз кызы итеп ачык йөз белән каршыларга әзер иде. Чөнки өйдәш егетен дә бик ярата, кызы да туры килгән: чибәрлеккә дә чибәр, сүзгә-өнгә дә ягымлы, «Шәмсияттәй!» дип үлеп тора. Җитмәсә тагын, ару нәселдән, үзе дә телгә-тешкә кергән кыз түгел, карчыкның уйлавынча, менә дигән пар күгәрченнәр булачаклар.

Шәмсия карчык, мөмкин чаклы кызга якынлык хисе күрсәтергә тырышып, аны көчләп дип әйтерлек сәке йөзлегенә китереп утыртты, хәтта утырмастан элек кызның астына зурлап киез салырга да онытмады һәм, аналарча җылы күңел белән, шул ук вакытта карчыкларча кызыксынып та булса кирәк, әле теге яктан, әле бу яктан читләтеп-читләтеп кенә сорашкаларга тотынды.

— Котдусем үзе дә әйтеп утырган ие бүген иртәнчәк... үзен күрмәгән икәнсең, алайса?

Әмма Нәҗиянең рухи халәте бу кызыксынучан карчык белән җәелеп сөйләшеп утырырдай дәрәҗәдә түгел иде. Купшынган күңеленә урын тапмагандай, ул яңадан аяк-өс торып басты: карчыкның сорауларына бик үк туры да килми торган кыска-кыска гына җаваплар кайтара, шул ук вакытта борылып чыгып китәргә дә ашыкмый иде. Әйе, бу фәкыйрь өйдән, гөлләр һәм жанга ягымлы тынычлык белән тулы бу тәбәнәк өйдән һич кенә дә чыгып китәсе килми, әгәр шулай мөмкин булса, аяк өсли басып торса торыр, «Ай-һай-ла! Ник миңа урын бирмисез?» димәс, мәңгелеккә шушында калыр иде.

— Өең бик җылы икән, Шәмсияттәй... рәхәтләнеп киттем,— ди ул, карчыкның сорауларын соңга таба бөтенләй ишетмәгән дә бер кыяфәттә. Шәмсия белән сөйләшүдән дә бигрәк үзе белән үзе сөйләшкәндәй итеп әйтә. Карчык куйган сорауларны тик соңыннан гына исенә төшереп, кинәт каушап, тәне эсселе-суыклы булып китә.

— Котдус абый бит ул... чит авылныкы. Күрәм дигәндә генә күреп булмый аны тиз генә. Гел эштә, гел чаба...

Бүтәнчәрәк әйтмәкче иде Нажия, ә менә әллә нәрсә килеп чыкты. Котдус абыйсы «чит авылныкы» булып чыкты. Шәмсия карчык өйдәш егетенең чит авылныкы булганлыгын белмимени соң? Гомумән, нинди бәйләнеше бар соң бу өзек-төтек сүзләрнең? Әле генә «Өең бик җылы икән, Шәмсияттәй» иде, шундук тагын Котдус абыйсы «чит авылныкы» икән. Менә шул керделе-чыктылы сүзләрдән вакытсыз йокысы бүленгән һәм колакка саграк Шәмсия карчык нәрсә булса да аңларга тиеш. Их син, бәгыре өзгәләнгән яшь гашыйк! Озын сәфәргә чыгу алдыннан синең карамакта калган бердәнбер зәңгәр төндә шушы да булдымы инде сүз! Һәм, гомумән, «гел шулай чаба» торган үтә эшем кешесе өчен синең бу чаклы өзгәләнүең ялгышлык түгелме икән? Комсомолга да алмады бит үзеңне, тәмам таш йөрәк икән.

Хәер, моны Нажия өчен без шулай битәрләп әйтәбез. Нажия үзе Котдус абыйсына карата тары бөртеге кадәр генә дә үпкә сакламый, булмаган икән,— димәк, булмаган, китәргә икән,— димәк, китәргә. Бер Котдус абыйсы гына нишләтә алсын аны. Әйе, кыз нинди дә булса икеләнүләрне хәтта күңеленә дә китерми, кайтмаган икән — кайтмаган, чит авылныкы икән — чит авылныкы, таш йөрәк икән — таш йөрәк, әнә шул таш йөрәк хәлендә дә ул аны яратты, шул таш йөрәк хәлендә күңеленә утыртып ерак җирләргә алып китә...

Шәмсия карчык белән дә рәтләп сүзе ялганып китмәде, шулай булгач, киң күңелле карчыкның өе гәрчә бик җылы булса да, монда артык калырга мөмкин түгел иде. Инде чыгып китәргә дип торганда, Нажиянең башына кинәт шатлыклы бер уй килде, һәм ул, Шәмсия карчыктан Котдус абыйсының карандашын таптырып, әлеге үзе китерә килгән «Яшь йөрәкләр» китабының иң ахырда калган ак битенә иләс күңелендә туган бәйләнешсез уйларны ничек туры килсә шулай сызгаларга тотынды.

Шәмсия карчык, зур кызыксыну белән, кызны каршысыннан күзәтеп тора иде. Нажиянең озын керфекләре артындагы кара күзләре кинәт дымланып калды, кыз, аны-моны сиздерергә теләмичә булса кирәк, карчыкка кыры беләнрәк борылып, ашыгып-ашыгып сызгалавын белде.

— Син аңа мин язганны әйтмә, Шәмсияттәй, монда килеп йөрүем турында да әйтмә, күрсә үзе күреп укыр,— диде ул, дулкынланып чыккан йомшак тавышы белән. Китапны өстәлгә, Вафинның бүтән китаплары янына куйды да, тиздән менә

тагын әйләнеп керәчәк кеше кебек, хәтта рәтләп саубуллашып та тормыйча, ашыгып чыгып китте.

Сер сыярдай кешеләргә алдан кергәли йөрү дә нәтиҗәсез калмагандыр, бигрәк тә кичтән Мүкләк Гайфул өенә җыелып, мәчет картлары һәм, гомумән, арага керә алырдай кешеләр белән сөйләшеп куюю ярады булса кирәк. Таң белән Әтәчле авылында үзенә бертөрле, башка иртәләрдә һич сизелми торган, ыгы-зыгылы хәрәкәтчәнлек кузгалды. Кемнәрнеңдер капкалары шыңгырдап ачылды, керүче булдымы, чыгучымы — кешесе күренмәде. Гадәттәгедән иртәрәк өйләргә утлар алынды, гадәттәгедән иртәрәк мәчет манарасыннан кайсыдыр берсе бик каты сузып азан әйтте. Гата мәзин тавышы түгел, аның тавышы манарадан ерак китми иде, ә бу бөтен авылны яңгыратты. Азан тавышына ялганып тегермән очында бик яман сузып эт чинаганы ишетелде, ахрысы, кайсыдыр берсе бик иртә уяулык күрсәтеп өрә башлаган этнең әченә типте булса кирәк.

— Мин бүген тиз кайта алмам, иртәнге чәйгә мине көтмәссең,— диде Латыйп. Аягына оек-чабатасын ныклап киеп, чикмәне өстеннән пута бәйләп, кырпулы бүрекне кыңгыр салып, егетләрчә ялт кына ишеккә атлады... Әмма нәрсәдер исенә төште булса кирәк, ишек төбендә тукталып калды. Әнисе Фәрхинур түтинең, гаҗәпсенү катнаш, беркадәр шелтәле караш ташлап карап торуына һич игътибар итмичә, кире борылып килеп, ян тәрәзә өстендә кармаланып нидер эзли башлады. Нәрсә эзләгәнен үзе белгән икән, бераздан инде аның чикмән түшендә «МОПР» значогы ялтырый иде. Значоклы кешегә кырпулы бүрек килешмәс дип уйлады булса кирәк, искерәк булса да колакчын бүрек белән алыштырды.

— Кая кабаланасың болай таң тишегеннән? — дип, аптырап сорап куйды Фәрхинур түти.

— Бүген безгә — комсомолларга эш бар, әни,— диде Латыйп, эре генә. Чыгып барышлый, шаярткандай итеп өстәде: — Латыйп кына калмас ятып.

Дөресен генә әйткәндә, бераз ятыбрак калынган икән шул. Кичтән булып узган актив утырышында ул керфек тә какмыйча Галләм хаҗи йорты тирәсендә күз-колак булырга дип сүз биргән иде. Бераз җылынырга дип кенә кергән җиреннән изрәп йоклап киткән. Җитмәсә тагын, ачу китереп әнисе сорашып торган була: кая барасың, имеш. Комсомолларча биргән сүзен онытып йоклап ятканы өчен бик шәп кенә типкәләп чыгарасы урында.

Урамда барганда, Латыйпны бер-бер артлы ике кеше ашыгып узып китте: берсе — Бытбылдык Әхмәтҗан, икенчесе — Түбән очның Мүкләк Гайфул иде боларның. «Йөриләр шунда, әллә ни кырырдай булып»,— дип ачуланып уйлап куйды Латыйп. Бытбылдык Әхмәтҗан инде әллә кайчан колхозда, ә теге Түбән оч Мүкләгенең сүзәм дисә дә мөгезе юк. Елына ике гаеттән башка мәчет юлын белми торган Мүкләк Гайфулның бүген болай таң тишегеннән мәчеткә кузгалуы шулай да бераз сәеррәк иде.

— Үкчәң артка әйләнгән, Гайфулла абзый,— дип кычкырып калды Латыйп, тегене мыскыл итеп. Бу аның Мүкләкне таныганлыгын сиздерергә тырышуы иде. Ләкин мәчеткә кердеме ул әллә мәчет коймасы буеннан тыкрыкка борылдымы? Ул чаклысын шәйләп өлгермәде. Күренде Мүкләк, шундук юкка да чыкты Мүкләк. Мәчеткә якынлаша төшеп, аулаграк бер урыннан намазга килүчеләрне, мәчет буе тыкрыкны һәм Галләм хаҗилар тирәсен күзәтеп тора башлагач, Латыйп тагын да ныграк аптырап калды. Мәчет юлында мүкләк түгелләре дә шактый күп күренә иде бүген, бу оч гомумән бик ыгызыгылы иде. «Никадәр доклад сөйләнә, әллә күпме театр куябыз... Ә Алла дигәнең, җиргә үзе бөтенләй төшеп тә карамыйча, күктә торып кына болгатып ята дөньяны»,— дип, бу көфер уйлардан үзе дә беркадәр шикләнә төшебрәк, уйлап куйды Латыйп.

Аннары тагын егетне Галләм хаҗилар ишегалдында ары атылып, бире сугылып һәм ара-тирә ярсып кешнәп куючы айгыр да бераз шикләндерә калды. «Тикмә түгел, юри чыгарган карт җен. Янәсе, эзләүсез-сораусыз капкадан керүче булса, бәреп үтерсенгә». Сарайдан сирәк чыгарыла торган һәм дүрт яшенә җитеп муенына камыт кимәгән бу котырган хайванны теге вакытта да шулай чыгарганнар иде. «Актырнаклары кайда соң боларның, эт урынына атны файдаланмасалар» йокысы вакытсыз бүленгән башны аптырату өчен бу да бер табышмак иде.

Әмма маена котырган айгырның берсендә дә эше юк, ул капкага сикерә, дөньяны айкамакчы була, чыгар урын тапмагач, кешни-кешни үрсәләнергә, тояк астындагы карны тырнарга, янә атылып-бәрелеп чабарга керешә иде. Ул арада Галләмнәрнең урам буе өйләренә ут алынды, нәрсәдер карандылар гына булса кирәк, ут шундук юк булды, ә бераздан исә, ахрысы, өйалды тирәсеннән генә булса кирәк, бик ачык итеп, кистереп,

хәтта зәһәре урамга бәреп чыга торган тавыш белән кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелеп калды:

— Кирәк булса алыгыз... Миңа бернәрсәгез дә кирәк түгел.

Бу йортта бераз бил бөккән кеше, Латыйп шундук чамалады, бусы — Нәҗия тавышы иде. Күрәсең, кызга нәрсәнедер көчләп такмакчылар, кыз карыша, алмаска әйтә. Өзгәләнгән тавышына, карышып кычкырган сүзләренә караганда, аны инде болай да җитәрлек йөдәткәннәр, киенгән өстенә киенергә бер дә дәрте юк иде булса кирәк. Кыска гына бервакыт эчендә күз алдыннан узды Латыйпның: гаризасы тикшерелеп тә, үзен комсомолга алмыйча кире боргач, шулай өзгәләнгән иде кызый. Менә бит кырын килсә дә килә кешегә. Үз оясында да чукыйлар, яңа ояга да сыймый.

Ничек кенә булмасын, Латыйп башына гына сыеп бетми торган ниндидер тынгысыз иртә иде бу. Шул ук вакытта аның бу хакыйкать белән килешәсе дә килми: нишләп сыймасын? Сыярга тиеш! Комсомол башына сыймый торган эшнең булуы мөмкинме соң дөньяда?! Шушындый эшләр кубарга торган бер чакта, әллә югыйсә, значок таккан күкрәген кире борып, әнисе янына кайтып китсенме!

Әнә шундый каршылыклы уйлар белән башы каткан хәлдә, Латыйп авыл Советы председателе Гафины эзләп китте. Гафи өендә юк иде, хатыны картының бүген кунарга да кайтмаганлыгын әйтте. Авыл Советы йортына килеп кергәндә, председатель, кемнәрнеңдер җиде бабалары белән искә төшерә-төшерә, телефон аппаратын боргычлый иде. Латыйп бер читтә туктап, тынып калды. Төн йокысы йокламаган Гафи бик йончылган күренә, нәрсә булса да әйтеп, аны чыгырыннан чыгаруга караганда, сабыр гына көтеп тору, әлбәттә, хәерлерәк иде.

Сүгенү аралаш колакка кереп калган өзек-төтек сүзләреннән аның волмилиция идарәсен алырга азапланганлыгы мәгълүм булды.

Микрофонга әле өреп, әле аны бар көченә селеккәләп, телефонда бернинди кыштырдау да ишетмәгәч, күзгә күренмәгән элемтәчеләрне аты-юлы белән сүгәргә тотынды:

— Асып куйган булганнар бәләк чаклы уенчык, барысын да кубарып утка ягасы... Кара әле син аларның эндәшмәгәннәрен, сволочьларны. Мә, син яшь кеше, син чыгара алмассыңмы берәр нәрсә?

Телефон трубкасын ачу белән Латыйпка атып бәрде дә гаҗизләнгән бер кыяфәттә урындыкка авып төште. Һәм, кабала-

нып, кесәләрендә актарынырга тотынды. Тәмәкесен тартып бетергән икән, бу хәл аны тагын да ярсыта төште:

— Сезгә, братишкалар, хатыннарыгызның итәге астына гына кереп ятарга икән бу килештән, билегезгә каеш буып, сөяк саплы наган тагып йөрергә түгел.

Әмма милиция кешеләрен уптым илаһи сүгеп ташлау да файда итмәде, яшь кеше Латыйп та эш чыгара алмады. Чөнки, Мүкләк Гайфул өендә кичтән булган сөйләшенү буенча, кемдер иртүк «эш чыгарган», телефон чыбыгын өзеп өлгергән иде инде.

Телефонга тәмам ышанычы беткән Гафи, ул якка сулагай кулын селтәп, Латыйп каршына килеп басты. Элек, бер сүз дә кушмыйча, егетне башыннан аягынача усал күзләре белән бер сөзеп алды, ләкин Латыйпның күкрәгендәге значогын күргәч, беркадәр рәхимләнә төште булса кирәк, алай кинәт орылып бәрелмәде. Шул ук вакытта бик үк җебеп тә тормады.

— Йокы туйдырып чыктым диген, алайса, чибәр егет Мостафа,— дип, мыскыллап, авыз чите белән генә зәһәр көлеп куйды.— Сезнең ише йокы чүлмәкләренә ышансаң, көрәшерсең кулак белән.

Латыйп акланырга тырышып нидер әйтмәкче иде дә, председатель аңарга хәтта авыз ачарга да бирмәде.

— Сиңа партийный-правительственный бурыч шул,— диде ул, эшнең мөһимлеген күрсәтергә тырышкандай, хәзинәсендә булган русча сүзләрне кыстыргалап,— хәзер үк Теләчегә чабасың. Милициягә кереп эшне аңлатып бир. Монда безнең тамаша чыгар төсле күренә бүген. Сузарга вакыт юк, сәгать уннан да соңга калдырмыйча безнең авылга ике милиционер бирсеннәр. Булдырырсыңмы шул эшне?

— Ә нишләп булдырмаска,— дип, «МОПР»лы күкрәген киерә төшебрәк җавап кайтарды Латыйп. Җавапны шулай батыр солдатча бирсә дә, соңыннан күңеленә ниндидер бик мөһим бер уй килде булса кирәк, кинәт җитдиләнеп калды егет, хәтта төсенә дә чыккандай булды.

— Кара әле, Гафи абый, әгәренки мин анда чакта...

— Карап торырга вакытыбыз юк,— диде Гафи, кискен генә, Латыйпны ярты сүзендә бүлдереп. Әмма Латыйп та авызны ярты юлда ябар өчен ачмаган иде, кыскасы, уйнап сөйләшкәнгә бер дә охшамый иде.

— Теләчегә йөгертергә кешесен табарбыз,— диде Латыйп, җитдиләнгәннән-җитдиләнә барып,— әнә Әптерине җибәрербез. Миннән шәбрәк йөгерәчәк, ә мин... — Латыйп бу сүзләрне

аннан — яшь кешедән — һич көтелмәгән сабырлык һәм, бер үк вакытта бугазына килеп бөялгән ярсу белән әйтә, аңарга колак салмыйча мөмкин түгел иде,— ә минем, Гафи абый, монда буласым килә. Алар тозагында бер булып чыккан кеше, мин аларны борыным белән сизәм: тагын нинди дә булса тозак куярга маташмагайлары...

Бу, чынлап та, колакка керә торган сүз иде һәм Латыйп бу сүзне төшеп югалмаслык итеп әйтә дә белде. Сүзне озак сузмыйча, кечкенә генә язу тоттырып, Теләчегә Әптерине йөгертергә булдылар. Комсомолга керергә бик теләп тә, әле рәтлерәк эш күрсәтергә җае бер дә чыкмаганга аптырабрак йөри торган Әптери, бу йомыш өчен бик тә шатланып, шундук ындыр артлатып кына җил урынына чапты.

Гафи — төн кошының да борыны сизгән, шикләнүе бөтенләй үк нигезсез булмаган икән: тамаша ук чыкмаса да, шулай да һич көтмәгән гыйбрәтле хәлләр булды ул көнне Әтәчле авылында. Һәм бу Гафи уйлаганча сәгатен-минутын көттереп тә тормады. Көн яктырып, авыл инде тәмам аякка баскач, морҗалардан чыгасы төтеннәр чыгып туктагач, ишле балалы семьялар мичтә пешкән бәрәңге белән авызларын өтә-өтә иртәнге чәйне эчкәч, сугасы сәгате суккач, нәкъ алдан сөйләшеп куйган вакытка туры китереп, Галләм хаҗи йортының капкасы төбенә чанасына печәнен, паласын салган дүрт олау килеп туктады. Эшнең нәрсәдә икәнлеген барысы да чамалый иде бугай, олы-кара бик алай кызыксынырга яхшысынмаса да, малай-салай шундук җыела да башлады. Үзенең активын ияртеп, менә берзаман Гафи да килде. Тәкәллеф саклап тора торган чак түгел, эшкә керешергә кирәк, ә шулай да бикле капканы ачып, хәзергә берәүнең дә аларны сәламләп каршы алганы күренми иде. Ниһаять, Гафи кулындагы таягы белән кече капканы шакылдатырга тотынды. Ишегалды ягында серле тынлык, ахрысы, айгырны да арт капкадан гына каядыр озатканнар иде. Шакып-шакып та, эчке яктан капка ача чыгучы кеше заты ишетелмәгәч, берсенең күзенә икенчесе карашып, ничектер аптырашыбрак калдылар. Болай тик тору уңайсыз иде, капканы катырак шакыдылар, ниһаять, эчке яктан Хәзинәбикә тавышы ишетелде.

— Кем анда, Алланың рәхмәте төшкере, шулкадәр дөнья җимермәсәгез? Янмый торгандыр ич берәр җирдә?

Тавышы булды, әмма үзе капкага якын да килмәде. Галләмнекеләрнең әйтү белән үк төялеп чыгып китәргә бик алай

ашкынып тормаганлыклары күз алдында иде. Ул арада, кызыксынуларына каршы тора алмыйча, кайбер сакаллы сабыйлар да килеп туктый башлады, олаулар янында шактый гына кеше җыелды. Капка төбендәгеләр берсе икенчесенә мәгънәле генә карангалап алдылар, артык катып торырга мөмкин түгел, нинди дә булса бер чара эзләп табарга кирәк иде.

— Койма аркылы төшеп ачарга кирәк, без монда бурыч сорый килмәдек, закон кушканны үтәргә дип килдек,— диде Гафи, ачуын көчкә-көчкә генә тыеп торган хәлдә. Гафи абзыйсының авызыннан шул сүз чыгуга, Латыйп өстендәге сырмасын салып атты, су торбаларына ябыша-ябыша, мәче кебек, койма өстенә үрмәли дә башлады. Кайсыдыр аңа сак булырга киңәш итеп маташты. Әмма Латыйп мондый кисәтүләрдән узган, ул үзен дә, Галләм хаҗиныкыларны да белә, инде бу юлы да ятып калырга һич риза түгел һәм ятып калмаганлыгын авылдашларына күрсәтә алуы өчен чак-чак кына кодрәтләнгән дә иде.

— Менгәч күренер,— дип, авыз эченнән генә мыгырданды ул, биек койма өстенә мәче кебек үрмәләп,— этме безне тешләр, безме этне урталай өзеп ташларбыз.

Шулай да серле рәвештә тынып калган ишегалды ягына сикереп төшәргә бик ашыкмады, менеп җиткәч, ниндидер уенкөлке сүз тапкан булып, койма өстендә җилпенеп басып калды.

Ләкин, кайдан икәнлеген шәйләми калдылар, кинәт мылтык шартлаган тавыш ишетелде, Латыйп иңрәгән тавыш белән тик бер ухылдап кына өлгерде һәм, кулларын як-якка чайкап, атылган яшь бөркет кебек, бу якка авып төште. Дәррәү ыгызыгы купты, кызыксыну, кызгану, киңәш бирү һәм белдеклелек — барысы бергә буталды. Әгәр Гафи председатель катырак тормаса, моны тамашага әйләндерергә һәм, әллә ниләр булуы белән өркетеп, бүгенге төп эштән кешеләрне читкәрәк алып китәргә тырышучылар да табылырга тора иде. Шулай ук берьюлы кабынып китеп, кулакны шушы минутта терелә́й чәйнәп ташларга торучылар да юк түгел иде. Ярсудан кинәт кара коеп калган Гафи, бер кешегә бер сүз катмыйча, дүрт олауның берсен тиз генә борып алып килде.

Йөзеннән каны качкан Латыйп шулай да серне бирмәскә тырышкан була, аягына басарга, тагын капкага таба барырга омтыла, шул тирәдәгеләр аны култыклап алганнар, сырмасын кидерергә маташалар, болай да юка гына калган иске сырма җиңенә бәреп чыккан кан тапларына караганда, пуля Латыйпның беләгенә тигән иде булса кирәк.

— Ят чанага и кузгаласы булма,—дип боерды Гафи, кушудан да бигрәк ачулангандай итеп. Латыйпны, аның каршылык күрсәтеп маташуына карамыйча, чанадагы печәнгә сузып салды һәм, ничек тә хәрәкәтләндермәскә тырышып өстеннән басып торган хәлдә, Вафинга кычкырды.

— Хәзер үк больницага чаптыр! — Кинәт кузгалган ярсудан булса кирәк, аның тавышы карлыккан, сүзләрен әйтә алмас хәлгә җиткән иде.— Ю-ю-юып бәйләргә ки-ки-кирәк булыр элгәре!

Вафин аның авызыннан бик авырлык белән генә чыккан сүзләрне, әлбәттә, көтеп тора алмады, председатель кушып бетергәнче, алар кузгалып киткәннәр иде инде.

Тик шуннан соң гына бераз аңына килгәндәй булды Гафи. Иң элек тамаша карар өчен җыелган ачык авызларга ташланды:

— Сез нәрсә монда? Әбиегезнең килен булып төшәчәк сәгатьләре түгелдер бит? — Ул хәзер сүзләрен әйтә ала башлаган, хәтта хатын-кызларны бераз уңайсыз хәлгә куя торган кирәкмәс сүзләрне дә пулеметтан сиптергән кебек коя иде.— Сездән башка да эшләнер, ничу монда аяк астында буталырга.

Әмма халыкның таралыр исәбе күренми, киресенчә, кызыксынып килүчеләр һаман арта бара иде. Шуннан соң Гафи үзе кирәкле дип тапкан кешеләренә кул изәде дә хатын-кызларны гына түгел, суфирак ирләреңне дә кызартырлык итеп сүгенә-сүгенә капкага китте. Әмма капка сүгенү сүзләренә битараф, капка эчтән бикле, күрәсең, аны ачарга әле ашыкмыйлар иде. Бермәл аптырап калган Гафига як-яктан көч бирделәр:

— Нәрсә монда аптырап торырга, ватарга да кирәргә.

— Ватарсың ватуын, ә соңыннан җавап бирергә кирәк булса?

— Алар җавап бирүдән курыкмадылар,— диде Гафи һәм бар көченә кече капкага китереп типте. Капканың бер тактасы урталай сынып чыкты, ишегалдындагы ата каз каңгылдап тавыш биреп куйды, ләкин кеше затыннан берәү дә күренми иде.

Капка ватыгыннан күз төшергәләп, хуҗаның үзен көткәндә, һич истә-оста юк кеше, аш өе ишегендә баштанаяк киенгән Нажия күренде. Өйдән кинәт кабаланып чыкканлыктан булса кирәк, ул аяк астына килеп чалынган зур ак песинең тәпиенә китереп басты, теге чырылдап кычкыргач, песине кулына алып берничә мәртәбә сыпыргалады да өйалды ишегеннән кире эчкә

кертеп җибәрде, калын киенеп чыккан булуга карамастан, гаҗәп бер җитезлек белән ата казны лапас астына куды һәм, ниһаять, килеп капканы ачты.

Капканы ачты, әмма үзе капкадан кире ишегалды ягына үтмәде. Күрәсең, ул өеннән соңгы мәртәбә, инде бөтенесенә әзер булып чыккан, аның өчен хәзер нәрсә булса да барыбер иде. Бу бай нигезнең калуына бер дә исе китми, хәтта авылына да, хәтта кешеләренә дә исе китми, хәтта бу авылдан китүенә беркадәр шатланган да кебек күренә иде.

— Әти өйдә юк, мәчеттән — иртәнге намазга киткән җиреннән кайтмады,— диде ул, олауларга таба үтешли. Һәм кире борылып, мондагыларны бераз мыскыллаган тавыш белән өстәде: — Кереп култыклап ук алып чыкмасагыз, үз аяклары белән чыкмас ул.

Олаулар янына килде дә, кайсысына утырырга икән боларның дигәндәй, чаналарның әле берсенә, әле икенчесенә карангалап алды, аннары, үз санын үзе туп кебек чөеп бәргәндәй итеп, чана башындагы коры печәнгә чумды. Җайлап-нитеп тормады, атка таба карап түгел, артка таба карап утырды да, кара калын шәленә төренеп, кулларын һәм йөзен шәл астына яшерде. Аның үпкәләү һәм нәүмизлек белән тулы күзләре генә, менә-менә түгелеп китәрдәй булып, шәл астыннан елтырап күренә иде.

Ул арада мәчет юлында карт хаҗи үзе күренде. Мәчеттән, чынлап та, култыклап алып чыктылармы аны, әллә үзе чыктымы? — ничек кенә булмасын, әнә ул ашыкмыйча гына атлап өенә таба кайтып килә, чукмар башлы яшел таягы, һәрвакыттагы кебек, бу юлы да үзе белән, хәтта үзеннән бераз алгарак та ашыга кебек. Әйтерсең дөньяда берни дә булмаган, булачак та түгел, әйтерсең гадәттәге иртәләрнең берсе, менә ул иртәнге намазны укып, тынычланып, кайтып керер дә хатынына чәй табыны әзерләргә кушар...

Әмма бу аның тышкы күренеше генә шулай булган икән, эчтән ул барысын да үзенчә эшләргә план корып кайтып килә, имеш. Капка төбендә олаулар көтеп торганны күргәч, кинәт ул туктап калды, як-ягына каранталады, аннары үзе артыннан мәчеттән чыгып килүче картлар төркеменә борылып, ялварган тавыш белән көйләп-көйләп такмакларга кереште:

— Шулаймыни инде, җәмәгать? Сабый бала өммәтендә калган карт бер бәндәгезне илдән сөрәсезмени? Уйлап карагыз, кемгә нинди зыяным тигәне булды икән минем?

Шуны гына көткән кебек, аның артыннан килә торган төркем кинәт туктап һәм, сарык көтүедәй, бер җиргә укмашып, беравыздан диярлек кычкырып тәкбир әйтә башлады. Урам кинәт гөжләргә тотынды, олауга җигелгән атлар, нидер сизенгәндәй, колакларын шомартып, пошкыргалап куйдылар.

Ул арада, тамаша карарга чыккан кебек кенә булып, теге капкадан да, бу тыкрыктан да хатын-кыз халкы күренә башлады. Берәү, икәү, унау, егерме... Өстенә ни эләксә — шуны элгән, кулына ни эләксә — шуны тоткан. Табагач, ипи көрәге, юллык пумаласы... Кыскасы, тамаша карарга гына чыккан кешеләр түгеллеге әллә кайдан сизелеп тора иде. Һәрвакыттагы кебек, хатын-кызлар баштарак читтән-чаттанрак остарып тордылар, берсе янына икенчесе килеп, аны-моны бер дә белмәгән-ишетмәгән кыяфәт белән сорашырга тотынды, икенчесе янына өченчесе килеп кушылды, шау-шу ускәннән-үсә барды. Хәзер инде аларның нәрсә дип болай шаулашуларын аерып та булмый, урамны тоташ гөжләү — тәкбир һәм хатын-кыз чыр-чуы баскан иде.

Гафи бермәл юк булып торды, ахрысы, абзар-кура арасында эзләнеп, әлеге теге мылтык белән шаяручы кешене сөйрәп чыгармакчы булып йөрде булса кирәк. Әмма эзләнүе нәтиҗә бирмәгән, җитмәсә, тагын монда да ире-хатыны, бигрәк тә хатын-кыз, яхшы ук кызып өлгергән, аларны хәзер коры сүгенү сүзләре белән генә өркетеп булырлык түгел иде.

Шул арада берсенең, күкле-яшелле тавыш белән:

— Ирләр ачык авыз шул бездә, менәтрәк савалар шуңа сава алганчы. Янәсе имеш, бер аягы җирдә, икенчесе гүрдә торган кешене, әче таң белән дигәндәй, тот та авылдан сөр. Кайдан чыккан эш бу? Кем күргән мондый тамашаны моңа тиклем?— дип көйләп-көйләп такмаклаганы аермачык ишетелеп калды.

Аңа бүтәннәре кушылды.

— Әйтмә дә, сөйләмә дә. Ат карагымыни кеше? Ат карагын да тикшермичә-нитмичә генә Себер җибәрмиләр ие элгәре.

— Ичмасам, кешегә ашап-эчәргә, туган-тумачалары белән бәхилләшергә ирек бирсеннәр икән.

— Ил каршы килсә, пычагымны да кыра алмаслар. Ил белән каршы торырга, бирмәскә кирәк хаҗи абзыйны.

— Изге юлда җан фида, әйдә, ахирәт, киттек. Капкага, хаҗи абзыйның үзеннән гайре, берәүне дә якын җибәрмибез.

Баштарак читтән-чаттанрак кодрәтләнгән хатын-кызлар, ишәя төшкәч берьюлы батыраеп, яңгырдан сөрлеккән көтү

кебек, Галләм хаҗиларның капкасы янына ябырылдылар һәм, ата улны, ана кызны белмичә, һәрберсе үзенчә остарырга, гөжләргә тотынды:

— Бирмибез хаҗи абзыйны. Бирмибез булгач бирмибез.

— Авылга сыймаган килмешәкләр үзләре чыгып китсеннәр, басу капкасы ачык.

— Кари кешенең каргышы төшүе бар, авылыбызны җир йотар, Алла сакласын.

— Кер, хаҗи абзый, өеңә. Кер дә биклән. Җил, яңгыр тидермәбез.

— Чәчем озын, акылым кыска: миңа ут та юк, суд та юк, яныма килеп кенә карасыннар...

Эш болай зурга киткәч артык аптырап торырга вакыт калмаган иде, Садри белән Гафи председатель икесе ике яктан тиз генә килеп картның колагына нәрсәдер әйттеләр, шау-шусыз гына аңлатырга тырыштылар. Әмма карт, аларның сүзен чүпкә дә санамагандай, артындагы төркемгә әйләнеп бер карап алды да, дога кылгандагы кебек кулларын күтәреп, яңадан тәкбир әйтә башлады. Төркем дә аңарга кушылды, урам тәкбир тавышыннан янә бер гөрләп алды. Артык түземлеге калмаган кызу канлы Гафи, бөтен тавышларны берьюлы басарга теләгәндәй, җан ачуы белән акырып җибәрде. Төркемдәгеләргә һәм капка төбендә җыелып торган хатын-кызларга хәзер үк таралырга, өйләренә кайтып китәргә кушты. Соңыннан бу кешеләрнең үзләре өчен яхшы булмаячагын аңлатып куркытып та карады. Әмма әллә ни файдасы тимәде. Киресенчә, эшнең мондый әйләнеш алганлыгын күреп, кешеләр, таралудан бигрәк, һаман җыела, шау-шу көчәя бара иде.

Шушы форсаттан файдаланып, Галләм хаҗи янә үз тирәсендәге төркемгә борылды, янә кулларын өскә күтәрде.

— Тәкъдирдә шулай язылган икән, ни күрсәк тә Ходай эше. Ягез, алайса, җәмәгать, озын сәфәргә чыгу алдыннан туган туфрагыма маңгаемны орып, бер-ике рәкәгать намаз укып алырга рөхсәт итегез. Хаҗ юлларында, сусыз чүлләрдә интегеп исән-сау әйләнеп кайткан кари бер бәндәгезне, бүген килеп, хозурыгыздан сөрәсез икән.

Ул сүзләрен әйтеп бетермәде, баскан урынында кычкырып камәт төшерергә, намазга кереште. Бу юлы аңарга иярүче булмады, күрәсең, аек баштан берәүнең дә карлы урамга маңгаен орасы килми, аннан да бигрәк Гафи председательнең кисәтүе колакларына кереп калган, «арты хәерле булмас моның»

дип шүрлиләр иде. Әмма шулай да урам уртасында болай «ят та тор» ясап азапланучы картны карап тору кызык, бигрәк тә яшь-җилкенчәк, бала-чага этешә-төртешә һаман эчкәрәк үтәргә маташа иде.

Галләм хаҗиның «ике рәкәгать» кенә дип башлаганы озынга китте, бу эшнең ачыктан-ачык күз буяу өчен булганлыгын барысы да күреп тора иде. Олау белән килгән бер егет, ниһаять, чыдамады, кемгә булса да атап әйтмәсә дә, шактый үткәзә торган итеп ярып салды:

— Кызыгы китте бу тиятрнең, егетләр. Атларны көттермәгез, кузгаласы булсак — кузгалыйк. Әгәр хаҗиның тиятре сезгә бик ошый икән, карап тора бирегез, мин атымны борып алып китәм.

— Укып бетерсен, бәлки ул бичараның бу авылда соңгы намазыдыр.

— Башың яшь әле синең, Кыйбый.

— Шаулама, әнә бетерергә чамалый.

— Чыдаса да чыдар икән маңгай.

— Көлмә кешедән, үлгәч эссе таба ялатырлар.

— Әллә илне ташлап китү бик ансат дисеңме?

— Намаз түгел бу, терәтергә маташу безнең ише ачык авызларны.

Җыелган халык яхшы ук нык гөжли башлаган иде дә, ул арада ат менгән ике милиционерның бу якка таба чабып килүен күргәч, «эссе таба ялату» белән өркетүче кешеләр кинәт шып булдылар. Җитмәсә тагын, милиционерларның берсе, төркем тирәсенә якынлаша төшкәч, һавага таба шартлатып бер атып та җибәрде. Күрәсең, Әптери-беркатлы «тамаша чыгар төсле күренә» дигән сүзләрне анда баргач тагын да куертыбрак аңлаткандыр, аннары тагын шулхәтле җирдән ат пешереп чабып килеп тә кызык өчен бер шартлатып та куймагач, күңелле буламыни ул.

Галләм хаҗиның алдан әзерләп куйган иярченнәре һәм аларның пумала, табагач күтәреп чыккан хатыннары, бу юлы инде тәкбир әйтеп тормыйча гына, төрлесе төрле тизлек белән өйләренә чаптылар. Олаулар тирәсендә бары тик курку белмәс малайлар гына калды. Төялә башлагач, хәер, озакка сузмадылар. Хаҗи белән хатыны Хәзинәбикә ташып өлгермәгән әйберләрен комсомоллар ташышты. Әмма чана түренә кереп, калын шәл белән төренеп утырган Нәҗия әйбер дип селкенеп тә карамады. Берәүгә бер сүз катмыйча, берәүгә бер күтәрелеп

карамыйча, шәл астыннан уйчан гына карап утыра бирде ул. Әйтерсең лә аның өчен бу һич тә сөрелү түгел, тәнне һәм күңелне басып яткан нindидер албастыдан котылу гына иде. Тик менә бер генә нәрсә борчыды кызны: «Ник соң Котдус абый күренми? Киткәндә кул биреп күрешеп калу өчен, ник чыкмаган ул? Әллә югыйсә кулак кызының кулы йогып калыр дип курыктымы икән?»

Сораулар һәм биремнәр

1. Салкын февраль төнен Әтәчле авылы халкы нинди хәлдә үткәрә? Шушы хәлне сөйләп бирегез?

2. Үзләренең авылдан сөреләчәкләрен Нажия ничек кабул итә? Аның авылдан куылыр алдыннан соңгы төнне ничек үткәрүен үз сүзләрегез белән тасвирлап бирегез.

3. Шушы төндә Нажия ни өчен Вафин янына бара?

4. Галләм хаҗи гаиләсенең авылдан ничек сөрелүен әңгәмә рәвешендә сөйләп бирегез. Әсәрдә сурәтләнгән бу күренешкә үзегезнең мөнәсәбәтегезне белдерегез.

Ибраһим Гази
(1907—1971)

Совет чоры татар прозасының күренекле вәкиле Ибраһим Гази (Мингазиев Ибраһим Зарифулла улы) 1907 елның 7 февралендә хәзерге Татарстан Республикасының Кама Тамагы районындагы Олы Карамалы авылында крестьян гаиләсендә туа. Ятим калганнан соң, 1919—1924 елларда Тәтеш балалар йортында тәрбияләнә. 1924 —1926 елларда Казандагы партия-совет мәктәбендә укып, алга таба ул комсомолның төрле оешмаларында эшли. Шул вакытларда ук әдәби иҗат белән дә кызыксына башлый. Беренче адымнарын шигърият өлкәсендә ясаса да, алга таба И. Гази прозага күчә. Аңлашыла ки, аның иҗади эзләнүләре шул чор рухында була. Ягъни ул беренче очеркларыннан алып заман тормышын һәм кешеләрен совет идеологиясе кысаларында сурәтләп килә.

И. Газины язучы итеп таныткан беренче әсәрләре — «Көмеш сулы Нурминкә» хикәясендә һәм «Бригадир кыз» повестенда ул, комсомол эшендә күргән һәм кичергәннәренә нигезләнеп, шул вакыттагы яшь буын яшәеше мәсьәләләрен күбрәк романтик-лирик планда яктыртырга алына.

Сугыш елларында фронтта хәрби журналист булып һәм алгы сызыкта күргәннәренә нигезләнеп, ул совет кешеләренең сугышчан һәм рухи батырлыгын чагылдырган очерклар һәм хикәяләр яза. Алар арасында иң уңышлыларыннан булган «Алар өчәү иде» (1944) хикәясендә һәм сугыштан соң тәмамланган «Без әле очрашырбыз» (1947) повестенда, үз геройларын традиция буенча каһарман итеп сурәтләү белән бергә, автор аларның яу кырында да төрле уй-хисләр белән яшәүче шәхесләр булып калуларын ачуга да дикъкать итә.

Иҗатының аеруча әһәмиятле чоры булган 50—60 нчы елларда эзләнүләренең колачын бермә-бер киңәйтеп, И. Гази

сугыштан соңгы авылга багышланган «Алмагачлар чәчәк ата» (1950) повестен, нефтьчеләр турында беренче күләмле әсәр булган «Гади кешеләр» (1955) романын, үзенең балалык еллары гәүдәләндергән «Малайлыкта кунакта» (1966) дигән автобиографик повестен һ. б. яза. Әдип иҗатының төп китабы булып исә «Онытылмас еллар» трилогиясе тора. 40 елга якын вакыт эчендә язылган бу әсәр жанры буенча автор тарафыннан «повесть» дип билгеләнсә дә, чынлыкта тормышны киң колачлавы, сюжет-композициясе белән роман-эпопеяны хәтерләтә. Анда сүз беренче бөтендөнья сугышыннан алып 30 нчы елларга кадәрге каршылыклы да, катлаулы да булган тарихи чорда татар халкының язмышы турында бара. Әдипнең дөньяга карашлары шул вакыттагы совет идеологиясе белән бәйләнгән булуы сәбәпле, әсәрдә сурәтләнгән чор да нигездә әлеге идеология рухында яктыртыла һәм бәяләнә. Ягъни трилогиянең төп конфликтын Октябрь революциясе тудырган яңа система белән иске капиталистик система арасындагы көрәш тәшкил итә.

Трилогиянең өч китабын үзара бәйләп торган үзәк герой Хәлим образында (аның прототибы булып язучы үзе тора) Совет чорының иң мөһим идеяләреннән берсе — революция тудырган яңа кеше идеясе чагылыш таба.

Гомумән алганда, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Онытылмас еллар» трилогиясендә И. Гази үз чоры идеологиясе кысаларында татар халкының искә алынган тарихи чордагы яшәешен шактый колачлап яктыртуга ирешә, һәм бу әсәр Совет чоры әдәбиятында күренекле урын яулады.

Сораулар

1. И. Газиның балачагы нинди була, һәм ул аның иҗатында ничек чагыла?

2. Ни өчен «Онытылмас еллар» трилогиясе әдип иҗатының төп китабы булып тора?

ОНЫТЫЛМАС ЕЛЛАР

(Повестьтан өзек)

Шәрифҗан, ай буе авылдан авылга чабып, сабан җирләрен кысыр калдыртмау артыннан йөрде дә бүген менә шәһәргә кайтып бара. Язгы әче җилләрдән бите кирпеч төсенә кереп кызарган, яңакларын кара сакал баскан, тырнаклары җиткән. Чыраенда кырыслык һәм усаллык тагы да арта төшкән.

Иртә белән үк болытлар бик салынкы иде, яңгыр буласы күренеп тора иде. Шулай да Шәрифҗан юлга чыкты. Төшкә таба каты җил кубып, атның ялын туздыра, койрыгын бер якка каера башлады. Ахырда җил шулхәтлегә җитте, кошлар, оча алмыйча, җиргә сыена, кантарлар артына поса башладылар. Ул да түгел, яңгыр тотынды. Аның салкын камчылары Шәрифҗанны гел уң яктан чыбыркылап торды. Ат, Шәрифҗан тарткан якка бармыйча, җилгә ян белән борыла иде.

Җир йөзендә табигать шулай котырынса да, яңгыр шулай дуласа да, сабан тургайлары барыбер шашынып сайрыйлар иде. Шәрифҗан, суга манып алган кебек чыланса да, елмая-елмая, тургайларны тыңлап кайтты. Юлда су биянең тубыкларына җитте. Иңкү җирләргә болганчык гөрләвекләр чапты.

Ләкин җилнең баягы куәте беткән иде инде. Ул, тагын берике тапкыр гайрәтләнеп, атның койрыгын йолкып-йолкып карады да, юл буендагы урманга кереп, кинәт юк булды. Яңгыр иренеп кенә тамгалый, бераздан ул бөтенләй туктады. Болытлар арасында, чәчәкле көнбагыш башыдай, кояш күренде. Бераздан болытлар офыкка иңеп, кояш берүзе күк йөзенең баш хуҗасы булып калды.

Ияр өстендә чайкала-чайкала әкрен генә кайтып барган Шәрифҗанның киемнәреннән кайнар пар күтәрелә башлаган иде. Шундый ук җылы пар яшәреп килгән сабан басуларыннан да, анда-санда яңгыр суы җыелып калган юл өсләреннән дә рәшә төсле җем-җем итеп күтәрелә иде.

Шәрифҗан, тирбәлеп кайта-кайта йокымсырап китеп, чак кына ияр өстеннән мәтәлеп төшмәде. Йокы белән көрәшә-көрәшә, байтак шулай чайкала-түнә кайтканнан соң, ул, аягын өзәңгедән чыгарып, җиргә сикерде. Буыннары язылды, йокысы ачылды, дөньяның матурлыгына күзләрен тутырып карый ала башлады. Гүя бөтен Казан губернасының тургайлары аның баш очына җыелганнар, тургай тавышыннан басу өсте гөр итеп тора. Ә игеннәр күзгә күренеп үсәләр кебек. Шәрифҗан карабодай чәчелгән җир кырыена чүгәләде дә кына гөле төсле кызыл сабаклы шытымнарга текәлеп карап калды. Бер урында юеш туфрак кыймылдап китте, һәм Шәрифҗанның күз алдында туфрак астыннан кызгылт яфрак очы килеп чыкты. «Ах, сине! — диде Шәрифҗан, яфракка таба сузылып,— соңга калмыйм дип кабаланасыңмыни, туфракларны күтәреп-күтәреп атасың!..»

Шәрифҗан карабодай шытымы белән шулай сөйләшкән арада, биясе инде шактый юл алган иде. Шәрифҗан куып җитеп атланды да яңадан ияр өстендә салмак кына тирбәлә башлады.

Ул төнлә белән генә кайтып егылды. Бик арыган булса да, тынычсыз йоклады. Гомер булмаганча, төнлә эчәсе килеп уянды. Иреннәре көйгән иде. Тәне кызу, аркасы чемер-чемер итә... Тиф булмасын дип курыкты. Ревкомга шалтыратып, үзенең авырып кайтуын әйтте. Якуп әле һаман авылларда икән. Көндез Чекадан дежурный килеп чыкты. Ул хатлар алып килгән иде. Шәрифҗан, Федяның кулын танып, конвертны шатырдатып ертты, хатка чумды. Аның йөзе бер ачылып, яктырып китә, бер сүрелә, карала иде. Ахырда ул, тезенә йодрыгы белән сугып: «Ах, Федя, Федя! Башсыз! — дип кычкырып җибәрде.— Ә шулай да мин сине яратам! Молодец!»

Федя үзенең батырлыкларын яза, Уфа каласына якынаеп киләбез, эшләр болай барса, көзли Колчакка панихида укыячакбыз, ди.

Фронтта үлем белән янәшә йөрүчеләр турында уйласа, Шәрифҗанда уңайсызлану, оялу хисе туа иде. Гүя барлык кеше җиң сызганып урак урганда, ул читтән генә карап йөри. Гүя теге кешеләр аның хакында: «Әнә эшлексез, әнә дезертир!» — дип әйтәләр кебек. Федюшкинның чак кына үлем тырнагына эләкми калуы турында укыгач, Шәрифҗанның күңелен нидер тырнап тора башлады. Федяның үлә язып калуында ул, ягъни Шәрифҗан, гаепле кебек иде. Федя анда кан түгеп йөргәндә, нигә Шәрифҗан монда тыныч кына ята? Кешеләр үлгәндә, монда ятарга аның ни хакы бар?

Хатлар алып килгән дежурный әле китмәгән икән. Ул Шәрифҗанның уйларын бүлде:

— Ике көн рәттән сине нindидер бер кыз-хатын сорый.

— Беләм мин аны,— диде Шәрифҗан,— әйтелгән бит инде аңа, тикшерү бетмичә, ире белән күрешүне өмет итмәсен. Килеп тагын йөдәтсә, шулай диярсең!

— Ул хатын түгел бу, нindидер симпатичный гына авыл кызы.

— Авыл? Нindирәк кыяфәтле?

Дежурный «симпатичный» кызның кыяфәтен сөйләп бирде. Шәрифҗан яткан җиреннән сикереп торып утырды. Әллә Мәгъсүмәме? Ләкин дежурныйның сөйләвенә караганда, Мәгъсүмәгә бик үк охшап җитми иде.

— Тагын килсә, миңа шалтырат, яме? Тукта, миңа доктор җибәрт.

Дроздов килеп, Шәрифҗанга салкын тигән дип тапты, банка салды, бер-ике көн чыкмаска кушты.

Икенче көнне, төш аугач, Чекадан шалтыраттылар. Телефонда... кем соң бу? Мәгъсүмә! Шәрифҗан шундук киенмәкче, Чекага бармакчы булды. Шәрифҗанның авырып ятуын белгәч, Мәгъсүмә: «Рөхсәт итсәгез, үзем кереп чыгам»,— диде. Рәхим ит, керә күр!

Шәрифҗан көзге кыйпылчыгына карады. Абау сакалы! Торып тизрәк кырынырга утырды. Мәгъсүмә үзе аның янына керә... Бу соң теге күзләрен күтәреп туры карарга да тартынучы Мәгъсүмәме? Юк, чынлап та, Мәгъсүмә булдымы соң бу?

Бервакытта да әле аның Мәгъсүмә белән очрашыр алдыннан болай дулкынланганы юк иде. Өч атна пәке тимәгән кара сакалын Шәрифҗан ялт кырып атты. Идәндә аунап яткан итекләрен карават астына тыкты. Иске чалбарын матрац астына кыстырды. Урындыкларны төзәткәләп куйды. Аннары урынына ятып, юрганын иягенә кадәр тартты да көтә башлады.

Инде кызга килеп җитәргә дә вакыт иде. Ә ул әле юк. Шәрифҗан берничә тапкыр ымсынырга да өлгерде: өйалды ишеге шыгырдап ачылган кебек. Мәгъсүмә анда кем беләндер сөйләшә кебек тоелды. Ләкин Шәрифҗанның бүлмәсенә килүче, ишеген шакучы булмады. Шылт иткән тавышка да колак салып, борчылып, зарыгып көткәнгәме әллә авыргангамы, битләре яна иде. Ул бер сәгать, ике сәгать шулай дулкынланып көтте, ахырда, көтүдән тәмам арып, «кайсыдыр шаяртты» дигән карарга килде. Әмма нинди хатын-кыз аның белән шулай шаярып сөйләшә алсын?

Шалтыратучы кеше, чынлап та, Мәгъсүмә иде. Ул, капка төбенә килеп җиткәч, кире борылып китте, керергә кыюлыгы җитмәде. «Шәрифҗан абыйның әллә ни уйлавы бар, керәм дип ник әйттем?» — дип, юл буе үзен шелтәли-шелтәли килгән иде.

Әнә ул Иделгә таба китеп бара. Өстендә озын зәңгәр күлмәк, билле кыска жакет. Атлаганда итәк астыннан кечкенә кара ботинкалары күренеп-күренеп кала. Ирләр аңа борылып-борылып карыйлар. Мәгъсүмәнең елкылдап торган кап-кара күзләре барлык кешене (хәтта хатын-кызларны да) җәлеп итә иде. Шәрифҗан да, кышлый беренче тапкыр очрашкач, аның шушы матур күзләренә гашыйк булды. Соңыннан исенә

төшергәндә дә, шушы зур кара күзләр егеткә бер дә тынычлык бирми иде. Сап-салкын мәктәп... Иңбашларына мамык шәл салган яшь кенә мөгаллимә... Суыктан бичараның тырнакларына кадәр күгәргән. Ә күзләре... сихерле иде кызның кара күзләре...

Мәктәпне авыл контрлары ут төртеп яндыргач, Мәгъсүмә Сараланда өч көн качып ятты да аннары Зур Каенлыктагы кардәшләренә китте. Шәрифҗанның, авылга килеп, үзен эзләп йөрүен ул ишеткән иде һәм бик сөенгән иде. Шәрифҗан турында ул еш уйлады. Гомер Чекада эшләмәс, гел генә кеше атып йөрмәс дип, Шәрифҗанны инде үзенең бик якын кешесе итеп, хәтта булачак ире кебек итеп тә уйлаштыра иде. Шәрифҗан абыйсы бит инде берничә тапкыр: «Чык миңа!» — дип, кыстап карады. Мәгъсүмә хәзер тик бернәрсәдән генә курка: әти-әнисе чыгарга рөхсәт итмәсләр, ә Мәгъсүмәнең ата-ана хәер догасыннан башка кияүгә чыгасы килми, бәхетсез булырмын дип курка... Ул монда әти-әниләре янына авылга кайтышлый гына туктаган, бер уңайдан шунда Шәрифҗан абый белән дә күрешеп китәрмен дип уйлаган иде. Дөресрәге, Шәрифҗан абый суынмаган микән дип, үзенчә тикшермәкче иде ул. Керергә бик әйбәт сылтау да була торып, керергә базмады.

Элек калага килгәндә, Мәгъсүмәгә кала ят булып тоела торган иде. Кешеләре караңгы чырайлы, үзләре гел каядыр ашыгалар. Эчә торган суларыннан керосин тәмнәре килә. Мәгариф бүлегендә йомышын тиз генә йомышлый иде дә тизрәк кайтып китәргә ашыга иде. Бу юлы шәһәр кызның күңеленә ошап куйды. Гүя гомер буе шушы таш йортлар арасында яшәгән. Бигрәк тә менә бу урам, Мәгъсүмә кайтып бара торган туры яшел урам матур. Чыгарып арканлаган бозаулары, чирәм чемченүче казлар, җир ертучы дуңгызлары, капка төбенә чыгып утырган, картаеп беткән картлары, карчыклары белән Мәгъсүмәнең күңеленә бик якын Шәрифҗан абыйсы тора торган урам.

Квартирына кайтса, дүрт стена эчендә утырып хәзер анда ни бар? Урамда, ичмаса, тормыш гөрли! Пароход карарга дип, Мәгъсүмә Иделгә төшә торган урамга борылды. Ни өчен икәнен тел белән әйтеп бирә алмаса да, күңеле белән сизенә: кермичә ул яхшы итте. Тик менә керәм дип кабалан вәгъдә итеп ташлавы гына начар булган. Хәзер инде Шәрифҗан абыйсына берәр нәрсә ялганларга туры киләчәк.

Мәгъсүмә Идел тавына килеп җитте. Пароход-мазар юк, ә су өсте вак көймәләр белән тулган иде. Ишкәкләрдән чәчрәгән

су тамчылары кайвакыт ялт-йолт кабынып китә иде. Кыз, итәкләрен җыештырып, яр буена утырды. Аның күңеле бүген барлык нәрсәне яхшы итеп кенә күрергә тели. Су буенда йөрүче әнә теге ак фуражкалы кешеләр дә бик әйбәт кешеләрдер, Идел эченә көймә белән кереп баручы әнә теге егет белән кыз бик бәхетлеләрдер, яр астындагы әнә теге сыңар тәрәзәле йортта яшәүчеләрнең дә тормышлары үзләре өчен бик матурдыр... Мәгъсүмә, күңел сафлыгыннан кулларын кояшка таба сузып: «Их, рәхәт тә соң дөньяда яшәү!» —дип әйткәнен сизми дә калды.

Тезләрен куллары белән кочаклап, битен тез башларына куйды. Якында гына ниндидер ялгыз сары чәчәк, ялкын төсле чәчәк үсеп утыра иде. Күз карашы шул чәчәккә төште. Мәгъсүмә сузылып аны өзмәкче булды, ләкин кулын шундук кире алды. Яшәсен! Сары күзләре белән кызга карап торган ялкынчәчәк: «Тимә син миңа, минем шушында дөньяның матурлыгына сокланып утырасым килә»,— дип әйтә кебек иде.

Бер кочак ап-ак шомырт чәчәкләре тоткан бер кара малай узып бара икән. Мәгъсүмә, сүзсез генә елмаеп, аңа таба кулын сузды. Гаҗәпкә каршы, малай бер уч шомырт чәчәге тоттырып китте. Күңеле кебек керсез ак чәчәкләрдән бик тәмле ис аңкый иде.

Кинәт... Эчләргә салкын шом салып, шәһәр өстендә чаң үкерә башлады. Баң! Баң! Баң!.. Мәгъсүмә куркып урыныннан сикереп торды. Нәрсә бу? Әллә дошман киләме? Әллә шәһәргә ут каптымы? Кешеләр йөгерешкән якка Мәгъсүмә дә йөгереп китте. Чаң авазы кешеләрне чакыра, кешеләр урам буйлап чабалар, ләкин ни булганын белмиләр. «Ник чаң сугалар? Нәрсә яна?» — дип, бер-береннән сорашалар. Мәгъсүмә йөгерде-йөгерде дә арып туктады. Чәчәкләрен учына кысып тоткан, ләкин чәчәкләре барлыгын оныткан иде ул. Күргәч, яңадан борынын ак күбек эченә төртте. Яшьтән таныш шомырт исе гаҗәп тәмле иде.

Шаулаша-шаулаша кайтып килүчеләрне туктатып, Мәгъсүмә сорашты. Мыеклары салынып төшкән сары, ябык кеше: «Балалар йорты янды,—диде.— Знамо, тәмәке тартканнардыр, көн әнә нинди кызу...» Һәм ул, көннең кызулыгын расларга теләгәндәй, күзләре белән кояшка таба ишарәләде.

Икенче көнне иртән Мәгъсүмә йокысыннан торып, битләрен дә юып өлгермәде, квартир хозяйкасы Шәмсекамәр җиңги:

— Сине бер ир кеше сорый, керсенме? — диде.

— Юк, юк, кермәсен,— дип, Мәгъсүмә мич артына ук кереп посты. Ул әле киенеп өлгермәгән иде. Кем уйлаган бит аны шулай иртә килер дип. Мәгъсүмә чуалып, буталып калды. Кичә генә авырып яткан кеше... «Синең өчен авыру башы белән сикереп торган,— диде күңеле,— шатлан, кызый, сине эзләп шулай иртүк килеп җиткән...»

Кыз киенгән арада Чека председателе ишегалдында, малайлар кебек, көтеп торды. Кияү егете төсле, матур һәм көяз иде ул бүген.

Бераздан Шәрифҗанны өй эченә чакырып керттеләр. Мәгъсүмәнең оялган күз карашы белән Шәрифҗанның әрсез карашы очрашты. Аның бу карашыннан Мәгъсүмә һәрвакыт куырылып төшә һәм югалып кала иде, шул ук вакытта бу кыю караш кызның күңеленә бик ошый да иде.

Мәгъсүмә, егетнең шушы әрсез, кыю күз карашыннан сихерләнгәндәй, хәрәкәтләнә алмыйча һәм сүз ката алмыйча байтак торганнан соң гына, сихер көчен җиңеп, ниһаять, телгә килде:

— Шәрифҗан абый, узыгыз.

Чәй эчкәндә Мәгъсүмә авызына капкан сыныгын чәйнәргә базмыйча утырды. Башка кешеләр арасында ул бер дә алай булмый, ә менә Шәрифҗан абыйсы алдында коела да төшә.

Хуҗа хатын, рәхмәт төшкере, үзенең монда артык икәнен аңлаган, өйдән чыгып китте. Шәрифҗан форсаттан файдаланып калырга булды: эчә торган тәлинкәсен куеп, кызның каршысына килде.

— Мәгъсүмә, сеңлем,— диде.— Кыш көне сөйләшкәннәребезне хәтерлисеңдер? Мин синең җавабыңны көтәм бит!

Мәгъсүмәнең бер агарып, бер кызарып торган битләре тагын әкрен генә алллана башлады, бераздан ике яңагы икесе дә кыпкызыл булып кызарды. Чынаяк төсле ак күз алмалары, зур күзләре бу минутта аеруча матур иде. Ул, Шәрифҗанның текәлгән үткен карашларына чыдый алмыйча, бер якка борылды да:

— Шәрифҗан абый,—диде,— хәзер сорама, ярыймы, мин оялам.

— Ризамы миңа чыгарга? Әйт инде, ризамы?

Мәгъсүмә, алдындагы чәй тәлинкәсенә карап, әкрен генә:

— Әүвәл сиңа ике соравым бар,— диде.

— Нинди? Сора.

— Хәзер түгел, икенче вакытта.

— Юк, хәзер үк сора. Аннары син качасың, сине табып булмый.

Мәгъсүмә үзенең ал тырнакларына карап-карап торды да башын калкытты.

— Хәзер түгел, ярыймы?

Аның тавышында инәлү яңгырый иде.

— Кайчан?

— Бүген. Тик хәзер түгел. Мин оялам.

Һәм ул учлары белән битен үк каплады.

Чәй урынын да җыймыйча, алар урамга чыктылар. Көн Шәрифҗан шикелле көяз һәм матур иде. Кояш янгын каланчасын узып киткән, галәмәт кыздыра. Мәгъсүмә белән Шәрифҗан урамның күләгә ягыннан баралар. Капка төбендәге эскәмияләргә чыгып, карт сөякләрен иртәнге кояшта җылытып утыручы гайбәтче карчыклар, Чека председателенең ниндидер кыз белән узып баруын күргәч, бер-беренә терсәкләре белән төртештеләр.

— Кара, иблис мәлгунь, нинди сабыйны иярткән.

— Ата-анасыз берәр ятимәдер, тамагы ачканга чыдаша алмыйча, ипиенә була тагылгандыр.

— Үзе ишедер әле, марҗадыр...

— Мөселман кызы ич, күрмисеңмени. Бичараның йөзеннән иман нуры да китеп бетмәгән әле, яңарак кына себерелә башлагандыр.

— Ай үләм! Яңарак кына. Бишектән үк тотына хәзергеләр.

Мескен Мәгъсүмә, убырлы карчыкларның ниләр лыгырдавын ишетсә, оятыннан җир тишегенә кереп китәр иде. Ул ишетми, карчыклар шундый начар уйда булырлар дип башына да китереп карамый, Шәрифҗаннан уңайсызланмаска, аның күз карашыннан курыкмаска тырышып, әкрен генә янәшә атлый. Кая баралар соң алар? Сорасаң, үзләре дә әйтә алмаслар иде. Аяклары кая таба атласа, шунда баралар.

Күңелләре хуш, иреннәре елмая. Сөйләшкән сүзләрендә әллә ни мәгънә дә юк. Күзләренә ни чалынса, шул турыда сөйләшеп алалар. Баш өсләреннән кара карга очып китте. Шәрифҗан аңа бармагы белән төртеп күрсәтте, янәсе, әнә нинди матур карга очып бара. Чирәмгә чыгарып арканлаган кәҗә бауга чорналып беткән, нишләргә белмичә, күкле-яшелле тавышлар белән акыра. Шәрифҗан, йөгереп барып, аны тиз генә бәладән коткарды. Әнә бер малай коймага менгән, канәфер чәчәген ботарлап ята. Һәйт! Малай әйләнеп карады, ләкин зыян итүеннән туктамады.

Бара-бара урамның башына килеп җиттеләр. Шәһәр бетте, кыр башланды. Ерак та түгел, яшел стенадай урман басып тора. Һавада, канатларын җәеп җибәреп, тилгән әйләнә. Күңелле дә соң җәй көне! Шәрифҗан кызның иңбашларыннан тотып, үзенә табарак елыштырды.

— Мәгъсүмә, я сора инде.

— Оялам,— диде кыз һәм тагын кызара башлады.

— Нинди сорау соң ул, шундый оялта торган?

Кыз уңайсызланып елмайды, аның чыраенда, күзләрендә эчке көрәш сизелеп тора иде.

— Әйтим микәнни соң? Берсен әйтәм.— Шулай диде дә тагын тотлыгып калды.— Шәрифҗан абый! — дип башлады ул аннары,— син... син моннан соң... кеше атмассыңмы?

Шәрифҗан кулларын җәеп җибәрде.

— Мин бит кеше атмыйм, контрларны гына атам. Анда да үз кулым белән түгел. Үз кулым белән мин бер генә кешене... юк, кешене түгел, бандитны аттым.

— Берне булса да аттың, алайса? Я кемне аттың, әйт? Шәрифҗан авыл талап йөрүче бандитлар атаманын ничек атып үтергәнен сөйләп бирде. Кыз, башын төшереп, байтак дәшми барганнан соң, керфекләрен сирпеп, күзләрен егеткә күтәрде.

— Ә моннан ары, Шәрифҗан абый?

— Атмам дип вәгъдә итә алмыйм.

— Менә шул шул. Әти белән әни гомер сиңа бирергә риза булмаслар.

— Бөтен кеше дә ата-ана ризалыгы белән генә чыкмый.

— Ә мин аларның хәер догасыннан башка чыга алмыйм. Бәхетсез булырмын дип куркам.

Тегермән турысында болытлар кабара башлаган иде. Ул да булмады, еракта күк күкрәгән тавыш та ишетелде. Ә шәһәр өстендә кояш яндырып кыздыра иде әле.

— Икенче соравыңны да бир инде,—диде Шәрифҗан, елмаеп.

Мәгъсүмә уйга талган иде. Болыт ягыннан исә башлаган җил кызның маңгай өстендәге чәч бөртекләрен кыймылдатып куйды. Шәрифҗан, аның бу минуттагы тын, сабыр матурлыгына сокланып, ирексездән Мәгъсүмәгә таба талпынды. Кыз уянып киткән кебек булды, күзләрен зур итеп ачып, Шәрифҗанга карады.

— Я инде икенче соравыңны!

— Ансын хәзер әйтмим. Әйтә алмыйм, оялам.

— Күзләреңне йомып әйт,— диде көлеп Шәрифҗан,— давай икебез дә күзләребезне йомабыз, син әйтәсең.

— Юк, хәзер түгел, Шәрифҗан абый.

Тегермән турысындагы болытны җил кабарта, бөтерә, айкый башлады һәм шәһәр өстенә таба алып китте. Болытның кара-кучкыл итәкләрендә яшен камчылары чарт-чарт итә иде инде.

Шәрифҗан белән кыз кайтыр якка борылдылар. Болыт, чабуларын өстерәп, аларны узып китте һәм шәһәр өстенә килеп җитте, урамнар караңгыланды, агач башлары иелделәр, яфраклар кайный башлады. Ул да түгел, озын урам буйлап, «пәри туйлары» чабышып узды. Яңгыр тамгалый башлады. Урамдагы кешеләр кайсы кая йөгерештеләр. Шәрифҗан белән Мәгъсүмә дә, кулларын ычкындырмыйча гына йөгерешеп барып, бер капкага ышыкландылар. Бәрелеп-сугылып искән каты җил яңгырны, әллә кайлардан айкап алып килеп, болар өстенә сибә иде.

— Әйдә миңа,— диде кинәт Шәрифҗан һәм, кызның ризалык бирү-бирмәвен көтмәстән, кулыннан тотты да йөгертеп алып та китте.

Чыланышып, мышкылдашып беткән килеш парадный ишектән йөгерешеп керделәр дә, бер-беренә карашып, көлешә башладылар. Мәгъсүмәнең чәчләре маңгаена төшкән, юеш күлмәге ботларына сыланган иде. Шәрифҗан ябырылып кочаклады да, кызның башын артка каерып, авызыннан йотлыгып үбә башлады. Мәгъсүмәнең: «Юк, юк, шушында гына торабыз, шушында гына...» — диюенә карамастан, кулларыннан тартып, баскычка алып менеп китте.

Алар бүлмәгә килеп керүгә, яшен чалтыратып җибәрде. Тәрәзә пыялалары ыңгырашып куйдылар. Кызның якынлыгыннан, тәрәзәләрдә бер сүнеп, бер кабынып торган каты яшеннән тәмам шашып киткән Шәрифҗан, Мәгъсүмәнең биленнән кысып алды да, кайнар сулышы белән кызның иреннәрен пешерә-пешерә:

— Икенче соравың! Тизрәк бул! — дип пышылдады.

— Шәрифҗан абый җаным, нишләвең бу, кирәкми!

— Икенче соравың!

— Җибәр, сулуым кысыла, Шәрифҗан абый... бәгърем, кирә... кир...

Кызның Шәрифҗан күкрәгенә терәлгән куллары хәлсезләнеп бөгелеп төште. Колакларында аермачык кичәге чаң

авазы яңгырый башлады, кичәге тәмле шомырт чәчәге исе борын тишекләренә бөркелде...

Чалырга алып барган сарык бәтие кебек калтыранган кызны Шәрифҗан күтәреп китереп салды.

...Төнне-көнне белештермичә, алар бер-береннең кочагыннан чыга алмыйча яттылар. Телефонга җавап бирмәделәр, килгән кешегә ишек ачмадылар. Дөньяда ашау-эчү барлыгын да оныттылар. Иртән уянгач, Шәрифҗан, торып, Чекага китте. Анда барып керүгә, Якуп аны янган балалар йортын карарга алып китте. Йорт әллә ни зарарланмаган иде. Шулай да балаларны Идел буендагы, көзли беравык ревком башлыклары торып чыккан зур пыяла балконлы йортка күчерергә булдылар. Чекага борылып кайтуга, Шәрифҗан телефонга сузылды, тизрәк Мәгъсүмәгә шалтыратты. Алар менә шулай бергә тора башладылар.

* * *

Мәгъсүмә белән тора башлаганнан бирле, Шәрифҗан үзенә үзе гаҗәпләнә. Моңа кадәр ул үзен контрлар белән генә түбәләшеп йөрергә ярый торган бер каткан күңелгә саный иде, кемне дә булса өзелеп ярата алырмын, аның өчен үлеп торырмын, иртән бергә өстәл янында чәй эчеп тә кичкә кадәр, сагынуга түзә алмыйча, әллә ничә тапкыр өйгә телефон шалтыратырмын, ә кичләрен аның өчен генә өйдә утырырмын дип һич уйламаган иде. Ул үзен бөтенләй белмәгән икән. Әйе, үзен дә белмәгән, яратышуның нинди рәхәт, нинди олы тойгы икәнен дә аңламаган. Мәгъсүмәгә башта ул, матур кыз итеп, ирләр күзе белән генә караган, тик менә хәзер генә, өйләнеп бераз торганнан соң гына, ул үзенең хатынына гашыйк булды һәм сөешүнең нинди ләззәтле икәнен, сөя алмаучыларның нинди зур байлыктан мәхрүм икәнлекләрен төшенде.

Иртән Мәгъсүмә, чәй урынын хәзерли-хәзерли, бүлмәдә йөгереп йөргәндә, Шәрифҗан аңа читтән карап торырга ярата. Хатынының аяк атлаулары, башын борып елмаеп карап куюлары, кырт борылганда чәч толымнарының атлыгып китүләре — барысы да Шәрифҗанны сокландыра, ул, баскан җирендә сабыр гына тора алмыйча, Мәгъсүмә янына атлыгып килә дә биленнән кочаклап ала: «Ни өчен мин сине бу хәтле яратам?» — дип сорый, Мәгъсүмә кухняга чыкканда, аңа тагылып кухняга чыга, күлмәк-мазар үтүкләргә керешкәндә, Мәгъсүмәгә

комачаулап, аның тирәсендә чуала башлый, ә тегесе, иренең шулай яратуына рәхәтләнеп, тыштан кырыс булып кылана: «Китсәнә, балалар кебек, итәгемә тагылып йөрмәсәнә»,— дигән була, «Өте белән берне кундырырмын!» — дип кизәнгәндәй итә, үзе рәхәтләнеп көлә.

Шәрифҗан эшкә соңга калыбрак барса, Чекадагы иптәшләреннән ояла, гәрчә тегеләр, тел белән әйтмәсәләр дә, күз карашлары белән: «Беләбез инде, яшь бикәчнең куеныннан тиз генә чыгып булмый»,— диләр кебек, Шәрифҗанның суырылып калган битләренә мәгънәле итеп карап: «Хәлеңне аңлыйбыз, башыбыздан үткән нәрсә...» — диләр төсле иде. Бер кеше дә белмәскә, бер кеше дә кагылмаска тиешле ир белән хатын арасында ят кешеләрнең шулай күз карашы белән генә булса да тыгылуларына Шәрифҗанның күңеле рәнҗи, Мәгъсүмәгә булган саф тойгыларына пычрак кул белән кагылып буйыйлар, пычраталардыр кебек тоела иде.

Кайвакыт Шәрифҗанга үзенең бу бәхете озакка бармас, Мәгъсүмәгә я үзенә бер-бер хәл булыр да бу рәхәт көннәр бетәр, барсы да үкенеп сөйләргә генә калыр кебек була; кайвакыт аңа, фронтларда кешеләр кан койганда, зур шәһәрләрдә сабыйларга хәтле ачка шешенгәндә, мондый бәхет, мондый рәхәт эчендә йөзү оят булып тоела, бернәрсәгә карамыйча, бүген үк фронтка ут астына китәргә кирәк дигән уйлар биләп ала. Ләкин Мәгъсүмә янына өйгә кайтып керүгә, йөрәкне изеп торган авыр уйлар шундук таралып юкка чыга иде.

Казанга ул бер дә теләмичә генә китте. Аны Губерна башкарма комитетына хуҗалык эшләре белән җибәрделәр. Бер уңайдан шунда, партия комитетына да кереп, өяздә чыга торган газетага редактор сорарга да куштылар.

Моңа кадәр газетага алмаш-тилмәш үзләре редакторлык итеп килгәннәр иде. Газета эше берсенең дә белгән эше булмаганга, күбрәк секретарьга ышанырга туры килә иде. Газетаның эше көннән-көн арта, бер секретарь гына барысына да өлгерә алмый, редактор кирәк.

Губерна партия комитетында Шәрифҗан шушыларның барысын сөйләп биргәннән соң, комитет агайлары: «Кеше табуга җибәрербез»,— диделәр.

Казаннан кайткач, Шәрифҗанны өч волостьта Советлар съезды үткәрергә чыгардылар. Башлап торып ул иң ерак волостька китте, съездларны уздыра-уздыра өйгә якынаермын, соңгысын үткәргәндә өйгә, Мәгъсүмәгә инде бик якын

булырмын, съезд бетүгә ялт итеп өйгә кайтып китәрмен, дип уйлады.

Салкын Чишмә волостеннан төнлә өенә шалтыратып бакты. Җавап бирүче булмады. «Мин киткәч, өйдә үзе генә кунарга шүрләгән икән, элекке фатирына — Сәрби апаларга киткән икән»,— дип, күңелен тынычландырып, Шәрифҗан почтадан чыкты. Иртәгесен көндез шалтыратып карады. Бу юлы да җавап ала алмагач, ни уйларга белмичә аптырап калды. «Чекага үчле кешеләр берәр яры тотып үтермәделәр микән? Шәһәрдәге таныш кызлары белән Идел аръягына чыгып, су коенганда батып үлмәде микән? Кинәт кенә тиф белән авырып китеп, больницага илтеп салмадылар микән?» кебек уйлар белән борчылды. Ә бит тегесе дә, бусы да — барысы да чынлап булуы ихтимал. Шәрифҗанның үчле кешеләре шәһәрдә күп. Тиф чире дә бетеп җитмәгән...

Өяздән килгән вәкилнең съезд президиумында үз хатыны өчен пошаманга сабышып утыруын белсәләр, делегатлар — әнә теге кырыс чырайлы сакаллы агайлар, яисә алдагы рәттә утыручы әнә теге наган таккан волость милиция башлыгы, яисә әнә теге чибәр йөзле яшь авыл мөгаллимәсе ни дип уйларлар иде икән? Ә бит алар аны, өяз Чекасы башлыгын, бик каты бәгырьле, күз дә йоммыйча, атып үтерә ала торган мәрхәмәтсез, бернигә исе китми, пошына белми торган усал кеше дип уйлыйлар булыр.

Кызыл чалбары, җилбәгәйгә җибәргән кыска күн пиджагы, билендәге наганы, йомарлап өстәлгә салган зур-зур йодрыклары, съезд председателе Зариф агайның минут саен аның белән киңәшләшүе — шушылар бөтенесе дә делегатларда «Бик хәтәр кеше булса кирәк безнең Чека башлыгы» дигән уй тудырса, бер дә гаҗәп түгел.

Салкын Чишмәдән ул Шоңгаты волостена китте. Өенә, Мәгъсүмәгә ун чакрым якыная төште. Монда съезд озаграк барды: волость зуррак, делегатлар ишлерәк, зарларын сөйләргә теләүчеләр күбрәк иде. Әнә көрәк сакаллы таза гына бер урыс агай идәнгә карап сөйли:

— Иптәш Ленин-Ульяновка керәстияннән бик рәхмәт, ул бик белеп әйткән. Ул әйткән, керәстиянгә гелән-гелән акыл өйрәтеп кенә тормагыз, үзегез дә аңардан акылга өйрәнегез, дигән. Бирәсеңне керәстиянгә башлап син бир, аннары гына кулыңны сузып сорарга бар, дип әйткән. Ә бездә нишлиләр? Кадерле иптәшебез Ленин-Ульянов Владимир сүзен тоталармы?

Шәрифҗан: «Ай хәйләкәр, Ленин артына нинди оста кача...» — дип, күңеленнән елмаеп утырды. Агай, бер генә минутка башын калкытып, Шәрифҗанның кызыл чалбарлы сыйракларына битараф кына күз ташлады да янә идәнгә төбәлде:

— Тотмыйлар шул менә Ленин-Ульянов иптәш сүзен. Команданы өстән яудырып кына торалар, ә керәстияннән киңәшфәләнен бер дә сорамыйлар. «Давай-давай»ны бик беләләр, «мә»гә сараннар... Ә бит без аларны команда яудырып торыр өчен сайламадык!

Аңардан соң чыккан делегат, сеңер муенлы чандыр бер татар агай, съездга арты белән борылып, президиумга карап сүз башлады:

— Бирсеннәр безгә чәчүлек, урак, сабан, чалгы, торгызыйк без егылып яткан хуҗалыгыбызны, дәүләткә дә булыр, үзебезгә дә калыр! Вәт Сәйфетдин агай ни рәвешле уйлый. Юкса нәрсә инде бу? Чабам дисәң, чалгы юк, урам дисәң, урагы юк. Ат җигеп чыксаң, арба көпчәге таралам-уалам дип тора... Белербелмәс безнең эшкә тыгылмасыннар иде. Безгә әйтсеннәр: вәт сиңа, керәстиян агай, нәрсә кирәк шуны бирәбез, ә син давай тешкә кыстыра торганны! Сез безгә — без сезгә! Шулай булырга дулжен бит ул.

Бүтән делегатларның да зарлары шушы тирәдәрәк йөрде. Шәрифҗан өчен бу бер дә яңа түгел. Тиешлесен шәһәр авылга биреп җиткерә алмый. Нишләмәк кирәк? Кинәт кенә Шәрифҗанның башына «Ник әле мин Чекага үземнең егетләргә шалтыратып сорамыйм? Мәгъсүмәгә ни булганын алар белә торганнардыр» дигән уй килде. Съезд ял иткән арада шалтыратып карады, белә алганы шул булды: өен бикләп, Мәгъсүмә каядыр киткән, кая киткәнен берәүгә дә әйтеп калдырмаган. Шәрифҗанның кылт кына исенә төште: «Авылга әниләргә кайтып киләм әле»,— дип йөргән иде. Җибәр мине әниләргә дип сорап та караган иде. Шәрифҗан ул чакта: «Сөеп туйганым юк әле, бер яры җибәрмим»,— дип, китәргә рөхсәт итмәгән иде. Күрәсең, ире өйдә юк арада кайтып киләсе иткәндер.

Шәрифҗан эшнең шулай булуына тәмам ышанса да, күңеле тынычланмады. Кызның аңа чыгуын Мәгъсүмәнең атааналары бер дә яратмаганны ул белә иде.

Өченче волостька күчкәч, кайтып җитәргә унбиш кенә чакрым калды. Ләкин кайтудан хәзер ни мәгънә? Мәгъсүмә өйдә юк! Съездны япкач, Шәрифҗан волость башкарма комитеты

пленумын ашыкмыйча гына уздырды. Инде эш бетте. Кайтып китәргә мөмкин. Шәрифҗан, тагын-тагын йомышлар табып, янә бер тәүлек юанганнан соң гына кайтырга чыкты.

Ачкычны күршеләрдән тапты. Өстәлдә язу: «Өч көннән кайтырмын. Мин авылда». Өч көн дә, биш көн дә узды, ә Мәгъсүмә һаман юк. Шәрифҗан тиз генә җыенды да кечке пароходка төшеп китте. «Страж революции» дигән калын тавышлы пароход аны түнгә каршы юлга алып чыкты. Шәрифҗан җәяү су өстеннән йөгереп китәрлек булып, ашкынып, түземсезләнеп, палубада әрле-бирле сугылып йөрергә тотынды.

Тәүлек ярымнан, ниһаять, болын як пристаньнарының берсенә төшеп тарантаслы ат яллады да, урылган, сары чүмәләләр тезелешеп торган арыш басуы буйлап, Мәгъсүмәләр авылына таба ашыкты.

Ике мәчетле зур авылга җитәрәк, менә хәзер Мәгъсүмәне күрәм дигән куанычлы уйдан йөрәге алма урлап тотылган малайлар йөрәге кебек тибә башлады. Урыс капкалы йорт каршында тарантастан төште. Хуҗаның караңгы чыраена алдан ук әзер булып, капкадан килеп керде. Ләкин Мәгъсүмәне күрү насыйп булмаган икән: атасы кызын бүген иртән-иртүк «пырахутка» озатып куйган. Шәрифҗанны кун дип кыстамадылар, кыстасалар да калмаган булыр иде. Шул ук ат белән Шәрифҗан кире китеп барды. Ике тәүлектән ул инде өендә Мәгъсүмә янында иде.

— Бигрәк син инде,— диде аңа Мәгъсүмә,— хатының бер көнгә әниләренә кайткан, шунда да артыннан куа чыккансың...

Мәгъсүмәне авылдан гүя алыштырып кайтардылар. Элек өй эшләрен җырлый-җырлый эшләп йөргән хатын хәзер сайрар вакыты узган кош кебек тынып калды, көлеп сөйләшүләр, иренә барып сарылулар бетте. Шәрифҗан үзе килеп кочаклаганда да ничектер теләр-теләмәс кенә күнә, элекке шикелле кабынып, ялкынланып китми иде.

Аңардагы бу үзгәрешкә аптыраган Шәрифҗан: «Әллә пәри алмаштырдымы сине?» — дигән булып, сөйләтергә тырышып карса да, Мәгъсүмә берәр сылтау табып, гел сөйләмичә кала килде. Хатынының көннән-көн ябыгуы, агаруы күрше-күләнгә дә сизелә башлады. Хатыннар: «Әллә ирең кыйныймы, әллә өстеңнән йөриме?» — дип, Мәгъсүмәне йөдәтә башладылар.

Шәрифҗан яхшылык белән хатыныннан җавап ала алмагач куркытып карамакчы булды.

— Сине авылдан бозып кайтардылар. Барсына да этиең белән эниең генә гаепле. Әйтмәсәң, иртәгә үк Чекадан отряд җибәртеп, синең ул контрларыңның бөтен ояларын туздыртам!

Мәгъсүмә, кычкырып елап җибәреп, мендәргә бите белән капланды.

— Әни бәддога... бәддога кылды,— диде ул, калтыранып.— Кеше үтерүче имансыз татарга чыктың, ди, нәселебезне черттең, ди, та-кыямәт риза-бәхил түгел, ди.

Шәрифҗан тыела алмыйча көләргә тотынды.

— Шуның өчен саргаясыңмы? И юләр, юләр! Ә үзең укытучы! — Һәм ул үксеп елаудан туктый алмаган хатынын, бишек бәбие кебек кулына салып, идән буйлап йөри-йөри юатырга керешге.

— Тиле димәсәң... Аның бәддогасыннан безнең кай җиребез кылтая? Ташла юкны, тынычлан...

— Үлгәч каберемә дә якын киләсе булма, ди.

— Димәгәе. Кызулык белән әйткән, кайтып төшәчәк ул, менә күрерсең.

Кичен йокларга яткач, Шәрифҗан хатынын назламакчы булып, биленнән кочып алды, әмма тегесе, иренең кысып тоткан кулларыннан бушанырга тырышып:

— Кирәкми, акыллым, яме? Бүгенгә кирәкми,— дип пышылдады.— Күңелем тартмый, эниемнең бәддогасы менә бу җиремдә таш булып тора.

Шәрифҗан, җене чыгып, каты диванга төшеп ятты. Мәлгунь карчыкның ике-өч сүзлек бәддогасы Шәрифҗанның өеннән шундый зур бәхетне очырды. Бандитлар алдында да каушамый торган Шәрифҗан ниндидер карчыкның догасы алдында аптырап калды. Наган белән монда берни эшләп булмый иде шул. Каты диванда, яктан якка әйләнеп, авыз эченнән сүгенеп, ул төрлечә фикер йөртеп карады. Ана була торып үз баласын шул дәрәҗәдә каһәрләргә! Бәлки, алар Шәрифҗанны көн саен иртән бер, кич бер кешене бугазламый яши алмый торган ерткыч-җанвар дип беләләрдер? Карт белән карчыкны йомшартыр өчен, бәлки, аларга күчтәнәчләр, чәй-шикәрләр җибәреп карарагадыр? Бәлки, Мәгъсүмә белән икәүләп авылга озаккарак кайтып килергәдер?

Ләкин ул арада волость съездлары бетеп, өяз съездын чакырыр вакыт килеп җитте. Шәһәрне ташлап, бер яры да китәргә мөмкинлек булмады. Мәгъсүмә дә, ара-тирә ярыйсы гына ачылып, бернәрсә дә булмаган кебек йөри башлады. Шәрифҗан,

ахры шулай да үтеп китәр, дип авылга бару турындагы уеннан кайтты. Өяз съезды башлангач, гомумән инде ул турыда уйларга вакыт калмады. Съезд, Ревкомны бетереп, Өяз Башкарма комитеты оештырды, Якупны Башкарманың председателе итеп сайлады. Чека да бетте, Башкарма комитет каршында бер бүлекчә генә калды. Дөрес, бурычлары әллә ни кечерәймәде, ләкин хокуклары шактый кимеде.

Мәгъсүмә бер көн ачык, икенче көн тагын чытык. Шулай да өй эшен вакытында эшли, ирен дә, беркөнге кебек, диванга куып төшерми. Шәрифҗан әкренләп шул тормышка күнегә башлады. «Бәддога астында шуннан да яхшырак яшәп булмый инде, күрәсең»,— дип, кайвакыт хатынын шаярткалап та алгалый иде.

Август узып бару сәбәпле, Мәгъсүмәгә билгеләнгән мәктәбенә китәргә дә вакыт җитте. Бу юлы ул укытачак авыл шәһәргә бик якын, атна саен кайтып-килеп йөрергә була; халкы мәктәпне үзе сорап ачтырды, мөгаллимәнең килүен ике күзләп көтәләр: эшләү кыен булмас.

Яңгырдан соң юлда тузан басылгандыр дип, Шәрифҗан ат җиктерде дә, кучер урынына үзе утырып, хатынын авылга үзе илтә китте. Яшь мөгаллимәне күргәч, авыл бик куанды, аерым өйгә урнаштырмак булдылар. Мәгъсүмә, ялгыз торасым килми, бала-чагасызрак йортта кеше белән бергә уңайрак булыр дигәч, шундук андый өй дә табылды. Ул да түгел, таякка таянган ак сакаллы бер карт: «Аллаһ боерса, исән булсак, иң әүвәл үзебезгә кунакка килерсең!» — дип, мөгаллимәне ашка да чакырып өлгерде. Мәгъсүмә, кызарынып, керфекләре астыннан бер әлеге картка, бер тирә-юньдәге бүтән кешеләргә карап алып, чакырган өчен рәхмәт укыды. Шәрифҗан, кайтып китәргә дип тарантаска утыргач, озатырга чыккан Мәгъсүмәнең кулыннан тотты.

— Кара аны,— диде,— кунак-кунак уйнау мөгаллимә эше түгел. Я, сау булып тор. Киләсе атнада Гыйльметдинне ат белән җибәрермен, кайт, яме?

Шәрифҗан дилбегәне какты. Шуны гына көткән исполком аты тарантасны зырылдатып алып та китте. Мәгъсүмә, Шәрифҗан борылып карар микән дип, кермичә басып көтеп торды. Шәрифҗанны алып китеп баручы тарантас янгын сараен узды, менә сиртмәле коега җитеп, аны да узып китте, ире һаман борылып карамый. Мәгъсүмә нәүмизләнеп китеп торганда, Шәрифҗан, күңеле сизгән кебек, борылып карады, капка төбендә елмаеп басып торган хатынын күреп, фуражкасын болгарга тотынды.

* * *

Иртән шәһәргә кайтып җиттеләр. Телефон чыбыкларына ап-ак бәс сарган, суык бабай тәрәзәләргә бизәкләр ясаган иде.

Шәрифҗанның нияте бүген үк Мәгъсүмәне алып кайту иде, әмма Якуп аңа бер яры китмәскә әйтте. Бүген Өяз партия комитетында Дәүләтьяровның газетада басылган мәкаләсе тикшереләчәк икән, Шәрифҗанның катнашуын Якуп кирәк саный.

— Кеше җибәр,— диде ул, Шәрифҗанның ничектер күңелсезләнеп китүен сизгәч.— Ә монда катнашмый ярамый.

Гыйльметдин рәтләп җылынып та өлгермәде, кошовкага утырып, тагын юл чыкты. «Яңадан Галия янына барып килсәм?» дигән уйдан үзе дә гаҗәпләнеп куйды. Дилбегәне тарткалап, атны кызуларга тотынды: «Күңеллерәк атла, малкай».

Битен тун якасы белән ышыклап, Гыйльметдин әллә нинди уйларга чумды. Чынлап, барырга да чыгарга! Капка төпләренә ат белән килеп туктасаң, кызның күзләре шар булыр иде бугай. Банат дип, Гыйльметдиннең кендеге Банатка бәйләнмәгән, өйләнәм дип биреп куйган вәгъдәсе юк. Үпкән, кочкан — җилгә очкан, дигәннәр.

— На, бахбай, атла җәтрәк! Синеңчә ничек, биякәй җанкисәгем, аттырып кына Дәүләкигә барып килмибезме? А, койрыгын болгый башлады, яратмады. Ераксынасыңмыни? Нишләтергә соң менә бу күңелне? Һаман Дәүләкигә таба оча! Биякәй, әйдә инде, җилтерәтеп кенә илтеп куй мине шул кызкай янына!

Мәгъсүмә катына йөреп ияләшкән бия юл аерылышында кинәт кенә сулга каерды.

— Ярый, алып барасың килмәде,— дигән булды Гыйльметдин.— Минем дә кирәккән чагым булыр әле.

Гыйльметдин дилбегәне уйнатып куйды. Биянең тоягыннан атылган кар чанага шап итеп килеп төште.

Ап-ак булып җәелеп яткан кыр буп-буш, күз тукталырлык бер кызык нәрсә юк. Я шунда череп каралып беткән ялгыз чүмәлә очрый, я юл чатында кәкре шәрә агач басып кала, яисә кар күмеп өлгермәгән тирән яр, кызыл авызын ерып, басу түреннән узгынчыга карап тора. Сирәк-мирәк ала каргалар тамак артыннан авыл ягына очалар, Гыйльметдиннең күңеле нечкәрә, егетнең моңланасы, җырлап җибәрәсе килә башлый. Һәм ул, күңеленнән ташып чыккан тойгыларны тыя алмыйча, кычкырып җырларга тотына:

Уф дип әйтеп сулау белән
Уфа күренәмени?
Аерылышып тору белән
Күңел сүреләмени?

Ялгыз имәнне узып, аска таба чаптырып төшә башлагач, авылның җил тегермәне күренде. Революция алдыннан гына салынган, такталары яңгырларда каралып җитәргә дә өлгермәгән яңа тегермән, очып китәргә җыенган шикелле, канатларын ашыгып-ашыгып болгый иде.

Авыл капкасыннан килеп кергәч, гадәттәгечә, этләр өреп килеп чыкты. Чана шуучы малайлар туктап карап калдылар.

Йорт хуҗаларының Мәгъсүмәне төнгә каршы чыгарып җибәрәселәре килмәде.

— Буран кубарга тора, кая ашыгасыз? — диде Сәмигулла абзый.— Әйбәтләп кунып, иртәгә көн яктысында китәрсез. Гаҗилә җиңгәгез карабодай коймагы белән сыйлар үзегезне.

Юк, юл кешесенең юлда булганы яхшы. Шәрифҗан абый да бик зарыккан. Төялделәр дә чыгып киттеләр. Капкадан озата чыккан Сәмигулла агай, Мәгъсүмәнең толып итәге кардан өстерәлеп барганны күреп, чана артыннан йөгереп килде дә әйбәтләп кыстырып куйды. Ул гына да булмады, шәл тотып, өйдән Гаҗилә җиңги дә йөгереп чыкты.

— Мамык шәлеңне онытып китеп барасың ич!

Авылдан чыккач, Мәгъсүмә толып якасына чумды.

Кайтканда җил каршы булды. Тегермәнне узып, тигез басуга күтәрелгәнче бала җилләр генә уйнаклап йөрсә, тегермән калкулыгын күтәрелгәннән соң, ата җилләр сызгырып килеп чыкты. Әүвәле җил атның маңгай чәчен туздырып ыргытты, аннары Гыйльметдиннең толып якасын кайтарып атты, Мәгъсүмәнең сарык яка эченнән күренеп барган бит алмаларын кызылга бизи башлады.

Баштарак җәяүле буран гына чана тирәсендә айкалып йөрде. Сул кулда гел күренеп барган авыллар, урманнар беравыктан күренми башлады. Дөнья караңгыланды. Чын буран котырынырга тотынды. Ләкин Гыйльметдин адашудан курыкмый иде: ат юлны белә, ара ерак түгел, озакламый баганалы юлга, шәһәр юлына, барып чыгарлар, аннан соң инде күзне бәйләп тә кайтып җитеп була.

Буран көчәя. Бия юыртудан туктады, атлап кына бара. Гыйльметдиннең буранда эше юк.Дәүләки кызы һаман күңе-

леннән чыкмый. Ул инде, имеш, Галиягә өйләнгән. Яшь бикәче белән бергә җәйге кичтә, яшел чирәмгә җәелгән чыбылдык өстендә, катык каткан аш ашап утыра. Кояш батып бара. Каядыр якында гына ялгыз тартар кычкыра, чикерткәләр черчер итә. Бакча ягыннан алма исе аңкый. Абзарда сыер мышный, сарыклар пошкыра. Хатын бик уңган. Аш бик тәмле. Гыйльметдин, күп ашаудан авыраеп китеп, чирәм өстенә кырын төшә дә корсак шиңдерә башлый. Галия табак-савытны җыештырырга керешә. Күктә йолдызлар кабына.

Гыйльметдиннең хыялы крестьян тормышының күңелле якларын гына сайлый, гүя ул гомер-гомергә шушылай хатыны белән янәшә катыклы аш кына ашап утырачак. Хәер, аның бу уйлары, киләчәк турындагы татлы хыял булудан бигрәк, үткәнне, малай чакны, сагынып искә төшерү генә. Киләчәге зәңгәр томан эчендә, әлегә барсын да аерып бетереп булмый, тик шулай да Гыйльметдин, заманалар тынычлануга, берәр яры укырга кирәк дип, ниятне төенләп куйды. Аның әтисе русча ике авыз сүз белми, ә Гыйльметдин абразауный шәһәр урыслары белән дә теттереп сөйләшә ала. Заман башка! Әтисенең төшенә дә кермәгәнне Гыйльметдин өнендә күреп йөри. Әнә безнекеләр Деникинның бүксәсенә типкәннәр, Орел каласын, Воронеж каласын кире алганнар. Дошман коньякка таба чигенә. Май-Маевскийга Мәскәүдә рождество бәйрәм итү тәтемәде. Озакламас, дошманның тәмам башына җитәрбез. Сугыш бетәр, менә шунда Гыйльметдинегез духтырлыкка я зимләмирлыкка укырга китәр... Галияне дә укытыр. Аны кем итәргә икән? Аны духтыр итеп, үзе зимләмир булса? Әллә икесенә дә духтыр булыргамы? Авылга кунакка кайткач, карт-корылар, килеп: «Улым, Гыйльметдин, син духтырга укып кайткансың икән, монау төшем бик чәнчешеп тора, берәр дару-мазар биреп җибәрә алмассыңмы?» — дип, авырткан җирләрен күрсәтерләр. Гыйльметдиннең даруы килешеп, теге агай савыгып китәр дә бөтен авылга Гыйльметдиннең даны таралыр. Юк, үзләре килгәнне көтеп яту килешмәс. Кайтканның икенче көне үк өй борынча үзенә йөри башларга кирәк булыр. Ап-ак киемнәр киеп, Галия белән икәүләп, авылның бер башыннан тотынасың да икенче башына барып чыкканчы йөрисең. Кергән бер җирдә: «Гыйльметдин улым, син түгелме соң бу? Сөбханалла, духтыр булгансың ич!» — дип гаҗәпләнәләр. «Булдым шул, Минҗиһан түти. Менә бу — минем катыным Галия. Дәүләки кызы. Өегездә хаста кешеләрегез юкмы?» «Бар шул, улым, бар. Менә

Мөхәмәдулла абзаң көздән бирле аяксыз ята, инде кыландырмаган әмәлебез калмады, Карагай Садыйгына аппарып, өшкертеп тә баккан булдык, аның сулышы бик шифалы дип әйтәләр иде, юк, аңардан да файда күрә алмады. Аптырадык инде, гаҗиз булдык, нишләргә дә белмибез. Мөхәмәдулла, кузгал әле, менә Гыйльметдингә күренеп кара, белмәссең, Ходай насыйп иткән булса, сихәтләнеп тә китәрсең». «Әһә, синдә раматиз авыруы, Мөхәмәдулла агай. Менә бу даруны эчсәң, ә менә бусы белән уынсаң, аякларың язылыр, чыраеңа нур кереп китәр».

Ул шулай йорттан йортка йөрер. Хатын-кызны чаршау артында Галия карар, түр якта Гыйльметдин ирләрне багар... Аның кулы бик килешер, авырулар барысы да сихәтләнер. Бөтен авыллары белән рәхмәт укырлар, өйдән өйгә кунакка йөртерләр...

— Гыйльметдин! Гыйльметдин! — дигән тавышка егет, хыялыннан көчкә айнып, чанадагы Мәгъсүмәгә борылып карады: хатынны кар күмеп китә язган, толып якасы эченнән борын очы гына күренеп тора иде.

— Гыйльметдин җаным, әллә адаштыкмы?

— Каян килеп адашыйк? Юлдан барабыз ич! — дип, Гыйльметдин буран тавышын җиңәрлек итеп кычкырды, гәрчә юлдан барганга ул үзе дә ышанып бетми иде.

Дилбегәне атның үзенә тапшырып, җил сызгырганны тыңлый-тыңлый кайта башлады Гыйльметдин. Кинәт чана артында тавышлар ишетелгән кебек булды. Буран эченнән атка атланган тонык шәүләләр килеп чыкты. Бу — Гыйльметдин белән Мәгъсүмәне тәмам тынычландырды. Адашмаганнар икән.

Шәрифҗан ат җибәрмәгән булса, Мәгъсүмә үзенең ирен әле бер көн дә, ике көн дә күрмәс иде, күрә алмауга карап әллә ни зарыкмас та иде. Күрешү сәгате якынлашкач, күңеле ашкына, тизрәк күрешәсе килә башлады. Юл бик озын, бик күңелсез булып тоелды. Исән-сау кайтып җитә алмас, күрешә алмас кебек аңа. Әнкәсе каргаганнан бирле, ул гел шомлана, төш күрсә дә, әллә ниләргә юрап бетерә, өй белән мәктәп шартларында тойгыларын акыл көче белән җиңеп килсә дә, гадәтләнгән шартлардан чыкса, тагын күңелен шом баса башлый иде.

Инде ни гомер кайтып та, һаман баганалы юлга җитә алмагач, Мәгъсүмә: «Адаштык, ахры»,— дип, борчуга төшкән иде, юлчылар тавышын ишеткәч, эченә җылы керде. Кар баскан толып якасын төзәткәндә, күзләренә чалынып калды: атка атланган бер шәүлә Гыйльметдингә нидер әйтә, Гыйльметдин

аңа ни диптер җавап бирә иде. Мәгъсүмә, тәмам тынычланып, якасын күтәрде. Кинәт чана туктады. «Тәмәке төрәләр»,— дип уйлады Мәгъсүмә. Шулай дип уйлап та бетермәде, «Шарт!» иттереп атып җибәрделәр. Мәгъсүмә, куркып, якасын ачып ташлады. Гыйльметдин тиздән кар эчендә, наганын сузып, кашын-күзен җимереп, шарт-шорт ата, тегеләр дә буран эченнән Гыйльметдингә аталар иде бугай.

Мәгъсүмә «аh!» итеп сикереп торды да чанадан буран эченә атлады, биленнән карга чумды.

— Нишлисез! Туктагыз! Атмагыз! — дип ачыргаланып кычкырды. Җил аның тавышын өзгәләп ыргытты. Мәгъсүмә талпынды, алга атлады, аяклары толып чабуларына буталды, ул егылды да тагы күтәрелде.

— Нишлисез! Гаепсез кешене ү-үте-рә-сез!..

Мәгъсүмәнең колак төбендә «Чарт! Чарт!» итеп китте, авыртуны сизеп өлгергәнче, ул кар өстенә егылды, «Әнием каргышы»,— дип уйлап өлгерде, аңын югалта башлады. Имеш, ул Идел тавында пароходлар узганны карап утыра икән. Ниндидер малай аңа бер кочак шомырт чәчәкләре бирде дә, Мәгъсүмә аларны иснәргә тотынды. Шомыртның татлы исе ни өчендер күкрәкне әрнетә иде. Кинәт кенә колак төбендә чиркәү чаңнары набат суга башлады. Янгын бар дип, Мәгъсүмә торырга талпынды, күкрәгендәге каты авырту аны кире кар өстенә салды. Күкрәге hаман әрни... Колакларында hаман набат... «Янам!»— дип кычкырмакчы була Мәгъсүмә, авызыннан тавышы чыкмый, күкрәге бик пешә... Пуля Мәгъсүмәнең нәкъ күкрәгенә килеп тигән иде.

...Башкарма комитет капкасы төбенә кайтып туктаган бияне күреп, Шәрифҗан мәтәлә-кадала йөгереп чыкса, күз аллары караңгыланып китте. Гыйльметдин... Мәгъсүмә... Гыйльметдиннең инде тәне үк суынган, ә Мәгъсүмәнең әле җаны бар иде. Шәрифҗан аны шундук больницага алып чапты. Ярты сәгать үтмәде, операция өстәленә салдылар. Операцияне доктор Дроздов үзе ясады. Мәгъсүмә пычак астында үлде.

Шул көнне үк бандитларның эзеннән милиция чыгарып җибәрделәр. Шәрифҗан, кая барып бәрелергә белмичә, хәбәр көтеп йөрде. Ахырда, түзә алмыйча, отряд белән үзе чыгып китмәкче булды:

— Рөхсәт итегез! Барып табам, башларына җитеп кайтам!

Аны тыеп калдылар. Милиция бернәрсәсез борылып кайтты. Шәрифҗан, тәмам котырынып, сез мәми авызлардан

буламы соң дип, тагы үзе җыена башлады. Бу юлы да Якуп аны тотып калды:

— Йөрисе булма! Синнән башка да табарбыз.

Шәрифҗан, наганын өстәл өстенә атып бәреп («Алыгыз! Юкса мин үз-үземә ышанмыйм»), төн буе Башкарма бүлмәсендә ишекле-түрле чабып йөрде. Ялгызын гына калдырырга куркып, Якуп та төн буе шунда утырды. Шәрифҗанның бу котыруы, бу авыруы бер атнага сузылды. Йокысыз, ашаусыз, тәмам эштән чыгып арыгач, ахырда ул бер тәүлек егылып йоклады, уянып аңына килгәннән соң, Якупка барды:

— Мине бүген үк фронтка җибәрегез. Бер минут та монда яши алмыйм!

Ике көннән аны озатып калдылар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шәрифҗан Мәгъсүмә белән очрашуны ни өчен дулкынланып көтә?

2. Мәгъсүмә белән гаилә корып тора башлау Шәрифҗанга ничек тәэсир итә?

3. Шәрифҗанны якыннан белмәгән кешеләр аны, өяз Чекасы башлыгын, нинди кеше дип уйлыйлар?

4. Әнисе Мәгъсүмәгә ни өчен бәддога кыла?

5. Мәгъсүмәнең үлеменнән соң Шәрифҗанның тормышында нинди үзгәреш була?

6. Әсәрне тулысынча укып чыгыгыз.

Мәхмүт Хәсәнов
(1927—1990)

Узган гасырның 60 нчы елларыннан татар әдәбиятында башланган яңарыш хәрәкәтенә мөһим өлеш керткән әдипләрнең берсе Мәхмүт Хәсәнов була. Әдәбиятта мондый югарылыкка күтәрелгәнче, аңа зур гына тормыш һәм иҗат юлы үтәргә туры килә.

Мәхмүт Максут улы Хәсәнов 1927 елның декабрендә Татарстанның Саба районы Югары Кибәхуҗа авылында крестьян гаиләсендә туа. Зеленодольск шәһәрендәге татар урта мәктәбендә укыганда сугыш башлана, һәм ул, һөнәр училищесын тәмамлап, слесарь булып эшли. Мәктәп елларында ук әдәбиятсәнгатькә туган мәхәббәте аны 1944 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате институтына алып килә. Институтның актерлык факультетын тәмамлагач, ул Казанга кайтып Яшь тамашачылар театрына эшкә урнаша. Бераздан аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына чакыралар. Театрда актер булып эшләү белән бергә, М. Хәсәнов әдәби иҗат белән дә кызыксынып китә. Матбугат битләрендә аның очерклары, хикәяләре күренә башлый. 50 нче еллар башында, театрны калдырып, ул тулысынча язучылык эшенә бирелә. 1952 елда аның «Беренче хикәяләр» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Алга таба иҗади активлык күрсәтеп, ул бер-бер артлы «Яңа горизонт», «Урман шаулый», «Кыюлар юлы» повестьларын, татар һәм рус телләрендә хикәя җыентыкларын бастырып чыгара. Бер үк вакытта М. Хәсәнов балалар әдәбияты өлкәсендә дә актив эш алып бара. Яшь укучылар өчен «Очар кошлар», «Җирән кашка», «Шайтан малае», «Без алтынчы «А»дан», «Динозаврлар өнендә» кебек повестьларын яза. Яшьтән үк театр белән тыгыз бәйләнгән М. Хәсәнов каләмен драматургия өлкәсендә дә сыный. Аның 50—60 нчы елларда язылган «Нурихан»,

«Рамай», «Көя күбәләге», «Хикмәтле Хикмәтулла» дигән пьесалары республиканың төрле театрларында куела.

Мәхмүт Хәсәновны әдәбиятта ныклап таныткан төп әсәре исә 80 нче елларда дөнья күрә. Сүз «Язгы аҗаган» романы турында бара. Гәрчә бу әсәрен автор 60 нчы елларда ук яза башласа да, аны бастырып чыгару мөмкинлеге бары тик илдә, бигрәк тә идеология өлкәсендә, зур үзгәрешләр башлангач кына туа. Бу роман 80 нче елларда илдә барган зур үзгәрешләр йогынтысында татар әдәбиятында да яңарыш башлануын күрсәткән әсәргә әверелде. Анда колхозлашу хәрәкәтенең һәм сугыш белән аннан соңгы чордагы яшәешебезнең моңа кадәр күләгәдә калдырып киленгән фаҗигале яклары күрсәтелде. Автор әдәбият-сәнгатьтә дә гел мактальш кына килгән совет системасының гаделсез, кешелексез якларына яки гамәлләренә күз салды. Моның белән «Язгы аҗаган» романы совет җәмгыятен татар әдәбиятында беренчеләрдән булып объектив күрсәтергә һәм бәяләргә омтылган әсәр төсен алды. Бу романы өчен Мәхмүт Хәсәновка 1988 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

Бирем

Язучының тормыш юлын кыскача сөйләп бирегез һәм аның үзенчәлекле якларына игътибар итегез.

ЯЗГЫ АҖАГАН

(Кыскартып алынды)

БЕРЕНЧЕ КӨН

Язын аҗаган күргән кешене гомере буена ачы язмыш, зур афәтләр, көтелмәгән газап-михнәтләр, фаҗигале хәлләр эзәрлекләр, тормышы тоташтан бәла-казалы, зар-интизарлы булыр, ди.

Халык сынамышыннан

1

Алар өч бертуган иде: Гази, Таҗи һәм кече энеләре — Һади. Өчесе дә — минем булачак дусларым. Өйләребез дә янәшә генә, бер-беренә орынып ук торалар иде. Бәлки шуңадыр, без үзүзебезне белешә башлаганнан бирле мәш килеп, әүмәкләшеп

бергә үстек. Айкамаган урын, җитешмәгән җир, кермәгән тишек калды микән? Шагыйрь әйтмешли, «дөнья белән шулай танышып йөргән идек бергәләп...»

Әмма без Бөек Ватан сугышына кадәр үк авылыбыздан китү сәбәпле, араларыбыз өзелде дә куйды. Балачак хатирәләре исә, таң алдыннан күргән могҗизалы матур төш булып, күңел төбендә гомерлеккә уелып калды.

Балачакны юксынуны, аны сагынып искә төшерүне картаю билгесе, диләр. Бәлки, шулайдыр. Тик ничек кенә булмасын, еллар үткән саен, туып-үскән җирләрне, балалык дусларымны күрү теләге яңадан-яңа көч белән кузгала торды. Шуңа уңайлырак чак туры килүгә үк, газиз туган ягым, балалык дусларым белән араны якынайту, дуслыкны яңарту чарасын күрдем. Уртанчы һәм кече Зәкиевләр белән очраштык, хәтта кабат дуслашып киттек. Сирәк-мирәк кенә булса да, анда бер, елда бер дигәндәй, хат яки открытка алышып, хәтер яңартып торгандай итәбез.

Әмма җан дустым, «язмышы тумыштан ук фаҗигале» яшьти Гази белән генә очрашырга туры килмәде. Туган-тумачалары, таныш-белешләре әйтүенә караганда, ул үз тормышын кешечә кора алмаган, кара язмышка тап булган... Барысы да шул каһәр суккан сугышка бәйле. Имештер, Гази фронтта әсирлеккә төшкән, шунда фашистлар белән турыдан-туры хезмәттәшлек иткән һәм Ватаны алдында гафу ителмәслек җинаять эшләгән. Җитмәсә тагын, әлеге хәбәр-сүзләрнең кире каккысыз дәлилләр, хәтта рәсми документлар белән расланганлыгы турында өстәп куярга да онытмыйлар.

Авыр, бик авыр булган иде миңа бу хакта ишетүе. Ә бит Гази мәктәптә укыганда безнең барыбызга караганда да зирәгрәк, акыллырак иде. Нәкъ шул елларда, башлангыч сыйныфларда укыганда ук инде, аның авылыбызның иң сылу кызы Гөлүсә белән чын мәгънәсендә дус булуына без соклана, хәтта чак кына көнләшә дә идек. Аларны «кияү белән кәләш» дип үртәсәләр дә, үсеп җиткәч, ниндидер сәбәпләр аркасында, кавыша алмаулары турында да ишеткән идем.

Дөрес, баштарак Гази яшьтием турында күңелләрне җилкендерерлек, сөенеп туймаслык хәбәрләр дә йөрде. Мәсәлән, Газиның авыл яшьләре арасында бик яшьли комсомолга керүе, ә инде колхозлашу елларында, нәкъ этисе Хаҗи абый кебек, курку белмичә, сыйнфый дошманнарның өненә үк басып кереп, аларны фаш итүе, шунда яралануы турында берсеннән-берсе могҗизалы сүзләр ишетергә туры килде.

Ә инде сугыш башланыр алдыннан Газиның Казанга килүе, күпмедер вакыт рабфакның хәзерлек курсларында укып, медицина институты студенты булуы турында ишеткәч, башларым күккә тиярдәй булды. Мин Мәскәүдә укыдым. Каникул көннәрендә Казанга кайткач, балачак дустымны күрим дип, институтка барганда, аның да авылга кайтып киткән вакытына туры килә идем. 1942 елның шыксыз кышында исә миңа аның, өченче курста укуын ташлап, үзе теләп фронтка киткәнлеге турында хәбәр иттеләр.

Шуннан соң минем еш кына: «Эшли алдымы икән ул Ватаны гафу итмәслек зур җинаятьне?» — дип, икеләнеп куйган чакларым да булгалады. Тик нишләмәк кирәк, бәла-каза агач башыннан түгел, кеше башыннан йөри ди бит. Андый чакта, булган хәл булган, диярга һәм шагыйребезнең «Мин тормышта һаман яктыга, югарыга таба юл алдым... Ә син меналмадың... калдың, югалдың» дигән сүзләрен генә искә төшерергә кала.

Аннан соң күп еллар үтте, күп сулар акты. Тормышлар үзгәрде, берничә буын алышынырга өлгерде. Мин инде Газины кабат күрә алуыма өметемне җуя башлаган идем. Әмма гомуми реабилитация елларында аның да, каяндыр кайтып төшеп, район үзәге больницасында эшли башлавы турында ишеттем. Ләкин әлеге хәбәрләр дә ничектер икеле-микеле иде. Берәүләре, хәйраннарга калып: «Кайда шулай оста хирург була алган, могҗизалар эшли», — дисә, икенчеләре бөтенләй киресе, тиле-миле кеше турында сүз алып баргандай, җыен тузга язмаган нәрсәләр турында гәп сата иде. Имештер, ул картаеп акылдан язган картлар белән мәш килә, аларны яшәртү турында хыяллана, хәтта бу турыда ниндидер «гыйльми трактатлар» яза...

Һәм менә, чирек гасырга якын вакыт үткәннән соң, бөтенләй уйламаганда-юрамаганда, балачак дустым, классташым Гази белән очрашу мөмкинлеге чыгып тора бит, егетләр!

Иртә таңнан, беренче рейс самолеты белән мин, өлкә газетасының махсус корреспонденты буларак, Мәскәүдән һәм өлкә комитетыннан килгән бик вәкаләтле комиссия составында мәшһүр Чулман буена командировкага чыгып китәргә тиеш.

Әмма бу баруымда, күңелемдә мәңге саклана торган гаҗәеп сихри дөнья — балачагым белән генә түгел, тәкъдир тарафыннан бик нык кагылган-сугылган Гази белән дә очрашасы барлыгы турында уйлагач, дустымның әтисе, авылыбызның беренче большевигы Хаҗи абый белән булган коточкыч фа-

җигале хәл бөтен тулылыгы белән күз алдыма килде дә басты...

Явыз контрлар, аның эчен ярып, арыш тутырганнар. «Авызборын тирәләренә дә кан белән арыш аралашып укмашкан иде»,— дип сөйләделәр.

Әмма сүзнең күңелемә мәңгегә онытылмаслык булып уелырлыгын чак кына соңрак ишеттем. Имештер, им-том, күрәзәлек итү, багу кебек нәрсәләр белән шөгыльләнүче Мәгыйшә карчык Газилар гаиләсендә зур фаҗига буласын, ә Газиның гомере буена зур афәтләр, иләмсез газап-михнәтләр кичерәсен атна-ун көн элек белгән икән. Янәсе, Гази, әтисе үтерелергә атна-ун көн кала, аҗаган балкышын күргән. Күргән дә, имеш, өенә йөгереп кайтып, әнисенә әйткән. Мәгыйшә карчык та шунда булган. Им-томчы әби ишеткән дә: «Саташа күрмә, Газиулла балакай, бу вакытта, яз башында, нинди аҗаган булсын»,— дип, әнисе алдында ук, яшьти дустыма җан кайтаргыч шомлы, михнәт һәм афәт-фаҗигаләр белән түшәлгән кара тормыш юлы юраган, ди.

2—3

Комиссия җитәкчесе Анатолий Степанович Кремнев кинәт кенә чирләп китә, һәм аны Гази хирург булып эшли торган больницага салалар. Баш врач Хәмзин, Газиның әсирлектә булуына ишарә итеп һәм башка сәбәпләре дә бар дип, аны операция ясаудан читләштерә. Бу вакыйга йөрәге авыру Газига бик нык тәэсир итә. Ул өенә кайтып урынга ята.

4

Әрнү-сызлануларга түзә алмыйча, үлем белән якалашып урын өстендә яткан Гази, саташу халәтеннән ычкынып, ниһаять, эзлекле фикер йөртә алыр хәлгә килде. «Уф-ф!» — дип, кул аркасы белән маңгаендагы эре тир бөрчекләрен сөртте. Беренче булып башына килгән уй Гөлүсәнең: «Тиздән, бик тиздән очрашырбыз...» — дигән сүзләре булды. Гомерлек үкенечкә, төзәлмәс йөрәк ярасына әверелгән Гөлүсәнең менә шулай уйхыялларында күзаллануына да бик риза иде ул. Ни хикмәттер, теләсә-теләмәсә дә Газиның уенда Гөлүсәнең нәни чагы, аны беренче тапкыр күргән вакытлар гәүдәләнә иде. Бу — очрашуның гадәти булмаганына күрә шулайдыр, мөгаен. Әле дә хәтерендә, колак артларын, бит-аякларын кемнеңдер нәкъ чебен

йөргән сыман итеп кытыклавыннан уянып киткән иде Гази. Күзен ачса, ни күрсен: ул йоклаган сәке өстендә, нәкъ аның баш очында, арык тезләрен янәшә куеп, аларны ямаулы күлмәк итәге белән каплап, нәни бер кызчык утыра.

— Син кем?— дип сорады Гази.

Тыела алмыйча чың чәчеп көлгән кызчык үзенең исемен атады:

— Гөлүсә.

— Каян килдең?

Тезләре өстенә ияген куеп утырган кызчыкның кем белән булса да сөйләшергә теләгәнлеге йөзенә чыккан. Менә ул һаман да әле елмайган көе кулларын чәбәкләп алды да тәтелдәргә кереште:

— Ә мин сине беләм. Әйе, беләм! Синең исемең Гази. Шулай ич? Мин сине электән үк белә идем инде. Без әнә теге өйдә яшәгәндә үк белә идем... — Кызчык, кайчандыр күршеләр яшәгән, хәзер инде җиргә сеңәрдәй булып кыйшаеп, күңелгә шом салып утырган ташландык йорт ягына ым какты.

Шунда барысына да төшенде Гази. Ике-өч көн элек булып узган бер вакыйгага да күз алдына килде.

Күрде Гази, ишелеп төшәргә торган шыксыз өй катында басып торган солдат янына әнисе йөгереп килде. Кочакларга җыенгандай итеп, хәтта чит-ят кешенең җилкә-иңнәренә кагылып алды. Шунда ук, каядыр алып китәргә теләгән сыман, солдатның шинель җиңнәренә ябышты.

Бераздан солдат үзе дә керде. Әнисе исә, кетеп алган иң кадерле кунагын каршылагандай, күгәрченнәр булып кына гөрләмәде инде.

— Әйдүк, әйдүк, Иргали күрше. Батыплар үләрмен димәсәң, әйдүк, түргә уз. Менә бит, ә! Шул тиклем гомерләр узгач янә очрашырбыз дип кемнәр уйлаган. Җыяр ризык булгач, бер кайтасың икән аны. Без бит, Иргали, ут күршеләр генә түгел, якын дуслар да идек. Ә хатының Гөлниса белән ахирәтләр идек әле. Хаҗи абыең да үлепләр ярата иде үзеңне. Әйдүк, әйдүк, Иргали... Менә моннанрак уз...

— Хафаланма, Зәйтүнә апа, борчылма. Мин дә менә туган нигезгә баш иярмен дә иң әүвәл Хаҗи абыйның гаиләсенә керермен дип күңелемә беркетеп куйган идем. Яз башында булып узган фаҗигале хәлләр турында Чаллыда, пароходтан төшкәчтен үк ишеттем... Ничек соң, Зәйтүнә апа, тормыш алып барулары бик кыен түгелме, чыдар-түзәр чама бармы?

— И-и, күрше, син сорама, мин әйтмим дигәндәй, такы-токы белән тартып-сузып, көн күреп яткан булабыз шунда. Ничек кирәк алай очын-очка ялгагандай итәбез инде. И-и, Иргали, йорт башы да, йорт терәге дә ир-ат икән. Ир-ат булмагач, йорт-җирнең дә рәте китте, ачык та тишек, тәрәзә дә ишек дигәндәй, ир-ат булмагач, тормыш дигәнең нәкъ иске-сәләмә киемгә әверелә икән: аннан ертыла, моннан сүтелә... Ир-атсыз өйдә кояшлы көндә дә эңгер булыр, димәсләр иде аны.

— Ярдәм итәләрдер бит. Ни әйтсәң дә, Хаҗи абый авылның беренче большевигы иде. Совет власте дип башын салган кеше.

— Ярдәм дип, юк инде ул. Мондыен кысынкы заманда кемгә генә ярдәм итеп бетерә алсыннар. Бөтен мир белән шундый хәл бит, Иргали. Аh-зардан әнә бөтен ил иңрәп-сыкрап тора.

Изге җан Зәйтүнә, киңәш бирү белән генә дә чикләнмәде, бу олуг эшне нәрсәдән башларга кирәклекне дә өйрәтте: «Туптуры Ярлылар комитетына бар, ат-олау белән ярдәм итми калмаслар»,— диде.

ВЦИК чыгарган махсус декрет нигезендә, авылларда Ярлылар комитетлары төзелү турында Иргали белә иде инде. Шул комитетның рәисе булып әнисе ягыннан чыбык очы тиешле Бәhрам җизнәсе сайлануы турында ишеткәч, Иргалинең күңел түрендә пыскыган өмет чаткысы тагы да актыра төште.

Ул шулай итте дә. Иң әүвәл Бәhрам җизнәсен күрергә булды. Юк, өенә бармады ул аның. Кыегына уңып беткән әләм эленгән Совет йортына таба юнәлде.

Иргалинең гаиләсе турында нибары ике-өч авыз сүз әйтә алды Бәhрам җизнәсе. Әнисен үтә зәхмәтле узган елны җирләгәннәр. Иргали солдат хезмәтенә киткәч туган кыз баласы белән хатыны Гөлнисаны ярым үле хәлләрендә туган якларына алып киткәннәр.

Шунда Бәhрам җизнәсе, сүзне икенчегә борырга теләгән сыман, искәрмәстән генә:

— Фиркалеме?— дип сорап куйды.

— Керергә вакыт тимәде...— диде Иргали, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. Әмма шундук, акланырга теләгән сыман, солдат юлларының нәкъ чәбәләнгән йомгак кебек булуы, иртәгесен язмыш кая илтеп ташлаячагын да белмәгән чаклары еш булуы турында гәп сатып алды. Башта Австрия фронтында булган. Окопларда революцияне каршылаган. Бернинди икеләнүсез Кызыл Армиягә язылган. Шуннан башланган да инде Иргалинең Россияне аркылыга-буйга гизүләре.

Кайларга гына илтеп ташламый аны язмыш, кайларда гына булырга туры килми. Аеруча хәтердә калганы,— әлбәттә, Петроградта хезмәт итү. Казармалары Петропавловск крепостенда була. Баштарак Монет дворын, Смольныйны саклаганнар. Әмма әлеге тыныч тормыш озакка сузылмый, аларны янә фронтка, бу юлы инде Юденичка каршы алып чыгып китәләр.

Юденичны тар-мар итсәләр дә, ут боҗрасы эчендә калган яшь Совет иленең хәле моңа карап тиз генә җиңеләйми. Англия-Америка интервенциясе башлангач, инде ничәмә тапкырлар әҗәлнең күзенә караган солдат Иргали Миргалиев хезмәт иткән полкны төньякка озаталар. Архангельскины азат итү өчен барган каты сугышларда ул беренче тапкыр яралана. Ярасы әллә ни хәтәр булмаганлыктан, хәрәкәттәге армиядә кала. Дошманнан тартып алынган азык-төлек, кием-салымны һәм башка төрле кирәк-яракларны үзәк Россиягә озату эшләрендә катнаша.

Ишектә, элек-электән ялкаулык һәм фәкыйрьлекләре белән даны чыккан, Үшән кушаматы тагылган нәселнең бер вәкиле Халәп күренде. Өс-башы ташка үлчим: ямау өстенә ямау чәпәләгән тышсыз кыптыр кыска тун, башында чите камалы мескен бүрек, төбе асылынып торган ычкырлы киндер ыштан. Аягында, кайчандыр ак булып та, хәзер инде лимон сарылыгы, янә тагын күп төрле төсләр иңгән тула оек белән чабата. Чабатасының да бер сыңары «мыек» җибәргән. Аның каравы, кыяфәте бик әшлекле, горур, түш киеренке, баш күтәрелгән. Иргали белән дә, бер дә исе китмәгән кыяфәттә:

— Ба-а, кемне күрәм мин?! Былтыр үлгән ябалак быел башын калкыткан, диләрме әле? Син дә исән икән ич,— дип, эре генә исәнләште.

Иргали дә:

— Җеназамны укырга иртәрәк ашыккансыз,— дип җавап кайтарды.

Харап та соң, Халәпнең тавышы ай-һай көр, һавалы чыга:

— Партиядәме? — Бу аның беренче соравы.

— Юк. Өлгермәдем.

— Как так?! Шул заман эчендәме?

Сүзгә Хәят кушылды:

— Зарар юк. Иргали абый кебек авыр тормыш сынаулары үткән кеше бездән әллә ни ерак китә алмас...

Хәзрәттән ат белән арба сорап торып, Иргали ерак авылдан хатынын һәм кызын алып кайта. Алар вакытлыча Газиларда яшәп калалар.

ИКЕНЧЕ КӨН

1

Бүгенге маршрутыбыз — промыселда булу. Аның да нефтьчеләр теленә «Бондюг ятмасы» дип кергән өлешенә юл тотуыбыз. Комиссия әгъзаларын, Түбән Кама ГЭСын корып бетергәч, «Чулман-диңгез» сусаклагычы астында калачак йөзләрчә скважинаның язмышы кызыксындыра иде.

«Чаллыга Мәскәү кадәр Мәскәүдән ниндидер бик зур комиссия киләсе икән» дигән хәбәр халык арасына күптән таралып өлгергән иде инде. Шул уңай белән райкомда, район Советы башкарма комитетында берничә көн рәттән киңәшмәләр уздырылды. Район үзәген чистарту, тәртипкә кертү чаралары билгеләнеп, өмәләр үткәрелде.

Киләчәк комиссиянең шаукымы район үзәк больницасын да читләтеп узмады. Ике көн рәттән «генераль» җыештыру булды. Ишегаллары чистартылды, авырулар ята торган палаталарның да асты-өскә китерелде, төп корпусның паркет идәннәре көзгедәй елкылдап калды. Ансыз да чисталыкны, пөхтәлекне яратучы баш врач халыкның өстендә торды. Чак кына ул дигәнчә булмаса да, күтәрелеп бәрелде, түз генә; ул яктан талканы коры аның.

Комиссия шаукымы кемгә ничек тәэсир иткәндер, әмма Гайния түтинең моңа әллә ни исе китмәде. Чөнки аңа соңгы көннәрдә шактый авыр хәлләр кичерергә туры килде. Барысы да шул бораулау мастерының үлүеннән башланды.

Баш врач Хәмзин мәсьәләне Газины гаепләгән сыман куя. Дисә белән баш врач арасында җитди сөйләшү була.

Дисә дәвам итте:

— Менә бит ул тормыш нинди гаделсез нәрсә! Кемнәрдер «бәхет» дигән төшенчәнең «б» хәрефен дә татымый. Кайберәүләр, кеше бәхетенә күләгә төшерүдән куркып, булган бәхетләреннән дә ваз кичә... Ә кайберәүләр әнә, булган бәхеткә генә риза булмыйча, аны яңарту турында да кайгырталар... Бик, бик гаделсез нәрсә бу тормыш!

— Безнең хөрмәтле Гази Хаҗиевич турында әйтәсезме?

— Әйе, аның турында...

Баш врач шундук аны бүлде:

— Үз бәхетенә үзе балта чапкан кеше ул. Аның бәхетле булырга хакы да юк... Аңар дигән бәхет, Гайния түти әйтмешли,

сәмруг кош канаты астында. Булган кадәресенә бик тиз риза булып яшәргә тиеш ул.

— Үзе теләп алмагандыр ич ул яман дәһшәтләрне. Бәхетсезлекне аны беркем дә теләп алмый.

— Хикмәт аның пленда булуында гына түгел, ә пленда вакыттаниләр эшләвендә. Баштарак мин дә, нәкъ сезнең кебек, ышанасым килмичәрәк йөргән идем. Әмма моннан берничә ел элек мине махсус урынга чакыртып алдылар. «Кем белән бер түбә астында эшләвегезне сез дә белергә тиеш»,— дип, алдыма бер «Дело» куйдылар. Шул «Дело»дан ниндидер журнал чыгарып[1] кәгазь кыстырып куелган урынын ачтылар да бер фото күрсәттеләр... Әле дә булса күз алдымда тора ул фоторәсем. Анда аягүрә баскан бер фашист палачы бернинди гөнаһсызга вәхшиләрчә җәзалап үтерелгән меңнәрчә совет кешеләренең канына буялган кулы белән 4862 номерлы әсирне, ягъни мәсәлән, безнең хөрмәтле хирургыбызны кочаклап тора... Ә рәсем астында мондый сүзләр: «Рейхскомиссар обергруппенфюрер Отто Шульц үлемнән коткарып калган Фәрештә кушаматлы совет врачына рәхмәтен белдерә...» Менә шундый ул сезнең сокланып туя алмаган Гази Хаҗиевичыгыз...

2—3

Гази, әрнү-сызлануларга чыдый алмыйча, ут сулап, урын өстендә ята. Йөрәген ялкын өтәли. Сызланулары бәгыренә төшә. Кичәге газап чигүләр бүгенгенең күләгәсе генә булган икән, дип уйлый ул. Һәр көн шулай.

Өендә ята Гази. Үзе шулай теләде. Врач кешегә шифаханәдә яту килешми, янәсе, бигрәк тә үзе эшләгән больницада...

«Кеше үләр алдыннан бөтен үткән тормыш юлын күз алдыннан кичерә» дигән сүз, мөгаен, хактыр. Гази да уй эчендә. Ул секундлар эчендә әллә никадәрле вакыйгаларны, шатлык-куаныч, кайгы-хәсрәт тулы гомерен күз алдыннан үткәрә.

Юк, кичә район больницасының баш врачы белән ике арада килеп чыккан низаг, йөрәк пристубы башлануга сәбәп булган җәнҗал турында уйларга теләми Гази. Уйлыйм дисәң, җәрәхәтле, кан саркып торган йөрәккә дәва булырлык, хәтер диңгезе офыгыннан калкып килгән кояш кебек, җанны иркәләп-назларлык истәлекләр дә бихисап...

[1]Сүз фашистлар тарафыннан оккупацияләнгән халыклар өчен махсус чыгарылган «Сигнал» дигән журнал турында бара.

* * *

Уйлый калсаң, исең-акылың китәрлек бит. Һәр адымда үлем сагалап торган яу кырларында ниләр генә кичерергә туры килмәде Иргалигә. Берничә тапкыр әҗәл белән күзгә-күз очрашты, бары тик кыюлыгы белән тапкырлыгы аркасында гына исән калды. Аны бит бер тапкыр хәтта хәрби-кыр суды белән атарга дип тә хөкем иткәннәр иде. Алты ел эчендә башыннан кичергән хикмәтләр, кем әйтмешли, үзе биш-алты кешегә җитәр иде.

Шулай уй иркенә бирелеп атлый торгач, искәрмәстән генә яшен камчысы уйнаклап алгандай, миендә бер балкыш чагылып китте Иргалинең. Ул бер мизгелгә туктап калды. Күрче зинһар! Соң бит, шул ук Казан каласында аның, ярдәм кулы сузмаса да, барып һич югында киңәш-миңәшләшерлек кешесе бар икән ләбаса! Кешесе нинди бит әле! Мәшһүр Казан каласында гына түгел, ә бөтен губернага танылган, үзлегеннән шифаханә тоткан атаклы доктор Клочкинның бердәнбер улы. Исеме дә хәтерендә — Илья Олегович. Хәер, ул вакытта Илья Олегович аның өчен бары тик «Ваше благородие!» иде. Иргали күпмедер вакыт прапорщик Клочкинда денщик булып торган иде. Офицер булса да, Илья Олегович ифрат та миһербанлы, олы җанлы кеше иде. Иргалине дә кимсетмәде, башкаларга да кыерсытырга ирек бирмәде. Тик шулкадәресе бар: Иргалинең Илья Олегович белән соңгы тапкыр очрашуына да биш-алты ел вакыт үтеп китте. Әлеге утлы-кылычлы, канлы-дәһшәтле дәвердә кемнәр белән ниләр генә булып бетмәгәндер дисең. Дөрес, моннан ике ел элек Иргали әле Клочкинның якын дусты Аркадий Алексеевич Тарановны очратты. Уйламаганда-көтмәгәндә очраштылар. Шуның аша ул Илья Олеговичның исән-сау икәнлеген белде. Алай гына да түгел, Илья Олегович та Иргалине хәтерли икән. Хәтта: «Шул татарны күрергә язса, алдына тезләнер идем»,— дип әйтеп әйткән, имештер. Хәер, әйтсә дә әйткәндер, чөнки Иргали сугыш яланында Илья Олеговичның гомерен саклап калган иде. Аныкын гына микән? Бәлки, үзенекен дәдер...

Туплардан утка тоту тынарга да өлгермәде, окоплар өстендә икенче бер җан өшеткеч хәбәр таралды: «Га-а-аз!.. Га-а-аз!» Бу яман хәбәр күпләрне өнсез итте, тәмам тетрәндерде.

Иргали дә аякланды. Ышыграк урын сайлап, зур саклык белән дошман ягына күз салды. Әмма газ дигәннәре дошман

ягыннан түгел, ә уң яктагы калкулык өстеннән җибәрелгән икән. Күрде Иргали: сары-яшькелт төстәге төтен, бөтен басу киңлеген иңләп, дулкын тәгәрәвен хәтерләтеп, алар яшеренгән окопларга таба якынлашып килә. Хикмәте Хода, төтен кебек һавага күтәрелми, ә җиргә елышып, авыр нәрсә сыман, җиргә сыланып хәрәкәтләнә. Туган якларында кыр бәрәңгесен алганда, сабакларын җыеп яндырганда, аның төтене шушындыйрак саргылт-яшел төстә булыр иде. Ә исенең тәмлелеге турында әйтеп торасы да юк, хәзер сагынып искә төшерергә генә калды.

Калкулык ягыннан шуышкан газ дулкыны, ниһаять, окоплар өстенә дә килеп җитте. Иргалинең иң беренче тойганы — күзләреннән, чыдый алмаслык дәрәҗәдә әчеттереп, яшь ага башлавы иде. Нәкъ шул мизгелдә, ерегән кургашын салган сымандай, тамак төбе өтәләнде. Тыны кысылды, һава җитми башлады. Тончыга башлавын тоеп, күкрәген тутырып һава алмакчы иде дә, искәрмәстән генә бугазына ялкынлы кисәү тыгып куйдылармыни, кинәт күз аллары караңгыланып китте, егылмас өчен, янә окоп төбенә чүгәргә мәҗбүр булды.

Шунда ул станок пулеметы расчеты белән җитәкчелек итәргә тиеш Илья Олеговичны барларга булды. Күрде Иргали: офицерларның хәле тагын да мөшкелрәк, һушын җуйгандай, окоп төбенә сузылып ук яткан. Үзе хәрәкәтсез. Иргали, җәһәт кенә сикереп торып, офицеры янына ташланды. Әмма Илья Олеговичның буыла-буыла ютәлләүдән сыны каткан, йөзе күм-күк зәңгәрләнгән, күзләре аларган иде. Иргали аның башын күтәреп тезенә салды, дәшеп карады. Тик инде офицерның аны ишетерлеге дә, сүз катып җавап кайтарырлыгы да калмаган иде.

Бүтәне ничектер үзеннән-үзе эшләнде. Иң элек Аркадий Алексеевичтан аралап алган офицерын, бала урынына күтәреп, окоп каршына салды. Аннары үзе дә мәче җитезлеге белән өскә ыргылды. Шундый ук җитезлек белән ярым үле гәүдәне лафеты җимерелеп кырын ауган туп ышыгына тәгәрәтеп төшерде. Бары тик шуннан соң гына, мылтыгын иңенә элеп, бушап калган куллары белән, җан барлыгы да сизелмәгән Илья Олегович гәүдәсен җил искән якка, куе әрәмәлек белән капланган калкулык булырга тиешле тарафка сөйри башлады.

Иргалинең бәхетенә каршы, газ зонасыннан азат калкулык та әллә ни ерак булмаган, газ таралуын, атышларның чак кына тына төшүен көтеп торган санитарлар да шунда, әрәмәлектә генә посып утырганнар икән.

Тормышын ничек җайга салырга белмичә аптырап йөргән Иргали, Казанга килеп, доктор Клочкиннарга мөрәҗәгать итә.

Кече Клочкин:

— Син үзең бу турыда ничегрәк уйлыйсың?— дип сорап куйды.

Кеше икмәгеннән дә ачы, аннан да яман нәрсә юктыр бу фани дөньяда. Үз уйларына бирелеп утырган Иргали кырт кистереп бирелгән әлеге сораудан бермәлгә югалып калды. Әмма бик тиз кулга алды ул үзен.

— Бу очракта Олег Авдеевич хаклы,— диде ул. — Бездә, татарларда, «Иген иккән — нужаланмый көн иткән» дигән мәкаль дә бар...

— Үз акылы уенда булган кешегә хәзер авыл җирендә дә тормышны җайга салып була,— дип дәвам итте өлкән Клочкин. — Игенче бәхете — җирдә. Ата-баба һөнәрен сайлаган кешенең бәхетле булуын гасырлар исбат иткән. Ә инде ярдәм итүгә килсәк, бездән калмас. Һәрхәлдә, ач-ялангач булмас. Баш өстен түбәле итү чарасын да күрербез...

Аштан соң ир-атлар яңадан Илья Олегович кабинетына җыелдылар. Сүз иярә сүз китеп, Чаллыда яшәүче ниндидер Кузька-Бурлак исемле бер башкисәрнең исемен телгә алдылар. Аның турында сүз кузгату Клочкиннарның икесенә дә кызык иде ахрысы — бик аңлаешлы итеп елмаештылар. Иргали аша шул Кузька-Бурлакка хат җибәрергә, ярдәмне таш астыннан чыккан шул «зимагор» аша күрсәтергә булдылар. «Юкны да таба торган кеше»,— диделәр аның турында.

* * *

...Кемнәрнең генә теләкләре кабул булгандыр, Иргалинең юлы котырып уңды: Казаннан ат җигеп кайтты. Крестьян хезмәте белән көн күрә башларга ниятләнгән кеше өчен ат кадәр атның нәрсә икәнен аңлатып торуның хаҗәте юктыр. «Аты юкның — заты юк»,— ди мәкаль.

Шуның өстенә әле чанада, торыпша астында, ике капчык он, бер капчыкка якын солы, кеше җилкәсеннән төшкән булса да, ярты авылны киендерерлек кием-салым да бар.

Өйдәгеләрнең шатлык-куанычлары баштан ашты. Тормыш көтмәгәндә-уйламаганда бәйрәм төсе алды.

Иргали, бөтен көчен туплап, ун тырнагы белән берьюлы җиргә ябышып терлекчелек һәм игенчелек белән шөгыльләнә

башлады. Яхшы сүз йөгәнле дә, иярле дә була шул, Иргали дә күп нәрсәләрне рәхмәтле бәндә Динис кушканча, аның киңәше белән эшләде. Иң әүвәл җир-биләмәләр булдыру хәстәренә керешге. Бу мәсьәлә дә үзеннән-үзе хәл ителде: һәркайда фәкыйрьлек, ятимлек, күпчелек хуҗалыкларның сөрим дисә — аты, чәчим дисә орлыгы юк иде. Шунлыктан калдау җир-биләмәләрнең иге-чиге юк, кодрәтеңнән, көч-хәлеңнән килә икән, теләсәң күпме җир эшкәрт: сукала, тырмала, умырып уңышын җыеп ал. Иргалинең терлек-мазар белән әвәрә килүен исәпкә алып, күбрәк мал азыгы булдырырга, моның өчен борчак, ясмык, солы, кәрешкә ише нәрсәләр чәчәргә киңәш итте Динис. Сортлы, яхшы чәчү орлыклары да табышты.

ӨЧЕНЧЕ КӨН

3

Малай-шалай чактан ук, авылда яшәгән заманнан бирле, күңелем түрендә «авыл Советы» дигән сүзгә карата тел белән аңлатып булмаслык тирән ихтирам хисе саклаңып калган. Гаҗәп тә түгел, чөнки ул дәверләрдә яңа властьны тәшкил иткән бердәнбер идарә аппараты — авыл Советларының хокуклары да, мөмкинлекләре дә чикләнмәгән, шунлыктан киң катлам халык арасында дәрәҗә-абруе да ифрат зур, һәркем аңа зур өметләр баглап, үзенең бөтен киләчәген бәйләп карый иде.

Әмма ул елларда иң хәтердә калганы, әлбәттә, колхозлашу чоры булгандыр. Шул дәверләрне күз алдыма китерәм дә, ирексездән: «Ай-һай ла, авыр булган икән!» — дип, һаман хәйранга калам.

Нинди хикмәттер, колхозлашу, күмәк хуҗалыклар төзү дигән сүзне ишетү белән, күз алдыма туган авылыбызның ифрат фәкыйрьлеге, аның салам түбәләре, җимерек йортлары, талдан үргән читән ихаталары, гомер-гомергә михнәттән, мохтаҗлыктан башы чыкмаган Шәвәли абзый килә дә баса.

Шуның өстенә әле сыйнфый көрәш тә кискенләшә төште. Дин әһелләре, бай иярченнәре тагын да активлаштылар. Кулакларның кораллары уйнавы турында да сүзләр ишетелгәли башлады. Кайдадыр кемнедер атканнар, җәзалап үтергәннәр... Икмәк ягы да кытлыкланды. Кулаклар булган икмәкне дә яшерү яки юк итү юлына басты. Икмәк өчен көрәш яңадан революция казанышларын яклау өчен көрәшкә әверелде. Моңарчы оешкан колхозлар турында да имеш-мимеш сүзләр күбәйде.

Күмәк хуҗалыкның үзенә генә хас кыенлыклары да озак көттермәде. Терлекләр бергә туплану сәбәпле, корчаңгы, башка төрле йогышлы авырулар башланды. Моның сәбәбе бер: тиешле каралты-куралар юк, салам түбәле тишек абзарларда, азык салу өчен, ике-өч киртәдән кадакланган утлыклар гына. Яңгыр яуган көннәрдә аяк асты кеше ерып үтмәслек сазга әверелә, баштанаяк пычракка баткан арык малларның таныйрлыгы калмый...

Ул вакытта инде без дә, буй җиткереп, яшүсмерләр рәтенә кереп килә идек. Өлкәннәр телендә «Моназара кичәләре» дип йөртелгән җыеннарга сирәк-мирәк кенә булса да эләгү ягын карый идек. Чөнки ул кичәләр еш кына хәйран-тамаша төсен ала торганнар иде.

Кем сөйләсә, шуныкы дөрес дигәндәй, нинди генә фикерләр, нинди генә сүзләр ишетми идек анда. Иң кызыгы: әлбәттә, «авыл хәбәрчесе» дип аты чыккан Үшән Халәпе белән Иргали абыйның сүз көрәштерүе булыр иде. Әлеге бәхәс-низаг һәрчакта да Иргали абыйның җиңүе белән тәмамланыр иде. И-и, гарьләнер иде Халәп агай, ачу-ярсуыннан кара көеп чыгар иде.

Әле дә булса хәтеремдә, яратмыйлар иде Халәп агайны. Күз артында гына түгел, үзе алдында ук аның исемен «ата ялкау», «эт каешы», «һавалы хәерче» кебек сүзләр белән аралаштырып телгә алырлар иде. Чыннан да, ярпач, бик һавалы, кирәксә-кирәкмәсә дә кукраерга яратучы кыланчык бер адәм иде. Кулыннан әллә ни эш килмәсә дә, власть дип җанын, иманын бирергә әзер тора торган кеше иде. Шуның өстенә әле вак җанлы, тар холыклы. Телгә дә бик беткән, усал, тешләк. Аның каравы үзенең серкәсе бер дә су күтәрмәс иде. Турысын, дөресен әйткәнне яратмый, шундый гарьләнә, үртәлә, агарына: «Бу сүзләрең өчен үкенергә туры килмәгәе»,— дип, яный-куркыта ук башлар иде.

Иргали абыйның «Моназара кичәләре» дип йөртелгән әңгәмәләргә килеп чыгуының тагын бер хикмәтле ягы шунда: Иргали абый белән Халәп агай очраштылармы, шаулы бәхәс чыгуын көт тә тор. «...Колхозның нәрсә икәнен төшенәм дә кебек. Колхоз — ул күмәк хезмәт. Мин аны, үз акылым белән, умарта күче белән чагыштырыр идем. Анда вакыт белән дә, эшнең нindiлеге белән дә санашып торырга туры килмәячәк. Әмма арада Үшән Халәп кебек кешеләр булачагы турында уйлыйм да кулымны селтим. Үшәнлек белән ялкаулыктан да мәсхәрәлерәк нәрсә юк бу фани дөньяда. Страм! Халәп кебек ата

ялкауны йодрык белән чукындырсаң да эшләтеп булмаячак. Андый адәм өчен тир түгәсем дә, чиләнәсем дә юк»,— дип әйтеп әйткән, имеш.

Халәп агай аның әлеге сүзләрен кичерә алмаган. Аты-юлы белән сүгенеп: «Фәләнне-фәлән итмәсәмме, исемем хәрам булсын»,— дигән. Тәки үз сүзен сүз иткән, Иргали абыйга күп еллар буе беркем тарафыннан да файдаланмаган, кара эрем, бакра, шайтан таягы, билчән үләненнән башка үсемлек заты күренмәгән Ташлы Үр дип аталган ташландык урыннан җир бүлдереп бирдерткән, имеш.

Сүз уңаенда шуны да әйтеп үтәсе килә: Иргали абыйның җир турында һәрчак тере зат, нәкъ җан иясе турында сүз алып баргандай яратып-сөеп сөйләүләре әле дә булса хәтер түремдә калган. «Җир, ул нәкъ газиз ана кебек, игътибарлы, ихтирамлы кешене күз карашыннан ук тоя. Бер үк вакытта Җир, нәкъ сабый бала кебек, кадерләгәнне, назлап өстенә иелгәнне, бил бөккәнне ярата».

Сүзендә торды Иргали абый, үз басуларын, чыннан да, карап-сокланып туймаслык итте, адәм әйтеп адәм ышанмаслык уңышлар алды. Аның җир-биләмәләре тирәсенә килеп чыккан кеше: «Бирсә дә бирә икән Ходай!..»— дип, үзенең хәйранга калуын яшерә алмас иде. Ләкин бу үзеннән-үзе генә килмәгән; чын мәгънәсендә маңгай тире белән эшкәртү бәрабәренә алына торган булган ул йөз потлы уңышлар.

Баядан бирле кыбырсып утырган Халәпнең бүтән түзәр тәкате калмаган иде булса кирәк. Иргали абый ягына күз кырые белән генә кинаяле караш ташлап алды да сүз кыстырып куясы итте.

— Ничава, Шәвәли абзый, зарланма. Заманалар үзгәрде хәзер. Безнең заман — ярлылар заманы килде. Син әйткәнчә, бил бөгүләр, тир түгүләр бетте ул хәзер. Колхозыбыз яшәсен диген...

Бермәлгә өзелеп калган әңгәмәне Шәвәли абый дәвам иттерергә булды:

— И-и, кем, Халәп туган, ни әйттең иде кана да бит! Белмим шул, белмим. Ипи — иман, ипи юклыгы яман дигәндәй, бил бөкмичә, тир түкмичә генә яшәүләр безгә тәтемәс инде ул...

Тирә-юньнән өзек-өзек сүзләр ишетелгәләде.

— Халәпкә нәрсә аңа... Үзе әйтмешли: не горит тә, не кипит аныкы...

— Ул таш астында баш асарга өйрәнгән инде...

— Әйтмә дә! Тел белән тегермән тарту җиңел лә ул. Ипи

кадерен җилкәң белән күтәрә, күкрәгең белән яра башласаң гына беләсең икән аны...

Ниһаять, Иргали абый да телгә килде, үзалдына сөйләнгән кебек кенә итеп әйтте:

— Белмим, белмим... Нинди генә власть үз халкының ачлы-туклы, хәерче булып яшәвен максат итеп куяр икән. Белмим. Халык өчен андый хөкүмәтнең поты бер тиен...

— Әһә-ә!..— диде Халәп агай, Иргали абыйның сүзен тартып алгандай итеп. — Әһә-ә! Син әпәйт властька тел тидерәсеңме әле? Карап-карап торам да, чамаңны җуя башладың... Бу сүзләрең бик кыйммәткә төшүе, ихтимал. Знамо шулай!..

— Син мине дөрес аңларга тырыш, Халәп. Мин бары тик синең тир түкмичә, бил бөкмичә, ягъни эшләмичә, җитенке тормышта яшәргә җыенуың белән генә килешә алмавымны әйтәм. Колхоз ул — әкиятләрдә генә сөйләнә торган, күпме алсаң да кимүне белми торган тәгам-ризык, иксез-чиксез байлык тутырылган тагарак түгел. Анда да, ни тартсаң, шуны иләрсең дигәндәй, колхоз табынына ни салсаң, шуны алырга туры килер, минемчә. Адәмчә яшәүнең, тормыш итүнең беренче бисмилласы — хезмәт, шуны аңла. Син мине дөрес аңла, Халәп, тормышны аны элек-электән эшлекле кешеләр алып барган.

ДҮРТЕНЧЕ КӨН

1

Автобуста урыныбыз янәшә туры килде. Галина Николаевнаны күрү белән, кәефем күтәрелеп, җаным тынычланып киткәндәй булды. Димәк, Анатолий Степановичның хәле аруланура таба бара.

Кузгалып киттек. Машина алга ыргый. Алдан ук сүз куешкандай, әңгәмәбез дә нәкъ шул мәрхәмәтсез төннән башланып китте. Ул низагның нәрсәдән килеп чыгуына ачыклык кертергә, әлеге тәмсезләнүнең серенә төшенергә тырышып карадым. Мин, әлбәттә, телем бик кычытса да, операция ясарга рөхсәт бирелмәгән хирург Газиның авылдашым, балалык дустым булуын әйтеп тормадым.

3

Юк, Гази белән Гөлүсәгә кавышырга насыйп булмаган икән, тормыш дигән мәрхәмәтсез нәрсә башкачарак хәл итте аларның язмышларын.

Алар өйләнәсе елның көзе бик ямьсез килде. Декабрь азагына кадәр кар ятмады. Тагын дәһшәтле егерме беренче ел кабатланыр микәнни дип, халык пошаманга төште. Кар яумаган елны мал-туар да мантымый, үрчеми, имештер.

Нәкъ менә шундый пошаманлы көннәрнең берендә, бик күпләрнең якты өметләрен өзеп, хыял-максатларын пыран-заран китергән яман хәл булды — халык теленә «авыл хәбәрчесе» дигән абруйлы аты чыккан Үшән Халәбен үтереп ташладылар. Гәүдәсен су буена төшә торган караңгы тыкрыктан — Иргалиләрнең коймасы буеннан табып алдылар. Заманында волость дип йөртелеп тә, инде район үзәгенә әверелгән Чаллыдан көне-сәгате белән милиция вәкилләре килеп җиттеләр.

Тикшерүләр башланды. Бик җентекләп, инәсеннән-җебенә кадәр тикшерделәр. Күбрәк Иргалиләр өе тирәсендә чуалдылар.

Ул арада тыкрык буенда, бакча эчендә тыз-быз килеп, адымнар белән санап, нәрсәдер үлчәп йөренгән вәкилләрнең берсе, тыны-көне бетеп, Иргали янындагы милиционер янына йөгереп килде. Кулында канга буялган чүкеч иде.

Шундук үзләренә ияргән Иргалигә сорау артыннан сорау да бирә башлады:

— Чүкеч кемнеке?

— Безнеке,— диде Иргали. — Менә тамгасы да бар...

Иргалиләрнең сажинга охшаган сурәт өстенә ике сызык сызылган тамгасы авылда һәммә кешегә дә мәгълүм иде.

Ул арада мәет тирәсендәге тикшеренүчеләр яныннан да берәве килеп җитте. Үтергәндә Халәпнең башына бөркәлгән арыш капчыгына да нәкъ чүкечтәге төсле тамга сугылган булуы турында хәбәр китерде ул.

Менә шунда наган таккан милиционер үзенең кырыс-катгый сүзен әйтте:

— Сезгә хәзер үк безнең белән барырга туры килер...— диде ул...

Бары тик шушы шыксыз әмер-боерыктан соң гына Иргали ешрак тибә башлаган йөрәгенә үзәккә тиярдәй салкын шом, кара күләгә үрләвен сизде. Бар шатлыгы, бар дәрте кинәт кенә сүрелгән кебек булды аның.

— Кая? Озаккамы?..— дип сорады Иргали, әкрен һәм дәртсез тавыш белән.

— Хәзергә авыл Советына. Калганын прокурор хәл итәчәк. Нинди санкция бирсә, шулай булачак.

...Алга таба вакыйгалар баш әйләндергеч тизлек белән дәвам итә... Һәм, ниһаять, җан туңдырырлык шыксыз сүз дә килеп җитә: «Иргали Миргалиевлар бөтен гаиләләре белән Себергә сөреләләр икән...»

БИШЕНЧЕ КӨН

1

Безнең биш-алты машинадан торган эскортыбыз яңадан юлда. Бүген без яңа оештырылачак нефть һәм газ чыгару идарәсенең нефтьне комплекслап хәзерләү һәм кудыру цехы төзелешендә булырга тиешбез.

2

Газины ялгызлык хисе яңадан талкый, җанын баса, җанын изә башлады. Гази менә шулай күңелендә чокчына, кирәгеннән артык казына-актарына башласа, мең төрле югалтулар, үпкәләр, сагыну-юксынулар, язмышның каһәрләре, бөтен дөньясына рәнҗүләр — барысы бергә җыелып, үткән еллар элпәсе генә тарта алмаслык, кара кан саркып торган җәрәхәткә җитәсен яхшы белә. Үзәк өзгеч үкенү ачысыннан укмашкан яра ул. Әлеге лаф орып үкенү бары тик бер авыз сораудан гыйбарәт: «Нишләп болай булды соң әле бу?..»

Менә тагын бер мизгел эчендә, Газиның зиһенен телгәләп, әлеге аянычлы сорау калыкты. Чыннан да, нишләп алай булды соң әле бу? Нилектән кавыша алмадылар соң әле алар, яшьли сөешкән, вәгъдәләр бирешкән ике яшь йөрәк? Нәрсә комачаулады? Сәбәбе нәрсәдә?..

Әйе, булды андый сәбәпләр. Гази белән Гөлүсәне никахлаштырып кавыштырырга җыенулары турында комсомол секретаре Кадыйр Надыйров та ишетеп калган булса кирәк. Газины аулаграк урында эләктереп алды да, бик гадәти сүз алып баргандай, гәп сата башлады.

— Күрше районда бер комсомол белән ниләр булып беткәнен ишеттеңме әле? Юктыр, мөгаен. Яшәрлеген калдырмаганнар егетнең. Комсомолдан ук чөелдергәннәр... Ни өчен диген? Бер нэпман калдыгының кызына өйләнгән. Бөтен шартларын китереп никах укыткан, ди, бит ул намуссыз җан! Җә, әйт, комсомол әхлагына сыя торган нәрсәме шул?

Артык тугры, артык беркатлы, артык хәйләсез иде шул Гази. Яшь Совет иленең бөек омтылышлары, илаһи олуг хыял-

идеаллары белән яши иде. Барысына да ихластан инанды. Шул якты идеаллар хакына берсүзсез җанын фида кылырга да әзер иде Гази. Кемнәрнеңдер әлеге якты идеалларны үз мәнфәгатьләре өчен кулланырлар, бер мәгънәсезлеккә әверелдерерләр дип, башына да сыйдыра алмый иде шул ул.

Күңелгә шөбһә сала торган әлеге сүзләр көне-сәгате белән ут күршеләренә дә барып җитте. Сөмсере коелып, кара сөремгә төренгән Зәйтүнә торараштай катты да калды.

Ул арада ана кеше елый ук башлады:

— Чистый туң йөрәк икәнсең, кадалгыры!.. Бигрәк кенәләр үкенечләргә булган икән. Ил-көн алдында адәм мәсхәрәләренә каласыларыбыз бар икән. Ничекләр итеп түзәрбез!.. Шулайлар итеп хәзер инде иҗаби-кабул ителеп ярәшкән-вәгъдәләшкән кәләшеңнән дә йөз чөереп маташкан буласыңмы? Кыз баланы вәсвәсәләндермиләр аны, гөнаһларын кая куярсың? Алла оруыннан курык бер дә булмаса. Үкенәсе көннәрең алда әле, тик соң булыр. Матри аны! Тикмәгә генә: беренче мәхәббәт — йөрәк хуҗасы, димиләр. И-и, тинтәк! И-и, тәкәббер хәерче! Нәрсә, тамагың туйдымыни? Өс-башыгыз бөтәйдеме? Шулдыр шул! Кем аркасында? Ә?.. Әй-йе, кадер-хөрмәтләрен күп күрдек. Бердән, Ходайга, икенчедән, аларга рәхмәт укырга тиешле кешеләр без. Каты баш!.. Тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстә. Каян туды ул синдә андый юк-бар уйлар? Әллә теге Кадыйр мөртәтнең мәкеренә төшенмичә калдыңмы? Шуны бел, гаиләкорганда, кеше сүзе — агу ул. Исем-акылларым китә, валлаһи газимдыр! Әгәр дә бик беләсең килсә, Гөлүсә сиңа хәрам ул. Теләсәгез нишләгез... Алайса, йөрегез инде зар-интизарлар булып,— диде ана кеше, үзе өчен дә, игелексез улы өчен дә берьюлы әрнеп.

Кадыйрның маҗаралары моның белән генә чикләнмәде. Иргали абыйлары өстенә бәла килеп, баш очларында кара болытлар куерган көннәрнең берендә, район газетасында комсомол башлыгы тарафыннан оештырылган мәкалә басылып чыкты. Әлеге язма астында үз фамилиясен күргәч, ярсуыннан, гарьлегеннән шартлар дәрәҗәгә җитте Гази. Очрату белән, өзгәләп ташлардай булып, Кадыйр янына йөгерде. Әмма тегесе бик тиз суытты егетнең кайнарлыгын.

— Син нәрсә?!— диде ул, Гази өстенә ябырылып килеп. — Имзаңны куеп дөрес итмәгәнбезме әллә? Бәлки, синең шул контрны, кеше үтерүчене яклап язарга теләгең бардыр? Ә?.. Син әйт, тартынма. Без бит сиңа үзеңнең тирә-юньдә атаклы большевик, продкомиссар Хаҗи малае икәнлекне исеңә төше-

рергә дә күп сорамабыз. Бәлки, аларның иске-москылары, хәергә биргән чүпрәк-чапраклары күзеңне томалыйдыр? Бәлки, табыннарыннан калган каты-котылары авыз суларыңны корыткандыр? Шулар сыйнфый сизгерлегеңне оныттыргандыр?..

И-и китте тезеп, и-и китте ярсып, авызыннан утлар чәчте, түз генә. Газиның күңелендә купкан давылы шундук юкка чыкты. Кадыйрның эче тулы зәһәрлек, агу булуын, әшәкелек, этлек дигәндә, аның җиңнәре һәрчак сызганулы икәнлекне Гази белеп бетерми иде шул әле.

Ул вакытларда Кадыйр тантана итте, бөтен дөньяны утка ягардай булып йөрде. Иң яманы, әлбәттә, Газиның аяк терәп каршылык күрсәтә алмавында иде. Ниһаять, Иргали абыйларын авылдан сөрү көне дә җитте.

Һуштан язу дәрәҗәсенә җиткән Гөлүсә кабат Газига таба тартылып куйды. Гази, аны ике иңеннән алып, ниһаять, күтәрелеп, кызның йөзенә текәлде. Текәлде дә дөньялардан китәрдәй булып катты да калды. Гөлүсәнең тутырып, туры итеп караган күзләрендә мәңге сагынмаслык итеп карап калырга теләү дә, газизлек белән коелып төшү галәмәтләре дә, тел белән әйтеп аңлатып булмаслык тагын әллә нинди хис-халәтләр дә бар иде.

Гөлүсәнең көч-хәл белән иреннәрен кыймылдатып әйткән җан өзгеч сүзләре ишетелде:

— Гази!.. Аерылабыз да микәнни!.. Йа-а, йөрәккәем, ярылмыйча түзсәңче. Мәңгегә хушлашабыз бит... — Бу сүзләрдә дә «Бу хәлләрне булдырмаска да мөмкин иде түгелме соң?» дигән ялвару-өзгәләнү сизелде шикелле.

Йөрәгендә өермә уйнаган Гази җавап сүзләре эзләде. Эзләде, әмма табалмады. Ул арада алдагы атлар кузгалдылар. Газига да кинәт әллә нәрсә булды. Әллә инде вөҗданы уянды, ул җилтерәтеп кенә Гөлүсәне кочагына алды һәм соңгы сүзен әйтте:

— Ярар, Гөлүсә! Нишләмәк кирәк... Бәхил бул, җаным!..

Аның кочагыннан ычкынган Гөлүсә, егылып китүдән курыккандай, кузгалган арба үрәчәсенә барып тотынды. Аннары, мәйдан кебек киң ишегалдына үткәч, соңгы тапкыр артка таба каерылып карады.

* * *

...Кеше гомере — бербөтен, диләр. Кемнәргәдер, бәлки, шулайдыр. Әмма Газига еш кына туганнан бирле дүрт-биш кеше гомере кичерелгәндер кебек тоела башлый. Бер гомере — балачагы. Ятимлектә ачлы-туклы узса да, язгы таң кебек якты,

сагышлы төш кебек татлы, моңлы җыр кебек матур булды аның балачагы. Аннары яшьлеге. Яшьлекне, тиз уза дип, таң офыгы белән тиңлиләр. Әйе, тиз уза икән яшьлек. Баксаң, гомер буена дәвам да итә икән ич. Гази бик яшьли чын мәхәббәтне белде, аның назын татыды, татлы газапларын кичерде. Гомеренең иң бәхетле, берни белән дә чагыштыргысыз гүзәл, керсез, гамьсез мизгелләре шул еллар булгандыр, мөгаен. Тикмәгә генә: яшьлектә айның утыз көне утыз төрле, дип әйтмәгәннәрдер. Шуңа күрә дә Газиның үзе бер гомергә тиң яшьлеге, якты бер истәлек, чын ядкарь булып, хәтеренә инде дә калды. Хәзер инде: «И-и, зәңгәр урманнар, яшел болыннар артында калган яшьлегем, кайда син?» — дияргә генә калды.

Аннары инде тәүге һәм соңгы мәхәббәтен югалту ачысы... Казан каласы. Яңа тормыш. Яңа дуслар. Алай итәм дә болай итәм дип хыяллану, үсеш-омтылыш еллары. Болары инде икенче бер гомер...

Һәм, ниһаять, халкыбызның якты көнен төнгә әверелдергән, бөтен дөньяны кара сугыш сөреме каплаган еллар... Газиның әсирлектә калып, фашизм афәтенең бөтен авырлыгын, тоткын кичерергә тиешле барлык газабын, ачысын, мәсхәрәсен, каһәрен күреп тә, нацистларның ерткычларча җәзалауларын кичереп тә, бер авыз сүз белән җыеп әйтсәң, фашизмның мең төрле үлем «тегермән»нәре аша үтеп тә исән калу еллары...

Бер үк вакытта шулкадәресен дә күрде Гази: тоткынлыкның барлык газабын кичергәндә дә, бөтен ачысын татыганда да, әҗәл дигән нәрсә адым калмый үкчәгә басып йөргәндә дә әсирләр явыз, мәкерле дошман алдында баш имәделәр, сынсалар сындылар, әмма бөгелмәделәр, туган ил язмышы өчен көрәшкә даим әзер тордылар. Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашып, никадәр батырлык, фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр алар.

Гази җәфа чиккән ике төрмә, өч концлагерьның һәркайсында бар иде андый яшерен оешмалар. Концлагерьларның иң мәрхәмәтсезе булган Биркенауда да бар иде фашизмга каршылык күрсәтү оешмасы. Анда төрле милләт кешеләре туплангангамы, әлеге оешма да «Хәрби әсирләрнең сугышчан Бердәмлеге» (БСВ) дип атала иде. Гази һичкайчан да андый оешмалардан читтә калмады. Биркенауда да ул тиз арада үз кешегә әверелде, әлеге антифашистик оешманың элемтәчесе булып китте.

Концлагерьда кешене исем-фамилиясе белән атау юк, берәр кушамат яки алдан-арттан киеменә сугылган номеры белән

атап йөртәләр. Газига да, эш урынында гел халат белән күренгәнгәме, Фәрештә дигән кушамат тактылар.

Тагын шулкадәресе бар: Гази һичкайчан да үз-үзен аямады, эләгә-нитә калса, үлем җәзасы, крематорий миче көткәнен белсә дә, заданиеләрен төгәл итеп, җиренә җиткереп үтәргә тырышты. Үз-үзен куркыныч астына куеп, кирәкле медикаментлар тапты. Хирургия инструментлары кулга төшерде. Шуның өстенә әле ул чыра яктысында, яшерен рәвештә, әсирләргә операцияләр ясады, бик күпләрне үлемнән коткарып калды. Хәлләре бетеп егылган тоткыннарны аякка бастыру өчен, мөмкинен дә, мөмкин булмаганын да эшләде.

Бервакыт лагерьга Берлиннан югары дәрәҗәле офицер килә. Юлда ул партизаннар засадасына очрый һәм яралана. Гази аңа операция ясый. Терелгәннән соң ул яңадан килә һәм үзен «коткаручы» белән фотога төшә. Әлеге фоторәсем журналда басылып та чыга. Беркадәр вакыттан соң лагерь партизаннар тарафыннан азат ителә. Берләшмә командиры «Батя» каты яралана. Гази ясаган уңышлы операциядән соң ул исән кала.

3

Гази сугыш елларын хәтеренә төшерә. Иргали гаиләсе белән Себергә киткән Рәхимҗан авылга кайта. Авыл кешеләренә ул юлда күргән авырлыклар, яңа урында беренче йорт салулары, тормыш башлаулары турында сөйли.

АЛТЫНЧЫ КӨН

1

Башкарылган эшебезгә йомгак ясау көне иде бу. Барыбыз да халык депутатларының Чаллы районы башкарма комитетының утырышлар залына җыелдык.

2

Шундый кешеләр була, бер күреп сөйләшсәң, көн буена җитәрлек җан азыгы, илһам, җан шөһрәте аласың. Киресенчә дә була. Искәрмәстән баш очында гына карга кычкыргандай яки күмәргә табут күтәреп баручыларны очраткандай хис итә башлыйсың, булган кәефең дә челпәрәмә килә, күңел күгеңне кара болытлар биләп ала. Яшьлек дусты, көрәштәше дип якын күреп йөргән Кадыйр Надыйров белән очрашкач та шундый хисләр кичергән иде Гази.

Кемнеңдер искәрмәстән генә:

— Нихәл!..— дип дәшүеннән чәчрәп киткән иде ул. Кара-са, авылдашы Надыйров.

— Саумы, Кадыйр!

— Кара, исән икәнсең ич...

Надыйровның күрешү өчен кул сузарга ашыкмавын күр-гәч, Гази йөрәксенеп әйтә салды:

— Нәрсә, күмгән дә идегезмени инде?

— Күммәсәк тә, җеназаңны укыган идек шул.

— Бераз иртәләгәнсез...

— Ал-лай-й!..— дип сузды Кадыйр. Тавышы отыры кырыс-ланды аның. — Иртәләгәнсез дисең, алайса? Йә, әйтеп җибәр, нинди ниятләр белән кайттың?

— Нинди дип... Кеше туып-үскән җирләренә нинди ният белән кайтсын инде. Туган туфракны җирсеп, туган якларым-ны сагынып кайттым. Аннары менә авылдашларымны, дус-ишләремне юксынып кайттым... Без дә заманында дуслар идек бугай бит?..

Тегесенең җавабы — гүя эт өрде:

— Ул кадәресен хәтерләмим!

Гази бермәлгә аптырап калды.

— Син исерек, ахры, Кадыйр?

— Ха-а!.. Һаман да шул ук акыллы баш, беркатлы тинтәк икәнсең әле...— Кадыйрның төксе йөзенә кырыслык галәмәт-ләре бәреп чыкты. Ул да түгел, чырае күзгә күренеп караңгы-ланды, йөзендә нур әсәре калмады. Сүзләрендә дә рәхим-шәф-кать булыр төсле түгел иде. — Ух-х, күралмыйм да соң үзең-не!.. Әгәр дә кодрәтемнән килсә, менә шушы урында бугазың-ны чәйнәп өзәр идем...

Гази аптыраушта.

— Нәрсә өчен?..

Күзләреннән кыргый очкыннар чәчрәтә башлаган Кадыйр-ның тиз генә басылырга нияте юк иде бугай.

— Нәрсә өченме?.. Ишет, алайса... Барысы өчен дә күрал-мадым мин сине!.. Ишетәсеңме?.. Барысы өчен дә. Балачак-тан, үз-үземне белә башлаганнан бирле күралмый идем мин сезне... Бөтен нәсел-ыруыгыз белән җан дошманым идегез... Аңлыйсыңмы шуны? Балачакта кызык итеп, миңа караганда матуррак итеп уйный белүегезне үлеп яратмый идем. Ничә тапкырлар уенчыкларыгызны ваттым, уеннарыгызны җимер-дем... Ләззәтләнеп ботарлый идем!..— Авылдашының

кыяфәте генә түгел, тавышына кадәр үзгәрде, гыжылдап чыга башлады. Күр инде, явызлык адәм тавышын да шул тикле үзгәртер икән. Йөрәгенең иң түрге катламнарыннан ургылып чыккан җан ачуы белән дәвам итте Кадыйр: — Ә инде чак кына үсә төшкәч, сабагыңны башкаларга караганда яхшырак белүең өчен күралмый идем. Җенем сөйми иде үзеңне. Аңлыйсыңмы шуны?.. Егет булып үсеп җиткән чакларыбызны әйтмим дә... Авылыбызның иң сылу, беренче кызы Гөлүсәне син генә түгел, мин дә җан атып сөйдем, аңа мин дә үләрдәй гашыйк идем. Аның сине сайлавы, сине яратуы янә кан дошманыма әвереләдерде... Караңгы төннәрдә таш белән башыңны ярыр өчен сагалап торган чакларым да еш булды. Ә син: «Нәрсә өчен?» — дип сораган буласың!..

Гази тәмам аптырашта калды. Күз аллары караңгыланып китте. Менә йөр син кемнең кем булуын да белмичә... дип уйлады ул. Ә Кадыйр, күңелендә яңадан яман көч белән зилзилә купкан кеше сыман, төкерекләрен чәчеп дәвам итте:

— Юк-к, китми тор әле. Тыңлап бетер. Кайчан да булса бер ишетергә тиеш идең син бу сүзләрне. Әй-йе, ишетергә тиеш!.. Син минем гафу итә алмаслык кан дошманым идең. Үч иткән кебек, тормышың һаман алга баруын күралмадым. Ә инде эшмәкәр Иргали сезнең Гөлүсә белән кавышуыгызга ризалык биргән дигән сүзне ишеткәч, күзләремә ак-кара күренмәс булды. Баш очымда кояш сүнде... Аулаграк урыннарда җиргә авып, тырнакларым белән туфракны тырный-тырный елаган чакларым еш булды. Бәлки, котылырмын дип, мин сине күрәләтә торып дошман өненә җибәрдем. Әмма аннан да җиңел яра белән котыла алдың. Дөрес, гел син дигәнчә генә дә булмады... Мин дә тантана иткәләдем. Үзеңнең мәми авыз булуың аркасында Гөлүсәдән колак кактың. О-о, ул көннәрдә миннән дә бәхетлерәк кеше булдымы икән! Юк, булмагандыр. Авызыңа капканны йота алмадың бит син, арыш боламыгы!.. Менә шунда туйганчы, күңелем булганчы яңакладым үзеңне... Сине түбәнәйтү, синнән көлү өченниләр генә эшләмәдем. Иргалиләрне сөргәндә, Бөгелмәгә кадәр озата баручылар исемлегенә дә мин керттем сине. Шундый юк кына җимгә дә алдана идең син, бичара! Инде үчемне алдым, ниһаять, аяктан ектым дип уйлаган идем. Юк икән! Тагы бәхет елмайды үзеңә... Уку бәхетенә ирештең. Безнең күбебезнең төшенә дә кермәгән бәхет иде ул. Ниһаять, сугыш... Тормыш юлымнан юк булдың дип уйлаган идем. Илен саткан, хыянәтче дип сөйләделәр... Менә

каршымда яңадан син... Син!.. Нишлим, нишлим?!— шашу дәрәҗәсенә җиткән Кадыйрның сүзе бетмәгән икән әле, авызыннан төкерекләрен чәчүен белде. — Күкрәгемне этләр талый... Ух-х!.. Менә шушы куллар белән йөрәгеңне йолкып аласы иде дә, тузанга салып, ләззәтләнә-ләззәтләнә таптыйсы иде... Изәсе иде!..

Тәмам югалып, тәмам каушап калган Гази бер генә сүз әйтә алды:

— Әйтче, зинһар, ни өчен?..

Әмма Кадыйрның кыяфәте, халәте Газины ишетүдән, аңлый алудан узган иде инде.

— Каршымда, юл өстемдә тагын син... Тагын теләсә кем кызыгырлык эшең бар... Йә-ә, әйт, әйт!.. Кай җирем белән ким идем соң мин синнән? Ник дәшмисең?! —Кадыйр, аңлыминле кеше сыман, тагын Гази өстенә килүен белде. — Менә яңадан син минем юл өстендә... Әмма кем белән бер сукмактан йөрүеңне чамала... Аңла, без икебез янәшә яши алачак түгел. Кайсыбыз артыктыр, анысын язмыш үзе күрсәтер. Көт мине... килермен мин синең янга. Газраил булып, җаныңны даулап килермен. Син белергә тиеш... Мин янап кына кала торганнардан түгел. Мин бернәрсә белән дә санашып тормам...

— Бик янама!.. Шашынма алай... Закон бар, хакыйкать бар...— диде Гази, теленә башка сүз килмәгәч.

— Ха-ха!.. Закон, хакыйкать, имеш!.. Кем-кем, ә син, беркатлы тинтәк, хаклык белән хакыйкатьне күпме күтәргә кирәклекне башкаларга караганда да яхшырак белергә тиеш идең кебек... Бар-р, көт!.. Эзлә хакыйкатьне!..

Адәм баласы шул тикле дә кара эчле, каты бәгырьле булыр икән дип хәйранга калды Гази, берничә көн аңына килә алмыйча йөрде. Төн йокыларын алды. Күр инде ә, күңелендә никадәрле явызлык, рия! Бер чишмә суы эчеп, бер мәктәптә сабакка йөреп, төрле мөнәсәбәтләргә кереп үскән һәм, ниһаять, дус дип йөргән кешеңнең күңелендә шулкадәр киная сакла给ныр, синең ансыз да тоташ кара каннан гына торган йөрәгеңә шундый яман җәрәхәтләр ясый алыр дип, кем уйлаган?!

4

Гази үзенең хатирәләрендә тагын Рәхимҗан абыйсы сөйләгән гыйбрәтле, маҗаралы хикәяләргә әйләнеп кайта. Тайга уртасында яңа тормыш башларга җыенучы якташларына Иргали болай дип мөрәҗәгать итә:

— Киләчәккә йөз тотып, көр күңел белән яшик, кардәшләр. Дөрес, морадыбызга ирешер өчен байтак вакыт кирәк булыр, тир түгү кирәк булыр. Түзәргә туры килер, илдәшләр, сынаулардан сыгылмыйк.— Бу сүзләрдән соң тыңлап торучыларның күзләрендә өмет чаткылары кабынгандай булды, йөзләре ачылып китте. Шул гап-гади генә сүзләр дә тыңлаучыларда кешелек тойгылары уятты, тагы да шәфкатьлерәк буласы, изгелек эшлисе килә башлады.— Монда без яхшысын да, яманын да күргән кешеләр. Һәркемнең иңендә үз язмышы йөге. Ул яктан Ходайга шөкер... Һәркайсыбызның үз үткәне, анда теләсә кемнең тыкшынырга хакы юк. Кирәге дә юк. Үткән, беткән. Һәркем кулы белән кылганын җилкәсе белән күтәрә. Дөрес, арада нахакка гаепләнгәннәр дә бардыр. Кайчандыр өстебезгә ябырылып килгән бәла-казалар, михнәт-газаплар, кара кайгы, ачы хәсрәтләрне юлда килгәндә арбадан төшеп калдыга саныйк, илдәшләр! Яңа тормыш башлыйк. Коргаксыган күңелләр язылсын. Хәзер бөтен көч-дәрманыбызны туплап, шул яңа тормышыбызны төзүгә юнәлтик. Гаилә иминлеге дә, үзара татулык та, ахыр чиктә, җан тынычлыгы да — хезмәттә, кардәшләр. Мәгълүм хакыйкать бар: бәхетне аны эзләп түгел, эшләп табалар. Ә без,— белгәнегезчә, бәхет эзләүчеләр. Ә бәхет эзләүче бәхетледән дә бәхетлерәк ул...

Халык арасында чын күңелдән көлешеп алдылар.

— И-и, рәхмәтнең иң зурысы сиңа, Иргали туган!..

— Авызыңа бал да май.

— Акыллыдан акыллы сүз шул...

— Тагын бер үтенечем бар, кардәшләр! Зур үтенеч!..— дип кабатлады Иргали абый, сабыр гына сөйләвендә булып.— Халкыбызның йөз суын түкмик, хилаф эш кылмыйк. Без — монда яңа кешеләр.

Беркадәр вакыттан соң Иргалинең гаепсезлеге һәм иреклe булуы турында хәбәр алына. Аны һәм гаиләсен котларга яңа авылдашлары килә.

Ул арада Сираҗиның хатыны да телгә килде. Аның, үзәк өзгеч тавыш белән: «Иргали абый!.. Ташлама безне!..»— дигән сүзләре барчабызны тетрәндереп җибәрде.

Хатынның сүзен башкалар күтәреп алдылар. «Бүгенге көндә абруебыз, бәһабез бар, йөзебез ак икән, бу фәкать синең аркаңда гына, Иргали туган!..»

Китте тагын зар елашу, китте аһ-зар ору. Ирләр сыткы сыга, хатыннар елый. Бала-чагалар турында әйткән дә юк. Мәхшәр көне диярсең инде менә. Ә бит безнең халыкта сагыш-михнәтләрне, кайгы-хәсрәтләрне сабыр кичерә белмәү гаепкә санала.

Мин дә, күзләремне яшь элпәсеннән арындырып, түрдә утырган Иргали абыйга карадым. Аның да, салкында озак булуданмы, бәлки эчеп куйган балыннандыр, йөзе алсуланган. Күз төпләре ялкынсынып киткән...

...Ул кичне Иргали агай тел тибрәтеп уңай якка да, тискәре якка да ләм-мим сүз әйтмәде, бары тик бер үк сүзләрне кабатлады: уйлашырбыз, дусларым, киңәшербез...

Бары тик соңыннан икәүдән-икәү генә калгач, әйтте бу: «Беләм, кайда да тамагыбыз тук, өстебез бөтен булыр иде. Хикмәт андамыни!.. Яшәү мәгънәсе — халык ышанычын аклау. Шул нәрсә бар бит әле. Зур нәрсә ул...»

Мине баскыч болдырына кадәр озата чыккач, Иргали абый тагын бер авыз сүз әйтте: «Әх-х, Рәхимҗан,— диде ул. — Әле иңәргә дә өлгермәгән Миңсылу кабере белән ничек хушлашып китмәк кирәк...» Кан туганы кебек якын күрә иде шул ул балдызкаен.

Шулай итеп, Иргали абый халык үтенечен җиргә салмады. Себердә калырга ризалык бирде. Үз урыныма кеше тапкалаганчы, халык баш-күз алгалаганчы дип, берәр елга калып торырга булды. Вакыт үтә торды. Бераз ияләшенде дә. Кем әйтмешли, кеше тәмугка да ияләшә ди бит.

ҖИДЕНЧЕ КӨН

1

Ниһаять, соңгы көн дә килеп җитте. Сәфәр чыкканчы, Мәскәүдән килгән комиссия җитәкчесе Анатолий Степанович Кремнев белән саубуллашып чыгасы бар.

Кремнев, бик әһәмиятле нәрсәләр турында әйтергә җыенып та, хәтере алдалавыннан курку аркасында гына әйтә алмый калырга мәҗбүр булган кеше сыман, чыраен сытты.

— Беләсезме нәрсә?..— диде ул, ахыр чиктә, чамадан тыш зур серен ачкандай итеп.— Миңа операция ясаган хирургны... мин инде кайдадыр, кайчандыр бер тапкыр күргәнмендер ке-

бек. Тик үтерсәгез дә хәтергә төшерә алмыйм. Кайчан? Кайда?.. Менә ничәмә-ничә төннәр инде исемә төшерергә тырышып карагандай итәм... Юк! Шул эзәрлекләгән бәйләнчек фикердән һич кенә дә котыла алганым юк.

— Зарар юк,— диде Горцева, көр-күтәренке тавыш белән.— Андый хәлләр булгалар инде. Берәр кеше белән бутагансыздыр...

Кремнев, аңлатырга теләп тә аңлата алмавына гаҗиз булган кеше кебек, кабат чыраен сытты.

— Юк, Галина Николаевна! Юк, кадерлем!.. Бу очракта ялгышмыймдыр кебек. Таныдым мин аны. Иң кызыгы шунда: беренче тапкыр күргәндә дә, ул марля маскада иде сыман. Хәзергедәй күз алдымда... Аны башкалар белән бутап булмый, ул тамгалы... Маңгаендагы мөһереннән, кашын урталай ярган җәрәхәт эзеннән таныдым. Тик менә кайда, кайчан очрашуыбызны гына хәтеремә төшерә алмыйм. Үзен күрәсе иде...

Сүзгә Дисә Зиннәтовна кушылды:

— Хирург хәзерге минутта гына больницада түгел иде шул...

Анатолий Степанович, һушны алырлык сылу ханымның гүзәллегенә сокландандай, бер генә мизгелгә карашын алмый торды Дисәдән.

— Чибәрем, бәлки беләсездер, фронтовикмы ул? Хирург турында соравым...

— Әйе, фронтовик, башыннан адәм әйтеп адәм ышанмаслык могҗизалар кичергән ул. Әсирлеккә төшеп, концлагерьларда берничә тапкырлар үлем белән күзгә-күз килгән кеше...

— Соң, әлбәттә!..—диде ул, кинәт кычкырып.—Әйттем ич!.. Ялгышмыйм дидем бит мин сезгә. Әлбәттә, шул!..—Тавышы көр, күтәренке иде аның.—Андый кешене онытырга мөмкинме соң?! Әгәр дә хәтерем ялгышмаса, аның әле концентрацион лагерьда Фәрештә дигән кушаматы булуы турында да ишеттергәннәр иде.

«Фәрештә» сүзен ишетү Дисәне сагайтып кына калмады, тәмам тетрәндерде, һәм ул, үз-үзен белешмәгән кеше сыман, авыруга якынайды.

— Сез... Сез, Анатолий Степанович, ялгышмагансыз. Аның, чыннан да, шундый хикмәтле кушаматы булган.

Бу хәбәр әллә нишләтеп җибәрде авыруны. Ул утырган җиреннән сикереп торырга җыенгандай талпынып куйды һәм палатадагыларга таба кулларын сузды:

— Әйтәм ич!..— диде ул, тәмам канатланып.— Ялгышаммы соң!.. Менә бит, ә!.. Ничәмә-ничә еллар үткәч... Язмыш кабат очраштырыр дип кенә уйлаган?! Һай-й бу картлык! Искә төшерә алмыйча газаплануымны күр инде, ә!.. Соң бит шул, герой!.. Без бит инде аны күптән җирләгән идек... Карательләр тарафыннан юк ителүе турында бик төпле мәгълүмат та алган идек.

Сылу Дисә кабат авыру янына омтылды һәм, соравын алдан ук әзерләп куйган өлгерлек белән, шул ук вакытта бераз каушап:

— Сез әллә... «Батя»мы?..— дип сорап куйды.

Анатолий Степанович: «Сезгә әле вакыйганың шул кадәресе дә билгелемени?» — дигән бер кыяфәттә күзләрен кысып, бөтен йөзе белән елмайды да әйтте:

— Юк, кадерлем, мин «Батя» түгел. Мин — аның көрәштәше, әгәр дә шулай дип әйтергә мөмкин булса, аның уң кулы идем. «Батя» Берлин өчен барган сугышларда һәлак булды.

4

Шулчак телефонга кабат җан керде. Тамагына елаткыч төен тыгыла башлавын тойган Гази телефон янына килде. Бәлки әле кабат Таҗи шалтырата торгандыр дигән өмет белән телефон трубкасын кулына алды.

Гайния түти башта хәл-әхвәл сорашты, кәефе белән кызыксынды. «Ашар-эчәреңә бармы? Берәр җаның теләгән нәрсә кирәкмиме? Тартынып торма, әйт»,— диде.

— Менә монда, Газиулла, синең белән тагын бер кеше сөйләшергә тели. Хәзер трубканы аңа бирәм...

Чыбыкның теге башында серләшкән кебек итеп пышылдашып алдылар. Һәм шулчак аермачык булып чак кына таныш сыман тавыш ишетелде:

— Исәнмесез... Исәнме, Гази!..

— Саумысез!

— Бу мин... Гөлүсә...

Газига әллә нәрсә булды. Кинәт кенә зиһене томаланды. Ул да түгел, йөрәге шартлар дәрәҗәгә җитеп, ярсынып тибә башлады. Еллар томаны аша ишетелгән сыман яңгыраган бу тавышны таныды ул. Бу тавыш аңа колак төбендә генә чаң суккандай тәэсир итте. Күз алдында яшелле-күкле тәңкәләр биеште. Әмма акылы бу хәлнең чын булуына ышанырга теләмәде.

— Гази, ишетәсеңме?.. Хәзер яныңа барам. Каршы килмәссең бит?.. Шушы кадәр җиргә килеп, сине күрмичә китә алмам бит инде. Күт, синең янга йөгердем. Күт, яме!..

Гази янә үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә килде. Чыннан да, килерме икән?.. Чыннан да, күрер микәнни ул үзенең Гөлүсәсен? Менә кем аңа моңарчы яшәү көче, вакытның дәһшәтле агышына каршы торырга егәр бирде. Менә кем тормышка ашмас хыяллар белән өзгәләнгән, меңгә телгәләнгән җанын азмаз җылыта, боек күңелен беркадәр юата, алҗыган тәненә чак кына ял бирә торган иде. Чыннан да, күрер микәнни үзенең тәүге мәхәббәтен, үзенең Гөлүсәсен?.. Йөрәге артык ярсып тибүдән туктамаса гына ярар иде. Өзгәләнмә, йөрәккәй, ул тиклем ярсыма, түз, йөрәк, сабыр бул, чыда!.. Һай-й, ачы язмыш, нинди генә хәлләргә төшермисең син газиз адәм балаларын!..

Шулчак ниндидер көч урыныннан күтәрде Газины. Аякларын караваттан төшерде. Башы әйләнүгә, күз аллары караңгылануга түзәр чама юк. Шулай да ул, үз-үзен көчләп диярлек, караватбашына тотынды да аягүрә басты. Башта стенага, аннан өстәл кырыена ябышып, көзге каршысына килде. Әмма үз-үзен танымады. Аңа таба сакал-мыек баскан, күзләре эчкә баткан бер таныш булмаган адәм заты карап тора иде. «Әй-йе, чыкмаган бер җаның гына калган... Бу кыяфәттә Гөлүсәң күзенә ничек күренерсең?..» дигән уй чагылып китте аның башында.

Гази, исерек кеше кебек, анда-монда тотынгалап, мич аралыгына керде. Ут кабызды. Юынгыч янында кабат көзгегә күз төшерде. Җитенке сакал-мыекны электр бритвасы белән генә алырлык түгел иде. Бит-яңагын мул итеп сабынлады да киштәдә торган иске бритвасы белән кырына башлады.

* * *

Ниһаять, ачык ишектә Гөлүсә үзе пәйда булды.

— Исәнме, Гази!..

Йа-а, Алла!.. Изге җан, синме соң бу?! Төш кенә түгелме? Бары тик шунда, Гөлүсәнең тавышын ишеткәч кенә, яшьлеге белән кабат күзгә-күз очрашкандай булды.

— Саумы, Гөлүсә... Исән-имин генә йөрешме?..

Сүзләре беткән кешеләр сыман, икесе дә бермәлгә тынып калдылар. Кая китте Газиның, очраша-нитә калсалар дип,

йөрәгенең иң түренә, иң тирән урынына туплап-хәзерләп куйган иң кадерле, иң мөкатдәс сүзләре?! Кайда алар?..

Хәер, хисләр тулышканда сүзләр нигә!.. Менә Гөлүсәсе аның каршысында гына ич... Кул сузымында гына.

Гөлүсә тагын да якыная төшкәч, янә бер нәрсәгә игътибар итте Гази: кунагының күзләрендә мәңге эремәс боз булып тирәнгә киткән бер яшерен сагыш чагыла. Менә ул еллар моңсулаткан күзләре белән Газиның йөзенә томырылып карап торды да:

— Йа-а, Ходаем! Бу көннәрне дә күрәсем бар икән!— дип куйды. Гөлүсәнең йомшак-мөлаем тавышы йөрәкләрне айкап алды.

Гази тамак төбенә ниндидер элпә килеп бөялүен тойды. Әмма үзен бик тиз кулга алды, күңелендә кайнаган хис-фикерләрен бер җепкә тезәргә көч тапты:

— Минем дә, Гөлүсә... бер күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем, дигән чакларым күп булды. Бөтен ихтыярымны туплап: «Юк-к, Гөлүсәне күрмичә үләргә хакым юк!»— дип, гел тәкрарлап тордым...

Гөлүсә тагын елмайгандай итте, тагын Газины тынычландырды. Әмма күпме генә тырышса да булдыра алмады: күзләре көлсә дә, күңеле елый иде аның.

Менә аның бер генә мизгелгә иреннәре тетрәнеп куйды. Йөзендә авыр кичереш, югалып-аптырап калу галәмәтләре... Күз яшьләрен күпме генә тыярга тырышса да, күңеле мөлдерәмә тулган иде, ахры, дымлана башлап авырайган керфекләрен чет-чет йомгалап алды да кисәк кенә читкә борылды... Һәм, йөзен куллары белән каплап, сулкылдап үксергә үк кереште.

— Зинһар, Гази... Гафу итә күр мине...

— Һаман да ышанып бетә алмыйм... Синме соң бу, Гөлүсә?..— диде ул, йөрәк түреннән чыккан бер җылылык, ягымлылык белән. Хисләренә буылыр дәрәҗәгә җитеп дәвам итте:— Бу сүзләремә гаҗәпләнмә, Гөлүсә!.. Менә чирек гасыр инде уем, сагышым, сөенечем, көенечем, өметем, шигем бер син идең. Бу хис шундый кодрәткә ия иде, хәзер инде уйлавы да хәтәр... Әгәр дә шушы көнгәчә бу дөньяда яшәгәнмен икән, бел, бары син булганга, күңелемдә сине бер күрергә ашкыну булганга гына яшәдем. Мәхәббәтем исәбенә яшәдем...

Газины яман да хәтәр уйларыннан арындырырга теләгәндәй, Гөлүсә сөйләвендә булды: — Күп тә үтмәде... безнең нәселле

җәнлекләр совхозының даны илебезгә генә түгел, бөтен дөньяга таралды. Эти эшне зурдан йөртә белде. Совхозның директоры да, бер үк вакытта баш зоотехнигы да иде. «РСФСРның атказанган зоотехнигы» дигән мактаулы исем дә бирделәр үзенә. Ун-унбиш ел рәттән инде район Советында депутат булып тора.— Бу сүзләрне Гөлүсә бары тик сүз булсынга, бары тик Газины кирәкмәгән ямьсез уй-кичерешләрдән, кара өметсезлеккә бирелүдән азат итү өчен генә сөйләде.— Алда әйткәнемчә, совхозыбыз асыл мех җитештерү белән шөгыльләнә. Һәр елны җиде-сигез миллион сум саф табыш алабыз. Кешедән өзелгән юк. Шуны истә тотып, эти, тайганы ярып, сопкаларны шартлатып, район үзәге белән совхоз арасына менә дигән юл салдырды. Хәзер бездә чит ил кунаклары да бик еш булалар. Мин дә, Гази, вакытны тиккә генә уздырмадым. Эти белән бергә эшлим. Баш ветврач мин хәзер. Тагын бер куанычлы хәл булды: газеталарда чыккан мәкаләләремне, киңәшмә-слетларда ясаган чыгышларымны бергә туплап, аерым китап итеп бастырып чыгардылар. Шул китап нигезендә диссертация яклатып, фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирделәр үземә...

— Гөлүсә!.. Кулыңны бир...— диде Гази, тыныч, бер үк вакытта шомлы тавыш белән.— Тиз бул!..

— Нәрсә булды, Гази?..— Гөлүсәнең дә тавышы каушап, калтырап чыкты.

— Гөлүсә...—диде Гази, ниндидер хәлсез бер пышылдау белән.— Хуш!.. Бәхил бул... Мин китәм...

— Ю-ук, Гази-и!..— диде Гөлүсә, әчке бер тетрәнү белән,— ю-ук, үлмисең...

Ул тәкате бетеп сикереп торды да сырхау өстенә иелде. Газины шушындый да битараф, шушындый да гаҗиз кыяфәттә күрермен дип ул башына да китермәгән булгандыр, күрәсең. Кинәт кенә дөньяның асты өскә килгән сыман булып тоелды аңа. Һәм ул, кабат Гази өстенә иелгәндә, чәчрәп чыккан кайнар яше аша, Газиның тутырып, томырылып караган хәрәкәтсез күз карашларын гына абайлый алды...

Сораулар һәм биремнәр

1. Романның сюжет сызыкларын билгеләгез. Алар кем образлары белән бәйле?

2. Әсәрнең жанрын ачыклагыз.

3. Газиның фаҗигале тормышын исегезгә төшерегез. Аның балачагы нинди шартларда үтә?

4. Гази ни өчен мәхәббәтенә хыянәт итә?

5. Аның тормышында Кадыйр нинди роль уйный? Алар арасындагы каршылыкның сәбәбе нәрсәдә?

6. Гази фаҗигасенең тагын нинди сәбәпләре бар?

7. Әсәр исемен аңлатыгыз.

8. Иргали башыннан үткән хәлләрне кыска, җыйнак итеп сөйләп чыгыгыз.

9. Иргали — Халәп каршылыгы белән автор нәрсә әйтергә тели?

10. Иргалинең эш-гамәлләренә бәя бирегез. Туган ягында һәм Себердә яшәгәндә аның нинди сыйфатлары ачыла?

11. Әсәрдәге төп каршылык нидән гыйбарәт?

Әмирхан Еники
(1909—2000)

Әмирхан Еники (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев) 1909 елның 2 мартында Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында туа. Әмирханга ике яшь булганда, аларның гаиләсе Дәүләкән дигән авылга күчеп килә. Башлангыч белемне ул шушы авыл мәктәбендә ала. Шул елларда ук әдәбият-сәнгатькә туган мәхәббәте аны 1925 елда Казанга китерә. Биредә ул иҗат эше белән дә кызыксынып китә. 1926 елда «Безнең юл» журналында аның «Озын көй тыңлаганда» дигән беренче хикәясе басыла.

Ә. Еникинең җитлеккән әдәби иҗаты Бөек Ватан сугышы елларында башлана. Бу еллар аның өчен катлаулы һәм тирән мәгънәле тормыш мәктәбенә әвереләләр. Сугыш чорында ул дөньяны һәм кешеләрне төрле яклабрак, тирәнрәк аңларга өйрәнә. Нәкъ менә шушы шартларда Ә. Еникинең иҗат үзенчәлеге формалаша башлый. Моны аның сугыш елларында язылган «Бала»,«Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каен», «Мәк чәчәге» кебек хикәяләрендә шактый ачык күрергә була. Аларда, ул вакытта әдәбиятта гомумән кабул ителгәнчә, сугыш кырын, анда күрсәтелгән батырлыкларны сурәтләү максат итеп куелмый, автор игътибары сугыш темасын күбрәк мораль-этик планда, кешеләр күңеле аша яктыртуга юнәлдерелә.

Кеше күңеле, аның язмышы белән кызыксыну Ә. Еники иҗатында алга таба тагын да көчәя. Әйтик, «Саз чәчәге» повестенда татар әдәбиятында беренче мәртәбә диярлек партия җитәкчесе — райком секретаре тәнкыйть объектына әверелә. Әгәр моңа кадәр һәм әле алга таба да дөньяда иң гадел һәм иң саф дип пропагандалап киленгән коммунистлар партиясе вәкилләре

әдәбиятта уңай яктан гына, үрнәк герой рәвешендә генә күрсәтелеп килсәләр, Ә. Еники әсәрендә исә райком секретаре Мостафин социалистик мораль нормаларын бозучы, шунлыктан тәнкыйтькә лаек зат итеп бирелә. «Рәшә» повестенда үзәк герой Зөфәр Сабитов совет чынбарлыгына яраклашып, ул биргән мөмкинлекләрдән файдаланып яшәгән сорыкорт итеп күрсәтелә. Үзәк геройның бу рәвешле сурәтләнүе ул вакыттагы әдәбият өчен шулай ук яңа күренеш иде. «Вөҗдан», «Без дә солдатлар идек», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьлары да үткәндәге һәм хәзерге яшәешнең моңа кадәр татар әдипләре күреп өлгерә алмаган күренешләрен һәм мәсьәләләрен психологик планда, ягъни әхлакый анализ аша үткәреп яктыртулары белән татар әдәбиятында үз урыннарын алдылар.

Ә. Еникинең соңгырак чор иҗатында бигрәк тә ике әсәре игътибарга лаек. Сүз «Әйтелмәгән васыять» исемле күләмле хикәя (1965) һәм «Соңгы китап» дигән автобиографик характердагы әсәр (1981—1985) турында бара. Алар татар халкының милли рухы һәм язмышына караган мәсьәләләрне яктыртулары белән укучылар дикъкатен җәлеп иттеләр һәм милләт язмышы мәсьәләләренә, гомумән, татар әдәбиятында игътибар артуга булыштылар. «Әйтелмәгән васыять»тә милли-рухи кыйммәтләрне белү һәм саклау татарны милләт буларак яшәтүнең мөһим чараларыннан берсе итеп карала. Икенче яктан, автор хәзерге шәһәрләшү процессының кайбер замандашларны, бигрәк тә яшьләрне, милли җирлектән аеруын һәм шунлыктан аларның үз халкы язмышына һәм рухи кыйммәтләренә битараф манкортларга әверелүләрен күрсәтә. «Соңгы китап»та да үзенең тормыш юлын, шәхси күргән-кичергәннәрен сурәтләү аша әдип шулай ук татарның милли тарихы һәм язмышы турында уйлана.

Өлкән язучыбыз Әмирхан Еники 2000 елның февралендә Казанда вафат булды.

Сорау һәм биремнәр

1. Ә. Еникинең тормыш юлын, ул булган урыннарны ачыклап, әдәби карта сызыгыз.

2. Әдипнең «Кем җырлады?» хикәясен хәтерегезгә төшерегез. Темасын билгеләгез. Автор сугыш фаҗигасен нинди чаралар ярдәмендә ача?

ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

I

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр. Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәр»не җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнгәме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә яки тиктомалга яндыра да башлый. Менә бүген дә гел туңып тора, аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк»,— ди ул, үз-үзенә иренеп кенә һәм авылга таба борыла.

Бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән?

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Аның хәзер бер генә эше бар — ул ялан таптарга ярата. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да төгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр.

Карт әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

— Нихәл, арумы, Миңлебай агай?— диде.

— Каян кайтып киләсең болай?— диде карт.

— Менә кизәк җыярга чыккан идем.

— Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

— Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора,— диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

— Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек,— диде карт.— Ярый, кортка, юлыңда бул!— Һәм карт озын аякларын сыга биреп китеп барды.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда ашсуы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗалы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә иплэп кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су җылытып, табак-савытын юу, аннары әзер казанда үзенә бер-ике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Ләкин карчык сизә: пешерә дә, ашый да алмас төсле; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана. Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрен алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишегалдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

— Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә бөгәрләнеп ятты. Ятып күзләрен йомуга, ул салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте. Күпмедер вакыттан соң бераз җылынган кебек булды. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсың-эчәсең килмиме дип сорады. Әбинең җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте.

Карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күршеләре кереп аның хәлен һаман белә тордылар.

Гарифә исә, ашау-эчүен кайгыртып, йорт-җирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа әллә улларыңа, кызларыңа хәбәр итикме дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде. Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, шушында гомере буе яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята — йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр — шулай уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы нигезендә нык торды. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта. Тик бу бәләкәчләрнең эти-әниләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарган кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча тордылар. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә, кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян — хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач...

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле... Менә зур улы Суфиян. Беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар — аңа

бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, ниндидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисекарчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушка»ны күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык аның чуар күлмәк кигән киң аркасына читән аша гына карап кала иде.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиңнәре бөтенләй юк диярлек иде — кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр. Оныгының күңелен табар өчен, Акъәби әледән-әле башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий, берни аңламыйча, «бабушка»сына бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

— А, да-да, точно!— дип баш кагып куя иде.

Менә шулай Акъәби, ялгыз башы улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, исән-имин генә яшәп килде. Әмма быел урынга ук ятарга мәҗбүр булды. Күршеләре, карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип, үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар. Гарифә барып әйткәч тә, Сәетгали икенче көнне үк, мотоциклын пырылдатып, Акъәби капкасы төбенә килеп туктады:

— Саумы, Акъәби!— диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп. — Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

Сәетгали карчыкның суырылып саргайган йөзенә беравык сынап карап торды:

— Әллә, мин әйтәм,— диде бригадир, сак кына,— калага хәбәр итикме? Суфиян агай йә булмаса Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

— Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр,— диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап. — Рәхмәт керүеңә, Сәетгали улым.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар.

Ә берничә көннән соң өр-яңа «Волга» машинасы Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Кызының: «Әсәем!»— дип дәшүен ишеткәч, Акъәби сискәнеп күзләрен ачты.

— Кызым, Гөлбикә!— диде ул, өзелеп.

Кызы, шунда ук килеп, аның өстенә иелде, маңгаеннан үпте, һәм алар, тотынышып, икесе дә елап җибәрделәр.

Карчыкның кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп уңайсыз иде, һичнигә карамыйча, аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде.

— Әсәем,— диде кызы, әнисенә үрелеп. — Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсең.

Кияве дә шунда ук өстәде:

— Дөрес, әби, бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең?

Карчык авыр сулап кына куйды. Тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, Ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына — карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар, каладан кайткан кадерле кунакларга ашап-эчкәндә комачауламас өчен, шулай әдәп саклап көтебрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби — аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, аңа бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур

вакыйга иде. Йөзләре дә аларның җитди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде, ахрысы, һәркайсында корткабызны яңадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гаҗәп бит ул — кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тора кебек.

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине, кызы белән Гарифә ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар, ипләп кенә утырттылар. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде:

— Акъәби җаным, хуш, сау бул инде!

— Акъәби бәгырем, терелеп кайта күр!

— Хуш, безне онытма, без көтәбез сине!— диделәр аңа.

Ә таякка таянган бер корткa:

— Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен!— диде, бик тыныч, әмма чын күңелдән бик ихлас итеп.

Машина шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби, кинәт урыныннан кузгалып:

— Һай, кәфенлегемне оныткaнмын лабаса!— диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм, чыраен сытып:

— Куйсана, әсәй!— диде, үпкә катыш рәнҗү белән. — Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

II

Менә Акъәби ялгызы кечкенә генә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тоныкс кына ишетелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята.

Карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп киттеләр. Чукечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тартынмыйча киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә, рәхәтләнеп

яши иде. Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли.

Әнисе янына күрешә килгәч тә, ул карлыкканрак тавышы белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

— Һай, әсәй, әсәй, әсәем! — диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып. — Ну, ничего, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: «Солдатны пуля түгел, паника үтерә»,— дип... менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..

— Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна, каенанасы белән ике куллап күреште. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк — карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде.

Икенче көнне карчык янына күрешергә дип Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде — барыбер аның токымы, аның каны! Ах бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы — Татьяна, Светлана, Рита белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, бабушка!» — дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен карават янындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик дигәндәй, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык.

Ә Акъәби үз нәүбәтендә бу җитеп килгән таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Карчык тирән генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул, үзенеке! Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгыре күпме генә сызланмасын, әмма оныклары аңа бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын доктор ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Тагын берничә көн үтте, һәм менә шул ук хатын доктор олы яшьтәге озын, чандыр, күзлекле бер ир кешене ияртеп керде. Моны шәһәрнең бик атаклы профессоры дип әйтәләр. Үзе татар икән. Шул профессор карчыкны игътибар белән тыңлады, сорашты... Карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык белән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» — диде. Шуннан соң барысы да, залга чыгып, үзара тагын нидер сөйләштеләр.

Докторлар карчыкның үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, җитмештән узган карчыкка операция ясап торуда мәгънә юк. Хәер, үзенә әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мөсафир гына...

Акъәби калага килеп урынга яту белән, Казакъстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип гел юатып тордылар. Ләкин шулай да язарга ашыкмадылар.

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. Бигрәк тә соңгылары өчен бу бик читен хәл: алар үзүзләренә икърар итәргә курыксалар да, ничектер ихтыярсыздан «ахырын» көтә башлыйлар. Акъәби моны әле сизми иде, элекке кебек игътибар да бар, карыйлар да үзен, әмма шулай да нәрсәдер, җан җылысымы, борчылып торумы кимеде кебек.

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый. Тик ул көне буе ялгыз ятудан туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә. Бигрәк тә кызының ике баласын — алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Гүзәле, кыз бала булганга, ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына, аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!» — дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу җанга якын, тансык, кадерле «әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр. Кунакларның күбесе читтәге бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем!» — дип, ике куллап күрешә, аннары урындык алып, карават кырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк, тезләренә таянып, тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның эчкәнме-түгелме икәнен дә аера алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бертөсле була торган иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, берберсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

— Акъәби, Акъәби! — ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй, әкрен генә. — Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

— Минем исемем Акъәби,— ди карчык, бу көтелмәгән сорауга бераз пошынып. — Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...

— Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул.

— Рәхмәт, улым! — ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

— Юлкотлыны сагынасыңмы?

— Сагынам, улым!

— Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби! — дип әйтәсе килеп тора.

Шагыйрь, кызыксынып һәм карчыктан ипләп кенә, аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны,

җырларны сорашырга тотына... Карчык ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр эчке уен раслагандай әйтеп куя:

— Ийе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

— Килешмичә нихәл итәсең инде...

— Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

— Хәзергесе начар булса, сагыныр идем,— ди карчык, уйланып кына. — Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

— Шулаймы?.. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — барысы да онытылмаска тиеш, минемчә...

«Сәер кеше! — дип уйлана карчык. — Ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә ниндидер сызлавыгы бар шикелле, җанына урын таба алмыйча, шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!» Һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, ихластан кызганып кала торган иде.

...Бер ике-өч атна үтүгә, карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Башта ул, чынлап та, Юлкотлысын сагынып йөдәде. Бөтенесе — яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре, маллары — бер генә минутка да исеннән чыкмый...

Карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар — җитдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, Алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән, гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели: гәүдәмне әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле кабергә куйсыннар иде.

Кызы бер кичне аның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

— Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар,— диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән. — Алладан вакыт җитә шикелле, шулай сизәм... Э-э, әйе... кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч, гәүдәмне...

— Әсәем бәгырем, ярамый сиңа сөйләшергә, — диде кызы, кат-кат башын селкеп. — Хәлең юк, тавышың бетә, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

— Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул...

Кызы урыныннан ук торды, ул, гадәтенчә, каядыр ашыга иде.

— Ярый хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде. Әмма аның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Балалар белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизенә: балалары аның — бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Ләкин шулай да аның балаларына үпкәлисе, рәнҗисе килми.

Җитмеш алты ел буе дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы малмөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән, үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар — шуларның барысын да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзаркурасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсеннәр.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп, атап биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын — Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән әдрәс[1] астарлы кашмау[2] белән чәчкабын[3] — Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат

[1] Әдрәс — ярым ефәк чуар тукыма.
[2] Кашмау — кием.
[3] Чәчкаб — баш киеме.

бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде.

Билгеле, кызы — кашмауны, килене бөятне киеп йөрмәсләр. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул — Акъәби дигән кортка яшәп килде. Ул менә аларны моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, Ходаем, туган илкәйгә юл? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил — туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларның сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минҗиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар, һәм ул аларны, кая гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә: «Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез Аслы күл әйләнәсендәге киң, тигез далада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы Аслы күл Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендыру өчен, атагыз мәрхүм сезне арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә Аслы күлнең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган нәкъ түбәсенә куш каен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зыятүләк белән Сусылу» әкиятен ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган әкият ул, ә тауның түбәсендәге куш каенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере диләр, каеннар түбәннән бәреп торган чишмәне Сусылуның озын, кара толымнарыннан саркып чыккан су диләр. Әнә шулай әкиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең Аслы күл яклары! Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз...

Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны бетергәч, калага китәбез дидегез,— каршы тормадык. Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез. Бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз?

...Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыруглан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы сүз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәбберга бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит — халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә. Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган зиратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның каберенә бер ком таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени?

Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде — сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы? Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Ләкин ул авызын ачты исә, аңа: «Һәй, әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма әле»,— диделәр, гел тыйдылар һәм аны юатыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Үлем дә ашыга иде шикелле. Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте. Тын алуы бик авырлашты, кислород мендәреннән бер дә аерылмас булды.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр — торса, тагын бер атна-ун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тудырды.

Кияве белән кызының фикерләре бер иде: карчык квартирада үлсә, бик авыр, бик күңелсез булачак. Нишлисең инде, үләргә булгач, кайда да барыбер... Аның каравы балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар.

Бу карарларын, уңайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште.

— Што сез,— диде кычкырып,— кадерле әсәебезне, өйдә үлмәсен өчен генә, больницага илтеп салмакчы буласыз!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

— Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык... Әсәй үзе моның өчен безгә рәхмәтен әйтер дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тотасың да үзеңә аласың... Сиңа да ана бит ул!

Бу сүзләрдән соң Суфиян, шактый аптырауга төшеп, җилкәсен кашырга тотынды. Һәм бу мәсьәләдә үзенең ялгыз калуын гына түгел, бигрәк тә көчсез булуын сизеп, ниһаять, килеште.

Инде моны карчыкның үзенә җиткерергә кирәк иде. Улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй җаным,— диделәр алар аңа, иплэп кенә,— докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та, кире алып кайтырбыз үзеңне...»

Акъәби моның сәбәбен сизгәндерме-юктырмы, әмма «болнис» дигән сүз үзе генә дә аның котын алды. Тәмам куркып, рәнҗеп һәм ялварып ул: «Балакайларым, зинһар кузгата күрмәгез, шушы җылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми, вакытым җитте, аңлагыз шуны!» — диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып, хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар һәм больницага илтеп салдылар.

...Өч тәүлек үткә, төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Җан биргәндә, янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча, күбәләктәй киткән дә барган.

Иртән иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве шунда ук машинага утырып больницага киттеләр. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария

Васильевна да килеп җиттеләр. Ак җәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек җирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, җеназа укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең Аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин гөнаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы марҗалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан, Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәҗбүр булдылар.

Табутны кабергә төшергәндә, кызы Гөлбикә бик каты елады, Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушкаларын» кызганып елашып алдылар. Ләкин ирләр түзделәр... Суфиян, әсәен озату шәрәфенә бөтен орден-медальләрен өр-яңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник, кабер кырыенда таш сындай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән оныткан кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр иде шикелле.

...Күмеп бетергәч тә, борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды:

— Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы, инде үләннәре дә корыган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек,— диде ул, салмак кына. — Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?.. Күрә белдекме без аның шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, аның уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян, кычкырып, аның сүзен бүлде:

— Син ни сөйлисең, ә? Ташла, кирәкми...

— Безобразие бу! — диде кияве дә, кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич игътибар итмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп,

кабердән җилтерәтеп читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Иң ахырдан кузгалган Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы карт-корыларның учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр... Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъәби берүзе генә торды да калды.

Әмма ләкин Акъәби, биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Хикмәт шунда: кызы Гөлбикә Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахырында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми, Гарифәдән дә Акъәбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күрше-тирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз, дип борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук карчыкның колхоз машинасына салып җибәргән иске яшел сандыгы да килеп төшә. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр аның шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары да бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты.

Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта бербересенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте, кашмавы, чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында ук үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарының камчат бүреге дә килеп чыкты. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле камчысы иде.

— Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бу! — дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

— Да-а, менә бу ичмасам реликвия! — диде кияве дә, сокланып. — Тик кем саклар аны?

— Ә аның хуҗасы бар, — диде Суфиян катгый рәвештә һәм улы Геннадийга борылып әйтте: — Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы бу!..

...Инде калган әйберләрне нишләтү мәсьәләсе кузгалды. Кияүләренең башына шәп бер идея килде. Ул болай диде:

— Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит... Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр.

Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен кием-салымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп саф көмештән эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш, үзенең иске эзеннән ашыгып, һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә.

Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:

— Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми — ул бит аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган ахрысы бу картка»,— дип уйлый ул эченнән генә һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:

— Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый.

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

— Алдама, — ди ул, таягының башын селкеп. — Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич аңламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөз яшәр Миңлебай карт!

Сорау һәм биремнәр

1. Вакыйгаларны мөмкин кадәр кыска итеп сөйләп чыгыгыз һәм әсәрнең композиция үзенчәлеген билгеләгез.

2. Хикәянең конфликты нидән гыйбарәт?

3. Акъәбинең эчке каршылыгын аңлатыгыз.

4. Әсәрдәге кылган һәм учак образларының вазифасын билгеләгез.

5. Хикәянең темасын ачыклагыз.

«Әйтелмәгән васыять» хикәясе

60 нчы еллар уртасында язылган хикәя бүген дә яратып укыла, җанны айкый, хис-кичерешләрне кузгата. Моның сәбәбе нидә соң? Күрәсең, бер яктан, күтәрелгән мәсьәләләрнең җитдилегендә, яшәү һәм үлем фәлсәфәсенә бәйле ана-бала мөнәсәбәтенең якты дөньядагы соңгы теләк-васыятькә бәйле ачылышында булса, икенче яктан, Әмирхан Еники стиленә хас булганча, сайлап алынган тормыш материалының ачыклыгы, вакыйгаларның кеше күңеле аша сурәтләнүе, үзгә бер моң, лиризмның җан сыкравы белән кушылуы аша аңлатыла. Зур булмаган хикәягә эчке җыйнаклык, композицион төзеклек хас. Ул башкорт даласы күренеше белән башланып китә һәм шуның белән үк тәмамлана. Әлеге вакыт аралыгында бер гаилә язмышы, кеше фаҗигасе ачыла. Хикәянең мәгънәви, фәлсәфи катламы тагын да тирәнрәк — анда тулы бер милләт язмышы чагыла. Үзәктә Акъәби һәм аның балалары арасындагы каршылык тора. Ул ике катламда бирелә. Тышкы яктан әлеге каршылык артык күзгә бәрелеп тормый. Дөрес, әбинең кәфенлеген кире кайтып алмыйлар, васыятен тыңламыйлар, теләгенә каршы килеп, больницага салалар һ. б., әмма башкалар күзенә балалары яхшатлы булып күренә, чөнки авырып киткәч, әбине шәһәргә алалар, төрлечә күңелен күрергә тырышалар, һәрвакыт төче елмаеп сөйләшәләр. Каршылыкның чын асылы рухи дөнья белән бәйле. Акъәби балаларын намуслы, әхлаклы тәрбияләргә тырышып, укытып кеше итсә дә, ике арада рухи бәйләнеш, күз карашыннан аңлашыла торган үзара җылы мөнәсәбәт юк. Балалары, заманча яшибез дип, туган җир, нәсел, ата-баба туфрагы, буыннан буынга бирелә торган изге төшенчәләр белән бәйләнешне өзгәннәр. Балалары белән ике арада күңел җылылыгы булмау Акъәбине тирән кайгыга сала, әйтелмәгән васыять рәвешендә бирелүе хәсрәтне тагы да тирәнәйтә, җәрәхәтле

итә. Монда әбинең эчке каршылыгы да ачыла. Ул, бер яктан, мәңге искерми торган төшенчәләрнең югалуын күрә, шунда ук заманнан артта калдым дип шикләнә, икенче яктан, балаларының үзләре теләгәнчә һәм бәхетле (һәрхәлдә, тышкы яктан һәм алар аңлаган мәгънәдә) яшәүләренә сөенә, шунда ук үзе үлү белән нәрсәнеңдер өзелүен аңлап, киләчәк өчен борчыла.

Әсәрдә кылган һәм учак образлары бар. Кылган, дала күренешенең мөһим элементы булу белән бергә, Акъәби балаларының яшәү рәвешен аңларга ярдәм иткән символ да булып тора. Җил уңаеннан әле бер, әле икенче якка бөгелеп утырган кылганнар кебек, иманнарын югалткан әлеге кешеләр дә — туган туфрактан, милли яшәештән аерылган, үз кыйбласы булмыйча, тормыш уңаена гына яраклашучылар. Учак образы да тереклекне, тормыш дәвам итүен аңлата. Ул сүнмәсен өчен, буыннар арасындагы бәйләнешне өзми сакларга кирәк. Әсәр ахырында Миңлебай карт болай ди: «Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен». Җәмгыятьтәге шартлар шундый булу аркасында милләт үзенең асыл сыйфатларын югалта бара. Әмма тормыш үзгәрер. Гореф-гадәт, традиция, яшәү рәвешен сакларга, үстерергә кирәклеген аңлаган яңа аккиленнәр, акъәбиләр җитешер. Аларга әлеге бәйләнешне тапшыручы, үзара тоташтыручы гына булсын, дип әйтә кебек әдип. Шулардан чыгып, хикәянең темасы ачыклана — рухи-әхлакый мирасны саклау.

Мөхәммәт Мәһдиев

(1930—1995)

Үзенең кайбер чордашларыннан Мөхәммәт Мәһдиев әдәбиятка соңрак, әмма катлаулырак юл үтеп һәм зуррак тәҗрибә туплап килүе белән аерылып тора. Табигый, бу хәл аның иҗатына да билгеле бер эз сала.

Мөхәммәт Сөнгат улы Мәһдиев 1930 елның 1 декабрендә хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы Гөберчәк авылында туа. Сикертән авылындагы җидееллык мәктәпне һәм Арча педагогия училищесын тәмамлагач, ул төрле мәктәпләрдә укыта. 1950—1954 елларда М. Мәһдиев Балтыйк хәрби диңгез флотында хезмәт итә. Армиядән кайткач, ул кабат мәгариф эшенә алына, ягъни 1955—1960 елларда туган районындагы мәктәпләрдә укыта. Бер үк вакытта Казан дәүләт педагогия институтының тарих бүлегендә читтән торып укый. 1960 елда ул Казан дәүләт университетына аспирантурага укырга керә һәм, аны тәмамлап, 1964 елда «Татар совет әдәби тәнкыйте (1917—1932 еллар)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Моннан соң ул әлеге университетның татар әдәбияты кафедрасында озак еллар укыта.

Табигый, М. Мәһдиев үзенең иҗат эшчәнлеген дә әдәбият фәне һәм тәнкыйть өлкәләрендә башлый. Аны бигрәк тә татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере, әдәбият һәм тәнкыйть тарихы, халык иҗаты кызыксындыра, һәм ул болар хакында күп санлы мәкаләләр һәм монографик хезмәтләр яза.

Шулай зур гына тормыш тәҗрибәсе туплаганнан һәм фикри яктан шактый җитлеккәннән соң гына М. Мәһдиев әдәби иҗат эшенә ныклап алына, бу эштә баштан ук үзенең күргәнкичергәннәренә таяна. Бу хәл аны үзенчәлекле язучы итеп таныта башлаган беренче күләмле әсәре — «Без — кырык

беренче ел балалары» повестенда (1968) ук ачык чагыла. Укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан җылы каршыланган бу беренче җитди иҗат җимешендә ул, педагогия училищесында укыганда күргән һәм кичергәннәренә нигезләнеп, сугыш елларында әлеге училище укучыларының көндәлек ачлы-туклы тормышын һәм бай хыялый дөньясын бик оста тотып алынган детальләр һәм тапкыр күзәтүләр ярдәмендә, әле тормыш кырыслыгы белән, әле шаян юмор ярдәмендә, кыскасы, моңа кадәр әдәбиятта күрелмәгән рәвештәрәк яктырта һәм болар белән әсәр әдәбиятыбызга яңа үзенчәлекле әдип килүен хәбәр итә.

Беренче повестеның шулай җылы каршылануы белән рухланып, М. Мәһдиев алга таба әдәбиятның тагын да күләмлерәк, масштаблырак формасына алына һәм «Фронтовиклар» дигән романын яза. Монда инде автор шулай ук үз биографиясенә нигезләнеп, сугыштан соңгы еллар авылына мөрәҗәгать итә һәм аның авыр тормышын төрле яклап сурәтли. Әсәрдә бигрәк тә әлеге еллардагы авыл мәктәбе тормышына игътибар зур булды. Бу тормышны үзенә бер дөнья итеп күрсәтеп, автор шушы дөньяның үзенчәлекле кешеләрен алга бастыра. Биредә дә язучының үзенчәлекле характер сыйфатлары — оста күзәтүчәнлеге, тапкыр фикерле булуы мөһим роль уйный.

Татар халкы өчен асыл дөнья булган авыл хәятен фәлсәфи-әхлакый пландарак аңлату һәм күрсәтүне дәвам итеп, М. Мәһдиев алга таба «Каз канатлары» романында, «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Ут чәчәге», «Исәнме, Кәшфи абый!» повестьларында әлеге дөньяның яңадан-яңа якларын ачты, аның турында белемебезне тагын да баетты. Аларда аеруча туган җиргә, аның тырыш һәм тыйнак кешеләренә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләрен чагылдыруга басым ясады.

Мөхәммәт Мәһдиевнең гомере ахырындарак язылган һәм иҗатына күпмедер нәтиҗә ясау төсен алган әсәре — «Бәхилләшү» повесте. Анда әдип татар авылының рухи-әхлакый характердагы елъязмасын хәтерләткән иҗатында әлеге дөньяның моңа кадәрге әсәрләрендә чагылып бетмәгән яңа мизгелләрен таба, аны тагын да тулыландырып, баетып күрсәтә. Бер үк вакытта бу әсәр әдипнең үзе тумыштан яхшы белгән, хөрмәт иткән, әмма хәзер инде үткәндә калып барган традицион татар авылы белән саубуллашуы, бәхилләшүе кебек тә яңгырый...

Сорау һәм бирем

1. М. Мәһдиев иҗатына аның шәхси тормыш тәҗрибәсе ничек тәэсир итә?

2. Әдипнең әсәрләрен тема һәм жанр ягыннан төркемләп, дәфтәрегезгә языгыз, нәтиҗә ясагыз.

БӘХИЛЛӘШҮ

(Повестьтан өзекләр)

> Миңа калса, заманнар узу белән язучылар әдәби әсәр уйлап чыгарудан гомумән туктарлар кебек... Язучылар, әгәр инде алар булсалар, уйлап чыгарып язмасалар, бәлки тормышта үзләре күзәткән әһәмиятле яисә кызыклы нәрсәләр турында гына сөйләрләр.
>
> *Л. Н. Толстой*

> Бәлки, сез «әхлакка моннан ни файда» диярсез. Гафу итегез, кешеләргә татлы әйберләрне җитәрлек ашаттык, моңардан аларның ашказаннары бозылды; ачы дарулар, яндыра торган хакыйкатьләр кирәк.
>
> *М. Ю. Лермонтов*

I

Исламгали — колхозның менә дигән тракторчысы — сугышта ике кулын беләзектән өздереп кайткан иде. Казанның ортопедлары могҗиза ясадылар: ике кулының икесен дә урталай ярып, җәплекә эшләделәр һәм кашык тотарлык, каләм тотарлык уентык әмәлләделәр. Исламгали гомер буе җор булды, гарип калу да аның бу сыйфатына зарар китермәде: аның ике ордены бар, ә медальләрне гел өсти тордылар. Сугыштан да дүрт медаль белән кайткан иде, хәзер исә түгәрәк дата саен өстәп баралар. Исламгали ишетеп яши: шәһәрдә эчүчелек юлына баскан адәмнәр медальләрен саталар икән. Кайберәүләр шуны өч, ун, егерме сумга сатып алалар һәм тугызынчы май көнне күкрәкләренә тагып урамга чыгалар икән. Исламгали — сугыш гарасатын күргән кеше — бу турыда уйларга, сөйләшергә җирәнә. Ут эченә кергән өчен бирелгән медальне берәү дә сатмас; ут эченә үзе кереп, үлем белән күзгә-күз бер генә тапкыр булса да очрашкан кеше беркайчан кеше медален такмас...

Исламгали агай сугыш, госпиталь, өйгә кайту моментларын энәсеннән-җебенә кадәр хәтерли. Ул кайткан көннәрдә аларның өеннән кеше өзелмәде. Берәүләр аның җәплекәле кул белән ничек итеп ашаганын карарга, икенчеләр сугыш турындагы

хикәяләрен тыңларга киләләр иде. Ләкин үзенең ничек кулсыз калганын сөйләргә яратмый иде ул.

Аңа Ходай бирмеш һәр җәйне район тәэминат бүлегеннән санаторийга бер путевка җибәрәләр, Сочига тимер юл билетын өенә китереп бирәләр иде. Малае Хәмит, этисен җитәкләп, Сочи каласына ничә тапкыр барды икән? Ун яшеннән шулай йөрде, юл йөри торгач, русчага да байтак шомарды, моның исә Хәмит биографиясендә роле гадәттән тыш зур булды — анысын алдарак күрербез...

Берсендә, Тифлис — Мәскәү поезды белән кайтканда, этисенең пиджак кесәсеннән акчасын урладылар. Дөньяда ике кулсыз сугыш инвалидын талаучылар да булыр икән! Исерек бер адәм, төнлә кереп, бер-ике станция арасы гына утырып барган иде. Иртән купеда ул юк иде инде — кошелек та табылмады. Проводницага чәй өчен түләрлек тә акча юк иде. Ә көньяк юлындагы проводницалар шундый: биш тиенлек чәй өчен егерме тиен бирәсең икән — ярый, ләкин дә инде синең бер тиенең җитмәсә... Алла сакласын. «Безнең бригада фәлән-фәләнчә хезмәт күрсәтә, фәлән исемне йөртә» дип язганнарның ул моментта хәрефе дә калмый.

Шулай да кесәләрдән егерме тиенләп акча кырыштырып алдылар — анысы метрога кирәк булды. Малае Хәмит шунда эчтән бик нык елады; бер тиен акчасыз, билетсыз Мәскәү хәтле Мәскәүдә калып кара әле син... Этисе нишләр икән? Бер әмәл бар барын. Ул елларда инвалидлар вагон, вокзал тирәләрендә алларына кепка яки калай кружка куеп утыргалыйлар иде. Исламгали агай да, аягын бөкләп вокзал идәненә утырса, ике-өч сәгать эчендә кайтырлык акча туплый алыр иде. Халык сугыш инвалидларына карата ихтирамлы. Кемдер әлеге шәхеснең гариплеген күреп, кызганып, кемдер сугыштан кайтмый калган туганы — этисе-бабасы өчен садака бирә. Күзен түбән каратып, шул хәлгә риза булып утыра алган инвалидлар байтак кына акча җыялар. Малай этисен шул хәлдә күз алдына китерде. Менә актык тиеннәрен түләп, метродан Казан вокзалына килделәр. Нишләргә? Дошман гаскәрләренә каршы танк белән барган, Кызыл Йолдыз, Дан орденының өченче дәрәҗәсен алган батыр сугышчы хәзер нишләр? Малай ялварулы, кызганыч караш белән этисенең күзләренә текәлде. Нишләргә?

Этисе исә һич тә асфальтка утырырга җыенмады.

— Улым, кара әле кесә төбеңне,— диде. — Анда күпме бакыр калган?

Габделхәмит моны күңелдән белә иде. Тирләп беткән ике тиенлек ике акча аның уч төбендә иде.

— Менә, алайса, без болай эшлибез. Әйдә әле телефон янына...

...Сугыш ветераннары Советының җаваплы секретаре Алексей Маресьев кечкенә малай җитәкләгән инвалидны ишек ачып каршы алды, шундук ике стакан чәй китертте, Исламгали агайның кайсы тирәдә сугышканын сорашты, үзе гел нәрсәдер язды, язды, нәзек үкчәле туфли кигән нәзек билле секретарша кыз керде дә чыкты, керде дә чыкты. Шулай ярты сәгатьләр чамасы узды. Габделхәмит телсез калды: Борис Полевой язган очучы Маресьев бит инде бу! У, минме? Авылга кайткачмы? Малайларны күргәчме?

Маресьев исә алай шаккатмады, өстәл тартмасыннан бер китап алды да, аның тышлыгын ачып, беренче битенә нидер яза башлады.

— Исемең ничек?— дип сорады ул телсез калып утырган малайдан. Һәм бераздан аның вак, әлегә көчсез, шертләмә бармаклы кулын кысты: — Бу китап минем турыда,— диде. — Әлбәттә инде, Борис Полевой бераз арттырган. Мин андый ук герой түгел. Ләкин бер нәрсә факт — ике аягым да юк. Менә мин моны сиңа адреслап яздым. Миннән теләк шул: солдат хезмәтен уз. Билләһи! Шуны уз! Шуны узмаган егетләр белән узган егетләр арасындагы аерманы әгәр белеп бетерсәләр иде...

Казан вокзалына аларны Маресьевның машинасында секретарь кыз китерде. Купейный билетлар инде кесәдә иде, шуның өстенә, вагонга кергәч, теге кызый өстәлгә бер тартма куйды.

— Менә монысы сезнең хатыныгызга, Алексей Петровичтан күчтәнәч,— диде.— Ә менә монысы,— кызый конверт чыгарды.—Комитеттан. Сезгә бит әле тәүлеккә якын кайтасы.

Конвертта акча иде.

Исламгали әнә шулай асфальтка утырмыйча калды.

Поезд кузгалгач, улына әйтте:

— Менә, улым, кешеләр шундый булырга тиеш. Ә теге, кичә төнлә безнең купеда барган адәм — кеше түгел. Ул үзенең тормышын барыбер чәнечкеле чыбык эчендә чикләячәк. Аның әнә ике кулы, ике аягы бар иде. Ә безнең — Алексей Петрович белән — икебездә ике аяк, ике кул җитешми. Недостача! Менә ничек...

Халыкка исә, танкист Исламгали сугыш турында бер генә дә чын нәрсә сөйләмәгән кебек, бу очракны да сөйләми калды.

Ничә тапкыр аңа төрле газеталардан хәбәрчеләр йөрде, һәр орденының тарихы белән кызыксындылар — юньле бер материал ала алмадылар. Сөйләмәде. Сөйләгәне исә гел мәзәк булды. Кичен капка төбендә сугыш турында хикмәтле хәлләрне берәү сөйләп утырса — Исламгали агай, үзенең имәндәй таза, яшь килеш ике кулсыз калу фаҗигасен искә төшермәс өчен, һәрвакыт көлкеле тема тудыра, эзләп таба, кыскасы, гел ялган сөйли иде.

— Танкка кадәр разведротада булдым мин. Мине фашистлардан белмәгән кеше юк иде. Гитлер әйткән, ди, әллә ничә тапкыр: Мәскәүдән — Левитанны, Беренче Украина фронтыннан Ягудинны тотып китерегез, һәр икесенең башына йөзәр мең марка акча түлим дип әйтеп әйткән, ди. Шуларны пирвый усакка асам дип әйткән, ди.

Хатын-кыз кызыксына:

— Ул йөз мең маркага нәрсә алып була?— дип сорый.

— Аңамы?— ди Исламгали агай, бераз уйга калып. — Аңамы? Ике центнер арыш (икмәксез ел), аннан килеп бер кибән печән (мал курмысы хәзерләү крестьянның үзәгенә үткән!). Аннан килеп ике пар күн итек. И һәм дә бер тальян гармун. Өстәмәсенә.

Халык аһ итә. Аның саен әңгәмә кыза гына.

— Бервакыт Днепрны кичкәндә «разведка боем» ясадык. Камышлык тегендә. Чаж үләне. Җилдә чажылдап хәтәр шаулый. Ну мин сизәм: шул камышлыкта фашистлар утыра. Миңа нәрсә: мин инде — орденлы сугышчы, фашист белән йөзгә-йөз очрашкаладым. Автоматымны кысып тоттым, чакылдатып взводка куйдым, иптәшләремә мине ут белән сакларга кушып, камышлыкка ташландым. Хенди хох, мин әйтәм, такой-такой майтьлар, дим. Ие. Сугышта сүгенергә өйрәндем мин. Менә әле дә бизеп булмый. Хенди хох, фәлән майтьлар, ганслар, фрицлар, куртлар һәм башка сволочьлар, дим. Шуннан ни булды дип уйлыйсыз? Камышлыктан чаштырдап сигез фриц килеп чыкмасынмы? «Ягудин, атма, биреләбез,— дип ялвара ыстаршийлары. — Атма, Ягудин»,— ди... Ыстаршийны алар үзләре «обер» дип йөртәләр.

Шулвакыт күрше хатын Хәерниса җай белән генә Исламгалине бүлдерә:

— Карале, Исламгали, алар да татарча белә диген, ә? Үзе немец бит инде, немецнең дә бигрәк ние — «убыр» дигәне — безнеңчә белә диген, ә?

Мәсьәләнең мондый юнәлештә куелуы Исламгалигә ошап бетми, ул өстән генә, мыскыл итеп, Хәернисага карап ала. Ләкин ул кызган инде, кызган...

— Ә бервакыт урман аланында чолганышта калгач, сигез йөз фашистны әсирлеккә алдым.

Ирләр елмаешты, хатын-кыз таң калды.

— Ул тиклем халыкны нишләттең?— диде сугыш темасын аеруча яратучы Хәерниса.

— Нишләтим? Эш таптым. Бер колхозга алып бардым да атна буе чөгендер чүбе утаттым. Аннары ике көн буе бәрәңге басуында колоратурный жук чүпләттем. Эшләсеннәр. Талый белделәр ич.

— И Ходаем, теге корткыч коңгыз шул вакытта ук булган икән...

— Булмый ни? Фашист-собакаларга ияреп килде дә инде ул безнең илгә.

Габделхәмит үсеп килгән саен Исламгали агай мондый «капка төбе лекцияләрен» сирәгәйтте. Лекциянең соңгысы менә монысы булды, ахрысы. Авылда сугыш ордены икәү булган кеше бер Исламгали агай гына иде, көннәрдән бер көнне Кызыл Йолдыз орденын кайда, ничек алуын сораша башладылар.

Монысында ул баштарак дөресен сөйләде, ахрысы.

— Маршал Жуков үзе бирде, күкрәккә адъютанты такты,— диде.— Украинаны азат иткәндә. Тел алып кайттык — шәп күркә эләкте, офицер. Ну да ләкин телгә тилмергән идек инде. Һөҗүм алды — Мәскәү фронт командующиен кыса, тегесе — дивизия штабын.— Давай тел,— диләр. Шуннан башка һөҗүмгә тотынырга ярамый. — Тел кирәк, тел,— диләр. Ә аларның кысуы түбәнгә төшә-төшә миңа килеп терәлде. Миңа һәм дә бер урыс егетенә. Костромадан — Федор Шарапов. Таза инде менә — бер ашаганда дүрт пурсы ботка, бер кирпеч ипине ишеп кенә куя. «Полтора Ивана» дип йөртәләр иде үзен. Шуның белән чыктык теге якка. Шәп «кош» алдык. Кайтканда Федорым яраланды, аны тиз генә кыр госпиталенә озаттык. Сөйләделәр: маршал Жуков үзе кереп орденны тегеңә палатасында биреп чыккан. Менә нинди кеше! Ә миңа бөтен рота алдында бирде. Маршал киләсен бер сәгать алдан белдекме-юкмы, аны бит әле әйтергә дә ярамый. Шулай да юындык, кырындык, төймәләрне, итекләрне чистарттык. Бер урман аланы сыман җирдә без. Менә бервакыт капитан — рота командиры — бөтен бугазына кычкыра:

— Рота-а-а!— Ул гел шулай сузып әйтә иде.— Рота-а-а! Станови-и-и-сь!— Шулай сузып: —Ста-а-но-о-вись!

Ул арада урман юлында яшел-чуар газик та күренде. Комбат каушый калды, сузып торырга вакыт юк, чак-чак әйтте:

— Рота, равняйсь, равнение на середину,— диде дә машинага каршы торып та йөгерде. Ул арада машина кырт кына туктады, ишеге ачылды да маршал үзе килеп чыкты. Буйга бик биек түгел, ну да ләкин калын гәүдәле. Кызу-кызу атлап капитан янына килеп тә җитте, докладын тыңламады, кул биреп күреште дә строй каршына килеп басты. Тагын бер машина зур офицерлар килеп туктап читкәрәк коелдылар. Күз кырые белән карыйм, стройдагы солдатларның күзләрендә яшь. Менә солдат нинди нечкә күңелле була. Ул ара да булмады, маршал көр тавыш белән кычкырды:

— Сержант Ягудин, выйти из строя!

Менә шунда, билләһи, каушадым. Тез буыннарының хәле китте. Чыга алмыйм и вчу шунда. Комбат та куркып калды, анысы тиктәскә генә йөткеренә башлады. Ул арада маршал күзләре белән бөтен стройны ялап алды — ә мин торам.

— Сержант Ягудин!

Монысы үзебезнең комбат икән, бу тавыш минем аякларны ычкындырды. Чыктым, бастым. Ул арада командующийның адъютантыдыр инде, яшь кенә майор йөгереп килеп җитте. Калганын мин хәтерләмим. Шунысын гына тойдым: илләдә мәгәр маршалның кулындагы куәт! Ул учларының зурлыгы, ул минем кулны кыскандагы көч, мин дә бит инде таза (ул үзенең кулын күтәреп куя, әмма кул урынында анда кызганыч җәплекә генә...), шулай да ул миннән куәтлерәк иде. Кеше йөрәгенең зурлыгы йомарлаган йодрыгы кадәр була, диләр. Моның да шулайдыр, йөрәгендә бер хикмәт булгандыр. Ул бит — теге сугышта ук Георгий крестының тулы кавалеры... Ә андый кеше Россиядә бармак белән генә санарлык. Менә шулай орденны маршал үзе бирде миңа. Бер генә җөмләсе хәтердә калган:

— Молодец, Ягудин, татар солдатларын мин беләм, алар белән сугышка кирәргә була,— диде. Тагын бер сүзе истә: — Син,— диде, — Шараповның хәлен бел, аны бүген тыл госпиталенә озаттылар,— диде.

Исламгали агайның бу хикәясен халык рәхәтләнеп тыңлады — ирләр монысының чын икәнен аңлыйлар иде. Шулай да сугышка кагылышлы мәсьәләдә һәрвакыт сорау бирә торган

Хәерниса бу юлы да сорау биргәч, Исламгали агай элеккеге «дулкыны»на кире кайтты. Хәерниса ип белән генә сорады:

— Карале, Исламгали, ул маршал дигәнегез ничек киенгән инде? Өстенә-башына, дим.

Ирләр көлештеләр. Шунда Исламгали агай элеккечә сөйләп алды:

— Ничек дип... Аларның билгеле инде. Сугышта иң зур кеше бит ул инде яхшы киенергә дә тиеш. Шунсыз нинди ул сиңа автарит? Ничек киенсен? Өстендә чем-кара кәчтүм-чалбар, аягында кап-кара лаклы ботинкалар. Башында яхшы эшләпә...

Ирләр читкә борылалар, Хәерниса да ышанган сыман риза була. Әмма Исламгалинең хатыны Рәшидәдән башка берәү дә белми: шулай уен-көлке сөйләшеп утыра да кеше барында Исламгали, аннан, юрган астыннан ике җәпләкәсен чыгарып, төне буе ыңгыраша, сызлана. Бигрәк тә көн болытласа. Анысын — кеше белми. Үзенең дә белдертәсе килми.

...Исламгали агай, Япония белән сугышта катнашмаган көе, олыгайгач, Ватан сугышында җиңүнең кырык еллыгын билгеләгән, өр-яңа «Отечественная война» ордены белән бүләкләнгән җәйдә «Япун Ягудин» дигән кушамат алды.

...Кайчандыр аны җитәкләп Сочига йөргән улы, укып югары белем алгач, профсоюз эшенә сайланды. Өйләнеп, матур гына гаилә корып җибәрде, шәһәр кызы авыл малаен гел шәһәрчә яшәргә өйрәтте. Профсоюз малай инде үз хатыны белән көньякка йөрде, әтисенә, Исламгалигә, кардиологлар рөхсәт бирми иде. Профсоюз малай бераздан гади ял итүчедән чит илләргә йөрүче туристка әйләнде. Ул сиңа кирәкме Урта диңгез буенча круиз, ул сиңа кирәкме Төньяк круизы. Йөреп кайткан саен күргәннәрен әти-әнисенә сөйләп таң калдыра малай. Профсоюз эше кызык бит ул — анда гел алга барсаң гына яшәп була. Профсоюз малай бераздан чит илләргә баручы туристлар төркеменә үзе җитәкче буларак йөри башлады. Шундый сәяхәтләрнең берсендә ул, Исламгали агайның күрәчәгенә каршы, Япониягә барып чыккан: туристлар төркеменә җитәкче булып. Менә шуннан малай икенче кеше булып кайтты да инде. Ул анда барганчы Япония турында күп әдәбият укыган (профсоюз малай пединститут тәмамлаган иде), тегендә баргач та гел мәктәп, балалар тәрбиясе мәсьәләләре белән кызыксынган: кая гына барса да, нинди генә сорау бирсә дә мәсьәлә гел бер тирәдә әйләнгән: Япониядә балаларны аерым бер методика белән тәрбия-

лиләр. Кечкенә вакытта бала тулысынча ирекле: нәрсә теләсә шуны эшли. Нинди генә зарар салса да, кыйныйсы, җәза бирәсе түгел. Бары тик акрын-акрын гына теге, бу эшнең яман яки яхшы икәнен аңлата килергә. Бала тулы ирекле булып үссен.

Профсоюз малай дүрт яшьлек улы Рабисны (малайның исем тарихын Габделхәмит болай аңлатты: «Рабоче-крестьянское искусство» сүзеннән кыскартып ясалган,— диде.— Сез,— диде,— миңа иске исем кушып, биографиямне кыенлаштыргансыз.— Һәм визит карточкасын күрсәтте. Анда фәлән-фәлән хезмәт кешесе «Ягудин Хэмид Галеевич» диелгән иде) ата-ана йортына җәй уздырырга кайтарып куйгач, шуларны сөйләде.

— Без инде япон методикасына күчтек, сез дә шуны дәвам итегез, без әнисе белән ике атнага бер кайткалап торырбыз, кирәк-яракны үзебез кайгыртырбыз,— диде.

Исламгали агай, тирән сулап, секунд эчендә үзенең сугыш алды һәм сугыштан соңгы еллардагы тормышын баш мие аркылы уздырды. Балаларга каты куллы булды ул. Шаярышып узынсалар, чыгырдан чыксалар, Исламгали агай биргәләп алырга күп сорамый иде. Профсоюз малай сугышка кадәр үк туган иде — этисе әле сугыш чыгасы елны гына язын тополь башындагы сыерчык оясына кулын тыгып актарынган өчен малайны пешерде. Малай, ике-өч сәгать елап, шыңшып, этисенә рәнҗеп, абзар артында утырды.

...Госпитальдә аңына килгәндә ике кулы да беләзектән киселгәнен күргәч, Исламгали агай ыңгырашып куйды:

— Һай-й,— диде ул, күз яшьләренә тыгылып.— Һай-й-й... Сабыем Габделхәмит рәнҗегәндер. Юкка гына кызып китеп яңакладым бит шул чакта. Ул бит сыерчык оясына зарар салам дип менмәгән. Аның бит, оядан яшькелт-зәңгәр кабыклы бер генә йомырка алып, өйдәге гөл төбенә куясы килгән. Аңа бит элеккеге язда үзем шулай күрсәткән идем: тополь төбеннән табып алынган ул йомыркага малай никадәр шатланган иде. Сабый... Шул рәнҗегәндер...

Оныгы Рабисны алып калган көнне аның йөрәге әнә шул истәлекләр белән телгәләнде. Профсоюз малай шәһәренә китеп барды, дәү эти белән дәү әни исә, оныкны «японча тәрбия»ләргә вәгъдә итеп, капка яныннан борылып, лепердәтеп газ биреп шәһәргә таба чапкан «Волга»га карап калдылар.

— Габделхәмит акыллы шул,— диде Исламгали агай, карчыгына таба борылып. Бер җәпләкәсен оныгының җылы,

йомшак муенына куйган иде — шул көе басып тордылар.— Акыллы. Әнә мин ни үкендем каты куллы булганым өчен. Дөрес, минем бала әйбәт булып чыкты. Но да ләкин минем тәрбия дөрес корылмаган булган. Әйдә, улым, мультфильм башлангандыр. «Заяц, погоди»ны яратасыңмы? Мин үзем бер дә калдырмыйм аны.

Ләкин «Погоди»ны карарга туры килмәде аларга ул көнне. Өйгә кереп, диванга урнашып рәхәткә чумабыз дип кенә торганда, малай, үҗәтләнеп, стенадагы герле сәгатьне сорый башлады (ул аны бая әтисе белән ашап-эчеп утырганда ук планына кертеп куйган, сәгатьнең эченнән баш тыгып күкелдәгән кош малайны шаккатырган иде). Сәгатьне стенадан алып бирергә туры килде: моннан ун еллар элек җиңү бәйрәме көнендә колхоз парткомыннан бүләк иткәннәр иде бу сәгатьне. «Погоди» башланырга ун-унбиш минутлар бар иде әле, малай зур дәрт белән сәгатьнең калай ишеген каерып ачты, бәләкәй куллары белән теге хикмәтле кошны, әләктереп, җан-фәрманга бугазлый, тарта башлады. Исламгали агай, бу бәләкәй варварга бераз гына рәнҗеп, ләкин япон методикасына зур ихтирам саклаганы хәлдә, урыныннан торып, ишегалдына чыгып китте.

— Ярар инде, күкесез булса да йөреп торыр әле, берни эшләр хәл юк,— дип чоланга сөялде: сәгатен кызгана иде, ул аңа һич тә сәгать булып түгел, ә гаилә әгъзасы, дус, ышанычлы иптәш, бергәләп картаючы фронтовик булып тоела, шулай уйлап күнегелгән иде.

«Погоди» башланырга бер-ике минут кала Исламгали агай өенә керде, карчыгы әле тавык-каз белән абзар-кура тирәсендә мәш килә иде. Гадәттәгечә: һай, җүнсезләр, көш дим, көш, азынып калыгыз, киләсе елга берегезне дә калдырмыйм, чисти үзәкләремә үттегез, гомерләрем әрәм узды...— Исламгали агай белә, сугыштан кайтканнан бирле ишетеп яши инде ул мондый «чыгыш»ларны, ләкин бу — болай гына: хуҗа хатын барыбер ике ана каз, бер ата каз, егермеләп тавык белән тубал кадәр зур әтәч, ике баш үрдәк калдыра кышка. Болай гына инде ул, болай гына. Тукта, ярар, «Погоди» вакыты җиткәндер... дип өйгә керсә, бәләкәй варвар, сәгать чылбырының очын учына чорнап, гер селтәп, идән уртасында әйләнеп уйный иде. Исламгали агайның шунда кул бармаклары чымырдап сызлап алды: герне әйләндереп селтәгәннең берсендә тәрәзә төбендәге яран гөл, идәнгә төшеп, чүлмәге-ние белән көл булды, икенче селтәнгәндә, гер авыр хут белән өстәлдәге электр чәйне-

генә килеп чыкылдап бәрелде, чәйнек, бичара, күз алдында яньчелде, әле аннан соң да чыкыр-чыкыр итеп эчтән ватылып утырды.

— Чү, улым, чү, алай ук ярамас,— дип чак әйтә алды Исламгали агай, үзенең һаман кул бармаклары сызлый, ул әле һаман аңлап бетерми иде, андый вакытта ир кеше һәрчакта да хатынына сыена, шуңа күрә ул ишекне этеп кенә ачып чыкты да абзар якка карап кычкырды:

— Син, дим, син... Кер әле тиз үк! Кер әле, дим...

Өйдә нәрсәдер шартлап ук ватылды һәм чәлпәрәмә килде. Монысы инде чамадан тыш иде һәм Исламгали агай җәһәт кенә ишекне ачып өйгә керим дисә — бәрәч!— ишек тоткасын тотарга куллары юк бит аның. Кырык елдан артык инде аның кулсыз калганына. Ни чуртым кычыта соң? Ул, ишек киндеренә аның өчен кагылган каеш элмәкне хәтерләп, аны җәпләкәсенә кидерде һәм атылып өенә керде. Керсә... телевизорның экраны юк, идән тулы аксыл-зәңгәр пыяла, ә малай ике кулы, башы белән телевизор эченә кереп киткән иде. Исламгали агай, ыңгырашып, ишек бусагасына утырды.

...Кичен капка төбенә җыелган ирләр арасында, өр-яңа тема күтәреп, болай сөйләде:

— Безнең тәрбия дөрес түгел ул. Без балага кычкырабыз, җикеренәбез. Сугабыз да. Әнә японнар. Алар балага берни әйтмиләр. Бала өйдә теләсә нәрсә эшли: гөлләреңне йолка, чынаяк вата — аларга әйбер әйтелми. Бала үсә төшкәч үзе аңлый. Әнә минем Габделхәмитнең малае. Яңача тәрбиялиләр. Шулкадәр тере бала. Һич кенә дә тик тормый. Шулай кирәк, японнар — акыллы халык алар. Аларның эшләгән транзисторларын гына кара син: бишенче каттан асфальтка ыргыталар икән, шайтаным да булмый. Ә телевизорларын...

Шулвакыт ул эчтән ыңгырашып куя, ләкин кешеләргә белдерми.

Берәр атнадан исә күрше хатыннары сизәләр: Исламгалиләрнең түр тәрәзәсендәге яран гөлләр гел кими, гел сирәгәя. Исламгали агай исә һәр кичне «японча тәрбия» турында «лекция» сөйли. Агай-эне, яңа тема бит, рәхәтләнеп тыңлый.

Әти-әнисен бик тә, бик тә көткәндә, инде ике атна тула дигәндә, Исламгали агайның өендә инде телевизор, күкеле сәгать, кырыну машинкасы, электр чәйнеге, зур көзге ватылган, исән калган ике чүлмәк яран гөле мич башына мендерелгән, кухня якка чыга торган аралыкка яшелчә бакчасының рәшәткәле

капкасы кертеп сөялгән, һәм хуҗа хатын, японнарны каргый-каргый, кергән-чыккан саен шул капканы күчереп куеп иза чиккән көннәр иде...

Шулай да беркөнне малай кухняга уза алды. Һәм дәү әнисе күрмәгәндә генә кулына шырпы кабы эләктерде. Исламгали агайның нервлар артык чигенә кадәр тартылган иде, күршетирә инде бу бәләкәй афәтнең болар хуҗалыгына күпме зыян салганын чамалый да иде, җитмәсә, күрше Хәерниса иртә белән радиодан көлкеле бер тапшыру тыңлаган да кичке капка төбе «җыелыш»ында шуны сөйләде.

— Әй, дим, ну шушы Казанның тапшырулары. Кем булды икән ул, танымадым, әллә Равил Шәрәфиев инде, әллә Ринат Таҗетдинов. Әллә Ирек Баһмановмы? Мин үзләрен күрмәгәч, тавышларыннан аера алмыйм. И дә кызык итеп сөйли инде. Бер малайны, ди, Таҗикстаннан монда, Казанга алып кайтып әбибабасына калдырганнар. Җәйне, дигәннәр, сездә торып торсын, безнең монда, дигәннәр, җир тетри, бала куркып бетте.

Шуннан соң берәр ай узгач, әби белән бабай Таҗикстанга хат язганнар, ди: «Малаегызны кайтып алыгыз, безгә сез лутчы җир тетрәүнең үзен җибәрегез»,— дип әйтеп әйткәннәр, ди...

Исламгали агайдан башка барысы да хахылдап көлә.

...Нәкъ унбиш көн үткәч, «японча тәрбия»нең нәтиҗәсен карарга авылга ак «Волга» кайтып төште. Әмма... урамнан тыкрыкка таба борыла алмады. Техника — бензовоз, сөт машинасы, аммиак сыекчасы ташый торган машиналар тыкрыкка бөялгән. Һавада кисәү, көйгән салам, тагын әллә ниләр исе. Урамда тынлык. Кешеләр төркем-төркем җыелганнар. Сөйләшмиләр.

Профсоюз Габделхәмит машинасыннан чыкты, арткы ишекне ачып, кулыннан сак кына тотып, чибәр бер ханымны чыгарды — бу инде бер дә шиксез теге бәләкәй ташбашның әнисе иде, сак кына атлап, техниканы әйләнеп, үз капкаларына таба юнәлделәр. Капка төбендәге эскәмиядә милиция формасы, хәрби форма кигән ике-өч кеше нәрсәдер язалар, сорашалар, киңәшәләр иде.

Шыр ачык урыс капка аша ишегалдына карагач, профсоюз Габделхәмит имәнеп китте: бәрәңге бакчасының түренә тезеп, бурап салынган келәт, корт өе, ак мунча урынында кисәү өеме пыскып утыра, ишегалды ермачланган, урыс капканың бер баганасы төптән кырт өзелгән, бер торык койма ауган, бөтен әйләнә-тирә су, кисәү, изелгән балчыктан тора иде. Халык,

ни гаҗәп, янгын турында түгел, Исламгали агай турында сөйли иде. Келәт артында чытырдап ялкын күтәрелүгә, урамда кычкыра башлаганнар: Пужар, пужар! Шунда Исламгали агай ишегалдында киләп сарып гел йөгереп йөргән. Нәрсә эшләргә белмәгән. Хатыны Рәшидә шундук оныгын күтәреп алган, икенче кулына иренең орден-медальләрен таккан пиджагын алган да торып йөгергән, күршеләргә кереп, шуларның бурабзарына качкан, Исламгали агай исә, янып яткан келәткә кереп, нәрсә алырга белми аптырап торгач, майланып, балавызланып беткән бер иске бишмәт тотып, авыл башына чыгып йөгергән. Каралты-кура янып беткәч, аны җитәкләп алып кайтканнар. Бишмәт дигәннәрен таныганнар: кырык бишенче елны киеп кайткан солдат бушлаты, ди. Элек яшел төстә булган, ди. Мин моны белеп эшләмәдем, дип әйткән, ди.

...Шул көнне авылда «Япон Яһүдин» дигән яңа кушамат туды. Халык, Тукай әйткәнчә, шагыйрь шул: «Япон Исламгали» диелергә тиеш иде дә бит, юк шул, халык, сүзнең поэтик яңгырашын күңеле белән тоеп, алай итмәде, кушамат өчен аның фамилиясен файдаланды. «Япон Яһүдин» — бу инде яңгырый.

Йомшак җылы муенлы, аяк-куллары чебиләгән бәләкәй ташбашны ул көнне кич кире үз оясына — Казанына алып киттеләр.

Теге каралтыларның страховкасы бар иде, аннан байтак чыкты, тагын профсоюз малай белән профилакторийда баш врач булып эшләүче килен байтак ярдәм иттеләр. Хәер, теге каралтылар тузган, аларны барыбер яңартасы бар иде инде.

Шулай да Исламгали агай бу вакыйгадан соң җитдиләнеп калды. Аның күңелендә күпмегәдер юмор үлде. Шулай, шулай, дип уйланды агай. Шулай... Габделхәмит менә ничә ел инде ашау-эчү әйберсен ничек юнәтергә, транспорт каян табарга, фатирны ничек ремонтларга, врачка ничек эләгергә дигән тормыш мәшәкатьләреннән азат. Аның бөтенесе әзер, транспорты — баскыч төбенә килә, врачка чакырып алалар, ашау-эчү әйберсен кухнясына китереп кителәр. Ул моны үзе белми дә. Шулай, андый тормыштагы кешенең чынбарлыктан аерылмый хәле юк. Ул бит инде синеңчә булып уйлый алмый. Баш миендәге андый күзәнәкләр аның инде үлгән була. Хәер, аның гаебе дә түгел инде ул. Әнә Хәерниса сөйли: олы кызы Энҗе фатир сораган вакытта шәһәрдәге зур кеше исеменә болай дип гариза язган: «Уңай шартлары булмаган бер бүлмәле фатирда ирем

белән бергәләп ике бала үстерәбез. Үзем кандидатлык диссертациясе язам. Мондый шартларда, үзегез аңлыйсыз, фән белән шөгыльләнеп булмый». Шул гаризасын больницаның баш врачына күрсәткән. Баш врач — акыл иясе — кардиолог, гаризаны укып чыккан да, кызыл карандаш алып, андагы ике сүзне шыгырдатып сызган: «үзегез аңлыйсыз». Энҗенең аптырап карап торуына каршы ул әйткән:

— Син аның үзенең нинди шартларда яшәгәнен күз алдына китерәсеңме соң?— дигән. — Ул,— дигән,— синең шартларыңны берничек тә аңлый алмый. Гаризада,— дигән,— бер генә артык сүз дә булырга тиеш түгел. Гариза ул,— дигән,— кешенең йөрәк тибеше. Ә йөрәк эшчәнлегендә бер генә дә артык тибеш була алмый...

Шулай, бу вакыйгадан соң Исламгали агай үз эченә батты, уйчанланып калды.

Габделхәмит исә әлеге вакыйгадан соң ярты ел буе авылга кайтмады. Дөрес, ара-тирә хатлары килә иде. Мәшәкате булган икән, соңгы хатыннан шул аңлашылды.

«Көннәр эчендә чираттагы ялымны алырга уйлыйм... Моннан өч атна арттан яңа фатирга күчтек, дүрт бүлмәлегә... Әле ун көн генә арттан туйда булдык: минем шефның малае гаилә теркәде...»

Исламгали агай хатны кат-кат укыды һәм укыган саен үзенең наданлыгын ныграк сизә барды. Утызынчы елларда ул башлангыч мәктәптә, аннан ТБУМда укып йөргән иде: иллә дә туган телгә өйрәтмәгәннәр икән аны укытучылар ул елларда!

Менә бит хәзер ничек сөйләшәсе икән. Менә бит культуралы кеше ничек шәп сөйләшә ул. Һай, һай, һай, һай... Идрит-кудрит...

Сорау һәм биремнәр

1. Бүлекне мөмкин кадәр кыска, җыйнак итеп сөйләгез. Төп вакыйга-күренешләрне билгеләгез.

2. Исламгали, Хәмит, Рабис — әлеге өч буынның ничек үсүе, тәрбияләнүе турында фикер алышыгыз. Исламгалинең яңача тәрбиягә мөнәсәбәтен ачыклагыз.

3. Бүлектә чор каршылыклары ничек бирелә? Аларга авторның бәясе.

4. Исламгалигә характеристика бирегез.

IX

Фәләхетдин белән без бергә үстек. Ул миннән күп булса ике яшькә яшьрәктер. Авыр тормыш кичердек, ачлыкны, киемсезлекне кайсыбыз күбрәк күргәндер, хәзер инде әйтүе кыен. Тик минем аннан бер өстенлегем бар иде: мин бала вакытта ук бик күп китап укыдым. Матур әдәбият миңа ярлылыкны, гаделсезлекне кичерергә ярдәм итә иде, мин киләчәккә гел якты өметләр белән яшәдем. Тарих мине алдамады: 1956 елда партиянең мәшһүр егерменче съезды булып, тормышка яңа сулыш өрде, аннан мин инде байтак олайгач, егерме җиденче съезд һәм Апрель пленумнары кебек тарихи-революцион җыелышлар булды.

Мин әле һаман яшим.

Тик Фәләхетдиннең генә гомере киселгән икән. Ул шактый надан иде, ихтимал, үз гомерендә ул бер генә дә әдәби әсәр укымагандыр, тормыш авырлыгын сәбәп итеп, ул дүртенче класстан ары мәктәпкә йөрмәде дә кебек, һәрхәлдә, башлангыч мәктәпле безнең авылдан җидееллык мәктәпле күрше авылга күчү процессында байтак кеше «юлда югалып» кала иде.

Фәләхетдин әтисе белән йә хуҗалык көтүен көтте, йә җәй буе колхоз басуын мал-туардан, каз-үрдәктән саклады. Инде дә борчак кузакланган чорда... Көннәрдән бер көнне авылда хәбәр тарала: Хөлләбетдин абзый үзенең малае Фәләхетдин белән борчак басуында шалаш корганнар икән. Димәк, колхоз идарәсе аларга борчак саклауны йөкләгән. Шалаш сүзен безнең авылда үзебезчә әйтәләр: чалаш. Мин уйлыйм ки, безнең авылныкы дөресрәктер: агачларны туры итеп түгел, чалыш итеп утырткач ясала ул.

Безнең авыл басуы шул көннәрдә шигъри, өметле бер нурга чума иде. Яшел борчак басуы зәңгәр күккә кояш нурлары аша тоташа иде, басу өстендә баш әйләндергеч яшькелт-зәңгәр һава катламы ясый. Шундый көннәрдә борчак басуы җирдән һәм кояштан куәт алып туена, калыная, киерелә. Менә көннәрдән бер көнне Хөлләбетдин абзыйның шалашы янында сыек кына төтен күренә, ул төтен, җир өстендәге яшькелт нурдан оялган сыман, нәзек ефәк шарф булып кәкрәя-бөкрәя өскә күтәрелә — без белеп торабыз инде — йомшак борчакны җыйган да Фәләхетдин, әтисе шуның боткасын пешерә, димәк, аларның бүген тамагы туя. Бәс шулай икән, димәк, безнең тамак та, шәт иншалла, туя башлар, бүген төнгә борчак басуына

кайсы тыкрыктан, кайсы межадан шуышып сәяхәт ясарга икәнлеге турында көндездән үк планнар корыла, киңәш-табыш ителә. Инде моңа күп еллар узды, яшьтәшләрем миңа бер серне ачкан өчен үпкәләмәсләр дип уйлыйм. Мин үзем төнлә борчак ашарга барганда, һәрвакыт дошман тылына (ягъни борчак басуына) алдавыч һөҗүм оештыру планын яклый идем. Ягъни бер-ике малай борчак басуына авыл ягыннан килеп керәләр дә кычкырып сөйләшә-сөйләшә ашый башлыйлар. Акрын гына йөри торган Хөлләбетдин абзый белән юаш Фәләхетдин, шул флангка китеп, шул тирәне саклыйлар. Әмма отрядның төп өлеше шул вакытта бөтенләй икенче яктан — урман буеннан, тылдан кереп позициягә урнаша һәм иркенләп кузак яра, ашап туйгач, күлмәкне чалбар якасына кыстырып, кузакны шунда тутыра һәм ашказаны да, күлмәк эче дә калынаеп, авыраеп алгач, әйләнгеч юл белән авылга кайта. Тик бер шарт намус белән үтәлергә тиеш: теге «провокатор»ларга һәркем бирәр кушуч борчак кузагы бирергә тиеш. Бу хәтәр эш — котырту — чират буенча башкарыла иде.

Тук карын белән ятып йоклау... Хәзер әнә медиклар язган була, тук карын белән йоклау зарарлы, «кичке ашыңны дошманыңа бир» дигән булалар...

Теләсә нәрсә әйтегез, теләсә нинди киңәш бирегез, хөрмәтле докторлар, әмма ләкин безнең буын кешеләрен андый эшкә этәрмәгез! Беләбез без ач кунуның нәрсә икәнен! Ә менә борчак басуыннан кайтып йоклаган көнне иртәгесен йокыдан торып, атмы, үгезме җигеп, басу юлыннан эшкә барып карагыз әле сез! Дөньяның матурлыгын шунда күрерсез. Әнә ул теге яшькелт басу, әнә аның түрендәге серле шалаш, әнә шалаш янындагы теге төтен. Тамак тук булганда бөтен әйбер ямьле күренә, әле узган төн генә сине куркыткан Хөлләбетдин абзыйның таякка салынган бөкрәйгән гәүдәсе дә, нинди материалдан һәм нинди төстә икәнлеген әйтү мөмкин булмаган күлмәк, ыштан кигән Фәләхетдин дә шул сихри шалаш янында халык әкиятләрендә генә очрый торган серле каһарманнар булып күренәләр. Ә күктән борчак басуына иксез-чиксез кояш нуры агыла, бу нурга, җылылыкка чыдый алмыйча бүртенеп чәчәк аткан билчәннәр, баллы куәтләр, күкчәкләрдән дөньяга затлы конфет исе таралган, бу ис тамак төбен җыера, күзгә дым куа.

Дөньяда безнең авылның урманга таба җәелеп яткан басуында борчак кузакланган кояшлы көннәре кадәр ямьле вакыт, рухи күтәренкелек, хөрлек, матурлык тагын кайда була икән?!

Мин Ак диңгез, Балтыйк диңгезе, Кара диңгез, Урта диңгез һәм Һинд океаны өсләрендәге кояшны күрдем. Финляндия, Кипр, Мисыр, Италия кояшларын күрдем, Амур буендагы сопкалар арасыннан чыккан кышкы кызгылт кояшны, Мурманск, Североморск өстендәге авыр кургаш болытларны чак-чак ертып, кешеләргә бер-ике минутлык кына якты чырай күрсәтеп алган кояшны күрдем. Һәр якның үз кояшы була. Бер якта ул газаплы күренә, икенче якта — купшы кыланчык, өченче якта — хәлсез, көчсез, дүртенче якта — ышанычлы, куәтле. Бер илдә ул ап-ак була, икенче илдә — тоныкк сары, өченче илдә — яшькелт-сары. Әмма кояшның иң бай төслесе, иң көләче, иң мәрхәмәтлесе — безнең әнә шул борчак басуында июль аенда була. Кояшның нинди икәнен күрәсегез килсә, июль аенда безнең авылга килегез.

Фәләхетдин үсеп буй җиткәнче әнә шунда булды. Ел саен кояш астында — йә шалаш янында, йә басуда.

Ундүрт яшемдә мин авылдан чыгып киттем, озак вакытлардан соң картайган егет булып авылга кайттым. Яшьтәшләр турында сораштым. Дөнья безне кырган: сабакташлардан ике егет, колхоз ашлыгын урлауда гаепләнеп, төрмәгә озатылган, берсе шунда үлгән. Тагы берсе товар поездына утырганда, аска эләгеп, ике аягын өздергән, берсе, нахак бәлагә тарып, үзенең гөнаһсызлыгын исбат итәр өчен, формалин ашап үлгән... Ә берсе күп еллардан бирле инде Казан психиатрия шифаханәсендә икән. Тагын берсен үпкә авыруы бәреп еккан...

Фәләхетдин турында сораштым. Армия хезмәтенә алынгач, Фәләхетдин Мәскәү гарнизонына эләккән. Шунда өч ел хезмәт иткән. Менә бәхет! Берәүләр өч ел сопкалар арасында, җансыз чүлдә, тарлавыкта, калын тайга эчендә, бозлы утрауда хезмәт итә, ә Фәләхетдин — Мәскәүнең үзендә. Ничектер, командировкага эләгеп, Ленинградны да, Риганы да күргән. Менә бәхет!

Ләкин... борчак басуыннан зур шәһәргә кисәк сикереш аның баш миенә авырга туры килгән, һәм Фәләхетдин, хезмәт срогы тәмамланганда, әти-әнисен дә, туган авылын да оныткан: Мәскәү тирәсендәге бер шәһәрчектә ашханәдә эшли торган бер кыз — Валентина белән танышкан. Ә тегесе әйткән:

— Ул фәкыйрь авылыңа кайтып нишләрсең, әйдә, минем абзый сине экскаваторчылар курсына урнаштыра, укып чыккач, акчаны көрәп алырсың, безнең фатирыбыз иркен, телевизорыбыз бар,— дигән.

Фәләхетдин «телевизор» дигәнне аңламаган, әмма беркөнне «увольнение» алып боларга килгәч, өй эчендәге тере киноны күреп телсез калган.

Валентина һәм аның тол әнисе моңарчы Фәләхетдин күрмәгән, ишетмәгән «окрошка» дигән аш «пешергәннәр», ни хикмәт, суытып алдына куйганнар. Аш алдыннан дип кара пыялалы шешә белән эчемлек биргәннәр, «Мартовское пиво» дип язылган, ди. Егет төп мәсьәләгә ризалыгын белдергән.

Һәм Фәләхетдин, үзенең бу карарын хәбәр итәр өчен, авылга — картлар янына кайткан. Кайтса, тегеләрнең икесе дә авыру, ди. Ягарга утын исәпле, абзар-кура тузган, капка җимерелгән. Өй дә авышкан, почмаклары черғән, матча башларыннан яңгыр үтә, ди.

Фәләхетдин картларга бүләкләрен биргән: ирләр күлмәге шыгырдап тора, төрелгән, ди. Галстук (Валентина оештырган бүләкләр), яхшы хром перчаткалар, карчыкка һәйбәт йон фуфайка һәм... яхшы ислемай.

Хөлләбетдин абзый да, карчыгы да бермәлгә тынсыз калалар. Шуның өстенә малай бер авыз сүз эндәшми, икенче көн үткәндә нибары бер җөмлә әйтә:

— Я ваш язык забыл,— ди. — Я женился,— ди,— скоро уеду от вас,— ди.

Карт белән карчык телсез калалар.

Малай авылына хатыны кушуы буенча кайткан икән. Хөлләбетдин абзый иртәгесен, таягына таянып, күрше Масра авылына чыгып киткән. Анда аның апасының улы, гаяр егет, ил-җир күргән Фәтхулла яши икән. Ташлытауда финагент булып эшли, торуы — гаиләсе белән — Масрада икән.

...Фәтхулла, атка утырып, шул көнне кичке якта ук килеп җитә. Атын җимерек капканың Ходай ярдәме белән исән калган баганасындагы күгәргән боҗрага йөгән тезгененнән бәйли дә йортка керә. Какшау агач өстәл кырыенда ата белән малай утыра. Хәмденисаттәй, ыңгырашып, ян сәкедә ята.

Дүрт ел авиация частьларында хезмәт итеп, Германияләрне күреп кайткан Фәтхулла «обстановканы» шундук чамалап ала.

— Ну-ка, чыгып сөйләшик әле,— ди, ул кырыс тавыш белән. — Ә син, дәү абый, җиңгине борчымыйча гына самавыр куя тор.

Чоланга чыгып тәмәке кабызалар. Тынлык. Фәтхулла «Метро» сигаретын еш-еш суыра. Аннан риза булмыйча, кесәсендә капшанып, ачырагын чыгара: «Аврора». Ул вакытта әле фильтрлы сигаретлар юк. Анысын кабыза. Фәләхетдин дәш-

ми. Бер-ике минут шулай төтен чигәләр. Ләкин гел болай торып булмый бит инде. Фәтхулла кинәт кенә, сигаретының очына төкереп, табан астына баса да таза кулы белән Фәләхетдиннең күлмәк якасыннан чытырдатып умырып-җыеп ала, битен биткә терәп ырылдый:

— Син нәрсә... (боларын язып булмый), син нәрсә, ә? Син нәрсә? Атаң-анаң телен оныттыңмы? Нигезеңне оныттыңмы? Каян чыкканыңны оныттыңмы? Мин сине... Майть! Изәм мин сине! Сопляк! Үз телеңдә сөйләшергә хурланасыңмы?.. Майть! Үтерәм! Бетерәм мин сине, татар халкы моның өчен мине судка бирмәс! Ата-анаңны оныткан син падланы бетергән өчен, миңа чуртым да булмас...

Фәтхулла дер-дер килә, Фәләхетдин агарына. Ләкин дәшми.

Шулвакыт чоланга, ыңгырашып, Хәмдениса түти чыга һәм җыерылып, сыкранып Фәтхуллага ачулана.

— Ай-й-й... Син килеп кергәч тә, йөрәгем сикергән иде аны. Ник бәйләнәсең малайга? Бөтен нәселегез шулай булды. Безнең якка кара дошман булдыгыз. Ник кул күтәрәсең син аңа? Бала бит әле ул. Ачылыр, теле дә ачылыр. Бик кара эчле нәсел шул сез. Гомер буе безнең якка дошман булдыгыз...

Фәтхулла, өйгә кереп тормыйча, төкеренеп чыгып киткән һәм Масрага җиткәнче атны күбеккә батырган, ди.

...И гомер! Хөлләбетдин абзый белән Хәмдениса җиңгинең каберен дә белүче юк инде хәзер. Аларның нигезе аркылы кышын бүрәнә төягән трактор узган да соңгы истәлек булган карт шомыртны изеп киткән. Җәен инде тигәнәкле, чокырлы бу урынга бозау да арканламыйлар икән. Кемдер, каядыр — санаторийгамы барганда, әллә шул ук Масра Фәтхулламы, имеш, белешмәләр бюросыннан эзләтеп, Фәләхетдинне тапкан. Сүнеп, Хөлләбетдин абзыйның исемен дә онытып барган авылга хәбәр кайткан. Хәбәр — шаккатарлык.

Имеш, Фәләхетдин экскаваторда эшләп бик күп акча туплаган, Мәскәүнең «Юго-Запад» дигән районында өч бүлмәле яхшы кооператив фатир алган. Ни хикмәт: ике баланың икесе дә укуга хирыс булып чыкканнар. Беренче улы Мәскәү университетының биология факультетын кызыл диплом белән тәмамлаган да Фәннәр академиясендә эшли, ди, торналар буенча инде Союз күләмендә танылып килүче яшь галим, ди. Кызлары исә, артык чибәр һәм тыйнак, әхлаклы булуы аркасында, курслар тәмамлап, халыкара авиалиниядә стюардесса булып эшли, ди. Фәләхетдин белән әнисе Валентинага бер кайтканда — ананас,

кокос чикләвеге сөте, икенче кайтканда — эченә тере елан тыгып ясалган файдалы эчемлек, өченче кайтканда Цейлонның үзендә үстерелгән, үз фабрикасында эшкәртелгән чын чәйне, килолы яшел калай тартмада алып кайтып, әнисенә тоттыра, ди.

Фәләхетдин чын мәскәвич, ди, ял көннәрендә стадионга йөри, ди, футбол караганда ЦСКА өчен гомере буе «авырган», ди. Адрес бер ачылгач, Мәскәү аркылы узганда ярты еллардан соң Фәләхетдиннәргә тагын кемдер кереп чыккан.

Бичара Фәләхетдин... Терелмәслек авыру эләктергән дә кинәт кенә урынга егылган, ди. Авылдашына, мөлдерәтеп карап, саф татарча әйткән, ди:

— И туганым... Безнең авылның урман юлындагы басуда үскән бер генә учма яшел борчак җибәрә алмыйсыңмы, саламыбилчәне белән,— дигән.— Шуны ашасам терелермен кебек. Төшләремдә гел шуны ашыйм, иртән торгач, утырып елыйм.

Туганы моны эшли алмаган: карлы көз икән.

Фәләхетдин салкын декабрь көнендә үз өендә, хатыны һәм балалары янында утырганда җан биргән.

— Бәхил булыгыз,— дип, саф татарча әйткән, ди. Хәер, аның хатыны Валентина, эшләгән җирендә мишәр хатыны белән дуслашып, татарчага өйрәнгән булган, ә балалары инглизчә укыганда беррәттән татарчаны да өйрәнгәннәр икән. Фәләхетдин әйткән:

— Бәхил булыгыз,— дигән.

Нәкъ безнең авылча әйткән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Фәләхетдин белән бәйле вакыйгаларны сөйләгез.

2. Фәләхетдиннең каршылыклы язмышының сәбәбе нәрсәдә? Ул үз телен нигә «оныта»? Аны «акылга утырту» вакыйгасына бәя бирегез.

3. Туган җиреннән читләшкән Фәләхетдин якты дөнья белән хушлашу сүзен ана телендә әйткән. Ни өчен дип уйлыйсыз?

4. Автор идеясе белән эпиграф арасындагы бәйләнешне табыгыз.

XI

Дөньяда бик күп төрле, бик күп жанрда музыка, җыр бар. Болар ике төрлегә бүленәләр: беренчеләре — шул халыкның үз эчендә генә популяр була алырлык «локаль» әсәрләр. Әйтик, безнең «Әпипә», «Җизнәкәй», «Ончы Фәхри» шулайдыр. Икен-

че бертөрле җырлар, музыка әсәрләре — бөтен халык өчен уртак, үз була. Әйтик, русның «Не брани меня, родная», «Катюша», грузинның «Сулико», украинның «Распрягайте, хлопцы, коней», татарның «Каз канаты», «Ай былбылым» көйләре,— бер дә шиксез, интернациональ әсәрләр, «Аппассионата» да шулай, «Сурок» та, «Зәңгәр Дунай» да, Г. Свиридовның Пушкин әсәре «Метель»гә язган музыкасы — болар бөтен халык байлыгы. Музыкада туган җир тавышы булырга тиеш. Музыкада кеше намусы мәсьәләсе төп тема булырга тиеш. Күңел чисталыгы, мәхәббәттә сафлык, илгә тугрылык дигән үлчәүләрне алып салып карасаң — җырлар ачыла да бетә! Әнә шул сыйфатлар белән сугарылган җырлар гына халыкара байлыкка әйләнә дип уйлыйм мин.

Мин күп уйландым: туган илен үз теләге белән ташлап читтә яшәгән кешенең безнең кебек гадәти кеше белән чагыштырганда нинди аермасы бар? Җавап минем өчен инде ачык: теге кешенең күңелендә туган җиргә бәйләп торучы җыр юк. Җыр — бәйләргә тиеш! Ярлымы, баймы ул синең туган төбәгең, юллары яхшымы аның, Азнакай, Зәй, Чаллыдагы кебекме ул, әллә Буа, Саба, Арча ягында машина колагыннан үтеп керерлек пычракка батканмы ул, һич тә аларга карамыйча, кешене туган ягына җыр, моң беркетеп тора. Синең туган авылың чирәмле, татлы, каенлы, чишмәле булырга мөмкин; синең туган ягыңның район үзәге яңа Актаныш кебек заманча матур, кислородлы, кояшлы, ямь-яшел газонлы, агачлы, асфальт юллы булырга мөмкин, синең туган ягыңның район үзәге Саба, Буа, Кукмара, Биектау кебек рәтсез, системасыз, Сарман кебек үтә шыксыз булырга мөмкин, ләкин бит ул — синеке. Ямьсез балалар була, матур балалар була. Ә кайсы ананың үз баласын ямьсез дип әйткәне бар?

Хәтер... Мең тугыз йөз илленче елның эссе, коры июнь ае. Яздан тибеп чыккан тавык үләне, бичара, кызарып янды, аяк астында кетердәп кала торган булды. Кояш саргайды, җир өстен шомлы хәтәр рәшә басты, тән кычыта, аяклар сызлый, карт-корының күзе эчкә батты. Корылык! Бөек юлбашчы, аның үзе кебек үк мәшһүр трубкасы һәм Идел буе картасы төшерелгән «И засуху победим!» дигән плакат та ярдәм итмәде — иген кырлары инде агарып калган кояш астында янды да янды.

Мин ул вакытта авылда, җидееллык мәктәптә егет-малай, укытучы булып эшли идем. Халык шикләнеп кенә Сабантуй-

га әзерләнде: болай корыга китсә, игеннәр янып бетсә, Сабантуй булырмы, юкмы? Шикләнде халык, әмма әзерләнде...

...Әйе, Сабантуй көнен көткән вакыт иде. Сабантуй дигән зур хезмәт бәйрәменең вакытына, эчтәлегенә акыллы агай-эне соңгы заманда ике төрле зарар салды. Беренчедән, Сабан туе — ул сабан туе, ягъни язгы сабанга чыгар алдыннан, кар беткәндә, үлән типкәндә уздырыла торган хезмәт бәйрәме. Моның вакытын күчерү төп мәгънәсен югалтуга китерде. Июнь уртасында сабан (язгы кыр эшләре) бәйрәме буламыни инде? Икенчедән, аның көнен крестьянга югарыдан әйтә башладылар. Сездә фәлән көнне Сабан туе! Вәссәлам! Яңгыр явамы, кармы, кояшмы-болытмы, сез шул көнне Сабантуй уздырыгыз! Нәкъ инде команда биреп туйда егет белән кызны үбештергән кебек...

Тарих боларны төзәтер әле.

Илленче елның коры, эссе, ап-ак кояшлы, вак тузанлы җәе — июнь иде. Кинәт халык арасында хәбәр таралды: Сабантуйларны, корылык аркасында, райком «әтминәйт» иткән икән.

Шундый киеренке, коры, тын буылырлык эссе көннәрнең берсендә авыл Советы телефонограмма алды:

«Иртәгә, ундүртенче июньдә, сәгать унга район культура йортына килергә тиешләр:

1. Барлык колхоз идарәсе әгъзалары, авыл Советы депутатлары;

2. Барлык укытучылар, кибет, медпункт, клуб хезмәткәрләре.

Килү мәҗбүри».

Телефонограмманы тапшырды: Шәмсуарова.

Телефонограмманы язып алды: Баһавиева.

Шулай эссе иртәдә район үзәгендәге культура йортына — элеккеге чиркәүгә җыелдык. Халык күп, клуб эссе, тынчу иде, кемдер әйтте: кояшта кырык дүрт градус, диде. Тагын берәү әйтте: Сабантуйны «әтминәйт» итәләр, бүген үк силос әзерләргә чыгасы, район активы шуның өчен җыелган, диде.

Ләкин тиешле кешеләр активның нәрсә өчен җыелганын беләләр, һәм моңа инде ун-унбиш көн буе әзерлек тә алып барылган икән.

Президиум үз урынын алды, зал шым калды. Район җитәкчесе көн тәртибен игълан итте:

— Бөтендөнья фәненең корифее, галимнәрнең өлкән әтисе, бөек юлбашчы, безнең җиңүләребезне тәэмин итеп бәхетле мул

тормышка чыгарган, исеме тарихта алтын хәрефләр белән язылган даһиның «Марксизм һәм тел белеме мәсьәләләре» дигән гаять тирән, җир шарындагы бөтен фәннәрдә борылыш ясый торган һәм дә безнең бүгенге тормышыбызны тагы да алгарак алып китеп чәчәк аттыра торган гаҗәеп гүзәл хезмәтенә багышланган район активы җыелышын ачык дип белдерергә рөхсәт итегез, иптәшләр.

Бөтенебез, аягүрә торып, ун минутлар чамасы кул чаптык. Беренче булып кул чабудан туктарга һәм беренче булып утырырга берәүнең дә йөрәге җитми, бу бик хәтәр эш икәнлеген һәркем аңлый иде. Аннан икенче секретарь (сәгать тә ун минут кирәк диде) доклад ясады. Докладтан аңлашылды: Николай Яковлевич Марр дигән академик кайчандыр яңа лингвистик агым — яфәтизм теориясенә нигез салган икән. Ул картвель телләренең семит, баск телләре белән уртаклыгы турында фәндә факт белән беркетелмәгән теория уйлап чыгарган икән...

Җыелышка, нинди уңай беләндер, безнең күрше Исламгали агай да килгән иде, ул, җәплекәле кулы белән колак яфрагын алгарак этеп, зур игътибар күрсәтеп тыңлады, ара-тирә миңа караштырып алды.

Докладтан соң фикер алышулар китте. Район укыту бүлеге мөдире һәм район җир бүлеге мөдиренең чыгышыннан соң тәнәфес игълан ителде.

Клубның арткы яктагы ян бүлмәсендә буфет эшли иде, анда морс, кечкенә ак булканы ярып, эченә колбаса телеме тыгылган ризык (дөнья күргән, сугыш узган кешеләр аны «бутерброд» диделәр; бала итәкле күлмәк кигән, кояшта янып кара чутырга әйләнгән авыл хатыннары бу сүздән сискәнеп калдылар, чөнки дөнья күргән ирләр ара-тирә сүгенгәләгәндә шуңа охшашлы бер сүз ычкындыралар иде) һәм чирек литрлы шешәдә алтмыш градуслы виноград аракысы сатыла иде. Район җитәкчеләре тегесен дә, монысын да авыз иткәләделәр, авыл халкы исә — ирләре тәмәке тартудан, хатын-кыз клуб артындагы такта корылмага барып килүдән узмады. Тегеләй-болай кыланырга бит акча кирәк, ә аны каян аласың?

Тышка чыкмаска тырыштылар, анда — көн үзәге, һава яна иде.

Актив җыелышының икенче өлешендә фикер алышулар китте. Ферма мөдире, агроном, ветфельдшер сөйләде. Китапханәче, тимер юлчы, военкомат офицеры, укытучы, кибетче сөйләде. Кибетче кызның сөйләве аеруча ялкынлы булды.

— Менә монда базис һәм өскорма турында сүз бара, иптәшләр,— диде ул. — Миннән алда сөйләгән тимер юлчы, путевой обходчик Петухов иптәш тә бу мәсьәләгә кагылды. Бөек юлбашчыбыз дөрес әйтә: тел сыйныф була алмый. Маррның төп хатасы шунда. Тел ничек инде өскорма булсын? Ул базис та була алмый. Без моны ачык белергә тиешбез, иптәшләр. Һәм мин бөтен районның сәүдә хезмәткәрләре исеменнән Маррга үзебезнең нәфрәтебезне белдерәм.

Аннары «Кызыл партизан» колхозының агротехнигы Рамазан абый сөйләде.

— Менә мин, иптәшләр, карт кеше инде,— диде ул, учындагы кәгазьгә бик нык текәлеп. — Мин сезнең шикелле шәп сөйли алмыйм, шуңа күрә язганны гына укыйм. Менә болай: «Тел ул, иптәшләр, культура түгел. Әкәдимик Марр әйткән була: имеш, тел дүрт илиминттан тора: бер, сал, йон, рош. Аннан соң ул телне җитештерү кораллары белән чагыштыра. Безнең бөек даһи исә әйтә: тел, ди, ул җитештерү коралы да түгел, культура да түгел, ди бит, иптәшләр. Базис та түгел, ди, өскорма да түгел, ди. Менә бит хикмәт кайда; монысы үземнең сүз!» — Рамазан абзый, кәгазен бөкләп пинжәк кесәсенә тыкты, күзлеген салып учына алды да үзеннән, үз йөрәгеннән чыкканны гади генә итеп әйтеп салды: — Шушындый корылык, афәт вакытында, иптәшләр, терлек-туарга кышлык курмы әзерләү өчен янып-көеп йөргәндә, Сабантуй кебек газиз йоланы уздырабызмы, «әтминәйт» итәбезме дип йөргәндә дөнья хәлләрен белмичә газиз телебезне шулай бутап, халыкның миен, зиһенен мурить итеп яткан әкәдимиккә ни дип әйтим? Ыстырам бу, билләһи, бүгенгесе көндә, ыстырам. Актык сүзем шул минем. Алдагы елда терлек-туарга нәрсә ашатырбыз?

Рамазан абзый академик Маррның мең тугыз йөз утыз дүртенче елда ук үлгән икәнлеген, әлбәттә, белми иде.

Мин үзебездән ерак булган бер мәктәптә эшли идем, актив барган вакытта авылдашларым белән ым кагып кына исәнләшкәләдем.

Җыелыш кич кенә тәмамланды. Урындыклар шыгырдады, кешеләр дә шыгырдады бугай, чөнки җитәкченең йомгаклау сүзе нәкъ ике сәгатькә сузылды, ул актив җыелышына йомгак ясаганнан соң болай диде:

— Бернинди Сабантуй юк, иртәгәдән үк яфрак азык, силос хәзерләүгә чыгабыз, әле бер атнага кадәр шундый коры һава буласын әйттеләр...

Район үзәгеннән атлар, җәяүлеләр таралганда, июнь кояшы батып бара, тынчу коры кич килеп ята иде. Клуб хезмәткәрләре актив уңае белән танцы кичәсе оештырганнар икән.

Мин шунда калдым. Яшьлек бит!

Түбәндә сәхнә кырыендагы урындыкка баянист килеп утырды. Бу — Чуриле урта мәктәбенең математика укытучысы Василий Осипов. Район үзәгендә — Вася. Сап-сары чәчле, аксыл битле, зәңгәр гәрәбә күзле. Сугышта катнашкан, шушы авыл — Чуриле егете. Кызлар арасында — король.

Вася гармун каешларын рәтләде дә «заигрыш» бирде, күзләрен читкә борды да клуб эченә моң сипте. Моңы... татар моңы иде. Ул арада район үзәгенең егетләре, кызлары парлашып уртага да чыктылар.

— Танго! Танго!— дигән тавышлар ишетелде. Минем бу сүзне ишеткәнем булса да, тангога биегәннәрен күргәнем юк иде.

Иң беренче хәрәкәтне безнең авыл Исламгали агайның энесе, авылның горурлыгы Әхәт абый ясады. Мең тугыз йөз кырык сигезенче елда ул, сугыштан соң әллә ниләр күреп, авылга кайтып төште һәм үзе генә түгел: Красноярск краеның төньягындагы бер лагерьда санитарка булып эшләүче Өммеһани исемле якты йөзле, сылу гәүдәле, аксыл тәнле — безнең якта әлегәчә бөтенләй күрелмәгән өр-яңа бер «порода»лы киленне эләктереп кайтты. Кайтты да шундук район клубына культорг булып урнашты. Өммеһанины (район үзәгенә урнашкач ул бик тиз генә Майяга әйләнде) шундук район шифаханәсенә санитарка итеп алдылар.

Менә бүген Әхәт абый үзенең йомшак билле Майясы белән «вечер»ны башлап җибәрде инде.

Вася Осипов — акыллы егет. Культорг Әхәт абыйның күңелен күрәсе килә. Русның юньлесе — гел шулай: татар янында гел татар сүзе кушып сөйләшергә ярата. Татар да шулай: руска беркайчан да (юньлесенә, эшлеклесенә) «ызнакум» дип дәшмичә, аркасыннан какмыйча калмас.

Һәм чиркәү-клубка гап-гади, ләкин тирән мәгънәле музыка тулды. Майяның йомшак биленнән сак кына тотып, гимнастерка-каешлы, шыгырдавыклы солдат итеге кигән кара чәчле чибәр Әхәт абый, баян тактына басып, башын артка ташлап, танго бии һәм бәрхет тавыш белән җырлый иде:

Син кайларда йөрисең и-и-к-ә-ә-н...

Шул тактка бөтен зал кушылды. Сәламәтлеге аркасында запаска чыгарылып, үзенең хатыны, фронтны узган шәфкать туташы Лизага ияреп монда кайткан украин егете өлкән лейтенант Петя Курманаевский, аккош гәүдәле хатынын сак кына кочаклап, «пачум зрә» татарча җырлап, тангога бии иде:

Кайтырсың диб мин умид итям,
Мин сине көтям, көтям, көтя-м-м...

Залда, әлбәттә, иң бәхетлесе Әхәт абый иде. Бөтен татарырусы шушы тынлы тактка җай гына басып, белгәне — белгәнчә, белмәгәне белмәгәнчә кушылып җырлый-җырлый биеде. Түшәмнәр биегәйде, стеналар читкәрәк китеп, чиркәү-клуб эче зурайды, Вася Осипов, хәйләкәр елмаеп (игътибар итегез: татар телен, җырын-моңын белгән рус һәрвакытта да татарлар арасында үзен мәгънәле хәйләкәр тота), баянның бакаларына кинәт-кинәт каты басып, биючеләргә карап ала иде. Зал кызды. Кызды...

Сагналар сине очар кошлар,
Сагналар сине...

Вася Осипов: Тоң! Тоң! *(Үзе елмая.)*
Петя Курманаевский *(җырлый)*:

Кайтырсың диб мин умид итям-м-м...
Мин сине көтям, көтям, көтя-я-м.

Әхәт абый бәхетле: гәүдәсенең бөтен авырлыгын кулы аркылы хатынының биленә тапшырган да күзләрен ярым йомып җырлый, идәндә солдат итекләрен шудырта.

«Көт, иркәм, мине» дигән сүзләр
музыка төсле тоела миңа...

Тагын бераздан:

Күңлем эзли сине кич-иртән,
Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...

Әхәт абыйның тормыш юлы — бөтен бер китап. Безнең авылны биографиясез, тарихсыз дип кара инде! Әхәт Яһүдин, утыз сигезенче елны Ташлытау педучилищесын тәмамлагач, комсомол путевкасы буенча Шпицбергенга укытучылык эшенә китте. Норвегия дәүләтенең архипелагы турында, мең тугыз йөз егерменче елда АКШ, Бөекбритания, Франция, Италия, Дания, Норвегия, Нидерландлар, Япония, Швеция дәүләтләре

табигый байлыклар һәм стратегия мәсьәләсендә пакт төзегәннәр иде. Егерме дүртенче елда бу килешүгә СССР да керде. Норвегия акционер компаниясе һәм СССР предприятиесе бу архипелагтагы запасы сигез миллиард тонна чамаланган ташкүмер чыгару эшенә керешкәннәр иде. Бераздан анда безнең илнең консульствосы да булдырылды. Шпицберген шахталарына бездән эшчеләр китте. Эшче гаиләләренең балаларына мәктәпләр ачтылар. Әхәт Яһүдин әнә шундый мәктәпләрнең берсендә эшләде. Аннан хатлар килгәләде. Ул хатлардан аңлашылганы шул булды: Әхәт уйлаганча түгел икән анда. Мәктәптә аны арифметика укытырга билгеләгәннәр (дөрес, ул математика буенча училищеда беренче иде); аннан соң бу утраудагы мәктәптә руслар гына түгел, башка милләт балалары да укый икән. Әхәт абыеңа ашыгыч рәвештә немец һәм француз телләрен өйрәнергә кирәк булган.

Ул бер тапкыр да ялга кайтмады, тик һәр җәйнең башында ниндидер юллар, почталар аша авылга посылка килә иде. Шпицбергеннан! Балык икрасы (авыл халкы аны «укъра» дип әйтә һәм, күчтәнәч итеп күршеләргә өләшкәч, һәркем аны мәчегә бирә иде), кызыл балык, һинд чәе (такта чәйгә генә табынып яшәгән халык үзара сөйләшә: бу чүпне нәрсә дип сала инде, бичара, такта чәй күрмичә интегә икән), кофе (анысының мәгънәсен бөтенләй аңламыйча, «имән чикләвеге оны» дип исем куштылар), балык консервлары. Берсендә хәтта калай банкада «Шпинат-пюре» дигән нәрсә дә килде. Ил-җир күргән (ни әйтсәң дә, авылдан ун чакрым ераклыкта фатир торып трактористлыкка укыган) Исламгали дә монысын аңламады, җидееллык мәктәпкә барып, бөтен укытучыларга күрсәтеп карады, сүзнең ни беренчесен, ни икенчесен аңлаучы табылмады. Шулай да беркөнне кичке аш алдыннан бөтен тыкрык-күршеләрне җыеп моны ачтылар. Ачтылар... һәм барысы да кәефсез калдылар. Бу яшел боткага тегеләй-болай тел очын тидереп караганнан соң, ишек янындагы чиләккә түкереп таралыштылар һәм татарча бер начар исем куштылар: һәркемнең ишегалдында каз бәбкәләре йөри, һәм алар, әлбәттә, яшел чирәм ашыйлар, шунда ук башка мәшәкатьләрен дә хәл итеп баралар иде. Бу әйбер — шул инде.

Әхәт Яһүдин сугышка шуннан — ерак утраудан киткән. Бәхетсезлеккә каршы, сугышның өченче елында яраланып әсирлеккә эләккән. Тагын да яманрагы шунда: әсирлек карточкасын тутырганда «нинди телләр беләсең» дигән сорауга

«рус, татар, немец телен — иркен, французчаны аңлыйм, укыйм» дип язган. Яшь бит — нибары егерме өченче яше! Тәҗрибә юк. Немецлар, әлбәттә, моңа игътибар иткәннәр һәм аны, савыктырып, штабта калдырганнар.

Комсомол путевкасы белән дәрәҗәле эшкә җибәрелгән егет бервакыт немецларның кыр штабында безнең егетләргә — хәрби әсирләргә — бланк тутырып утыра башлаган. Чигенәчигенә Польша чигенә җиткәндә, төнге бер бомбежка вакытында фашистларның штаб машинасыннан кача алган һәм ике көн буе туңып, күшегеп ятканнан соң, үзенең нәкъ чик буенда икәнен аңлаган: СССР дигән җанга якын чигебезгә багана утыртып яткан үзебезнең бер отделение янына килеп чыккан. Аны һөҗүм белән алга баручы дивизия штабына озаталар, анда «махсус бүлек» (особый отдел) аркылы «чистарыну» узгач, хәрәкәттәге армиягә язалар. Һәм озак та үтми, кулына автомат тотып, ул әлеге чик аркылы көнбатышка таба кабат уза. Нәкъ менә шул ук юлдан. Теге баганага күзе төшә. Багананың бу ягына — «СССР» дип, теге ягына «Poland» дип язып куйганнар. Аңа карап узганда, һәр солдатның йөрәге, тыны кысыла. Туган илнең иң газиз, иң мәгънәле ноктасы — ул чик баганасы. Тик монда... бу юлы тын кысылып кына калмый, солдатлар нигәдер гагылдап көләләр иде. Игътибар беләнрәк карагач, Әхәт аңлады: баганада, астарак бер щит бар икән. Ашыгыч кына, бизәмичә генә кызыл буяу белән язганнар: «До Берлина осталось 872 км». Шуның астына ук кемдер, бер шаяны тагы да ашыгыбрак, яшел буяу белән тозлы бер җөмлә өстәгән: «Ни... дойдем!»

Шуннан көләләр икән.

Күңелле, дәртле көннәр иде. Ул көннәрдә инде бик нык исән каласы килә иде. Польша язы, юл өстендәге чәчәкле авыллар, кечкенә җыйнак шәһәрчекләр, поляк хатын-кызларының шатлыклы күз яшьләре. Аннан Германия туфрагына аяк басуга тын буыла башлады. Безме бу? Шушымы бөтен дөньяның астын өскә китергән Дойчечланд? Шушымы безне кол итү турында озак еллар буе программа төзегән халык?

Ләкин немец авыллары, шәһәрчекләрендә дә шатлыклы күз яше белән каршыладылар солдатларны. Немец телен бик яхшы белгән Әхәт Германиянең сиреньгә чумган кояшлы апрелендә көнбатышка таба яшьлек дәрте белән атлады, фашист әсирлеген кичергән яшь егеткә мондый халәт аеруча, аның янындагы бер иптәше дә аңламаганча рәхәт, шатлыклы иде.

Җиңү килде. Әхәт Яһүдин Тугызынчы май көнен Карлсхорста каршылады. Аннан искиткеч шатлыклы, дәртле, сагышлы матур җәй башланды, ул хезмәт иткән дивизия ике ай буе, эшелонга танк, артиллерия, снаряд, зенитка төяп-бушатып, нәрсәгәдер, нииндидер бер зур вакыйгага әзерләнде. Ничек кенә булмасын, яшьләрнең күңеле шат иде.

Тик беркөнне солдат Яһүдинне «махсус бүлек» чакыртып алды. Алды һәм... шул көннән соң аның эзе югалды.

Аның авылга, Исламгали абыйсына килгән беренче хатының конвертында «Норильск» дигән штемпель тора иде. Берничә тапкыр хат алыштылар.

Кырык сигезенче елда исә ул, чибәр хатынын иярте, авылга ук кайтып төште. Абыйсы Исламгалигә әйтте:

— Подчистую,— диде. — Бу тормыш мине бер гаепсезгә әллә нишләтеп ташлады. Үзем дә аңламыйм. Кеше ничек аңласын?

Чиста документлы Әхәт солдат шулай бер атна узганчы район үзәгендәге клубка эшкә керде, исәбе — шундагы урта мәктәпкә чит тел укытучысы булып урнашу иде.

...Танго кичәсе үткәндә, төн уртасында ниндидер бер явызы район үзәгендәге куркыныч бер оешманың ишеген каккан һәм, имеш, уч төбе кадәрле бер кәгазь калдырган: «Тел турындагы шундый әһәмиятле бер сөйләшүдән соң, район клубында яшьләргә шул җыелышның әһәмиятен аңлатасы урында пленный Әхәт Яһүдин намуссыз рәвештә бию оештырды, хатыны белән икесе парлап җырлый-җырлый биеделәр, бөтен көннең авторитетына төкерделәр. Чын коммунист».

Хәтерлим: бик озак хәбәрсез торганнан соң, Өммеһани апа елый-елый ябыгып, тартылып, йомылып беткәннән соң, ике ел үткәч кенә Әхәттән бер хат килде. Төгәлрәге, каяндыр, каядыр узучы бер абзый, Исламгали агайның өенә кереп тә тормыйча, чоланнан гына бер хат биреп китә. Әйбер төрә торган сары кәгазьгә карандаш белән язылган, конверты кулдан ясалган, пешкән бәрәңге белән ябыштырылган. Өммеһанига...

«Сөеклем Майя!

Син миңа рәнҗемә инде. Син минем бәхетем иден. Мин бик еракта. Безгә хат язышу тыелган. Әйттеләр: бу урын — сезгә мәңгелек, диделәр. Монда хатын-кызлар да бар. Теләгәнегез гаилә корыгыз, диделәр. Кайту, кавышу беркайчан да булмаячак, диделәр. Син акыллы, чибәр, яшь әле. Үзеңә тиңнәрне табарсың. Мин сиңа моны рөхсәт итәм. Син дә миңа рәнҗемә,

мин дә шулай — сиңа тиңен таба алмасам да, картаеп түшәккә егылгач җан биргәндә авызыма су тидерергә тиешле берәр хатынга өйләнермен инде. Безнең беребезнең дә гаеп юк бит! Без ник бу хәлгә калдык? Башым җитми. Әти сөйли торган иде: күгәрчен күченә козгын җитәкче булса, бөтен күгәрчен дә үләксә ашый башлар, дип.

Син мине гафу ит, мин сиңа бәхет китерә алмадым. Хуш, бәхил бул, җаныкаем. Бу җырларны, әгәр яңа иреңнән бала тапсаң, аны бишектә тирбәткәндә җырларсың:

Еракларда күренеп тора
Эсвирлау дигән кала.
Иленнән сөреләмени
Бәхетле булган бала?

Кулларыма алдым яулык,
Җилгә чыгып болгадым;
Тыныч торган дөньяларны
Кайгым белән чолгадым.

Хәтерлисеңме? Соңгы кичне без тангога биегән идек. «Син кайларда йөрисең икән?» Ул бит безнең татар халкының беренче тангосы. Аны җырчы Сара Садыйкова иҗат иткән. Ул тангода бит гел сагыш тавышы. Ләкин мин андагы сүзләрне кабатлый алмыйм инде: «Каушырбыз дип мин өмет итәм...» Юк, без кавышмыйбыз инде. Хуш, бәхил бул, бәхетем, бердәнберем минем».

Исламгали агай бу хатны үзендә саклый. Майя шулай рөхсәт иткән...

...Мең тугыз йөз сиксән бишенче ел. Җәй. Яңа Чуриле авылы. Элеккеге район үзәге, танголар яңгыраган клуб-чиркәү. Мин, яшьлегемне сагынып, картларча бер елап алырга җыенып, шул чиркәү янында басып торам. Зур булмаган икән ул. Гадәти бер авыл чиркәве. Дөнья күрмәгән малайга гына мәһабәт, биек булып күренгән икән ул. Буяулары уңган, аны инде бер дә ачмыйлар икән, баскыч такталары тузган, Чуриле авылы үзе дә беткән. Урамнар тып-тын. Без яшь чакта киерелеп, халык белән тулып яши иде бит ул. Нигә шулай икән бу дөнья? Менә бу бина кайчандыр чиркәү булган, анда поп, пономарь хезмәт иткән, куәтле тавыш белән чиркәү хоры җырлаган. Аннан чиркәүне япканнар, попны сөргәннәр. Чиркәү хоры таралган. Бераздан аны клуб иткәннәр. Ул клубта яшьлек чәчәк аткан, анда җырлаганнар, биегәннәр, кино караганнар, сөешкәннәр, кавышканнар. Бераздан ул клубны да япканнар, җыр, бию беткән. Кая инде ул хәзер танго тавышлары? Нигә шулай — булган әйбер бетеп бара?

Ярымүлек авыл урамында эт тә юк. Чиркәү кәрнизләрендә элеккеге кебек чәүкәләр чикылдамый. Авыр тынлыкта мин күзләремне йомам да хыялым белән илленче елларга кайтам. Ә аннан хәсрәтле, дәһшәтле, афәт катыш танго тавышы ишетелгән сыман. Колагымда Әхәт солдат тавышы:

Син кайларда йөрисең икән?
Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...

Хуш, мәңгегә хуш, яшьлегем тангосы!

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәр ни өчен «Бәхилләшү» дип исемләнгән?

2. Вакыйгаларны берләштереп икегә бүлегез. Исем куегыз.

3. Конференциядә ялган һәм дөреслек каршылыгында ачылган хакыйкать нинди?

4. Яшьләр кичәсе, аның төп геройлары турында фикер алышыгыз. Бу вакыйга белән автор нәрсә әйтергә тели?

5. Әхәт Яһүдиннең фаҗигале язмышына бәйле чорга характеристика бирегез.

«Бәхилләшү» повесте

Сез танышкан өзекләр «Бәхилләшү» повестеның идея-эстетик үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә. М. Мәһдиев, башка әсәрләрендәге кебек үк, авыл турында, аның үткәне һәм бүгенгесе турында яза. Повестьта тоташ сюжет юк, вакыйгалар төрле планда һәм бер урыннан икенчесенә шактый еш күчеп йөри. Әмма «мин» аларны бер үзәккә бәйли, бербөтен итеп күзалларга ярдәм итә. Безнең каршыда сугыш чоры һәм сугыштан соңгы татар авылы, аның кешеләренең шатлык-борчулары бөтен тулылыгында ачылып китә. Әдипнең геройлары — гади, гадәти кешеләр. Ниндидер искитмәле эш-гамәлләр дә кылмыйлар, йә язмыш кочагында калып, йә чор мохите йогынтысында, йә аңлап һәм чын күңелдән ышанып көндәлек мәшәкатьләр белән яшиләр. Шулай да һәрберсенең үз йөзе, яшәү рәвеше бар. Зур булмаган штрихлар белән автор күбесенең кабатланмас шәхес булуын күрсәтә алган.

Беренче бүлектә сурәтләнгән Исламгалине без беркем белән бутамыйбыз. Әлеге сугыш батыры — чын мәгънәсендә милли образ. Татар халкына хас булган сабырлык, рухи ныклык кебек сыйфатларны Ходай аңа мулдан биргән. Әйе, ике кулын сугышта калдырып кайткан, төннәрен сызланып интегүче

Исламгали агайга капка төбенә җыелган күршеләренә мәзәк хәлләр генә сөйләү нинди кыенлык белән бирелүен үзе дә хатыны гына белә. Шуңа да ул безне үзенең оптимизмы, яшәү көче, горурлыгы белән сокландыра.

Тугызынчы бүлектә сурәтләнгән вакыйгалар артында туган җиргә, халыкка, телгә мөнәсәбәт, аның кеше тормышындагы ролен ачу һәм киңрәк планда милләт язмышы турында борчылып уйлану ята. Билгеле бер шартлар тәэсирендә Фәләхетдин туган җиреннән, теленнән ераклаша. Абыйсының саллы «сабагыннан» соң да ипкә килми. Автор аның уй-фикерләрен күрсәтмәсә дә, кыска гына күренеш, дөресрәге, әдәби деталь булып килгән сүзтезмә ярдәмендә Фәләхетдиннең бөтен күңел дөньясын ачып сала. Якты дөнья белән саубуллашканда, ул татар телендә ике сүз әйтә: «Бәхил булыгыз!» Моның артында исә бу кешенең гомере буе туган җирен, авылын, телен сагынып яшәве; әлеге изге төшенчәләрдән аерылган адәмнең бәхетле була алмавы; аның әти-әнисе, якыннары алдында гафу үтенүе, бәхиллек соравы ята.

Ә инде унберенче бүлектә сурәтләнгән Әхәт Яһүдин тетрәндергеч язмышлы шәхес буларак күңелдә кала. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы капма-каршы пландагы ике вакыйга аша бирелә. Конференциягә бәйле күренешләрдә идеологиянең кешене бер винтикка әйләндерүе, җәмгыятьтәге мәгънәсезлекләр, сүз сөйләү, җыелышлар үткәрү белән мавыгу һәм халыкның күпгасырлык традицияләренә, гореф-гадәтләренә кизәнү, аларны санга сукмау ачылып китә. Әдип уңышлы тотып алганча, язып биргәнне, кушканны әйтергә, сөйләргә мәҗбүр булсалар да, кешеләрдә иман, дөреслекне аңлау, күрү, халык тормышы өчен борчылу саклана. Рамазан абзыйның кешене эштән аерып юк белән баш катырулары турында әйткән сүзләре — моның ачык мисалы. Яшьләрнең кичке уенына бәйле вакыйгага «мин»нең солдат хезмәте турындагы күренешләр кушылып, музыка һәм сүзнең эчке берлегеннән туган танго кебек, лиризм һәм фаҗигалелекнең гаҗәеп синтезына ирешелә. Төрле милләт кешеләренең бердәм теләк белән һәм чын күңелдән беренче татар тангосын башкаруы һәртөр идеологиягә, куштаннарга җавап булып яңгырый: тормыш дәвам итә, яшь буын килә, татар милләтенең әле киләчәге бар! Әхәт Яһүдин образында күпләрнең башына төшкән кайгы-хәсрәт чагыла. Талантлы, ут-суны кичкән, бәхетле тормышка лаеклы бу егетнең әнә шулай юкка чыгуы җанны тетрәтә, әләкчеләргә,

аларны тудырган җәмгыятькә нәфрәт уята. Гомумән, М. Мәһдиев чор каршылыкларын тормыштагыча бирә, сындырылган язмышларга бәйле хакимиятнең кешелексез якларын, эш-гамәлләрен ачып сала.

Әдипнең теле чын мәгънәсендә матур, урыны белән ул күп мәгънәле, күп сыйдырышлы, урыны белән кинаяле, урыны белән җор. Язучы сөйләм теленең бөтен нечкәлекләрен белеп яза, халыкчан гыйбарәләрдән, чагыштырулардан, мәкаль-әйтемнәрдән иркен файдалана. Күпчелек геройларын индивидуаль сөйләмнәре аша тасвирлый.

Повесть «Бәхилләшү» дип атала. Мондый исем бирүнең сәбәбе турында М. Мәһдиев үзе үк яза. Ул балачагы, яшүсмер еллары үткән, үзе бик яхшы белгән, кабартма-коймак, яңа пешкән ипи тәме белән хәтерендә калган, бәрәңге сабагы, салам исләре белән күңеленә береккән, матур күңелле, ярдәмчел гадел кешеләре белән төшләренә керә торган авылы белән хушлаша.



Нурихан Фәттах
(1928—2004)

60 нчы еллардан татар әдәбиятында да башланган яңарыш хәрәкәтенең үзәгендә торган әдипләребезнең берсе — Нурихан Фәттах. Мондый дәрәҗәгә ирешкәнче аңа зур гына тормыш һәм иҗат мәктәбе үтәргә туры килә. Ул 1928 елның 25 октябрендә хәзерге Башкортстан Республикасының Яңавыл районына кергән Кучтавыл дигән татар авылында крестьян гаиләсендә туа. 1946 елда, Яңавыл татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Нурихан Татарстанга килә һәм Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Студент еллары үткәч, ул Татарстан китап нәшриятында, Чистай шәһәрендә газета редакциясендә эшли. 1953 елдан профессиональ язучы булып китә.

50 нче елларның икенче яртысыннан Н. Фәттах иҗатының тормыш офыгын киңәйтү турында кайгырта башлый кебек. Казакъстанда чирәм җирләрне үзләштерү башлангач, ул, анда китеп, Павлодар өлкәсендәге «Казан» совхозында эшләп ала, бер үк вакытта ул яктагы тормыш белән таныша һәм шул нигездә «Бала күңеле далада» дигән романын яза. Чирәм җирләргә килгән якташларыбыз хезмәтен һәм тормыш-көнкүрешен, җирле халык — казакъларның үткәнен һәм бүгенгесен яктыртырга алынган бу әсәрендә авторның тормышка үз карашын чагылдырырга омтылуы да ачык күренде. Рәсми фикерләүгә туры килеп бетмәгән бу караш «Бала күңеле далада» романының әлеге темага багышланган башка әсәрләрдән шактый аерылып торуына китерде. Медицина училищесын тәмамлаган фельдшер кызның авылга килеп эшли башлавын сурәтләгән «Мөдир Саҗидә» повесте да яшь кешенең тормыш-

та үз урынын һәм бәхетен эзләве мәсьәләсен шактый үзенчәлекле яктыртуы белән аерылып торды.

60 нчы еллардан Н. Фәттах иҗатының яңа һәм аны ныклап әдәбият тарихына керткән чоры башлана. Бу вакыттан ул тарихка йөз белән борыла. Моңа әзерлек инде студент елларыннан башланган була. Университетта укыганда фольклор һәм археография экспедицияләрендә катнашып, ул халык иҗатына һәм тарихына караган материаллар җыя. Менә шулар аңарда тарихыбызның моңа кадәрге чоры турында әсәр язу теләген тудыралар. Нәтиҗәдә X гасыр башында Идел буе болгарлары дәүләте — Бөек Болгарның төзелүен чагылдырган «Итил суы ака торур» романы языла. Аның тарихи әһәмияте шунда: ул, татарларны монголлар белән бутап, аларны каяндыр читтән килгән, баскынчы, кыргый һ. б. шундый кара төсләрдә күрсәтүгә чик куя башлаган беренче әсәрләрдән булды. Романда безнең халыкның бабалары Идел буе болгарлары булуы, соңгыларының үз җирендә Көнчыгыш Европадагы иң әүвәлге дәүләтләрнең берсен төзүе күрсәтелде.

Халкыбыз тарихының чишмә башы белән кызыксынуын дәвам итеп, Н. Фәттах алга таба б. э. к. VII гасыр урталарында Чин (Кытай) империясе белән чиктәш булып яшәгән төрки сөн халкы тарихына мөрәҗәгать итә һәм бу халыкның фаҗигасен чагылдырган «Сызгыра торган уклар» романын яза. Әлеге фаҗиганең сәбәпләрен автор, бер яктан, ил эчендә бердәмлек булмауда, икенчедән, аның ул вакытта куәтле Чин империясенең башкаларны басып алып дөньяда хакимлек итү сәясәтенең корбанына әверелүендә күрә. Язучының бик ерак тарихтан ясаган мондый күзәтүләре һәм нәтиҗәләре халкыбызның бүгенге хәле һәм язмышы турында уйлаганда да әһәмиятен югалтмыйлар.

Сорау һәм бирем

1. Н. Фәттахның әдәбиятка ничек килүе турында фикер алышыгыз.

2. Әдипнең тарихи темага мөрәҗәгать итүенең сәбәпләре нидән гыйбарәт?

ИТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

(Романнан өзекләр)

БЕРЕНЧЕ БАБ

Менә тагын яз җитте. ... Сулар акты... Аҗун яралганнан бирле сулар кая таба аккан булса, быел яз да сулар шул бер якка юнәлделәр. Инешләр, елгалар, ермаклар, ташулар... — барысы да Чулман атлы олуг суның кочагына омтылдылар... кушылдылар, көчәйделәр, ургып-шаулап, алга ыргылдылар. Чулман исә еракларлан, якыннардан җыеп алган язгы суны, сыяларны, бозны-карны тагын ары алып китте. Кайдадыр кояш баешта, кыялы ярлар янында олуг Чулман үзенең бөек туганын очратырга тиеш. Алар шунда кавышалар, бергәләшеп, кочаклашып, көн ягына юл тоталар. Кайнар ком, кояш илендә, тау-ташлар, камышлар илендә, Итил-Чулман суын ямансулап, иксез-чиксез тиңгез, төпсез тиңгез көтеп ята. Хазар тиңгез көтеп ята. Анда изге Хазар җире, анда изге каган...

Кояш су астыннан чыгып бер-ике таяк күтәрелгәндә, сөрәнчеләр, Яр-капкага җитеп, кире борылдылар. Күрән би урдасы янында аксакаллар төркеме туктап калды. Би өендәгеләр дә быргы уйнап җибәрделәр, байракларын күтәрделәр. Капка сакчылары, каерып, имән капкаларны ачтылар. Капкада би углы Тотыш күренде.

Атасы кебек ул таза, эре сөякле иде. Тик аңа караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк. Борын асты әле аның яңа гына караеп килә. Бүгенге көндә караңгы чырайлы булу язык саналса да, алсу иреннәре кысылган, матур кара кашлары җыерылган. Җылый-җылый күз төпләре кызарып беткән. Ул кайгылы, ул ачулы, ул ярсулы иде. Сул кулына яшел төстәге язгы йолык байрагын тоткан, уң кулына үзенең сөеклесен — Йолдыз-кашканы җитәкләгән. Бүген ул туй башчысы санала. Аксакаллар кебек, ул да бүген баштанаяк актан киенгән. Биленә аның көмеш аеллы киң каеш буылган, муенына көмеш чылбыр белән ыруның сакчысы — кечкенә алтын бүре башы тагылган.

Яшь чибәр җегет Йолдыз-кашка белән икәүләп капкадан чыкты да, тирә-якта җыелып өлгергән кешеләрнең берсенә дә карамыйча, төп юлга төште. Углы артыннан ук капкадан Күрән би чыкты, Койтым бикә, бинең башка хатыннары, балалары, туганнары чыкты. Ыру башы белән Койтым бикәгә урам якта-

гы сигез аксакал кушылды. Барысы да, үзләренең урыннарын белеп, би артыннан, аксакаллар артыннан иярә бардылар. Ясанган, бизәнгән, куанып елмайган кешеләр төркеме, көчле бер агым булып, урамнан Басу-капка ягына юнәлде.

Барлык кешенең күзе бары Йолдыз-кашкада гына булды. Алар аңа, сокланудан бигрәк, куркып, аптырап карадылар. Күрән бинең мактанычы, яшь Тотышның куанычы булган атаклы чаптарның бүген менә йолык туенда чалыначагына беркемнең дә ышанасы килмәде. Бу ничектер башка сыймый торган, аңлап булмый торган нәрсә булып тоелды. Тик шулай да бу турыда беркем дә ачыктан-ачык әйтергә батырчылык итмәде.

Икенче көнне, таң атар-атмас борын, Күрән бинең капка төбенә Утташ кам килеп җитте. Ул чамадан тыш ачулы иде. Үзен капкадан кертергә теләмәгән сакчыларга ул яман сүзләр әйтте. Сакчылар аңа бинең йокыдан уянганын көтәргә куштылар. Утташ кам теләсә дә, теләмәсә дә көтәргә тиеш булды.

Би аны үзенең ак өендә каршы алды.

— Нишләп бик иртә? Бер-бер эш чыктымы әллә? — диде ул, бабасының таң тишегеннән килеп җитүен ошатмыйча.

— Эш чыкты, би... кияү! — дип кычкырды ул, чәрелдек тавыш белән. — Ниндидер явызлар изге наратны... бөтен ыругның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Тәүбә! Тәүбә! Изге аланны бозганнар, би! Изге Кайракканның йөзенә төкергәннәр! Тәүбә! Тәүбә!

— Шуннан? — диде би, аның сакалын бушаткандай итеп.

— Ш-шуннан...— диде Утташ кам.— Из-зге нарат төбендә... ч-ч-чүмәлә дисәң, ч-чүмәлә түгел... у-утын дисәң, утын түгел... Йа Тәңрем! Үле бүреләр өелеп ята! Кайсын ук белән, кайсын кылыч, сөңге белән... Унлап-унбишләп! Бүре каны койганнар! Изге җиргә, изге нараткаебызга... бүре каны койганнар!

Утташ кам, сакалы ычкынгангамы, изге наратны кызганыпмы, кычкырып җылап җибәрде.

Күрән би яшен суккан кебек телсез-өнсез калды: бу, чыннан да, коточкыч иде, бу, чыннан да, беркайчан да булмаган, була алмастай яман бер эш иде.

Коллар бүре үләксәләрен, шулай ук барлык карачкыларның сөяк-санакларын урман арасындагы тирән чокырга илтеп ташладылар. Берәрсе ялгыш күрә-нитә күрмәсен дип, Күрән би үләксәләргә ут төртергә кушты.

Өенә ул бик күңелсезләнеп кайтты. Кайткач та Койтым бикә белән Тотыш угланны үз янына чакырткы.

— Кем эше булыр икән бу? — диде ул, авыр гына, изге аланда күргәннәрен сөйләгәч.

— Мин! — диде Тотыш, өй эчен яңгыратып.

Ул алай кычкырып та әйтмәде бугай әйтүен, шулай да ата белән анага аның бу «мин» дигәне күк күкрәве сыман булып ишетелде. Койтым бикә чак-чак кына артына аумады. Күрән би тораташтай катты да калды.

— Син... син...— диде ул, тотлыгып.— Беләсеңме шуны... бөтен ыруга... атаңа-анаңа каргышы төшәр!..

Кинәт ишек ачылып китте, күзе-башы акайган яшь сакчы, тамак ярып:

— Сөенче!— дип кычкырып җибәрде.— Киләләр! Каеклар килә!

Би дә, бикә дә шундук терелеп киткәндәй булдылар. Бүреләр кайгысы, Тотыш кайгысы онытылды, бөтен катауны, бөтен өй эчен көндезге кояштай якты куаныч биләп алды. Әйе, киләләр, соңлап булса да киләләр. Соң булса да уң булсын... Төкле аяклары белән!

Борыннан, койрыктан казаяклар аркан ыргыттылар, уртадан басма суздылар. Каек, күпер читенә тәрәлеп, чайкалудан туктап калгач та, унлап кеше аягүрә басты. Кыска итеп киселгән сакал-мыеклы, озынча битле, очкынланып торган шаян, тере күз карашлы чандыр бер кеше, елмаеп, Акбүре ыруының башы алдында бүреген салды, башын иде. Күрән би белән чагыштырганда ул бик яшь күренә иде. Күп булса аңа утыз биш-кырык яшьләр чамасы булыр.

— Казаяк ыруының башы Ямгырчы би синең җиреңә килде,— диде ул, Күрән бигә эндәшеп.

— Илме, яумы?— диде Күрән би.

— Ил!— диде Ямгырчы би.

— Төкле аягың белән, туганым Ямгырчы би! — диде Күрән би, бозылган йөзенә елмаю билгесе чыгарып.

Казаяк ыруының башы Ямгырчы би белән Кызыл Яр катауга йөзләп коралллы ир килгән иде. Йөзләгән ир арасында бер хатын-кыз да бар. Ул да булса Ямгырчы бинең кызы Тәңкә иде.

* * *

Казаяк ыруы белән Акбүре ыруы арасында борын-борыннан туганлык яшәп килгән. Алар икесе дә бер тамырдан — Ак хан йортындагы[1] Ак җылан ыруыннан аерылып чыккан булганнар. Ак ханның тамыры үзе бөек төрек бөдүнен[2] барлык җир-суларга, барлык илләргә, телләргә баш ясаган бөек Көн каган углының углына тоташкан булган. Казаяк белән Акбүре ырулары кайчандыр Чулманның түбән агымында, Итил белән Чулман бергә кушылып, өчпочмак ясаган иркен җирләрне биләгәннәр. Бер-берсе белән алар җир-су өчен дә, терлек-туар өчен дә ызгышып-талашып яшәмәгәннәр. Киресенчә, бер-берсенә кыенлык килсә, үләт, кыран килсә, шундук бер-берсенә булышка ашыкканнар. Шуның өстенә алар йорт башы Ак ханның иң көчле, ышанычлы ыруларыннан саналганнар.

Шулай итеп, ике ыру кешеләре, кайгы, талау күрмәенчә, тыныч кына, тату гына тормыш кичергәннәр. Тик шулай да мондый тыныч, тату тормыш мәңгелек булмаган. Көннәрдән бер көнне — моннан бик күп еллар элек — язгы сулар китеп җирләр кипкәч, көн ягыннан Итил буйлап кара яу басып килгән. Кара яуның башында явыз Кара хан торган. Аның кешеләре бик күп булган. Алар көчле булганнар. Аларның укларына, сөңге, кылычына каршы беркем, берни каршы тора алмаган. Язгы ташкын суны берничек тә тотып торып булмаган кебек, Кара ханның чирүен дә беркем, берни тоткарлый алмаган.

Соңгы орышта олуг йортның башы Ак хан кергәннәргә тоткын булган. Ханның, балаларының, туганнарының башын чабып өзгәннәр. Шулай итеп, тамырга балта чабылган, йорт-ил юкка чыккан. Исән калган ирләр, куркып-каушап, кайсы кая качып киткән. Кайберәүләр, башын саклап, Кара ханга бил бөккәннәр.

Әйе, Ак хан йорты юкка чыккан. Ирләр үлгән, ирләр качкан, Кара ханга бил бөккәннәр. Тик шулай да үтә батыр ирләр килмешәккә баш бирергә теләмәгән. Туган җирен-суын ташлап тәлим кеше, төмән кеше югарыга — төн ягына күчеп киткән. Шуларның беренчесе акбүреләр булган. Казаяклар, Кара ханга калан түләп, Чулман-суның түбәнендә, уңъяк ярда торып калган.

---

[1] Йорт — дәүләт.

[2] Төрек бөдүне — а) төрек — гомумән төркиләр; б) бөдүн — халык, улус.

Казаяклар белән буласы зур сөйләшүгә Күрән би акбүреләр ягыннан Койтым бикәне дә алды. Сөйләшүдә тагын Утташ кам белән Майчан аксакал да, Күрән бинең өлкән угыллары Акбога белән Котан да катнашты. Ямгырчы би үзе белән бары ике генә юлдашын алып килде.

Сүзне ул бик ерактан башлады: ике ыруның борынгыда бербереенә кардәш булуларын, элекке иркен тормышны, Ак хан, Кара хан турындагы бабайлар сүзен — барысын да искә төшерде дә әкренләп-әкренләп бүгенге көнгә күчте. Акбүреләр аны тыныч кына тыңлап утырдылар.

Ямгырчы би җентекләп акбүреләргә карап чыкты, тирән итеп тын алды да:

— Уем шул,— диде,— Алмыш хан көчәйгәнче, безгә берләшергә кирәк, Күрән би! Без — Ак хан токымнары! Бөтен Чулман бер булып безгә болгарларга каршы чыгарга кирәк. Бүре безне берәм-берәм тотып ашаганчы, тупланып, безгә аның үзен ашарга кирәк! Менә шуңа килдем дә мин сезгә, туганнар, акбүреләр. Сез көчле, бай. Бөтен Чулман буенда сезнең кебек көчле ыру юк. Сез кузгалсагыз, башкалары да кузгалачак.

Өлкәннәр Тотышны шулай башсыз дип, явыз дип уйласалар да, үзен ул бер дә алай дип белми иде. Ул яшь иде, көчле, кыю иде. Аның бертуктаусыз каядыр йөгерәсе, чабасы килә, нидер эшлисе, кырасы-ватасы килә. Аның йөрәге беркайчан да тынгы белми шикелле. Шуңа күрә дә ул үзенең көчен, ярсу тойгыларын кая куярга белмичә интегеп бетә. Шуңа күрә дә ул, ачуы килеп, йә үзенең яшьтәшләрен тукмап ташлый, йә булмаса ат атланып чаба, уктан ата, сөңге чөя иде. Инде ул да булмаса, Чулман ярындагы текә кыяларга, биек агач башларына менеп, кош ояларын туздыра, төрле куркыныч уеннар эзләп таба иде.

Куркып-өркеп, кыерсытылып яшәгән ананың улы да баштарак куркып-өркеп үсте. Аннан да бигрәк, ул үзенең «кырнак баласы», «кимчелекле бала» икәнлеген аңлап үсте.

Атасы аңа быел беренче тапкыр ышанып эш йөкләде: кыш көне ул, этләр җигеп, кораллы йөз ир белән, илле йөк товар белән төн кешеләренә сату-алуга барды. Атасы аны юри җибәрде, сынап карау өчен... Аннары ул аның көченә, кыюлыгына да ышанды... Шулай ук аның бу углында баш та юк түгел иде.

Кыш көнендә бер дә кояш чыкмый торган дөм караңгы төн иленнән, боз иленнән Тотыш углан биш ай дигәндә кире кай-

тып төште. Чаналарга таудай тире төяп, бер тиенен, бер кешесен, бер этен дә югалтмыйча, баеп, кырысланып, олыгаеп кайтып төште. Моңа тикле «шар тибүдән» башканы белмәгән «башкисәр», «юлбасар» угланның исән-аман кайтып керүен күреп, бөтен катауның исе китте. Ата белән ананың исә куанычы эченә сыймады. «Булдырдың, углым!— диде аңа атасы. — Синең кебек чакта атай мине дә шулай товар белән җибәргәние. Каты буранга юлыгып, этләрне, йөкләрне югалтып, кешеләрне туздырып, ярты юлдан кире кайттым. Болай булгач, атаңны уздырдың, углым».

Атасыннан мондый мактау сүзләре ишетеп, Тотыш угланның күзләренә яшьләр килде. Туганнан бирле бу аның атасыннан гына түгел анасыннан кала барлык өлкәннәрдән ишеткән беренче мактау сүзе булгандыр. Ата белән угыл арасындагы салкынлык, кырыслык шул көннән соң әйтерсең мәңге юкка чыкты. Шул көннән соң Тотыш углан атасына тәңрегә табынган кебек табына башлады.

Акбүре ыруы болгарларга каршы яу чыгуга каршы килә. Тотыш Ямгырчы би кызы Тәңкә белән таныша. Алар бер-берсен ошата. Егет, кызны алып, катаудан кача. Берничә көннән соң гына әйләнеп кайталар.

ИКЕНЧЕ БАБ

Иртән аны ниндидер дөбердек уятты. Шыбыр тиргә баткан килеш ул сикереп торды, кылычына тотынды, аннары, калтыранып, ишек артындагы дөбердеккә колак сала башлады. Кем булыр бу? Нәрсә кирәк бу вакытта? Кояш әле чыкмаган, әле бик иртә булырга тиеш.

— Кем бар анда? Нәрсә кирәк? — дип кычкырды ул, күпмедер тыңлап, көтеп торганнан соң, ишеккә якынаеп.

— Бу мин, каравыл Чынташ!— диде тыштагы ир кеше.

— Ни булды? Ник дөбердәтәсең? — диде би, ишек биген ычкындырып.

— Улакчы килде, улакчы! — диде Чынташ.— Ашыгыч битек китергән. Менә.

Би каравылчы кулыннан битекне тартып алды да шартлатып ишеген япты, биген яңадан элдерде. Битекне ул ачу белән идәнгә атып ормакчы булды. Каравылчының «ашыгыч» дигән сүзен исенә төшергәч, бу уеннан кире кайтты. Төннек янына килде дә вак-вак пыяла кисәкләре аша үткән таң яктысында

ал тамга сугылган, җеп белән кысып бәйләнгән күн тышлы битекне кулында әйләндергәләп карады. Аннары җепне теше белән өзде, аксыл каен тузына төрек иҗекләре белән язылган түбәндәге сүзләрне укыды:

«Атай! Алмыш хан килә. Төшкә монда булыр. Үзән аша күпер салалар. Көче күп. Мин Чулманга чигенәм. Шуннан кайтырмын.

Алай башы Күзәмеш углан».

Күрән бинең чәчләре үрә торды. Күрән бинең куллары, аяклары калтыранды. Суларга тын җитмәде, уйларга уй җитмәде.

Баштанаяк коралланган, көр-таза атларда нык утырган ул ят кешеләр, ягы кешеләр ашыкмыйча гына, иркен, тыныч кына киләләр иде. Алар күп иде, бик күп иде. Кечерәк төркем-төркем булып, җир астыннан чыккан сыман, сырт итәгеннән менә тордылар, тигез җиргә җәелә тордылар. Бераздан алар богдай чәчелгән җир өстен бөтенләй каплап алдылар. Шул ук мәлдә, тыелгысыз бер көч булып, тигез җиргә җәелеп аккан язгы ташкын булып, катауга таба басып килделәр. Тигез, ачык ялан күз алдында атлар, кешеләр белән тулды. Тигез, ачык күркәм яланда — катаудагы меңләгән күзләр алдында — әйтерсең тиз арада кара урман калкып чыкты, әйтерсең берничек тә үтеп чыгып булмастай тау-таш калкып чыкты!

Юлның ике ягына да тезелгән ир-атлар кинәт кыймылдап куйдылар, як-якка тайпылгандай иттеләр. Юлда, тар аралыкта яхшы акбүз атка атланган бер кеше күренде. Бу кеше, йөзләгән, меңләгән ир-атлар арасында таудай калкып, ерактан ук күзгә ташланып тора иде. Ул бик таза, көчле кеше күренә иде. Башындагы алпагы да, күбәсе дә, калканы да аның көмештән, алтыннан ясалган иде. Озын муенлы, биек, таза атының йөгәне, ияре, өзәңгеләре шулай ук алтын-көмеш белән бизәлгән иде. Күбә өстеннән ул ал төстәге бөркәнчек ябынган иде. Кара сакал-мыегы аның кыска итеп, түгәрәкләп киселгән иде. Аның болай да киң, түгәрәк бите шунлыктан тагын да түгәрәк булып, табактай зур булып күренә иде.

Эре сөякле, бай киемле бу ир-ат Алмыш хан иде.

Яшь, тук көрән атка атланган бер яшь ир байракчылар төркеменнән аерылды да катауга таба чабып китте. Атта чабып барган уңайга ул җәясенә ук утыртты. «Һай» дип бер кычкырды да акбүреләр ягына атып җибәрде. Төз атылган ук Басу-капка янындагы каравыл өенең ишек башына килеп кадалды.

Сакчылардан берсе сикереп укны тартып алды; алды да йөгереп аны Күрән бигә илтеп бирде. Укка каен тузы бәйләнгән, тузга шундый сүзләр язылган иде:

«Мин, Болгар йортның башы Алмыш хан, синең Җиреңә килеп урда кордым. Атам Шелкә үлгәч, син, минем колым Күрән би, өч җыл миңа калан түләмәдең. Шуны алырга килдем. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм, ыруыңны юк итәм. Ил белән бирәсеңме, яу беләнме?»

Нинди күп алар шулай да! Шул тикле ерак җирдән юллар ярып, күперләр салып килгән бу чирүнең, күрәсең, балтачылары да күптер. Үр аша күпер салып, катауның капкасын җимереп, яндырып керү аларга берни тормас. Шулай булгач... катавың белән, ыруың белән бергә кырылуга караганда, сораганын биреп котылу яхшырак булмасмы?

Соңгы көннәрдә бик нык йончыган, тиешенчә йокламау аркасында йөзе агарынып калган би аксакалларга, кораллы ирләргә күтәрелеп карады.

— Нишлибез?— диде ул, карлыккан тавыш белән.

Майчан аксакал сүзләрен башкалар да яклады.

— Түләргә кирәк!

— Алсын да китсен! — диештеләр кешеләр, шау-гөр килеп.

— Юк, түләмибез!— диде шул чакны кемдер, шау-шуны күмеп.

Кешеләр тавыш килгән якка — койма өстенә күтәрелеп карадылар. Сакчылардан, кораллы ирләрдән бер читтәрәк анда баштанаяк коралланган яшь бер углан басып тора иде.

— Тотыш!

— Югалган Тотыш! — диделәр акбүреләр.

— Сөйлә, углан! — диде Майчан аксакал, Тотыш ягына таягын изәп, тынлык урнашкач.

— Сөйлә, сөйлә! — диештеләр башкалар да.

— Атам, анам! Ырудашлар, туганнарым!— диде Тотыш углан, көлгән тавышларга колак салмыйча.— Моңарчы сез минем бер генә теләгемне дә үтәмәдегез. Яшьлегем, белексезлегем аркасында мин сезгә, ыруга күп кайгы салдым. Инде сезгә бер сүзем бар... бер теләгем бар: тыңлагыз! Мин Алмыш ханның иң көчле алыбы белән очрашырга телим. Мин берүзем ыру өчен ягыдан үч алырга телим! Җиңсәм, болгарлар буш кул белән китәр, җиңеләм икән — калан түләрсез!

— Углым! — диде ул, Тотышны кочагына алып.— Бүгеннән башлап син — ир! Әй ырудашлар, ишетәсезме, Тотыш углым минем ир булды! Мин аның теләгенә каршы килмим, мин аңа ак юл телим, җиңү телим. Орыш, углым, ягы белән, күрсәт ирлегеңне!

— Орыш ягы белән!

— Ак юл сиңа, Тотыш углан!— диделәр аксакаллар.

Күрән би, углының теләген белдереп, болгарларга ук атарга кушты.

Болгарлар укны алдылар, битекне укыдылар да ат кешнәгән кебек шаркылдап көләргә тотындылар.

— Ничек көләләр бездән!— диде Тотыш, иреннәрен чәйнәп.

Күп тә үтмәде, болгарлардан икенче ук килеп төште. Каен тузына ике генә сүз язылган иде. Бу «бергә өч» дигән сүзләр иде. Акбүреләрнең йөзе каралай янып чыкты. Бергә өч! Димәк, Тотыш бер-бер артлы өч алыпны җиңәргә тиеш, бары шул чагында гына ул җиңүче булып саналачак!

Яшь егетнең нык кысылган иреннәре калтыранып китте. Шулай да куркуын тиз арада җиңә алды. Су астында озак чумып торганнан соң өскә калкып чыккан кеше сыман, ул озын итеп, күп итеп бер тын алды да:

— Мин орышам!— диде.— Мин сүземнән кайтмыйм.

— Юк!— диде Күрән би, болгарларның битеген урталай ертып.— Бу тигезлек түгел. Бу бернинди йолага да, түрәгә дә туры килми. Алар бездән юри көләләр.

— Мин барыбер орышам, атай,— диде Тотыш, кабатлап.— Мин баш тартсам, алар бездән тагын да ныграк көләчәкләр.

— Бергә өч булуына исең китмәсен, углым,— диде Койтым бикә, аның уйларын сизенгәндәй.— Өчкә түгел, өч унга, өч йөзгә каршы чыгудан да курыкмый торган батыр бул, углым! Синең ерак бабаң Кайду алып шундый батыр булды, синең бик еракта калган ерак туганнарың барысы да шундый булдылар. Анаңның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган җирен басучыдан канлы үч ал, углым! Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!

— Мин курыкмыйм, анам!— диде Тотыш, елмаеп.

— Куркуын курыкмыйсыңдыр да,— диде Күрән би, үртәлеп.— Бу тигезлек түгел. Бу — бездән көлү!

— Син ни телисең, би?!— диде Койтым бикә, иренә эндәшеп.— Ягыдан син кызгану, тигезлек, изгелек көтәсеңмени?! Ул сине таларга, үтерергә, яндырырга килгән, түбәнсенеп, шуңа

үпкәләргә уйлыйсыңмы?! Күтәр башыңны, күзеңне ач, Күрән би!

— Баш та каткан инде,— диде би, мыгырданып.— Әле өч көн бар, ашыкмыйк, уйлашыйк...

— Уйлашыр чак түгел — илне ягы баскан!— диде Койтым бикә, кискен генә.— Углыңны җибәрмәсәң, үзем чыгам Алмыш ханга каршы. Тик, берне үтерсәм, өчкә саналырга тиеш. Җибәр укны Алмыш ягына!

Күрән би авыр башын күтәрде, көрсенеп: «Язмыш... каргыш»,— дип мыгырданды да битекчегә карап алды. «Мин орышам. Тотыш»,— дип язарга кушты.

Койма тышына тагын ук очты.

Тотышка киенергә атасы булышты. Ул аңа үзенең авыр күбәсен, нык, авыр калканын бирергә теләде. Тотыш атасының бернәрсәсен дә алмады. Ул җиңелчә генә киенергә булды. Өстенә ул иң элек юка, җиңел күлмәк, аның өстеннән кыска тунын киде. Муенына нечкә каешка тагылган кечкенә бүре башы — ыру кумарткысын такты. Кыска тунның күкрәк турысына юка тимер кисәкләре тегелгән иде. Аның өс киемендәге тимер бары шул гына иде. Аннары баш киеме — алпагы — тимердән иде. Алпак башыннан төшеп китмәсен өчен, ул ияк астыннан сакалдырыгын бәйләп куйды да кысып билен буды, кылычын такты. Шуннан соң ул бер кулына — калкан, икенче кулына сөңгесен алды.

Ул туп-туры җаваҗга таба карап чапты. Иң элек ул үзе белән орышачак алыпны күрмәкче булды, тик каршыда урмандай калкып торган ир-атлардан башка, аллы-зәңгәрле-сарылы ефәк җаваждан башка бүтән берни күрмәде. Бер җиргә тупланган шул тикле күп кешеләрнең тере, усал, кызыксынучан күз карашларын тою аны чак-чак кына каушаткандай булды. Шулай да бу тиз арада юкка чыкты. Ул анасы Койтым бикәнең өндәү сүзләрен исенә төшерде. Ул әйтерсең кинәт кенә шушы башлар, сөңгеләр, байраклар өстеннән югары күтәрелде; күтәрелде дә аларга — үзләренең җирен таптап, ия булып, күкрәк киереп торган килмешәкләргә корычтай нык, салкын бер күз карашы ташлап алды. Бу мәлдә ул үзен барлык алыплардан, барлык сөңгеләрдән, кылычлардан көчле итеп, бөек итеп тойды.

Шул чакта ул, сөңгеләр, алпаклар, калканнар урманыннан аерылып, үзенә таба якынлашып килгән болгар алыбын күреп

алды. Болгарларның бу иң атаклы батырлары Чәкән алпагыт иде.

Алар шулай икесе бер-берсенә капма-каршы чабып килделәр. Атлар, арт аякларына басып, усал итеп кешнәп җибәрделәр. Чәкән алпагыт, сары тешләрен ыржайтып, җиңел генә, шаярткан кебек кенә сөңгесе белән төртеп алды. Сөңге башы шыгырдатып Тотышның тимер калканын тишеп чыкты. Егет агарынып китте. Тиз генә ул калканын тартып алды, Ташбәкәлнең корсагына төртте дә читкә ташланды. Чәкән алпагытның артына чыгып, ул аны узып китте. Шуннан соң кырт кына борылды, сөңге ыргытмакчы булды, тик каршыда гына болгар алыбының ямьсез, коточкыч йөзен күреп каушап калды.

Өченче кат буш сөңге тотып калган Чәкән алпагыт, ахрысы, кирәгеннән артык кайнарланып ташлады. Ул, ачуына булашып, күрәсең, онытылыбрак китте. Кирәк чакта ул атын борып өлгермәде — аты аны еракка рак алып китте. Ике яктагы кешеләр, әле генә булган очрашу күренешеннән айный алмыйча торганда, Тотыш углан беркемнең башына килмәгән, көтелмәгән бер җегетлек эшләде. Үзенә төбәлгән сөңге башын читкә тайпылдырып, Чәкән алпагытны узып киткәч, ул атын борып тормады: сикереп кинәт иярге басты, артына борылды... борылды да күз ачып йомган арада сөңгесен ераклаша барган җайдакка тондырды. Туры ыргытылган саллы сөңге, тимер киемне, тимер сөякләрне җимереп, киң арканы үтә-сүтә тишеп керде.

Үз көченә, үзенең үлемсезлегенә нык ышанган Чәкән алпагыт сөрлегеп китте, тезгенен тартып, атын кире борды. Тешләрен кысып, соңгы көчен җыеп, ул да сөңгесен ыргытты. Сөңге ерак китә алмады — чыңлап, ыңгырашып, аяк астындагы тузанга барып төште. Атаклы алпагыт, күкрәген тишеп чыккан очлы тимерне кысып тоткан килеш, көчәнеп беравык ияр өстендә утыргандай итте дә барлык авыр киемнәре, кораллары белән гөрселдәп, ишелеп җиргә төште.

Яңа орыш башлаганлыгын белдереп, тагын быргылар кычкырды, тагын дөңгерләр дөпелдәде. Киң җаваҗ артыннан яланга Будрач килеп чыкты.

Будрач сукман — Алмыш ханның Чәкән алпагыттан кала икенче батыры. Чәкән алпагыт үзенең коточкыч көче, кансызлыгы белән, ат өстендә яхшы орышуы белән танылган булса, Будрач сукман икенче яктан атаклы. Ул — чирмеш, урман кешесе, шуңа күрә атта яхшы орыша алмый. Аяк өсте орышка исә аңа беркем каршы тора алмый иде. Тотыш белән Чәкән

алпагытның орышын күзәтеп утырган Алмыш хан яшь җегетнең көчле якларын да, йомшак якларын да тиз арада төшенеп алды. Аның иң зур өстенлеге җиңеллек булса, иң йомшак ягы да шул ук җиңеллек иде. «Җәяүлегә каршы торып карасын әле»,— дип уйлады хан, үзалдына көлемсерәп.

— Мин кылыч белән орышам!— диде Будрач сукман.

Тотыш берни әйтмәде, атыннан сикереп төште дә сөңгесен җиргә кадады, кылычын кыныдан алды. Ташбәкәл, иясе өчен пошынган сыман, кыска гына итеп кешнәп куйды, теләр-теләмәс кенә катау ягына юыртты.

Карар күзгә таш тутырылган капчык сыман авыр күренсә дә, чирмеш батыры да бик җитез, өлгер кыланды — андый җитезлекне, өлгерлекне Тотыш аннан бөтенләй көтмәгән иде. Будрач сукманның кулында кылыч уйнап кына торды. Тотыш, кысрыклауга чыдый алмыйча, әкренләп-әкренләп чигенә барды, Будрач исә, яшь җегеткә тын алырга да ирек бирмичә, шулай кысрыклап килде-килде дә, кинәт кылычын ике куллап тотып, бар көченә орды. Шундый иттереп орды — кылыч астында кеше түгел, таш булса, таш та урталай ярылып чыккан булыр иде! Тотыш ярылмады — җиргә егылды. Карап торучылар «аһ!» иттеләр. Сөенергәме, сөенмәскәме икәнлеген әлегә беркем белмәде. Нык селтәнгән кылычның яртылаш диярлек җиргә батканлыгын, яшь җегетнең үлемгә кыл арасы гына торып калганлыгын күргәч, акбүреләр дә, болгарлар да күкрәк тутырып тын алдылар.

Шулай мачы белән сычкан шикелле куышкан арада, Будрач сукман Тотыш угланның кая, ничек тайпылачагын алдан ук чамалап алды, тагын бер тапкыр — монысында инде соңгы тапкыр!— кизәнергә булды. Читкә киткән җегет исенә килеп өлгергәнче, ул аның артыннан килеп тә басты, кылыч сабын тагын ике куллап тоткан килеш, бар көченә селтәнеп тә җибәрде. Монысында өстән аска түгел, кыйгачлап, уңнан сулга таба селтәде. Чалгы белән печән чапкандагы кебек, ул Тотышны, кай төшеннән генә булса да, урталай кыеп төшермәкче булды. Тотыш углан кайсы якка тайпылса да, ничек кенә егылса да, барыбер аның чалгысына эләгергә тиеш иде.

Тик ул Будрач сукман уйлаганча уңга да, сулга да тайпылмады, туп-туры аның аяк астына ташланды. Үткер кылыч аның баш өстеннән ыжгырып үтте. Алмыш ханның икенче батыры, кылычы артыннан ияреп, баскан урынында әйләнгәндәй итте. Шул ук мәлдә бөтен яланны тутырып, йөрәк ачысы белән:

— А-а-а-а!— дип акырып җибәрде.

Тотыш кулындагы үткер тимер астан, корсак турысыннан сабынача йомшак иткә батып керде, эчәкләрне, бөер-бавырларны кисеп үтеп, күкрәгенә таба шуышты. Сукман кулындагы кылыч, калкан чыңлап җиргә төште. Ак чырайлы, саргылт кашлы чирмеш алып, авызын ачып, ашыгып тын суыра-суыра, баганадай артка ауды.

Берьюлы ике батырыннан колак каккан Алмыш хан, Тотыш угланга тын алырга да ирек бирмичә, өченче кешесен чыгарды. Монысы Корыч-Тимер дип аталган яшь, чибәр алып иде. Ул — Алмыш ханның чыбык очы туганы булган Алып-Тархан бинең сөекле улы. Ул да болгарлар арасында атаклы алыплардан санала. Корыч-Тимер инде күп кенә яуларда булган, орышларда катнашкан, җиңгән, бүләкләр алган. Холкы белән ул — эре, борнай бер җегет. Барс кебек җитез, кансыз бу яшь алып бер дә юктан кызып китә, кирәк икән — шундук үзгәрә дә белә. Үзенең якыннары аны «ике яклы пычак» дип атыйлар. Тотыш углан кебек, ул да җиңелчә генә киенгән.

— Мин дә кылыч белән орышам!— диде ул, ялан уртасына чыккач.

Батырларның кара-каршы килеп басулары булды, быргыларның чинарга тотынулары булды, шундук орыш башланып та китте. Яшен чаткылары чыгарып, тиз арада кылыч йөзләре чәкәшергә тотынды.

Тотыш ярсый башлады. Нинди дә булса яңа нәрсә уйлап табарга аның башы җитмәде — күз алдында ялт-йолт килгән кылыч йөзе торган саен аның эчен пошырды, ачуын китерде. Ул яңадан анасының сүзләрен, Тәңкәне исенә төшерде, тик инде берни дә аңа баштагы өстенлекне, салкын канлылыкны кайтара алмады.

Көтмәгәндә ул нәрсәгәдер абынып китте. Шул чагында Корыч-Тимер, ач бүредәй, аның өстенә ташланды. Аның кылычы Тотыш кулындагы калкан читен уеп төшерде, сул беләкне кисеп керде дә, сөяккә җитеп тәртелеп калды. Тотыш углан чайкалып китте. «Беттем»,—диде ул, үз-үзенә бик тыныч кына, бөтенләй чит кеше турында уйлаган кебек. Булган бар көчен, ярсуын бер учка туплап, ул Корыч-Тимернең ияк астына, муен турысына орды. Болгар алыбы башын иеп өлгерде, бары тимер алпак өсте генә сыдырылып китте дә, киселгән беләктән, киемнәрне чылатып, кайнар кан агарга тотынды. Шул ук мәлдә

яшь җегетнең күңеленә: «Бетәм!» — дигән икенче уй килде. Бар нәрсәне онытып, ул канлы ярасын кысып тотты.

Җирдән алар икесе дә бер үк мәлдә сикереп тордылар. Тордылар да... Тотышның уң кулы буш түгел, яралы кулында корал юк иде.

— Ы-ы-ы! — дип үкерде кара мыеклы чибәр алып, куанычыннан нишләргә белмичә.

Ул инде орган да булыр иде, урталай кискән дә булыр иде. Корыч-Тимернең үкерүеннән дә көчлерәк булып, көтмәгәндә куар оган әйтерсең күкрәп җибәрде.

— Тукта! — дип кычкырды кемдер аның артында гына.

Ирексездән ул туктап калды, артына борылды. Аның каршысында, таудай булып, Алмыш хан калкып тора иде.

— Тукта!— диде хан, кабатлап.— Син җиңдең!

Ялангагы үлекләрне алып китү белән, орыш урынына имчеләр чыкты. Алар яралы Тотыш янына килделәр, аның киселгән беләген карадылар: яраны яхшылап салкын су белән юдылар да киселгән иткә яра ташы кырып салдылар, шуннан соң беләкне ныгытып бәйләп куйдылар. Шул эшләрне башкаргач, төсе качкан, агарынган яшь егетне кабыкка салдылар, күтәреп шулай ук аны да каядыр алып киттеләр.

Ике як арасында кыскача гына сөйләшү булып алды. Күрән би Алмыш ханның катау янындагы яланнан үзе урда корган җиргә — Тәкәшүр болынына кайтып китүен теләде. «Тиешле бурычны дүрт көндә үзем илтеп түләрмен»,— диде. Алмыш хан үз чирүенә шундук кире борылырга боерык бирде. Болгарлар, тузан туздырып, әкрен генә чигенә башладылар.

* * *

Сырт өстендәге юлдан сулга борылып, вак куаклар янына килеп җиткәч тә, Койтым бикәне болгар күзәтчеләре туктаттылар. Унлап ир-ат каяндыр караңгыдан килеп чыктылар да тавыш-тынсыз гына аларның юлларына аркылы төштеләр, төрле яктан уратып алдылар.

— Ым[1]? — диде күзәтчеләрнең алдагысы, сөңгесен югары күтәреп.

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны,— диде бикә, көттеребрәк, битенә капланган бөркәнчеген чак-чак кына ачып. — Мин Алмыш ханга барам.

---

[1] Ым — пароль.

— Үзең генәме?— диде бер күзәтче, күрәсең, алай башы.

— Үзем генә,— диде бикә,— болар — минем сакчыларым.

— Сезне бүген туйга чакырганнарые, шунда барасыңмыни?— диде алай башы.

— Мин болай гына барам. Мин — Койтым бикә. Минем улым Тотыш — хан кулында.

Койтым бикә урынына береккәндәй утырганда, каршыдагы ишек үзе ачылып китте. Чүлмәккә кычкырган сыман калын, көр тавыш белән таныш кеше:

— Кем бар анда? Керсен! — дип кычкырып җибәрде.

Күрән бинең өлкән хатыны, ятактагы кешегә таба бер-ике адым атлады да, йола саклап, башындагы бүреген салды, тезләнде. Алмыш ханның йокламаудан, күп эчүдән бөтенләй йомыла язган күзләренә бер күтәрелеп карады да коры, нык бер тавыш белән:

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны Койтым бикә... — дип сүзгә башлады.

Нәрсәдер исенә төшерергә тырышып та, төшерә алмыйча, кашларын җыергалап, аптырап утырган ханның йөзе кинәт ачылып китте.

— Койтым! — диде ул, урыныннан торып.

— Алайса, син Күрән бидә?— диде ул бераздан, елмаеп, бикәнең күзләренә карап.— Белмәдем, монда мин элегрәк килгән булырыем.

— Ярый әле элегрәк килмәгәнсең,— диде бикә.

— Менә килдем, таптым! Алам!— диде Алмыш хан, эчке бер омтылыш белән.

— Инде соң,— диде бикә, салкын гына.

— Соң түгел!

— Соң!— диде бикә, ачуына ирек биреп.— Синең атаң Шелке минем туган ыруымны туздырды, атамнан-анамнан аерды. Инде менә син килдең минем икенче оямны туздырырга. Син миңа кан-яшь, кайгы алып килдең. Минем икенче туган ыруымны да син кара кайгыга салдың. Шулай булгач, ничек итеп син миңа, соң түгел, дип әйтә аласың?! Моннан унтугыз ел элек мин берни аңламыйдырыем. Инде мин күп нәрсәне аңлыйм. Мин — Күрән бинең хатыны — сиңа үтенеч белән килдем. Тыңлыйсыңмы мине, Алмыш хан?

— Сөйләп кара,— диде хан.

Ул, күрәсең, истәлекләреннән дә, исереклегеннән дә айный башлады. Кисәк кенә ташкын булып калкып чыккан күңел

тойгылары аның шулай ук ташкын булып тиз арада кире чигенде.

— Мин... Тотыш угланның анасы...— диде бикә, калтыранып.

— Тотышның?!

— Әйе. Син аны миңа кайтарып бир. Үлеме, тереме — кайтарып бир. Үтенечем шул.

— Ул миндә тотык булып калачак,— диде хан, кабатлап.— Ике елдан соң ул синең яныңа исән-сау килеш кайтыр. Аның урынына тотык итеп миңа Күрән би үзенең бүтән углын җибәрер. Югыйсә үзеңә тиешле каланны да менә шулай яу белән килеп алырга туры килә. Моннан соң мин дә, каган кебек, үземә буйсынган биләрнең угланнарын тотыкка алачакмын!

ӨЧЕНЧЕ БАБ

Авыр яраланган Тотышка ярдәм күрсәтүчеләрнең, дәвалаучыларның берсе Алмыш хан кызы Аппак була. Юлда алар бер-берсенә гашыйк булалар. Беркөнне Тотыш кача һәм Ямгырчы би янына килеп чыга. Би аны Алмыш ханнан үч алырга ризалата. Сугыш вакытында Ямгырчы бинең Аппакны кулга төшерергә теләве ачыклана. Тотыш, сөйгәнен яклап, бигә каршы көрәшә башлый һәм аны качып китәргә мәҗбүр итә.

Алмыш хан гаскәре белән кайтып җиткәндә, Болгар каласы суварлар тарафыннан таланган, яндырылган була.

Алмыш хан ханбалыкны аркылы-торкылы йөреп чыкты: янган, җимерелгән коймалар буенда булды. Кая гына бармасын, аңа пыскып көйрәп яткан кара күмер, агач өемнәре, үлгән, янган кешеләр көлгә-корымга буялган, шашынып әрле-бирле чабышкан ирләр, хатыннар, балалар очрады.

Шунда аның күз алдына икенче төрле янгыннар килде. Әйе, әле кайчан гына ул үзе талап-яндырып йөрде. Инде менә аның үзен талап-яндырып киттеләр. Менә сиңа Бөек Болгар! Болай булгач, болгарлар түгел — хазарлар, Хазар каганы җиңелмәс булып чыкты. Каган шымчылары күршеләрне туктаусыз котыртып тормасалар, болгарларга каршы туктаусыз корткычлык эшләмәсәләр, Килдеш бинең мондый эшкә йөрәге җитәр идемени? Димәк, тынгысыз кешеләрнең явызлыгыннан котылу өчен, иң элек Хазардан котылырга кирәк. Үзеңне, чыннан да, бай итеп, ирекле итеп тою өчен каган белән ике арадагы җепләрне өзеп ташларга кирәк!

Алмыш ханның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Өченче көнне хан туган-тумачаларын яшерен киңәшкә җыйды.

* * *

Алмыш хан сүзгә башлады:

— Элеккечә ил тотып булмый. Талау, яндыру белән ерак китеп булмый. Көтү көр булсын өчен, терлекләр тынычлап утларга тиеш. Безгә бердәмлек кирәк, иминлек кирәк. Шуларны ничек булдырырга? Без янган ханбалыкны торгызырга тиешбез, без катауны беркемнең теше үтмәслек таш койма белән уратып алырга тиешбез.

— Кулыңда кылыч барында, дошманнардан куркып яшәү — оят! — диештеләр кайберәүләр, шаулаша башлап.

Кашларын җыерып, йодрыкларын йомарлап, Алмыш хан яңадан урыныннан торды.

— Кулдагы кылычка гына да таянып яшәп булмый. Миңа кылычтан да, ук-җәядән дә, сөңгедән дә көчлерәк корал кирәк. Андый корал бар. Ул да булса — гарәпләр йоласы. Болгар тауга үрләргә теләсә, ислам динен тотарга тиеш.

— Әйтеп кара: ничек ирешерсең икән моңа?

— Мин дин белгечләре — муллалар, мәзиннәр сорап туры Багдадка, хәлифәнең үзенә илче җибәрәм[1]. Багдадка илчем итеп мин Тәкин угланны җибәрәм.

ДҮРТЕНЧЕ БАБ

Яңа урында Тотыш өчен хан урдасының читендә аерым өй кордылар. Аның янына, кечерәк өйгә Торымтай урнашты.

Тотыш белән Торымтай барган турыда елга сай иде. Алар су янына якынрак килделәр дә, тирә-яктагы үсмерләргә карамыйча, өсләрен чишенә башладылар.

Шул чакны аның колак төбендә генә:

— Әй, син, килмешәк, кая тыкшынасың?!— дигән сүзләр ишетелеп китте.

Тотыш ялт кына артына борылып карады. Аннан берничә адым читтәрәк бер җегет басып тора иде. Бу теге Тотышны җиңгән Корыч-Тимер алып иде.

— Исеңдәме, син минем аяк астымда аунап яттың? Сине анда хан коткарып калды. Монда беркем коткармас — яхшы чакта үкчәңне күтәр! — диде Корыч-Тимер. Янап, күзләрен

---

[1] Багдад шәһәре — мөселман диненең үзәге, хәлифә барлык мөселманнарның дин башлыгы саналган.

чекрәйтеп, ул Тотышка якын ук килде. Ул аны, күрәсең, суга төртеп җибәрмәкче булды.

Тотыш күңелендә, давыл булып, үч, ярсу, оят — барсы берьюлы калкып чыкты. Масайган Корыч-Тимер исенә килергә дә өлгермәде, Тотыш аның биленнән ике куллап кысып алды да «ә» дигәнче баш аркылы атып бәрде.

— Җәгез, кем тагын килмешәккә каршы килә? — диде Тотыш, усал елмаеп.

Аңа каршы чыгарга беркем дә батырчылык итмәде. Кемдер бары арттан гына таш ыргытты. Тотыш үзенә таш ыргытучыны эзләп тормады — күзенә эләккән беренче угланны тотып алды да аны да баш аркылы җиргә орды. Авызын ачып торган икенче берәүнең яңагына тондырды, өченчесенең корсагына төртеп алды. Ул арада Корыч-Тимер дә аягына басты. Басты да, ярсып, яңадан Тотышка таба килә башлады. Тотыш искәрмәстән аның эченә тибеп җибәрде — Алмыш ханның макталган алыбы гөрс итеп арты белән җиргә барып төште.

— Әй, болгар куркаклары, белегез, бу мин — Тотыш булырмын! — дип кычкырды Акбүре батыры, качып баручыларны мыскыллап.

— Юлбасар! Килмешәк! Сиңа монда барыбер көн булмас! — диделәр яшь этәчләр, куак арасыннан йодрык янап.

Очынып, җиңеләеп, Тотыш суга ташланды, колач салып йөзеп китте. (...)

* * *

Үзләре өенә бер йөз адым чамасы калгач, Торымтай барган җирендә туктап калды.

— Карале! — диде ул, каядыр алга күрсәтеп. Тотыш үз өе ягына карап тора башлады. Өйдән күккә шәбәеп төтен үрләп ята иде. Ул тизрәк өенә ашыкты.

Учак янында кемнедер күреп, ул чак-чак кына артына авып китмәде.

— Аппак ич! — диде кинәт Торымтай кычкырып.— Минем күзем күрмәде, агып яткан су күрде...

Үзалдына сөйләнә-сөйләнә ул каядыр китеп барды.

— Син... Торымтайдан курыкмыйсыңдыр ич? — диде Тотыш кызга. — Әллә Торымтай синнән куркамы?

— Мин — гарәп динендәге кеше, — диде Аппак.— Гарәп дине буенча, ир кеше алдында хатын-кыз битен каплап йөрергә тиеш, ди. Көн дә мулла безне җыя да шундый нәрсәләр

өйрәтә. Аннары гарәпчә укырга-язарга өйрәтә. Кызык түгел. Телләрен дә, язуларын да өйрәнәсем килми. Мин куркам. Мин Тәңредән куркам, ияләрдән куркам. Күңелемнән минем беркайчан да ата-баба йоласыннан баш тартканым юк.

— Ник син кешеләрдән генә түгел, көннән, кояштан куркасың? Мин тотык булган өченме?.. «Килмешәк» булган өченме?

— Юк, юк, Тотыш!— диде Аппак, куркып, аның муеныннан кочып. — Ни сөйлисең?! Ташка язмаганны!..

— Нәрсә, тагын «йола»мыни? — диде Тотыш, мыскыл итеп.

— Әйе, йола, — диде кыз.

— Минем кулларымны, аякларымны богаулап ташлый торган йолаларга төкерәм мин!

— Язык, язык! — диде кыз, дер-дер калтыранып.

Колакларын ике кулы белән томалап, ул ишеккә ташланды.

* * *

(...) Тотышны хан янына чакырдылар. Алмыш хан аңа кымыз бирде, аннары, тыныч булырга тырышып, сүзгә башлады.

— Тотыш углан,— диде,— Кызыл Яр катау янындагы орышта минем алыпларны үтереп, син атаңны-анаңны, ыруыңны якладың. Моның өчен сине яманлап булмый. Анда син хаклы идең. Ләкин тормыш катлаулы. Тормышта... хаклы кеше түгел, көчле кеше хаклырак. Син углан, үзең турында гына, үз катавың турында гына уйлыйсың. Шуннан башка барлык кеше, барлык ырулар — синең өчен дошман. Шуңа күрә дә сез акбүреләр, суарлар, казаяклар бер-берегез белән сугышып-ызгышып яши бирәсез. Таркаулыктан миңа да, сезгә дә файда юк. Шуны аңласаң, син мине дә аңларсың, минем игым түгел, минем якчым булырсың. Син инде уйлыйсыңдыр: ни өчен Акбүре Алмыш ханга буйсынып яшәргә тиеш дип. Акбүре ирекле булырга тиеш дип. Сезнең уч төбедәй ирегегез ахыр чиктә сезнең өчен ирексезлек булып кайта. Минем кул астындагы ирек сезне талаудан, кыраннан, кан-яшьтән коткарачак. Син, Тотыш углан, менә шулар турында уйлап кара. Мин сиңа ат бирергә, үзеңнең коралларыңны кайтарырга боердым, Тотыш углан. Минем көтүдән үзең теләгән атны сайлап алырсың.

— Бай бул, Тәңре сиңа күп яшь бирсен, ханым! — диде куанычыннан нишләргә белмәгән җегет.

* * *

Юл буена Тотыш уйланып кайтты. Моңарчы ул бары үзе турында гына, үзенең язмышы турында гына уйланса, бүген ул башкалар турында уйланды. Чынлап торып уйлап карасаң, ник кирәк бу яулар-сугышлар? Акбүрене болгарлар килеп басты, болгарларны — суарлар. Алмыш хан белеп сөйли, үзара сугышлар булмасын өчен, чыннан да, бер йодрыкка тупланырга кирәк түгелме соң?!

Көне буена ул үзендә бер куанычлы җиңеллек тойды. Ул арада кояш та баеды. Ышкыйсы, тазартасы, төзәтәсе эшләре беткәч, Тотыш бушанып калгандай булды. Өенә керде дә, тезләрен кочаклап, кызу учак каршысына утырды. Тиздән йокларга ятты. Күзен йомып та өлгермәде, ишек тарткан тавышка ул сикереп урыныннан торды.

Ишекне ачып җибәргән иде... тимерле киемнәрен чылтыратып, нindидер кораллы ир атылып килеп керде.

— Сиңа ни кирәк? — диде Тотыш, каушавын яшерергә тырышып.

— Син кирәк! — диде Аппак, көлә-көлә.— Кичер мине, Тотыш. Киен, әйдә, киттек.

— Кая?

— Кая булса да! Җәйге төн шундый матур! Коралларыңны ал, Тимеркүккә атлан,— диде кыз.

Бераздан алар, атларын әкрен генә атлатып, сөңгеләрен югары тотып, караңгылыкка кереп юк булдылар.

* * *

Бүген алар яктыра башлаганны сизмичәрәк калдылар. Таллык бетеп, тәбәнәк калкулыктан менеп килгәндә, алда, якякта нindидер атлылар күренде. Тотыш каршысына беренче булып килеп җиткән кораллы ир, битлеген күтәрмичә:

— Ым?— дип кычкырды.

Тотыш аны тавышыннан танып алды. Каушау, аптырау кыргый бер ярсу белән алышынды.

Корыч-Тимер битлеген ачып җибәрде. Тотышка туры карап, шаркылдап көләргә тотынды:

— Барыгыз, бар, ник тукталдыгыз?

— Тотыш... беттек! — диде Аппак пышылдап, алга узып.

Корыч-Тимер, җирне-күкне калтыратып:

— Уйнаш! — дип кычкырып җибәрде. — Тотыш — Аппак — уйнаш! — Атын борып, ул урда ягына чапты.

* * *

Болгар йоласы буенча, кояш баеганнан алып кояш чыкканчыга тикле чит ир белән чит хатын-кыз бергә очрашса, уйнаш санала иде. Уйнаш өчен ирне дә, хатынны да — кем булуларына карамастан! — аяк-кулларын чабып, тураклап үтерәләр иде. Корыч-Тимер аларны үзенең әшнәләре белән ике көн күзәтеп йөрде.

Аппак Тотышка барысын да сөйләп, аңлатып бирде. Җегетнең йөзен кайгы-сагыш билән алды. Менә ни өчен Аппак бары төнлә генә килгән икән аның янына! Хан кызы тотык белән бернинди бәйләнешкә кермәскә тиешләр. Ах, менә нинди кеше икән ул тотык!

— Тизрәк, тизрәк! — диде Аппак, Тотышны ашыктырып. — Мин әле ышанам. Ничек тә этине алданрак күрергә кирәк.

Алар ашыктылар. Үлемгә ашыгалар идеме алар, ирекәме — беркем дә белмәде.

* * *

Аппакның Тотыш белән бергәләп керергә теләген ишеткәч, Алмыш хан, аңлап җиткермәгәндәй:

— Минем каршыгамы? — диде.

— Әйе, ханым,— диде хан-агасы. — Анда тагын Алып-Тархан углы Корыч-Тимер алып та килгән. Никтер кызган, бик ашыгыч, ди.

— Корыч-Тимер сүреләп төшсен. Әйт, керсен кызым,— диде хан.

Алар икәүләп керделәр.

— Эти! — диде Аппак, ялвару белән.— Без сиңа зур йомыш белән кердек. Эти! Мин Тотышны яратам, Тотыш... мине... Без өйләнешергә булдык — ирек бир безгә!

— Син, кызым, үзеңнең кем икәнлегеңне онытып җибәргәнсең, ахрысы,— диде хан.

— Юк, эти,— диде Аппак, тынгысыз бер кабалану белән.— Тотыш мине үлемнән коткарды! Мине саклап унлап казаякны үтерде.

— Тотыш — Алмыш ханның тотыгы,— диде хан.— Мин кызымны тотыкка да, колга да, йолкышка да бирә алмыйм. Сау булыгыз, угланнар.

— Бар ышанычым синдә, эти! Безне бергә күрделәр. Корыч-Тимер... Тозак... Кызган мине, эти!

Алмыш ханның йөзен кара болыт каплап алды. Шул чакны кара болыт арасыннан якты кояш балкып чыкты.

— Тыңлагыз, сүзем шул,— диде ул, авыр гына сүзгә башлап,— Тотыш үзе, ата-анасы, ыруы гарәп диненә күчсә... тиешле калымын түләгәч... ике елдан соң өйләнешерсез. Ак юл сезгә, балалар.

БИШЕНЧЕ БАБ

Ике ел искән җилдәй үтте дә китте. Тотыш өчен бу ике ел бөтен бер тормыш булды. Алмыш хан аңа зур эшләр тапшырды. Тотыш углан ике мең кешелек чирү белән көтмәгәндә суарларны барып басты. Килдеш бинең үзен кулга төшерде. Башкортлардан ике ел түләнмәгән каланны көч белән алып кайткач, йорт башы аны мукшыларга каршы җибәрде...

Ни булса да булды, ике ел узып китте. Алмыш хан аны бүген үз янына чакырып алды.

— Син ирекле, Тотыш углан,— диде ул.— Иленә кайт, мин әйткәннәрне үтә, калым китер. Шунда киявем булырсың... Алла боерса...

* * *

Тотыш, бүләкләр алып, туган ягына кайтып китәргә җыенып йөргән арада, Ага-базарга уникe каек белән акбүреләр килеп төште. Акбүре каекларына Тотыш үзенең бүләкләрен, кием-салымнарын төятте. Шунда аны Алмыш ханның йомышчысы эзләп тапты. Хан янында ниндидер ят, чит кунаклар бар иде. Зур кунакларның берсе Башту углы Габдулла иде. Шушы көннәрдә генә ул түбәннән, Хазар йортының ханбалыгы Итил-Торадан килеп төшкән иде. Габдулланың әйтүенә караганда, Корыч-Тимер хазарларга барып чыккан. Корыч-Тимер Итил-Торага килеп җиткәндә, Тәкин углан әле Хазаранда булган. Шунда кышлап, ул быел яз Багдадка юл тотарга уйлаган. Корыч-Тимер боларны күргән дә каган кешеләренә җиткергән: Тәкин углан сатучы түгел, Алмыш ханның хәлифәгә җибәрелгән яшерен илчесе, дигән. Каган кешеләре Тәкин угланны, Барыс угланны, аларның кешеләрен тотып алганнар.

Менә шуңа да күңелсез иде хан Тотыш белән саубуллашканда.

* * *

Имгәк аяк астында, дип белми әйтмәгәннәрдер, күрәсең,— Күрән би үзенең үлемен аяк астында тапты. Манара башыннан төшеп килгәндә, аның аяк астындагы басма сынып китте. Авыр, авыру би «әх» дигәнче баштүбән аска мәтәлде.

Бине күмгәндә ырудашлары чын күңелдән җыладылар. Күрән би үлгәч, аның туганы, ыруда иң атаклы кешеләрдән саналган Утташ кам, йола буенча, ыру башы булып калган иде.

Кайгы туе төштән соң башланды. Ашау-эчүнең, уен-көлкенең кызган чагында Койтым бикә, арып-алҗып, үз өенә кереп китте. Бусага янында аның каршысына кинәт бер кеше килеп басты.

— Бикәгә минем бер сүзем бар,— диде ул, телен көчкә әйләндереп.— Аулакта гына.

«Кем соң әле бу?»— дип уйлады Койтым бикә, тиз генә таный алмыйча. Туктале, Талут ич бу! Тотыш чыбыркы белән сугып күзен чыгарган Талут.

Талут, өйгә керү белән, бикә алдында тезләнде, сыңар күзеннән яшьләр коеп җыларга кереште.

— Бикә, кичер мине. Тәңре каршында языклы мин. Иреңне... Күрән бине... мин үтердем, бикә,— диде.

— Ни өчен?!— диде бикә, пышылдап.

— Тотыш минем күземне чыгарды бер дә юкка. Күңелдә улыңа, сиңа, бикә, ачу саклап йөрдем. Шунда мине Утташ кам котыртты. Баскычның бер басмасын алыштырып куярга ул әйтте. Тагын шул: Утташ кам... ни... миңа Тотышны да... Мин баш тарттым.

— Мин сине тулысынча кичерәм, Талут!— диде бикә, дулкынланып.— Тулысын сөйләвең өчен мин генә түгел, Тәңре дә ярлыкар сине, Талут.

Бикәнең авыр кайгыдан бастырылып ойый, тына барган йөрәге оясыннан атылып чыккан кош кебек ыргылып куйды. Аңа кичекмәстән берәрсен күрергә, сөйләшергә, ни дә булса эшләргә кирәк иде. Юкса ул соңга калачак! Кем белән сөйләшергә? Котан, Акбога... Аның үги угыллары.

Исерешеп беткән, баш-аяк килгән кешеләр арасында Котанны ул бик тиз тапты. Үзе артыннан барырга кушты.

Койтым бикә елмайды, учактагы утка яны беләнрәк торган Котанның күзләренә туры карады да:

— Мин сиңа ошыйммы, углым. Ошасам, шул: синнән башка мин беркемгә кияүгә чыкмаячакмын!— диде.— Тик син

шуны аңларга тиешсең: мин өлкән хатын гына булмаячакмын. Ыру башы булачакмын! Шуңа килешсәң, иртәгәдән мин — синең хатының!

Котан үзенең зур, көчле кулына бикәнең ак кулын алып кысты да, чын күңелдән соклану белән:

— Синнән дә башлырак, кыюрак кеше калмады ыруда, анам! Тулысынча мин сиңа буйсынам. Ант! — диде.

Шул чакны кемнеңдер бәрелә-сугыла өйалдына килеп кергәне ишетелде.

Койтым бикә ишекне ачып җибәргән иде, каршысында Утташ кам урынына Тотышны күреп, артына авып китә язды.

— Углым, Тотыш!— диде ул, кочагын җәеп.

* * *

Җыен үзенең соңгы сүзен әйтте: ыру башы Күрән бине үтергән өчен, Утташ камны Тәңре катына озаттылар. Талутны Койтым бикә җыенда яклап калды. Койтым бикә җиңеп чыкты. Җыен аны ыру башы итеп куйды. Билекне[1] ыру башы үзенең углы Тотышка бирде.

Берничә көннән Тотыш анасына үзенең эч серләрен ачты. Койтым бикә, елмаеп, углына озак кына карап утырды.

Аның улы Тотыш Тәңкәсен оныткан. Ул әнә хан кызын ярата! Нәрсә бу: язмыш шуклыгымы әллә соң Болгар ханының бик еракка ташлаган җәтмәсеме? Ун мең тиен калым түләргә, бөтен ыруың белән гарәп диненә күчәргә... Бу аз түгел. Хан кызы Аппакка торырлык бүләк бу. Ханның, чыннан да, үз уйлары бардыр. Акбүрене үз кулына алса, бөтен Чулман буе аныкы булачак. Биарны төн ягыннан диңгездән килгән явыз юлбасарлар талаган. Биар тузган, юкка чыккан.

Алмыш ханга... аның белән туганлашуга? Була торган эшме бу? Барысы өчен ул аңардан үч алырга тиеш түгелмени?

Ул монда, Акбүредә, бикә булып, баш булып яши. Шулай булгач, ул инде үзеннән бигрәк ил-көн турында, аның бүгенгесе, иртәгәсе турында кайгыртырга тиеш түгелмени?

Акбүре яшәргә тиеш. Алмыш хан белән туганлашу ул — мәңге иминлек дигән сүз. Акбүре җирендә беркайчан да олы яу, сугыш булмаячак дигән сүз.

— Мин, углым, синең бер генә теләгеңә дә каршы килмәячәкмен,— диде бикә, озак кына сүзсез утырганнан соң.— Син

[1]Билек — би дәрәҗәсе.

инде үзең би. Үз башың белән уйлап кара: бүгеннән тотып без ата-баба йоласыннан баш тартсак, ыру безгә ни әйтер? Кулдан тотарлар да артка тибәрләр.

— Нишләргә соң, алайса?— диде Тотыш, караңгы чырай белән.

— Ашыкмаска кирәк, углым,— диде ана кеше.— Көтәргә, ыруны тулысынча үз кулыбызга алырга. Ике айдан түгел, дүрт-биш айдан...

* * *

Бераздан Тотыш һәм аның якыннары, тиешле калымны түләп, Алмыш хан кызы Аппакны алып кайту максатында юлга чыгалар. Аларны Ямгырчы би тотып ала. Тотыш Тәңкәгә Аппакны яратуын әйтә. Егетне зинданга ташлыйлар. Соңрак кыз аны азат итә.

АЛТЫНЧЫ БАБ

Тотыш Алмыш ханга килеп җиткәндә, Аппакны Хазар ханы гаскәр белән килеп алып киткән була. Кайгыдан үзен белештермәс хәлдә, Тотыш Алмыш хан белән ачуланыша һәм, Аппакны эзләп, ерак юлга чыга.

СОҢГЫ БАБ

Шуран катауда ике кич кунганнан соң, акбүреләр Болгар-торага юл тоттылар.

Ямгырчы бигә ханның кичекмичә бөтен ыруы белән Өчкүл янына килеп җитәргә дигән боерыгын тапшырдылар.

— Ни булды?— диде би, сагая калып.

— Болгарга җырактан, Багдадтан илчеләр килә! — диде, тартык күтәренкелек белән. — Барлык мөселманнарның башы Әл-Моктадир Алмыш ханга үзенең ышанычлы кешеләрен җибәргән. Ханга буйсынган барлык ил-көн, барлык ырулар, ислам диненә күчкәнлекләрен танып, хәлифә илчесе алдында ант бирәчәкләр. Кем дә кем каршы килә, аларга хәлифәнең каргышы төшәчәк. Алар Алла колы Алмыш ханның үткер кылычын татыячаклар. Ханның боерыгы шундый.

Ямгырчы би карышып тормады. Ул үзенең бөтен ыруына Чулман аръягына чыгарга, Өчкүл ягына юнәлергә боерды. Казаяк ыруы тиз арада аякка басты. Булган барлык каекларга, көймәләргә утырып, кешеләр Болгар ягына агылдылар.

Алмыш хан урдасына, Өчкүл янындагы болыннарга башка яклардан да, төркем-төркем булып, кешеләр килделәр. Оя-оя

булып өйләр корылды. Барлык болыннарны, басу-кырларны, урман буйларын, аланнарны атлар, кешеләр каплап алды. Кеше күплектән атлап йөрер урын да калмады.

Дүрт көн, дүрт төн буена кешеләр шулай килә тордылар, бер тирәгә җыела тордылар. Якын-тирәдәге барлык ырулар, ыру башлары, биләр, тарханнар җыелып беткәч, кояшлы бер иртәдә кешеләр Өчкүл янындагы иң зур бер болынны бал кортыдай сарып алдылар.

Менә кешеләрне тын калырга өндәп, быргылар кычкырды. Чит илдән килгән илчеләр хәлифә җибәргән ике кара байракны югары күтәрделәр, Алмыш ханның өстенә — кара чапан, башына ак чалма кидерделәр. Хәлифә илчесе Сүсән әр-Рассиенең битекчесе Әхмәт ибн Фадлан — озын борынлы, җирән сакал-мыеклы таза гына бер гарәп җиң очыннан бөтәрләнгән битекне алды да укырга җыенды. Шунда ул үзе янында торган Башту углы Габдуллага үз телендә нидер әйтте, Габдулла Алмыш ханга борылды, аңа битекченең сүзләрен җиткерде. Әхмәт ибн Фадлан: хәлифәнең битеген укыганда аяк өсте басып тыңларга кирәк, дигән икән. Берничә ел эчендә картаеп, юанаеп калган Алмыш хан аягүрә басты. Аннан күрмәкче башкалар да аякларына бастылар.

Алмыш хан үзенең атына атланды, уртадагы түгәрәк ачыклыкны бер әйләнеп чыкты. Ул үзенә буйсынган кешеләргә — ирләргә, хатыннарга, бала-чагаларга карап алды. Аларның башы өстеннән ул еракка — Итил буе киңлекләренә, Чулман буйларына, Урал итәкләренә, Җаек далаларына күңеленнән күз йөртеп чыкты. Күз алдына килгән шул биләмәләрен, җирсуларын бергә туплаган сыман, ул зур авыр йодрыгын йомарлады да кулын күтәрде.

— Болгарлар! Болгар җиренең барлык иле-көне, ырулары! — дип кычкырды Алмыш хан, көчле, күтәренке бер тавыш белән.— Моңарчы таркау булган, бер-берсе белән ызгышып, берберсенең канын коеп яшәгән... миңа калым түләгән ил-көн бүген бер байрак астына берләште. Моннан соң безнең барыбызның да Тәңребез бер генә. Ул да булса — Алла! Алладан бөек беркем юк. Барлык каралар, аксөякләр — Алланың коллары. Аллага табынган, аны бер дип белгән барлык мөселманнар — тигез!.. Шушы язгы кояшлы көндә, барлык үләннәр, агачлар... барлык тереклек иясе куанып башларын калкытканда, бөек Итил, Чулман җирендә безнең изге йортыбыз — Болгар йорт та яңадан туды! Болгар, яшь булса да, өлкән алыплар

тезмәсенә басты. Безне изге хәлифә үзе таный, безгә үзенең изге теләкләрен юллый. Бүгеннән башлап мин, Алмыш хан, Болгар йортының башы, үземнең Хазар каганына бәйсез икәнлегемне белдерәм. Бүгеннән башлап Болгар йорт җирдә үзенә ирек даулаячак, үз көнен үзе күрәчәк, үз язмышын үзе сайлаячак. Күктә кояш сүнми торып, Болгар йорт сүнмәячәк. Итил суы корымый торып, Болгар йортының тамыры корымаячак!

Шулай итеп, Алмыш хан теләгенә иреште: Багдадтан биш мең кеше белән илчеләр килде, изге хәлифә аны үз канаты астына алды. Моннан соң инде ул барлык эшендә аңа таяначак. Моннан соң инде аның теләсә нинди яуларга, давылларга каршы калканы булачак.

Шундый көннәрнең берсендә Алмыш хан янына Койтым бикәнең керергә теләвен белдерәләр. Алмыш ханның йөрәге кузгалып куйды. Койтым бикә... Тотыш... Алар турында ул беркайчан да тыныч кына уйлый алмады.

* * *

— Алайса, тыңла,— диде ул аңа, йомшарып.

Ул үзе бер сүз дә әйтмәде. Койтым бикәгә барсын да Габдулла сөйләде. Үзе белгән, үзе ишеткәннең барысын да төкмичәчми сөйләп бирде.

Габдулланың белгәне-ишеткәне исә шул иде: теге истәлекле көнне көймәгә утырып киткәннән соң Тотыш та, Әмин дә кире кайтмаганнар. Шул төнне ханбалыкта, дүрткел койма эчендә ут чыккан. Койма эченә, имеш, ниндидер угрылар үтеп кергәннәр. Алар анда нәрсә урламакчы булганнардыр — беркем берни белми икән.

Утны да, имеш, шулар төрткәннәр. Угрылар белән сугышканда әллә биш-алты, әллә унлап-унбишләп сакчы үтерелгән. Угрыларны сакчыларга булышка килгән кораллы ирләр генә җиңә алган. Кайберәүләр әйтә, имеш, аларны шунда үтергәннәр, ди, икенче берәүләр әйтә: үтермәгәннәр, тотып алганнар, ди. Өченчеләре әйтә, имеш, ул угрылар качып котылганнар икән, ди. Телдән телгә сөйләнелгән ул «угрылар»ның Тотыш белән Әмин булуына аз гына да шикләнмәсә дә, Габдулла шулай да аларның язмышы турында башка берни дә белә алмады. Итилторадагы иң ышанычлы кешеләр дә ачык кына итеп берни дә әйтә алмадылар. Бары Аппак турындагы сүзләр генә бернинди имеш-мимешкә урын калдырмый иде. Каган хатыны

булуына бер ай булды дигәндә Аппак сагыштан корып-кибеп үлгән. Бу турыда каган кешеләре үзләре әйткәннәр.

Алмыш хан, мондый сүзләрне ишеткәч, Койтым бикә аңын җуяр, егылыр, я булмаса тилереп, чәчен-башын тырнап җыларга тотыныр дип уйлаган иде. Кайгы күреп йөрәге ташка әйләнгән ананың, ичмасам, ыңгырашкан тавышы да ишетелмәде, күзләренә бер бөртек яшь тә килмәде. Аның болай да нык кысылган иреннәре генә кысыла төште дә, авыз читләрендәге, күз төпләрендәге җыерчыклары гына кызганыч булып тартышып-тартышып алды.

Габдуллага хан чыгарга кушты. Койтым бикә белән генә калгач, ул, авыр көрсенеп:

— Язмыш...— дип куйды.— Язмыштан узмыш юк. Син — улыңны, мин кызымны югалттым.

— Әйе, язмыштан узмыш юк, ханым,— диде Койтым бикә, каядыр читкә, еракка карап.— Син минем туган ыруымны тармар иттең, иремне үтерттең... ата-баба йоласын аяк астына салып таптадың. Барысы өчен сиңа Тәңренең авыр каргышы төшкән, Алмыш хан... көч, байлык иясе... хәлифә ялчысы!

* * *

Кызыл Ярга кайтканда, Койтым бикә тагын Шуран катаугa туктады.

Ямгырчы би белән аның арасында зур гына сөйләшү булды. Койтым бикә Тотыштан туган Күкене үзенә биреп җибәрүне сорады. Тотыш инде юк, диде, аның кайдалыгын беркем белми, диде. Күке минем бердәнбер юанычым, диде. Ямгырчы би ике арада мондый сөйләшү буласын, күрәсең, алдан ук көтеп торган иде.

— Күкенең анасы бар,— диде ул.— Мин дә, син дә — яңа йоладагы кешеләр. Ислам дине яшь баланы ата-анадан аерырга кушмый. Күке сиңа юаныч булган кебек, анасына да юаныч. Кая куярмын мин аның баласыз анасын?

— Чакырт кызыңны,— диде Койтым бикә.

Тотышның инде бөтенләйгә, мәңгегә юкка чыгуын белгәч, Тәңкә тынычланып калгандай булды. Койтым бикә, киленен кызганып, аңа улының кайда, ничек югалуын әйтмәде. Ул аңа: Тотыш Итил аръягында юлбасарлар белән сугышта үлгән, ахрысы, дип ялганлады.

— Нишлисең, бирәсеңме балаңны? — диде ата кеше үзенең кызына.

— Мин углымны беркемгә бирмим,— диде Тәңкә, каны качкан иреннәрен чәйнәп.— Анам каршы килмәсә, мин аның белән китәрием... углымны алып.

— Мин синнән шуны гына көттем дә, кызым! — диде Койтым бикә елмаеп, Тәңкәне кочагына алып.— Берегез дә артык түгел, икегезне дә алып китәм. Икегез дә балаларым булырсыз.

— Минем тагын бер кешем бар,— диде Тәңкә, оялчан гына. Аның бит очларына көчсез генә кызыллык йөгерде.— Торымтайны да... каршы килмәссеңме, анам?

— Торымтай? — диде Койтым бикә, аңлап җитмичә.— Ә-ә, Торымтай! Аңа да каршылыгым юк. Тагын кемнәрең бар — әйдәгез барыгыз да. Кайгылы ана күңеле өч кешене түгел, йөз кешене, мең кешене сыйдыра ала! Баласын югалткан ана өчен барлык үксезләр — бала! Күкем минем... Куаныч-Бога, атла алдан. Барлык йортым — сиңа, җирем-суым — сиңа... бар байлыгым, көчем — сиңа. Атла, углым... Күке балам!

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрнең жанр үзенчәлеген билгеләгез.

2. Роман нинди сюжет сызыкларыннан тора? Алар үзара ничек тоташа? Шул турыда сөйләгез.

3. Төп конфликтларны, аларның характерларын билгеләгез. Әлеге каршылыкларда чагылыш тапкан проблемаларны ачыклагыз.

4. Тотышка характеристика бирегез.

5. Койтым бикәгә хас сыйфатларны күрсәтегез.

6. Алмыш ханны тарихи шәхес буларак бәяләгез.

7. Романның бүгенге көн белән аваздашлыгы турында фикер алышыгыз.

8. Әсәр исеменә салынган мәгънәләрне билгеләгез. Шуларга таянып, романның төп идеясе турында нәтиҗә ясагыз.

«Итил суы ака торур» романы

Татар халкының күпгасырлык бай тарихы бар. Әмма анда чәчәк ату чорларына караганда фаҗигале еллар өстенлек итә. Явыз Иван тарафыннан Казан ханлыгы басып алынгач, халкыбызның үткәнен, тарихын оныттыру яисә аны түбәнәйтеп күрсәтү өчен күп көч куела. Бу аңлашыла да, чөнки үткәне юкның киләчәге юк. XX гасыр башы һәм 20—30 нчы елларда әдәбиятта тарихыбыз турында дөреслекне халыкка җиткерү омтылышлары ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 ел карары белән чикләнә. Дөресрәге, татар тарихын фәнни яктан түгел, әдәбият-

сәнгатьтә сурәтләүгә дә билгеле бер дәрәҗәдә киртә куела. Мондый шартларда тарихның берьяклы гына яктыртылуын аңлау кыен түгел. «Төрки халыклар тарихын башлыча төрки булмаган галимнәр язган һәм яза. Безгә карата булган дошманлык тойгысы аларның канына сеңгән. Әле дә булса алар безнең ата-бабаларыбызның батырлыгын, бөеклеген оныта алмыйлар һәм бүген — без инде бик нык түбәнәйтелгән, артта калырга мәҗбүр ителгән бер вакытта безнең хәзерге халәтне ата-бабалар чорына күчереп, тумыштан ук безне бернинди иҗатка сәләтсез кыргыйлар итеп күрсәтергә тырышалар»,— дип яза Н. Фәттах. Әлеге хаксызлыкны кире кагу өчен, әдип археологик экспедицияләрдә катнаша, ә инде 60 нчы еллардан башлап, тарихи жанрдагы әсәрләр иҗат итә башлый. «Итил суы ака торур» романы, бер яктан, торгынлык шартларында халкыбыз турындагы хакыйкатьне ачуы белән игътибарга лаек булса, икенче яктан, роман сәнгатьчә уңышлы эшләнеше, олы характерларга, эмоциональ бизәкләргә бай булуы белән үзенчәлекле.

Әсәргә нигез итеп Н. Фәттах X гасыр башында (922 елда) Багдадтан Идел буе болгарларына килгән илчелек вәкиле Ибн Фадланның юлъязмаларын файдалана. Болгар чорының берничә елын, анда бердәм дәүләт оешуын, рәсми рәвештә яңа дин — ислам динен кабул итү фактын үзәккә куеп тасвирлый.

Роман үзара тыгыз бәйләнгән ике сюжет сызыгыннан тора. Берсе Болгар дәүләте оешу, аның ислам динен кабул итүенә бәйле күренешләрне үз эченә алса, икенчесе Тотыш язмышына бәйле вакыйгаларда ачыла. Әлеге сюжет сызыклары тагы аралашып бара, чөнки төп геройлар булган Тотыш һәм Алмыш ханның үзара мөнәсәбәтләрен, каршылыкларын күрсәтүгә киң урын бирелә. Ә инде Тотышның хан кызы Аппакка мәхәббәтен сурәтләү вакыйгаларны тагын да тармакландырып җибәрә.

Романдагы вакыйга-күренешләрне Тотыш образы бәйләп тора. Ул — тирән кичерешләргә бай, гаҗәеп кыю, батыр, көчле, оста, үзсүзле һәм горур егет. Әлеге геройга бәйле әсәрнең романтик рухы ачык сиземләнә. Ул вакыт-вакыт утта янмый, суда батмый торган әкият геройларын хәтерләтә. Ә инде мәхәббәт маҗаралары моны тагы да үстерә. Тотышның сокланырлык сыйфатлары, эш-гамәлләре никадәр генә күп булмасын, аны бәхетсез иткән, хәтта үлеменә китергән бер үзенчәлеге бар. Ул — сабырсызлык, дуамаллык. Тотышның Алмыш хан белән каршылыгы да, нигездә, шуңа барып тоташа. Егетнең бу сыйфатына капма-каршы буларак, әдип күп тапкырлар өлкәннәргә,

шул ук Алмыш ханга хас сабырлыкны, акыл белән уйлап эш итүне сурәтли. Тотышның соңгы эш-гамәлен ул мондый әдәби деталь белән тасвирлый: «Ут күбәләге утсыз торалмаган кебек, ул да ут-ялкынга карап китте».

Алмыш хан — тарихи шәхес. Ул тарихка Болгар дәүләтенә нигез салучы булып кереп калды. Әсәрдә тулы канлы, каршылыклы характер буларак ачыла. Акыллы, сабыр холыклы Алмыш хан — үз чоры өчен билгеле бер социаль катлау вәкиле. Ул гади халыкка түбәнсетеп карый, эш-гамәлләрендә дә еш кына шәхси мәнфәгатьләре өстенлек итеп, дәүләт эшенә комачаулый.

Әсәрдәге Койтым бикә, Күрән би, Утташ кам, Ямгырчы би, Тәңкә, Аппак, Бәкәч чичән, Торымтай образлары да үзләренә хас сыйфатлар белән бирелә һәм каршылыкларны төрле яклап ачарга, чор күренешләрен, төрле гореф-гадәтләрне, йолаларны тулырак аңларга ярдәм итә.

Борынгы халык җырының беренче юлы булган әсәр исеме романның эчтәлеге, төп идеясе белән тыгыз бәйләнгән. Гомумән, Н. Фәттах Итил образын сурәтләүгә шактый киң урын бирә, еш кына ул вакыйга-күренешләргә метафора булып та килә. Аның түбәндәге мәгънәләре игътибарга лаек: бердән, Итил, ваграк елга-инешләрне үзенә җыйган елга буларак, бердәм дәүләт символы булып килә; икенчедән, сулар агып, гасырлар үтсә дә, кешенең, халыкның ирекка, азатлыкка омтылышы, бәхеткә хокукы кала бирә; өченчедән, Итил суы агып торган кебек еллар, заманнар үтә, безнең күз алдыбызда булган вакыйгалар да тарихта кала; дүртенчедән, табигать күренешләреннән (шул ук Итилдән) аермалы буларак, кеше гомере шактый кыска, шуңа күрә аны максатчан һәм мәгънәле итеп үткәрергә кирәк; бишенчедән, Итил — борынгы бабаларыбыз яшәгән җир, ул туган ил образын да гәүдәләндерә; алтынчыдан, Итил елгасының агуы, табигать күренеше буларак, геройның күңел дөньясын, рухи халәтен билгеләргә, аңларга ярдәм итә; җиденчедән, беренче эпиграфка бәйле, Итил борынгы тарихыбызга символ булып, ул акканда тарихыбыз, халкыбыз яшәячәген аңлата.



Мөсәгыйт Хәбибуллин
(1927 елда туган)

Үз иҗатында кызыклы эволюция кичергән һәм хәзер татар прозасының әйдәп баручы затларыннан берсенә әверелгән Мөсәгыйт Мөдәррис улы Хәбибуллин 1927 елның 25 декабрендә Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылында туа. Туган ягында башлангыч белем алганнан соң, Татарстанның Баулы районына күчеп килеп, анда җидееллык мәктәптә укый. Бөек Ватан сугышы башлангач, ул колхозда эшли. 1944 елда Чиләбе өлкәсенә китә, анда һөнәр мәктәбен тәмамлап, 1946—1953 елларда Магнитогорск, аннары Башкортстандагы Октябрьский шәһәрендә эшли. 1953 елда туган авылына әйләнеп кайтып, анда инженер-механик вазифасын башкара. 1958 елда Баулы эшчеләр поселогына күчеп килә һәм «Баулынефть» транспорт конторасында шофер, автомеханик, ә 1961—1962 елларда районда чыккан «Байрак» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1966—1968 елларда М. Хәбибуллин Азнакайдагы «Маяк» газетасы редакциясендә бүлек мөдире була. 1971 елда, читтән торып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, 1969—1971 елларда Таҗикстанда урта мәктәптә тарих фәнен укыта.

1971 елда ул Казанга күчеп килә һәм байтак еллар Татарстан Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе вазифасын башкара.

Бик яшьли үз көнен үзе күрә башлаган М. Хәбибуллин әдәби иҗатка шактый бай тормыш тәҗрибәсе туплап керешә. Шушы ук тәҗрибә байтак дәрәҗәдә аның иҗади эзләнүләренең юнәлешен һәм эволюциясен дә билгели. Баштарак ул яшьлек дәрте белән замандашлары, бигрәк тә яшьләр тормышын чагылдырган хикәяләр яза, ә 1969 елда аның беренче күләмле

әсәре — «Унсигезенче яз» повесте дөнья күрә. Яңа гына унсигезенче язын каршылап урта мәктәпне тәмамлаган яшь кыз Әнрусәнең артистка булу хыялын тормышка ашырудагы беренче адымнарын, реаль чынбарлык тудырган каршылыклы уй-кичерешләрен лирик пафос белән чагылдыруы аркасында, әлеге әсәр укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан җылы кабул ителә һәм авторны тагын да активрак иҗатка рухландыра. Тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе арта бару М. Хәбибуллинны әсәрләрендә заман тормышының җитдирәк һәм катлаулырак мәсьәләләрен яктыртуга этәрә. Шул нигездә аның «Икмәк кадере» (1968), «Тау белән тау очрашмаса да» (1970), «Хәтер ярлары» (1977) повестьлары һәм «Чоңгыллар» романы (1973) дөнья күрә.

Әмма иҗади эзләнүләрен дәвам итеп, М. Хәбибуллин алга таба тарихи темага мөрәҗәгать итә һәм үзенең әдәбияттагы чын урынын да шушы өлкәдә таба. Әдипнең бу темага килүе, бер яктан, аның татар тарихы белән күптәннән кызыксынуы, икенче яктан, илдәге мәгълүм иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр аркасында әлеге тарихны өйрәнү мөмкинлеге туу белән бәйләнгән иде. М. Хәбибуллинны тарихи романчы итеп таныткан һәм киң яңгыраш алган беренче әсәре — «Кубрат хан» романы (1985). Моңа кадәр безгә бик аз билгеле дәүләт — безнең эраның VII гасыр урталарында Таман ярымутравында яшәгән Бөек Болгар ханлыгы турында әдәбиятта беренче булып сүз әйтергә алынып, әдип халкыбыз тарихының легендар дәверләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүгә лаеклы өлеш кертте. Биредә әдәби осталык белән бергә, авторның тормыш материалын шактый җыйганы һәм өйрәнгәне дә мөһим роль уйный. Дөрестән дә, роман М. Хәбибуллинның байтак еллардан бирле татар тарихы белән актив кызыксынуы, бу очракта әлеге дәүләткә караган материалларны бөртекләп җыюы һәм үзләштерүе нәтиҗәсе булып тора. Әлбәттә, биредә автор фантазиясенең дә роле бар.

М. Хәбибуллин алга таба да милли тарихыбызның күләгәдә калган дәверләренә мөрәҗәгать итә һәм «Илчегә үлем юк» (1990), «Шайтан каласы» (1993), «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1996), «Хан оныгы Хансөяр» (1998), «Аллаһы бүләге» (1999), «Батый хан һәм Ләйлә» (2000), «Атилла» (2001) кебек әсәрләрен яза. Бу соңгы романнар арасында «Атилла» милли яктан аеруча әһәмияткә ия. Чөнки анда автор бөтен кешелек тарихындагы иң данлыклы шәхесләрнең берсе булган Атилланың безнең ерак бабабыз икәнлеген, аның ничек җир йөзендәге иң куәтле дәүләтләрнең берсен төзүен сурәтли.

Гомумән алганда, халкыбыз тарихының моңа кадәр аз билгеле борынгы сәхифәләрен сурәтләп, М. Хәбибуллинның тарихи романнары киң милли һәм сәяси яңгыраш алдылар.

Сорау һәм бирем

1. М. Хәбибуллин иҗатында төп тематик юнәлешләрне санагыз һәм аларга кыскача характеристика бирегез.

2. Әдипнең тарихи темага мөрәҗәгать итүе нинди сәбәпләр белән бәйләнгән?

АТИЛЛА

(Романнан өзек)

Ауропалылар өчен Идел-Урал буйларыннан кузгалган ат менгән җиңелмәс гуннар турындагы миф-уйдырма готлар «Алла камчысы» дип атаган җиһангир Атилла Рим каласының басу капкасына җитеп туктагач кына чынга әверелә.

Л. Н. Гумилев

I

Атилла ханның тәхете императорларныкы кебек кирә-керүгә үк күзгә бәрелми, киресенчә, җыйнак кына тәхет Атилла ханны үзе олуг бер зат итеп күрсәтә иде. Императорлар исә алтын-көмеш белән коендырылган гаҗәеп мәһабәт һәм зиннәтле ташлар белән чуарланган тәхетләрендә кәрлә кебек кенә булып утырсалар, бу исә түр якны тутырып утыра иде. Кешене тәхет түгел, тәхет кешене бизи икән дигән фикергә килде Приск түргә таба барганда. Атилла хан берәүгә дә игътибар итмәде, ул Хилхәл атакай белән сөйләшеп тора. Алар янына Идекәй узды, һәм алар өчесе дә ике империядән килгән илчеләргә карадылар. Атилла салмак кына хәрәкәт белән өстәл яннарына узып утырырга ишарә ясады. Әмма Идекәй илчеләрне туктатты һәм Атиллага карады.

Атилла хан аңа илчеләрне сул кулга утыртырга дигән ишарә ясады. Илчеләр сул кулдагы өстәл яннарына кереп утырышкач, ни сәбәпледер, Идекәй Византия илчеләрен уң кулдагы өстәл янына күчереп утыртты. Ул арада теге яктан да, бу яктан да өстәлләр янына йөзләрчә кешеләр узып утырыштылар. Атилла хан берәүгә дә күтәрелеп карамый, башын түбән игән килеш утыра бирде. Хилхәл атакай аңа нидер сөйли, ә Идекәй, арлы-бирле йөри-йөри, илчеләрне урнаштыра. Ниһаять, барысы да утырыштылар. Ул да түгел, өстәлләргә көмеш кружкалар

тезеп чыктылар, һәм алар артыннан ук шәрабчылар, кымызчылар, сырачылар йөри башладылар. Алар һәр кунакка теләгән эчемлекне салып йөрделәр һәм хезмәтләрен башкаргач, тезелешеп, бер читкә бастылар. Атилла хан башын күтәрде һәм һәммәсенә дә күз йөртеп чыкты, бигрәк тә илчеләргә игътибар итте. Аннары ул кулындагы кружканы артка сузды, аңа тирләп торган кувшиннан салкын чишмә суы салдылар. Илчеләр Атилла ханның ни эчкәнен беләләр идеме икән, әмма Приск белә иде — салкын чишмә суы. Ул арада Атилла аягүрә басты һәм кружкасын күз турысына китерде.

— Илчеләр һәм кунаклар, мин бу эчемлекне сезнең игелеккә күтәрәм,— диде ул латин телендә һәм шул ук сүзләрне грек телендә кабатлады, аннары гун телендә.

— Хан полиглот,— диде сенатор Максимин Прискның колагына.

— Ишеткәнем хак булса, император Валентиан ана телендә дә көчкә сөйләшә,— диде аңа Приск.

— Ә хан миңа торган саен ошый бара.

— Варварлар да адәм балалары, сенатор.

— Син хаклы, алар да адәм балалары, тик тәрбия башкадыр.

— Һәр халык үз тәрбиясен башкалардан өстен күрә, сенатор.

Ул арада ашау-эчү башланды. Һәр кеше үз табынына нинди ризык тели, шуны чыгып алды һәм үз урынына узды. Тавыштынсыз гына ашап-эчтеләр, төнәтмәләрдән җитештеләр. Идекәй Атилла хан янына күчеп утырды. Ул аңа нидер сөйли. Сөйли-сөйли дә Вигиләй ягына күз төшереп ала. Шуны сизепме, Прискка өч-дүрт кеше аша утырган Вигиләй гасабилана башлады, бертуктаусыз боргаланды, чарасызланды, кемнәндер яклау эзләгән кебек әле тегеңә, әле моңа карады. Аның шулай гасабилануын күрепме, Атилла хан аны үз кырына дәшеп алды.

— Кунаклар, илчеләр, монда минем бабам утыра. Мин аны үз кырыма дәшәм. Сенатор Максимин, мөмкиндер бит?

— Баш өсте, баш өсте, хан,— диде, ашыгыбрак аягүрә басабаса сенатор Максимин.

— Мин беләм,— диде Атилла хан.— Феодосий илчеләре Гунстанга изге ният белән килгәннәрдер. Ләкин без гуннар кайчак бик якын кешеләрне дә тикшерәбез. Вигиләй бабай, уз әле бире, уз-уз, якынрак кил. Минем синең күлмәк астындагы илле солид салган янчыкны күрәсем килә. Миңа җиткерделәр, ә мин ышанмый торам. Чынмы икән? Әллә соң минем якын киңәшчем Идекәй ялганлыймы?

Вигиләй торып тәхеткә таба китте, йөзе ап-ак, чырае качкан, әмма ярты юлга җитәр-җитмәс тезенә төште. Аны шундук ике гун култык астыннан эләктереп алдылар һәм Атилла хан янына китереп бастырдылар.

— Янчык маҗарасы дөресме, бабай?

— Юк сүз, юк сүз, Атилла хан, юк сүз!

— Тикшерегез, түшендә, чынлап та, янчык бармы?

Ике таза гун Вигиләйнең күлмәк астыннан бер янчык алтын тартып чыгардылар. Вигиләй тагын Атилла хан алдына тезләнде.

— Кичер мине, Атилла хан.

— Тор, бабай, тор. Түбәнсенмә. Императорың түбәнсенгән дә җитәр. Янчыкта кем алтыны? Әһә, янчыкка Хрисафәй дип язылган. Димәк, янчык хәрам атакайныкы. Ә солидлар, алтын солидлар кемнеке?

— Кирәк-ярак алырга алган идем.

— Хәрам атакай Хрисафәйдәнме?.. Улмы сине яллады?..

— Хан, хәрам атакай Хрисафәй аны гына түгел, мине дә яллады. Һәм алар моны император Феодосий белән бергә эшләделәр. Сине, Атилла хан, Вигиләй бабаң түгел, мин үтерергә тиеш идем. Нинди юллар beləнме? Агу биреп. Һәм мин, кыласы яман хыянәтемне ачыклау өчен, император Феодосийдан язма рәвештә рәсми кәгазь алдым. Хрисафәй атакай сине үтерергә котыртса, император Феодосий үз фатихасын бирде. Менә ул кәгазь, илчеләр, күрегез, менә ул император Феодосий кул куйган кәгазь! Монда императорның имзасы да куелган, мөһере дә сугылган.

— Орест,— диде сәркатибенә Атилла хан.— Ал кәгазьне, укы.

Император һәм аның сәркатибе кул куйган рәсми кәгазьне укып чыккач, барысы да бертын дәшми утырдылар. Приск тәмам телсез калгандай булды. Нинди мәкерле эшләргә катнашып йөри икән ич ул. Бит Вигиләй аның белән килде.

— Йөкләмәне мин Атилла ханга бирәм,— диде Хилхәл атакай.— Хан ни әйтә, хөкем шул булыр.

— Кайдан, нинди илдән генә килмәсеннәр, илчеләр минем кунаклар,— диде Атилла хан.— Утырышыгыз, урыннарыгызга. Утырыгыз, утыр.

— Кеше ышанмастай хәл бу,— диде Хилхәл атакай.— Атилла ханны үтертер өчен, аның иң якын кешесенә шартнамә кадәр шартнамә язып, кулына биреп җибәр, имеш. Бу ни була

инде, Атилла хан? Гуннар да шул юлга бассалар, бу дөнья ничекләр бетәчәк. Күзаллагыз бераз, илчеләр. Иң гаҗәбе, моны ил башында утыручы адәм эшли — император Феодосий, безгә ничәмәләр тапкыр тыныч яшәргә, тиешле салымын түләргә вәгъдә биргән кеше! Императорыңның оятсызлыгын ничегрәк аңлатырга исәбең, сенатор Максимин?!

— Мин чарасыз, атакай, чарасыз,— диде Византия империясе илчеләр башы һәм тәхеткә таба кузгалмакчы итте. Әмма аны кул күтәреп Атилла хан туктатты.

— Утыр, Хилхәл атакай,— диде Атилла хан.— Хөкемне үзем чыгарам. Исегезгә төшерим, сенатор Максимин, мин император Феодосий алдына шарт куйган идем: елына җиде йөз кадак алтын һәм бездән качып киткән фетнәчеләрне кайтарырга.

— Мин бу хакта белмәдем, император Феодосий...

Атилла хан тагын кулын күтәрде, Византия илчеләр башына сабыр итәргә кушты һәм, урыныннан кузгалып, сенатор Максимин янына килде.

— Мин сине гаепләмим, сенатор,— диде һәм сенатор кырында утырган Прискка күз төшереп алды.— Һәм язучы Прискны да. Минем сезгә хөрмәтем зур. Ә Вигиләй бабам белән мин үзем аңлашырмын. Бүген исә барыгыз да ял итегез, күңел ачыгыз. Сез бүген минем кырыма килгән илчеләр генә түгел, кунакларым да.

Атилла хан урынына барып утырды. Идекәй исә сүзне Рим илчеләре башы Ромулга бирде. Префект Ромул торып басты, тамак кырды. Шулчак Ромулның кулындагы кружкасы чайкалып китте, шәраб күршесенең баш киеменә түгелде. Барысы да елмаешып алдылар.

— Рим каласына нигез салучы Ромул түгелсеңдер инде син,— диде кинәт кенә Атилла хан, тәхетенә җайлабрак утыраутыра.— Мин сине дә тыңларга теләр идем, Ромул. Әмма башта син мине тыңла әле. Чөнки мин дә — аз-маз Римда тәрбияләнгән кеше. Ун яшем тулар-тулмас узар-узмас атам Мәңгүк хан мине яшерен рәвештә сәүдәгәрләр һәм илчеләре белән бергә Римга озаткан иде. Әнә шулай мин Хонориус сараена эләктем. Андагы тәртипләр барыгызга да мәгълүм. Ләкин мин анда озак тора алмадым, таныш сәүдәгәрләргә ияреп качып киттем. Ромул дим, утырып тыңла, утырып. Мин беләм, Ромул, сез римлылар императорыгыз белән бергә, без ак төрекләрне варварлар дип атыйсыз. Имеш, чи ит ашыйлар, хәмер эчмиләр, итне

чәнечке белән ашыйлар. Шулаймы, Ромул?.. Шулай. Иллә кем кыргый микән?! Сез, римлылар, без килгәнче чалбарсыз атта йөри идегез, иярегез дә юк иде, өзәңгегез дә. Мин моның шулай икәнен Римда үз күзем белән күрдем. Сез әле күптән түгел генә рәтләп атта йөрергә өйрәндегез. Без килгәнче үзегезнең патрицийларыгызны кул бишекләрендә йөртә идегез, арба да сирәк күренә иде Рим урамнарында. Тимер кылыч, ук, сөңге, чукмарбашлар турында әйтеп тә тормыйм. Сез моңа кадәр бакырга төренергә яраттыгыз. Сезнең бер генә легионерыгыз да минем яугирләрем кебек уктан ата белми. Мәңгелек ташбакаларыгызны да без бик тиз туздырдык. Сез, римлылар, безнең атта сугышучы яугирләрне үзегезнең ялтыравык җиһазларыгызга, шәрә тәнле фахишәләрегез белән кызыксындырдыгыз һәм үз ягыгызга тарта башладыгыз. Шуларның берсе ярым гот, ярым римлы Аэцәй. Гуннар арасында да каршылыклар булырга мөмкин, әмма безнең төп дошманыбыз Византия дә, Рим да түгел, ә бездән качып киткән Аэцәй. Мин беләм: ул шундый кеше, император Валентиан алдында ялагайланадыр. Һәм ул үз дигәненә ирешер, ләкин соңыннан ул аларны барыбер сатар һәм юк кына бәһагә. Бер уйлаганда сез кемнәр соң, римлылар? Дөресмедер, юкмыдыр, Римда чакта, дөресрәге, Хонориуста сөйләделәр, укыттылар дияргә дә була, кайчандыр шушы төбәкләрдә латин дигән халык дәүләт төзи. Һәм ирекле рәвештә үзләренә патша сайлыйлар. Ул патшаның исеме буладыр Нумитар. Әнә шул патшаны энесе тәхетеннән куа. Ул гынамы, Нумитарның угылын да үтерергә боера. Ә Нумитар патшаның бердәнбер кызын весталка итеп игълан итә. Рим кануны буенча весталкаларның утыз яшькә җитмичә кияүгә чыгарга хаклары юк икән. Шулаймы, префект Ромул?

— Гаҗәп, әмма хак сөйлисез, гуннар ханы.

— Әмма весталка Рим канунына буйсынмыйча кияүгә чыга һәм күп тә үтми игезәк бала таба. Һәм кемнән дип уйлыйсыз инде, префект? Марс алладан. Тик моңа ничек ышанмак кирәк! Игезәк баланы весталка алладан таба, ягъни Марстан. Әмма бу чорда Рим тәхетендә утыручы Амуләй балаларга үсәргә бирми, аларны хезмәтчесенә, кәрзингә салып, елгага илтеп ташларга куша. Патшаның хезмәтчесе Тибер кәрзингә утырткан ике баланы елгага ташларга кызгана һәм су буенда калдырып китә. Тибер китеп бераз торгач та, балалар еларга тотыналар. Шунда каяндыр бүре килеп чыга һәм балаларны имезә. Имезеп кенә китми, балаларны тәрбияләп үстерә дә. Ул гынамы, аларга

Ромул һәм Рем дип исем куша. Ахыр чиктә, үсеп-исәйгән балалар үзләренең кем икәнлекләрен беләләр һәм җай китереп, Амуләй патшаны үтерәләр. Әмма ике туган арасында тәхет өчен бәхәс туа. Һәм алар, уртак тел табып, бу каланы ташлап китәләр. Һәм икесе ике җирдә кала корып, калага исем бирергә булалар. Ике туган арасында янә бәхәс туа. Бит калалар берберсенә якын булу сәбәпле тора-тора кушылалар. Кем исеме белән атарга каланы? Шул сәбәпле ике туган арасында сугыш чыга. Ромул туганы Ремне җиңә һәм үтерә, ә туганы кешеләрен кол итә. Коллык Римда, имеш, әнә шул чордан башлана. Шулаймы, дөрес сөйлимме, префект Ромул?.. Синең атаң шул патшаның исемен кушкан икән. Моның белән мин шуны әйтергә телим: адәм балалары барысы да бертуганнар, әнә шул бертуган халыкны кол итеп тоту гаделлекме?.. Римлылар, гомумән, колбиләүчеләргә дан җырларга яраталар. Әмма бертуганыңны кол итеп тоту данмы, префект Ромул?! Бүген миң еллар элек булган кебек император Валентиан весталка урынына сеңлесен үз сараенда бикләп тота. Гаделлекме бу?!

Весталка сүзен ишетүгә, префект Ромул тагын торып басты, бер утырды, бер торды. Ул, күрәсең, гуннар ханына шаккаткан иде. Варвар-варвар, ә сәяси көндәшләрен ничекләр китереп кысарга белә.

— Бу мәсьәләдә мин күптәннән сезнең якта, гуннар ханы.

— Әйе, минем яктасың. Ә весталка хөкемендә булган Һөнәрияне алып килмәгәнсең. Бирегез префектка Һөнәриянең миңа җибәргән хатын, күрсәтегез ат-исеме сугылган туй балдагын,— диде Атилла.

Тиз арада префект кулына балдак белән хатны китереп тоттырдылар. Ромул балдакны алды, әйләндерә-тулгандыра карады һәм весталка кызның исемен укып таң калды, ахыр хатны укый башлады. Хат ахырында весталка Һөнәриянең мөһерен күреп исе-акылы китте. Ул ышанмады, ул шикләнде, ул ни кылырга белми аптырады.

— Хат белән балдакны весталка Һөнәриянең хәрам атакае китергән икән, гуннар ханы. Сез шушындый хат алуыгыз белән горурланырга тиешсез, Атилла хан. Хатын-кыз батыр ирләрне илләр аша күрә, диләр иде, дөрес икән. Гүзәл Һөнәрия сезне илләр аша күрә алган. Ул сездән мине әсирлектән коткарыгыз дип үтенә. Сезгә — илбашына мөрәҗәгать итә кыз, улыгыз Иллакка түгел. Димәк, гуннар ханы, весталка кызга үзегез өйләнергә тиеш буласыз. Ләкин весталка кызга белеп өйләнсәгез

иде, Рим кануннарында, ул кем генә булмасын, хатын-кызга биләмә җир бирелми...

Илче Ромул сүз сөрешен дәвамлы төстә алып бара алмады, каушады, фикере чуалды. Илче буларак Приск аның өчен оялып утырды. Атилла хан латин телен начар белми иде, тылмачына төзәтмәләр кертеп утырды.

Кыен булыр Ромулга, дип утырды Приск. Кыен булыр. Ә бит ару гына башлаган иде. Әйткәннәре хак булса, префект Ромул — готларны җиңгән кеше, шул хәлдән соң аны префект дәрәҗәсенә күтәрәләр, сарайга якынлаша. Әнә шул кешене император Валентиан Гунстанга илче итеп җибәргән. Императорга бик тиз җиткерерләр, Валентиан аның Атилла каршында сөйләгән нотыгын килештермәс һәм туып килгән илчене сарайдан куар. Сәясәт — гаять җитди мәсьәлә, сугыш кырында бар нәрсә дә ачык, ә менә сәясәттә барысы да йон йомгагына төренгән. Приск үзен Ромул урынына куеп карады. Әйе, Ромул урынында булса, ул ни кыра алыр иде микән? Илле күпме уйласа да, Атилла куйган тозактан ычкыну җаен таба алмады. Префект Ромул иң әүвәл Атилла хан каршына әнә шул весталка кызны тотып китерергә тиеш иде. Көчләп булса да, көчләп түгел, чөнки үзе Атиллага хатлар язган, Валентианнан урлап... Хәзер бердәнбер чара кала: префектка — Римга кайтмау. Кайта калса, император Валентиан аны барыбер кичермәс. Иң кулае — Ромулга сенатор Максиминга ияреп Византиягә китү. Ләкин болар бары тик язучы Приск фаразлавы гына иде.

— Префект Ромул, мин синең аша император Валентианга яңа таләпләр куям. Йә ул минем таләпләрем үти, йә сугыш!

Тәхет ягындагылар барысы да аһ итеп куйдылар. Алар беләләр иде. Атилла хан беркайчан да ике сөйләмәде. Әйтте — өзде.

Бераз торгач кына табындагылар шаулаша башладылар, янә ашау-эчү китте. Ул арада Идекәй торып басты һәм Византия илчеләре башы сенатор Максиминга сүзне бирде.

— Барыгыз да беләсез,— диде ул.— Хәрам атакай Хрисафәй мәкерле уйлар белән кеше җибәрә. Сенатор Максимин, инде син әйт үз сүзең.

— Хөрмәткә ия гуннар ханы Атилла, мин бу хакта сенат алдында игълан итәрмен. Белсен сенат, кем утыра Византия тәхетендә.

— Каты әйтте,— диде Хилхәл атакай.

— Хак, моның өчен мине император кичермәс,— дип дәвам итте сенатор. Әмма астыруын астырмаса да сарайдан куар.

— Яхшы, бихуш,— диде Атилла.— Син ошыйсың миңа, сенатор. Ләкин син бүген миңа сүз бир, сине сенатта тикшергәндә янәшәңдә кул-аягы богауланган Хрисафәй атакай да булсын.

— Мин аны сенат каршына китерермен, гуннар ханы.

— Яхшы, бихуш, мин сиңа ышанам, сенатор. Тик император Феодосийга минем сүзләрем түкми-чәчми җиткер. Мин мәшһүр Мәңгүк хан улы Атилла, атам исемен күккә күтәргәндә, син атаң исемен аяк астына салып таптадың. Син минем хезмәтчеләрем дәрәҗәсенә төштең. Син миңа ясак түләп торасың, син минем ясакчым. Шуңа карамастан иң түбән кол сурәтендә үзеңнең ияңә кул күтәрергә кеше яллап җибәргәнсең. Шул чиккә җитеп түбән тәгәрәде микәнни горур Рим императорлары! Балачакта мин Искәндәр, Цезарь исемнәрен ишетеп соклана идем. Миңа ул исемнәр яшен суккандай тәэсир итәләр иде. Хәзер исә мин аларга түбәнсетеп карыйм. Ике империя дә миңа берсе артыннан берсе илчеләрен җибәреп тора, алтын белән ясак түли. Ә үзләре мине төрле әшәке сүзләр белән орышалар. Килешми, килешми куәтләре дөнья халыкларына таралган императорларга, кол дәрәҗәсенә төшеп, ясак түләп яткан хуҗаларына кул күтәрү. Шулаймы, сенатор Максимин?! Шулаймы, префект Ромул?!

— Хак, хак, килешми,— диделәр беравыздан илчеләр.

— Мин беләм, префект, Рим тарихчылары мине мактамас, мәгәр мин аларның мактауларына мохтаҗ да түгел. Минем үз халкым бар. Үз гуннарым, яраннарым, тату яшәгән, Ауропага иңгә-иң килеп, яу килгән халыкларым. Алар мине данлар, гасырлар үтә-үтә булса да данлар... хәзер кунак булыгыз, кунак булыгыз...

Атилла барча илчеләргә дә, кунакларга да күз йөртеп чыкты. Ни өчендер Идекәй Приск янына килеп утырды.

— Хәзер тамаша карыйбыз,— диде.

Прискка Атилла хан ошады. Һәрхәлдә, хан үзен императорлар кебек Алла сурәтендә тотмый. Гап-гади тота, кигән киеме дә башкаларныкыннан әллә ни аерылмый. Шулвакыт Атилла янына кече улы йөгереп килде. Атилла аны янәшәсенә утыртты, малайның битеннән тарткалагандай итте, яратты, нидер әйтте.

Менә кайчан Приск грек Идекәйнең хәленә керде. Империядә Идекәй йөз чиновникка баш игән булса, монда нибарысы бер Атиллага буйсына иде. Приск табында утырган гуннарга күз төшереп алды. Кигән күлмәкләре күн, кайберләренеке

аркалары тишекле. Күлмәкләр, чалбарлар төрле төстә. Моңа кадәр чалбар кимәгән Приск бирегә килгәндә кигән иде, ошады тагын, атта уңайлы, атлавы җиңел, йөгергәндә дә юбкага буталмыйсың. Җитмәсә, гуннар ат менәсе төшенә ике кат күн теккәннәр. Приск түзмәде, янәшәдә утырган Идекәйдән:

— Кайберләре күлмәкләрен арт яктан тишкәләгәннәр, ни өчен? — дип сорады.

— Җил өрсен өчен,— диде Идекәй, бер дә исе китмичә.

Чынлап та, эссе көндә күлмәктән җылыдыр, яшьрәк гуннар шуңа күрә арка якларын тишкәләгәннәр. Приск күршесенә самими сорау бирүенә үзалдына елмаеп куйды.

Ул арада берьяк читтәрәк, тәхет кырындарак корылган мәйданчыкка ике яшь егет чыгып бастылар, алар артына көйчеләр урнаштылар. Бераз моңсу, шул ук вакытта тантанага тартым көй башладылар. Көйчеләр арасында кыллы кораллар да, ниндидер сыбызгылар да, думбра да, шылтыравык кораллар да бар иде. Ләкин җыр башлануга, көйчеләр тынып калгандай иттеләр. Кызык иде Прискка гун җырчыларын тыңлавы. Ниндидер озын көйгә, берсе югарырак тавыш белән, икенчесе түбәнрәк аһәңдә җыр башкардылар. Аны әнә шул җыр үз дулкынына алып кереп китте. Чит-ят халык булса да, Приск дөрес аңласа, көй матур иде, күңелгә май булып ятты. Нәкъ кичә аулак өйдә аның белән шулай булган иде. Ул күрде, күзәтте, кунаклар арасындагы олы яшьтәге агайлар күзләрен сөрткәләп алдылар, яшьрәкләре исә җырга кушылгандай иреннәрен кыймылдатып утырдылар. Җырчылар артыннан мәйданчыкка шамакай чыкты. Ул берничә телдә мәзәкләр сөйләде, һәммәсен дә көлдерде, ахыр ниндидер такмаклар әйтте, көйчеләр аңа шыңгырдабрак булса да көй тарттылар. Аның артыннан янә бер шамакай мәйданда пәйда булды. Аның өстендәге киеменә кадәр котны алырлык иде. Төрле-төрле ямаулардан торган карачкы кыяфәтендәге шамакай шундаен көлке әйберләр сөйләде ки, барчасы да аңласалар да, аңламасалар да кычкырып-кычкырып көлделәр. Шамакайның аягындагы киеме дә алга таба кәкрәеп тора, ул әнә шул аяк киеме белән әллә ниткән хикмәтләр ясый, йә бер урында бөтерелә, йә сыңар аякта титаклый, йә кем булыптыр сөйли. Баш киеме тоташ каурыйдан һәм каурыйлар төрле төстәләр. Халык аның сүзләреннән эчен тотып көлә, аларга карап Приск та көлә, гәрчә шамакайның ни турыда сөйләгәнен аңламаса да. Бары тик Атилла хан гына һаман исә улы белән сөйләшеп утыра, ул гүя шамакайны күрми дә, белми дә, тыңламый да иде.

Жырчылар, шамакайлар киткәч, көйчеләр әкрен генә көй башладылар, һәм кунаклар янә эчәргә-ашарга керештеләр. Бер Приск кына аз ашады, эчмәде, тыелды. Тәхет ягындагы мәҗлес-табын караңгы төшкәнчегә кадәр сузылды. Мәҗлес-табыннан шактый исерә төшеп чыкканнары да күренгәләде. Идекәй исә Прискны кунак йортына кадәр озатып куйды һәм, китәргә җыенып:

— Приск, онытма, иртәгә сиңа кыз куасы,— диде.

— Антоний кая соң?

— Антонийны эзләмә, Атилла хан аны Римга җибәрде.

— Кем артыннан?..

— Булдыра алса, весталка Һонәрия артыннан.

Приск барысын да аңлады. Бу хәл аңа кагылмый иде. Иң мөһиме, Атилла аларны кабул итте һәм барысы да, шөкер кыла, әйбәт бетте кебек. Һәрхәлдә, боерган итсә, Атилла Византиягә яу йөрмәячәк. Бу инде җиңү иде.

Тик бер нәрсәне белмәде Приск, чын җиңү сенатор Максиминга да, аңа да иртәгә киләчәк иде — кыз куганнан соң. Ләкин бу хакта ул уйларга курыкты. Ә юрыйсы килмәде, барысын да Аллаһына тапшырды һәм йомшак ятакка сузылып ятты.

* * *

Соңгы айларда Атилла хан тәмам тынычлыгын югалтты. Иллак угланның Рим тарафында үлеп калуы, Диңгизид угылының Илбикә белән кавышырга теләмәве, император Маркианның ясак түләүдән читләшүе, ул гынамы, Атилла ханга янавы — ханның бик нык кәефен бозган иде. Император Маркианны ул болай гына калдырмас, вәгъдәсезлек илбашларына хас сыйфат булырга тиеш түгел, аңласын иде, ниһаять, Гөлсәриягә өйләнеп ил башына менгән Маркиан. Тик Тәңре үз адәмнәренә акылны капчыклап өләшмәгән кебек, ахмаклыкны да һәр кешенең үзенә калдырган икән шул. Уйлан вә уйлан да, җәмгыятьтә үз юлың тап, үз сукмагыңа төш. Үз юлың, көчең вә сәләтең җитәрлек сукмагың тапмагансың икән, башкаларга үпкәләмә, башкаларны гаепләмә, үзеңне гаеплә, үзеңә үпкәлә. Яраткан улы Диңгизид тагын нинди гүзәл заттан йөз чөермәкче. Имеш, аның үз кавеменнән яраткан кызы бар. Бу хакта ишетүгә, Атилла хан угланны акылга утыртырга иткән иде дә, уйлана торгач, кул селтәде — мәхәббәтне көч белән җиңеп булмый. Бу хакыйкатьне дә яхшы белә иде ул. Шул ук

вакытта Визигаст корольнең гүзәл кызына да өйләнү зарур дип тапты Атилла. Диңгизид угланның Визигаст король кызына өйләнүе — йөрәктән йөрәккә тартылган халыклар арасындагы дустанәлек җебе ул. Менә шуны аңласын иде углан. Әнә шуның туып килгән Гунстан ил-дәүләтенә никадәр хасыяти зарур нәрсә икәнен, дөресрәге, сәясәт икәнен аңларга теләми углан. Имеш, башка берәүне ярата. Ни соң ул ярату? Хак, Атилла хан моны гына белә, белми түгел. Яшь чакта Күркәмгә ничекләр гашыйк булган иде. Куенына кереп йоклама — дөнья бетәр сыман иде. Аннары Виницага күзе төште. Иллә аны абасына бирде. Ә инде Элиана аны тәмам чарасыз иткәләде. Аның кырында бер төн йокламаса, барысы да асты-өскә килер кебек иде. Шушындый көннәрдә Хилхәл атакай, аның халәтен аңлап: «Бүген хан берьялгызы йоклаган,— дип мыек астыннан гына елмаеп куяр иде. Һәм ул хак булыр иде. Ни генә булмасын, Диңгизид углан Илбикәгә өйләнергә тиеш. Моны аның атасы Атилла хан тели. Аннары, кыз да каршы түгел. Хәер, карышыр-карышыр да, углан да килешер. Атасы тели ич моны! Ниһаять, сәясәт!..

Атилла урыныннан кузгалды, углан янына барырга булды. Хак, хан башы белән углан кырына бару килешеп бетмәсә дә, әлегә кадәр хан кылган нәрсә түгел бу. Мондый адымны ул әлегә кадәр ясамады, кем генә булмасын, аның янына үзләре килделәр, угланнар турында әйтеп тә торасы юк.

Атилла хан җансакчысын дәште, туры кара айгырын иярләргә һәм болдыр янына китерергә кушты. Шуннан соң гына, бераз көттереп, болдырга чыкты. Аны болдыр янында унлап җансакчысы көтә, ханның ни боерасын белмиләр, әмма аның күз карашыннан ук әмерен үтәргә әзер торалар. Тантаналы мәлләрдә генә атлана торган кара туры айгыр болдыр каршында, ишектә торучы сакчы атның мәрҗәннәр тезгән йөгән башыннан тотып тора. Айгыр ярсына, гасабиланып, иясен көтә, уң тоягы белән җирне тырный һәм тыенкы гына кешнәп куя. Ат ашкына, кыяфәтенә үк чыккан, ә менә иясе бер дә ашыкмый кебек, чыкты да болдырда туктап калды.

Углан янына бара. Килешерме? Хан ич ул! Углан каршына баш иеп барган кебек килеп чыкмасмы?!

Юк, кире уйлау ярамас. Углан янына барсаң-бармасаң да, атыңа атлан да бер җилләнеп кайт. Элек шулай итә торган идең бит. Ә кайтыр юлда Диңгизид торган өйгә туктарсың. Углан болдырга йөгереп чыгар, өйгә дәшәр, анда Күркәмне күрер,

киңәшкәндәй итәр. Тик карт хатын аны күрүгә сөенерме?.. Ул да угланны сөйгән кызына өйләндерәсе килә дигән хәбәр ирешә Атиллага. Ләкин уйланасы уйланган иде инде, Атилла хан йөгерә-атлый баскычлардан төште дә яшьләргә хас җитезлек белән атка атланды, тезгенне тотты.

— Йә! — диде ул атына һәм басу капкасына чапты. Башта ул Илбикәне күрер, булачак киленне, дип уйлады Атилла колак янында сызгырган җилдән арынырга теләгән кебек, артына әйләнеп карады. Ике җансакчысы кала төшеп, аның артыннан киләләр иде. Атлары аныкы кебек үк каралар, җилле киләләр. Кара айгыр басу капкасын үтте, басу юлына чыкты. Атилла тезгенне җибәрә төште. Әйдә, бер элдереп калсын...

Шуны гына көтеп барган кебек, кара айгыр сузылып чаба башлады. Бу сулышта ат ерак китә алмый, кире борылмаса да, Атилла атны тыя төште һәм ат юртуга күчкәч, уратыбрак борыла башлады.

Атилла хан улларының өчесенә дә аерым өй салдырткан иде. Иллак белән Ирнак шул өйләрдә тора башладылар, ә менә Диңгизид углан анасы йортында торды. Бу хәл Атилла ханга ошамаса да, беркайчан да угланга бу хакта бер сүз дә әйтмәде. Ата буларак Атилла угланнарын башка чыгарган кебек килеп чыккан иде. Ике туганы моны кабул иттеләр, аталарыннан бүләк дип аңладылар, ә Диңгизид үзенә дип салдырган өйнең капкасын да ачып карамаган дигән хәбәр ирешкәч, ата кеше аңардан: «Нигә син атаң салдырган өйгә күчмисең?» — дип сораган иде. Угланның җавабы кыска булды: «Өйләнгәч тә күчәчәкмен, атам»,— диде.

«Менә хәзер чыгарсың инде»,— дип уйлады Атилла хан басу капкасын үтеп, туп-туры Диңгизид углан өенә таба юнәлде. Ләкин кинәт кенә исенә төште: углан анасында тора ич!

Атилла атын Күркәм хатын йортына таба борды. Мәһабәт өй салдырган иде ул Күркәм хатынга. Ике катлы шәмдәлләрдәй нараттан. Аскы катта зур зал, икенче катта йокы бүлмәләре, өйгә кушып диярлек аш-су хәстәрли торган йорт. Шунда ук хезмәтче хатын-кызлар торагы.

Өй-каралтыга җитәр-җитмәс үк, кайдан күрептер, Күркәм хатын болдырга йөгереп чыкты, аның артыннан ук килен буласы Илбикә. «Бу ни бу! Диңгизид углан кая?» — дип уйлады Атилла хан һәм, килә-килүгә, атыннан төште, йөгән тезгенен җансакчысына ташлап, җилле генә адымнар белән болдырга менде һәм Күркәм хатынга баш иде, аннары булачак килененә.

— Укулар ничек бара, анакай? — дип сорады Атилла хан булачак килененә күз ташлап елмаеп куйды. Илбикә дә чак кына тез чүккәндәй итте.

— Бала ушлы, тиз аңлаштык, атасы. Тик Диңгизид углан гына Илбикә бирегә килү белән син салган өйгә күчеп китте.

— Бихуш, яшәсен әлегә шунда, өйләнгәч, кәләшен дә үз кырына алыр,— диде Атилла хан.— Димәк, сезнең хәлләр ару.

— Син аның белән сөйләш әле, атасы. Ул Илбикәгә минем сөйгән кызым бар диде.

— Яшь кешенең сөйгән кызы булмаса шаккатыр идем, Күркәм хатын. Яшьлектә сөйгән яшьлектә кала, диләр. Дөнья көтү өчен кәләшне ата-ана теләге буенча алалар иде кебек, Күркәм хатын, бездә. Әллә мин ялгышаммы, анасы?..

— Сөйкемсез сөякләр белән яшәве дә бик авыр бит, атасы.

— Илбикәме сөйкемсез сөяк, йә Тәңрем, җир йотар үзен бу сүзне әйтергә кыйса. Греклар алиһәсе бит булачак килен, анасы, греклар алиһәсе!

— Карале, карале, атасы. Син угланны куркытма инде, бик кысма да. Җаны теләгән җылан ите ашаган, ди.

— Камчы татымый үсте ул углан, син яркладың аны, Күркәм хатын, син узындырдың...— Атилла хан Илбикәгә ым кагып кына өйгә кереп торырга кушты, булачак килен артыннан ишек ябылуга, Атилла хан камчысын селти-селти: — Баланы акылга утыртырга беркайчан да соң түгел, Күркәм хатын, беркайчан да.

— Кычкырма әле алай, атасы, кешедән яхшы түгел. Диңгизид углан Илбикәдән баш тартам димәде ич әле.

— Дисә нишләр идең, Күркәм хатын? Нишләр идең үз балаң атасы сүзен тыңламый башласа?!

— Аның сөйгән кызы бар. Бәлки, вәгъдәләшкән үк булгандыр.

— Вәгъдәләшсен. Бер елдан икенче хатынга алыр. Ә угланның беренче хатыны Илбикә булыр! Мин әйттем, Күркәм хатын!..

Шулай диде дә Атилла хан куй маенда кайнаткан камчысын чажлатып алды һәм атына таба китте.

— Бала янына бара күрмә тагын!

— Ә ул минем белән киңәштеме, миңа сөйгән кызым бар дип әйттеме?!

— Атасы дим, хан башың белән кеше көлдереп йөрмә. Ир кадере — җирдә, җир кадере илдә, аталары. Йөрмә бала янына!

— Ата кешегә баш бирмәгән бала белән мин башкача сөйләшә белмим!

— Тукта, тукта, куй, куй дим, атасы. Нинди сүз инде ул тагын, җиткән җегетне!

— Мин аңа дөньяда бер булган гүзәл кыз таптым, дөньяда бер булган.

Атына килеп җитүгә. Күркәм хатын ир-канатының җиңенә килеп ябышты.

— Кеше көлдермә дим, атасы.

— Кем кызына өйләнмәкче соң?

— Меңбаш Барс кызы Сандугачка.

— Актай төмәнбашы Барс кызын яратамыни?!

— Үзе. Балачактан ук сөешеп йөргәннәр. Быел кызлар туенда куарга вәгъдә иткән икән.

— Җитте! Мин кем аңа, атамы?!

Күркәм хатын тагын нидер әйтергә иткән иде, әмма өлгерә алмый калды, Атилла хан сикереп атына атланды, кала читендәге үзе салдырган Диңгизид углан өенә таба чапты. Җансакчылары хан артыннан кузгалдылар. Урам тузан белән тулды, үтүче-сүтүчеләр коймаларга сыендылар. Өй каршына килеп туктауга, аның каршына Диңгизид углан йөгереп чыкты.

— Ни булды, атам?!

— Башта өйгә дәш! — диде Атилла хан, коры гына һәм алдан өйгә кереп китте.

— Ни булды, атам, яу килмидер бит?..

— Мин килдем сиңа яу белән, углан, мин — атаң! Анаңда тора идең түгелме? Тора идем, дисең? Ә нигә Илбикә килүгә монда качтың? Кызлар ашар дип курыктыңмы әллә? Гунмы син, Атилла хан улымы?!

Ачулы иде Атилла, үзе дә белми ни өчен, шул ук вакытта бераз шәйли дә. Иң оста мәргән улы аның сүзеннән чыкты. Үз балалары тыңламагач, халкы ничек тыңласын ханны?!

Атилла хан почмакта сәке күрде, барып утырды, кымыз сорап алды, агач касәне бармак очларына утыртып, күтәреп эчеп куйды. Һәм шуннан кинәт кенә сабырланып китте.

— Берүзең бер өйдә торасыңмы? Бичура түгелсеңдер бит?.. Хезмәтчеләрең кая дим?..

— Мин аларны кайтарып җибәрдем, атам.

— Аулак өй ясарга исәбең идеме әллә?

— Юк, уйлыйсы уйларым бар иде, атам.

— Уйлыйсы уйларың... — Атилла кырын күзе белән генә угланга күз төшереп алды. Үзенә охшаган иде егет. Суеп капландай үзе иде. Гәүдә-сыны да, йөз-кыяфәте дә, хәтта үз-үзен

тотышы да. Күзләренә кадәр аныкы. Атилла хан угланда үзенең яшьлеген күргәндәй булды. Һәм аңа кинәт оят булып китте. Ә бит үзе өйләнгәндә берәүдән дә сорамады — угорларга баргач өйләнде дә кайтты. Аның өйләнүенә атасы Мәңгүк хан да бер сүз дә әйтмәде, һәрхәлдә, нигә минем белән киңәшмичә өйләндең дип тиргәмәде. Гуннарда өйләнешү, сөешү, гомумән, ирекле иде, кияүгә чыгу да хәтта. Угланның да үзе теләгән кызга өйләнергә хакы бар. Бар, бар, тик бит бу дөньяда сәясәт тә бар, бер кавем белән икенче кавемне кардәшләштерү, ары таба бер булып яшәү.

— Тыңла әле, углан. Иртәгә син өйләнәсең. Визигаст король кызы Илбикәгә. Кыз сылу, зифа, яшь. Ул хәзер синең анаңда тора. Күргәнсеңдер, кыз чибәр, хәтта артыгы белән чибәр.

— Атам!

— Тик тор, углан, тик тор! Мин әйттем! Егет бул, атаң сүзен җиргә салып таптама. Зарланасың килсә, анаңа барып зарлан, миңа түгел, мин әйтәсен әйттем! Инде Сандугач дигән кызны бик яраткан булсаң, бер елдан икенче хатынга алырсың. Әнә атаң тора бит әле ике хатын белән. Тора. Ярар, мин киттем...

* * *

Икенче көнне Атилла хан оран салучыларга йөк йөкләде — сала-калаларны, җәйләүләрне, авыл-утарларны йөреп, Атилла хан улы Диңгизид гепидлар короле Визигастның гүзәл кызы Илбикәгә өйләнә. Җыелыгыз, килегез, Атилла хан өч көн, өч төн башкалада туй уздырачак. Туй Кызлар тавында башланыр. Ким куйганда йөзләрчә чатыр корылыр, һәр чатыр янында шәрабчылар, кымызчылар, ит кыздыручылар, хезмәтчеләр булыр.

Атилла хан белә иде: аның әмере карусыз үтәлер. Шуның өчен туй буласы көнне Атилла хан яшь хатыны Элиана янында булды.

— Элиана, туйда син һәр җирдә минем янымда булырсың,— диде аңа иртән уянгач та Атилла хан.

— Алпарны да алыйммы?

— Алпарны да алып килерсең. Сиңа сиртмәле арба җибәрермен. Мине кичә кинәндерделәр әле, Элиана, кияү Приск белән Таңчулпан Гунстанга килеп төшкәннәр. Күркәм хатынның кунак йортына туктаганнар. Таңчулпан әйткән, имеш, алар Дингизидның туена килгәннәр, ягъни кунакка. Мин алар-

га аерым чатыр корырга куштым. Аулаграк җиргә. Ә безнең чатыр яшь кәләш белән яшь кияү янәшәсендә утырыр, Визигаст кодага да ерак куярга кушмадым. Туй мәртәбәле булыр, халык ял итәр, бер җайдан без дә. Тик менә минем бераз угланга гына ачуым чыкты. Илбикәгә өйләнмим дип әйтми, сөйгән кызым бар дип ачуым китерә. Җитмәсә, Күркәм хатын угланны яклый. Имеш, меңбаш Барс кызы Сандугач белән алар балачактан ук бергә уйнап үскәннәр, имеш, бер-берсен балачактан ук яраталар.

— Илбикә дә чибәр ич, мин аны күрдем, кыз миңа ошады, сылу, күз алмалы түгел үзеннән.

— Сиңа ошаган, углан әнә баш тартмакчы. Ләкин аныңча булмас. Атамы мин! Атасына сырт кабарта, имеш. Сөйгән кызы бар дип мактана. Яшь чакта кем кемне яратмаган да, кем кемгә гашыйк булмаган. Гыйшык үтә ул, ә менә кешене тансыклау, аны гелән юксынып тору — әнә шунда мәхәббәтнең асылы, Элиана.

— Туй булгач, акчалар да сибелерме?

— Акчаларны Ирнак углан сибәр. Ат башында ул булыр. Визигаст король белән сөйләштек. Кызлар тавында Диңгизид углан Илбикәне куып тормас, гепидларда андый гадәт юк икән. Хуш. Кызны куып тормас. Мин Визигаст король белән килештем. Чөнки Диңгизид угланның кызны куып тотмавы бар, йә кызның тоттырмавы. Ә минем гепидлар короле белән туганлашу ачкычын кулдан ычкындырасым килми.

— Килешеп бетәрме соң, халык ни уйлар?

— Халык — судагы балык бит ул, Элиана. Килешер. Римлылар әнә тәре үбеп тә никахлашалар.

— Приск белән Таңчулпанның туйга килүләренә мин бик шат, Атилла.

— Мин аларны күрмәдем әле, әллә туйга кайтканнар, әллә Маркиан куып җибәргән. Ирештерделәр, генерал Аспар Византиядә хезмәт иткән гуннарны сарайдан куган икән, бер җайдан готларны да. Имеш, исаврәйләр белән генә сарайны саклатмакчы. Гарәпләр кебек исаврәйләр дә ташлап китәрләр әле үзләрен.

— Нигә алай дисең?

— Чөнки сәясәттә кыйблалары юк, койрыксыз төлке хәлендә хәзер Византия. Әйтте диярсең, анда тиздән бер-бер хәл булыр. Шигем бар, Таңчулпан туйга кайтмаган, явыз Маркиаңнан качып кайткан. Рим минем баш улымның башына җитте, монысы кызымны сыйдырмый башлаган кебек тоела миңа.

— Нигә алай дисең, Атилла, бәлки алар, чынлап та, туйга килгәннәрдер.

— Эчем сизә, алай түгел, туйга килгән кеше олау белән килә, ә алар ике ат өстендә, җайдак атлары да юк хәтта. Римны мин акылга утырттым, бөтен байлыгын алып кайттым, ә вандаллар короле Гейзерих, миңа калса, Римны җир белән тигезләмәсә дә, бетереп талар. Шулайрак тоела миңа. Гейзерих күптән тоҗрый иде Римны алырга.

— Византиягә кагылмый тор, ханиям. Калдыр син аларны. Бер кайгысыз туйны уздырыйк әле, аннары Маркианга түгел, Гөлсәриягә илчеләрең җибәрерсең.

— Илчеләрем җибәрермен?! Шул надан ике күзе ике төсле булган амбалгамы?! Булмас ул. Яу йөриячәкмен мин аңа, яу, Элиана...

— Янама алай, Атилла ханиям, синең кебек ханга килешми алай янау. Һәр халык та мөстәкыйль яшәргә хокуклы, кечкенәме, зурмы ул, Тәңре аларга шул хокукны биргән.

— Ни генә булмасын, мин туйдан соң Византиягә яу кузгалачакмын.

— Ә ул үзе безгә таба кузгалса?..

— Ике башлымы әллә ул? Мин беләм ич, Маркианны Константинополь халкы яратмый дип бара Вигиләй бабай да. Маркиан башына мин җитмәсәм, византиялеләр аның башына үзләре җитәчәк, ди. Мин бераз чамалыйм, Элиана, Маркиан — императрица Гөлсәрия кулындагы курчак кына ул. Беләсеңме, ни кылырга җыенган ул? Белмисең шул, ә миңа җиткереп торалар. Приск кияү белән Таңчулпанны соборда еретиклыкта гаепләргә җыенган. Әнә шуның өчен әйттем мин сиңа, туйга дип килмәгәннәр алар Гунстанга, ә Маркианнан качып киткәннәр. Әйттем ич, туйдан соң мин Маркианны акылга утыртачакмын. Сөйләштек инде, туйдан соң Визигаст король Тулузага яу кузгалачак, ә мин Византиягә юнәлермен...

— Гаскәрбаш Аспар кулында көчле гаскәр, күбесе синнән качкан гуннар...

— Мин Византиягә якыная башлауга ук, алар минем якка күчәрләр, Элиана. Гунстанда Маркиан кешеләре булган кебек, минем дә Византиядә кешеләрем бар, һәрдаим хәбәр итеп торалар.

— Кискән ипи кире ябышмый, Атилла ханиям.

Атилла хан дәшмәс булды, бертын уйланып ятты. Ниндидер күләмдә Элиана да хаклы иде. Качкын гуннарның барысы

да кайтмас. Империя кешеләрне алдый белә. Гуннар атта оста сугышалар, нәкъ шул атта сугышучыларга мохтаҗ Византия. Империя атлы сугышчыларга барлык шартларны да тудырачак. Шул сәбәпле гуннарның, Элиана әйтмешли, империядә калулары да бар икән шул. Тик бит Атиллага җиткерделәр инде, өске готлар белән аскы готлар арасында сугыш башланган. Ике туган канга-кан килерләр, алар нәселеннән булган Визигаст король әзер тәхеткә барып утырыр. Шулай да булып куюы бар бит әле. Атилла хан бераз чамалый иде, Визигаст король сәясәтне дөрес алып бара. Гомумән, әлегә барысы да ул уйлаганча юл яра. Тик менә Диңгизид углан гына кәефен бозды. Бәлки әле туйдан соң анысы да җайланыр, ут белән су да елга бер килешәләр, ди бит.

— Шулай бит? — диде Атилла хан, муены янында хатынының кайнар сулышын тоеп, аңа таба тартылды, яшь бикәне кочагына алды.

* * *

Кызлар тавына җыелган халыкның исәбе-хисабы юк иде. Атилла хан чатырыннан Алпар улын җитәкләп чыкты. Иң әүвәл ул Диңгизид улы белән килене өчен корылган чатырга күз ташлап алды. Чатыр алдында яшь кәләш Илбикә тора, аннан бер читтәрәк — Диңгизид углан. Алар ни турындадыр аңлашалар, еракган ук күренеп тора — яшьләр арасында татулык юк, ике арада бәхәс бара. Ләкин әңгәмә бара, димәк, углан бераз тынычланган, атасын аңлаган, дөньяда барган сәясәтнең асылына төшенә башлаган. Балаларны капма-каршы милләт вәкилләренә өйләндерү — ике яшьне кавыштыру гына түгел, сәясәт тә ул. Борын-борын заманнарда да ул шулай булган, хәзер дә шулай. Менә шуны аңлау җитми хәзерге яшьләргә, көчләп аңлатырга туры килә. Кызлар куу туе булмады, хәерле булсын, аның каравы кыз ягыннан килгән гепидларның күңелләре булды — Диңгизид углан кәләшен чатырына кулына күтәреп алып кереп китте. Бер уйлаганда вак кына нәрсә кебек, шул хәлгә гепидлар шау-гөр килеп куанышкач, Атиллага да күңеллерәк булып китте.

Атилла хан Алпар улын җитәкләгән килеш чатырына таба борылган гына иде, өлкән хатын Күркәм утырткан чатыр янында уралган Сандугачка күзе төште. Чибәр, сылу иде меңбаш Барс кызы Сандугач. Кошларны көнләштерерлек итеп җырлый иде. Әле дә җырлыйдыр. Тик әле җырлый микән,

еламый микән кыз. Атилла хан кызны кызганып куйды. Сәясәт корбаны иде кыз. Атилла хан аңлый иде — кызның монда мыскал да гаебе юк. Ярата Диңгизидны, үлепләр яратадыр бәлки, тик бит бу дөньяда халыклар дуслыгы да бар ич әле. Ә ул дуслык дигән төшенчә Атилла ханга бик тә, бик тә кадерле. Әйе, ата кеше буларак ул зур гөнаһ кылды, бер-берсен үлепләр яратышкан егет белән кызны аерды. Бабалары мондый хәлләргә беркайчан да бармаганнар, яратышкан яшьләрне һәрчак хуплап кавыштырганнар. Барысы да гадел булсын өчен, хәтта «Кызкуыш» уеннарын уйлап тапканнар. Бу уен бик борынгыдан килә икән инде. Бу хакта аңа Хилхәл атакай бер тапкыр гына сөйләмәде. Имеш, борын-борын заманнарда кытайлылар белән күрше яшәгән татарлар дигән кавем үзенең меңьеллык дәүләтчелеген бәйрәм иткәндә шушы олуг тантанага күрше Кушан төркиләрен кунакка чакырганнар. Ә төркиләрнең гадәтләре кунакка биш йөз кыз алып килү икән һәм үзләре белән биш йөз татар кызларын алып киткәннәр. Бермәлне бу бәйрәмне татар һәм төркиләр һәр елны уздыра башлаганнар. Һәр елны Кушан төркиләре татарларга биш йөз кыз китергәннәр һәм биш йөз татар кызы алып киткәннәр. Еллар үтә-үтә бу ике кавем шул хәлгә җитеп карендәшләшеп киткәннәр ки, икесе дә бер телдә сөйләшә башлаганнар. Әнә шул кавемнәрнең бер чаткысы булып, гун төркиләре аерылып киткәннәр һәм мөстәкыйль дәүләт булып яши башлаганнар. Әнә шул кавемнең бер чаткысы Атилла хан җитәкчелегендә Аурoпа үзәгенә килеп оялады һәм үзенә бер ил-дәүләт төзеде. Ә бит борын-борын заманнардан ук ил-дәүләтләр кызлар алышу аша оешкан. Бик ихтимал, гуннар белән гепидлар кушылып та куәтле халык килеп чыгар. Әйе, гасырлар аша булса да.

Бик ихтимал, болар барысы да Хилхәл атакай сөйләгән әкият кәнәдер, ләкин барыбер матур әкият ич. Шул ук вакытта Атилла хан белә иде, тормыш ул ачы хакыйкать, әкият исә аның хыялы гына. Угланны гепид короле кызына өйләндереп, бәлки ул хата кыладыр?.. Тик инде кире чигенү юк, югыйсә Каталун кырыннан качкан Аэцәй хәленә калуың бар. Генерал Аэцәйне Атилла хан Римга килеп киткәннән соң император Валентиан хәтта сараена да кертмәгән, диләр. Ахыр килеп, үз кавеменнән булган Сандугач та кызганыч. Сөйгән егетен тартып алалар ич. Меңбаш Барстан да яхшы түгел, соңгы вакытларда күзгә-күз карашканнары да юк. Ә бит меңбаш Барс һәр орышта алда булыр иде — батырларның батыры, каһарман-

нарның каһарманы, бер сүз белән, гун халкының горурлыгы, мактанычы. Бу адымың белән, Атилла хан, син бер аның кызын гына рәнҗетмәдең, баһадирны да рәнҗеттең. Моның өстенә меңбаш Барс Диңгизид угланның атакае, хәрби орышларга өйрәтүче остазы булды. Хата кылдың, хата кылдың бугай, Атилла хан. Әйтик, уктан алганда бәйгеләрдә Диңгизид углан гел беренчеләрдән булды, мәргәнлек бүләген ел саен ул алды. Меңбаш Барс белән аралаша торгач, күрәсең, баһадирның кызы белән дә танышкандыр углан. Яратышып киткәннәрдер... Диңгизид углан чираттагы Кызлар туенда Сандугачны куарга җыенгандыр, шул хакта хыялланып, кыз белән егет, һәр көн булмаса да көн аралаш, яшьләр белән Кызлар тавына кичке уеннарга чыкканнардыр...

Юк, кылган гамәле өчен үкенү түгел иде бу. Атилла хан бу уй сөреше белән үзен үзе акларга гына теләде, ә эчке бер хисе исә: «Син хаклы, хаклы, хан!» — дип тәкрарлады. Бер сүз белән, башына әнә шуңа охшаш уйлар килсә дә, Атилла бер дә үкенү тоймады, тирәнгәрәк төшеп уйлаганда, ул хаклы иде. Әйе, дөрес эшләде ул, бик дөрес хәтта. Визигаст король белән берләшү, кардәшләшү аңа кадерлерәк, заруриятрак иде.

* * *

Туй кояш чыга башлауга ук гепидлар ягыннан башланды. Сөйләшү буенча яшь кәләшне кияү егеткә гепид егетләре Кызлар тавына килер юлда ук тапшырырга тиешләр иде. Шулай иттеләр дә. Диңгизид углан, үз ишләре белән сиртмәле арбага утырып, гепидларга таба кузгалды һәм кисәк алдан корган яшь кәләш чатырына таба җилле генә чаптырып китте. Кинәт кенә төрле чүпрәк-чапракка төренгән гепид егетләре кияү арбасын уратып алдылар. Кияү егет арбадан янәшә барган атына күчмәкче итте, ләкин моны кылырга аңа бирмәделәр, кайсы күлмәк җиңен тартып өзеп алды, кайсы итеген салдырды, кайсы баш киемен йолкып алды. Әмма шунда гепид егетләренә энесе Ирнак углан уч-уч тәңкәләр сибә башлады. Кияү егетен уратып алган гепид егетләре чылтырап коелган акчаларны җыярга ташландылар. Шул мәлдән файдаланып, кияү егет атына сикереп атланды һәм кыз чатырына таба чапты. Моны сизми калган гепид егетләре ай-вай кilә-килә аны куа киттеләр. Ләкин соң иде инде, ул арада егет кыз чатырына җитте һәм күп тә үтми өс-башын алыштырып, көяз кияү егете кыяфәтендә яшь кәләшен кулына күтәреп чатырдан чыкты һәм кәләшен ат сыр-

тына салды да далага чыгып чапты. Әмма ерак китмәде, кызны алдына утырткан килеш, алдан корып куелган чатырга юнәлде. Әмма гепид егетләре аңа аркылы төштеләр, иярдән кызны тартып алмакчы иттеләр. Диңгизид аларга көмеш акчалар сипте, яулыклар, хәнҗәрләр ташлады, гепид егетләре, ташланган бүләкләргә алданып, кияү егетне янә кулдан ычкындырдылар. Чатырга җитәрәк кияү егете атыннан төште, кәләшен иярдән суырып алды да, кулына күтәреп, чатырына алып кереп китте.

Кияү егете кызны чатырга алып кереп киткәч кенә, барысы да туктап калдылар һәм җырлый-бии башладылар, аларга көйчеләр кушылдылар, китте күңел ачу...

Боларның барысын да чатыры янында күзәтеп торган Атилла хан күрше чатырга урнашкан кодасы Визигастка кул болгады. Ул шат иде, үз дигәненә иреште, күрде ич, король дә булган хәлдән канәгать иде, янындагы кунаклар бииләр, җырлыйлар, күңел ачалар. Ул Атилла ханга кул изи, янына чакыра. Әмма Атилла хан кузгалмый, сабыр итәргә тиеш ул беразга, кияү егет яшь кәләшнең эчке күлмәген чатырдан чыгып болгарга тиеш. Атилла хан сабыр итә белә иде, ул моңа балачактан ук өйрәтелгән. Атилла хан Күркәм хатын чатыры ягына күз ташлады. Күркәм хатын үтә бәйрәмчә киенгән, башында асылташлар белән бизәлгән очлаеп килгән башлык, озын һәм киң җиңле күлмәге яшел-сары төстә, итәкләре итек башларын каплый хәтта. Күр әле, Күркәм хатын янында Айгөл апасы. Ишеттерделәр Атилла ханга, ул да Диңгизидны Сандугачка өйләндерү ягында булган, хәтта бу хакта кеше аша булса да Атиллага да ирештерде. Әмма Атилла кырт кисте: «Диңгизид углан Визигаст корольнең кызы Илбикәгә өйләнә. Мин әйттем!» — диде.

Бүген исә кызның хәленә керергә теләпме, Айгөл апа Сандугач янында басып тора, кызның колагына нидер әйтә, тынычландырырга тели булса кирәк. Тынычландырып торасы юк, кылынасы кылынды инде. Әгәр дә мәгәр Атилла хан хатынкыз сүзен тыңлаган булса, әле булса Өрәк елгасы буенда тулганыр иде. Ә хәзер Аурупа үзәгенә әнә нинди кала күтәрде.

— Элиана, Элиана дим, чык әле бире, чык әле,— диде Атилла хан бала белән сөйләшеп торган яшь хатынына.— Күр әле боларны, Күркәм хатын белән Айгөл апамны дим. Теге кызны юаталар.

Чатырдан бәйрәмчә киенгән Элиана чыкты.

— Ни булды?

— Диңгизид кулына күтәреп, кәләшен чатырга алып кереп китте, күрми калдың. Сандугач үз-үзенә урын табалмый.

Элиана әле Күркәм хатын, Айгөл бикә, Сандугач басып торган якка, әле яшьләр чатыры тарафына күз төшереп алды да:

Каты бәгырьле дә соң бу ир-ат. Берәүнең сөйгән егетен тартып алганнар, хан кадәр хан кинәнә. Беләсең килсә, мин дә беләм, Сандугач Диңгизидны үлепләр ярата иде, Диңгизид та кызны киләсе Кызлар туенда куам дип кинәнеп йөри иде... Синнән куркып кына өйләнде углан Илбикәгә. Ят ул аңа, ни теле, ни холкы белән сезнең өчен ят нәселдән.

— Иң мөһиме чибәр, сылу, зифа.

— Матурлык туйда гына кирәк ул, ханиям. Яши башлагач һәрнәрсәгә башка күзлектән карый башлыйсың.

— Тик тор, Элиана, ир-ат булса Сандугачка да өлгерер.

— Беренче хатын беренче хатын инде, сезнең халык беренче хатын балаларына өстенлекне бирә. Аннары Сандугачның үч итеп башка берәүгә тоттыруы да бар.

— Карале, Элиана, Приск белән Таңчулпан нигә күренмиләр?

— Алар далага чыгып киттеләр. Яшьлекләрен искә төшереп.

— Кулай шәй, мактыйм. Ләкин минем аларны да туйда күрәсем килгән иде.

— Аларның үз кайгылары үзләренә бик җиткән, ханиям. Тимә аларга. Үз җайлары белән кайтырлар.

— Кайсы ягың белән тордың син бүген, Элиана?

— Уң ягым белән, уң ягым белән, ханиям. Хәтереңдәме, син миңа Алпар угланың Византиягә укырга җибәрәм дип әйткән идең?

— Ышандырдым. Һәм җибәрермен дә. Вигиләй атаң алып барыр угланны. Кирәк кадәр акчасын бирербез, барыр, карар, укытыр.

— Сандугач тәмам үз-үзенә урын табалмый, бичаракай бала.

— Куй әле шуны. Эш узган ич инде.

Ул арада кияү егет кәләшенең эчке күлмәген чыгарып болгады.

Кемнәрдер урра кычкырдылар, ауман-тәүмән килә-килә җырлый башладылар. Кияү егет күлмәкне болгады-болгады да җиргә ташлады һәм Сандугач басып торган чатыр ягына карап туктап калды. Атилла хан угланга йодрык күрсәтте.

— Тәмам көчләп өйләндерден угланны,— диде Элиана.

— Көчләп түгел, Элиана. Көчлене көчләмиләр, ә мәҗбүр итәләр. Бүген углан егылып үлсә дә, Илбикә янында булыр. Үзем саклап торачакмын. Төне буена. Бар нәрсә дә куелгандыр бит анда?

— Куелды, барысы да хәстәрләнде, шәрабы да, җиләк-җимеше дә.

— Шәрабның ниндиен куйдыгыз?

— Иң зәһәрен, атам хәстәрләде.

— Яхшы,— диде Атилла хан һәм Алпар улын җитәкләде дә шау-гөр килгән яшьләргә таба китте. Аларга теләр-теләмәс кенә Элиана иярде.

Күп тә үтми туй буласы урынга яшь кәләш белән яшь кияү килделәр. Китте уен-көлке, җырлау-бию. Яшьләр әле куышып уйнадылар, әле әйлән-бәйлән, әле гун яшьләре, әле гепид яшьләре җырладылар, биеделәр. Атилла хан улы Алпарны җитәклəгән килеш бу хәлгә карап-карап торды да янә чатырына таба кузгалды. Кәефе юк иде ханның. Күрде ич ул, углан да, булачак килене дә баш күтәреп тә аңа карамадылар. Сандугач, гомумән, яшьләр янына килмәде. Атилла хан саксыз йөрде, ул әле җор телле, шаян сүзле төркемнәр яныннан узды, такмак әйтүчеләр каршында басып торды, бәйге уздыручыларны күзәтте. Әмма күңел күзе угында һәрдаим Диңгизид углан, Илбикә, Сандугач булды.

Шул мәлдә мәйдан уртасына шамакай чыгып басты, ул әле гун, әле гепид, әле гот телендә мәзәкләр әйтте, халыкны көлдерде. Бәйрәм итү кояш баеганчы дәвам итте. Барысы да корылган чатырларына таба кузгалдылар. Атасы күз алмый күзәтеп торгангамы, чатырына җитәрәк Диңгизид кәләшен кулына күтәрде һәм эчкәре алып кереп китте.

Боларның барысын да күз алмый күзәтеп торган Атилла хан кылган эшеннән канәгать калып, улы Алпарны җитәкләгән килеш, Элиана хатынын ияртеп, үз чатырына юнәлде. Чатырга керер алдыннан Атилла хан янә Күркәм хатынга корылган чатыр ягына күз ташлап алды. Чатыр каршында берәү дә юк иде. Атилла хан йөреп түгел, ниндидер эчке бер киеренкелектән арыган, алҗыган иде, чатырга керүгә, сузылып йомшак тирегә ятты, күзләрен йомды.

Хан күңеленә борчулы шикне үз кырына килеп яткан Элиана салды.

— Мин куркам, Атилла, Диңгизидның яшь кәләшен ташлап, Сандугач янына китүе бар...

Шуңа охшаш шик-шөбһә менә ничәмә көн аның күңелен бимазалап тора иде инде һәм бу хакта берәүгә дә әйтергә кыймый йөри иде, яшь хатыны арыкны гүя ерып җибәрде. Хан яткан җиреннән сикереп торды, тиз-тиз камчысын, ни өчендер хәнҗәрен барлады, кылычын такты. Хатыны аңа аптырау аша исе китеп карап торды.

— Кылыч нигә тагын?

— Сакчыларым юк, кайтарып җибәргән идем.

— Әллә соң, ханиям?.. Яшьләр чатырына барырга исәбеңме?.. Балигъ улыңа ышанмыйсыңмы? Бу ни инде тагын, хан башың белән. Дивана түгел бит инде ул, яшь кәләшен ташлап, Сандугач янына чыгып китәргә, мин болай гына әйткән идем. Йөрмә кеше көлдереп, ханиям?!

— Тыйма, Элиана. Барам. Чын булып чыга кала икән...

— Мәхәббәт белән акыл түгел, йөрәк идарә итә, ханиям, йөрәк!

— Син мине шиккә калдырдың, Элиана, син! Беләм, Күркәм хатынны яратып бетермисең. Ләкин әйткәнең чын булып чыкса, углан Атилла ханны бөтен дөнья халкы алдында хур итсә?!

— Йөрәккә йөгән салып булмый, ханиям. Китсә китәр. Тимә син аларга. Калдыр, яшә үз җаең белән. Хан ич син, хан!..

— Нәкъ менә хан булганга борчылам да мин, Элиана. Киләчәктә ил белән идарә итә торган угланнар ич алар. Сәясәтне — мәхәббәттән, мәхәббәтне сәясәттән аера белмәгән угланга кем ил дилбегәсен ышандырып тапшырсын. Зиһене саф, йөрәге таш кеше генә ил белән идарә итә ала. Хак әйтәсең, йөрәккә йөгән салып булмый, атасы димләгән кәләш кочагыннан чыгып китә икән углан, ул минем өчен углан түгел!..

Түзмәде, йөрәге тәмам кабарудан чарасыз калып, чатырдан чыкты һәм күршедәге чатырга бакты. Күк гөмбәзенә күз төшереп, гүя Тәңресе белән киңәшеп алды һәм зур-зур адымнар белән угланга һәм аның яшь кәләшенә махсус корылган чатырга таба китте. Кай тарафтадыр тырышып-тырышып тартай кычкыра, ул да түгел, тартайга ияреп диярлек байгыш ухылдап куя. Килеп җитәр-җитмәс ишетте: чатырда кемдер елый, сыктый хәтта. Ул белми иде әле, әгәр дә мәгәр, чынлап та, углан кәләшен ташлап, Сандугач янына киткән булса ни кыласын, берни белми иде, ләкин кулындагы майда кайнатылган камчының сабын кысыбрак тотты, хәтта бер кулы белән Тәңре кылычына кагылып алды. Чатырга якыная барган саен, шыңшып елау ачыграк ишетелде. «Тукта! — дип тыярга теләде ул үзен.— Бәлки, берни дә булмагандыр. Яшь кәләш углан коча-

гында ятадыр. Әгәр дә мәгәр шулай булса, ничек барып кермәк кирәк чатырга?!»

Туктады, йөрәк тибешен колак түрендә үк ишетеп, бермәл янә тыңлап торды. Чү, чынлап та, кемдер елый түгелме соң? Аннары сөюдән туган шатлык яше вә авазы түгел бу, моны гына Атилла хан белә иде. Шыңшу туктады. Шиге сүрелә төште, борыласы итте, әмма кузгалмады. Ә йөрәк күкрәк челтәрен ертып чыгардай булып тибә, баш шаулый, колакларда — тоташ ургылып аккан тау елгасы шавы.

Юк, ул моны үз күзе белән күрергә тиеш.

Тәвәккәлләде. Кузгалды. Чатырга җитте, япманы ачты. Узды. Һәм үз күзләренә үзе ышанмады. Түр яктагы җофар тиресе җәйгән тактада яшь кәләш шыңшып елап утыра, ул инде үксеп беткән, шунда ук кечкенә өстәлдә бер бокал тәгәрәп ята. Икенче мөлдерәмә шәраб тулы бокал өстәлчектә тора. Өстәл тулы ризык-нигъмәт.

Башта борылып чыгып китәсе итте, йомшак җофар тиресе җәелгән такта ятакта чәчләрен туздырып елап утырган килене аңа ошамады. Бәхет өчен шулай көрәшәләрме?! Бәхет ул — көрәш, көрәш исә — мәхәббәт! Саф мәхәббәт өчен асыл затлар утка ташланганнар! Утка?!

Атилла хан әкрен генә кыз янына килде, бер тезенә төште, булачак киленнең иягеннән тотып, башын күтәрде, күзләренә карады.

— Килен, Диңгизид углан кая?

Яшь кәләш башын чайкады, күзләрен күтәреп карамады, бер сүз әйтми, кисәк янә үксергә тотынды. Атилла хан өстәлдә янып торган шәмдәлләргә игътибар итте, каршы яктагы чатыр чүпрәгенә төшкән шыксыз күләгәләр уйнаша, шыксыз хәрәкәтләр ясыйлар. Атилла хан шәраб тулы бокалга үрелде, бер күтәрүдә эчеп куйды. Идәндә аунап яткан бокалны да алды да икесен янәшә куеп, кувшиннан икесенә дә мөлдерәмә тутырып шәраб салды.

— Тот! — диде ул, боерган рәвештә коры гына.— Тот бокалны!

Килен буласы кеше теләр-теләмәс кенә кулына бокалны алды, хәтта угланның атасы белән чәкешкәндәй итте. Атилла хан икенче бокалны күтәреп эчеп куйды. Аңа эчәргә ярамый иде, табибы аңа һәрчак кисәтеп торды. Ләкин аны бүген иң яраткан угланы чарасыз итте — атасына хыянәт итте, аңа, атасына, мәргән угылы!..

Ул көмеш кувшиннан тагын-тагын шәраб койды, тагын-тагын күтәреп эчеп куйды. Никадәр мәгънәсезлек. Бит аңа эчәргә ярамый, шәраб түгел, хәтта кымыз да, ә ул бокал артыннан бокал. Аз гына эчсә дә авыз-борыныннан кан китә торган иде, ә монда бокал өстенә бокал. Никадәр мәгънәсезлек!

— Син дә эч, балакай, эч-эч! — диде Атилла хан, чираттагы бокалны аңа сузып.— Эч, балакай. Кайгырма. Минем өченче улым бар. Телисең мин сиңа үзем өйләнәм? Ә?!

Хан шулай диюгә, булачак килене аңа елаудан кызарынып беткән күзләре белән карап алды һәм елмаерга тырышты бугай, әмма ни елмаю, ни елау килеп чыкмады, кыз кинәт башын түбән иде.

— Миңа беркем дә кирәкми, хан...

— Кирәк, кирәк, балакай, ки-и-ир-әк...

Атилла ханның кинәт сулъяк яңагы тартышып куйды һәм ул, авызын зур ачып, сулышы җитмәүдән интеккән берәүдәй бермәл торды да, йомшак җофар келәменә тәгәрәп китте. Ул арада чатырга Элиана йөгереп килеп керде.

— Атилла, Атилла ханиям, бәгырь, ни булды? Ни бирделәр сиңа?

Яшь хатын Атилла ханның битләрен учларына алды, акайган күзләренә карады.

— Элиа-н-а, А-л-п-а-р-н-ы...

Атилла хан уң кулын күтәрмәкче итте, әмма кулы кинәт сынып киткәндәй кире идәнгә төште.

— Табибны, табибны дәшегез! — дип яшь аралаш кычкырды чатырга кереп килгән җансакчыга Элиана.— Табибны китерегез, хан үлә!

Ул аның яңакларына суккалады, идәндә яткан кулын алып яңагына кысты. Шулчак Атилла хан күзен ачты һәм ап-ачык итеп:

— Кичер мине, Элиана, ялгыштым,— диде. Икенче мәлдә инде типсә тимер өзәрдәй 58 нче язына яңа аяк баскан гуннар ханы Атилла тынып калды.

Бу хәл милади белән 453 елның ямьле җәй аенда булды.

— Һәм шул сан белән Мәңгүк хан улы Атилла ханның үлеме дә Аурупа тарихына кереп калды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Атилла ханның тәхете җыйнак булуы аның нинди сыйфаты турында сөйли?

2. Атилла нинди телләрне белә?

3. Хан мәҗлесендә музыкантлар нинди уен коралларында уйныйлар? Шуларны санагыз.

4. Соңгы айларда Атилла ни өчен тынычлыгын тәмам югалта? Бу хәлнең сәбәпләрен әйтеп бирегез.

5. Атилла ни өчен үзенең улын Визигаст король кызына өйләндерергә була?

6. Атилла фикеренчә, ил белән нинди кеше идарә итә ала?

7. Атилла кайсы елны ничә яшендә үлә? Аның үлеменең сәбәбен автор ничек аңлата?

8. Атилланың тарихтагы роле турында әңгәмә үткәрегез.

9. Атилланың безнең ерак бабабыз булуын М. Хәбибуллин бу әсәрендә ничек нигезли?

«Атилла» романы

Совет чорында татар тарихы вакыт ягыннан шактый чикләп һәм берьяклырак аңлатылды. Һәм 50 нче еллар урталарыннан илдә сүз ирегенә күпмедер юл ачыла башлау белән үк, безнең әдипләр әлеге тарихи гаделсезлекне юкка чыгарырга, ягъни халкыбыз тарихының моңа кадәр рәсми төстә күләгәдә калдырылган яки бик каралтып бәяләнгән дәверләрен яктыртырга алындылар. Биредә татар халкының килеп чыгышын дөресрәк өйрәнү бурычы да алга куела иде. Бу милли-тәкъдири әһәмиятле мәсьәләне объективрак хәл итүгә тарихчы галимнәрдән дә алдарак алынган әдипләр арасында башлап йөрүчеләрнең берсе М. Хәбибуллин булды. Ул үз иҗатында Казан ханлыгы чорыннан алып тарихыбызның тагын да борынгырак, легендар дәверләренә мөрәҗәгать итә. Аның шушы юнәлештәге эзләнүе булып «Атилла» романы тора. М. Хәбибуллинның бу әсәрен язарга алынуы V гасырның беренче яртысында кешелек тарихындагы атаклы Һун империясен төзегән Атилланың безнең ерак бабабыз булуын ачыклавы белән бәйләнгән. Романда шул дәвернең киң тарихи фонында һәм халыкларның бөек көчеше үзәгендә сурәтләнгән Атилланы мәшһүр полководец һәм сәясәтче итеп күрсәтү белән бергә, аны адәм баласына хас гадәти уй-кичерешләр белән яшәгән җанлы шәхес итеп сурәтләүгә дә киң урын бирелә. Идел буеннан Альп тауларына кадәрге гаять зур территорияне колачлаган ил мәнфәгатьләрен

кайгырту белән бергә, әсәр герое, гадәти ата кеше буларак, үзенең гаиләсе хакында да күп уйлана. Автор Атилла ханның 453 елда 58 яшендә кинәт кенә үлеп китүен дә улы Диңгизидның гадәт буенча әтисе тәкъдим иткән кызга өйләнергә теләмәвенә борчылуы белән бәйләп аңлата. Куәтле илбашы һәм кайгыртучан гаилә башлыгы булып алга баскан Атилла турындагы әсәр, гомумән алганда, татар тарихының легендар дәверен сурәтләү белән бергә, бик ерак бабаларыбызның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, уй-омтылышларын да чагылдырып, халкыбызның килеп чыгышын сәнгатьчә яктыртуга да мәгълүм бер өлеш кертә.

1960—2000 ЕЛЛАР ДРАМАТУРГИЯСЕ

XIX йөзнең соңгы чирегендә беренче адымнарын ясаган татар драматургиясе, әдәбиятның бер төре буларак, һәрвакыт халык мәнфәгатен күздә тотып, аның рухи-әхлакый ихтыяҗына җавап биреп килде. XX гасырның 60—80 нче еллар сәхнә әдәбияты чор һәм җәмгыять белән бергә үсеп-үзгәреп яши. Шул еллардагы хәбәрдарлык һәм демократия күренешләренең уңай тәэсирендә татар драматургиясе җитди үзгәрешләр юлына чыга. Сәхнә әдәбиятын әйдәп баручы өлкән буын драматурглар Н. Исәнбәт, М. Әмир, Р. Ишморат, Г. Насрый һ. б. янәшәсендә Х. Вахит, Ю. Әминев, Ш. Хөсәенов, З. Шаһиморатов, С. Шәкүров, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Ә. Баянов, И. Юзеев, Р. Мингалим кебек әдипләр иҗатка килә. Соңрак аларга Р. Хәмид, Ә. Гаффар, Ф. Садриев, Р. Батулла, Ю. Сафиуллин һ. б. килеп кушыла.

Драматурглар, сәхнә закончалыкларын тирәнрәк үзләштерә барып, сурәтләүнең төрле чара-формаларына иркенрәк мөрәҗәгать итәләр. Шартлылык алымнарына, символларга нигезләнү, бер яктан, әсәрдәге төп идеяне тулырак ачуга мөмкинлек бирсә, икенче яктан, укучы-тамашачыга эмоциональ йогынты ясауга, аның хис-кичерешләрен кузгатуга, сурәтләнгән вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдерүгә этәрә. Бу чор сәхнә әдәбиятының төп яңалыгы тормышчан конфликтка йөз тоту белән бәйле, ул, яшәешнең төрле якларына мөрәҗәгать итеп, тема һәм проблема киңлегенә омтыла. Т. Миңнуллинның «Кырларым-тугайларым», А. Гыйләҗевнең «Хушыгыз, тургайлар», Р. Хәмиднең «Синең урыныңа кайттым» пьесаларында авыл-колхоз тормышы, гаилә-көнкүреш мәсьәләләре, хезмәткә караш тормышчан ситуацияләрдә, кызыклы интрига аша бирелүе белән җәлеп итә. Драматурглар мөрәҗәгать иткән темаларның берсе булып мәктәп тормышын, укытучы хезмәтен төрле яклап ачу тора. Иң уңышлы үрнәкләре белән Х. Вахит («Мәхәббәтең чын

булса»), Т. Миңнуллин («Үзебез сайлаган язмыш») иҗатында очрашабыз.

Яшь кешенең шәхес буларак формалашуы, зур тормышка килүе мәсьәләләре драматургларыбызның даими игътибар үзәгендә тора. Әлеге проблемаларны яшьлек, дуслык, мәхәббәт, хезмәткә мөнәсәбәт һ. б. сораулар белән тыгыз бәйләнештә тасвирлаган пьесалардан Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт», «Туй алдыннан», Т. Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне», «Ак тәүбә, кара тәүбә» һ. б. укучы-тамашачыларның мәхәббәтен казана. Татар әдәбияты даими мөрәҗәгать итеп килгән әхлакый мәсьәләләрнең берсе булган ата-ана һәм бала мөнәсәбәте гаилә ныклыгы, милләт киләчәге белән бәйләп карала. Бу елларда урбанизация йогынтысында кечерәк авыллар таркалу, бетүгә йөз тота башлый. Шәһәрләшүгә бәйле яшәешкә чит гореф-гадәтләр үтеп керү, ата-ана белән бала, туган белән туган арасында каршылыклар, үзара аңлаша алмау күренешләре әдипләрне дә тирәнтен борчый. Шуңа нисбәтле әлеге мәсьәләләр бөтен кискенлеге белән куелган күп санлы әсәрләр дөнья күрә: Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары», Ш. Хөсәеновның «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде»), А. Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош», Р. Батулланың «Кичер мине, әнкәй» һ. б.

Замандашыбызның бай эчке дөньясын, рухи кичерешләрен әдәп-әхлак мәсьәләләренә нигезләнеп сурәтләгән (Ш. Хөсәенов «Зөбәйдә — адәм баласы», А. Гыйләҗев «Көзге ачы җилләрдә», «Әгәр бик сагынсаң»), нык ихтыярлы, зур хыяллар белән, үзенең, гаиләсенең, милләтенең язмышы өчен борчылып яшәүче геройларны үзәккә алган (Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар»ында Мәдинә, «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә Әлмәндәр, И. Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә»сендә Хәмзин һ. б.), каршылыклы тарихыбызның аерым вакыйга-күренешләрен билгеле шәхесләрнең әдәби образлары аша чагылдырган (Н. Фәттах «Кол Гали», Т. Миңнуллин «Канкай углы Бәхтияр», «Моңлы бер җыр») әсәрләр бу чор татар драматургиясендәге эзләнүләрнең юнәлешен, әдәби-эстетик табышларын билгели.

Сайлап алынган тормыш материалына, конфликт характерына бәйле бу чор сәхнә әдәбиятында түбәндәге жанр һәм жанр формалары күзәтелә: *тарихи-биографик драма* (Т. Миңнуллин «Без китәбез, сез каласыз»), *монодрама* (Р. Хәмид «Олы юлның тузаны»), *социаль-психологик драма* (Ш. Хөсәенов «Әниемнең ак күлмәге»), *публицистик драма* (Ә. Гаффар «Килер бер көн»), *интеллектуаль драма* (Т. Миңнуллин «Дуслар

җыелган җирдә»), *мелодрама* (Батулла «Кичер мине, әнкәй»), *лирик комедия* (Р. Мингалим «Кунак кызы гел килмәс»), *иҗтимагый комедия* (А. Гыйләҗев «Көттереп искән җил»), *сатирик комедия* (Р. Вәлиев «Әй машина, машина»), *водевиль* (Т. Миңнуллин «Диләфрүзгә дүрт кияү»), *моңсу комедия* (И. Юзеев «Сандугачлар килгән безгә»), *музыкаль комедия* (Р. Батулла «Сөйгән ярым ятка кала»), *трагикомедия* (Ш. Хөсәенов «Зөбәйдә — адәм баласы»), *трагедия* (А. Гыйләҗев «Өч аршын җир»), *тарихи трагедия* (Н. Фәттах «Кол Гали») һ. б.

XX гасырның 80 нче еллары уртасында башланып киткән үзгәрешләр татар драматургиясенә дә җитди йогынты ясый. Бу чор сәхнә әдәбиятында Т. Миңнуллин, И. Юзеев, А. Гыйләҗев, Ә. Баян, Р. Батулла, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ф. Садриев кебек үз иҗат йөзләре белән танылган драматурглар янәшәсендә Ә. Гаффар, Ф. Бәйрәмова, Ф. Яруллин, Ю. Сафиуллин кебек авторлар драматургик процесска көчле йогынты ясый. Хәзерге драматургиядәге сан һәм сыйфат үзгәрешләре 80 нче еллар ахырында сәхнә әдәбиятына килгән язучылар З. Хәким, Г. Каюмов, Д. Салихов, Р. Сәгъди, М. Гыйләҗев, Аманулла, Р. Зәйдулла, Ф. Галиев һ. б. иҗаты белән дә бәйле.

Татар драматургиясе, бөтен сүз сәнгате кебек үк, халык тормышындагы сорауларга җавап бирүне, аның рухи ихтыяҗларын үтәүне максат итеп куйды. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә сәхнә әдәбиятында күзәтелгән яңалыкларның берсе тематик төрлелек белән бәйле. Заман сорауларына нисбәтле электән килгән, еш кына мәңгелек темалар булып саналган сораулар чор мәсьәләләре белән кушылып, үрелеп китә һәм тема-мотивлар булып алга чыга. Аларның иң мөһиме — милләт язмышы. Халкыбызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән кызыксынуга бәйле, аның төрле этник катламнары яшәешен әдәби сурәтләрдә тасвирлаган Т. Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре», «Йөрәк маем» комедияләре, дөнья буйлап сибелгән милләттәшләр язмышының фаҗигале якларын ачкан И. Юзеевнең «Ак калфагым төшердем кулдан...» драмасы әнә шундыйлардан. Милләт язмышы яшәешнең төрле якларын иңләп ала. Шуңа да авторлар сайлап алган тормыш материалы да күптөрле. Әгәр Т. Миңнуллин «Илгизәр плюс Вера» драмасында катнаш никах мәсьәләсен әхлакый-иҗтимагый проблема буларак күтәрсә, З. Хәким «Телсез күке»сендә халыкны милләт итеп яшәткән телмоң төшенчәләренә мөрәҗәгать итә. Морзалар катламының

фаҗигале язмышына бәйле халыкның үткәне-бүгенгесе, гореф-гадәтләр саклануы турында уйлану буларак язылган Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә»се киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятып, матбугатта җитди сөйләшүләргә юл ачты.

Данлы һәм фаҗигале тарихыбызның аерым сәхифәләрен күз алдына бастырган әсәрләрдә (Р. Хәмиднең «Хан кызы» трагедиясе, Р. Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» тарихи риваяте, Н. Фәттахның «Сармат кызы Сәринә» тарихи драмасы) шул чор вакыйгалары аша хәзерге заманны фәлсәфи планда аңлау омтылышы ясала. Күренекле шәхесләрнең әдәби образларына Ә. Гаффарның «Соңгы сәгать», Батулланың «Сират күпере», Ф. Бәйрәмованың «Атылган йолдыз» пьесаларында мөрәҗәгать ителә. Һ. Такташның әдәби образы үзәккә алынган «Атылган йолдыз» драмасында, шәхес һәм җәмгыять каршылыгына бәйле, XX гасырның 20 нче еллары шагыйрен шул чорның әдәби-иҗтимагый мохите кысаларында ачу максат итеп куела.

Бүгенге сәхнә әдәбиятында кеше шәхесенә игътибар арту күзәтелә. Заман алып килгән үзгәрешләр алдында кешенең еш кына көчсез булуы, җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үзе һәм әйләнә-тирәсендәгеләр белән каршылыкка керүе дә драматурглар игътибарыннан читтә калмый. Әлеге проблемалар Р. Хәмиднең «Олы юлның тузаны», «Диде кардәш», И. Юзеевнең «Гашыйклар тавы», Т. Миңнуллинның «Сөяркә» һ. б. әсәрләрдә тулы чагылыш таба.

Драматургиядәге үзенчәлекләрнең тагын берсе аерым авторларның әдәби-эстетик эзләнүләре белән бәйле. Соңгы елларда шартлылыкка, символик образ-сурәтләргә, метафорик күренешләргә игътибар аеруча артты. М. Гыйләҗевнең «Бичура», «Баскетболист», З. Хәкимнең «Кишер басуы», «Шайтан куентыгы», Д. Салиховның «Алла каргаган йорт», Аманулланың «Әлепле артистлары» һ. б. әсәрләр милли эчтәлекне традицион булмаган алым-чаралар ярдәмендә чагылдырулары белән үзенчәлекле.

XX гасырның 80 нче елларында барган әфган сугышы, 90 нчы еллар уртасында башланып киткән чечен сугышы Россия халкына әйтеп бетергесез бәла-каза алып килде.

Ю. Сафиуллин «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедиясендә сугыш вакыйгаларының, кайтаваз буларак Татарстан җиренә килеп, кеше язмышларына гаять зур йогынты ясавын сурәтли. Пьеса үзәгендә чечен сугышы дәһшәтләрен үз күзләре белән күргән

фаҗигале язмышлы геройлар. Бер якта, Россия армиясендә командир боерыгын үтәп, чечен авылларын җимергән, кулларына корал тотып каршылык күрсәтүчеләргә генә түгел, бәлки хатын-кыз һәм бала-чагаларга каршы да танк белән барган Линар белән Рәсим, икенче якта, йорт-җирләрен генә түгел, сөйгәннәрен дә югалтып, туган иленнән качып китәргә мәҗбүр булган Хания белән Разия тора. Драматург трагик конфликт аша сугыш афәтен, аның аерым шәхесләргә китергән бәла-казасын тулы ачуга ирешкән. Линар белән Рәсимнең психологик тотнаксызлыгында, җан бәргәләнүләрендә җәмгыять, ил тарафыннан онытылган, читкә кагылган «югалган буын» язмышы күзаллана. Алар үзләренең гөнаһларын беләләр, боерыкны үтәргә мәҗбүр булуларына бәйле ярлыкау тиешлеген дә аңлыйлар, әмма гөнаһсыз кешеләрнең кан-яшьләрен оныта алмый газапланалар. Рәсим әлеге халәтен җиңеп чыга алса, Линарның бәргәләнүләре үлем белән тәмамлана. Чечен фаҗигасе Линарны үз туган җирендә дә эзләп таба һәм чираттагы корбаны итә. Әлеге яшь геройлар язмышы укучы-тамашачы тарафыннан ил, халык драмасы буларак күзаллана. Ю. Сафиуллин пьесасы белән Линар һәм Рәсим кебекләргә мәрхәмәтле булырга, аларны гаепләргә түгел, ә аңларга чакыра.

Гомумән, хәзерге татар драматургиясе эзләнүләр юлында. Әдипләр халкыбыз каршындагы зур җаваплылыкны тоеп, аңлап иҗат итәләр. Шундыйлар арасында **Рабит Батулла** (Роберт Мөхлис улы Батуллин (1938 елда туган) иҗатына аерым тукталып үтик.

Р. Батулла әдәби иҗатка хикәяләр аша килә. Аннан ул әкият жанрында актив эшли башлый. «Исемем минем Дүрткүз», «Куян баласы Нуяк», «Үлемсез егет», «Ташсуар патша» һәм аеруча «Алып батыр» әкиятләре белән ул балалар язучысы булып таныла. Курчак театрлары аның әсәрләренә бик теләп мөрәҗәгать итә.

Р. Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк», «Сөембикә», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» әсәрләре китап укучылар тарафыннан шатланып каршы алына. Соңгы ике әсәре өчен ул 2006 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Әдип сүз сәнгатенең драматургия төрендә дә уңышлы иҗат итә. Төрле елларда язылган «Кичер мине, әнкәй», «Өчәү чыктык юлга», «Туйлар узгач», «Сират күпере», «Мин Америка ачтым» кебек пьесалары белән ул әйдәп баручы драматурглар рәтенә баса. Соңгы елларда иҗат ителгән «Ана каргышы», «Җи-

мерелгән бәхет» әсәрләре «Яңа татар пьесасы» конкурсларында уңыш казанды.

Р. Батулла озак еллар дәвамында халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның шәхесен, тормышын, иҗатын өйрәнә, күп санлы истәлекләр белән таныша, архив материалларына мөрәҗәгать итә. Нәтиҗә буларак, шагыйрьнең фани дөньядагы соңгы көннәрен чагылдырган «Сират күпере» драмасы дөнья күрә. Әлеге әсәр Тукайны шәхес һәм шагыйрь буларак аңларга омтылуның иң уңышлы үрнәкләреннән берсе булып таныла. Автор Тукайны үз халкының бөек улы буларак ачуга ирешә.

Р. Батулланың **«Кичер мине, әнкәй»** (1979) пьесасы аеруча гыйбрәтле мәсьәләне — ялгыз ана, ятим бала тормышын үзәккә алуы белән аерылып тора. Ике пәрдәле драма 16 яшьлек егет белән кызның төртмәле, мәзәкчән, хәтта бераз гаҗәбрәк диалогы белән башланып китә. Әкренләп укучы-тамашачы каршында әнисе белән генә яшәүче Миргаянның характер сыйфатлары оеша башлый. Кешенең шәхес буларак формалашуында яшүсмерлек чоры мөһим роль уйный. 16—17 яшьлекләргә кискенлек, принципиальлек, артык горурлык, үз «мин»ен еш кына югары кую, гаделсезлекне авыр кичерү хас. Автор үз героеның психологик үзенчәлекләрен ышандырырлык итеп ача. Миргаянга беренче бәяне суга батканда ул коткарып калган Гөлзирә исемле кыздан бирдерә. Егетнең ярдәмчел, кешелекле булуын беренчеләрдән булып аңлый кыз. Һәм бу аны үлемнән коткаруда гына чагылмый. Әнә бит Кифая исемле классташы 50 сум акчасын югалткач, аның әти-әнисе тарафыннан җәберләнүгә дучар буласын белеп, күптән хыялланган велосипед алырга дигән акчасын сиздерми генә кызның сумкасына сала, Гөлзифа сүзләре белән әйткәндә, «кешене мең бәладән коткара». Миргаянның бу адымында Коръәндә күрсәтелгән иманлылык, изге күңеллелек, башкаларга булган миһербанлылык чагыла. Андыйлар турында халык мәкале болай яңгырый: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер». Егетнең хыялмаксатларын, дөньяга карашын тулырак ачу өчен, автор кычыткан арасыннан табылган көндәлекне файдалана. Әлеге уңышлы алым аның токарь-слесарь булырга һәм кичләрен институтта укырга теләвен, үзен кимсетүләренә гарьләнеп яшәвен, шуның өчен хәтта авылдан качарга йөрүен белергә ярдәм итә. Егетнең үз сүзләрендә дә күңел дөньясы ачыла. «Беркайчан да күземдә яшь күрмәдегез,— ди ул.— Беркайчан да, беркемгә дә серемне сөйләмәдем, зарымны зарланмадым». Бу юлларда аның яралы

күңеле, авырлыкларга теш кысып түзүе, яшьтәшләре арасында чын дус таба алмавы күренә.

Пьесада Миргаянны аңлаучылар булып әнисе Миңзифа һәм тимерче булып эшләүче ялгыз ир Әбүбәкер тора. Миңзифа улының күңеле саф булуын, тышкы кырыслыгының, кирелегенең үзен кимсетүчеләргә җавап булуын яхшы аңлый. Икесе генә калганда төрлечә ачуланып, хәтта киез итек белән кыйнаса да, моның чарасызлыктан икәнен аңлатып, үзе үк елый башлый. Әмма башкалар янында ул егетне яклау юлына баса. Акыллы ана буларак, Миргаян күңелендә аның да яклаучысы бар дигән фикерне үстерергә тели. Әбүбәкер исә — Миргаянны эшкә өйрәтүче, аңарда ир кеше сыйфатларын баетучы, хәзергә кадәр «улым» дип олылап та, кадерләп тә эндәшүче бердәнбер ир кеше.

Укытучы Сәмидә Миргаянны яманлап, тискәре сыйфатларын гына күреп, аларны күпертеп сөйләп, Миңзифага ничек бала тәрбияләү турында «акыл сатып» йөрүче буларак ачыла. Элегрәк сыер савучы булып эшләп, пединститутка читтән торып укырга кергәч, мәктәптә укыта башлаган бу кыз, билгеле, педагогика һәм психологиядән әлегә ерак. Шуңа да ул ялагайларны, җитәкче балаларын яклый, ә Миргаянны ятимлеге белән кимсетә.

Шактый тыныч барган вакыйгалар Миңзифага ниндидер хат килү, аның кисәк үзгәрүе белән тизләнә, кискенләнә. Интрига көткән укучы-тамашачы ялгышмый: Миргаянның лотерея билетына зур суммада акча отуы билгеле була, бераздан аның чын әнисе Дилфүзә яңа ире белән килеп төшә, соңрак исә этисе Карабаш Кирамы да кайта. Бу алым нәкъ менә әлеге адәм актыкларының әхлаксыз йөзен, имансыз эш-гамәлен күпертебрәк ачарга ярдәм итә. Яшьтән җилбәзәк булып үсеп, никахсыз бала тапкан, үз рәхәтен генә кайгыртып, улын апасына калдырып киткән, ирдән иргә күчеп йөреп ныклы гаилә кора алмаган, бала табудан мәхрүм калган Дилфүзә язмышы көлкедән бигрәк кызганыч булып тоела. Әлегә үзе моны аңламый, дөресен әйткәндә, аңларга да теләми. Тиздән, чираттагы ире тел галиме Имаметдин ташлап киткәч, олыгаеп барганда Дилфүзә ялгызлыгын күрәчәк, әмма инде соң булачак... Халык әйтмешли, терсәк якын булса да, аны тешләп булмый шул.

Миргаянның этисе Кирам теләк-максатын яшерми дә. Ул әдәп-әхлак ягы чамалы булган, бүгенге көне белән генә яшәүче бәндә булып күзаллана. Әнә шулай төп башына утырып кала-

кала, ул киләчәктә, дөресрәге, бүген үк инде беркемгә дә кирәк булмаячак.

Әлеге кешеләрнең мәгънәсезлеге, эгоистлыгы фонында Миңзифаның олы йөрәге, чиста вөҗданы, чын ана булуы бөтен тулылыгында ачыла. Гомере буе намуслы, башкалар кайгысын кайгыртып яшәп тә әйләнә-тирәдәгеләр тарафыннан кире кагылуын аңлый алмаудан гаҗиз калган ул. «Син матур да, җилбәзәк тә, бәхетле дә,— ди ул сеңлесе Дилфүзәгә.— Син кешеләрне алдыйсың, кешеләр барыбер сиңа ышана, ышанмаганы ышанган булып кылана. Алдасаң да, хыянәт итсәң дә сине гафу итәләр, сине яраталар. Мин алдый белмәдем инде, көне-төне кешеләр өчен эшләдем. Мине берәү дә яратмады». Ниһаять, хакыйкать өстенлек итә. Үз әти-әнисенең чын максатын ачык сизгән, тойган Миргаян аларның чит кеше булуын аңлатырлык сабак бирә. Чыбыркыны кулларына тоттырып, үзен кыйнауларын сорый. Тегеләр баш тарткач, Миңзифага бирә. Ул исә, кешеләрнең үзенә һәм улына карата гаделсезлегенә, рәхимсезлегенә булган ачуны чыгарып, Миргаянны кыйный һәм, чыбыркысын ташлап, «Авыртмадымы, балам?»— ди. Миргаян: «Каты куллы, йомшак күңелле Миңзифа минем туган анам булыр»,— дип, әнисенә китергән борчулары өчен гафу үтенә.

Гомумән, Р. Батулланың үзенчәлекле һәм гыйбрәтле пьесасындагы төп идея гаять тирән мәгънәле, күп сыйдырышлы халык мәкалендә чагыла: «Тапкан түгел, баккан — ана».

Драматургия турында сүз барганда, әлбәттә инде, **Илдар Юзеев** исемен әйтми калу мөмкин түгел. Чорыбызның танылган әдибе И. Юзеев әдәби иҗатның шигърият, драматургия төрләрендә бай мирас калдыра. Сез аның поэзиясенә хас сыйфат-билгеләр белән IX сыйныфта таныштыгыз инде. Түбәндә әдипнең драматургиясенә кыскача күзәтү ясала.

И. Юзеев сәхнә әдәбиятына XX гасырның 70 нче елларында килә һәм тиз арада үз укучы-тамашачысын таба. Сәхнәгә куелган беренче әсәрләре үк «шигъриятле драматургия» дип бәяләнә, чөнки ул татар драматургиясенә шигърияткә хас булган хисләлекне, хыял дөньясын, төсләр балкышын алып килә. Драматургның күпчелек пьесаларында романтик пафос өстенлек итә, геройлары еш кына көнкүреш ыгы-зыгысы белән каршылыкка кергән, хыялында туган идеалга омтылып яшәүче шәхесләр буларак алга килеп баса. Аның озак еллар дәвамында сәхнәләрдән төшми уйналып килгән «Сандугачлар килгән безгә» һәм «Кыр казлары артыннан» пьесаларының геройлары

саф рухи дөньялары, матурлыкка ышанып һәм омтылып яшәүче кешеләр буларак кызыклы һәм үзенчәлекле.

Әдипнең сәхнә әсәрләрендә дөньяга һәм кешеләргә булган лирик мөнәсәбәте чагыла. Аның соңгы елларда язылган «Гашыйклар тавы» пьесасы заман һәм кеше арасындагы каршылыкларны үзгә бер моң, җан хәрәкәте, хисләр муллыгы аша тасвирлый. Драматург заман сорауларына җавап эзли. Аны әхлакый кыйммәтләрнең югала баруы, халкыбызга хас гореф-гадәт, йолаларның онытылуы борчый. Әдип шәхеснең җәмгыятьтәге урыны турында уйланып иҗат итә («Бөркетләр кыяга оялый», «Бәхетемнән узып барышлый», «Эзләдем, таптым, югалттым»). Халкыбызның танылган шәхесләре әдәби образлары аша үткәнне һәм бүгенгене аңларга, киләчәкне тоемларга омтылуның матур үрнәге буларак «Очты дөнья читлегеннән», «Соңгы сынау» («Соңгы төн») кебек әсәрләре дөнья күрә. Беренчесендә әдип — Г. Тукай, икенчесендә М. Җәлилнең әдәби образларын тудыра.

И. Юзеевнең **«Ак калфагым төшердем кулдан...»** (1990) әсәрендә төрле сәбәпләр аркасында чит илләргә китәргә мәҗбүр булган фаҗигале шәхесләр язмышы чагылыш таба. Автор үзе «халык драмасы» дип атаган пьесада вакыйгалар Сан-Франциско — Казан телевизион күпере рәвешендәге композициядә бирелә. Бу исә күп мәсьәләләрне эчтән генә түгел, читтән торып күзәтергә, бәяләргә мөмкинлек бирә.

Телевизион күпердә барган фикер алышуның үзәгендә, билгеле, татар халкы язмышы, теле, гореф-гадәтләре.

Сан-Франциско ягыннан очраштыручы Сафия Нурхан болай ди: «Артта калган, читкә кагылган, кимсетелгән, үзен рәнҗетелгән дип хис иткән бичарага илтифат күрсәтү — милләтебезнең асыл сыйфаты. (...) Без барыбыз да — без дә, ә бәлки сез дә читкә кагылганнар, рәнҗетелгәннәр. Халкыбызның күпчелек өлеше үз туфрагында яшәми. Алар Сабантуйдагы чабыштан хәлсезләнеп, егылып калган атлар кебек. Әгәр халкыбыз артта калган атларның муенына ак сөлге бәйләү хисен югалтса, милләт буларак яшәүдән туктаячак». Әнә шул рәвешле милләт яшәеше милли сыйфатлар сакланышы белән бәйләп карала.

Телевизион күпердә милләт язмышы турында сөйләшү әкренләп аерым шәхесләр язмышына күчә һәм без чын мәгънәсендә фаҗигале язмышлар белән очрашабыз. Аларның берсе — 35 яшьлек Тайфур. Үз илендә танылып килүче яшь рәссам яшәп килгән тәртипләр, идеологик карашлар белән кар-

шылыкка керә. «Алар мине дә дошман ясадылар,— ди ул.— Үзләре кебек уйламаган өчен, алар кушканча иҗат итмәгән өчен». Егетне остазы Исмай Акчурин да аңламый, рәсемнәрен кире кага. Тайфур, яраткан эшен, сөйгәнен, туган җирен калдырып, чит илгә китәргә мәҗбүр була. Бу яшь кешенең халкыбызга хас матур сыйфатларның, милли йөзебезнең югалуы турындагы каты, кискен сүзләре артында Регинага булган мәхәббәте, туган илен оныта алмавы ачыла: «Мин ирекле. Ни телим, шуны эшлим. Әмма иң кадерле нәрсәне югалту бәрабәренә алынган ирек мине бәхетле итмәде. Басып торган үз туфрагым, җирем, суым, шунда тамырланган тал-тирәкләрем, телем-моңым җитми миңа. Һәрбер көнем-төнем иксез-чиксез газапка әйләнде». Чит илгә киткәч, бер генә рәсем-картина да ясый алмавы күңелендәге каршылыкны, рухи кризисын күрсәтә. Тайфур бу халәтеннән чыга алмый һәм үзен үзе үтерә. Әнә шулай меңнәрчә гөнаһсызларның канына буялган совет системасы тагын бер талантлы шәхеснең юкка чыгуына китерә.

Исмай Акчурин язмышы да тетрәндергеч. Бала вакытта ук «дошман баласы» дигән хурлыклы исем күтәреп йөргән, соңрак әтисеннән баш тартырга мәҗбүр булган егет күңелендә курку хисе тирән урнашкан. Бары сугышта дошманны җиңеп чыгу, америкалы Майк Стерн белән очрашу, соңрак та аралашып яшәү аның сынган канатларын турайта, көч-ышаныч бирә. Әмма тиздән Исмай Акчурин өстендә кара болытлар куера: «милләтче» буларак күзәтү астына эләгә. Болар, билгеле, эзсез калмый. Ул идеология рупорына әйләнә, Тайфур Кормаш кебек талантларны яклаудан баш тарта. Җәмгыятьтә хәзер барган үзгәрешләргә дә бик сак килә, һәрвакыт икеләнә, бутала, ачык кына җавап бирми. Шулай да Исмай Саттарович күңелендә дә үзгәрешләр башланган. Моның сәбәпчесе әдәпле, итагатьле улының Әфганстаннан психикасы бозылып, усалланып, кансызланып кайтуы дип уйларга нигез бар.

Пьесада сурәтләнгән фаҗигале язмышларның иң үкенечлесе, мөгаен, Жак белән Шәмсия әбидер. Жак (Габделхак) сугышта әсирлек газабын кичерә. Аннан котылгач, француз партизан отрядында сугышып йөрсә дә, туган иленә кайтмый. Ул Сталин режимының элекке әсирләрне төрмә-лагерьларга җибәрүеннән хәбәрдар була. Америкага күчеп килеп, ул гомере буе туган илен, телен, газиз әнкәсен, җыр-моңнарын сагынып яши. Бу вакыт эчендә бердәнбер куанычы итеп әнисенең ак калфагын саклый. Сагынып, саргаеп яшәсә дә, үзе турында әни-

сенә хәбәр итми. «Әгәр анда минем исәнлекне белсәләр, әнигә дә, нәсел-нәсәпкә дә көн күрсәтмәсләр»,— дип уйлый.

Жак-Габделхакның әнисе Шәмсия әби хакимият идеологиясе белән шулкадәр агуланган ки, башка төрле фикер-карашны һич кабул итә алмый. «Әгәр инде адәм, иленнән ваз кичеп, теге якка чыккан икән, аның исеме дә, җисеме дә — дошман»,— дип саный ул, Габделхагының шундый хәлдә булуын күз алдына да китермичә. Улын танырга да теләмәгән ана, үзенең истәлеге булган ак калфак турында ишеткәч, күз алдында үзгәрә. Жак-Габделхакның фаҗигале язмышы аның яралы күңелен кузгата, һәм Шәмсия әби гомере буе җыелып килгән ачы хакыйкатьне әйтә: «Нигә соң без шулкадәр шәфкатьсезләр?! Улым... балам... Габделхагым...»

Киселгән язмышлар... Боларда бит татар халкының фаҗигале язмышы чагыла. Һәр кеше — шәхес, җан иясе. Кеше гомере — иң югары кыйммәт. Язучы тоталитар системаның, торгынлык еллары идеологиясенең кешелексез якларын ача. Туган илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булучыларны гаепләргә түгел, бәлки аңларга, мәрхәмәтлелек күрсәтергә чакыра.

Әсәр исеме дә халык җырыннан алынган «Ак калфагым төшердем кулдан...» Ак алфакны кулдан төшерү ул — кешенең туган җиреннән китәргә мәҗбүр булуы. Әмма ул кайда да үзен халкының, ата-баба туфрагының бер кисәге дип саный һәм аны сагынып, курешүләргә өмет итеп яши.

Сораулар һәм биремнәр

1. 1960—1980 еллар сәхнә әдәбиятында әйдәп баручы авторларны һәм аларның әсәрләрен атагыз. Бу чор драматургиясендәге төп яңалык нидән гыйбарәт?

2. 60—80 нче еллар сәхнә әдәбиятындагы тематик төрлелекне, жанр байлыгын билгеләгез.

3. 1980 елларның икенче яртысы — 2000 еллар драматургиясенә хас яңалык-үзенчәлекләрне атагыз.

4. Р. Батулла әдәби иҗатның кайсы төр-жанрларында аеруча актив эшли? Аның Г. Тукай бүләгенә лаек булган әсәрләрен атагыз, аларны сыйныфтан тыш уку дәресендә өйрәнегез.

5. «Кичер мине, әнкәй» әсәренең темасын билгеләгез. Пьесада чагылыш тапкан проблемаларга мөрәҗәгать иткән тагын нинди әсәрләр беләсез? Фикер алышыгыз.

6. И. Юзеев драматургиясенә хас үзенчәлекләрне күрсәтегез.

7. «Ак калфакны төшердем кулдан...» драмасында сурәтләнгән геройларны характерлагыз. Пьеса исеменә нинди мәгънә салынган?

Хәй Вахит
(1918—1978)

60—70 нче еллар татар драматургиясен төрле жанрдагы әсәрләре белән баеткан, аңа заман төсмере, яшьлек романтикасы алып килгән, пьесалары бу чор татар театрлары репертуарында үзәк урыннарның берсен биләгән талантлы әдипләрнең берсе — Хәй Вахит була.

Габделхәй Каюм улы Вахитов (Хәй Вахит) 1918 елның 20 декабрендә татар әдәбиятына һәм сәнгатенә күп санлы талант ияләрен биргән, киң болыннары, урман-кырлары җырларда, әкиятләрдә сурәтләнгән Казан артындагы Биектау районы авылларының берсе — Мәмдәлдә крестьян гаиләсендә туып үсә. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, күңелендә иҗат көче ташып торган егет Казан театр техникумына укырга керә. Анда ике ел укыгач, музыка училищесына күчеп белем ала. Җыр-музыканы яратса да, әдәби иҗат аны үзенә күбрәк тарта. Х. Вахит, дәртләнеп, заман рухындагы шигырьләр, драма әсәрләре яза башлый. Әдипнең башлангыч чор иҗатына караган әсәрләре, татар әдәбиятына яңалык алып килмәсәләр дә, төрле жанрда үзен сынап карау өчен бик яхшы өйрәнү мәктәбе булдылар.

Сугыштан соң Х. Вахит Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Музыка белгече булу аның шигырьләренең һәм драма әсәрләренең музыкальлегендә, эчке аһәңендә, хис-тойгыларга бай булуында чагылыш таба. Бу елларда әдип үзенең шигырьләре белән танылa.

Х. Вахит үзен сынап караган һәм уңышларга ирешкән тагын бер өлкә — либретто жанры. Татар опера сәнгате кытлык кичергән бер чорда ул «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир» либреттоларын яза. Композитор Х. Вәлиуллин музыка язган «Самат» операсы 1957 елда Мәскәүдә узган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында югары бәя ала.

Х. Вахит, әнә шул рәвешле, әдәбият һәм сәнгатьнең төрле өлкәләре аша драматургиягә килә һәм, сәхнә әдәбиятында үзенең иҗат мөмкинлекләрен тулысынча ачып, җитди уңышларга ирешә.

Заман рухын тоеп, җитди әхлакый һәм иҗтимагый мәсьәләләр күтәрелгән «Беренче мәхәббәт» драмасы әдәбият-сәнгать сөючеләр тарафыннан шатланып каршы алына, драматургка дан һәм шөһрәт китерә. Әлеге әсәре өчен Х. Вахитка һәм пьесаны сәхнәгә куючы режиссер Р. Бикчәнтәевкә 1960 елда республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Әлеге уңышы белән рухланып иҗат итә башлаган драматургның бер-бер артлы «Рәхим итегез!», «Ике килен-килендәш», «Күк капусы ачылса», «Туй алдыннан», «Онытa алмасаң нишләрсең» һ. б. драма-комедияләре басылып чыга, татар һәм башка күп кенә халыклар театрларында уңыш белән бара.

Әдипнең драмалары, алардан бигрәк комедияләре юморга бай булулары, җыр-музыканың оста бәйләнеп китүе белән характерланалар. Драматург тел байлыгыннан оста файдалана, әсәрләре тапкыр сүзләргә, әйтемнәргә бай.

Биремнәр

1. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында хронологик тәртиптә сөйләгез.

2. Х. Вахитның әдәбият-сәнгатьнең төрле жанрларында эзләнүләрен мисаллар өстендә күрсәтегез.

3. Драматургның төп иҗат үзенчәлекләрен билгеләгез.

4. Х. Вахитның бер-ике комедиясен укып, сыйныфта фикер алышыгыз.

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

Өч пәрдәле драма

(Кыскартып алынды)

КАТНАШАЛАР:

Т ә л г а т ь.

Р ә х и л ә.

С ә л и м Г ә р ә е в и ч — урта мәктәп директоры.

К а м и л ә — Сәлимнең хатыны.

Г о с м а н Ә к б ә р о в и ч — укытучы, 27 яшьтә.

Н у р с ә н ә — фермада сыер савучы, Рәхиләнең дусты, 21 яшьтә.

Ә п с ә л ә м — Нурсәнәнең ире, 19 яшьтә. Терлекчелек фермасында эшли.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәлим Гәрәевич йорты. (...) Пәрдә ачылганда, сәхнәдә берәү дә юк. Сул яктагы бүлмә эченнән кемнеңдер скрипка уйнаганы ишетелә. (...) Бераздан ишек шакылдаталар. (...) Рәхилә тавышы *(бүлмәдә)*. Керегез! Рәхилә уйнаудан туктамый. Менә коридор ишегендә Тәлгать күренә. Юл киеменнән. Берәү дә булмагач тукталып кала. Дикъкатен музыка җәлеп итә. Көй аңа ошый булса кирәк, ул аны урындыкка утырып тыңлый. Вальс уйный-уйный Рәхилә чыга, каршында таныш булмаган кешене күреп туктала. Көй ярты юлда өзелә.

Тәлгать. Исәнмесез!

Рәхилә. Исәнмесез. Сез кем?

Тәлгать. Миңа мәктәп директоры Сәлим абый кирәк иде. Аны биредә тора, диделәр.

Рәхилә. Сез кем буласыз?

Тәлгать. Мин башка районнан, Сәлим абыйга хат китергән идем.

Рәхилә. Куегыз әнә өстәлгә. (...)

Тәлгать. Гафу итегез. Үзе кайчан кайтыр икән? Җавап алырга икенче керермен. (*Ишеккә юнәлә, Рәхилә аның юлын бүлә.*)

Рәхилә *(урындык тәкъдим итеп)*. Утырыгыз! Утырыгыз, утыр. *(Тәлгать утыра.)* Так... шулай итеп, баштагы сорауга кайтыйк, сезне кем дип беләбез инде? (...)

Тәлгать. Сез кызык кеше икәнсез. *(Урыныннан тора.)* Я, алайса, тыңлагыз: мин ерактан, быел унынчы классны тәмамладым, унҗиде яшьтә, комсомол, өйләнмәгән — егет кеше. Без әни белән икәү генә тора идек... Быел... әле күптән түгел генә мин аны җирләдем.

Рәхилә. Алай... Әтиегез?

Тәлгать. Әтием юк.

Рәхилә. (...) Бу хат кемнән соң?

Тәлгать. Әнидән.

Рәхилә. Ничек, үлде дидегез ич?

Тәлгать. Ул аны элек язган булган. Күңеле сизенеп. Хәле авырайгач, мине чакырып алды да: «Улым, мин тормыштан китәм инде, сине ышанып калдырырга кешем дә юк»,— диде. Шунда ул сезнең әтиегезне исенә төшерде. Алар кайчандыр бергә укыган булганнар. Минем киләчәгемне ул әтиегез кулына тапшырды. Күрәсең, ул мине һаман да балалыктан чыкмаган дип исәпләгәндер инде. Шушы хатны бирде, әтиегезгә тапшырырга кушты. (...)

Р ә х и л ә. Сезнең әниегез белән минем әти бергә укыганнар, дисезме әле?

Т ә л г а т ь. Бергә укыганнар.

Р ә х и л ә. Алай булгач, без танышлар икәнбез. *(Кул суза.)* Танышлар гына түгел, дуслар!

Тәлгать тә Рәхиләгә кулын бирә. (...)

Р ә х и л ә. Тәлгать, син нишләп минем белән дә кызыксынмыйсың әле? Берни дә сорашмыйсың? Неприлично.

Т ә л г а т ь. Ничәнче классны бетердең? (...) Унынчыны?

Р ә х и л ә. (...) Кияүгә чыга алмасам, быел институтка керәм. (...) Тәлгать, өегездә кем калды соң?

Т ә л г а т ь. Өебез юк, фатирда тора идек.

Р ә х и л ә. Торырга фатирың юк, эшләргә эшең юк, шулай булгач, бер җае чыкканчы, бездә тукталып тор диюем. Бездә урын җитәрлек. *(Кабинетка күрсәтә.)* Менә берүзеңә бер бүлмә. (...)

К а м и л ә кайтып керә.

Т ә л г а т ь. Исәнмесез!

Р ә х и л ә. Әни, ул безнең якын танышыбыз, әти янына дип килгән.

К а м и л ә *(Тәлгатькә).* Сез Сәлим абыегызга йомыш беләнме? *(Тәрәзәдән күреп.)* Әнә үзе дә кайтты. *(Каршысына атлый.)*

Коридорда С ә л и м Г ә р ә е в и ч күренә.

С ә л и м *(өйдәгеләрне күрмичә).* Кая, чәегез әзер түгелме? *(Кухняга юнәлә.)*

Р ә х и л ә. Сәлим Гәрәевич, сезне бер генә минутка мөмкин булмасмы?

С ә л и м. Ни бар?

Т ә л г а т ь. Исәнмесез.

С ә л и м *(игътибарсыз).* Исәнмесез. *(Рәхиләгә.)* Тыңлыйм сине, Рәхилә кызым.

Р ә х и л ә. Әти, таныш бул, Тәлгать. Ул сиңа хат алып килгән. Менә әнисеннән.

Р ә х и л ә китә.

С ә л и м. Хат? *(Тәлгатькә карап аптырап тора. Кабаланып хатны укый. Үзгәрә, таркау фикерен тупларга тырыша.)*

Тәлгать *(Сәлимгә).* Сез минем әнине хәтерегезгә төшердегез, ахры?

Сәлим. Ә?.. Ә, әйе, әйе. *(Маңгаеннан тирен сөртә. Хатны тагын бер мәртәбә укып чыга.)* Син Тәлгатьме?

Тәлгать. Сезнең әллә минем турыда ишеткәнегез бар идеме?

Сәлим. Тәлгать, менә син нинди икәнсең! *(Күкрәгенә кыса, маңгаеннан үбә.)* Тәлгать! *(Тагын кочагына ала, сокланып карап тора.)* Буйга җиткән егет булдым диген! Ә әнием?.. Һай, бигрәк тә яшьләй...

Тәлгать. Әни минем сезнең янга килүемне теләгән иде. Ә мин аның теләген үтәми булдыра алмадым.

Сәлим *(хатны кесәсенә сала).* Монда әниең сине эшкә урнаштыру турында сораган.

Тәлгать. Шулайдыр инде. Ул гел минем өчен кайгыртты. Шатлыгы да, кайгысы да мин идем. Сез борчылмагыз, мин сезгә авырлык китермәм.

Рәхилә керә.

Рәхилә. Әти дим, Тәлгать унынчыны бетергән, ә институтка керергә теләми. Эшкә керәм, ди.

Сәлим. Бөтен кешегә дә институтта укырга димәгәндер бит. Барысы да галим булып бетсә, калган эшне кем эшләр? (...)

Камилә керә. Рәхилә Тәлгать белән бүлмәгә, Сәлим кухняга кереп китә. Урам яктан өйгә килеп кергән Госман аны күреп ала. Госман ак чалбар, ак костюмнан. Башында крахмал белән катырылган эшләпә, аягында ак туфли, муенында чәчәкле галстук.

Госман. Сәлим Гәрәевич өйдә юктыр дисәм...

Камилә. Кәефе юк, авырып тора. Сез аңа игътибар итмәгез, Госман. Рәхилә кызым!

Камилә кухняга кереп китә. Рәхилә залга чыга.

Госман. Һем... Бу өйдә мине сәер каршылыйлар. Рәхилә күгәрченем, әгәр дә син булмасаң, мин бу бусагадан атлап керә алмас идем.

Рәхилә. Сез герой, Госман абый.

Госман. Герой түгел мин. Бәхетле кеше. Син минем гомер юлымның башында ук килгән бәхетем бит. Күктән төшкән, бушка килгән бәхетем! Ләкин мин бурычлы булып калмам. Бу

бәхет өчен сиңа гомерем буе түләячәкмен. Тормыш йөге димәм, тартырмын. Көн-төн димәм...

Р ә х и л ә. Әгәр дә ул шулай авыр булырлык булса, кирәкми, Госман абый.

Г о с м а н. Киресенчә! Мин сиңа бәхет өчен бәхет бирермен. Өрмәгән җиргә утыртмам, диләрме әле? Син бит — минем язмышымның бүләге. Тиңсез бүләк син. Карачы, нинди буй-сын! Карачы, нинди күзләр!

Р ә х и л ә. Госман абый, оялтасыз.

Г о с м а н. Мин беләм, бөтен кеше минем бәхетемә кызыгачак, минем язмышымнан көнләшәчәк.

Р ә х и л ә. Госман абый, күрше бүлмәдә этиләр бар.

Ишектә К а м и л ә күренә.

К а м и л ә. Госман, чәй эчәргә теләмисезме?

Г о с м а н. Рәхмәт, Камилә Шакировна, мин ашыгам. (...)

П ә р д ә төшә.

Сораулар

1. Тәлгатьне Сәлим Гәрәевич гаиләсендә ничек каршы алалар? Бу гаилә сездә нинди тойгылар тудыра?

2. Вакыйга-күренешләрдә Рәхиләнең нинди характер сыйфатлары чагыла?

3. Автор, әсәрдәге интриганы көчәйтү өчен, нинди композиция алымы кулланган?

4. Госманның үз-үзен тотышы, сөйләме сездә нинди фикерләр уятты?

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Тышта көчле яңгыр ява. Көн кичкә авышкан. Бербер артлы өйгә Р ә х и л ә, Т ә л г а т ь, С ә л и м кайталар.

С ә л и м. (...) Тәлгать, кил, утыр әле. Рәхилә, син чыгып тор.

Рәхилә чыгарга юнәлә, ләкин ишек буенда тукталып кала. Соңыннан аның янына Камилә дә килеп туктала.

Син этиеңне белмим дисең инде?

Т ә л г а т ь. Белмим.

С ә л и м. Ә син аның минем кебек кеше булуын теләр идеңме?

Т ә л г а т ь. Сезнең кебек? Ул бит...

Сәлим. Нәрсә — ул бит?

Тәлгать. Ул бит... кеше түгел, ә... кабахәт. Ул сезнең кисеп ташлаган тырнагыгызга да тормый.

Камилә. Тәлгать, үз атаң турында шулай сөйләргә ничек телең бара?!

Тәлгать *(Камиләгә күтәрелеп карый да җавап бирми. Сәлимгә)*. Сез аны белми идегезме?

Сәлим *(уеннан айнып)*. Кемне? Ә, этиегезнеме? Нишләп... Юк, белми идем. Аның турында, алайса, кабахәт кеше дигән фикер туган? Әйе...

Тәлгать. Әни башта алдап килгән. Этиең фронтта үлде, дип әйтә иде. Мин шуңа күнеккән идем инде. Ничектер шулай тиеш шикелле иде. Моннан өч ел элек, миңа унбиш яшь тулгач... ул көнне безгә әнинең дуслары җыйналганнар иде. Менә шунда, минем туган көнемне котлап, әти булган кешедән мең сум акча килеп төште. Аңынчы күңелле генә йөргән әни кинәт боегып калды, уйчанланды. Бераздан эзлим — әни бүлмәдә юк. Күршеләргә керсәм, мендәргә капланып елап ята. Шул чакта әйтте ул: «Әтиең исән, тик, зинһар, аның турында сорашма»,— диде. Мин исемен белергә теләдем: «Кем ул, кайда ул?» — дидем, әйтмәде. Әни аның исемен әйткән булса, ихтимал, нәрсә булса да кылган булыр идем.

Рәхилә. Нәрсә?

Тәлгать. Мин аны, мин анымы... Әнине шулай җәберләгән өчен мин аны... *(Тәлгать уен әйтә алмый өстәлгә каплана. Бераздан башын күтәрә, Сәлимгә текәлә.)* Сәлим абый, аның аркасында әни күпме газап кичерде, күпме күз яше түкте. Әниемнең шулкадәр иртә кабергә керүен мин аннан гына күрәм.

Авыр тынлык. (...) Тәлгать бүлмәсенә кереп китә. Рәхилә аның артыннан керә. Сәлимнең башы салынган, ул газаплы уй кичерә.

Камилә аның өчен борчыла.

Камилә. Сәлим, Сәлим дим! *(Сәлим дәшми.)* Синең шул булыр инде. Һәр сүзне йөрәгеңә якын алмасаң ярамый торгандыр. Болай булмый ич инде, Тәлгатькә дөресен сөйләп бирергә кирәк. Бәлки, аңлар... Үз-үзеңне генә бетерәсең.

Сәлим. Әнисен ничек ташлап, рәнҗетүемне сөйләп бирергәме? «Мин яшь чакта тормышка җиңел караганмын, гафу ит, йөрәгемә акылым баш була алмады»,— дияргәме? Әйе,

Тәлгатькә барысын да сөйләргә кирәк, беләм, әмма телем күтәрелми. Аның алдында, әнисе алдында гаебем зур. Сөйләргә мөмкин, Камилә, ләкин акланырга мөмкин түгел. Әйе, хәзер ул минем янда. Ләкин ике арада — упкын. (...)

Сәлим белән Камилә кухняга узалар. (...) Рәхилә тагын кулына мандолина ала, тагын шул таныш вальс моңы салмак кына тирбәлә. Ишектә Тәлгать күренә, кулында китап, ул да музыканы тыңлый.

Тәлгать. Йөрәккә үтеп керә, шәп уйныйсың.

Рәхилә. Син тыңлап торганны сизгәндер *(үзе уйный, үзе сөйли)*. Бүген клубта «Отелло» буласы иде, синең белән барырмын дигән идем. Ни өчен диген? Отелло кебек ярата белергә өйрәнмәссең микән дим.

Тәлгать *(янына утыра)*. Син Отелло дисең, аның кебек ярата дисең. Ялгышасың. Отелло ул Дездемонаны яратмаган, үзен яраткан. Юкса нигә ул яраткан кешесен үтерә? Ни хакы бар?! Көнләшә икән, ышанмый икән, аерылсын. Ә ул шундый гүзәл җан иясен харап итә. Шул булдымы мәхәббәт?! Аңламыйм, ни дип шуны сәхнәдә күрсәтәләрдер.

Рәхилә *(ихлас күңелдән)*. Беләсеңме, Тәлгать, без бит юллар чатында торабыз. Алдыбызда төрле юллар. Кайсысыннан китсәк, шул безнең гомер юлыбыз булачак. Аңла син, без хәзер язмышыбызны хәл итәбез. (...)

Пәрдә төшә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Елга буе. Болынлык, камышлык. Ферманың җәйге утары урнашкан җир. Әпсәләмнең кулында гармун, вальс уйный. Рәхилә килә. Ул үзе табын әзерли, үзе гармунга кушылып җырлый. Алар янына бераздан Госман килә.

Госман. Рәхилә, әйдә, танцевать итәбез.

Әпсәләм *(уйнавын кинәт туктата)*. Ай, уч төбем кычыта.

Әпсәләм өйгә кереп китә. Госман белән Рәхилә генә кала.

Госман. Гүзәл күренеш, энҗе нурлар тәңкә дулкыннар өстендә уйный. Сокланып туя алмаслык! Ә бит тиздән җир өстенә зәңгәрсу караңгылык җәелер дә күктә ай калкыр. Ул

чакта без айга сокланырбыз, ай барысыннан да гүзәлрәк төсле тоелыр. Ул да булмас, офык читләрен алсулыкка манчып, таң беленә башлар. Без инде таңны мактарбыз. Сөйгән ярлар да шулай: искеләре онытыла, яңалары якыная икән.

Р ә х и л ә. Сез, Госман абый, үзегезгә каршы сөйләдегез түгелме соң? (...)

Г о с м а н. Син мине яратмыйсың. Әйе, әйе, мин сизеп килдем моны.

Р ә х и л ә. Алай булгач, нигә соң яратмаган кешегә кияүгә чыгарга кыстыйсыз? Мин сезне аңлый алмыйм, Госман абый.

Г о с м а н. Синең кемне яратканыңны да беләм мин. Сизми дисеңме әллә? Көтүчене?

Р ә х и л ә. Госман абый, мине ачуландырасыз?!

Г о с м а н. Ләкин бик каты ялгышасың. Син бервакытта да, беләсеңме, бервакытта да аның белән була алмаячаксың!

Р ә х и л ә *(сагая)*. Әйтеп бетерегез.

Г о с м а н. Әйтәм, башта син каенга сөял. Сөял, сөял, ныклабрак сөял. Югыйсә егылып китәрсең. *(Рәхилә үзе дә сизмәстән каенга сөялә.)* Тәлгать — синең абыең. Бертуган абыең! Менә кем ул сиңа! *(Рәхилә коелып төшә, телсез кала.)* Я, ник дәшмисең?!

Р ә х и л ә. Ничек алай?.. Димәк...

Г о с м а н. Ә син үзең уйлап кара, ни өчен килде ул сезгә, ничек килде?

Р ә х и л ә *(уйлана)*. Әйе, әйе... мөмкин... бик мөмкин... аһ! *(Рәхилә каенга каплана.)*

Г о с м а н. Ярар, борчылма. Ташла. Мин сине гафу итәм. Синең алда хәзер бер генә юл. Минем белән генә. Әйдә, киттек! Син дәшмисең? Рәхилә кадерлем, уйлап кара. Киләчәгеңне абыең белән бәйли алмыйсың бит инде. Шулай булгач, икеләнеп торасы да юк. Безне язмыш үзе чакыра, безнең гомер юлыбыз бергә. Әйдә, киттек!

Р ә х и л ә. Юк! Миңа бигрәк тә хәзер фермада калу кирәк. Эш кирәк миңа, эш. Онытылырга! Фәкать эш белән генә онытылырга мөмкин.

Г о с м а н. Күгәрченем, син ни сөйлисең?! Синең биредә, бу пычрак абзарларда, канатыңны каерачаклар. Тыңла мине, мин сине кеше итәргә телим.

Р ә х и л ә. Госман абый, менә шул: канатларым каерылгач, ярдәмегезне тәкъдим итәрсез, яме? Әлегә бит канатларым каерылмаган. Ә бәлки, каерылмас та! (...)

(...) Өстәл тирәли утыралар. (...)

Госман *(Камилә янына килә).* Камилә Шакировна, сез Сәлим Гәрәевич белән сөйләштегезме?

Камилә. Өлгермәгән идем шул әле.

Сәлим. Сез ни турында?

Камилә. Теге, ронога язган язуыңны кире алырга уйласаң, җаен табарга була икән. (...)

Сәлим. Әгәр дә мин теләмәсәм?

Госман. Анысы сезнең эш. Әгәр дә Тәлгатьнең язмышы борчымый икән, әгәр сез аның шушында югалып калуын күтәрә аласыз икән, ул чагында... чамалагыз... *(Борылып китәргә уйлый, каршында Тәлгать басып тора.)*

Тәлгать. Нәрсә дидегез? *(Госман кул айкап китмәкче була. Тәлгать кычкыра.)* Туктагыз! Сез нәрсә һаман да Тәлгать белән авыз чайкыйсыз?! Тәлгать көтү көтә, югалып кала, имеш. Сезнең анда ни эшегез бар?! (...) Ә бәлки, ул шатланып, горурланып эшли торгандыр, сайлаган хезмәтеннән канәгатьтер, эшеннән тәм табадыр?! Бәлки, аның үзенең хыяллары, планнары бардыр?! Юк, сез Тәлгатьне кызганырга ашыкмагыз әле, иртәрәк булып чыкмасын! Беләсегез килсә, Тәлгать быел институтка заочно укырга керәчәк. Сезнең кесәгездә йөргән диплом анда да булыр. Әмма ләкин...

Госман. Син ни дип миңа ташландың әле? *(Сәлимгә күрсәтә.)* Әнә кемгә ташлан. Сине урнаштыруны сорап, ул бит миннән үтенде. Әтиеңә!

Тәлгать *(тынып кала. Госман әйткән сүзнең мәгънәсен аңларга тырыша).* Әти?.. Сез?..

Камилә. Әйе, Тәлгать, ул синең әтиең.

Сәлим. Тәлгать... улым...

Тәлгать (*кисәк кенә читкә борыла*). Ә!... Әнкәй, әнкәй! Сине кабергә илтеп тыгучы кеше менә кем икән, әнкәй бәгърем! *(Тәлгать ниндидер кискен карарга килә. Сәлимнең яңагына сугарга ниятләнеп, алга атлый, айкана. Сәлим яңагын яшерми. Тәлгать шулай да кулын күтәрә алмый. Эчке әвгәләнү белән.)* Бар да бер... Бар да бер. Яңагыма сукты дип исәпләгез. (*Тәлгать өй читендәге кадакка элеп куйган костюмы янына китә.*)

Рәхилә. Тәлгать, акылыңа кил.

Тәлгать туктала. Авыр тынлык.

Госман. Так, Сәлим Гәрәевич, менә сез нинди кеше икәнсез. Үз баласын язмыш хөкеменә ташлаучы! Үзегез шундый

җинаятьче була торып, ничек соң сезнең минем өстән язарга кулыгыз күтәрелде?! Хәер, ул шулай булмаса, гаҗәпләнергә урын калыр иде. Аңладым мин сезне! Әйе, без бергә эшли алмыйбыз. Или мин, или сез! Сәлим Гәрәевич, онытмагансыздыр дип беләм...

Сәлим. Нәрсәне?

Госман. Малаегызны институтка арт ишектән кертүне сорап, миңа мөрәҗәгать итүегезне. Хотя кулымда исбат итәрлек документларым юк. Хатыныгыз белә белүен дә, ул сезгә каршы сөйләмәс инде. Ышанам, сез үзегез баш тартмассыздыр?

Сәлим. Ышаныгыз. (*Нурсәнә белән Әпсәләмне күрсәтә.*) Менә шаһитлар алдында әйтәм: булды шундый җинаятем. Кирәк икән ронога да әйтермен.

Госман. Анысы кирәк булмастыр. Ронога болай да билгеле булыр! Үз баласын тәрбияләмәгән кеше укытучы булып эшли алмый. Андый кешегә йөзләрчә баланың тәрбиясен кем тапшырсын?! Кем ышансын аңа, кем рөхсәт бирсен?! Үз баласын урамга чыгарып ташлаган кешегә, мораль яктан череп таркалган кешегә, алай гына да түгел, баласының анасын...

Камилә (*Сәлим өчен коты чыгып*). Җитәр сезгә! Туктагыз!

Сәлим (*Госманга*). Сез мине авырлык китерү белән куркытырга уйламагыз. Иң авыры аның менә монда (*күкрәген күрсәтә*). Вөҗдан газабы аның иң авыры.

Госман. Сезнең бу эшегез менә нәрсәгә китереп җиткерде. Малаегыз белән кызыгыз...

Рәхилә (*туктатып калырга теләп*). Госман абый дим, зинһар...

Госман. Сезнең аркада бертуган балаларыгыз — абыйлысеңелле бер-берсенә гашыйк булдылар.

Рәхилә Нурсәнәнең күкрәгенә каплана.

Камилә. Ничек?

Сәлим. Сез нәрсә сөйлисез?!

Рәхилә. Ай... (*Йөгереп чыгып китә.*)

Сәлим (*кычкырып*). Рәхилә! Дөрес түгел бу!

Камилә. Әйе, әйе, дөрес түгел! Рәхилә дим, Рәхилә! (*Госманга.*) Сез дөрес сөйләмисез. Башта белергә кирәк, ә сез... Белмисез икән, белегез! Рәхилә — безнең балалар йортыннан тәрбиягә алып үстергән кызыбыз. (*Нурсәнә белән Әпсәләм катып кала.*) Ай, кайда соң ул? Рәхилә, Рәхилә дим. Нурсәнә җаным, бар йөгер, артыннан йөгер!

Н у р с ә н ә *(айнып)*. Рәхилә...

Н у р с ә н ә чыгып китә.

Г о с м а н. Әһә, монысын да яшереп килдегез? Кеше язмышы белән шулай уйныйлармыни? Бу нинди моральгә сыя? Күрәм, гомумән, сез дөреслектән куркасыз шикелле.

Г о с м а н китә. Тау артыннан Р ә х и л ә килә. Аның артыннан Н у р с ә н ә килә.

Р ә х и л ә. Мин... ятим баламы?

К а м и л ә. Рәхилә, кичер безне. Тәрбиягә алып үстергән бала икәнеңне без синең үзеңә белгертмичә килдек. Ятимлек сизелмәсен дип. Хәтта, авыл халкы сиңа белгертмәсен дип, элекке районнан күчеп үк киттек. Буйга үсеп җиткәч әйтербез дигән идек тә, үсеп җиткәнеңне сизми дә калганбыз. Менә ничек булып чыкты. Юк, биредә әтиең гаепле түгел, мин... мин генә... Минем сине үз балам итәсем килде. Дөреслекне сиңа түгел, үземә дә әйтергә теләмәдем: үз-үземне ышандырып килдем мин.

Р ә х и л ә *(күзендә яшь)*. Мин... мин ятим баламы? Минем үз әнием юкмыни? Минем әтием — миңа әти түгелмени?

К а м и л ә. Минем сине ачуланган чакларым да булгандыр инде, рәнҗи күрмә, Рәхилә.

Р ә х и л ә. Ни сөйлисең син! Юк, юк, ишетергә дә теләмим. Син — минем үз әнием! *(Янына килә.)* Әни!..

К а м и л ә. Рәхилә, кызым, үз кызым!

Тынлык. Алар янына С ә л и м якыная. Камиләнең күзендә яшь бөртекләре.

Р ә х и л ә *(Сәлимгә)*. Син әтием түгелдер дип кем ышандыра алыр? Беркем дә, бервакытта да! Сез миңа тырнак белән дә чиртмәдегез, кадерләп, иркәләп кенә үстердегез. Сез — минем үз әтием, үз әнием!

Рәхилә әтисе һәм әнисенең кочакларына сыена. Т ә л г а т ь чыбыркысы янына китә.

С ә л и м. Тәлгать, син кая болай? *(Тәлгать туктала, Сәлим аның янына килә. Тәлгать дәшми.)* Син нишләмәк буласың? Ярамый! *(Тәлгать Сәлимнең күзләренә карый. Әмма бер сүз*

дә дәшми.) Ах, кичерә алсаң иде син мине. Беләм, мин гаепле, бик гаепле. Менә бит... Яратам бит мин сине, улым!

Т ә л г а т ь. Бәлки, мин дә сезне ошатканмыңдыр, тик...

К а м и л ә. Ялгышасың бит, Тәлгать. Уйлап кара: Рәхилә булып Рәхилә, Сәлимнең үз баласы булмаса да, «әти» ди, ә син...

Т ә л г а т ь. Үз гомеремдә минем дә «әти» дип әйтәсем килгән чакларым күп булгандыр. Иптәш малайларым аталарының кулларына тотынып-җитәкләшеп узганда: «Эх, минем дә әтием булса иде!» — дип калган вакытларым аз булмады.

С ә л и м (*үзалдына әйткәндәй*). Бала...

Т ә л г а т ь. Әни миңа сезнең исемегезне дә әйтмәде. Димәк, ул сезгә нык рәнҗегән. Сез бит аны авырлы хәлендә ташлап киткәнсез, аның бөтен тормышын җимергәнсез. Сезне аның газапланулары да, кимсенүләре дә борчымаган. Сез үзегез турында гына кайгырткансыз. Малаегызның язмышы да сезне кызыксындырмаган. Юк, мин сезне «әти» дип атый алмыйм.

Р ә х и л ә. Тәлгать. (...)

Т ә л г а т ь. Мин монда кала алмыйм, китәм.

Р ә х и л ә. Җибәрмим, беркая да җибәрмим! Үзем дә китмим, сине дә җибәрмим! Киләчәгемне мин беренче мәртәбә шулай ачык күрәм. Син ачтың аны. Ул мине үзенә дәшә. Мин аңа икеләнмичә, тайпылмыйча ашкынып барам. Синең белән бергә җитәкләшеп барам! Син минем бөтен тормышымны әйләндереп ташладың. Тормышның бу кадәр матур икәнлеген белми идем әле мин. Әнә шул камышларны да, менә бу кәкре каенны да, әнә андагы көтүеңне дә — барысын да, барысын да яратам. Ишетәсеңме, яратам! Беренче мәртәбә!

П ә р д ә т ө ш ә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Өченче пәрдәдә Госманның нинди сыйфатлары ачыла?

2. Сәлим Гәрәевичне үз әтисе икәнен белгәч, Тәлгатьнең үз-үзен тотышы турында фикер алышыгыз.

3. Ни өчен Рәхилә Камилә белән Сәлим Гәрәевичне «үз әтием, үз әнием» дип атый?

4. Тәлгать үз әтисен «әти» дип әйтә алмаячагын белдерә. Сез аның белән килешәсезме? Гомумән, Сәлим Гәрәевичнең эш-хәрәкәтләрен аклап буламы?

5. Бу драманы тулысынча укып чыгыгыз һәм әңгәмә оештырыгыз.

«Беренче мәхәббәт» драмасы

«Беренче мәхәббәт» драмасында Хәй Вахит тормыш юлына яңа аяк басучы яшь геройларның өмет-хыялларын, теләк-омтылышларын, шатлык-борчуларын тормышчан материалга нигезләнгән вакыйгалар аша сурәтли. Драматург мәхәббәт хисенең тууын, аңа лаеклы булу мәсьәләсен тәрбиялелек, кешелеклелек, намуслы хезмәт төшенчәләре белән эзлекле бәйләп бирә. Әлеге олы хис кешенең әхлакый сыйфатларыннан аерылгысыз — автор әйтергә теләгән төп фикерләрнең берсе әнә шул.

Драматург кызыклы сюжет-композиция тапкан. Драма башка районда туып-үскән Тәлгатьнең килүе белән башлана. Тиздән аның өй хуҗасы Сәлим Гәрәевичнең улы булуы ачыклана. Ләкин геройның тормышына кискен тәэсир итәрлек бу вакыйга Тәлгать өчен әсәр ахырына кадәр билгесез булып кала. Ә инде Рәхилә белән Тәлгать арасында мәхәббәт хисе кабынгач, укучы сагаеп һәм шикләнеп кала — туганнар ич! Әсәрнең кульминацион ноктасы — Рәхиләнең балалар йортыннан алып үстерелгән булуы ачыклану. Ул, бер яктан, яшьләрнең берберсен яратырга тулы хокуклары барлыгын билгеләсә, икенче яктан, Госманның чын йөзен, түбән җанлы булуын күрергә һәм аңларга булыша, өченчедән, яшьлек ялгышы аркасында әлегәчә үкенеп яшәгән Сәлим Гәрәевич хисләренең югары ноктасы булып, аны аңларга һәм акларга беркадәр мөмкинлек бирә. Ул хатыны Камилә белән бер ятимә кызны алып үстергән, тәрбияләп кеше иткән.

Әсәрдәге вакыйгалар ике яссылыкта бирелә. Берсе — төп вакыйгаларга бәйле Тәлгать, Рәхилә, Госман һәм Әпсәләм, Нурсәнәләрнең мәхәббәт, хезмәт, яшәеш турындагы уйлары, эшгамәлләре, икенчесе — Сәлим Гәрәевич белән моннан 18 ел элек булган хәлләр. Соңгысы кичерешләр рәвешендә зур булмаган истәлекләрдә генә бирелсә дә, ул һәрвакыт укучыны күз алдында тота. Чөнки яшьләр арасындагы мөнәсәбәтне Сәлим Гәрәевичнең йөргән кызына карата кылган намуссыз адымы аша бәялибез, чагыштырабыз. Шулардан чыгып, драманың төп темасын һәркемнең мәхәббәте каршында, димәк, үзе алдындагы җаваплылыгы дип билгели алабыз. Ә ул исә геройларның һәрберсе арасындагы һәм эчке каршылыкларында ачыла.

Автор безнең каршыда мәхәббәткә, яшәешкә мөнәсәбәтнең дүрт төрен күрсәтә. Беренчесе драманың төп геройлары Тәл-

гать һәм Рәхилә белән бәйле. Әнисе белән генә үскән Тәлгать, яшь булуына карамастан, тормыш каршылыкларын шактый күргән. Ул инде тормышка зурларча карый белә, киләчәген авыл белән бәйләргә тели. Әсәрдә аның горур табигатьле, ихтыяр көченә ия булуы күренә. Шул ук вакытта анда аз гына дуамаллык та, кискенлек тә бар. Автор героен һич тә идеаллаштырып күрсәтми. Очраклы рәвештә Госман белән Рәхиләнең сөйләшүен тыңлап торгач, Тәлгать, беркем белән дә аңлашып тормастан, өйдән чыгып китә. Драма ахырында ул мәхәббәте өчен көрәшергә, аның кадерен белергә әзер егет булып күренә.

Тормышка китап аша караучы, үзен бары тик институт студенты итеп күрергә теләүче Рәхилә әсәрдә зур үзгәреш кичерә. Уен-көлке яратучы, беренче карашка җилбәзәк булып күренгән бу кыз бай рухи дөнья белән яши. Тәлгатькә булган мәхәббәте, фермада эшли башлавы Рәхиләнең карашларын кискен үзгәртә. Әлеге ике яшь геройның эш-гамәлендә әдипнең эстетик идеалы чагыла.

Икенче төрле яшәү рәвеше булып Госман тора. Әдәпсез, үзен генә кайгыртучы бу кеше теләсә нинди түбәнлеккә төшәргә әзер. Ул да мәхәббәт дип, яратам дип сөйләнә, ә инде аны гамәлдә ачыклау вакыты җиткәч, карашларын бик тиз үзгәртә.

Өченче төрле яшәү рәвеше итеп драмада яшь пар — Әпсәләм белән Нурсәнә тасвирлана. Җыр-музыка яратучы, шат күңелле әлеге яшьләр ниндидер эш-гамәлләре белән ачылмый, шулай да алар, булган белән канәгатьләнеп, башкаларга бик исләре китмәгән, ягъни һәркем, һәрнәрсә белән килешеп яшәүчеләр булып күренәләр.

Ниһаять, Сәлим Гәрәевич язмышы. Ул яшьлегенә, мәхәббәтенә хыянәт иткән, әмма улына һәм аның әнисенә берничек тә ярдәм итмәгән, ихтыярсызлык күрсәтеп, тормышның үз агышы белән яшәгән. Вакытлар узу белән үз гаебен аңлаган, ләкин төзәтергә соң. Улы белән дә аңлаша алмыйча яши. Тәлгатьнең аны «әти» дип әйтә алмавы — Сәлим Гәрәевичкә бирелгән иң зур җәза.

Драма «Беренче мәхәббәт» дип атала, һәм автор әлеге беренче, саф, чиста хис белән үзенең геройларын сыный. Берәүләр аңа хыянәт итеп, көчсезлекләрен күрсәтеп, гомере буе бәхетсез булып һәм үкенеп яши, икенчеләр исә мәхәббәткә, үз-үзенә тугры кала, нәкъ менә әлеге олы сөю хисе тормыш каршылыкларын җиңеп чыгарга көч бирә.



Туфан Миңнуллин
(1935 елда туган)

Хәзерге татар драматургиясе һәм театр сәнгатенең төп үзенчәлекләрен, табыш-юнәлешләрен билгеләгән әдипләрнең берсе — күренекле каләм остасы Т. Миңнуллин.

Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935 елның 25 августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында туа.

Унъеллык мәктәпне тәмамлагач, теләге университетка кереп уку булса да, тормыш Туфанны үз көнен үзе күрергә, әтиәнисенә материаль яктан булышырга мәҗбүр итә. Ул, бухгалтерлык курсында укып кайткач, кибетче, счетовод булып эшли, Казакъстан якларында чирәм җирләрне эшкәртүдә катнаша.

1968 елны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Миләүшәнең туган көне», Татар драма һәм комедия театрында сәхнәләштерелгән «Нигез ташлары» пьесалары драматургиягә талантлы, үзенчәлекле каләм остасы килүен күрсәттеләр. Шуннан соң үткән вакыт эчендә Т. Миңнуллинның уннан артык җыентыгы басылып чыкты, утызлап әсәре сәхнәгә куелды, йөзләгән мәкаләләре дөнья күрде. Аларның һәрберсе, драматургка хас осталык белән сәнгатьчә югарылыкта язылып, әдәби процесста үз урынын тапты, укучытамашачының тирән ихтирамын казанды. Әдипнең күп әсәрләре, башка телләргә тәрҗемә ителеп, Татарстаннан читтә дә танылдылар, ә инде М. Җәлил исемендәге яшьләр бүләгенә лаек булган «Үзебез сайлаган язмыш», Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Ай булмаса, йолдыз бар», РСФСРның Станиславский исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Әлдермештән Әлмәндәр» һәм үзәк телевидение аша күрсәтелгән «Моңлы бер җыр», «Әниләр һәм бәбиләр» кебек

әсәрләре Т. Миңнуллинны чорыбызның күренекле әдипләреннән берсе итеп танытты.

Т. Миңнуллин һәрвакыт эзләнүдә. Ул төрле темаларга актив мөрәҗәгать итә һәм һәрбер теманы үзенчә, үзе аңлаганча, башкаларны кабатламыйча уңышлы хәл итә. Аның тарихи, авыл-колхоз, нефтьчеләр тормышы, мәктәп-мәгариф, тарихи шәхесләр, буыннар бәйләнеше, әхлакый сафлык, Ватан һәм үз алдындагы бурычыңны үтәү, катнаш никахлар һ. б. темаларга нигезләнеп язылган әсәрләре тиз арада үз тамашачыларын таптылар һәм озак еллар сәхнәдән төшмичә уйналып киләләр. Әдип драматургиянең барлык жанрларында да бердәй актив эшли. Алар арасында сатирик, лирик, шаян, моңсу комедияләр, водевиль, интеллектуаль, социаль, фәлсәфи-публицистик драмалар, балалар өчен язылган пьесалар һ. б. бар.

Т. Миңнуллин әсәрләре төп геройларның шәхес буларак ачылу дәрәҗәсе, характер сыйфатлары, тормышчанлыклары белән аерылып торалар. Замандашыбызның уңай сыйфатларын үзләренә туплаган персонажлар халкыбызга хас гореф-гадәтләрнең, яшәү рәвешенең, буыннар арасындагы бәйләнешнең, әхлак сыйфатларының сакланышы өчен кайгыртып яшиләр. Әлеге ил картлары, тормышны төпкә җигелеп тартучы ир-егетләр, дөньяга иң камил җан иясе тудыручы, рухи башлангычны саклаучы хатыннар бик күпләргә яшәү үрнәге булып торалар.

Әдип тормыштан гел уңай герой, шатлыклы-куанычлы вакыйгалар эзләми. Җәмгыятебездәге каршылыклар, әхлаксызлык күренешләре аның каләме аша театр сәхнәсендә реалистик чагылыш табалар. Безнең тормышыбызда торган саен күбрәк урын ала барган кешелексезлек, миһербансызлык, ата-ананы хөрмәт итмәү, балаларны ятим калдыру күренешләре турында әдип чаң суга һәм аларга китергән иң җитди сәбәпләрнең берсен «Әниләр һәм бәбиләр» драмасында, үзенең баласыннан баш тартучы Дилемма образына бәйле рәвештә, укучы-тамашачыга күрсәтә.

Драматург реаль тормыш материалын фантастика һәм шартлылык элементлары белән кушып бирүдә сәхнә әдәбиятында билгеле бер адым ясады. Беренче карашка тормышчанлыгына ышануы кыен булган Әҗәл, хыялда тудырылган шагыйрь кебек образлар кергән «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр» әсәрләре, сәхнәдән үзенчәлекле яңгыраш табып, киң катлау тамашачыларның күңелен яулап алды.

Биремнәр

1. Әдипнең үзегезгә таныш әсәрләрен, тема һәм жанр ягыннан төркемләп, дәфтәрегезгә языгыз.

2. Драматургның берәр спектаклен театр сәхнәсендә карагыз, соңыннан әсәрне куюда режиссерның, артистларның роле турында әңгәмә оештырыгыз.

ҮЗЕБЕЗ САЙЛАГАН ЯЗМЫШ

(Драматик хикәя, 3 пәрдәдә, 10 күренештә)

(Кыскартып алынды)

КАТНАШУЧЫЛАР:

Туктаров Илгиз Кәримович — мәктәп директоры, 25 яшьтә.
Нариман — укытучы, 62 яшьтә.
Шәмсенур — укытучы, 54 яшьтә.
Нурия — укытучы.
Динә — унынчы класс укучысы.
Фасил — укытучы.
Айдаров Энгель Сабирович — роно мөдире, 40 яшьтә.
Шәйхаттаров Рәшит Талипович — колхоз председателе.
Рамил — укучы.
Мөнирә — мәктәп укыту эшләре мөдире.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

I күренеш

Мәктәп директоры кабинеты. Педсовет утырышы бара.

Айдаров. Иптәшләр! Бүгенге көн таләпләре буенча укытучы булу — гаять җаваплы эш. Яңа программа һәрберебездән зур җаваплылык сорый. Моны сез барыгыз да беләсез, иптәшләр. Бурычларыбызны да беләбез. Без югары өлгерешкә ирешергә тиешбез. Безнең бурыч — бер укучы да классында калмасын. (...)

Нурия. Рамилне дә тугызынчыга күчерергәме?

Айдаров. Кем ул Рамил?

Мөнирә. Мәктәпне артка сөйрәүче бердәнбер укучы, Энгель Сабирович.

Айдаров. Әйе, Рамил дә мәктәпне артка сөйрәмәскә тиеш. Дәвам итәбез. Тулы өлгереш булдыру. Ул яктан сезнең мәктәп — районда иң алдынгылардан берсе. Ярты ел йомгакларыннан күренгәнчә, сез туксан тугыз бөтен уннан бер процент өлгереш биргәнсез. Димәк, мәктәп җитәкчеләре, укытучылар коллективы җитди эш алып бара. Бу, иптәшләр, дөресен әйтергә кирәк, мактауга лаек. (...)

Нурия. Ялган!

Мөнирә. Нурия, җитте!

Нурия. Җитми торсын! Бик яхшы белеп торасыз, безнең мәктәптән өч ел инде югары уку йортына берәүнең дә кергәне юк. Нигә кергәне юк? Әйтегез әле, танылган укытучыбыз Нариман ага Газизов?

Айдаров. Иптәш Латыйпова...

Нурия. Юк, әйтсен. Сез дә әйтегез, Мөнирә Шакировна. Барыбыз да әйтик.

Тавыш башлана.

Айдаров. Иптәш Туктаров, педсоветмы бу, базармы? Тынычлык урнаштырыгыз. (*Утыра.*)

Туктаров та кузгалмый. Әкренләп тынычланалар.

Туктаров (*торып баса*). Нурия хаклы.

Айдаров (*сикереп торып*). Сез нәрсә әйтергә телисез, иптәш Туктаров?

Туктаров. Безне урынсызга мактыйсыз, Нурия хаклы. (*Кесәсеннән хат алып күрсәтә.*) Менә Нуриянең хаклылыгын раслаучы тагын бер дәлил. Бүген китереп бирделәр. (*Хатны Айдаров алдына куя.*)

Айдаров (*конвертны әйләндереп-әйләндереп карый. Конверт эченнән бер кәгазьне ачып укый.*) «Аттестат зрелости. Выдан Саттарову Халилу Хабировичу...» (*Туктаровка.*) Йә, шуннан?

Туктаров. Сез укып бетерегез. Анда бөтен предметлар «биш»ле. Аттестат хуҗасы мәктәпне алтын медаль белән тәмамлаган. Безнең мәктәпнең горурлыгы: фамилиясе почет тактасында. Ни өчен бу аттестат конверт эчендә дисезме? Рәхим итегез, менә монысы — Саттаровның хаты. Ишетәсе килгән

кешеләргә укып күрсәтәм. Өмет итмәгез, сәлам язмаган. Беребезгә дә сәлам юк. Минем фамилиядән башка берәүнең дә исеме телгә алынмаган хатта. «Туктаров абый, миңа биргән аттестатыгызны үзегезгә җибәрәм. Миңа аның кирәге юк. Чөнки ул — ялган аттестат. Мин ул аттестатка ышанып институтка кермәкче булдым. Хыялым инженер булу иде. Язма эшемә «өч»ле куйдылар. Телдән дә шул чама. Мин бернәрсә дә белмим икән. Сынау алучыларга үпкәм юк, алар тырыштылар, үзем белмәдем. Нигә сез белмәгән укучыга еллар буе «биш»ле куеп килдегез, нигә мине алдадыгыз? Алыгыз кәгазегезне. Мин хәзер эшкә урнаштым. Анда аттестат кирәкми. Мактаулы укучыгыз Хәлил Саттаров». Аңлашылдымы? Ә без алдынгылар сафында, мин — мактауга лаек директор.

Айдаров. Иптәшләр, читкә китмик. Бик күңелсез факт, әлбәттә. Ләкин, минемчә, паника куптарырлык нәрсә юк.

Нурия (*сикереп торып*). Туктагыз әле, ничек юк? Без нәрсә өчен акча алабыз соң?

Айдаров. Иптәш Латыйпова, тынычлык! Дәвам итәбез. Ярты еллык йомгакларына багышланган педсоветны дәвам итәбез. Безнең бурыч, иптәшләр, унынчы классны тәмамлаган һәр укучының югары уку йортына керүе түгел. Безгә производствода эшләр өчен дә белемле кешеләр кирәк. Әгәр сез укыткан балаларның барысы да югары уку йортларына керсә, кем сыер савар, кем җир сөрер, кем машина йөртер?

Туктаров. Әгәр без укыткан укучыларның барысы да сыер сауса, җир сөрсә, машина йөртсә, кем космоска очар, кем атомны йөгәнләр, кем балаларны укытыр?

Нурия. Камайлар, Сәгъдиевләрне кем әзерләр?

Туктаров. Безнең заманга белемле кешеләр кирәк. Аттестатлы кешеләр түгел, белемле кешеләр. Кайда гына эшләсә дә, ул белемле булырга тиеш. Аларны белемле итү — безнең бурыч. Ә без нишлибез? Әйдәгез әле, иптәшләр, шул турыда сөйләшик. Сөйләшергә вакыт җитте. Хакыйкать ачы булса да түзик. Мөнирә Шакировна, сез ни дисез?

Мөнирә. Ә ни өчен мин?

Туктаров. Алайса, Нариман ага. Сез ни дисез?

Айдаров. Иптәш Туктаров...

Туктаров. Юк инде, бергәләп сөйләшик, Энгель Сабирович. Нигә беркем дә сөйләми. Җайлы гына үтеп киткән җыелышларга күнектекме? Рәхәт. Берәүләр оек бәйли, икенчеләр йоклый. Уяныйк мәллә, иптәшләр?

Айдаров. Илгиз Кәримович, туктатыгыз бу кәмитне!

Туктаров. Кәмит түгел, фаҗига.

Айдаров. Иптәшләр, педсовет ябык. Таралырга мөмкин. (...)

III күренеш

Нариманнар өе. Пәрдә ачылганда, өйдә Шәмсенур белән Нариман. (...) Мөнирә керә.

Мөнирә. Керергә ярыйдыр бит?

Шәмсенур. Әйдә, Мөнирә, чишен, уз.

Мөнирә. Чишенеп тормыйм. Эчем пошкач, кереп чыгыйм дидем. Илгиз Кәримович кайтмадымы әле?

Шәмсенур. Юк.

Мөнирә (*пальтосын салып*). Нәрсә, Нариман абыйның кәефе юкмы әллә?

Нариман. «Биш»ле. Уз. (*Үзе диванга барып утыра.*) (...)

Мөнирә. Гомерең буе йомшак кеше булдың. Сине коллектив каршында мыскыл итәләр, синнән көләләр.

Нариман. Син шуңа сөенденңме?

Мөнирә. Ни сөйлисең, Нариман абый?

Нариман. Сөендең. Син кеше башына бәла килгәнне көтеп йөрисең. Сиңа рәхәт була. Директорга каршы компания җыярга чыккансың. Сиңа шатлык, ә мин җылыйм. Беләсеңме син, Нариман җылый. Җылый!

Шәмсенур керә.

Шәмсенур. Нариман.

Нариман. Чәй эчерт Мөнирәгә. Ул ашыга. Тагын унлап өйгә керәсе бар.

Мөнирә. Керәм, Нариман абый. Мин синең кебек җылак түгел. Мин үзем өчен көрәшә алам! Мин хакыйкатьнең тапталуын теләмим. Мин — укытучы. Минем хакым бар! Мин — егерме ел гомеремне мәктәпкә биргән кеше. Ә ул — тулар-тулмас дүрт ел. Үземә җинаятьче дип әйткәннәрен тыныч кына тыңлап тора алмыйм. (...) (*Урыныннан торып, элгечтән пальтосын ала.*) Мин яңадан педсовет җыюларын таләп итәчәкмен, Нариман абый. Болай калдырырга ярамый. Син, билгеле, гадәттәгечә, эндәшми утырырсың. Син, билгеле, сүз әйтә алмыйсың, ул синдә фатирда тора. Бәлки, файдасы да тиеп куяр. Киләсе елга да дәресләр бирер.

Ш ә м с е н у р. Мөнирә, юкны сөйләмә, син — олы кеше.

Н а р и м а н (*үзен көчкә тыеп*). Мөнирә, бар чыгып кит. Тизрәк чыгып кит.

Ш ә м с е н у р. Нинди көн булды соң бу!..

М ө н и р ә. Ярый, сау булыгыз. (...)

Т у к т а р о в кайтып керә.

Ш ә м с е н у р. Кайттыңмы? Чәй өлгергән, әйдә, чишен.

Т у к т а р о в . Хәзер, Шәмсенур апа. (*Үз бүлмәсенә уза.*) (...)

Туктаров чыгып өстәл янына утыра. Шәмсенур аңа чәй ясап бирә. Пауза.

Т у к т а р о в. Ничек, Нариман ага?

Н а р и м а н. Ал да гөл, иптәш директор.

Т у к т а р о в. Педсоветны дәвам итәбезме соң?

Н а р и м а н. Сезгә педсовет тансыктыр да, мин аларны күп күрдем, туеп беткән.

Т у к т а р о в. Шуңа күрә бер сүз дә дәшми утырасызмы? (...)

Н а р и м а н. Мин калай әтәч түгел. Телемә ни килсә, шуны кычкырмыйм.

Т у к т а р о в. Кычкырмыйча ярамый иде бит.

Н а р и м а н. Кычкырыгыз, әйдә. Сез — яшьләр. Без — картлар тыңларбыз.

Т у к т а р о в. Яшьлекнең, картлыкның ни катнашы бар, Нариман ага, укытырга кирәк. Сиксәндәме без, егермедәме — биргән белемебез бүгенге көн югарылыгында булсын. Бүген ун ел элек укыткан кебек укытырга ярамый.

Н а р и м а н. Без укытмаган шул, кырык ел буе урамда ат тизәге тибеп йөргән.

Т у к т а р о в. Шулай дип әйтерсез дип уйлаган идем. Нишләргә тиеш идем соң мин? Макталганга куанып утырыргамы? Дөрес түгел бит. Начар укытабыз. (...) Авылга болай да ярар әле дип, тыныч кына, канәгать булып йөргәнбез. Безнең медальле укучыбыз да хәтта укуын дәвам иттерергә сәләтсез булып чыккан.

Н а р и м а н. Математикадан «өч»ле алган.

Т у к т а р о в. Математикадан булмаса, бүтәннән алыр иде. Чәкәләшүдән мәгънә юк, уйлашырга кирәк. Без үзебезгә үзебез ревизия ясарга тиешбез. Сез дә, мин дә, башкалар да.

Нариман. Башкаларда эшем юк. Иртәгә мине эштән азат итү турында приказ яздырыгыз. Ревизияне калганнар белән ясарсыз. Эшләрегез яхшырыр. Бөтен укучыларыгыз академик булып бетәр. (...)

Туктаров. Болай сөйләшеп булмый, Нариман ага. Бу бала-чага сүзе, сезгә килешми. (...)

Пәрдә төшә.

Сораулар

1. Педсовет утырышында Нурия нәрсәгә каршы чыга? Туктаров ни өчен аны яклый?
2. Ни өчен Нурия белән Туктаров башка укытучыларда теләктәшлек тапмыйлар?
3. Мөнирә Нариман янына нинди максат белән килә? Ни өчен Нариман аны бик тиз чыгарып җибәрә?
4. Нариман Туктаровны нәрсәдә гаепли? Ни өчен алар аңлаша алмыйлар?

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

IV күренеш

Директор кабинеты. (...) Артта тәнәфестәге шау-шу. (...) Мөнирә керә. (...)

Туктаров. Рогаткадан кем атканын ачыкладыгызмы, Мөнирә Шакировна? Атучы Рамил түгел, анысы хак.

Мөнирә. Беләм.

Туктаров. Нигә алайса...

Мөнирә. Илгиз Кәримович, мин үз дәресемә үзем хуҗа.

Туктаров. Әлбәттә. Ләкин сезгә гафу үтенергә туры киләчәк Рамилдән.

Мөнирә. Башка әйтер сүзегез юкмы?

Туктаров. Аңлагыз, Мөнирә Шакировна, дөньяда иң явыз җан иясе — укучы. Син аңа яхшылык эшләсәң, рәхмәт әйтми, шулай тиеш дип кабул итә. Әгәр урынсызга рәнҗетсәң, беркайчан да гафу итми һәм беркайчан да онытмый. (...)

Мөнирә. Түздем, түздем. Инде чыдарлыгым калмады. Җитте. Уйнамагыз минем белән. Мин дә кеше. Әйтсәгез, туры әйтегез. Нишләргә җыенасыз сез, максатыгыз ни?

Туктаров. Безнең максат барыбызның да бер генә — укыту.

Мөнирә. Юк. Сезгә кемнәрдер ошамый. Сезгә алардан котылырга кирәк. Сезгә алар комачаулыйлар. Сез монда үзегезнең тәртибегезне урнаштырырга телисез. Укытучыларның авторитетын бетереп, укучыларны аларга буйсынмаска өндисез.

Туктаров. Бу — төрмә түгел, мәктәп, Мөнирә Шакировна. Укучылар буйсынырга түгел, укытучыларны хөрмәт итәргә тиеш. Ә без аларга белем бирәсе урынга авторитетыбыз турында күбрәк кайгыртабыз. «Алты еллык образованиебезне селкетеп» балаларны өркетәбез. (...)

Мөнирә. Минем дипломым бар.

Туктаров. Моннан егерме ел элек алган диплом һәм белем. Егерме ел буе шул килеш торган. Сез — татар әдәбияты укытучысы, хәтта «Казан утлары» журналын да укымыйсыз бит. Каныгумы бу? Хәтта бүген алган диплом да, яңартып тормасаң, иртәгә искерә. Тормыш хакыйкате.

Мөнирә. Хакыйкатегез белән Нариман абыйны ектыгыз инде. Хакыйкать дип сөйләгәнче, кешелекле булырга кирәк.

Туктаров. Мин — кешелексез кеше — Нариман аганы ектым, ә сез — кешелекле кешеләр — аның хәлен дә барып белгәнегез юк. Нариман ага икенче көн инде урын өстендә.

Мөнирә. Озакламый барыбыз да егылабыз.

Туктаров. Бүтәннәр нишләр, әмма сез егыла торган түгел, сез нык торасыз. Мин укытучы буларак кызганмыйм сезне, мин сез укыткан укучыларны кызганам. (...)

Мөнирә. Әйтегез, әйт. Килерләр, тикшерерләр. Кемнең кем икәнен белерләр. Кем үз укучысы белән типтергәнен дә белерләр.

Туктаров. Кем ул минем укучым? Динәме? Димәк, ул гайбәтне сез таратып йөрисез.

Мөнирә. Гайбәтне йөзгә бәреп әйтмиләр.

Туктаров. Сез — татар теле укытучысы, «типтерү» дигән сүзнең мәгънәсен беләсезме?

Мөнирә. Минем мораль йөзем чиста.

Туктаров. Теләсәгез ни сөйләгез, ләкин мәктәптә укыту мин теләгәнчә булыр. Ишеттегезме, мин теләгәнчә, сез укытканча түгел. Бөтен көч, бөтен ихтыяр, бөтен вакыт, гомеребез, иманыбыз балаларга багышланган булырга тиеш. Безнең теләсә кайсы укучы теләсә кайсы вузга кереп укый алырлык булсын. Без аларны шуңа әзерләргә тиешбез. Әгәр кем дә кем

шулай укытырга сәләтсез икән, мәктәпкә якын килмәсен! Монда сезгә дә, миңа да ташлама юк. Үзебез сайлаган язмыш, түзәргә туры килә.

VI күренеш

Нариманнар өе. Вакыт кич. Диванда Нариман ята. (...) Атылып Д и н ә килеп керә. (...) Бүлмәсенә кереп китә. (...)

Д и н ә *(үз бүлмәсеннән чыга).* (...) Син шундый кайнар, әти. Рәхәт. Мин шундый тундым. (...)

Ш ә м с е н у р. Сумкаң кайда?

Д и н ә. Ничек инде кайда? (*Бүлмәсенә күрсәтеп.*) Шунда.

Ш ә м с е н у р. Анда юк. Сумкасыз кайттың.

Д и н ә (*исенә төшеп*). Калган.

Ш ә м с е н у р. Кайда?

Д и н ә. Юк, калмаган. Ул Илгиз абыйда. Тик ни өчен аңарда дип сорамагыз. Ялганларга өйрәтмәгез.

Н а р и м а н. Син дөресен әйт!

Д и н ә. Дөресенме? Синең колагыңа гына әйтәм. (*Нариманның колагына пышылдый.)*

Ш ә м с е н у р. Нәрсә?

Д и н ә *(диваннан төшеп).* Яратам мин Илгиз абыйны, менә шул. (*Өстәл янына килеп утыра.*) Йә, инде, ачуланыгыз.

Ш ә м с е н у р. Илгиз абыең кайда?

Д и н ә. Хәзер кайта. Мин алдан чаптым.

Ш ә м с е н у р. Кайда идегез?

Н а р и м а н. Анысы нәрсәгә? Кайта, диде.

Д и н ә. Без аның белән басуда йөрдек.

Н а р и м а н. Бөтенесен сөйләп бирмәсәң дә ярый. Синең яшьтәге кызларның серләре дә булырга тиеш.

Д и н ә. Рәхмәт, әти. Менә, ичмасам, әти дисәң әти!

Н а р и м а н. Әмма ләкин дөньяда бернәрсә бар, кызым...

Д и н ә. Башны югалтмаскамы? Эх, әти, башны югалтырлык булмагач, мәхәббәт буламыни ул.

Ш ә м с е н у р. Йә! Артыгын сөйли башладың. Әтиең дигәч тә, ул бит сиңа иптәш кызың түгел, чамадан чыкма. Әтиең әйтеп бетергәнне тыңла. Алай бул, болай бул, дип боермасак та, киңәш бирергә хакыбыз бар.

Д и н ә. Мин сезне аңлыйм, әни. Курыкмагыз, минем өчен сезгә оялырга туры килмәс. Нариман белән Шәмсенур үстер-

деләр кызның әйбәтен, диярләр. Сезгә шул җитәме? Әллә инде Илгиз абыйга якын бармаска боерасызмы?

Нариман. Эш боеруда түгел. Әниең борчыла.

Динә. Кызы өчен борчылмаган ана анамыни ул! *(Шәмсенурны кочаклап.)* Борчылма, әнием. Мин ялгышсам да, Илгиз абый ялгышмас. Ул ялгыша белми. *(Бүлмәсенә кереп югала.)*

Нариман *(торып, урынын рәтли)*. Булды, Шәмсенур, безнең кирәк калмаган, инде тынычлап үләргә дә була. (...) Укытучы була алмасам да, менә дигән балалар үстергәнмен. Һәрберсе алтын казык. Кара син бу төпчекне! Яратсын, Шәмсенур, күңеленә кем ошый, шуны яратсын. Күңеле туры минем кызымның!

Туктаров кайтып керә. (...) Үз бүлмәсенә юнәлә.

Нариман. (...) Ашыкмагыз әле, Илгиз. Әйтеп калдырасы сүзләр бар.

Туктаров. Ничек — калдырасы?

Нариман. Тыңла. Әгәр бездән күчеп киткән булсаң, гафу итмәгән булыр идем. Егет кеше булып чыктың. Аннан соң, Динә сине ярата. Ә минем балалар теләсә кемне яратмыйлар. Күрәсең, мин аңлап бетермәгән яхшы якларың бар. Шулай да син тупасрак. Дөреслекне дә кешене рәнҗетмичә әйтеп була.

Туктаров. Мин сезне рәнҗетер өчен әйтмәдем.

Нариман. Ләкин мин рәнҗегән идем. Әлбәттә, син хаклы идең. Без мүкләнә башлаганбыз. Дөньяның чаптар ат икәнен онытканмын. Син хаклы. Мөнирәләр, Хәдичәләр, минем кебекләр белән бүген укытып булмый. Үтенечем шул: Илгиз, Динәнең киләчәге синең кулда. Канаты каерылмасын. Бик акыллы кыз булса да, кай якка очканын белеп бетермәве бар. (...) Мөнирә синең өстән министерствога жалоба язган. Бәлки, комиссия җибәрерләр.

Туктаров. Килсеннәр. Мин курыкмыйм.

Нариман. Килсеннәр, карасыннар, тикшерсеннәр. Ярдәмнәре тияр. Киңәшләр бирерләр. Юкса, син, алай ярамый, дип кычкырасың да, ничек кирәклеген үзең дә белеп бетермисең. Сөзәр өчен — мөгез, тибәр өчен тояк кирәк. Тагын менә нәрсә, Илгиз... *(Кинәт тынып кала.)*

Туктаров. Нариман ага, Нариман ага...

Нариман. Шәмсенур... Динә... чакыр...

Туктаров *(Динә бүлмәсе янына атылып барып)*. Шәмсенур апа! Динә! *(Шәмсенур белән Динә чыккач.)* Нариман ага...

Шәмсенур белән Динә, ашыгып, диван янына киләләр. (...)

Шәмсенур. Нариман, сиңа әйтәм. (*Кинәт ни булганын аңлап.*) Нари-ма-а-ан!..

Пәрдә төшә.

Сораулар

1. Мөнирәнең укучылар белән мөнәсәбәте нәрсәгә нигезләнә? Укытучы буларак, ул сездә нинди тойгылар уята?

2. Мөнирәнең түбәнлеккә төшүенең сәбәбе нәрсәдә?

3. Динәнең укытучысын — мәктәп директоры Илгизне яратуына сезнең мөнәсәбәтегез ничек?

4. Әти-әнисе белән мөгамәләсендә Динәнең нинди сыйфатлары ачыла?

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

VIII күренеш

Урам. Урамда Динә. Ул көтә. (...) Туктаров керә. (...)

Динә. Илгиз абый, мин ниндидер хат турында ишеттем. Дөресме ул? Дөресме, әйтегез, яшермәгез.

Туктаров. Дөрес.

Динә. Миңа, Илгиз абый, бу мәктәптән китәргә кирәк.

Туктаров. Кая?

Динә. Башка мәктәпкә күчәм.

Туктаров. Ни өчен?

Динә. Ни өчен икәнен сез беләсез. Миңа бер «ике»ле, бер «өч»ле куйдылар. Мин аларны хаксызга куелган билгеләр дип саныйм. Хаксыз билгеләр икәнен исбатлау миңа бу мәктәптә мөмкин булмаячак. Сезгә дә исбатлау авыр булачак. Шуңа күрә сынауларны мин башка мәктәптә бирергә тиеш. Айдаров абый белән сөйләшмәкче идем, сезнең киңәшне көттем.

Туктаров. Әллә ничек килеп чыга түгелме соң бу?

Динә. Мин үземә ышанам.

Туктаров. Эш ышануда түгел...

Динә. Үгетләргә уйламагыз, Илгиз абый, мин моны үземнең кеше икәнемне исбатлар өчен эшлим. Сезне яратырга хакым бар икәнен исбатлар өчен эшлим. (...)

IX күренеш

Мәктәп директоры кабинеты, кабинетта Фасил белән Айдаров. Фасил директор өстәле артында.

Фасил. Димәк, Илгиз безнең мәктәпкә ярамады?

Айдаров. Комиссия шундый нәтиҗәгә килде. Туктаров үзен коллективка каршы куйды.

Фасил. Ләкин Илгиз хаклы булып чыкты бит. Имтиханнар вакытында укучыларыбызның белеме түбән икәнлеге расланды. Комиссия моны яхшы белә. Сез дә беләсез.

Айдаров. Ә Газизова? Ул да бит шушы мәктәптә укыган. Бөтен экзаменнарын «биш»кә бирде.

Фасил. Ул — бердәнбер. Ул — талант. Андыйлар сирәк була. Аңа безнең ярдәмебез күп тигәндер дип әйтә алмыйм. Аның сәләте белән урта мәктәпне моннан ике-өч ел элек тәмамлап була иде. Янә торып, коллектив дигән сүзегез ялгышрак. Комиссия үткәргән педсоветта бөтен коллектив каршы чыкмады Илгиз Кәримовичка.

Айдаров. Сигез-тугыз кеше әз түгел инде ул. Комиссия дә бит Илгиз Кәримовичны хаксыз дими. Ул үзенең хаклы икәнлеген дөрес булмаган метод белән исбатларга тырышты. Кыскасы, хәл ителгән. Туктаров үз теләге белән китә. Ул — яхшы укытучы, ләкин җитәкче булырга өлгереп җитмәгән. Мәктәп скандал оясына әйләнергә тиеш түгел. (...)

Шәйхаттаров керә. Айдаров белән кул биреп күрешә.

Шәйхаттаров *(Фасилга)*. Барыгыз әле, чыгып торыгыз. *(Фасил чыгып китә.)* (...) Дөресен әйткәндә, егет кызганыч бит. Характеры бар, җебегән түгел. (...) Кемне куярга уйлыйсыз инде? Бу сандугачнымы? Ике көндә чәйнәп ташлыйлар бит аны хатыннар.

Айдаров. Ялгышасыз. Беләсезме, ул нәрсә диде? Әгәр мине директор итеп куйсагыз, Шәйхаттарованы мәктәптән куам... азат итәм, диде.

Шәйхаттаров. Җаныма тиделәр. Ярамый икән, кусыннар. Минем монда ни катнашым бар. Туктаровны җибәрергә ярамый. (...)

Туктаров керә.

Гомерең озын булыр. Нихәл?

Туктаров (*шат*). Исәнмесез, Рәшит Талипович. Кәефегез ничек?

Шәйхаттаров. Минем кәеф шәп. Менә син нигә авызыңны ерасың?

Туктаров. Ә ни булган?

Шәйхаттаров. Кыланма. Ишеттем.

Туктаров. Кечкенә мәсьәлә. Китүдә, китмәүдәмени эш? Хаклы булуыңның исбатлануын күрүдән дә зуррак нинди шатлык бар?

Шәйхаттаров. Хаклы кешене эшеннән кумыйлар.

Туктаров. Мине эшемнән кумадылар. Мин — укытучы. Ә директорлык... Печатьне кемгә тапшырырга, Энгель Сабирович? (...)

X күренеш

Басу капкасы. Туктаров, Шәмсенур керәләр. Алардан арттарак Динә атлый.

Шәмсенур. Иртә таңнан китмәсәң дә була иде инде...

Туктаров. Юлга иртән чыгарга кирәк, Шәмсенур апа. (...)

Шәмсенур. Миңа ачуланма... Хәсрәтем зур. Ничек авыр икәнен утыз ел бергә гомер иткәч аңларсыз. Йә, сау бул. Хат яз. (*Китә.*) (...)

Динә. Минем нигәдер җылыйсым килә, Илгиз абый. Автобуска утырганда, мине кысып-кысып кочакларсыз, ярыймы.

Туктаров. Сагынырмын инде.

Динәне кочаклый. Атлыгып Нурия керә. Кочаклашып торган Динә белән Туктаровны күреп туктап кала. Чыгып китәргә көч таба алмый. (...)

Нурия. (...) Нигә сез алай, Илгиз Кәримович, качып китеп барасыз?

Туктаров. Кичә бөтенесе белән дә хушлаштым.

Нурия. Бәлки, озатып куярга теләүчеләр булгандыр. Сез бит, төштән соң гына китәм, дидегез.

Туктаров. Шулай килеп чыкты.

Нурия. Фасил абый үпкәләячәк.

Динә сиздерми генә чыгып китә. (...) Атлыгып Фасил керә.

Фасил. (...) Нәрсә, Илгиз Кәримович, әллә чынлап китүегезме?

Туктаров. Кичә әйттем ич, Фасил абый.

Фасил. Мин ышанмадым. Өч ел бергә кайнашып кунакка да чакырганым булмады. Илгиз Кәримович, бәлки, кире кайтырсыз? Документларыгызны алмый торыгыз. Билгеле, сезне директор итмәсләр. Әш анда түгел. Без бит — директорлар түгел, укытучылар. Бәлки, китмәссез, ә?

Туктаров. (...) Кем белә, бәлки, кайтырмын да. Башта әле туган авылыма, әнием янына кайтып ял итәм.

Фасил. Монысы дөрес. Сезнең дәресләр сезне көтеп торачак.

Динә атылып керә.

Динә. Илгиз абый, автобус!

Туктаров. Исән булыгыз, Фасил абый. Исән бул, Нурия.

Фасил. Сине хәзер автобуска күтәреп утыртабыз.

Чыгарга хәзерләнә. Нурия аны кулыннан тотып туктата. Туктаров чыгып китә.

Фасил. Кулларымнан ник тоттың, Нурия?

Нурия. Без анда артык, Фасил абый. (...)

Пәрдә төшә.

Сораулар

1. Үзенең белем дәрәҗәсен исбатлау өчен, Динә нинди карарга килә? Сез аның белән килешәсезме?

2. Колхоз председателе Шәйхаттаровның Туктаровка мөнәсәбәте нинди?

3. Туктаровны эшеннән алып, мәктәп директоры итеп Фасилның билгеләнүе тулысынча акланамы? Фикерегезне дәлилләгез.

4. Туктаровның мәктәптән китүе аның җиңелүе түгелме? Сез ничек уйлыйсыз?

«Үзебез сайлаган язмыш» драмасы

Тормыштагы иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрне дөрес тоемлап иҗат итүче Т. Миңнуллин 70 нче еллар башында театр сәхнәсенә мәктәп тормышын алып менә. Укучыны тәрбияләп, аның шәхесен формалаштыра, белем бирә торган уку йорты ни белән яши, укуның сыйфаты ничек, киләчәк перспективалары ышанычлымы? Әлеге һәм башка мәсьәләләр һәркемне борчып тора. Мәктәпләр тормышына үтеп кергән күзбуяучы-

лык, формализм күренешләрен сурәтләп, драматург бу җитди проблемага киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә.

«Үзебез сайлаган язмыш» драмасында вакыйгалар шактый көчле драматик каршылыкка нигезләнеп үстерелә: мәктәпнең педагогик советы утырышында югары өлгерешкә ирешү турында җитди сөйләшү бара (экспозиция). Шунда ук мәктәпне медаль белән тәмамлаган элекке укучыдан хат килүе, аның укытучылар коллективын тиешле белем бирмәүдә, ялган билгеләр куюда гаепләве ачыклана. Бу мәсьәләгә мөнәсәбәттә коллектив ике төркемгә аерыла, ягъни сюжет сызыгының төенләнеше барлыкка килә. Алга таба Илгиз Туктаров һәм Нуриянең уку сыйфатын күтәрү өстендәге тырышлыкларына, икенче яктан, Мөнирә һәм аның тарафдарларының күнегелгәнчә, тыныч кына яшәп, билгене дә укучының яисә әтиәнисенең кем булуына карап куярга омтылуларына нигезләнгән вакыйгалар үстерелеше, көчәя барып, үзенең кульминацион ноктасына җитә — министерстводан комиссия килә. Һәм, ниһаять, чишелеш — мәктәп директоры Илгиз Туктаровны эшеннән алалар, завуч Мөнирәне башлангыч класс укытучысы итеп күчерәләр.

Укыту-тәрбия эшен оештыруга бәйле төп конфликт Туктаров һәм Мөнирә Шакировна каршылыгына нигезләнә. Моңа исә Илгиз белән Нурия, Илгиз белән Нариман, Илгиз белән Шәйхаттаров һәм Нурия белән Мөнирә, Динә белән Мөнирә, Рамил белән Мөнирә арасындагы конфликтлар килеп кушыла. Әлеге ярдәмче каршылыкларда төп конфликтның асылы, тирәнлеге, сәбәпләре һәм хәл итү юллары ачыклана. Каршы якларның максат-бурычлары, эчке каршылыклары аларның үзәгендә торган образларның эш-гамәлләре белән билгеләнә.

Вакыйгаларны үзенә туплап, әсәрнең үзәгендә Илгиз Туктаров образы тора. Өченче ел гына мәктәп директоры булып эшләвенә карамастан, аның район мәгариф бүлегендә авторитеты бар. Шул ук вакытта ул мәктәпнең ни өчен «алдынгылар» рәтендә йөрүен дә бик яхшы белә. Укучыларның белемтәрбия дәрәҗәсе, укуның сыйфаты өчен борчылып яшәүче директорга элекке укучының хаты соңгы этәргеч була. Ул мәктәптәге формализмга, макталу өчен процент артыннан куугa, кайбер укытучыларның ялган авторитетына каршы көрәш башлый. Ләкин моңа кадәр җыелышларда оек бәйләп яки йоклап утырган коллективны кузгату җиңел булмый. Әлегәчә булган белән канәгатьләнеп яшәргә күнеккән укытучылар-

ның бер өлеше аны аңламый һәм аңларга да теләми. Туктаров өстеннән төрле оешмаларга шикаятьләр җибәрелә. Шулай да яшь директор ялгыз түгел. Ул, яшь укытучы Нуриягә таянып, инде акны карадан аера белүче укучыларның ышанычын тоеп эш итә.

Элекке мәктәп директоры, пенсиягә чыккач та укытуын дәвам итүче Нариманга (Туктаровның фатир хуҗасы да) бәйле вакыйгаларда бу бәрелеш тагын бер баскычка күтәрелә. Иске белән яңаның тартышуын җентекләбрәк күрсәтергә омтылган драматург өлкән буын белән яшь буын каршылыгына килеп чыга. Нариман ага Туктаровның педсоветта шактый тупас формада әйтелгән фикерләрен баштарак кабул итми. Ул аны яшьлек дуамаллыгына бирелүдә, картларның элекке хезмәтләрен күрмәүдә гаепли. Гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган бу намуслы укытучы Туктаровның дөреслегенә тиз төшенә. «Әлбәттә, син хаклы идең. Без мүкләнә башлаганбыз. Дөньяның чаптар ат икәнен онытканмын. Син хаклы. Мөниреләр, Хәдичәләр, минем кебекләр белән бүген укытып булмый»,— ди ул Илгизгә.

Драмадагы каршылыкны «Нурия — Илгиз — Динә өчпочмагы» тагы да көчәйтеп җибәрә. Нурия җавапсыз мәхәббәт белән ярата. Бу исә аларның хезмәттәшлегендә дә чагыла. Туктаров формализмга каршы чыккан Нурияне тиз генә аңлый алмый. Мәктәп директоры җитди эчке каршылыкта яши. Мәктәпнең макталуын тели ул, шул ук вакытта хаксызлыгын да сизә. Шундый хәлдә Туктаров шактый тупас рәвештә коллективның бер өлешенә үзен каршы куя, аларның эшчәнлеген тиешле юнәлештә үстереп җибәрә алмый. Шулай да үзен туры сүзле, намуслы итеп кенә түгел, үз сүзендә нык торучы, принципиаль, зур ихтыяр көченә ия булган яхшы тәрбияче итеп күрсәтә. «Бөтен көч, бөтен ихтыяр, бөтен вакыт, гомеребез, иманыбыз балаларга багышланган булырга тиеш. (...) Әгәр кем дә кем шулай укытырга сәләтсез икән, мәктәпкә якын килмәсен! Монда сезгә дә, миңа да ташлама юк. Үзебез сайлаган язмыш, түзәргә туры килә»,— ди ул Мөнирәгә. Туктаров һәм Нурияләр йомыкыйланып йөрүче биология укытучысы Фасил кебекләргә дә тәэсир итәләр, аларны битарафлык сазлыгыннан тартып алалар.

Көн тыныч кына үткәнгә канәгать булып, «авыл баласына ничек тә ярар» дип йөрүче Мөнирә — каршылыклы образ. Мәктәп завучы буларак, үзен баш иючеләр белән чолгап алган

һәм, билгеле инде, кирәк вакытта аларга «ташлама» да ясый — эленке-салынкы дәрес бирүләренә күз йомып карый. Шунлыктан «тыныч күлгә оялаган җеннәрне» тузгытучы Туктаровка каршы чыгучыларның башында тора, укытучы исеменә тап төшерә торган гамәлләр кыла. Драмадагы эш-хәрәкәтләрендә аның үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртуы, педколлективта һәм укучылар арасында авторитетны ялган белән яки яхшы билге куюю аша яулап алырга омтылуы ачык чагыла. Мөнирә никадәр генә тискәре итеп сурәтләнсә дә, Туфан Миңнуллин бу героинясына да битараф түгел, аның мондый түбәнлеккә төшүе сәбәпләрен ачарга омтыла. Мөнирәнең күңеле яралы — ул гаилә кора алмаган, ялгыз яши. Яшь вакытта үзен яратып йөргән егеткә, гади колхозчы дип, кияүгә чыкмаган. Ялгызлык, үкенү, кеше бәхетенә көнләшеп карау, аның характерындагы тискәре сыйфатларның өстенлек алуына китергән. Драматург, әнә шул рәвешле, хатын-кызның тормыштагы урыны, бәхете мәсьәләләре турында да уйланырга этәрә.

Т. Миңнуллинның зур уңышы итеп пьесадагы Динә образының бирелешен саный алабыз. Автор өлкән класс укучыларының (бигрәк тә кызларның) психологиясен, уй-фикерләрен, теләк-максатларын яхшы белүен күрсәтә. Динә образы үзенең тормышчанлыгы, киләчәккә омтылышы һәм дөреслекнең өстен чыгуына ышанычы белән аерылып тора. Ул мәктәп директоры Илгиз Туктаровны ярата. Пьесадагы вакыйгалар, Динәнең әти-әнисе, укытучылар, Туктаров белән мөнәсәбәте шуны күрсәтә: ул — намуслы, саф күңелле, акыллы, нык ихтыярлы һәм принципиаль кыз. Үзенең белемен раслау өчен, хәтта имтиханнарын да башка мәктәптә бирә.

Драманың «Үзебез сайлаган язмыш» дип аталуы әсәрнең төп идеясен аңларга ярдәм итә. Укытучы әлеге профессияне сайлавы белән аңа гомере буе тугры калырга тиеш. Яшь буынны тәрбияләү киләчәк белән бәйле. Укытучының туктальп калырга хакы юк, аннан алга карап яшәү сорала. Мөнирә һәм аның кебекләр исә, бүгенге белән генә яшәп, хаксызлыкка ярашканнар, ул аларның яшәү рәвешенә, холыкларына үтеп кергән. Шуның белән бергә, драмадагы конфликтның хәл ителешендә каршылык та күренә. Әсәр Туктаровның мәктәптән китүе белән тәмамлана. Дөрес, рухи җиңү аның ягында. Фасил, Нурия, Шәйхаттаровларның аны озатырга килүе шуны күрсәтә. Укучы һәм тамашачы да Илгизнең киләчәктә яхшы укытучы һәм җитәкче булуына шикләнми. Әмма түбән-

дәге сораулар ачык кала: Ни өчен Туктаров үзенең дәресле-ген башка җирдә расларга тиеш? Әсәрдә шактый йомшак характерлы булып күренгән Фасил коллективның эшен ти-ешенчә оештыра алырмы? Укытучы исеменә бик үк лаек бул-маган Мөнирә ни өчен башлангычка күчерелә? Түбән классларда теләсә кем һәм теләсә ничек укытса да ярыймыни? Ә бәлки Т. Миңнуллин хаксызлыкның җәмгыятьтә киң урын алуын һәм аның әлегә (әсәр язылган чорда) көчле булуын, өстен чы-гуын күрсәтергә теләгәндер? Сораулар, сораулар! Әйдәгез, бергәләп уйлашыйк!

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрне тулысынча укып чыгарга тырышыгыз һәм андагы төп конфликтны билгеләгез.

2. Драмада нинди проблемалар күтәрелә? Көрәшүче якларның максатларын ачыклагыз.

3. Туктаровка бәя бирегез.

4. Мөнирә образын характерлагыз. Эчке каршылыгын билгеләгез.

5. Эш-хәрәкәтләренә бәйләп, Нурия һәм Фасилның характер сыйфатын ачыклагыз.

6. Динә образына характеристика бирегез.

7. Әсәр исеменә салынган мәгънәне ачыклагыз. Драманың төп идеясе нидән гыйбарәт? Ул бүген дә актуальме?

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Балалар әдәбияты, гомуми әдәбиятның бер тармагы буларак, шуның составында үсә. Кайбер әдәбиятчылар, тәнкыйтьчеләр фикеренчә, әдәбият фәненең балалар әдәбиятын өйрәнүче юнәлеше XIX гасырның икенче яртысында формалаша.

Балалар әдәбиятын фәнни классификацияләп, аның өч төрен бүлеп чыгарырга мөмкин («Татар балалар әдәбияты».— Казан: ТаРИХ, 2003):

1. Турыдан-туры балаларга багышланып язылган әсәрләр (А. Алиш әкиятләре, Ф. Әмирхан, Д. Аппакова хикәяләре, Т. Миңнуллин, Г. Гыйльманов пьесалары, Г. Тукай, Б. Рәхмәт, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин шигырьләре һ. б.).

2. Өлкәннәр өчен язылып, вакытлар үтү белән, балалар укуына күчкән әсәрләр (К. Гали. «Кыйссаи Йосыф: «Кисекбаш» һ. б.).

3. Балаларның үз иҗаты.

Башка халыклар әдәбияты кебек үк, татар балалар әдәбиятының да барлыкка килү һәм үсү тарихы, ерак гасырлардан юл алып, халык авыз иҗатына (фольклорга) барып тоташа. «Сак-Сок бәете», «Үги кыз», «Мәче белән Төлке», «Таңбатыр», «Гөлнәзек», «Шомбай», «Зөһрә кыз» һ. б. әкиятләр балалар укуында озак еллар дәвамында тәрбия хезмәтен үти. Фольклор әсәрләре яхшыны начардан аерырга өйрәтеп, гаделлек, зирәклек, шәфкатьлелек кебек сыйфатларның һәрвакыт кадере кимемәвен аңлата.

Балалар әдәбияты һәм аның тарихын өйрәнүгә күп өлеш керткән Ф. Ибраһимова үзенең хезмәтләрендә XIX гасыр балалар әдәбиятының мәгърифәтчелек дидактизмы кысаларында формалашуы, эчтәлеге ягыннан *дини* һәм *дөньяви юнәлешләргә* бүленүе турында яза. Беренче татар мәгърифәтчеләре Х. Фәезханов, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин һ. б. XIX гасырның урталарында ук мәктәп-мәдрәсәләрдә дини һәм дөньяви

белем бирү мәсьәләләрен күтәреп чыгалар. Шуның нәтиҗәсе буларак, беренче уку китаплары, хрестоматияләр төзелә һәм аларда фольклор әсәрләре, тәрҗемәләр, әдәби әсәрләр туплап бирелә.

XIX гасырның икенче яртысында татар балалар әдәбиятына рус, Көнбатыш Европа, гарәп-фарсы әдипләре әсәрләренең йогынтысы сизелә башлый. «Мең дә бер кичә», «Кәлилә вә Димнә» әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә. Бу чорда балалар өчен иҗат иткән мәгърифәтчеләрнең иң күренеклесе — мәшһүр галим Каюм Насыйри. Иҗат эшенә керешкән елларында ук, ул татар телендә халыкка аңлаешлы әдәби әсәрләр булмавын, ә балалар әдәбиятына игътибарның бөтенләй юклыгын күрә һәм бу өлкәдә эшне башлап җибәрү һәм үстерү өчен күп көч куя. Аның фәнни, әдәби һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарында балалар өчен уку китаплары, дәреслекләр язудан башлана. Мәгърифәтченең балалар өчен беренче фәнни-популяр хезмәте «Буш вакыт» 1860 елда дөнья күрә, ә 1868 елда күпкә тулыландырылган икенче вариантын эшләп бастыра. Әлеге китапның төп максаты — балаларга һәм дөньяви фәннәр белән кызыксынучыларга анатомия, табигать белеме, тирә-юнь турында кызыклы мәгълүматлар бирү.

К. Насыйри иҗатының тагын бер мөһим юнәлеше — тәрҗемә. Ул нигездә Шәрык әдәбиятына мөрәҗәгать итә. Ул тәрҗемә иткән «Әбүгалисина кыйссасы», «Гөлрөх һәм Камәрҗан» маҗаралы романы, «Кырык вәзир кыйссасы» һ. б. бүген дә әһәмиятләрен югалтмаганнар.

К. Насыйри балалар тәрбиясенә багышланган китаплары белән дә танылa. «Әхлак рисаләсе», «Балаларга тәгълим бирмәк», «Китап-эт-тәрбия», «Аракы эчәргә гадәтләнгән кешеләргә бер-ике кәлимә сүз», «Тәмәке тартучының әсәле» һ. б. хезмәтләре — яшь буынга сәламәт, белемле, әхлаклы булып үсү өчен файдалы чыганаклар.

Һәр чорның күренекле вәкилләре һәм балалар әдәбиятында әйдәп баручы темалар бар.

XX гасыр башы — тарихи үзгәрешләрнең күп булуы ягыннан гына түгел, ә татар әдәбияты һәм сәнгате үсешендә дә үзенчәлекле чор. Гасыр башында яңа программалар эшләнә, җәдит мәктәпләрдә төрле дөньяви фәннәр укытыла башлый. Чорның алдынгы карашлы шәхесләре, заман таләпләреннән чыгып, яңа *уку китаплары* төзиләр: Г. Тукай «Яңа кыйраәт» (1909), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910), Н. Думави

«Безнең мәктәп» (1911—1917), М. Укмасый «Алтын таҗ» (1912).

XX гасыр башында *милли тәрбия бирүне яктырткан китаплар* басыла. Мәсәлән, Р. Фәхреддиннең «Тәрбияле бала», «Нәсыйхәт», М. Саминың «Балаларга 44 киңәш», З. Насыйриның «Мәктәп кызларына уку» һ. б. шундый китаплар.

XX гасыр башында Г. Тукай, Дәрдемәнд, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ф. Агиев, Н. Думави, М. Гафури кебек талантлы шәхесләрнең балалар әдәбиятына килүе исә, алга таба сәнгатьчә фикерләү юнәлешенең өстенлек алуына һәм моңарчы яшәп килгән коры үгет-нәсыйхәт, дини дидактикага каршы көрәшнең башлануына этәргеч була.

Бу чор балалар әдәбияты тематик яктан баюы белән дә аерылып тора. Анда иске белән яңа көрәше, ятимлек проблемасы, табигать күренешләрен тасвирлау, атеистик мотивлар яңгыраш таба. Мәсәлән, Г. Тукайның «Юаныч», «Сабыйның укырга өйрәнүе», «Энҗе бөртекләре», Дәрдемәнднең «Балалар өчен вак хикәяләр» җыентыгы, Ф. Әмирханның «Нәҗип», «Ул үксез бала шул», Г. Исхакыйның «Кәҗүл читек», Г. Ибраһимовның «Яз башы», «Карт ялчы», Н. Думавиның «Ятим бала», З. Ярмәкинең «И, ятим» һ. б. әсәрләр заманның бик күп проблемаларын ачканнар.

Октябрь борылышыннан соң, гомуми әдәби мохит эчендә үскән балалар әдәбияты өчен дә яңа — социалистик эчтәлектәге үзгәреш этабы башлана. 1920—1930 еллар әдәбияты яңа буын вәкилләрен һәрьяклап камил һәм туган илен сөюче итеп тәрбияләү юнәлешендә эзләнүләргә аеруча бай булды.

20—30 нчы еллар балалар әдәбиятының формалашуы партия контроле йогынтысында бара, махсус карарлар чыгарыла.

Бу елларда татар балалар әдәбияты өлкәсендә иҗат итүчеләр С. Рәмиев, М. Җәлил, Һ. Такташ, Г. Толымбай, Ф. Кәрим, А. Алиш, Н. Исәнбәт, С. Айдар, Б. Рәхмәт, Ә. Бикчәнтәева, С. Әдһәмова, Ә. Түрәй, Һ. Сәгыйди, Г. Гомәр, Г. Рәхим, К. Әмири, Г. Мохтар, Ченәкәй, И. Госманов һ. б. булдылар. Әлеге чор язучыларының фикерләре, иҗатлары да бертөрле түгел. Әмма шул чор балалар әдәбиятын үстерүдә һәрберсенең роле зур. Гомумән, барлык әдәбият кебек үк 20—30 нчы еллар балалар әдәбияты да бәхәсләрдән читтә калмый. Балалар әдәбияты нәрсәгә таянып үсәргә тиеш? Традицион классикага таяныргамы әллә төптән үзгәрергәме? Уңышлы яки уңышсыз әсәрләрне

нинди принципларга таянып аерырга? Әлеге сорауларның барысына да җавап табарга туры килә.

20 нче еллар азагында Г. Тукай мирасы нигезендә дә кайнар бәхәсләр булып ала. Язучылар Н. Баян, С. Самадов шагыйрьнең «Шүрәле», «Су анасы» кебек әкиятләренең зарары турында язалар. Әмма шундый бәхәсләр вакытында Һ. Такташ, М. Гафури, М. Җәлил, Г. Ибраһимов һ. б. үткән тарихны яклау юлына басалар һәм аның яңа әдәбиятны үстерүдәге ролен ачыклыйлар.

Бу чор татар балалар әдәбияты нигездә тамырлары белән фольклорга, берникадәр татар һәм рус классик әдәбиятына барып тоташа. А. Алишның әкиятләре, Г. Ибраһимовның «Алмачуар», М. Гафуриның «Ялчы», «Хәзер ансат ул, элек кыен иде», Һ. Такташның «Караборынның дусты», И. Гази, Г. Толымбай, Ә. Айдар, С. Җәләл, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, М. Гафури, З. Гыйффәт һ. б. дистәләгән хикәяләре, повестьлары, шигырьләре һәм поэмалары языла. Шуның белән бергә, берничә шәһәрдә балалар өчен журналлар чыга башлый.

1940—1960 еллар әдәбияты нәрсә белән характерлы соң?

Бөек Ватан сугышы әдәбият һәм сәнгатькә дә җитди үзгәрешләр алып килә. Туган илне ярату, аны дошманнан саклау темасы, патриотик хисләр белән сугарылган шигырьләр матбугат битләрендә тагы да күбрәк басыла башлый. Балалар өчен чыгып килгән «Пионер каләме», «Яшь ленинчы» басмалары ябылса да, балалар темасы «Совет әдәбияты» журналы, «Кызыл Татарстан» газетасы битләренә күчә.

1945 елда СССР Язучыларының X пленумында балалар әдәбиятының сугыштан соңгы үсеше, бурычлары һәм максатлары турында зур сөйләшү була. Уку, белем мәсьәләсенә дә басым ясала. Татарстан Мәгариф комиссариаты, Язучылар берлеге белән берлектә, 1945 елның 1 ноябреннән балалар өчен иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан итә. Ул 1952—1955 елларда да уздырыла.

1954 елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышында балалар драматургиясе һәм аны үстерү мәсьәләләре карала.

Б. Рәхмәт, Ә. Ерикәй, Н. Исәнбәт, Җ. Тәрҗеманов, Ә. Бикчәнтәева, Л. Ихсанова, Ш. Маннур, М. Әмир, Г. Гобәй, Н. Гайсин, Ә. Фәйзи кебек язучыларның әдәбиятка килүе сугыштан соңгы чорда балалар әдәбиятын үстерүдә зур этәргеч була.

60—90 нчы еллар әдәбияты, моңа кадәр булган тәҗрибәләргә, традицияләргә таянып, яңа шартларда үсә. Балаларның

психологиясен өйрәнеп, аларның теләкләрен, кызыксынуларын аңлап иҗат итүгә игътибар арта. Ә. Бикчәнтәева, Н. Гайсин, Ж. Тәрҗеманов, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, Р. Хафизова, Р. Вәлиева, М. Фәйзуллина, Х. Халиков, Т. Миңнуллин, Р. Мингалим, Р. Миңнуллин, Р. Батулла, Ф. Яруллин, Р. Корбан һ. б. иҗаты шул турыда сөйли.

Аерым язучыларның әсәрләре кабат халыкка кайтарылды. Алар арасында Колшәриф (Кол Шәриф), Г. Исхакый, Г. Рәхим, Ф. Кәрими, Ә. Айдар, Ф. Агеев һ. б. аерым урын алып тора.

Күренекле әдипләр А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, И. Гази, Г. Бәширов, Ш. Маннур, Ф. Хөсни, Р. Мостафин, В. Нуруллин, Р. Төхфәтуллин, Ә. Баянов, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, С. Хәким, Н. Фәттах, Р. Харис һ. б. балалар әдәбиятына зур өлеш керттеләр. Аларның әсәрләрендә чор проблемалары, әхлак, гореф-гадәтләр, белем һәм һөнәр, кешенең рухи, эчке матурлыгы мәсьәләләре һ. б. күтәрелде.

Гомумән, 60 нчы еллардан соң балалар әдәбияты белән кызыксыну аеруча арта. Кайбер очракта таныш образлар, охшаш шигырьләр күренгәләсә дә, яңалыкка омтылыш әйдәп баручы фикергә әйләнде. Бу чорда Ш. Галиев, Ж. Тәрҗеманов, Ф. Яруллин, Р. Корбан, Г. Гыйльманов һ. б. шагыйрьләрнең таланты аша эчтәлек һәм форма ягыннан демократик, фәлсәфи, эстетик, психологик һәм социаль идеяләр балалар акылы өчен дә аңлаешлы итеп тәкъдим ителде.

Әдәбиятта фәнни-фантастик, детектив, маҗаралы жанрларда иҗат итүче язучылар күп түгел. Балалар өчен бу жанрда 60—90 нчы елларда А. Тимергалин, Р. Фәизов, Ж. Дәрзаман, Г. Рәхим һ. б. танылган язучылар иҗат итә.

Сораулар һәм бирем

1. Балалар әдәбияты нинди төрләргә бүленә?

2. Үзегезнең дә шигырь, хикәяләр, әкиятләр язганыгыз бармы? Аларны бергәләп сыйныфта укыгыз.

Җәвад Тәрҗеманов
(1920—1995)

Җәвад Әфтах улы Тәрҗеманов 1920 елның 8 июлендә Казан шәһәрендә туа. 1938 елда Яңа Бистәдәге 3 нче номерлы татар урта мәктәбен тәмамлагач, Казан химия-технология институтына укырга керә. 1944 елда диплом яклап, аспирантурага калдырыла, 1950 елда ул, техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен, диссертация яклый һәм аннан соң үзе укыган институтның металлар технологиясе кафедрасында чирек гасырдан артыграк доцент булып эшли. Аның үз белгечлеге буенча бик күп гыйльми хезмәтләре бар. Фән һәм техника өлкәсендәге хезмәтләре өчен Җ. Тәрҗемановка 1981 елда Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Җ. Тәрҗеманов матур әдәбиятка мәктәп партасыннан килә. Аның поэзия өлкәсендәге беренче тәҗрибәсе — «Безнең җавап» шигыре — VII сыйныфта укыган чагында языла, 1935 елда «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыга. Шуннан соң ул газетада шигырьләре, укучылар һәм мәктәп тормышыннан кечкенә мәкаләләре белән катнаша башлый. Ул иҗат белән шундый мавыгып китә ки, хәтта X нчы сыйныфта укыганда ук аның «Кызыл галстук» исемле шигырьләр җыентыгы басыла.

Җ. Тәрҗеманов катлаулы образлар белән эш итми. Аның шигырьләрендә тормыш чынбарлыгы урын ала. «Йөгерек су» шигырендә ул баланы чиста булырга кирәк дигән фикергә этәрә.

Йомшак су, йөгерек су!
Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын,
Битләрем аллансын...

60 нчы елларда аны балалар язучысы итеп танытткан күп санлы тезмә һәм чәчмә әсәрләре языла, китаплары басылып чыга. Туган ил, бәйрәмнәр, табигать һәм аның байлыклары, балалар бакчасы, мәктәп еллары, пионер тормышы, күмәк уеннар, үзара мөнәсәбәтләр — Җ. Тәрҗеманов иҗатының төп тематикасы әнә шулар.

Җ. Тәрҗеманов иҗатының икенче бер юнәлеше — әкиятләр. Балалар әдәбиятында А. Алиш традицияләрен дәвам итүче Җ. Тәрҗемановның әкиятләрендә төп геройлар — тырыш бал кортлары, шаян күбәләкләр, мактанчык чебеннәр. «Көмешкойрык мажаралары», «Ябалак белән Тавык», «Күбәләк җилбәзәк», «Шуктуган», «Шаян белән Наян», «Бал корты һәм Ишәк» һ. б. әкиятләренең теле халыкчан, гади.

«Тукран малае Шуктуган» әкиятенең исеме үк үзенә тартып тора. Әкиятне шигырь кебек укыйсың. Сүзләрне кабатлап бирү, бай эпитетлар, сынландырулар әкиятнең музыкальлеген арттыра, шигырь кебек укыла. Бу әкияттә балалар урманда сәяхәттә йөргән кебек. Автор бер генә күренешне дә игътибардан читтә калдырмый. Әкиятнең ахыры татар халык әкиятләренең тәмамлау тәртибен саклый. «Менә шунда әкият бетте. Бу вакыйгадан соң байтак еллар үтте. Шуктуган күптән инде үсеп буйга җитте. Ул хәзер үзе бабай, ләкин бигүк карт түгел алай. Көйли-көйли әкиятләр сөйли. Менә монысын үзем язып алдым — шигъри калыпка салдым».

60 нчы еллардан башлап Җ. Тәрҗеманов яшьләр һәм өлкәннәр өчен дә иҗат итә. Ул 1965 елда бөек математик Н. И. Лобачевскийның тормышы һәм фәндәге беренче адымнары турында «Лобачевскийның яшьлеге» исемле документаль роман яза. Галимнең бай, катлаулы, каршылыклы тормыш юлын бөтен тулылыгы белән ачарга тырышып, әсәрне тагы да дәвам итә, һәм, шулай итеп, «Көмеш дага» романы дөнья күрә. Бу романны иҗат итүдә Җ. Тәрҗеманов үзен математика өлкәсендә дә киң эрудицияле шәхес итеп танытты.

Сорау һәм бирем

1. Җ. Тәрҗемановның әдәбиятка килү юлы турында сөйләгез.
2. Аның иҗатының төп темалары нидән гыйбарәт?

ӘНИЕМ ТӘСБИХЫ

Сабый чагымда дәү әтиләрдә дә (Спас өязе — хәзерге Иске Әнҗерә авылы) безнең Казан шәһәренең татарлар күп яши торган өлеше Яңа Бистәдә дә йортның тышкы ишеген яки капканы һичкайчан бикләмиләр, ә шулай да мин тәрәзәдән йөрүне кулайрак күрә идем. Гөл чүлмәкләрен бәреп төшерүем, тәрәзә өлгеләрен чәлпәрәмә китерүләрем дә еш булгалый, ләкин боларның ачысын-төчесен күбесенчә мәчебез «татый» иде.

Берчак шулай җәй башында, Рамазан (ураза) аенда, авылыбыз мулласы — дәү әтиемнең, авыруларга эчерү өчен, тәлинкәгә догалык язганда куллана торган зәгъфран гөлен бәреп төшергән көнне, әнием хөрмә төшләреннән үзе тезгән дисбесен тартып, камыш намазлык өстендә кояшның баеп беткәнен көтеп утыра иде, башы илә ымлап кына мине чакырып китерде дә, алдында урын күрсәтеп, кулыма тәсбихын тоттырды.

— Бисмиллаһир-р-рәхмани-әр-рәхим! — дип сүзгә кереште ул.— Өфе шәһәрендә яшәүче Кәшшаф абыең, хаҗга баргач, Гарәбстандагы мөселманнар мәркәзе Мәдинә шәһәреннән алып кайткан хөрмә җимеше төшләреннән ясалган бу дисбе, ә хәзер, улым, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгаләдән изге Коръән иңгән мәрхәмәтле Рамазан аедыр... Берәр начар эшне моңарчы эшләгәнеңә үкенеп, яңадан кабатламаска сүз биреп, шул начар гадәтеңне ташлау өчен, менә бу тәсбих төймәләрен, «Әстәгъфирулла» (ягъни «Аллаһы ярлыкасын-кичерсен») дип әйтә-әйтә, бер якка күчереп куярга кирәк. Бөтен Җиһанны яраткан Аллаһы Тәгалә барысын белә, барысын күрә вә ишетә... Йәле, улым, менә шулай тот та һәр төймәне «Әстәгъфирулла» дип уңга таба күчерә бар...

Тәсбих тарта башлавыма, тәрәзәдән чыгып барганда зәгъфран гөле чүлмәген чәлпәрәмә китерүем һәм аны мәчебезгә сылтаганым исемә килеп төште дә, үз-үземне белештермичә, үксеп елап җибәрдем...

Әнием илә икәүләп елашкан шул көннән соң, мин инде ишектән генә йөри башладым.

Сораулар

1. «Әнием тәсбихы» хикәясе нинди вакыйгага багышлана? Лирик герой (мин) кайчан үз ялгышын аңлый дип уйлыйсыз.

2. Сез үз ялгышларыгызны таный беләсезме? Бу алдагы гамәлләрегезгә йогынты ясыймы?



Хәкимҗан Халиков
(1933—2002)

Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиков 1933 елның 16 гыйнварында Татарстанның Әтнә районы Мамыш авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1948 елда Чембулат мәктәбен тәмамлагач, Арча педагогия училищесына укырга керә. 1952 елда үз районнарында мәктәптә эшли. 1954—1960 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. 1963 елдан Казанда яши. Башта «Ялкын» журналында, аннан «Яшь ленинчы» газетасында, «Идел» әдәби альманахының мөхәррире, «Совет мәктәбе» журналының бүлек мөдире вазифаларын башкара.

Х. Халиков балалар әдәбиятында прозадан кала барлык жанрларда актив эшли: шигырьләр, җырлар, шигъри әкиятләр, табышмаклар, тел шомарткычлар, сәхнә әсәрләре яза. Ул балалар әдәбиятына килгәнче, шактый озак эзләнүләр чоры кичерә. Өлкәннәр өчен язылган баштагы шигырьләре район газеталарында басыла.

1969 елда сабыйларга атап язылган «Йолдызлар ничәү?» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыга.

Мәктәптә, пионер матбугатында озак еллар эшләгән педагог һәм журналист буларак, ул балалар тормышын, аларның үй-теләкләрен яхшы тоя һәм шуларны, җанлы тасвир һәм характерлар аша үтемле итеп, укучыларына җиткерергә тырыша.

Авторның поэтик стиле, шаян интонациясе балаларны үзенә тартып тора. Шагыйрь гади генә күренешләрне дә елмаеп сурәтли:

Нишләр инде Кыш бабай,
Ут капкан сакалына.
Ала-кола тунын сөйрәп,
Төньякка чаба гына.
Тук-тук...

Тизрәк бу хәбәрне
Җиткерим дип дусларга,
Телеграмма суга тукран
Көзен киткән кошларга.

(«Яз хәбәре»)

Х. Халиков әсәрләрендә бөтен табигать, үсемлекләр дөньясы да кешеләрдә уңай сыйфатлар формалаштыру өчен ярдәм итә. Аның герое табигать эчендә яши, андагы үзгәрешләрне сизә, матурлыкны күрә белә. «Тукран табыны», «Тартар белән сөйләшү», «Ятим тургай», «Кояшбикә челтәре», «Кырмыскадан сора», «Тыйнак инеш», «Өч яфрак» шигырьләрендә табигатьне ярата белүче шәхес тәрбияләү максаты куелган.

Шагыйрьнең сатира-юмор остасы булуын күрсәткән шигырьләре дә байтак. «Ни сыерчык, ни чыпчык», «Тавык йөри», «Мактанчык», «Кызык иттем», «Үзен яманлый» һ. б. шигырьләрендә тәнкыйть шактый көчле, әмма ул образлар эченә яшерелеп бирелә, кинаяләп әйтелә.

Х. Халиков — әкиятләр, театральләштерелгән уеннар авторы да. «Яшел докторлар», «Чәчәк җыйганда», «Балтырган ашы» һ. б. әсәрләре дару үләннәрен таный һәм куллана белергә өйрәтү, үсемлекләр дөньясына сак караш тәрбияләү максатын игътибар үзәгендә тотып язылган.

Балалар әдәбиятын үстерү һәм яшьләр матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Х. Халиковка 1984 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә. Ул — Россиянең Халык мәгарифе отличнигы.

Сораулар һәм бирем

1. Х. Халиков нинди жанрларда иҗат итә?

2. «Геройлары матурлыкны күрә белә» дигән юлларны аның әсәрләре мисалында раслагыз. Матурлыкны күрә белү нәрсә дигән сүз ул?

ТАВЫК ЙӨРӘК

Безнең Тәүфыйк ник болай
Шулкадәрле куркактыр?
Тавыктан да шүрли ул,
Ышанмасаң — тыңлап тор.

Чыккач баскыч төбенә
Беркөн чеби карарга,
Башын сузып, Чуаркай:
«Кыт-кыт», — диде аңарга.

«Һай, чукый!» — дип еларга
Шул да җитте Тәүфыйкка.
Булсаң тавык йөрәкле,
Куркыта шул тавык та.

Сорау һәм бирем

Бу шигырь балаларга гына атап язылды микән? Анда зурларга да ишарә юкмы? Булса, шул юлларны табып укыгыз һәм үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

ЧЫНЛАП АКСАДЫ

Үтеп бара бер бабай,
Чиста гына киенгән.
Тормыш изгән, күрәсең,
Көянтәдәй иелгән.

Протезы авырмы,
Чак-чак сөйри аягын.
Тук-тук итеп, адымын
Саный сыман таягы.

Аннан көлеп, бер малай
Бара иде аксаклап,
Абынды да лап — җиргә,
Кайтып китте чак атлап.

Хәзер чынлап аксый ул,
Маңгае да тишелгән.
Бәлки, инде моннан соң
Көлмәс гарип кешедән.

Сорау

Шигырьдә кешедәге нинди тискәре сыйфатка игътибар ителгән? Малайның үзе дә шул хәлдә калуы очраклы микән?



Җәүдәт Дәрзаман
(1945 елда туган)

Җәүдәт Харис улы Дәрзаман 1945 елның 13 октябрендә Татарстанның Лениногорск районы Сугышлы авылында туа. Иске Шөгер мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Шуннан соңгы тормышы Татарстан радиокомитетының балалар тапшырулары редакциясе, «Ялкын» журналы, «Татарстан яшьләре» газетасы, Татарстан дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе белән бәйләнгән.

Җ. Дәрзаман әдәби иҗатка мәктәп елларында ук кереп китә. Район һәм республика газеталары белән элемтәдә тора. Балалар шагыйре буларак, ул 70 нче елларда формалаша. 70—80 нче елларда аның «Ирбатыр», «Солдат булдым», «Төнге маҗара», «Гөлназ мәктәпкә бара», «Безнең әлифба», «Илләр гизә Илгизәр» китаплары дөнья күрә.

Ул өлкән сыйныф укучыларына адресланган «Җир авазы», «Җиләкле көннәр», «Бизмән йолдызлыгы», «Ник керәсең төшләремә?» проза әсәрләре, җырчы Гөлсем Сөләймановага багышланган «Моңнар фәрештәсе» поэмасы авторы буларак та танылды.

Җ. Дәрзаман — җыр текстлары авторы да. Аларның күбесе республиканың күренекле композиторлары тарафыннан көйгә салынган һәм яратып җырлана.

Җ. Дәрзаман шигъриятендә бала белән ата мөнәсәбәтенә аерым игътибар бирә, аны тирәнрәк ачарга тырыша. Үрнәк алырдай ата образы бирелү аның уңышлы алымы дип әйтергә кирәк.

Һәр көн иртүк торып
Йөрим сукмак ерып.
Бер эшләгән көнгә,
Сукмак салам өйгә.
Әти киңрәк көри,
Аннан зурлар йөри.

(«Көрәк»)

Үстең инде, улым дип,
Эш өйрәнсен кулың дип,
Әти чүкеч тоттырды,
Бер кадакка суктырды.

(«Тылсымлы чүкеч»)

Шагыйрь шигырьләрендә «яхшы бул» дип акыл сатмый, ә аны уен, эш-гамәл аша, теләк-хыял буларак балага җиткерергә тырыша. Тәрбияви характердагы «Карурман кунаклары», «Мотаһир коесы», «Айбулат» әкият-поэмалары фольклорга нигезләнеп язылган.

Җ. Дәрзаман — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләге лауреаты (2001).

Сорау

Җ. Дәрзаманның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Ул кайсы жанрда уңышлырак эшли дип исәплисез?

ЫШАН БАРЫ ЙӨРӘК АВАЗЫҢА

Күңелеңне кинәт моң-зар басса,
Чит-ятларга сөйләп бушанма.
Ышан бары йөрәк авазыңа,
Бер минутлык хискә ышанма.

Күзләр җитсә, гыйшык алмагачы
Биш гашыйкка бирер биш алма.
Ышан бары йөрәк авазыңа,
Буш сүзләргә, зинһар, ышанма.

Бер ялгышсаң, тагын ялгышырсың,
Ялгышырсың кабат тусаң да —
Ышан бары үзең сөйгән ярга,
Кеше сөйгән ярга ышанма.

Ачма, иркәм, ачма тәрәзәңне,
Кар-буранлы салкын кыш анда:
Ышан бары ихлас күңелләргә,
Ихлас түгелләргә ышанма.

Сорау

«Йөрәк авазы» дигән төшенчәне ничек аңлыйсыз? Автор ни өчен йөрәк авазына ышанырга өнди?

ӘЛМӘ

Урманда яз көне күрдем дә
Ни дип тә уйларга белмәдем,
Аланда шау яфрак ярганын
Былтыр көз киселгән әлмәнең.

Имәнеп, яшәргә дым эстәп,
Тамыр күк таралган тармаклар —
Әйтерсең тигезсез сугышта,
Тартышып, иң соңгы сулышта
Туфракта тырмаша бармаклар...

Сорау

Сез ничек уйлыйсыз, әлеге шигырендә автор табигать күренешләре турында гына әйтергә телиме?



Шәүкәт Галиев
(1928 елда туган)

Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. Шагыйрьнең үсмер чаклары Бөек Ватан сугышының кырыс, авыр елларына туры килә.

Ул матбугаттагы эшчәнлеген 1946 елда район газетасында башлап җибәрә. Республика матбугатында 1948 елда күренә башлый.

Шәүкәт Галиев үзенең беренче әсәрләрендә үк Бөек Ватан сугышының кырыс чынбарлыгын, ачлыгын, ятимлеген, авырлыгын, туган авылы һәм аның тырыш кешеләрен, мәхәббәт хатирәләрен чагылдырган тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә. Шагыйрьнең «Яңа көйләр», «Кичке утлар», «Әткәйгә хат» җыентыклары һәм «Хәтимә апа», «Сугышларда калган...», «Солдат әби» кебек шигырь-поэмаларында һәм шигырьләрендә дә сугыш калдырган күңел ярасы, толлар язмышы тирән эчке кичереш белән тасвирлана.

Кырык дүртнең кышы узып китте...
Без белмәдек күңел тынгысы.
Сөенешеп укыган теге хатың
Кайгылысы булды, соңгысы...

...Ә беркөнне, зарыгып хат көткәндә,
Почта авыр хәбәр китерде.
Кош теледәй кәгазь әнкәйне — тол,
Безне кинәт ятим иттерде...

60 нчы елларда шагыйрь аеруча балалар өчен актив иҗат итә башлый. 1962 елда аның «Камырша» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Шагыйрь әсәрләрендә үз фантазиясе

тудырган гаҗәеп, шул ук вакытта чынбарлык дөньяны тасвирлый. Аның шигырьләрендә яңа теле ачылган нәниләрдән алып үсмер егет һәм кызларның күпкырлы һәм кызыклы тормышы, кеше һәм шәхес буларак формалашу процессында катлаулы мөнәсәбәтләре сәнгатьчә һәм реалистик буяуларда бирелә.

Шагыйрь Шәүкәт Галиев үзенең хыялында тудырган Шәвәли, Камырша, Котбетдиннәр балаларның иң якын геройларына әверелделәр. Ул һәр фикерне үзенең герое фикере аша җиткерергә тырыша. Әмма һәр фикер җитди бер кимчелекне кисәтү чарасы булып тора:

Бөтен кеше шаккатты,
Шаккатты, тел шартлатты.
Кулларын тотып карасак,
Мөмкин түгел танырга —
Эшләмәгәч, Тимершабыз
Әйләнгән ич камырга!
Бигрәк йомшак мускул бу,
Мускул түгел, мыскыл бу!
Әй Тимерша, Тимерша,
Син бит хәзер — Камырша!

(«Камырша»)

Шагыйрь «Кадак», «Фән кушканча», «Сарыкмахерская», «Уяулык», «Космонавт булабыз дип...», «Борау», «Багана нык каккан» һ. б. шигырьләрендә авыл һәм шәһәр балаларының тормышка һәм кешеләргә мөнәсәбәтен, заман проблемалары белән кызыксынуын күрсәтә. Шигырьләрендә ул балалар кызыксынган сорауларга җавапны үзләреннән таптырырга тырыша. Шәүкәт Галиев бигрәк тә табигатьне, табигый матурлыкны саклауга басым ясый. Кычытканны оныткан Әсмага ул үзен тиз искә төшертә:

...Үзен искә төшергән,
Яндырган да пешергән,
Кара син кычытканны —
Яратмый оныткканны!

(«Кычыткан»)

Шәһәргә күчерелгән юкәләргә лирик герой болай дип дәшә:

...Ятсынмагыз, юкәләр,
Юксынулар бетәрләр,
Моңаешып калмагыз.
Сез безне дә аңлагыз:
Без дә үстек авылда,
Сезсез күңелсез монда.

(«Урман күчә урамга»)

Шагыйрь Шәүкәт Галиев иҗатының үзенчәлеген билгеләп, әдәбият белгече Нил Юзиев: «... Поэзиянең бер-берсеннән төрле чикләр белән аерылган өч өлкәсе... Лирика... Сатира. Нәниләр шигыре... Һәрберсендә әйтер сүзе бар... Һәрберсендә үзгә бер Шәүкәт...» — дип яза.

Балалар әдәбиятын үстерү өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен («Шәвәли», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Кызык», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» һәм рус телендә чыккан «С папой в кабине» шигырь китаплары өчен) Шәүкәт Галиевкә 1972 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Рус теленә тәрҗемә итеп чыгарылган «Заяц на зарядке» китабы өчен ул 1982 елда Х.К. Андерсен исемендәге дипломга лаек булды. Шулай ук 1984 елда ВЛКСМ Үзәк Комитетының А. П. Гайдар билгесе белән бүләкләнде, Ш. Галиевнең татар әдәбиятын үстерүдәге эшчәнлеге Татарстан хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнде: аңа 1996 елда А. Алиш исемендәге премия бирелде, «Почет Билгесе» ордены (1978), «Хезмәттәге батырлык өчен» медале (1970) белән бүләкләнде. Татарстан Республикасы Президенты указы белән 1995 елда Татарстан Республикасының халык шагыйре дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ш. Галиев иҗаты турында алдагы сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерегез.

2. Ш. Галиев — лирик шагыйрь. Шул фикерне үзегез укыган шигырьләр белән дәлилләгез.

3. Халык мәкаленә әверелеп киткән «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән фикернең авторы кем?

4. Балалар язучысы буларак, Ш. Галиев иҗатының үзенчәлеге нәрсәдә дип уйлыйсыз? Аның нинди шигырьләрен яратып укыйсыз?

УРМАН КҮЧӘ УРАМГА

Урманнарга көз килде,
Алтын-сары төс иңде.
Каеннар һәм чаганнар,
Имәннәр йоклаганнар.
Усаклар да юкәләр
Оеп черем итәләр.

Килделәр дә абзыйлар,
Агач төбен казыйлар.
Әйбәтләп, ипләп кенә
Алдылар төпләп кенә;
Машиналарга салып
Киттеләр ерак алып.

Күчерделәр барын да
Кала урамнарына.
Юкәләр берни белми,
Уянып та өлгерми...
Басып туп-туры алар,
Тезелешеп торалар.
Ә кешеләр, кешеләр
Сокланышып үтәләр:
— Бигрәк матур юкәләр!
...Яз җитте, йокы качты,
Юкәләр күзен ачты.
Гаҗәпләнгән бөреләр
Ят бер җирне күрделәр.
Урамнар тап-тар кебек,
Машина таптар кебек...
Юксындылар урманны —
Бергәләшеп торганны.
Җилләрдә кагындылар,
Дусларын сагындылар.
— Кайда син, урманкаем,
Кайда син, сылу каен?..
Әй юкәләр, юкәләр,
Юксынулар бетәрләр,
Моңаешып калмагыз.
Сез безне дә аңлагыз:
Без дә үстек авылда,
Сезсез күңелсез монда.
Кайгырмагыз, юкәләр,
Юллар шулай итәләр,
Сорамыйлар бит алар,
Төрле якка илтәләр...
Ятсынмагыз, юкәләр,
Еллар шаулап үтәрләр,
Шәһәр сезне иркәләр,
Малайлар үз итәрләр.
Сындырмас, каермаслар,
Дуслардан аермаслар...
...Урман күчә урамга,
Күңелле булыр анда.

Бирем

Әлеге шигырьдә автор әйтергә теләгән төп фикерне ачыклагыз.

БАГАНА

Кайтып килә Дөлфәт урманнан,
Шундый арган, шундый арган —
Кайта торгач өстерәлеп,
Туктый баганага терәлеп.
Малайның бик ачуы чыга,
Киерелеп торып бер суга.
— Син, багана, армаган,
Урманга да бармаган,
Көне буе тик торган,
Төне буе тик торган,
Гомер буе тик торган!
Кит юлдан!!

Тора-тора да багана тыңлап,
Җавап бирә малайга зыңлап:
— Кара, башыңны күтәребрәк,
Кәпәчеңне артка этәребрәк —
Бер дә утырмыйча басып торам,
Иңемә чыбыклар асып торам!
Кемгә дә сиздермибез арганны,
Күрәләр бары җиргә ауганны...

Сорау

Шигырьдәге сынландырулар нинди максаттан кулланылган?



Роберт Миңнуллин
(1948 елда туган)

Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин 1948 елның 1 августында Башкортстанның Илеш районы Нәҗәде авылында дөньяга килә. Балачагы һәм яшьлек еллары Шәммәт, Аккүз авыллары белән бәйләнгән. VIII сыйныфны тәмамлагач, ул Уфадагы сәүдә-кулинария училищесына укырга керә. 1966 елда Карабаш урта мәктәбен тәмамлый, район газетасы редакциясендә дә эшләп ала. Аннан соң ул Казанга килеп, университетның тарих-филология факультетын тәмамлап, 1973 елда «Яшь ленинчы» балалар газетасында эшли башлый, һәм бу аның иҗатының төп юнәлешен билгели. 1977—1983 елларда «Казан утлары» журналында эшли, Казан телевидениесендә балалар өчен «Шигъри тәлгәшләр» тапшырулар циклын алып бара. 1983 елдан ул — Татарстан телевидениесенең баш редакторы, аннан соң — «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире. Күп еллар дәвамында Татарстан Балалар фондына җитәкчелек итә. Соңгы елларда ул иҗат дөньясында кайнау белән бергә күренекле дәүләт эшлеклесе буларак та танылды.

Шагыйрьнең шигърияте Сөн буйларыннан башланып китә. С. Хәким ул турыда: «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек...» Робертның шундый җыры бар. Популяр җыр. Актаныш якларыннан, Сөннән, Агыйдел буйларыннан башланып китә ул җыр. Балалык күңеленнән, балалык моңсулыгыннан башлана. Балалар әдәбиятына Роберт шушы җырдан кереп китмәдеме икән? Очы шунда кебек. Киң дөньядан, әкият дөньясы — табигать эченнән башлануы ошый миңа. Актаныш якларының чын поэзия урыны икәнлегенә үзем ул якларда булып та ышандым. ... «Шагыйрьне шагыйрь иткән нәрсәләр: җир, табигать, халык»,— ди.

Таллар япь-яшь...
Соң мин дә бит
Сөн буеның бер талы.
Таллар белән бергәләшеп
Үсәр идем бер тагы.

(«Сөн буе талсыз булалмый»)

Р. Миңнуллин иҗатында һәркем өчен газиз, иң миһербанлы затлар — әнкәйләр темасы аерым урын алып тора. Аның «Әнкәйнең ак чәчләре» (1986) китабы әниләргә мәдхия буларак күзаллана.

Сокланып карап торырлык —
Күзне ала алмыйбыз.
Әнкәйләрнең бөеклеген
Соңрак... соңрак аңлыйбыз.

(«Әнкәйнең ак чәчләре»)

Шагыйрьнең иҗаты, әлбәттә инде, балалар әдәбиятыннан аерылгысыз. Ул гади генә хәл-вакыйгадан балаларча көтелмәгән кызык таба:

Мин тырышкач, комбайн да
Бик тырышып ура шул.
Тырышабыз — ипекәе
Бигрәк тәмле була шул.

(«Тырышам»)

Р. Миңнуллинның балалар өчен җитди тонда язылган шигырьләре дә шактый. «Авыру йоклый иде», «Бер бомба да калмас иде», «Һәйкәлләрне тыңлыйк!» һ. б. шигырьләре әнә шундыйлар рәтеннән.

Шагыйрь үзенең «Балалар әдәбияты ни хәлдә?» дигән мәкаләсендә: «Бүгенге бала күңеле кискен борылыш кичерә... Укучылар бездән яңа сүз, заман сүзе көтә»,— дип язган иде. Яшьләрне заманга яраклы, һәрьяклап үскән шәхес итеп тәрбияләүдә, әлбәттә, Роберт Миңнуллинның лаеклы үз урыны бар. Аның киң колачлы иҗади эшчәнлеге халкыбыз тарафыннан югары бәяләнде, ул Х.К. Андерсен исемендәге дипломга лаек булды (1992 ел), аңа Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге премиясе бирелде (1997 ел), ул шулай ук Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды (1998 ел).

Сораулар

1. Р. Миңнуллинны ни өчен балалар шагыйре дибез? Гомумән, «зурлар» шагыйре «балалар» шагыйреннән ни белән аерыла?

2. Р. Миңнуллинның бүгенге иҗаты турында ниләр беләсез?

ТУГАН ТЕЛЕМӘ

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел — вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.

Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.

Әйтә алмыйм әле — ул җырлардан
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне!

Сорау

Туган тел турында күп шигырьләр язылган. Ә «Туган телемә» дигән шигырь алардан кайсы ягы белән аерыла?

ҺӘЙКӘЛЛӘРНЕ ТЫҢЛЫЙК!

Җиңүчеләр калка һәйкәл булып,
Һәйкәл булып баса Батырлар.
Ә Батырлар үлми ике тапкыр —
Алар хәзер мәңге балкырлар.

Һәйкәлләрне җансыз дия күрмә,
Һәйкәлләрнең җаны таш түгел.
Һәр һәйкәлдә күпме солдат җаны?! —
Һәйкәлләргә сыкрау хас түгел.

Гасырларның һәр минуты хәзер
«Бер минутлык тынлык» аларга.
Тып-тын алар шуңа —
Таш һәйкәлләр
Эчтән генә тиеш янарга.

Таш һәйкәлләр җырлый эчтән генә —
Бухенвальдта җырлый, Хатыньда...
Һәйкәл җыры —
Батырлыкка Гимн —
Мәхәббәт һәм Нәфрәт хакында.

Таш һәйкәлләр балкый эчтән генә,
Җырлый алар акыртын гына.
Һәйкәлләргә килик!
Гөлләр куйыйк!
Һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына!

Сорау һәм бирем

«Һәйкәлләрнең җаны таш түгел» һәм «Һәйкәл җыры — Батырлыкка Гимн» юлларын сез ничек аңлыйсыз? Аларны бер-берсе белән бәйләп аңлатыгыз.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Матур әдәбият, сүз сәнгате буларак, тормыш-чынбарлыкны сәнгать чаралары ярдәмендә чагылдыра. Аның төп сурәтләү предметы булып кеше тормышы, шәхеснең каршылыклы рухи дөньясы, яшәеш хыял-омтылышлары, характер сыйфатлары тора. Әдәби әсәрдәге вакыйга-күренешләр, образлар системасы аша язучы үзен, вакыт-чорга бәйле уйлануларын, эзләнүләрен, яшәештәге гыйбрәтле, кызыклы, фаҗигале хәлләрне чагылдыра. Әдәби әсәр, *бер яктан*, безне әйләнә-тирә дөнья, ерактагы һәм якындагы тарихыбыз, ул чорларда яшәгән кешеләрнең хыял-максатлары, тормышы белән таныштыра. *Икенче яктан*, сүз сәнгатендә кешелекне гасырлар дәвамында уйландырып килгән әхлакый һәм фәлсәфи сораулар чагылыш таба. *Өченче яктан*, кайсы чорда язылган яисә кайсы чорны чагылдырган булуына карамастан, әдәби әсәр безгә эстетик ләззәт бирә.

Матур әдәбиятны сүз сәнгате буларак һәм иҗади процесс үзенчәлекләре аша өйрәнә, аның идея-эстетик кыйммәтен, эчтәлек-формасын, төзелешен, сурәт чаралары байлыгын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын билгели торган фәнне ***әдәбият белеме*** дип атыйлар. Ул үз эченә *әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть* һәм *әдәбият теориясе* дигән тармакларны ала. **Әдәбият тарихы** әдәбиятны үсеш-үзгәрештә, үзенә генә хас үзенчәлекләре булган процесс итеп өйрәнә. Ул әдәби фактларны системага сала, аларга бәя бирә, әсәрнең яисә язучы иҗатының әһәмиятен, чор һәм әдәбият тарихындагы урынын билгели. **Әдәбият теориясе** әсәрнең төзелеш закончалыкларын, иҗтимагый функциясен, төр һәм жанр үзенчәлекләрен, юнәлеш-билгеләрен өйрәнә.

Әдәбият белеменең үзенчәлекле бер тармагы — **әдәби тәнкыйть.** Аның төп максаты чор әдәби процессын анализлау, әдәби факт-күренешләргә үз вакытында бәя бирүдән гыйбарәт. Әдәби тәнкыйть әсәрләрне заман күзлегеннән чыгып аңлата,

китап турында киң катлам укучыларда фикер-караш, мөнәсәбәт тудыра. Гомумән, тәнкыйть, бер яктан, аерым әсәрләрне яисә шул чор әдәби процессын өйрәнеп бәяләве белән, әдәби иҗади процессны оештыруга, үсеш-үзгәрешенә ярдәм итә; икенче яктан, китап укучы белән әдип арасында арадашлык вазифасын башкара, соңгысының сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен төшенергә, аңларга булыша; өченче яктан, эстетик төшенчәләрнең нигезен ачу-аңлату аша әдәби зәвыкны үстерергә ярдәм итә.

Әдәбият һәм тәнкыйть һәрвакыт бергә, янәшә яши. Чөнки әдәби әсәр авторның тормыш-яшәеш турындагы уйлану-фикерләүләренә бәйле шәхси иҗат буларак дөньяга килсә дә, ул укучыга атап языла. Әдип үз фикерләре белән башкаларны да таныштырырга тели, һәм, билгеле инде, аның күңелендә рухи хезмәте турында фикер ишетү теләге дә яши. Әйләнә-тирәдәге замандашларының кулъязма яисә басма әсәрне хуплаулары яки кире кагулары белән тәнкыйть башлана.

Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты гомуммөселман мәдәнияте белән бәйләнештә үсә. Ул чорлар сүз сәнгате синкретик характерда булып, әсәрләрдә дини, педагогик-тәрбияви карашлар, иҗтимагый-сәяси, тарихи һ. б. мәсьәләләр урын ала, авторның аларга караш-мөнәсәбәте белдерелә. Шулай ук әдәбият турында теоретик һәм тәнкыйди фикерләр дә шактый еш очрый. Моңа гарәп-фарсы һәм төрки халыклар әдәбиятларының үзенчәлеге булган күчмә сюжетларның киң таралышы да мөмкинлек бирә. Татар әдәби тәнкыйте формалашуда XIX йөзнең икенче яртысы мөһим урын алып тора.

Бу чорда җитди сыйфат үзгәрешләре кичереп, реализм юлына чыккан, шәхес һәм милләт мәсьәләләрен үзара тыгыз бәйләнештә өйрәнүче татар әдәбияты яңарыш юлына баса. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхреддин һ. б. хезмәтләрендә шул чор әдәбияты һәм әдипләре турында беренче фикерләр әйтелә, халыкның рухи тормышында әдәбият-сәнгатьнең урынын билгеләү омтылышлары ясала.

Татар әдәби тәнкыйтенең фән буларак формалашу чоры булып XX йөз башы санала. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Г. Камал. С. Рәмиев һ. б. әдипләрнең әдәби процесска яисә аерым әсәрләргә кагылышлы мәкалә-хезмәтләре дөнья күрә. Иң мөһиме: Җ. Вәлиди, Г. Кәрам кебек профессиональ тәнкыйтьчеләр үсеп чыга. Совет чорында татар әдәби тәнкыйте, җитди каршылыклар аша булса да, үсеш-үзгәрешен

туктатмый. 20—30 нчы елларда аның торышы Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Г. Гали исемнәре белән бәйле. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда бу өлкәдә М. Гайнуллин, Г. Халит, Г. Кашшаф, Х. Госман, Б. Гыйззәт һ. б. зур хезмәт куя. 60 нчы еллардан соң татар әдәби тәнкыйтенең үсеше И. Нуруллин, Р. Мостафин, Ф. Хатипов, М. Хәсәнов, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин һ. б. исемнәре белән бәйле.

Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең торышы җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни шартлар, гомумәдәби процесс, үткән чорлардагы тәнкыйди фикернең йогынтысы, бу өлкәдә эшләүчеләрнең теоретик әзерлеге, традицияләр дәвамчанлыгы, буыннар бәйләнеше һ. б. белән аңлатыла. XX гасырның 80 нче елларында җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә башланып киткән үзгәрешләр рухи-мәдәни күренеш булган әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләргә дә зур йогынты ясый.

Җанлы әдәби процесс белән турыдан-туры бәйләнгән тәнкыйтьнең бу чордагы үсеш-үзгәреше дә бертөрле генә түгел. Җәмгыятьтәге чикләүләрдән, мәдәни өлкәдәге цензурадан, соцреализм кысаларыннан арынгач та, әдәбият һәм тәнкыйть өлкәсендә көтелгән үсеш күренми. Төп мәсьәлә, билгеле, иҗатчы шәхесе белән бәйле.

Тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашлары, теләк-максатлары тәнкыйть язмасының жанр формасында һәм эчтәлегендә чагылыш таба. Тәнкыйть объектының төренә һәм эчтәлегенә карап тәнкыйди язмаларның дистәләгән жанрын аерып чыгаралар. Алар арасында аеруча киң кулланылганы булып библиографик язма, рецензия-бәяләмә, монографик мәкалә, проблемалы мәкалә, әдәби күзәтү, тәнкыйди-биографик очерк, әдәби портрет, эссе кебек жанрлар санала.

Библиографик язма өчен оперативлык, ягъни яңа чыккан китаплар, әдәбият яңалыклары турында мәгълүмат бирү хас. ***Рецензия-бәяләмә*** дип яңа дөнья күргән әсәрнең төп проблемаларын яктырту аша гомуми бәя биреп язылган мәкалә атала. Тәнкыйтьче, әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтеп, китап укучыларның игътибарын җәлеп итә.

Тәнкыйтьне җанландыру, чор әдәби процессы белән бәйләнешен арттыру һәм китапны пропагандалау вазифасы ягыннан китапка күзәтү ясау мөһим роль уйный. Шуңа да әлеге бәядә әсәрнең эчтәлек һәм формасына бәйле сәнгати эшләнешен, яңалыгын объектив рәвештә билгеләү нигез шартлардан са-

нала. Чөнки шул рәвешле китап турында киң катлам укучыда фикер-караш, мөнәсәбәт тудырыла, һәм ул еш кына әлеге иҗат җимешенең шул чор әдәбиятындагы урынын билгеләүгә дә йогынты ясый. ***Монографик мәкаләдә*** язучының иҗатына яисә аерым әсәренә анализ шактый киң әдәби һәм иҗтимагый күренешләр белән бәйләнештә бирелә. Шуның белән бергә, тәнкыйтьченең фикер-карашлары теоретик һәм методологик нигезләмәләр белән үрелеп бара. Рецензиядән ул күләме, төзелеше һәм авторның социаль, фәлсәфи, эстетик гомумиләштерүләргә йөз тотуы белән дә аерыла.

Монографик мәкаләдә һәм рецензиядә теоретик мәсьәләләр тәнкыйтьченең карашларын, анализ нәтиҗәләрен методологик нигезләү өчен урын ала. Аерым очракларда алар тикшерү объекты буларак үзәк урынны били. Андый язмалар ***проблемалы мәкалә*** жанрын тәшкил итә, һәм алар, гадәттә, әдәбият теориясе, эстетика буенча дөнья күргән хезмәтләр белән бәхәс рәвешендә языла. Мондый язмаларда да аерым әсәрләргә җентекле анализ ясалырга мөмкин. Әмма әдәби материал теоретик мәсьәләләрне ачыклау, авторга үз карашларын яклау өчен хезмәт итә.

Тәнкыйди язмаларда әдәбиятның аерым чорын, аның үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен бәяләү ***әдәби күзәтү*** жанры буларак билгеләнә. Тәнкыйтьченең өйрәнү предметына бәйле рәвештә алар еллык күзәтү, аерым бер жанр торышына күзәтү, теге яки бу әдәби юнәлеш, агымга күзәтү һ. б. дип билгеләнә. Әдәби күзәтү, нигездә, чорның тарихи-иҗтимагый, социаль-мәдәни вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә алып барыла, һәм анда нинди дә булса әдәби тенденциянең үзенчәлекләре тикшерелә. Мондый хезмәтләрдә күп санлы әсәрләр бәяләнә, чагыштырып нәтиҗәләр ясала.

Тәнкыйди-биографик очеркта әдип иҗатына анализ тормыш юлын күз алдына бастыру белән үрелеп бара. Биографик фактларны барлау үзмаксат булып тормый, игътибар үзәгендә иҗат үзенчәлекләре, аерым тема-мотивлар, мәсьәләләр һәм дөньяга карашның һ. б. язучы биографиясе призмасы аша чагылуы тора. ***Әдәби портретта*** язучының иҗат үзенчәлеге бәяләнә. Тәнкыйтьче әсәрләрне анализлау аша әдипнең тормыш-чынбарлыкны чагылдыру, сәнгати фикерләү үзенчәлеген ача. Әлеге жанрда биографик материаллар, истәлекләр, башка язучылар белән чагыштырулар файдаланылса да, соңгылары ярдәмчел вазифа башкара. Әдәби портрет хәзерге тәнкыйтьтә шактый актив кулланыла.

Әдәби процесска, заман таләпләренә бәйле рәвештә тәнкыйди жанрлар билгеле бер үзгәреш кичерә. Соңгы елларда татар әдәби тәнкыйтендә *эссе* жанры активлашты. Аның үзенчәлеген язучы иҗатына анализда тәнкыйтьче «мин»енең керешеп китүе, лирик һәм публицистик чигенешләр, истәлек-мемуарлар белән үрелеп бирелү билгели. Тәнкыйть сүз сәнгате тарихы, әдәбият теориясе белән тыгыз бәйләнештә яши, алар бер-берсен баетып, тулыландырып тора.

Бүгенге татар әдәби тәнкыйтенең ныклап аякка басуы, тагы да җанлануы үз иҗат йөзләрен тапкан өлкән буын вәкилләре Р. Мостафин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Р. Сверигин, С. Хафизов, Ф. Хатипов, Н. Хисамов, Ф. Мусин, алар янәшәсендә атлаган А. Хәлим, Ә. Мәхмүдов, Ф. Галимуллин, Мөдәррис Вәлиев, М. Вәлиев, Ә. Сәхапов, Г. Гыйльманов һ. б., ныклы адымнар белән әлеге тармакка килүче Д. Заһидуллина, Р. Зарипов, И. Вәлиулла, Р. Фәтхрахманов, Ә. Закирҗанов һ. б. актив эшчәнлеге белән бәйле.

Түбәндә аерым шәхесләрнең әдәби-тәнкыйди эшчәнлегенә кыскача тукталып үтәбез.

Мансур Хәсәнов әдәбият белеменә 1960 елларда килә һәм тиз арада үзен теоретик әзерлекле, әдәбият тарихын яхшы белүче галим итеп таныта. Аның «Галимҗан Ибраһимов» (1977), «Интернационализмның җанлы традицияләре» (1980) исемле монографияләре сүз сәнгате тарихын теоретик нигездә өйрәнүнең уңышлы үрнәге буларак бәяләнә. «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре» (1991) хезмәтендә ул әдәбият фәне алдында торган бурычларны ачыклый һәм әдәбият тарихын өйрәнүнең төп принципларын аерып чыгара.

Тәнкыйтьче буларак **Тәлгат Галиуллинның** кызыксыну өлкәсе — татар шигърияте. Ул әдәбият тарихының аерым чорларына да, замандашларының әдәби портретларына да бердәй тигез мөрәҗәгать итә. Аның «Еллар юлга чакыра» (1975), «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985), «Дәвамлылык» (1987), «Илһам чишмәләре» (1988) кебек хезмәтләре җитди яңалык буларак кабул ителде. Соңгы елларда дөнья күргән «Шигърият баскычлары» (2002), «Шәхесне гасырлар тудыра» (2003) китапларында татар шигърияте тарихына һәм аның бүгенге торышына заман күзлегеннән бәя бирелә, төп үсеш-үзгәреш тенденцияләре билгеләнә.

Азат Әхмәдуллинның төп өйрәнү объекты булып татар сәхнә әдәбияты тора. Аның «Фәтхи Борнаш» (1979), «Татар

драматургиясе» (1983), «Дөреслеккә ирешү юлында» (1993), «Офыклар киңәйгәндә» (2003) китапларында драматургиянең аерым чорлардагы үсеше, табыш-югалтулары эзлекле рәвештә барлана. Тәнкыйтьче-галим күп санлы әдипләрнең иҗат портретын тудыра, аларның байтагын киң катлам укучылар өчен беренче тапкыр ача.

Әдәбиятыбызның проза төрен монографик планда тикшерүче галимнәребезнең берсе — **Флүн Мусин.** Ул «Тарих һәм заман» (1974), «Чор белән авываздаш» (1983) исемле китапларында чорның әдәби процессын җентекләп өйрәнә, аның милли сыйфат-билгеләрен аерып чыгара, дистәләгән әдәби портретлар тудыра. «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 томлыгында урын алган бүлекләрдә ул татар әдәбиятының аерым чорларына хас тенденцияләрне аерып чыгара, системага сала. Галимнең соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрендә XX гасыр татар әдәбиятын бербөтен итеп һәм милли максатчан өйрәнү мәсьәләләре алга куела. Бу исә сүз сәнгате тарихын өйрәнүчеләргә әдәбиятыбыз традицияләрен һәм заманга бәйле барлыкка килгән яңалыкларны үзара бәйләнештә тикшереп бәяләүгә юл ача.

Шулай итеп, татар әдәбият белеме, шул исәптән әдәби тәнкыйть, сүз сәнгате белән тыгыз бәйләнештә үсеш-үзгәреш кичерә. Һәр чорга хас үзенчәлекләрне аерып чыгару аша әдәбият тарихының сәхифәләре языла.

Сораулар һәм биремнәр

1. Матур әдәбиятның төп вазифа-бурычларын күрсәтегез.

2. Әдәбият белеме фәне нәрсәне өйрәнә? Аның төп тармакларын атагыз һәм кыскача аңлатма бирегез.

3. Татар әдәби тәнкыйте кайчан формалаша, һәм ул кемнәр исеме белән бәйле?

4. Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең максаты нидән гыйбарәт?

5. Тәнкыйтьнең киң кулланылган жанрларын атагыз.

6. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә актив эшләүче галим-тәнкыйтьчеләрнең эшчәнлегенә кыскача күзәтү ясагыз.

ЙОМГАК

Бу дәреслек-хрестоматиядә 1917 елдан соңгы татар әдәбияты бербөтен әдәби процесс итеп каралды һәм бәяләнде. Хәзерге иҗтимагый-сәяси һәм идеологик үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, әлеге процессны, үткәндәге кайбер берьяклырак карашлардан арынып, төрле яктан һәм объектив төстә анализлауга да дикъкать ителде.

Совет илендәге әдәбиятлар, шул исәптән татар әдәбияты да, нигездә яңа идеологиягә буйсындырыла һәм безнең халыкка да бәхетле тормыш алып килде дип пропагандаланган социализмга дан җырлаучыга әверелдерелә. Совет җәмгыятен кешелек тарихында иң прогрессив һәм гадел иҗтимагый система дип бәяләп, әлеге пропаганда әдәбиятларны башка төр яшәү рәвешләренә үтә тәнкыйтьчел карашка этәрде. Мондый позицияне теоретик планда да нигезләү максатында, СССР язучыларының Беренче бөтенсоюз съездында (1934) социалистик реализм илдәге күп санлы әдәбиятларның бердәнбер иҗат методы дип раслана һәм аның төп принцибы итеп сыйнфыйлык билгеләнә. Шушы принципка нигезләнеп, татар әдипләре дә Совет чорында тормышта сыйнфый каршылыкларны яки дошманнарны эзләү белән мавыгалар. Бу хәл әдәбиятта чынбарлыкны һәм кешеләрне шактый берьяклы гәүдәләндерүгә китерә. Үткәндә төрлечә изелгән халыкларга бәхетле тормыш китерде дип бәяләнгән совет җәмгыятен күркәм төсләрдә генә сурәтләү белән бергә, кайбер әсәрләрдә әлеге җәмгыятькә күпмедер тәнкыйтьчел караш та чагыла. Бу хәл Совет чоры әдәбиятын хәзер үткәндәгечә гел берьяклы гына, ягъни ул вакыттагы идеологиягә турылыклы хезмәт итүче дип кенә карарга ярамаганлыгын, аның шактый катлаулы һәм каршылыклы процесс булганлыгын ачарга кирәклеген искәртә. Хәзер Совет чоры әдәбиятыннан бигрәк тә Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил кебек әдипләр иҗатын реаль төрлелегендә һәм кат-

лаулылыгында өйрәнү кирәклеге ачыклана. Мондый анализ татар әдипләренең социализм шартларында яңа идеологиягә еш кына инанып хезмәт итү белән бергә, кайчак мәгълүм идеологик кысаларда гына кала алмаганнарын, кайвакыт яңа тормыш турында объективрак та фикер йөрткәннәрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Бу хакыйкать, аерым алганда, татар халкының Совет чорында яшәешен сурәтләүгә карый. Ачыграк әйтсәк, кайбер әсәрләрдә халкыбызның Совет илендәге реаль хәле дә күпмедер чагылыш таба.

60 нчы еллардан башланган яңарыш чоры әдәбиятында бу мәсьәләгә игътибар тагын да көчәя. Революциягә кадәр формалашкан милли әдәби традицияләрне кабаттан торгыза башлап, татар әдипләре янә милләт яшәеше һәм язмышы белән ныклабрак кызыксынырга тотыналар, бу өлкәдә борчу уята торган мәсьәләләргә дикъкатьләрен көчәйтәләр. Болар исәбенә татар авылы, милли рухи-әхлакый кыйммәтләрнең язмышы, хәзерге зыялыларыбызның иҗтимагый-әхлакый йөзе, табигатькә мөнәсәбәт һ. б. керә. Милләт турында уйлаганда, татар әдипләре, сүз ирегеннән файдаланып, халкыбыз тарихына, бигрәк тә аның моңа кадәр совет идеологиясе тарафыннан онытылуга дучар ителгән яки бик каралтып күрсәтелгән элекке дәверләренә игътибарларын арттырдылар һәм әсәрләрендә аның тамырларының атаклы төрки цивилизациясенә барып чыгуын, шунлыктан бик борынгыдан аң-белемгә омтылуын чагылдырдылар. Халкыбызның төрле җирләргә таралып яшәвен искә алып, соңгы вакытларда әдәбиятта тарихи Ватаныннан читтә яшәгән милләттәшләребез тарихына һәм хәзерге яшәешенә дә дикъкать ителә башлады. Татарның күпгасырлык гомер юлын һәм яшәү офыгын тулырак колачлый һәм аның бик катлаулы тарихи язмышын дөресрәк тасвирлый барып, әдәбиятыбыз, гомумән алганда, узган гасыр ахырына үзенең милли вазифасын нәтиҗәлерәк башкаруга ирешә.

ЭЧТӘЛЕК

20 нче еллар әдәбияты 5

Галимҗан Ибраһимов 8
Казакъ кызы 10
«Казакъ кызы» романы 49
Кәрим Тинчурин 51
Сүнгән йолдызлар 53
«Сүнгән йолдызлар» драмасы 70
Драма жанры турында 74
Һади Такташ 75
Мәхәббәт тәүбәсе. 77
«Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы 86

30 нчы еллар әдәбияты 88

Гадел Кутуй 90
Тапшырылмаган хатлар 92
«Тапшырылмаган хатлар» повесте 112

40—50 нче еллар әдәбияты 115

Муса Җәлил. 118
Хуш, акыллым 119
Кошчык 121
Бүреләр 122
«Тупчы анты» җыентыгы 124
«Моабит дәфтәрләре» җыентыгы 125
Фатих Кәрим 128
Сибәли дә сибәли 129
Разведчик язмалары 130

1960—2000 еллар әдәбияты 141
1960—2000 еллар поэзиясе 146

Гамил Афзал 150
Өф-өф итеп 152
«Кызыл балчык» промартелендә 154
Мыек борам 154

Зөлфәт 156
Тылсым 157
Дүрт җыр 158
Ренат Харис 160
Кеше кайчан матур? 162
Хәл-әхвәл 163
Хәсән Туфан 164
Ә үткәнгә хатлар бармыйлар 116
Кайсы атта сиңа кайтып була? («Кармәт истәлекләре» циклыннан) 167
Агыла да болыт агыла 168
Х. Туфан иҗаты турында 169
Сибгат Хәким 173
Гел кояшка карый тәрәзәләрең 175
Башка берни дә кирәкми 176
Туган як җырчысы 176
Равил Фәйзуллин 179
Яздан аерып булмый Тукайны! 180
Якты моң 181
Рәдиф Гаташ 183
Ирләр булыйк! 184
Укытучы 185

1960—2000 еллар прозасы 186

Фатих Хөсни 189
Утызынчы ел 191
Ибраһим Гази 208
Онытылмас еллар 209
Мәхмүт Хәсәнов 232
Язгы аҗаган 233
Әмирхан Еники 266
Әйтелмәгән васыять 268
«Әйтелмәгән васыять» хикәясе 285
Мөхәммәт Мәһдиев 287
Бәхилләшү 289
«Бәхилләшү» повесте 318
Нурихан Фәттах 321
Итил суы ака торур 323
«Итил суы ака торур» романы 351
Мөсәгыйт Хәбибуллин 354
Атилла 356
«Атилла» романы 382

1960—2000 еллар драматургиясе 384

Хәй Вахит 395
Беренче мәхәббәт 396
«Беренче мәхәббәт» драмасы 408

Туфан Миңнуллин 410
Үзебез сайлаган язмыш 412
«Үзебез сайлаган язмыш» драмасы 424

Балалар әдәбияты 429

Җәвад Тәрҗеманов 434
Әнием тәсбихы 436
Хәкимҗан Халиков 437
Тавык йөрәк 438
Чынлап аксады 439
Җәүдәт Дәрзаман 440
Ышан бары йөрәк авазыңа 441
Элмә 442
Шәүкәт Галиев 443
Урман күчә урамга 445
Багана 446
Роберт Миңнуллин 448
Туган телемә 450
Һәйкәлләрне тыңлыйк! 450

Әдәби тәнкыйть 452

Йомгак 458

Учебное издание

Мусин Флюн Муслахович
Хабибуллина Закира Нуриевна
Закирзянов Альфат Магсумзянович

ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Учебник-хрестоматия для 11 класса
средней общеобразовательной школы с русским языком обучения
(для учащихся-татар)

Издание третье, переработанное

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Мусин Флүн Мөслахович
Хәбибуллина Закирә Нуриевна
Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗанович

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
11 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия
(татар балалары өчен)

Яңадан эшләнгән өченче басма

Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы
һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, А. М. Закирова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләр
Л. Р. Вафина, Э. Ф. Нурмөхәммәтова

Тышлыкта Р. Заһидуллин рәсеме файдаланылды.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 01.11.06. Форматы $60\times90^1/_{16}$. Офсет кәгазе.
«Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 29,0 + форз 0,25.
Нәшер-хисап табагы 28,38 + форз. 0,38. Тиражы 21 500 д. Заказ 3-970.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Дәреслекнең саклану дәрәҗәсе

	Укучының исеме һәм фамилиясе	Уку елы	Дәреслекнең торышы	
			ел башында	ел азагында
1				
2				
3				
4				